Мәдинә Маликова
Тылсым. Шәфкать
Романнар
КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2007

УДК 821.512.145-31
ББК 84 (2 Рос=Тат)-44
М19

Маликова М.Г.

Тылсым. Шәфкать: романнар / Мәдинә Маликова.— Казан: Татар. кит. нәшр., 2007.— 400 б.— 2500 д.— ISBN 978-5-298-01594-3

Мәхәббәт һәм иман... Боларның бер-берсенә катнашы, мөнәсәбәте бармы? Иманлы кеше гашыйк булса, үз-үзен ничек тота да, имансызы нинди гамәлләр кыла? Аның кылганнары мәгъшугы белән ике арада гына каламы, әллә бүтәннәргә дә таш булып килеп бәреләме? Бу китап менә шундый гыйбрәтле язмышлар турында.

ISBN 978-5-298-01594-3
© Татарстан китап нәшрияты, 2007
© Маликова М.Г., 2007

Тылсым

Нурга төренгән фәрештә –
Ah, сөю, әллә синме?
Бер кулыңда — баллы касә,
Берсендә — утлы сөңге...

* * *

Яшен вакытында биек агач астына ышыкланырга ярамый. Ялан кырда ялгыз үскәненә якын тору аеруча куркыныч. Андыйлар яңгырдан шәбәргән кешеләрне генә түгел, болытлар арасындагы ут сөңгеләрен дә үзенә тарта.

Тәҗрибәле өлкәннәр бу хакта җай туры килгән саен искәртеп тора. Тик, күрәсең, кемдер аларның сүзен ишетми кала, кемдер ишеткәнен күңеленә салмый. Ә бәлки, давылга эләккәч, онытып җибәрәдер? Андый чакта зиһен чуала, чыланып калтыранган тән исә ихтыярсыздан якында гына киңәеп утырган каенның куе ябалдашы астына омтыла.

Һәм кеше юеш аркасын җылы, нык кәүсәгә терәп, җиңел сулыш алгач кына, кинәт...

Аннан соң ни булганын адәм баласы үзе аңламый-сизми дә кала. Күзне чагылдырган яктылык, колак тондыргыч шартлау исә, еракларга таралып, башка-бүтәннәрнең өнен ала, күңеленә шом сала.

Алсу кофта, джинсы чалбар кигән, кара чәчен киң ал тасма белән бәйләгән, кулына ак пластмасс чиләк тоткан унбиш яшьлек кыз белән нәкъ менә шулай булды да. Көтмәгәндә болытлар куерып, кинәт яңгыр коя башлагач, ул, аны-моны уйлап тормастан, юлдан ун-унбиш адымда киңәеп үскән карт каенга таба йөгерде. Агачның куе ябалдашы астына кереп, сыгылмалы гәүдәсе белән кытыршы кәүсәгә сөялде дә, битендәге тамчыларны сыпырып, җиңел сулап куйды. Шунда кинәт җир-күк ярылгандай булды... Яшен сөңгесе җиргә сеңеп, шартлау авазы еракларга таралып тынганда, урталай ярылган, көйрәп-пыскып торган каен кәүсәсе янында кызыкай күренми, ишелеп төшкән ботак-яфраклар арасында ак чиләк кенә аунап ята иде.

* * *

...Ah, нилектән давыллар кинәт куба да, яшенле яңгырлар каян көч алып, һич көтмәгәндә дөбердәп-шатырдап килеп җитә икән?

Иртән көн аяз, тыныч иде. Зәңгәрсу күк гөмбәзенә ак болыт мендәрләре бизәү өчен генә элеп куелган, очкычтан калган ак тасма да оста рәссамның тылсымлы пумаласы белән генә сызылган кебек иде. Авыл урамында тезелеп үскән биек-биек тирәк һәм каеннарның куе ябалдашларында ник бер

яфрак тибрәлсен дә ник бер шикле өн колакка чалынсын. Хәтта каргалар да тавыш-тынсыз гына агач башларындагы оялары тирәсендә кайнаша, көн кичәге кебек үк эссе булырга охшаган иде.

Мунчада керләр юып, аларны ишегалдындагы бауларга элеп азапланган Әлифә көнбатышта болыт мендәрләренең ястыкка, аннары түшәккә әверелүен, аннары тоташ юрган булып бер-берсенә кушылуын сизми дә калды. Ул арада офык артыннан, кояшны-күкне каплап, карасу-соры болытлар ябырылды, шомлы дөбердәү ишетелеп-ишетелеп алды, тупыл башларында куркынган каргалар каркылдашты. Бәлки әле, яумас, читләтеп үтәр дигән өмет белән газ плитәсе тирәсендә кайнашкан Әлифә урамнан тузанлы өермәчекләр уйнап узганын күреп ашыгып чыкты да керләрен баудан алып, ләгәнгә тутырырга кереште. Ул кире кергәндә, түбә калаенда тамчылар биешә, ачык тәрәзәдән җил бәреп, мул кызыл чәчәкле яран гөле идәнгә килеп төшкән иде. Әлифә ах итеп тәрәзәләрне япты. Ул арада пыялаларга шап-шап эре тамчылар бәрелеп чәчелде. Көчле җил тоташ койган яңгырны урам буйлатып дулкын-дулкын өереп йөртте. Идәннән чәчкәләре сынып чәчелгән гөлне, туфракны, чүлмәк кыйпылчыкларын җыеп чиләккә тутырып азапланган Әлифә әледән-әле тәрәзәдән урамга күз сирпеп алгалады. Зәңгәр коймадан биегрәк булып үскән бояр гөлләре арасыннан берничә чыланган баш чагылып узды. «Әһә, кайтып җиттеләр! — дигән уй Әлифәнең йөзендә елмаю балкытты. — Чыландыгызмы? Шул кирәк сезгә! Болытлар куера башлауга өйгә чабарга кирәк иде. Өстегезгә чиләкләп койганны көтеп тормаска... Яшьләр шул! Җиләк күрсәгез, дөньягызны онытасыз...»

Шул сүзләрен менә-менә ишектән килеп керәчәк Әнисәгә әйтергә әзерләнеп, идәнгә тезләнгән килеш сагаеп тыңланды ул. Әмма ишегалды ягыннан яңгыр шавы гына ишетелде, капка ачылганы сизелмәде. Әлифә, аягына басып, үрелеп ян тәрәзәгә карады: чыланган башлар түбән очка таба ераклаша, капкадан керүче күренми. Иртән җиләккә киткән кызлар өйләренә таба сыптыра, Әнисә генә юк... Кайда калды икән?

Яңгыры да бигрәк хәтәр ява бит аның. Яшен уты күзләрне чагылдырып уйнаклап ала да, бөтен дөньяны тетрәндереп күк күкри, аннары яңгыр отыры көчәеп, урап-урап коярга керешә. Әнә тәрәзә пыялалары черт-черт итә башлады: боз ява лабаса, боз!

Их, ялгышты Әлифә, ялгышты. Яше алтмышка җитеп тә акылга туймады. Әнисәне үзе кебек үсмер кызларга гына ияртеп урманга җибәрергә ярый идемени?

Аның өчен ят, чит урманга... Юлдашлары тирәсендә, күздән югалмыйча йөри торган булса икән. Чәчәкләргә, кошлар сайравына мөкиббән булып, җиләкле урынга юлыккач тәмам дөньясын оныта торган гадәте бар шул аның. Хыялый бит ул!

Урманга барсалар, Әлифә аңа гел кычкырып тора:

— Әнисә-әү-ү!

Әле ул тиз генә җавап бирсә икән. Дәшсә дә, чак ишетелерлек итеп кенә әйтә:

— Кошларны куркытасың бит, апа... — ди.

— Ә син юкка чыкма! Җырлар идең, ичмасам. Мондагы кызлардан өйрәнгән җырларыңны...

— Ә ник? Кошлар җырламасын өченме?

— Татарның кошы җырламый, сайрый! Урыслар гына ул «птицы поют» диләр.

— Ну... сайрасыннар, комачауламыйк!

Кызның алсу кофталы, джинсы чалбарлы нечкә сыны янә куе яшеллек арасына кереп чума.

— Әнисә-ә!

Дәшми кызый, аның өчен кошлар гына сайрап җавап бирә.

...Ә бу юлы кызлар туктаусыз аны гына күзәтеп йөрде микән? Ай-һай ла... Әлифә шулай дип уйлап кына өлгерде, тәрәзәләрдән ургылган яктылыктан күзләре чытырдап йомылды, коточкыч шартлаудан тезләре йомшап чүгелде. Аллаһемә, ләхәүлә вәлә куәтә... Нәрсәнедер сукты бу! Якында гына шикелле. Әллә соң?..

Куркыныч уйдан Әлифәнең сулышы киселде, тамагына ачы төер утыргандай булды.

«Риммаларга кереп ышыкламгандыр», — дип, тарсылдап типкән йөрәген тынычландырырга тырышты ул. Аларның өе югары очта, урам башында... Шунда гына булса ярар иде...

Әлифә чөйдән плащын алды да, аягына галушлар гына элеп, урамга чыкты. Абына-сөртенә югары очка барып җиткәнче, яңгыр астында манма тиргә батты, бит очлары янып чыкты.

Римма әнисе Раилә белән кара-каршы утырып җиләк чөмлиләр иде. Кызның җирәнсу чәче, чыланып, башына сыланган, чырае турсайган.

— Римма, Әнисә кая?..

— Исәнме, Әлифәтти, — дип урыныннан кузгалды Раилә. — Сезнеке кайтмадымыни әле?

— Кайда калдырдыгыз сез аны? — диде Әлифә, карашын кыздан алмыйча.

— Безме?.. Без калдырмадык... Яңгыр тама башлагач, кычкырдык...

— Ни дип?

— Әйдә кайтабыз, дип.

— Ә ул ни диде?

— Ишетмәдем... коя башлагач, торып чаптык...

— Бер-берегезне карабрак йөрегез, югалтышмагыз, дип әйттем бит мин сезгә... Кунак кызына игътибарлырак булырга кирәк иде...

Раилә дымлы җиләктән чыланган бармакларын итәгенә сөрткәләде. Кыска җиңле чуар халатына көчкә сыйган тулы гәүдәле, кызыл чырайлы бу хатыннан үзенә-үзе ышаныч бөркелеп тора иде.

— Ул сарык түгел, безнекеләр көтүче түгел, — диде ул, каты гына итеп. — Аның артыннан йөрсеннәрме, җиләк җыйсыннармы...

— Бергә чыгып киттеләр, бергә кайтсыннар иде...

— Үзенең колагына ныгытып киртлисең калган, иптәшләреңнән калма, дип...

Кеше баласына бәйләнгәнче, үзеңнекен кулда тота бел дигән сүз иде бу. Тик Әлифә кинаяне аңларлык хәлдә түгел иде.

— Бая бик каты шатырдады, нәрсәне сукты икән? — дип, Раиләдән юату сүзләре өмет итеп, күксел күзләре белән мөлдерәп карады ул.

— Сукты бугай шул. Минем дә котны очырды. Сезнең тирәдә түгел инде алайса?

— Авыл очындагы берәр агачка бәрде микән әллә? — Әлифә кулын күкрәгенә куйды. — Әллә нәрсә, йөрәгем кыса...

— Әнисә белән берәр хәл булгандыр, шуңа йөрәгем кага, димәкчеме әллә син? Тапкансың икән! Үз балаң булса, бер хәл иде. Анда да әле аналарның сирәге андыйны тоя. Ә монда җиде ят дигәндәй...

— Нишләп җиде ят булсын, үз каным! Бертуган апамның баласының баласы!

— Аның әле синнән якын үз анасы бардыр ла! Кем дисең әле? Чегәнме?.. Мондый гына яңгырга чегәннең исе китеп тора димени? Бер дә кайгырма, берәр ышык җирдә посып ятадыр. Кояш чыгуга ялтырап кайтып керер... Чиләгем тулсын дип, яңадан җыярга тотынмаса... Чаманы белми, диләр бит, көненә дүртәр чиләк җыймыйча туктамый, диләр...

— Арттырып сөйлиләр... Ике чиләк җыйганы бар барын... Комсыз түгел лә ул, тырыш бала!

Шулай диде дә Әлифә борылып чыгып китте. Әнисә өйгә кайтып, аны көтеп утырмый микән?

Галушлар болдырның аскы баскычында калган икән, мөлдерәмә булганнар. Әлифә аларның суын түгеп тә тормады... Йөрәк сыкрый, йөрәк нидер сизә иде шул!

Чүп өстенә чүмәлә дигәндәй, күршеләр турыннан узганда, кош баласының өстенә баса язды тагын... Тупыл башындагы оясыннан җил бәреп төшергән мескенне. Бу да начар фал булып тоелды. Зур авызын ачып, йомшак йонлы канатларын җәеп азапланган кошчыкның кыяфәте күңелдәге шомны тагын да күпертте. Ярый ла Әнисә агач астына ышыкланмаган булса... Бигрәк тә баек агачтан ераграк торса...

* * *

Яңгыр астына район үзәгеннән кайтып килгән яшел «уазик» та эләкте. Эре тамчылардан шадраланган юлдан үргә менеп килгәндә, машинадагы ике кеше кинәт ялтыраган яшен яктысыннан күзләрен чытырдатып йомып, коточкыч шартлаудан муеннарын җыердылар.

— Аллаһемә! Минем түбәгә бәрде дип торам! — диде кырык яшьләр тирәсендәге шофер. Һәм кабаланып рульне боргаларга тотынды: машина юеш асфальтта таеп, юл читендәге чокырга борылган иде. — Чак мәтәлмәдек. Әле дә ярый рульгә сине утыртмадым. Ә син сораган буласың... Бу юлны беренче күрүең, белмим, нишләп бетәр идең...

Аның янәшәсендәге егетнең кояшта янган чыраеннан кан качкан, иреннәре кысылган иде. Тырыша торгач, шофер машинаны турылады, башын алгарак сузып, парланган пыяла аша юлга текәлде. Бераз читтәрәк, клевер басуы эчендә пар чыгарып утырган каен кәүсәсен күрми дә үткән булыр иде, егет шәйләп алды.

— Сабит абый, карале, теге агач нишләгән ул?

— Кайсы агач? Бәлеш, яшен суккан бит моны! Әйтәм аны янда гына кебек иде! Бетергән бу каенны. Тураган да ташлаган, кибән итеп өеп тә куйган.

— Нинди ак нәрсә ята анда?

— Нидер бар бугай шул. Карарга кирәк. Ботак астында берәрсе ятмый микән...

Сабит тормозга басты. Машинадан төшеп, пычрак су тулы канауны сикереп чыктылар, чыклы клеверны ерып, эчкәрәк уздылар. Кроссовкалар, джинсы чалбар балаклары манма булды, күлмәкләр, чәч-баш чыланды. Чыннан да, ботак өеме янында кечерәк кенә ак чиләк ауный, үлән арасына җир җиләге сибелгән. Яфраклар астында сандалилы аяклар шәйләнде... Моны күреп, икесенең дә тыны кысылды...

Ашыгып, ботакларны араларга керештеләр.

— Әнисә бит бу! — диде Сабит. — Ярый әле синең күз очлы, Мидхәт! Күрми дә үтеп китә идек бит!

Мидхәт кызның битенә ябышкан яфракларны алгалый иде. Кымшанган ботаклардан эре тамчылар коелды, әмма кызыкайның йомык күз кабаклары тибрәнмәде. Егет тетрәнеп куйды. Үсмер

бала лабаса бу! Ал тасма астыннан бүселеп чыккан эре кара чәч бөдрәләре арасында томрап торган бит, дугаланып килгән кашлар, озын керфекләр. Бераз чөенке, килешле борын, нәфис уелган алсу иреннәр, алар арасыннан күренеп торган эрерәк, әмма тип-тигез ак тешләр... Иң нык җәлеп иткәне исә кечерәк кенә миң табы иде. Миңле кызлар күп, ә менә сөйкемле тамчысы ияк уртасындагы чокырга тамганы... Дөньяда андый тагын берәү бар микән? Гади миң генә түгел, мөгаен, илаһи бер көчнең тылсымлы тамгасы иде бу...

Мидхәт, сокланудан айнырга тырышып, күзләрен чет-чет йомгалады. Лачма су яфраклар өстенә тезләнде дә, кызның күкрәгенә башын салып, йөрәк тибешен ишетергә тырышты. Әмма чыланган ефәк аша яшь тәннең кайнарлыгы гына сизелде. Кечкенә, тыгыз күкрәк алмасы астында шомлы тынлык иде. Әллә... үлгәнме?..

Йөзендә үсмерлек ярылып ятса да, тыгыз, калку күкрәкләренә караганда, җитлегеп кенә килгәнгә охшый. Аңына килә алмас микәнни?! Бөтенләй китте микәнни инде?

Ясалма сулыш алдырырга кирәк... Мидхәт моның ничек эшләнгәнен исенә төшерергә тырышты. Институтның беренче курсын тәмамлагач, спорт лагерена китәр алдыннан, ашыгыч ярдәм итү курсларына йөргәннәр иде бит. Авызына сулышыңны өрергә дә йөрәк турына өч-дүрт тапкыр каты-каты басып алырга... Иптәш егетләрне идәнгә сузып салып кыланып та караганнары булды... Ул чакта бик ансат кебек иде дә бит... Хәзер зиһен чуалган шул.

Мидхәт кызның битенә ябышкан чәч бөтеркәләрен артка сыпырды да иреннәрен аның ярым ачык авызына терәде. Тетрәнеп сулышын өрде. Аннары калтыранган учын кызның күкрәк йомгагы астына куйды. Тәненә ток бәргәндәй булып эсселәнеп китте. Шундук: «Нәрсә җебеп төштең? — дип, эченнән үз-үзен тиргәп алды. — Әгәр шушында тәмам үлеп китсә? Синең кул астында, ә?»

Ул үҗәтләнеп янә иреннәрен кызның авызына терәде.

Сабит агач ботакларын читкәрәк авыштырды. Ничек кенә сак кыланса да, яфраклардан шыбырдап эре тамчылар, коелып, кыз белән егетнең икесен бергә чылатты. Хәер, Мидхәт моны тоярлык хәлдә түгел иде. Һушыннан язган кешенең теле артка китеп, сулыш юлын каплау ихтималы барын исенә төшереп, ул кызның авызын ныграк ачтырып карады. Тын юллары ачык, һава үтәрлек икән. Тагын аның иреннәренә авызын терәп, кайнар сулышын өрде, күкрәгенә басты... Әледән-әле башын кызның күкрәгенә куеп, йөрәк тибешен ишетергә теләде, әмма үзенең колак шавын гына тойды. Бераздан ул ясалма сулышны икенче төрле ысул белән алдырырга кереште: кызның баш очына тезләнде дә кулларын әле як-якка җәйде, әле күкрәгенә кушырып кысты.

Баштанаяк чыланган һәм күшегә үк башлаган Сабит ахыр чиктә түзмәде, кызарынып-пешеп чыккан энекәшенә:

— Ярар инде, азаплама, — диде. — Киткән бит инде. Урыны җәннәттә булсын...

Ә Мидхәт ишетми дә кебек, һаман үз эшендә иде.

— Кешенең мие биш минуттан үлә, — диде Сабит, тагын бераз тынып торгач. — Син монда ун ук булмаса да, җиде-сигез минут азапланасың инде. Әле без килеп җиткәнче күпме шулай яткандыр... Тор әйдә, машинага кертеп салыйк!.. Әлифә апага ничек әйтербез инде, ә?..

Егетнең карашы исә кызның йөзенә төбәлгән, куллары бер җилпенә, бер аска төшә иде. Вакытның күп узганын үзе дә чамалый, тик ниндидер үҗәтлек, әҗәл белән ризалашырга теләмәү аны хәрәкәтеннән туктатмый иде. Менә кинәт кызның йөзе тетрәнеп куйгандай булды, иреннәре ныграк ачылды. Күкрәк читлеге тыштан кысканга түгел, үзеннән-үзе тибрәлгәндәй тоелды. Әллә чыннан да сулыш алдымы?

Мидхәт янә яңагын кызның күкрәк йомарламы астына терәде. Һәм... һәм... тигезле-тигезсез генә лепелдәү ишетте! Егетнең йөрәге аша ләззәтле дулкын йөгереп узды. Кешенең гомерендә менә шушындый бәхетле минутлар да була!

Ул сикереп торды да абыйсына:

— Бар, машинаңны бор! — диде.— Хәзер үк больницага илтергә кирәк!

Кыз нечкә сынлы булса да, тыгыз тәнле, һушсыз булганга шактый авыр иде, ләкин Мидхәт моны тоймады. Ул, ашыгырга кирәген аңлап, шул ук вакытта куе үләнгә абынудан, юл кырыендагы юеш балчыкта таеп китүдән сакланып, машинага таба атлады.

— Илтеп җиткерә алсак кына ярар иде, бездән исән килеш кабул итсеннәр генә иде, — диде Сабит, кабаланып.

...Юлда барганда ул, әледән-әле башын борып:

— Син анда авызыңны ачып утырма! — дип кисәтте.— Тагын начараеп китмәгәе!

Арткы утыргычтагы Мидхәт, керфек кагарга да куркып, тезләрендә яткан кызның йөзенә текәлгән иде. Керфекләрен күтәрмәс микән? Күзләрен күрергә иде, нинди икән?

Тик бу юлы Мидхәткә аларны күрү насыйп булмады. Хастаханәгә барып җитеп, Сабит кереп әйтүгә, ак халатлы ике хатын йөгереп килеп чыктылар да авыруны эчкә кертергә куштылар. Анда һушсыз гәүдә тирәсендә берничә кеше ыгы-зыгы килә башлады.

— Ә сез комачаулап тормагыз, чыгыгыз моннан, — диде таза гәүдәле хатын, таләпчән тавыш белән. — Исән килеш китереп җиткергәнсез, рәхмәт.

— Ул-бу булмастыр бит?.. — дип сорады Сабит.

— Иң авыры узган булырга тиеш. Докторлар бик әйбәт бездә. Борчылмагыз. Барыгыз, кайтып китегез.

* * *

Алар кайтыр юлга чыкканда, яңгыр туктаган, баюга борылган кояш, болытлар арасыннан ярты битен чыгарып, нурларын сузган, каршыда дугаланып, киңәеп, илаһи бер тантана белән салават күпере күтәрелгән иде.

— Ну, син дә молодец, булдырдың, — диде Сабит энесенә. — Тәки исән килеш илтеп җиткердек бит. Ә мин өметне өзгән идем инде. Әлифә апа синең аяк астыңа егылып рәхмәтләр укыячак, болай булгач. Үз кызыннан артык күрә ул аны. Мин, ди, аның анасы урынында, ди.

— Үз анасы үлгәнме әллә?

— Исән, диләр. Кишиневта яши. Әгәр аннан да арырак алып китмәгән булсалар... Ишетеп кенә беләм. Монда кайтып, күзгә-башка күренгәннәре юк. Атасының да, анасының да.

Бу сүзләр Мидхәткә серле йомгак булып тоелды. Нишләп бу кызның анасы Кишиневта? Әлифә дигәне бу кызның кеме дә, ник ул аны үз кызыдай якын күрә?

Егет шуларны сорамакчы булып авызын ачкан иде, күзе юл кырыена төшеп тукталып калды. Анда, яшен суккан каен янында, ак чиләк аунап ята иде.

— Кара, тегенең чиләге һаман шунда бит, — диде ул.

— Алыйк әле без аны. Әлифә апага кайтарып бирик.

Шулай итсәләр, күңелсез хәбәрне әйтү җиңелрәк булыр кебек тоелды. Машинаны юл кырыендарак туктаттылар. Чалбар балакларын күтәрә төшеп, абына-тая янә сынган агачка таба киттеләр. Сабит, иелеп, чыклы үлән арасында чәчелеп яткан җиләкне учлап-учлап чиләккә салырга кереште. Һәм берничәсен авызына капты.

— Эшнең рәтен белә икән бу кызый. Эреләрен, баллыларын сайлап кына җыйган. Кызларның уңмаганы аны учлап-учлап умыра, савытына бөресен-яфрагын кушып тутыра.

Мидхәт, кеше әйбере дип уйлап, берне алып кабарга да кыенсынып тора иде, абыйсының авыз тутырып, ләззәттән зәңгәр күзләрен кысып чәйнәгәнен күргәч, татып карарга булды. Яшенле яңгырның шифалы тамчылары белән юылган сусыл җиләк чыннан искиткеч татлы тоелды.

...Кече урамга кереп, тыкрык янындагы ихата каршына барып туктагач, Сабит:

— Шушыларның кунагы инде ул Әнисә, — диде. — Әлифә апаның туганнан туганы Илгизләр йорты бу. Әйдә, бергә керик. Берүземә читен... Ал чиләкне...

...Әлифә — кечкенә генә буйлы, арык гәүдәле, өлкән яшьтә булуына карамастан вак сипкелләре беленеп торган аксыл йөзле алтмышлар тирәсендәге түти икән. Мидхәт кулындагы чиләкне күрүгә, аның сирәк керфекле күксел күзләре зур булып ачылды, йөзе күгәренеп чыкты.

— Үзе кая?! — диде ул кинәт, карлыккан тавыш белән.

— Исән ул, исән, — диде Сабит, ашыгып.

— Кызлар белән җиләккә киткән иде. Башкалар кайтты, ул юк. Адашкандыр, бер-бер хәл булмагае дип курыктым. Давылы да көчле булды бит... Курыкканга куш, диләр... Яшен сукмады микән дип котым очты бермәл...

— Әйе шул...

Әлифә сүзен өзеп Сабитка текәлде.

— Больниска илттек без аны. Менә шушы егет коткарды. Бик озак ясалма сулыш алдырды. Син борчылма, иң авыры үткән инде, диде врачлар. Җиләк җыйган булган менә...

Әмма апакай аны-моны күрер хәлдә түгел иде. Ул, каударланып, өстәлдәге савыт-сабаны ары-бире шудырырга кереште.

— Ни алып барыйм икән?

— Кая?

— Больниска инде, кая булсын.

— Син әллә хәзер бармакчымы? Кертерләр микән? Соң бит инде.

— Нишләп кертмәсеннәр? Аның бүтән кешесе юк ла. Мин генә. Хәзер, өстемә киям дә... Машинагызны сүндермичә торыгыз.

— Мин бара алмам шул, — диде Сабит. — Болай да әрле-бирле күп йөрелде. Идарәдә көтәләрдер.

Әлифә аның хәлен аңлый: Сабит — колхоз рәисе, һәр көнне кичке җидедә бригадирлар, ферма мөдирләре белән бергәләшеп көнлек эшкә йомгак ясарга, килгәннәрнең гозерен тыңларга тиеш.

— Юлга чыгып бассам, машина очрамый калмас әле,— диде апа.

— Әллә син алып барып кайтасыңмы соң? — дип, энесенә борылды Сабит. Мидхәт әле һаман, кулындагы чиләкне кая куярга белмичә, ишек төбендә басып тора иде, Әлифә аның беләгенә килеп ябышты.

— Ал син моны, үскәнем. Чиләге белән ал.

— Кирәкми миңа... Рәхмәт.

— Син танымыйсыңдыр да әле, бу безнең Пермь ягындагы Әсгать абыйның малае, Мидхәт исемле, — диде Сабит. — Казанда институтта укый. Авылга беренче кайтуы. Районга аны каршы алырга барган идем.

— Алайса, безнең урман җиләге тансык инде сиңа! Ал, үскәнем, ал! Шәһәргә кайткач, дусларыңны сыйларсың...

Әлифә моны шулкадәр ялварып әйтте ки, Мидхәт каршы тора алмады. Тик шунысы: инде күчтәнәчен алгансың икән, апаның гозерен дә аяк астына салып булмый иде.

— Правам бар, дип мактанасың, кайтканда ук рульгә утырмакчы идең, — дип, егетне үгетләвен дәвам итте Сабит. — Идарәгә кереп, путевка яздырыйк та, егетләрчә тәвәккәллә, булмаса...

...Күп тә үтмәде, яшел «уазик» район үзәгенә таба бара иде инде. Мидхәт рульдә, Әлифә аның янәшәсендәге утыргычта. Озын юлны сүз кыскарта, егетнең исә бу апа турында, аннан да бигрәк тылсымлы тамгасы булган кыз турында күбрәк беләсе килә иде. Ул сер йомгагын кайсы җебеннән тартырга икән дип уйлап барганда, Әлифә:

— Мием түнгән, кеше әйткән колагыма керә, зиһенемә барып җитми, — дип куйды. — Бая Сабит сине Әсгать малае диде бугай.

— Әсгать малае.

— Аның хәлләре ничек соң?

— Ярыйсы болай. Авылга күчеп кайтасылары килә. Эш табылыр микән, йортлар кыйбатмы, кайтып белеш әле, дигән иде. Сабит абыйның үзен күреп сөйләшергә кушты.

— Туган яклар сагындырадыр шул, — диде Әлифә һәм тынып калды. Бу сүзне озайтмады, өстәп сорау бирмәде, чөнки күңеле башкада иде. Сабитның «Әнисәне шушы егет коткарды» дигән сүзләре, ниһаять, аңына барып җитте дә, йөрәгенең хәле китте. Керфекләрен сарган яшь тамчылары аша Мидхәтне әле генә күргәндәй күздән кичерде ул. Урта буйлы, ипле, ыспай гәүдәле, көлсу йомшак чәчле, ак йөзле, зәңгәр күзле бу егет аңа ифрат чибәр булып күренде. Нык үзәкле ирләргә хас калын тавышы йөрәккә ятышлы. Урыс арасында үскәндер — «къ»ны йомшартып, «h»не катыландырыбрак әйтә, тик бу да аңа үзенә бер сөйкемлелек өсти шикелле.

— Сез дә монда кунакта икәнсез, — диде Мидхәт.

— Еш кайтабыз без. Казан моннан якын бит, сез үскән Урал ягы ише түгел. Туган авыл сагындыра. Нигез генә таралды. — Әлифә көрсенеп куйды.

— Кызыгыз тумышы белән бу якныкы түгел, ахрысы. Абый шулай диде.

— Молдавиядән ул... Аның атасы — минем апамның малае. — Аннары, Мидхәткә аңлаешлырак булсын өчен: — Племянник була инде ягъни, — дип өстәп куйды. — Апам үлеп китте дә, аның улын тәрбияләү миңа калды, менә хәзер шул баланың кызын үстерергә насыйп булды.

— Ә үзе?

— Кишиневта яши. Хатыны молдаванка аның. — Мидхәтнең сораулы караш ташлаганын күреп: — Балалары күп — өчәү, тәрбияләргә хәлләреннән килми, — дип өстәде Әлифә. — Ә мин ялгыз бит. Пенсионер карчыкка иптәш булу әйбәт ул.

Мидхәт бераз тынып торды да:

— Ике кеше бер пенсиягә яши алмый бит, әтисе ярдәм итә торгандыр инде, — диде.

Әлифә мәзәк сүз ишеткәндәй кеткелдәп куйды.

— Алардан аны-моны өмет итү юк инде ул. Үзем бераз булса да акча юнәтәм, сату-алу белән шөгыльләнәм.

— Фирмагыз бармы әллә? — дип сорады Мидхәт, гажәпләнеп.

Әлифә бу юлы тәмам яктырып китте:

— Ниткән фирма инде ул миңа! Палаткам бар,— диде.— Урам чатында. Кешедән ким яшәмибез, Аллага шөкер. Әнисә үзе дә каникул вакытында эшләп алырга атлыгып тора.

Һәм апакай егеткә озак итеп сокланып карады. Үз гаме ничек кенә көчле булмасын, юлдашының йөз чалымнарыннан, гамьле дикъкатеннән табигате йомшак, күңеле нечкә икәнлеген тоеп алды ул. Аннан күзгә күренмәс җылы нур бөркелеп, җанга дәва булып иңә, бүгенге хәлләрнең ахыры хәерле булачагына ышаныч бирә иде. Больницада Әнисә, тәрәзәгә карап, аны көтеп утырадыр, хастаханәгә барып керүгә килеп кочаклап алыр... Бәлки әле, менә шушы машинага утырып, бергәләшеп өйгә кайтырлар.

...Әмма аларны хастаханәгә кертмәделәр. Вакыт соң, диделәр. Кызыгызның хәле начар түгел, янында кизү торуның кирәге юк, иртәгә килерсез, дип ишек төбеннән кире бордылар.

* * *

— Исәнмесыз!

Капкадан бер оя каз куалап чыгып килгән кыз урамнан узып барган егеткә башын күтәреп карады. Танымады. Әмма сәлам бирүенә гажәпләнмәде: авыл кешеләре очраган һәркем белән исәнләшә. Егетләр кунак кызына елмаеп сүз кушмыйча узмый да узмый инде. Әнисә авылдагы мондый гадәтне белә иде, шуңа күрә битараф кына:

— Саумысыз...— диде дә: — Кая киттегез? Көш-көш! — дип, кулындагы чыбыкны селтәп, таралыша башлаган биш-алты бәбкәне аналары янына тупларга тырышты.

Мидхәт ысылдап, томшыгын сузып каршысына килгән ата каздан кулындагы юл сумкасы белән ышыкланып туктап калган, үзе исә кызны күзәтә иде. Әнисә теге көндәгечә киенгән: терсәккәчә төшеп торган киң җиңле ал кофта, балак очлары сәйләп белән чигелгән джинсы чалбар. Хәзерге кызлар өчен гадәти киемнән, ләкин күзгә ташлана торган үзенчәлеге дә бар: эре дулкынлы кара чәчен баш артына җыеп, кофтасы төсле үк ал тасма белән бәйләп куйган. Чыбык белән селтәнгән саен, җиңнәре җилпенеп куя. Бөтен дикъкате бәбкәләрдә, узгынчы егеттә һич гаме юк. Ах, белсә иде ул аның кем икәнен! «Без синең белән күп мәртәбәләр иреннәрне иреннәргә терәдек — үбештек диярга була. Ничек кенә үбештек әле! Мин синең күкрәгеңә башымны салдым... Мин сине, кочаклап, кулыма күтәреп йөрдем»,— дисәң, нишләр иде икән? Ә бит аның иреннәренең тәме хәтердә сакланган. Җиләк тәме килә иде алардан. Тәненнән дымлы үлән исе аңкый иде. Якынрак килеп иснәп карыйсы иде — һаман да шулай микән?

Әнисә исә егетне ата каздан шүрли дип уйлады. Борылып килде дә:

— Көш-көш! — дип, чыбыгы белән селтәнде. — Куркытма кешене! Ул синең бибиләреңне... — кыз тотлыгыбрак калды, сүз эзләде, ахрысы. — Алып китмәс... — дип тәмамлады ул җөмләсен.

Белсә иде ул Мидхәтнең аяклары нилектән хәлсез калганын!

Теге чакта аңсыз яткан бу зифа сынны үз тәнеңә кысу, күкрәк алмаларына орыну табигый иде. Ә хәзер якын да килеп булмый... Әйтер сүз табылмый, тел бәйләнгән, тик эчке бер рәхәтлектән авыз гына ерылган.

Әнисә, тамгалы ияген чөя төшеп, сораулы караш ташлады — бәгырьнең нәзек бер кылына орынгандай итте. Күзләре кара, карашы тирән, серле икән. Менә ул сыгылмалы, нечкә сыны белән әле бер, әле икенче якка талпынып, алсу җиңен җилпи-җилпи казларны тыкрыкка таба куып ераклашты.

Авыл җирендә үскән Мидхәтнең күңеленә бик якын күренеш иде бу: кояшлы, тыныч көн, күктә, каурый болытлар арасында кара тилгән әйләнә... Як-ягына куерып кычыткан, тигәнәк үскән, уртасына бәбкә үлән келәме түшәлгән киң тыкрык буйлап кыз бала казлар куып бара. Мидхәт аякларын чирәмнән аера алмыйча басып торганда, капкадан ашыгып Әлифә килеп чыкты:

— Исәнме, Мидхәт! Ярый әле очрадың, үзем сезгә барып килергә дип тора идем. Кич белән, безнекеләр эштән кайтуга, сезне кунакка чакырабыз. Хәзер тавык суйдырам... Абыеңнарга ныгытып әйтеп куй, җыелышып килегез! Рәхәтләнеп сөйләшеп утырырбыз бер.

— Мин китәм, — дип, кулындагы сумкасын болгап куйды Мидхәт.

— Нишләп алай бик тиз?

— Йомышны үтәдем, сөйләшәсен сөйләштек. Иртәгә безнең спорт лагеренда смена башлана.

— Ай Алла, сезгә рәтләп рәхмәт тә әйтә алмый калабыз бит! Әнисә кичә генә кайтты. Күрми дә китәсең бит, болай булгач...

— Күрдем. Әнә бит! — дип, ияге белән тыкрыкка ымлады Мидхәт.

Әлифә ашыгып ул күрсәткән тарафка атлады, кулын болгап:

— Әнисә! Кил әле монда! — дип кычкырды. — Мидхәт абыең бит бу! Сине коткарган...

— Кирәкми, кирәкми! — дип, кыенсынып аны бүлдерде Мидхәт.— Ашыгам. Автобустан калуым бар... Сау булыгыз!

Һәм ашыгып китеп барды. Әлифә уфтанып, Әнисә сәерсенеп аның артыннан карап калдылар.

...Аларның башка бүтән очрашмавы да ихтимал иде. Бер авылдан чыккан кешеләр, шәһәргә килеп яши башлагач, гадәттә, күп халык арасында эреп юкка чыккан кебек булалар. Очрашмыйлар-күрешмиләр, бер-берсенең хәл-әхвәлен, авылга кайткач, туганнар аша гына белешәләр. Бу юлы да шулай булыр кебек иде. Мидхәт белән Әлифә арасында кардәшлек-туганлык юк, очрашырга ни сәбәп булыр иде икән?

Дөрес, кара бөдрә чәчен ал тасма белән бәйләгән кызны тагын бер күрәсе килү үзе зур бер сәбәп була алыр иде алуын. Ләкин аларга күрешмәү хәерлерәк иде, чөнки очраклы танышлыкны дуслыкка әверелдерергә ярамый иде. Беренчедән, кыз яшь иде — мәктәп баласы. Икенчедән, шәһәрдә Мидхәтнең йөргән кызы бар, үзе белән бер группада укый, бер тулай торакта яши торган Лениза белән шактый ук дуслашып киткән иде инде ул.

Ләкин Әнисә белән аны яшен очраштырган иде бит. Акыл ирешмәслек бер хикмәте булгандыр моның, мөгаен. Бу очрашу онытылырга, алар бер-берсен югалтырга тиеш булмаганнардыр. Югыйсә ничек итеп Әнисә егетнең барыр юлына чыгып басар иде икән?

* * *

Спорт лагеренда смена алышынган көнне Мидхәт белән Лениза шәһәргә аны-моны алырга дип кайттылар. Трамвайга утырып тулай торакка баралар иде, бер тукталышта Лениза, кулындагы ромашкалар бәйләме аша үрелеп, ачык ишектән урамга карады да:

— Морожный саталар,— дип ялманып куйды.— Әйдә төшәбез!

— Безнең тукталышта да бардыр әле,— диде Мидхәт, урамга күз салмый гына.

— Әллә бар анда, әллә юк. Әйдә.

Һәм алар, ябыла башлаган ишекне этәреп, эссе кояштан кызып йомшарган асфальтка сикерделәр.

Урам почмагына өстәл биеклегендә ак тартма китереп куйганнар, алсу кофта, джинсы чалбар кигән, кара бөдрә чәчен киң алсу тасма белән бәйләгән кыз аның эченә иелгән иде. Менә ул турайды, янындагы балалы хатынга туңдырма бирде. Мидхәтнең йөрәге дерт итте — Әнисә иде бу. Үзенә төбәлгән карашны күреп, ул башта сагаеп калды, нәрсәнедер исенә төшерергә тырышкандай булды. Аннары йөзе яктырып китте — таныды. Аның кара күзләрендә очкын кабынгандай булды, шома бит очлары алланды, ирен читләрендә елмаю балкыды, кыенсыну аша сөенү йөзендә, хәтта тылсымлы ияк уемында да чагылды кебек.

— Ике пломбир!

Ленизаның төксе тавышы аларны айнытып җибәрде. Әнисә карашын аңа күчерде һәм кинәт үзгәрде: йөзендәге балкыш сүнде, борын канатлары тетрәнеп куйды, керфекләре аска төште.

— И-и, кем бу дисәм, Мидхәт, син икәнсең бит! — диде таныш тавыш. Биш-алты адым гына арырак, азык-төлек кибетенең почмагына терәп, зәңгәр палатка корылган, аның эчендәге тәбәнәк прилавка артыннан Әлифә ике кулын сузган иде.

Мидхәт, дулкынланып, киң елмаеп, аңа таба атлады. Исәнләштеләр, хәл-әхвәл белештеләр. Баксаң, Әлифәнең сату итү урыны биредә икән дә Әнисәгә дә каникул вакытына шушында ук эш табылган.

— Сатып алучыларым ярдәм итте инде,— диде Әлифә.— Блат бар бит минем дә. — Һәм, тәбәнәк прилавкада тезелеп яткан оекбаш, кулъяулык, бейсболка, чүәк ише вак-төяккә караган егетнең йөзендә гажәпләнү галәмәтләре күреп, шаярткандай кеткелдәп куйды. — Моның ише нәрсә һәр кешегә кирәк ул! — диде. — Мин аны вьетнам базарыннан барып алам да хакын арттырыбрак сатам. Бер-ике кием оекбаш йә кулъяулык өчен генә күпләрнең әллә кая барып, вакыт уздырып йөрисе килми, моннан гына алалар. Тегеңә-моңа заказ бирүчеләр дә бар.

Күренеп тора, апакай «бизнес»ның җаен алган, күңеле хуш иде. Тик иркенләп сөйләшергә мөмкинлек булмады, трамвайлар килеп тора, аннан төшкән халыкның күбесе палатка йә туңдырма тартмасы янында тукталып кала. Көн эссе, тамаклар кибә, битләр тирли, ялан башларга кояш тия — кулъяулык-бейсболкаларның иң кирәк чагы. Туңдырмасын әйткән дә юк.

— Кич белән безгә килеп чык әле! — диде Әлифә.

— Мин үзем генә түгел бит...

— Иптәшең белән килегез! Күңеллерәк булыр! Ник таныштырмыйсың соң әле син безне?

Лениза читтәрәк, бер кулы белән ромашкалар бәйләме кочаклап, икенче кулыннан туңдырма ашый, үзе, эче пошкан сыман, карашын читкә төбәгән иде. Мидхәт, барып, аның терсәгеннән тотты да палатка янына алып килде. Кызның холкын белгәнгә, чит кешегә кунакка барырга риза булмас дип уйлаган иде ул. Әмма ялгышкан икән. Лениза, башын борып, ак тартма янында әвәрә килгән ал тасмалы кызга күз салып алды да палатка эчендәге апага:

— Чакыруыгыз өчен рәхмәт, — диде. — Обязательно киләбез. Әйе бит, Мидхәт?

Һәм ул, егеткә борылып, бик якын, үз икәнлекләрен белдереп мөлаем елмайды.

— Килегез, кил, — диде Әлифә, куанычыннан нишләргә белмичә. — Рәхәтләнеп өй ашы ашарсыз. Монда сезнең пешеренер җирегез дә юктыр әле.

— Тулай торакта кунып чыгарбыз дигән идек,— диде Мидхәт.— Кертсәләр. Анда хәзер ремонт бит.

— Кертмәсәләр, туры безгә генә килегез! Сыярбыз!

Лениза кулындагы ромашкаларның яртысын аерып алып, Әлифәгә сузды.

— Бусы сезгә урманнан шүрәле бүләге,— диде шаярып.

Әлифә тәмам эреп китте.

— И-и, рәхмәтләр яусын! — дип, чәчкәләрне алып, битен каплады апакай.— Бер җаен табып, кибеттән су алып чыгармын да утыртып куярмын. Без монда җидегә кадәр торабыз. Сигезләргә килсәгез, әйбәт кенә булыр.

һәм кәгазь кисәгенә адресын сызгалап, Ленизага сузды.

Кире трамвайга утыргач, Лениза тәрәзәгә карап басты. Тик урам манзарасын күрми дә кебек, үз уйларына чумган иде. Мидхәт аны беренче күргәндәй баштанаяк күздән кичерде һәм ихтыярсыздан Әнисә белән чагыштырды. Әйе, аларның аермасы җир белән күк арасы иде. Лениза буйга Мидхәт белән бертигез диярлек, биек үкчәле танкетка кигәнгә, калкурак та тоела. Юка көлсу чәче тигезле-тигезсез булып маңгаен каплаган, беразы соры күзләренә үк төшкән, ян-яктан иңнәренә тиеп тора. Хәзер мода шундый: кызлар мунчадан чыккач чәч тарап тормыйлар диярсең. Сыны төз, чандыр Ленизаның, спорт белән шөгыльләнгәнгә тәне тыгыз. Джинсы чалбары, күкрәкләрен кысып торган, кендектән югары кара кофтасы бик килешле. Ачык изүенә катлы-катлы сары чылбырлар салынган. Ясалма алтыннан. Кыскасы, егетләрне бер карауда җәлеп итәрлек үк булмаса да, төшеп калганнардан түгел. Модный киенгән, сынын — туры, башын югары тоткан мондый кызлар тормышта үзенекен ала... Кинәт Лениза, борылып, кистереп карап куйды. Мидхәт керфекләрен аска төшерде...

Тулай торакның комендланты, таза гәүдәле чая хатын, ромашкаларны бик сөенеп кабул итте. Мидхәт аңа гел ярдәмләшә, Лениза белән булган дуслыгы да яхшы мәгълүм, шунлыктан яшьләрне кире борып җибәрү уе хатынның башына да килмәде.

— Куныпчыгарга рөхсәт бирмәссез микән? — дигән сорауга:

— Кайда урын табасыз, шунда урнашыгыз,— диде.— Хәзер чиста җәймәләр бирәм.

Лениза яши торган бүлмәдә тимер караватларны уртага тезеп куйганнар, әмма ремонтка керешмәгәннәр иде. Әйберләрен куйдылар да, кичен килербез дип, шәһәргә чыгып киттеләр.

* * *

...Әлифә Азинодагы яңа панель йортта, җиденче каттагы бер бүлмәле фатирда яши икән. Кайчан ничек өлгергәндер, кунаклар килүгә, туй табыны әзерләп куйган иде: алма-әфлисун, кыяр-помидор, өрек-йөзем. Табын уртасында яшел таҗын як-якка сибеп, алтынланган кабырчыклары белән кәперәеп, ананас тырпаеп утыра. Аның янындагы бәллүр вазада ромашкалар, янәшәдә — шампан шешәсе.

— Шартлатып ач әле шуны, Мидхәт! — диде бәхете тулып ташкан Әлифә.

Күбекле шәрабны затлы бокалларга салып куйгач, йөзләр тагын да яктырды, телләр чишелде. Ленизаның бите алланган, соры күзләре яктырган, һәр ымында, сүзендә, керфекләрен сирпүендә янындагыларга ягымлы игътибар, шул ук вакытта үз дәрәҗәсен белү дә сизелеп тора. Мондый чакларда ул бик тә сөйкемле була иде. Спорт лагеренда балаларның төрлесе бар, кызык хәлләр булгалап тора, берничәсен сөйләп алды. Аш бүлмәсе белән ике арада йөргән Әнисәнең чыгып торган чагын туры китереп, җай гына:

— Внучкагыздыр инде бу сезнең? — дип сорап куйды.

Әлифә Ленизага таба башын сузып, шыпырт кына:

— Племяннигымның кызы бу, — диде. — Тормышлары җитеш түгел, тагын ике малайлары бар. Шуңа үз янымда торырга чакырдым.

Лениза, апакайның хәленә кергәндәй, тирән итеп көрсенде дә:

— Вот оно ка-а-ак... — дип сузды. — Хәзерге вакытта кайберәүләр үз балаларын ничек кулда тотарга белми. Әнә безнең лагерьда да ниндиләре генә юк. Бик зур җаваплылык алгансыз икән үз өстегезгә...

Ул арада бүлмәгә чәйнек күтәреп Әнисә килеп керде, сүз өзелде. Кызыл чәчәкле, җиңсез халат кигән, чәчен гадәттәгечә ал тасма белән бәйләп куйган Әнисә җәлт кенә карап куйды. Карашы шундый үткен иде, әйтерсең лә һәммәсен фотокарточкага төшерде. Ул сурәттә өстәл артындагыларның тышкы кыяфәте генә түгел, эчендәге уйлары да чагылды булса кирәк, һәрхәлдә, Мидхәткә шулай тоелды.

Әлифә, уңайсыз тынлыкны таратырга тырышып, җиләк кайнатмасы салынган бәллүр савытны Ленизага таба шудырды.

— Менә моны авыз ит әле син. Әнисә сые бу. Җиләкнең татлысын гына җыя, газда күпертеп кенә ала. Һәммәсен үзе эшли!

— Бергә пешердек, — дип куйды Әнисә, җитди итеп.

— Кайнаттык диген! — дип көлеп төзәтте аны Әлифә.— Кайнатма бит ул! — Аннары, Ленизага борылып: — Татарчасы бик шома түгел шул әле,— дип куйды.— Бик тырыша, өйрәнер, Алла боерса.

— Миңа җиләк ярамый,— дип, пыяла савытны читкәрәк этте Лениза.— Аллергия.

— Хәзер, үзем ашыйм да сиңа әйтермен нинди икәнен,— дип, кара бизәкле көмеш балкашык белән савытка үрелде Мидхәт.

Сый-нигъмәт татлы, шәраб затлы булса да, күңелләр җылынып җитмәде, чөнки биредәге дүрт кеше арасына ниндидер бер киренкелек кереп оялагандай иде.

— Ә син нигә берәр кая ял итәргә бармадың? — диде Лениза Әнисәгә. — Әгәр теләсәң, мин сиңа үзебезнең лагерьга путевка табып бирәм. Бездә синең кебекләр күп.

— Мин дә әйткән идем аңа, каникулыңда ял ит, дип,— диде Әлифә.— Эшлим, ди бит. Кыз кешенең матур киенәсе килә. Энеләренә бүләк җибәреп булмасмы ди.

Лениза, «хм-м» дип көлемсерәп, башын чайкап куйды. Аның йөзендә, күзендә хуҗа хатынны — сай акыллыга санау, Әнисәне исә баласыту ярылып ята иде. Моны тоеп алган Әлифә, ара-тирә гадәтенчә кеткелдәп куйса да, боегуын яшерә алмады. Бераздан сүз дә өзелде.

Китәргә вакыт иде. Саубуллашканда Әлифә мәҗбүриләп диярлек Мидхәтнең кулына авыр гына полиэтилен капчык тоттырды.

Үзе, чәчәкле күлмәк өстеннән иңенә ефәк шәл салып, кунакларны озата чыкты. Трамвай тукталышына шактый барасы иде. Көн эссесе сүрелгән, биек агач башларына эңгер эленә башлаган, тирә-юньгә җәйге җилсез кичләрдә генә була торган рәхәт тынычлык иңгән иде. Алар биек тупыллар ышыгыннан сузылган сукмак буйлап әкрен генә атладылар.

— Странная девочка,— диде Лениза, үзалдына уйлангандай.— Шактый сәер.

— Ярамаган сүз ычкындырмады кебек бит үзе? — диде куркынгандай Әлифә. Рәнҗеп китә күрмәгез тагын... Мин үзем аңа караган саен сөенәм. Теге хәлләр искә төшкәндә, йөрәгем жу итә, тез буыннарым йомшап китә. Әгәр шунда Мидхәт булмаса... Ул коткармаса, беткән булган икән бит балакай!..

— Нәрсәдән коткарды аны Мидхәт?!

— Үзе сөйләмәдемени? Яшен суккан иде бит безнең Әнисәбезне.

Лениза күзләрен зур ачып егеткә төбәлде:

— Слушай, кайчан булды бу?

— Узган айны, авылга кайткач... Коткарды дип әйтеп булмый инде. Без күрми үтсәк, бераздан үзе дә торып басар иде... — диде Мидхәт. Сүзнең бу борылышы аңа ошамый, Әлифә аның серен чишкән кебек иде. — Без абый белән юлдан узып бара идек. Машинада. Ә бу кыз агач төбендә ята иде. Шуннан больницага илтеп тапшырдык. Фәкать шул гына. Аның нәрсәсен сөйлисең.

— Врачлар бер дә алай дими,— дип каршы төште аңа Әлифә.— Әгәр вакытында ясалма сулыш алдырмаган булсалар, ай-һай, без ярдәм итә алыр идек микән, диләр.

— Ах, шулаймыни?! Син аңа ясалма сулыш алдырдыңмыни?!

Лениза Мидхәтнең йөзенә сынап һәм шикләнеп карады.

— Абый бар иде бит анда,— диде Мидхәт. Үзе йөзенең кызарынып чыкканын тойды.— Барсын да ул эшләде. Ул белә... Тәжрибәсе зур...

Әлифә аңа каршы әйтергә авызын ачкан иде, Мидхәтнең каушаганын күреп тыелып калды.

— То-то странная. Башына зыян тимәде микән ул кызның? — диде Лениза, уйланып. — Шактый сәер күренә... Мин яшьләр белән эшлим бит, чамалыйм...

— Үзем дә сизәм инде,— диде Әлифә кинәт, тирән көрсенеп.— Шундый өздереп карый кайчакта, эчтән бөрешеп китәм. Күз карашы белән эченне актаргандай итә, ни уйлаганыңны белеп тора шикелле. Элек алай ук түгел иде, кинәт үзгәрде. Әллә чыннан да яшеннең тәэсиреннән, әллә башка берәр сәбәптән...

— Ә башкасы нәрсә? — дип, барган җиреннән туктап, апага таба борылды Лениза.

— Мидхәт сөйләгәндер бит инде... Анасы молдаванка бит аның. Кармен исемле.

— Безнең арада аның хакында сүз булганы юк.

— Җай чыкмагандыр,— диде Мидхәт ризасызлык белән.

— Кичә урын-җирне алыштырганда, диван япмасы астыннан бер төргәк хат килеп чыкты, — диде үз гамьнәре белән мавыккан Әлифә. — Анасы белән хат алышып ята икән. Адресы «до востребования» язылган. Миңа белгертәсе килми...

— Ниләр язган соң анасы?

— Шайтан белсен... Үз телләрендә бит... Молдаванча... Хәрефләренә хәтле икенче, латин алфавиты...

— Ә үзе ни ди?

— Сорамадым инде... Әйтәсе килсә, үзе әйтер иде... Болай бит артыгын тыкшыну була...

— Вот как... — диде Лениза. — Сез саграк булыгыз. Алтыннарыгызны яшереп тотыгыз. Акчагызны да...

Әлифә сискәнеп китте.

— Авызыңнан җил алсын! Бөтен нәрсә тарау ята, сорамыйча бер тиенгә дә орынганы юк!.. Күпме гомер бергә яшибез бит инде!

— Молдаваннар чегән токымыннан бит алар, — диде бер дә исе китмәгәндәй Лениза. — Кармен исемле дә булгач, чын чегәндер әле. Алар күз буярга оста!..

Әле бер кыз сөйләде, Кольцода җир асты юлына төшкән идем, бер чегән хатыны хәер сорады, ди. Итәгенә бәләкәй баласы тотынган, ди. Шул балага кесәмдәге вак акчаны чыгарып биргән идем, анасы рәхмәтләр укып, бушлай күрәзәлек итәм, дип ябышты, ди. Алардан ерак йөрергә кирәклеген дә беләм бит югыйсә, әллә ничек зиһенем чуалды, аякларым җиргә беректе, тукталдым да калдым шуның

янында, ди. Соңрак, урамга чыгып, трамвайга утыргач кына аңына килгән бу. Янчыгында бер тиен акчасы калмаганын, муенындагы алтын чылбыры юкка чыкканын күреп, кире җир астына йөгереп төшкән дә бит, тотарсың чегәнне, бар!.. Моны да анасы шундыйрак һөнәрләргә өйрәтмәде микән? Хат аша киңәшеп, бозып ташламасыннар тагын. Аның ишене хәзер бик күп сөйлиләр. Фатирыгыздан колак кактырмагайлары!

— И, анасы сихерли белсә, тикшерүчеләрне сихерләр иде, төрмәгә кереп утырмас иде, — диде пошаманга төшкән Әлифә.

— Ах, төрмәдәмени-и-и? Нәрсә өчен икән?

— Сату эшендә иде. Растратасы чыккан...

Әлифә, артыгын ычкындырганын тоеп, телен аркылы тешләде. Тик соң иде инде. Аңарчы хатын-кызлар сүзенә катышмыйчарак килгән Мидхәт каршы төште:

— Бәла агач башыннан түгел, адәм башыннан йөри, ди безнең әти. Ни генә булса да, юньле кеше анасыннан йөз чөерми.

— Анысы шулай инде...— диде юанырга тырышкандай Әлифә.

— Но, алма агачыннан ерак төшми дигәнне дә онытырга ярамый, нәсел-нәсәпкә, тилчә тамырга, ди минем әби, — диде йомгак ясагандай катгый итеп Лениза.

Бу сүзләр егетнең күңелен кырса да, каршы әйтергә теле кычытса да, ничектер кирәкле сүзләр табылмады.

— Сәерлегеннән зыян күргән юк үзе, ә файдасын бик сизәм.— Әлифә әңгәмәдәшләреннән бигрәк үз-үзен юатырга тырыша иде шикелле.— Соңгы вакытта мине дәвалый башлады әле ул. Көн буе басып торгангадыр инде, аякларым белән интегәм. Яшьли рәтле аяк киеме тәтемәде, тишек ботылар киеп урман кисәргә туры килде. Башка авыр эш тә күп булды... Хәзер шулар чыга менә. Төннәрен кая куярга белмим. Мазьлар да ярдәм итми. Берчак шулай төн уртасында кухняда таптана идем, Әнисә уянып килеп чыкты. Урындыкка утыртты да, каршыма тезләнеп, учларын балтырым тирәли әрле-бирле йөртә башлады. Орынмый да, кагылмый да үзе, ә җылысы тия. Ике-өч минут үткәндерме-юкмы, аякларым җылынып-йомшарып киткәндәй булды, җаныма тынгы инде. Иртәнгә хәтле изрәп йоклаганмын...

— Гипнозга сәләте бармы әллә? — диде Лениза.

— Әйтәм бит, андый сәләтен сизгән юк иде моңарчы. Бик рәхәт икән ул! Хәзер үзем сорыйм, непрямой массажыңны яса әле, дип. Врачлар булдырмаганны булдыра...

Сүз белән мавыгып, тукталышка килеп җиткәннәрен сизми дә калганнар икән. Урам уртасында трамвайның ишеге ачылганын һәм юл чатындагы светофорда яшел ут кабынганын күреп, Мидхәт Ленизаның шәрә беләгеннән эләктереп алды.

— Йөгердек! Икенчесе тиз генә килмәс! Сәгать уннан соң транспорт йөрми!

— Безне онытып бетермәгез, тагын килегез! — дип кул болгап калды Әлифә.

* * *

...Бу кич һәммәсен кинәт үзгәртеп җибәрде. Алай гына түгел, тормышны әйләндереп салды дияргә була. Алдагы көндә күрәчәкләр нәкъ менә шушы кичтән башланды да.

Моңарчы үзара мөнәсәбәт дуслыктан ары китмәгән иде әле. Аларны бер-берсенә егет белән кыз арасында була торганнан бигрәк, абый белән сеңел арасында була торган якынлык бәйли иде шикелле. Хикмәт шунда, Ленизага уку шактый авыр бирелде. Дөрес, ул тырыша: лекцияләрнең берсен дә калдырмый язып бара, семинарларга һәрвакыт әзерләнеп килә. Әмма химик һөнәре өчен кул яту дигәне дә бик мөһим бит әле. Бу җәһәттән Ленизага читен иде, чөнки, башка кызлар көлеп әйткәнчә, аның кулы иңбашына кире ягы белән утыртылган булса кирәк.

Мидхәтнең исә бу һөнәргә күңеле дә тарта, кулы да ята. Башкаларның башы җитмәгәнне шундук тотып ала, үтә катлаулы анализларны бер талпынуда башкарып куя.

Иң мөһиме, үз шөгыленең тәмен белә, башкаларның башы җитмәгәнгә төшенеп, бүтәннең кулыннан килмәгәнне булдырып, чын мәгънәсендә ләззәт кичергән чаклары да еш була!

Сораган кешегә ярдәм итүдән дә беркайчан баш тартмый. Группада исә ярдәмгә иң мохтаҗы Лениза булып чыкты.

Чөнки ялгыз иде бу кыз. Әллә артык нечкә күңелле булганга, әллә үпкәчеллеге аркасында, кызларның берсе белән дә якынаеп китә алмады. Андыйлар турында, серкәсе су күтәрми, диләр. Шул ук вакытта андыйлар яклаучыга, киңәшчегә аерата мохтаж да. Мондый очракта Мидхәттән дә кулайрагы булмагандыр. Ул кечкенәдән үзенең ике сеңлесе өчен нәкъ менә шундый таяныч булды да инде.

Беренче елны ук Ленизаның курс эше өчен кирәкле тикшеренүләрне алар бергәләп башкардылар. Рәхмәт йөзеннән кыз кичләрен аны борщ, тәмле салатлар белән сыйлый иде.

Менә шуннан китте бу якыннан аралашу. Лабораториядә кыз егетнең ярдәменә мохтаж булса, сессия вакытында Мидхәткә дәфтәрләрен биреп тора. Билгеле инде, кайбер имтиханнарга бергә

әзерләнү уңайрак. Дөрес, нәтиҗә төрле була — Мидхәт бишле ала, ә Лениза дүртле белән генә кала. Әмма кыз моңа күңелен төшерми, дусты өчен куана.

— Югары стипендияне синең кебек егетләргә бирми, кемгә бирсеннәр тагын! — ди.

Ярдәм итешеп яшәү икесе өчен дә кулай, бер-берсенең эчен пошырган чаклары исә шактый сирәк. Нәкъ шундыйлар үзләре хакында, без фәкать дуслар гына, дип сөйлиләр һәм, күңелне кузгатырлык башка берәү очрап куйса, бу дуслыкны өзәргә дә күп сорамыйлар. Үпкән-кочкан җилгә очкан, дип күптәннән әйтелгән бит инде... Тик моңарчы ни Мидхәткә, ни Ленизага андый «башка берәү» очрамаган иде әле.

Әмма бүген хәл кинәт үзгәргән иде...

Алар тулай торакка барып җиткәнче, караңгы төште. Ишек төбендә генә лампочка яна, эчтә утларны кабызмаганнар. Буш коридорлар серле һәм шомлы, ничек кенә сак атларга тырышсалар да, аяк тавышлары, диварларга бәрелеп, каты яңгырый иде. Лениза таныш бүлмәнең ишеген кармаланып ачканда, шыгырдау авазы колакны ярды.

Бусаганы атлауга, Мидхәт туктап калды. Эчкә керүдән нидер тыя, нәрсәдер шикләндерә иде.

Лениза исә һичкайчан булмаганча кыюланган, аның адымнарында, ярым караңгыда шәйләнгән хәрәкәтләрендә, сулыш алуында ниндидер тәвәккәллек, гасабилану сизелә иде.

— Әйдә, утны яндырып тормыйбыз, — диде ул.

Чыннан да, күз тиз ияләште, пәрдәсез тәрәзәләрдән урам фонарьларының яктысы саркый, аннан да бигрәк тулган ай идәнгә киң итеп нур тасмасы сузып салган иде.

Лениза бер җәймәне җилпеп өстәлгә япты, өстенә Әлифә биреп җибәргән пакетны китереп куйды.

— Син нишләп йомышка кергән күрше малае кебек басып торасың? — диде. — Апаң шампанский тыгып җибәргән монда! Ә бу нәрсә?.. Ох ты-ы! Пластик стаканнар да куйган!..

Шампан күбеге стакан тоткан бармакларны кытыклады, авызда эреде, уйларын бутады.

Алай да бөтенләй үк онытылып булмый кебек иде. Айның нуры якты булса да, салкынча тоела, ул нәрсә хакындадыр кисәтә кебек иде. Әйтерсең лә тәрәзә артына берәү поскан да Мидхәтнең һәр хәрәкәтен, йөзенең алланганын, күзләренең сәер ялтыраганын күзәтеп-күреп тора, башны томалаган томанны куарга, күңелне ургыткан хисләргә бирешмәскә куша. Юк, куша гына түгел, ялвара, моның яхшыга алып бармаячагы хакында кисәтә кебек.

Мидхәт караңгыда үзалдына елмайды: юкка күзәтәсең, юкка кисәтәсең, диде ул эченнән генә күз алдына килгән кара күзле кызыкайга. Лениза белән аралар чиста, вәгъдәләр бирелмәгән, ант касәләре эчелмәгән әле. Һәм шулай булып калыр да. «Ул оялчан, тыйнак кыз, мин дә үземне кулда тота беләм».

Дөрес, аның күкрәге кызның иңбашына якынайганнан-якыная бара. Әйе, гәүдә ихтыярга буйсынмый, аңа таба авыша, куллар үзләреннән-үзләре аның тәненә урала. Мондый очракта, мондый шартларда эчендә җаны булган егет башкача була ала димени?! Ләкин гадәттә ифрат тотнаклы, оялчан Ленизага ни булган әле бүген? Үзе дә гажәпсенә, ахрысы, йөзгә кайнар сулышын бөркеп: «Әллә ни булды миңа, — ди. — Шампанскийга сөйдергеч салганнар микән әллә?» — «Бардыр, бардыр...», — дип җавап бирә Мидхәтнең теле, акылга каршы килеп. Колагы белән моны ишеткәч гажәпләнми, эченнән: «Әй, бер суырып үпкәннән ни була! — дип уйлый. — Аннан артыгын Лениза барыбер рөхсәт итми. Бер чиктән уздырмый, вакытында туктата, айныта белә... Андыйга оста ул...»

Аулакта ялгыз калулары беренче генә түгел... Бу юлы да ахыр чиккә җитмәсләр, үз-үзләрен кулга алырлар...

Мидхәт, бераз тын алырга, чуалган зиһенен тәртипкә китерергә, йөрәгенең шашып тибүен басарга тырышып, стаканнан җылымса шәрабны зур йотымнар белән голт-голт итеп эчеп куйды. Әмма тынычлану-айну урынына зиһен тагын да ныграк чуалды, ай нуры аша кисәтеп карап торган күзләр эреп юкка чыкты. Лениза шоколад кисәген авызына яртылаш кабып, яртысын аның кызган иреннәренә тидерде... Ах, бигрәк баллы ла кәнфите! Аннан татлы иреннәре! Аннан ләззәтле бөтен тәненең орынуы... Аның бу кадәр кайнар, тәненең бу чаклы ипле икәне моңарчы ничек беленмәгән соң әле?

Ләкин... нишләп соң ул башка чактагы кебек читләшми? Юка гына кофта тукымасы аша күкрәк алмалары йөрәк турын көйдерә... Кызның гадәттә кырыс хәрәкәт белән аны читкә этәрә белгән куллары ничек болай йомшарган, тоташ назга әверелгән? Муенны, битләрне шушы рәвешле акылдан шаштырырлык итеп иркәләргә кайчан өйрәнгәннәр? Менә алар ачык изүдән күкрәккә шуыштылар, аннары аска таба...

— Нишләтәсең син мине, Лениза?

— Ә син мине?.. — дип шашып сарыла кыз. — Кадерлем... Бердәнберем... Иркәм...

Ленизаның теле дә шундый татлы була ала микәнни? Аның кәнфит исе аңкыган авызыннан шундый сүзләр сирпелеп чыга аламыни?! Еллар буе моны Мидхәт ничек белми йөргән соң әле? Тыштан караганда сары чыпчык кебек гадәти күренгән бу кызыйның эчендә кыйммәтле хәзинәләр ята икән бит. Менә кинәт затлы сандык ачылды, андагы асылташлар күзне чагылдырып, зиһенне чуалтты. Юк, бу затлы сандык түгел икән лә, бу тылсымлы касә икән... Аның эче тулы татлы шәраб икән...

— Әйдә, тагын берне эчәбез... Анда калды бит әле...

— Лениза, шаштырасың син мине, акылдан яздырасың...

— Мин түгел, син... Син шаштырасың мине... Мин берни дә белмим... Син өйрәт мине, пожалуйста, өйрәт...

— Әгәр син риза булсаң...

— Мин риза... Мең риза... Син мине үкенерлек итмәссең бит, җаным?

— Мин синеке, Лениза... Фәкать синеке генә... Без бергә булырбыз... Мәңгегә...

Мидхәт ни сөйләгәнен үзе дә аңламас хәлдә иде. Куллар кызның чалбар чылбырына шуышты, бармаклар бармакларга уралып чәбәләнде...

Кызның тәне һәр ишарәгә буйсына һәм бу акылдан шаштырырлык дәрәҗәдә ләззәтле иде... Ул ыңгырашып кычкырып җибәргәндә, Мидхәт үзен кайнар өермә күтәреп алып киткәндәй хис итте һәм бу очыш бернәрсә белән чагыштырып булмаганча татлы иде.

Бәгъзе мәгъшуклар менә шушындый мизгелләрне кичерү өчен гомерен бирергә әзер...

Әй сез, заман егетләре! Гомерлек яр булачак мәгъшукагызның сафлыгы, чисталыгы белән кайсыгыз түш киереп мактана ала? Андыйлар бик аз бит сезнең арагызда! Дөрес, күбегезнең башка төрле мактанырлык гамәлләре бардыр. Кайсыларыгыз зур ачышлары белән, кайсыларыгыз төзегән йортлары, салган күперләре белән горурлана. Яуда күрсәткән батырлыклары белән дан алганнар, биек кыяларга менгәне өчен, матур җырлар чыгарганы өчен макталучылар бар. Болар бик яхшы, бик кирәк. Тик бер саф кызны гомерлек яр итеп, аның белән ләззәт дәрьясында йөзмәгән ир, нинди генә өлкәдә танылса да, тулысынча бәхетле була алмый. Ир-егетлек ул сөюнең тәмен татуда һәм аның өчен җаваплылыкны үз җилкәңә алуда да. Ир заты үзенең зурлыгын, гайрәтен, көчен менә шунда аңлый. Моны аңлау аны үстерә, биегәйтә, рухын ныгыта!

Күпмедер минутларданмы, сәгатьләрдәнме соң, йөрәк тибеше тынычланып, баштагы уйлар бераз тәртипкә салынгач, Мидхәт язмышының бик кискен борылыш ясаганын аңлады. Моннан соң аның яшәеше бөтенләй башкача булачак иде. Ул хәзер ялгызы түгел. Алар икәү. Дөрес, моны әле аларның үзләреннән гайре һичкем белми. Ләкин анысы мөһим түгел. Антлар кызулык белән әйтеп ташланса да, Мидхәт аларны хәтерли, онытмаячак, сүзеннән кире кайтмаячак. Сафлыгын аңа бүләк иткән бу затны ул беркайчан да авыр хәлгә куймас, аңа газаплар китермәс, күз яшьләрен түктермәс...

Мидхәт борылды да култык астына сыенып яткан Ленизаны хуҗаларча нык, ышанычлы хәрәкәт белән күкрәгенә кысты.

Шулчак аның йөзенә салкын җил бәргән кебек тоелды. Ул эчтән сискәнеп китте... Күзләрен ачып, тәрәзәгә текәлде. Нинди җил булсын, ай нурының тасмасы күзгә төшкән, фәкать шул гына. Тик каян күңел почмагына салкын тамчы булып кисәтүле уй төште соң: «Артык мавыгасың... Ялгышасың... Хаталанасың...»

«Монда нинди хата булуы мөмкин? — дип эченнән каршы төште Мидхәт. — Очраклы кеше түгел, бер-беребезне күптән беләбез. Мин аны гел үземнеке генә итәрмен. Үзем дә гел аныкы гына булырмын. Җитешмәгән якларын гафу итәрмен...» Ул сөйгәненең һәр әйткән сүзен шундук үтәргә әзер, барлык моң-зарларын назлары белән таратыр кебек иде.

* * *

Сентябрьнең җилле-яңгырлы көнендә трамвай таныш урам чатына килеп туктады да ишеген ачты. Мидхәт үрелеп тышка карады. Зәңгәр палатканы күреп, үзе дә аңышмастан, чыгу ягына китте.

Юеш асфальтка төшеп баскач, ихтыярсыздан күзләре белән туңдырма тартмасын эзләде. Үтереп пломбир ашыйсы килгән икән. Вафлясы теш арасында шытырдап торганны... Тик урам чатында ак тартма да, аның янындагы ал тасмалы кыз да юк иде. Ә менә Әлифә үз урынында. Җилдә җилпенеп шытырдаган зәңгәр брезент куышы эчендә, тәбәнәк, тар прилавкасы артында басып тора. Калын гына куртка кигән, башына кара чәшке бүрек чәпәп куйган, колагы өстендә җепкә тагылган катыргы кисәге болгана — сатарга дигән әйбер, күрәсең...

Егетне күрүгә, апакайның авызы ерылды. Елмаешып, кул бирешеп исәнләшкәч, хәлләрнең хәер икәнен белешкәч, Мидхәтнең бүреккә караштырганын күреп:

— Ошыймы әллә? — дип сорады Әлифә. — Бүләккә алам дисәң, үз хакына бирәм...

Исемен әйтмәде, әмма кемгә бүләк алу турында сүз барганы икесенә дә аңлашылды. Мидхәтнең Әнисә хакында сорашасы килә, ләкин нидер тыя иде. Кызның исемен әйткәндә тавышы калтырап китәр шикелле... Үзе, карашын аска төшереп, прилавкада яткан оекбашларны сыйпаштырды.

— Менә болары әйбәт, чыдамлы. Бер биш парны бүләк итим әле мин сиңа,— дип, Әлифә товарын төрә дә башлады.

— Кирәкми, кирәкми, оекбашларым күп минем...

— Оекбашның артыгы булмый аның. Көн саен алыштырып торырсың. Сезнең тулай тораКта бүлмә саен кер юу машинасы юктыр.

— Прачечный бар безнең... — диде Мидхәт.

— Юучысы да бардыр әле, — дип кеткелдәп куйды Әлифә.

Мидхәт кызарынып чыкты. Әмма апакай аңа карамый, бүләген салырга матуррак пакет эзли иде.

— Оекбаш күп булса, юучыга да ансат ул. Һәммәсен бергә җыеп җебетә дә болгаткалап элеп куя. Алмасаң, үпкәлим!

— Ничек инде мин сезнең хисапка...

— Нинди исәп-хисап ул безнең арада? Студентка ярдәм итү фарыз гамәл.

Мидхәт, баш тартса, апакайның күңеле кителәчәген күреп, бүләкне кире кага алмады.

— Сине бик күптәннән күрәсе килә иде, — диде Әлифә, ничектер җитдиләнеп. — Тулай торагыңа барыйммы әллә дип тора идем әле. Әнисә һич тынгы бирми, көн саен күренмәдеме дип сине сорый. Бик борчыла...

Мидхәт сискәнеп китте.

— Бер-бер хәл булмагандыр бит?..

— Ул-бу булмады. Әйбәт кенә укып йөри. Ул яктан җан тыныч. Җәй эшләгән акчасына өс-башын рәтләде, энеләренә дә бераз җибәрде... — Әлифә кеткелдәп куйды. — Менә шундый шул ул безнең Әнисәбез. Үз авызыннан өзеп туганнарына бирә.

— Ә мине ни дип сорый?

— Сиңа әйтергә дә уңайсыз инде...

— Нәрсәне?!

— Бер караганда, бала-чага сүзе белән йөреп, кеше тормышына кысыласы да килми... Икенче яктан, Әнисәне бала гына дип тә булмый. Бездән күпне күрә, күпне белә.

— Минем өчен ник борчыла соң ул?

— Син миңа үпкәләмә. Аның гозерен генә үтәвем... Безгә алып килгән кыз белән сак булсын, башын шуңа бәйли күрмәсен, ди.

Мидхәт ике бит очының уттай кызышканын тойды, керфек кагарга да онытып, Әлифәгә текәлде.

— Кара эчле, ди. Мәңге үтмәс хәсрәт китерәчәк, тере бәхетсез итәчәк, ди!

Мидхәтнең эченә шом керде.

— Теге көнне мин сезне озатып кергәч үк нишләргә белми бәргәләнде, — дип дәвам итте Әлифә. — Сине исенә төшермәгән көне юк. Мин әйтәм, лагерьда бит алар, дим. Соңарабыз бугай инде, ди. Нишләп соң булсын, дим мин, Мидхәт өйләнгән дигән хәбәрнең ишетелгәне юк...

Ә егетнең күз алдыннан теге кичтә булган хәлләр, ай нуры, күләгәдә чалынган шәүлә чагылып узды, бөтен тәне тирләп чыкты.

— Соң шул инде... — диде үзе дә сизмәстән.

— Әллә... язылыштыгыз дамы? Туганнарыгызга, ата-анагызга әйтеп тә тормыйча?

— Язылышуын язылышмадык әле... Әтиләрдән рөхсәт аласы бар... Каникулда кайтып килербез дип торабыз...

— Әле... вакыт бар икән, — диде тынычланып киткәндәй Әлифә. — Нишләп соң булсын... Кайсы парлар загска гариза биргәч тә кире уйлый... Билгеләнгән көнне язылышырга бармыйлар гына...

— Мин андый түгел, — диде Мидхәт, кискен итеп.

Әлифә башын иде дә каршысындагы әйбер-караны рәтләштергәндәй итенде.

— Үзең беләсеңдер инде...— диде.— Мәктәп баласының сүзенә карап йөрмәссең... Алай дисәң, ул әйткәннең расланмый калганы да юк... Беркөнне күршебез кергән иде. Әллә нәрсә ямансу булып китте әле, эчне бушатасы килә, ди. Узган гомерләрен сөйләп шактый утырды. Ул чыгып киткәч, Әнисә әйтә, бу апа озак яшәмәячәк, ди. Юкны сөйләмә, дидем мин, сау-сәламәт кешегә ни булсын... Өч көннән җирләдек без ул хатынны. Машина бәргән...

— Астрология белән мавыкмыйдыр бит сезнең ул кызыгыз? — дип, сүзне шаяртуга борырга омтылыш ясады Мидхәт. — Хәер, алар фаразларын күпкә төгәл итеп әйтә бит. «Игезәк»ләр иртәгә начальникларына ярарга тырышсын, «арыслан»нар кесәсен сакласын, акча янчыкларын урлатулары ихтимал, «кәҗәмөгез»ләр бу атнада сөяркәләре янына бармый торсыннар, хатыннары килеп тотуы бар дигән кебегрәк киңәшләр белән гәзитләр тулган. Андый фараз кылулар бик төшемле шөгыль, күрәсең. Әнисә дә, мондый сәләте булгач, морожный сатып йөрмәс инде бүтән! Күрәзәлек итеп кенә акча эшләр!

Әмма Әлифә шаяртуны кабул итмәде, кыска керфекләрен кагарга онытып, бик җитди карап торуында иде.

— Аның һәр әйткәне рас килә дигән сүз түгел анысы,— диде аннары, башын иеп. — Алай да күзеңне ачыбрак йөрү зыян итмәс... Кешене ярып карый алмыйсың, эчендә ниләр ятканын белеп булмый, диләр... Бер кавышкач, аерылулар бик читен ул. Балаларыгыз туар... Әнисәнең үз атасы белән анасы ничекләр генә булып бетмәде. Мәхәббәтләре Ләйлә белән Мәҗнүннән бер дә ким түгел иде югыйсә... Хәзер әнә аларның тормышын дошманыңа да теләмәссең. Уйла әле син... Вәгъдәне бирү бар, аннары кире алу бар...

— Уйларбыз, ник уйламаска, баш үзебезнең муенда бит... әлегә... — дип елмайган булды Мидхәт.

* * *

Йөгереп барып трамвайга утырган Мидхәт артыннан Әлифә моңаеп карап калды. Егетнең йөзендә чагылган сискәнү, кыенсыну, ничектер үзен гаепле сизү сагайткан иде аны. «Соңаргансың бугай шул инде...» Бу уй Әлифәнең күңелен әрнетте дә әрнетте. Көндез яныннан кеше өзелеп торган минутларда, әледән-әле егетнең аксыл керфекләр аша мөлдерәп караганын күз алдына китерде. Төнлә исә бик озак йоклый алмый уйланып ятты.

Мидхәткә ул Әнисә хакында, бала-чага гына әле, дип әйтте әйтүен дә, әмма бу баланың сүзләре хак икәнен бик яхшы сизә иде. Менә бүген Мидхәтнең йөзендә дә чагылды ул дөреслек. «Соң инде... Тик ялгышмадыммы икән?» — диде егетнең алдый белмәс ихлас күзләре...

Ах җаный, ялгыша гына күрмә инде берүк! Мәхәббәттә хаталану адәм баласын юкка чыгара, язмышын җимерә. Андый хәлләр Әлифәнең үз күз алдында да булды...

Беренчесе — апасы Сәрия. Колхозда механизатор булып эшләгән әтиләре иртә үлеп, алар, мәктәп яшендәге ике кыз бала, хаста әниләре кулында калганнар иде. Сәрия урта мәктәпне тәмамлаганнан соң курсларда укып кайтты да колхоз бухгалтериясенә эшкә урнашты. Ул елларда һәр җәй саен авылга читтән төзүчеләр килә, колхозга абзар-кура сала торганнар иде. Сәрия шуларның берсе белән очраша башлады. Куе коңгырт чәчле, кара кашлы, елтыр күзле шаян егет беренче карашка бик тә сөйкемле иде. Сәрия аңа башын югалтып гашыйк булды. Танышуларына ай үттеме-юкмы, язылышып кавышты болар. Кечкенә өйдә дүртәү яши башладылар. Тик кияү дигәнең узгынчы булып чыкты, чын ир була белмәде, җигелеп көн итәргә теләмәде. Бала да тугач, нужадан туепмы, әллә җилбәзәклеге җиңепме, каядыр чыгып китте дә гаип булды. Яшь әни, күкрәк баласы тотып, ялгыз калды. Кайчандыр аталары салган дүртпочмаклы өй, тәмам череп, ишелер хәлгә җиткән иде. Авыл советы аларга урманнан делянка бүлеп бирде. Шунда өстенә агач авып, Сәрия үлеп китте...

Ул чакта Әлифә шәһәргә барып урнашкан, заводта эшли, тулай торакта яши, читтән торып техникумда укый иде. Апасының җеназасыннан соң сабыйның язмышы турында уртага салып сөйләштеләр. Әби кешенең үз-үзен дә авырлык белән караганын исәпкә алып, баланы приютка илтеп тапшыра алган булырлар иде. Әмма намус кушмады. Бала әбисе тәрбиясендә калды, шуның аркасында Әлифәнең җилкәсенә икеләтә җаваплылык төште: анасы өчен генә түгел, апасының баласы өчен дә.

Ә соң үз тормышы? Авылда бер чибәр булып саналмаса да, төшеп калганнардан түгел бит ул. Сүз кушучылар бар иде, күзне йомып суга сикергәндәй тәвәккәллек күрсәтсә, ялгыз калмас иде. Әмма, беренчедән, ашыгып кияүгә чыккан апасының ачы язмышы күз алдында булса, икенчедән, анасының сүзен аяк астына салып таптый алмады. Тәрбиясе ул түгел, канына ата-ана хакы дигән зур нәрсә салынган иде. Ә ананың сүзе бер булды: «Кияүгә чыгып, бала тапсаң, синдә безнең кайгы калмас. Ниш-ләрбез, ничек көн итәрбез?!»

Апасы кисеп өлгергән агачлардан бер җәйне ничек кирәк алай азапланып бура торгызып куйдылар, икенче елны Әлифә, бар булган акчасын туплап, җиң сызганып, ялга авылга кайтты. Буаз сыерны, кышлаган бозауны сатып, атасын хәтерләгән кешеләрнең ярдәме белән кечкенә генә бер йорт салып керделәр. Бу мәшәкатьләр арасында күзгә ак-кара күренерлек булмады. Йортны өя-өя көеп беттем дигәннәре хак шул...

Ул шулай гаиләне кайгыртып йөргәндә, чордаш егетләр үзләренә пар табып, җылы кочакларда эрегәннәр, Әлифә кебекләрнең базары узган иде инде.

Алай дисәң, чын мәхәббәт дөнья мәшәкатьләре белән, акыл белән санашып тора димени? Ахыр чиктә үзенең кыюсызлыгы ялгыз калдырды Әлифәне. Ятимлек тә фәкыйрьлек ул кесә такырлыгында гына түгел. Иң беренче чиратта күңелнең изелгәнлегендә ул. Ә бу — бөтен кыяфәтеңә бәреп чыккан, һәр сүзеңдә, кыланмышларыңда чагылган кимсенү дигән сүз. Моның шулай икәнлегенә ышану өчен, тулай торакларның дүртәр-алтышар кеше яши торган бүлмәләрендә картаеп килгән кызларга бер күз салу да җитә. Никадәр игелекләр кылынмый калган, назлы хисләр һичкемне иркәләмичә сүнгән... Нәкъ менә шундыйлар турында шагыйрь: «Җирдә күпме җаннар йөри иясез шатлык булып!..» — дип язгандыр да.

...Ах, кайларда йөрисез сез, мәхәббәткә сусаган, җан җылысына мохтаҗ егетләр? Нигә сез Әлифә кебек кызлар яныннан күз дә салмыйча узып китәсез? Күңел күзегез кайда сезнең? Йөрәк сизгерлегегез кайда? Нигә сез, минутлык хискә бирелеп, чәчкәдән чәчкәгә очып йөргән күбәләк кебек җилбәзәк кызларның елмаюына, ялагайлануына ышанып, капкынга эләгәсез?..

Аның тагын шунысы да бар бит әле: гаиләсез калганнарның күбесе куышсыз да кала! Заводта утыз ел эшләп, дистә еллар буе чират торса да, ялгызакның сирәгенә хөкүмәт фатиры тәти, чөнки шул ук чиратта ишле гаиләләр күп бит. Ә инде кооператив фатир сатып алырлык акчаны Әлифә кебекләр җыя аламы?

Әлифә дә, башка күп ялгызаклар кебек, гомеренең ахырынача, мөгаен, тулай тораста яшәп калган булыр иде. Ни гажәп, игелекле табигате, йомшак холкы фатирлы итте аны.

Ә анысы болай булды. Бергә эшләүче Фатыйма исемле хатын үзләренең күршесендә яшәүче ялгыз, хаста карчык белән таныштырды.

— Исәнлеге чамалы, үзе генә яши алмый, фатирга кертергә ышанычлы кеше эзли, — диде. — Синнән ышанычлырагы табылмас. Килешеп китсәгез, прописка кертер үзеңне. Өебез бик иске, сүтәчәкләр дигән сүз йөри. Сүтсәләр, безнең белән берочтан син дә фатирлы булып калырсың!

Фатыйма — түгәрәк гәүдәле, йомры башлы, чая-үткен шәһәр хатыны, дөньяның рәтен аңлый, кешеләрне таный белә. Әлифәне дә ул үтәли күрә иде кебек. Бу кызга үз гаиләсен корып, ир назын тату, бала табып үстерү бәхете тәтемәде. Әмма ул үз рәхәтен генә кайгыртып яши торганнардан түгел, аңа кемне дә булса кararга-тәрбияләргә кирәк. Шуны аңлаганга күрә, Фатыйма Әлифәне Киров урамында яшәүче ялгыз карчыкка алып китте дә.

Кысан, сасы ишегалдына барып кергәч, аның дүрт ягында хан заманыннан калган, беркайчан да буялмаган-сыланмаган ярым хәрабә, каралып беткән кызыл кирпеч йортларны күргәч, Әлифәнең күңеле шактый төште. Ә инде әбекәй фатирының бусагасын атлауга, борынга бәрелгән ис бөтенләй аяктан егарлык булып чыкты. Карчык атналар буе урыныннан кузгала алмый сырхаулап яткан, кереп хәлен белүче дә булмаган икән. Хәер, районның социаль яклау бүлегеннән беркетелгән бер хатын, атнага ике тапкыр килеп, кибеттән ипи-сөт сатып алып бирә икән үзе, әмма өйне җыештыру, әбине юындыру ише эшләр аның вазифасына керми икән шул. Күрше мәктәптән өлкән класс кызларын җибәреп караганнар икән дә, тегеләр бусагадан да атлап кермәгәннәр, шундук, борыннарын җыерып, тәртәләрен кире борганнар. Яшьләрне матурлыкка, яхшыга өндибез, ләззәтләнеп күңел ачарга өйрәтәбез. Хаста-хәлсезләрне тәрбияләргә өйрәтүче бармыни?

Әлифә исә нәкъ менә шушында үзенең бик кирәкле, хәтта алыштыргысыз кеше икәнлеген аңлады. Шундук җиң сызганып эшкә кереште: коридордагы газ плитәсендә чиләк-ләгән белән су җылытты, әбекәйнең укмашып каткан чәчләрен аралый-аралый юындырды. Аннары идәнне ике кат юып чыкты. Соңрак, нур иңгән, сабын-шампунь исе аңкыган җиләс бүлмәдә, тузаны сөртелгән абажурлы лампа яктысында кара-каршы чәй эчеп утырганда, әбекәйнең күзләреннән яшь акты. Бәхетеннән елый иде ул.

Шул көннән Әлифәнең дә аңарчы болытлы көн кебек ямансу аккан тормышы күгендә кояш ук булмаса да, ай калыккан кебек булды. Аның эштән кайтып, ишек ачып кергәнен зарыгып көтеп утыручы җан иясе бар иде шул. Һәркем белә, «сүтү чиратына теркәлгән» йортларда яшәүчеләрнең кулларына яңа фатир ордеры кергәнне көтә-көтә күзләре күгәрә. Хаста карчыкны исә көн саен, бүген кararга кирәк. Әмма Әлифә авырсынмады.

Маржа әби татарча аңламый, Әлифә урысча бик үк дөрес сөйләшә алмый, күп кенә бәйрәмнәр бергә туры килми, әмма бер-береңә кирәклегеңне аңласаң, күңелең киң, мәрхәмәтле булса, килешеп яшәү мөмкин икән. Алар бер-берсеннән бик тә риза иделәр. Тик менә айлар үтә торды, прописка турында гына сүз кузгалмады. Фатыйма бу хакта сораштыра башласа, Әлифә:

— Андый әбиләр, прописка кертсәм, үземне куып чыгармагае, дип курка бит, — дия иде.

Ахыр чиктә Фатыйма, кереп, әбекәй белән турыдан-туры үзе сөйләште. Баксаң, тегесе бу хакта уйламаган гына икән.

— Хәтер бар чакта, телем әйләнгәндә, эшләп куярга кирәктер шул, — диде.

Күңеле сизгән икән, шуннан соң озак яшәмәде, көннәрнең берендә, Әлифә эштән кайтуга, сулышы өзелгән иде. Аны кадерләп җирләү дә Әлифә җилкәсенә төште.

Әллә аның кылган игелекләре өченме, әллә чыннан да вакыты җитепме, йортны сүтәргә ниятләделәр, анда яшәүчеләрне яңа фатирларга күчерделәр. Әлифә өстенә бәхет тавы ишелгәндәй булды — аның кулына да ордер тоттырдылар. Яхшылык җирдә ятмый дигәннәре менә шушы буладыр инде!

Оҗмах та оҗмах, Әлифәнең яңа куышы да оҗмах иде. Тик бер генә җитмәгән җире бар: ул да булса биредә аның эштән кайтканын зарыгып көтеп торучы җан иясе генә юк иде.

Әмма яшәешнең шундый бер кагыйдәсе бар бит: башкаларны кайгыртырга күнеккән кеше җилкәсенә салынучы табылып кына тора. Күп тә үтмәде, Әлифәнең әнисе вафат булды, ялгыз калган энекәшне Казанга алып килергә туры килде. Малайны заводның һөнәр училищесына укырга кертте. Күктән йолдыз чүпли торган булмаса да, ипле иде, ярыйсы гына укып, әйбәт кенә фрезеровщик булып чыкты. Аннары армиягә китте.

...Һәм кире әйләнеп кайтмады. Ул чакта комсомол төзелешләре күп иде, тотыныр кешесе булмаган яшьләрне илнең әле бер, әле икенче тарафына озатып кына тордылар: кайда электростанция, кайда завод торгызырга, кайда шахта казырга. Берсеннән берсенә йөри торгач, Әнәс Молдавиягә барып эләкте.

...Кишиневтан туйга чакыру килеп төшкәч, Әлифә пошаманга калды: бигрәкләр дә ерак китеп, бигрәк тә чит-ятка башын бәйләргә ниятләгән иде егеткәй!

Әмма анда барып төшкәч, Әнәснең хәлен аңлады. Иңнәренә дулкын булып ишелеп төшкән кара чәчле, ут чәчеп торган кара күзле, бит очында миңе чекрәеп торган түгәрәк йөзле бу кызны яратмый мөмкин булмагандыр. Янындагы һәммә кешене бөтереп ала, биетә дә җырлата иде ул.

Бу туй Әлифәнең хәтеренә ярминкә кебек чуар, мул һәм шау-шулы тамаша булып кереп калды. Кояшлы көн, ишегалдындагы озын өстәлләр, кайсы берсен танып та булмаган җимешләр һәм тезелеп киткән шәраб шешәләре. Аксылы, яшькелте, саргылты, кызылы, кара-кучкылы... Өстәл башында гажәеп пар: киң чуар итәкле, кара чәченә кызыл роза кадаган Кармен янәшәсендә озын буйлы, йомшак саргылт чәчле Әнәс. Аның елмаюдан кысылган яшькелт күзләреннән сирпелгән бәхет чаткылары...

Тирә-якта халык ду килә. Ят телдәге дәртле җырлар арасында әледән-әле танышын сузып җибәрәләр:

Как-то утром на рассвете заглянул в соседний сад...

Итәген җилпеп, кәләш уртага атылып чыга:

Любовь — дитя, дитя свободы, законов всех она сильней...

Китә бөтерелеп, күзләр камаша!

Проспер Мерименың «Кармен»ы иде бу! Андыйның сөюенә каршы торып буламыни?

Капма-каршы холыклы һәм кыяфәтле булуларына карамастан, ә бәлки, шуңаргадыр, сокланырлык пар иде алар.

...Әйе, Әнисә — чын мәгънәсендә мәхәббәттән яралган бала. Ә андыйларның үзәге нык була. Аннан ике яшькә кече Александр да шулай ук... Катнаш гаиләләр өчен гадәттә четерекле булган исем кушу мәсьәләсен дә бу пар үзара килешеп хәл итте: беренчесенә — әтисе теләгәнне, икенчесенә әнисе сайлаганны куштылар. Шулай итеп, Кишинев загсларының берсендә Александр Анасович Гумеров теркәп куелды. Аннан соң тагын да ике ел узгач туган малай исә — Раду Анасович Гумеров. Хәер, анысына исемне башка кеше биргән булып чыкты... Моның серен Әлифә өч ел узгач кына белде.

Ул чорда Әнәстән хатлар бик сирәк килә иде. Адресы ят кул белән язылган конвертны алгач, Әлифәнең йөрәге жу итте. Юкка булмаган икән. Хат Әнәснең күршеләреннән иде. «Адресыгызны Әнисәдән таптырып алдык та сезгә хат җибәрергә булдык, — диелгән иде анда. — Йөрәгебез түзмәде. Энегезнең хәле мөшкел... Килсәгез, яхшы булыр иде. Безнең телефон...»

Икенче көнне таңнан Әлифә шәһәрара телефон станциясенә йөгерде. Үзендә телефон юк иде әле. Әнәс чирләгәндер дип коты алынган иде, Аллага шөкер, сау-сәламәт икән. Аргы баштан ир кеше читләтеп-йомшартып нидер аңлатмакчы булып азаплана иде, трубканы хатыны тартып алды булса кирәк:

— Кармен өйдән чыгып китте, Әнәс эчүгә бирелде, балалар караусыз калды, — дип ярды да салды.

...Анда барып кереп, өй эченә бер күз ташлауга, Әлифә хәлләрнең чыннан да бик аяныч икәнлеген аңлады: өй җыештырылмаган, балаларның өс-башы керле, ашарга рәтле ризык юк иде.

Карменның канатлы гыйшкы зәңгәр чәчәкле нәфис гөлдән очып китеп, әллә каян күзне ертып торган эре чәчкәлесенә барып кунган икән. Аның хәзерге мәгъшугы — Әнәснең капма-каршысы иде: башында куе кара бөдрә, кара мыеклы йөзендә ваемсыз елмаю, кулында гитара. Бармаклары — кылларны чиртүдән, аяклары тыпырдаудан бүтәнне белми. Читтән караганда күзнең явын алып, балкып торган бу гөл, якынрак килгәч, шайтан таягы булып чыккан. Егеттә җыр-бию, күңел ачу кайгысы гына, тамак ягын кайгыртырга дәрте юк икән. Анысын ул үзен сөйгән хатыннар җилкәсенә йөкләргә көйләгән. Күңел күбәләгең андыйга бер кунса, тиз генә ычкына алмассың. Кармен белән дә шулай булган. Раду исемле малайны да шуннан табып куйган икән ул. Ирне көйләү, балаларны тәрбияләү кирәклеге аның башыннан чыгып очкан, сөяркә кайгысы гына калган. Чөнки тегесен аз гына күздән ычкындырсаң да, эләктереп алырга гына торалар икән. Андыйларны буш тотмыйлар!

Ә Әнәс?..

Әнәс апасына махмырдан томанланган күзләре белән ялварып карады да:

— Аңламыйсың ла син! Менә монда яна, яна... — дип, күкрәгенә кулы белән шап-шап суккалап куйды. — Эх, вәгазь сөйләмә син миңа! Лутчы бер илле тәңкә акча бир!

Йөрәкне гыйшыкның ялкыны ялмаса, акылны аның төтене сара, күрәсең. Гашыйк кеше уңга-сулга карамый, бер ноктага — мәгъшугына гына карап бара. Юлында дөрләп учак янса да, читкә тайпыла белми...

Әйе, Әнәснең дә башын гыйшык дигән афәт ашады... Аның кырынмаган чырае сулып җыерчыкланган, иреннәре күгәренгән иде. Вакытсыз картайган иде балакай...

Әлифә балаларга ботка пешереп өлгергәнче, ак канистр күтәреп кайтып та керде ул. Монда шундый зур савытлар белән йөзем шәрабы саталар икән. Агын, кызылын, төрлесен... Әнәс алсуын алып кайткан иде, тимер кружкага салып чөмерде. Һәм апасына Карменны яратуы, аннан башка яши алмавы турында кат-кат сөйләде.

Әлифә каршында мәхәббәт дигән афәт харап иткән икенче кеше утыра иде. Беренчесе — апасы Сәрия, икенчесе менә аның улы... Мондый очракта нишләп була?

Әнисә белән Александрны — пионер лагерена, Радуны атналык бакчага урнаштырып, Әнәсне үзе белән алып китмәкче булган иде Әлифә, аны айнытып, хәлләндереп җибәрмәкче иде. Әмма паспортын таба алмадылар. Соңыннан ачыкланды: Кармен иренең паспортын сатып җибәргән икән. Рәсәй паспорты анда ярыйсы гына бәһале товарга әйләнгән, аның белән Мәскәүгәме, башка берәр урыс шәһәренәме килеп эшкә урнашырга була... Ә паспортсыз ничек юлга чыкмак кирәк?!

Бу шәһәрдә шәрабларны татып карау, ягъни дегустация урыннары бар. Әлифә Карменны шуларның берсеннән — тугыз катлы йортның идән астына урнашкан кибеттән табып алды. Йөзем төлгәшләре, ләкләк сурәтләре белән бизәлгән тәрәзәсез бүлмәне төрле төстәге лампочкалар җемелдәшеп яктырта, диварның бер ягындагы пыяла шкафның киштәләрендә төрле-төрле шешәләр тезелеп тора иде. Ымсындыргыч, серле куышның фәрештәсе булып ян ишектән Кармен килеп чыкты. Туйдагыча ук чибәр, биле нечкә, сыны сыгылмады. Өч бала табып, юанаймаган да, ичмасам, чукынмыш! Тик күзләре генә тынгысыз яна, кызартылган иреннәре генә дерелдәп-дерелдәп куя.

— Әйе, мин Әнәстән киттем,— диде ул гади генә итеп.— Андый бозау белән яшәп буламыни?

Әлифә аңа балалар турында, аларны карау кирәклеге хакында акыл сата башлаган иде, Кармен, тыңлап бетермичә, каядыр эчкә кереп китте дә түгәрәк өстәлгә яртышар литр сыешлы ике бокал китереп куйды. Андый зур савытлар белән Казанда гадәттә сыра чөмерәләр. Кара бокалларның тышына ак ләкләк сурәте ясалган, эченә мөлдерәмә итеп карасу-кызгылт сыекча салынган.

— Әйдәгез, очрашу хөрмәтенә берне күтәреп куйыйк әле. Сездә мондый нәрсә юк бит. Яшь вино дип атала бу,— диде Кармен.

— Яшен яшьтер дә, зәһәре чамасыз икән шул. Әнәсне бөтенләй эштән чыгарган,— диде Әлифә, бокалга орынмыйча. Кармен исә үзенекен тын да алмый каплап куйды. Бу якларда хәмер эчкәч нидер кабып кую гадәте юк, күрәсең, ул иреннәрен балдаклы бармакларының очы белән генә сыпырып алды.

Сүз сүзгә ялганмады. Паспорт турында сорауга:

— Кирәк булса, паспорт өстәленә барсын да алсын, — диде Кармен, исе китмичә. — Нәрсәсе бар аның. Ә мине көтмәсен. — Һәм кызыл кофта астыннан калкып торган күкрәген сыйпап куйды. — Менә монда аңа бер очкын да калмады. Сүнгән мәхәббәтне кире кабызып булмый. Күптән мәгълүм бит инде!

— Сөям-сөймим дип кенә булмый, балалар... — дип башлаган иде Әлифә, Кармен, син, кортка, йөрәк хәлләрен аңлыйсыңмыни соң дигәндәй астыртын елмаеп, аның иңбашыннан сыпыргалады.

— Сөймичә яшәп булмый! — диде. — Ә балаларның үз бәхете үзләрендә.

Кармен җиңел генә әйтсә дә, паспорт артыннан йөрү ифрат зур мәшәкать булып чыкты. Паспорт өстәлендәге хатыннар син килеп кергәндә урысча сөйләшеп утыралар, сәламенә исә молдаванча, ягъни дәүләт телендә җавап бирәләр. Гозереңне аңламамышка салышалар...

Әлифә Әнисәне алып китеп, ике ай үзендә яшәтте. Укулар башланыр алдыннан Мәскәүгә илтеп, шуннан Кишинев поездына утыртып җибәрде.

Аннан соң йөрәктәге сызлавык белән яшәргә генә калды. Әнәс хатларга җавапны сирәк яза, Әнисә исә балалыгы белән, ә бәлки, тормыш авырлыгы беләндер дә тутасын сирәк искә ала иде, күрәсең.

...Көннәрнең берендә аны шәһәрара телефон станциясенә чакырдылар. Әлифә, әлбәттә, иң элек Әнәс хакында уйлады. Ни булды икән?..

Әмма трубканы алуга, колакны каты холыклы ят ир-атның тамак төбеннән ургылып чыккан тупас тавышы ертты. Сәламне дә алып тормыйча, әмер биргәндәй:

— Заберите детей! — дип каркылдады ул. — Алып китегез балаларны!

Әлифә коелып төште. Теле бәйләнде, мие кайнады. Гәрчә нинди балалар хакында сүз барганын шундук аңлап алса да, авызыннан үзеннән-үзе:

— Каких детей? — дигән сорау ычкынды.— Нинди балаларны?

Калын тавышлы адәм Кишинев шәһәренең участок милиционеры икән. Кармен шәраб кибетеннән куылып, яшелчә сатарга алынган булган икән дә, акчасы өстенә чыккан. Суд ясап өч елга утыртып куйганнар. Элек тә караусыз балалар бөтенләй ялгыз калган. Һич кенә дә айнымый торган Әнәсне барга чутлап булмый бит инде! Милиционер, күршеләрдән сорашып, Әлифәнең адресын белгән... Һәм менә таләп итә:

— Хәзер үк килегез дә балаларны алып китегез!

Әлифә үзенең бер бүлмәле фатирында өч баланы күз алдына китерде дә тетрәнеп куйды. Бер пенсиясенә дүртәү ничек яшәрләр?

— Мин берне генә ала алам, — диде ул, тотлыгып. — Өлкәнен... Әнисәне...

Милициянең моңа ачуы чыгарга тиеш иде, Әлифә, аның телефон трубкасы аша кулын сузып сугып җибәрүеннән курыккандай, иңбашларын, муенын җыерып куйды. Әмма, ни хикмәт, теге адәмнең тавышы йомшап китте: үзе дә шуннан артыгын өмет итми иде булса кирәк.

— Озакка сузмагыз,— диде җиңел сулап.— Кайчан киләсез?

Аның йомшарганын тойгач, Әлифәнең башы нык кына эшли дә башлады. Молдавия чит илгә әверелгән, анда барып йөрү мәшәкатьле дә, ике кешегә билет алырга кесәдә акча да чамалы...

— Поездга утыртып җибәрсәгез, Мәскәүгә барып алыр идем,— диде ул.

— Юлга акчаны кем бирә?

— Мин җибәрермен... Күршеләргә.

— Мин контрольдә тотармын, — диде милиционер.

...Шулай итеп, кайсы ягы беләндер чегәнне, кайсы ягы беләндер татарны хәтерләтә торган җитеп килгән кыз бала бөтенләйгә Әлифәнеке булды да куйды.

Тыштан караганда чат әнисе үзе, суйган да каплаган. Миңе генә бит очында түгел, иягендә, чәченә ефәк тасманың кызылын түгел, алсуын бәйли... Әгәр холкы-табигате белән дә әнкәсенә охшаса?!

Бу уйдан Әлифәнең җаны убылып төшкәндәй була иде. Юк-юк, Әнисә андый булмас. Кечкенәдән энеләрен кайгыртып үсте, әле хәзер дә ярдәм итәргә тырыша. Бу яктан уйлап карагач, Әлифә аның анасы белән яшереп кенә хат алышуын да аңлый, гаепкә санамый. Димәк, үзен генә уйлый торган бала түгел, газиз кешеләрен авыр хәлдә ташламый. Туганнарына, ата-анасына игелекле кеше тормыш юлдашына да тугрылыклы булыр, иншалла. Гомумән, бик тә сизгер, шәфкатьле бит үзе. Мидхәт өчен дә әнә ничек өзгәләнә...

Һәм бу Ленизаның кимчелекләрен күргәнгә генә түгел. Анысы да бардыр, әмма төп сәбәбе бүтән. Көнләшә кызыкай. Мөгаен, йөрәгенә тылсымлы чаткы төшкән һәм ялкын үрләтеп көйдерә дә башлаган. Ни белән бетәр моның ахыры?

Әллә соң Әлифәгә тагын бер тапкыр мәхәббәт фажигасенең шаһиты булырга туры килерме? Алла сакласын! Үз тиңнәрен, гомер юлын бергә үтәрлек парларын таба гына күрсеннәр инде берүк. Әнисә Мидхәт кебекне, Мидхәт Әнисә төслене...

Аларны янәшә куеп карагач, Әлифә сискәнеп урыныннан торып утырды: «Тәүбә диген, әстәгъфирулла! Акылыңа кил! Бала бит әле ул, кем белән мавыкмас та кемгә күзе төшмәс! Укып бетерәсе бар, һөнәр аласы... Мидхәт шул Ленизасына өйләнеп куйса, безнең өчен хәерлегә булыр, мөгаен. Күзгә-башка чалынып йөрмәс, ныклап аягына басарга өлгермәгән кыз баланың күңелен алгысытмас, ичмаса!»

* * *

«Соң инде», — диде диюен Мидхәт Әлифәгә, әмма үзе, асылда, ныклы бер карарга килеп җитмәгән, һаман уйлана, һаман икеләнә иде әле. Тик бу хакта урам уртасына басып, бер-ике тапкыр гына күз күргән апа белән ачылып сөйләшеп буламыни? Иптәшләреннән берәрсенә эчеңне бушату да уңайсыз, мәсьәлә ифрат четерекле иде бит.

Мөнәсәбәтләр бер тирәнгә китсә, кире элекке эзенә кайтмый. Мидхәт белән Лениза да бер-берсенә тыелгысыз тартыла, яшерен очрашу өчен уңайлы вакыт һәм урын эзли торган булдылар. Кайчан бүлмәдәшләрнең юк чагын туры китереп, кайчан тулай торактагы спорт залының ачкычын алып торып, ашыгып-кабаланып сөешүләр гадәткә керде. Һәм табигый нәтиҗәгә китерде. Икесе дә тәжрибәсез иделәр шул. Инсаф ияләре булганга, бер-берсен ничек кенә якын итсәләр дә, оялу хисен югалтмадылар, бик күпләр өчен бияләй кебек гади тоелган нәрсәләрне кулланырга өйрәнмәделәр. Ә табигать синең чаманы-хәлең бармы дип сорап тормый, үз тәртибен үти бирә.

Октябрь урталарында Ленизаның кәефсезләнгәне сизелә башлады. Беркөнне студентлар ашханәсендә:

— Кажется, винегретлары свежий түгел иде, күңелем болгана, — дип зарланды. Шуннан соң:

— Щи исе күңелемә тия, — дип, кичләрен аш пешерергә авырсына торган булды.

Мидхәт шыр томана түгел, хатыннарның болай кәефсезләнүенә нәрсә сәбәп булганын чамалый. Тик моңа ышанасы килми иде. Аның гына түгел, Ленизаның да ышанасы килми иде булса кирәк, чөнки көннәр уза торды, алар арасында бу хакта ачыктан-ачык сөйләшү булмады.

Өеңдәге хәлне күршеңнән сора, дигәннәр, янәшә бүлмәдә яшәүче егет күзне ачты.

Кичен Мидхәт бик соңарып кына бәрәңге кыздырып ашады да юыну бүлмәсеннән тәлинкә-табасын юып чыгып килә иде.

— Әй, парин, сиңа бер сүз бар иде, — дигән тавышка туктап калды.

Коридорның бу почмагында кичләрен парлар очраша. Серләшәләр, кеше юк чакны туры китереп, үбешеп-кочышып та алалар. Баш очларында лампочка янып торганны яратмыйлар, куйган берсен борып алалар. Шунлыктан биредә ярым караңгы иде. Тәрәзә төбенә терәлеп баскан егеткә урам лампасының саран яктысы арттан төшә, тавышы тәмәке төтененнән карлыгып чыкты, шунлыктан Мидхәт беренче мизгелдә аны танымады. Өч якты ноктага — сигарет очына һәм янып торган күзләргә якынрак килгәч кенә күрше бүлмәдә яшәүче Фаязны шәйләде һәм, кулындагы савытларны тәрәзә төбенә куеп, күрешергә кулын сузды.

Алар якын дуслар түгел, Мидхәт бу егет белән икәүдән-икәү генә сөйләшкәнен хәтерләми иде. Аның пош-пош сигарет суыруыннан сүзнең бик үк матур булмаячагы сизелә, ләкин кырт борылып китү дә мөмкин түгел иде.

— Кабызасыңмы берне? — дип, Фаяз кесәсеннән сигарет кабы чыгарды. — Йөрәк януларың басылыр.

— Рәхмәт. Мин өйрәнмәдем инде... Ә син нишләп минем йөрәк яна дип уйлыйсың?

— Андый хәлгә тарысаң, йөрәккә ут каба инде ул.

— Нинди хәлгә тарыган әле мин?

— Сине йөгәнләргә чамалыйлар дигән сүз йөри,— диде Фаяз.

— Йөгәнләргә мин ат түгел лә...

— Ат булсаң, бәлки, тибеп очырыр идең дә чабып котылыр идең. Ә менә кайсыбер егетләрнең андый көче дә, елгырлыгы да юк. Андыйларга йөгәнне тиз кигезәләр. Авызлыклыйлар да сыртларына менеп атланалар. Ә аннары гомер буе шпор белән, шпор белән!.. Синең кебек эчми-тартмый торган тәти егетләрне күргәч, андый шпорлы затларның нәфесе котыра инде ул!

Фаяз хихылдап җавап көтте, Мидхәт дәшмәде.

— Карап-карап торам да кызганып куям әле мин сине... — диде Фаяз, аның битенә төтен өреп.

— Кызганырга мин бичара кыз түгел лә!

— Кызлар бичара түгел бу заманда! Егетләрнең кайсылары бичара! Ә син, күрәм, үзең хаталанып сабак ала торганнардан, башкалардан гыйбрәт ала белмисең. Күптән әйтелгән бит инде, эшләгән җиреңдә хатын-кыз белән бәйләнергә ярамый, дип. Укыган җиреңдә дә ярамый. Егет кеше күңеле төшкән кыз янына сагындырып кына барып кайтыр. Теләгәнен эшләр, күңеле кайтса, араны кырт өзәр дә китәр. Ә монда башыңны читкә борып кара! Бөтенесе аны яклап якаңа килеп ябышачак!

— Кемнең ни эше бар миндә?

— Ахмак булма. Йөгәнгә баш тыгарга ашыкма! Хәзерге кызлар оста алар һәм хәйләкәр. Башта килеп үзләре муенга асылыналар, аннары балага уздым, дип шантажларга тотыналар. Борылырга да җай калдырмыйлар. Андыйлар белән бәйләнүдән Алла сакласын. Бер баш биргәнсең икән, ычкындырмый ул сине!

Мидхәт аның чыраена ачу катыш гажәпләнү белән текәлде. Ләкин тупас сүз әйтүдән тыелды. Фаяз өч-дүрт яшькә өлкәнрәк, институтка ул, армиядә хезмәт итеп кайтканнан соң заводта бер ел эшләп, әзерлек курсларын тәмамлап кергән. Таза гәүдәле булуы да, ярты башка калкыбрак торуы да аңа күпмедер дәрәҗәдә өстенлек бирә иде. Мидхәт тешен кысты, сабырлыгын җыеп, дәшмәде. Фаязның тавышы исә йомшара бара, ул чыннан да ихлас күңелдән, яхшылык теләп сөйли иде.

— Күпме асыл егетләрдән юньсез хатыннар күндәм алаша ясадылар инде, — дип, чын күңелдән сыкрангандай дәвам итте ул. — Аң бул! Өйләнүче син, шуны онытма! Син хәл итәргә тиеш аны! Ниндидер бер чәчби түгел! Ниләр генә кыланмый аларның кайсылары. Балага уздым, дигән була, беренчесен төшерсәм, бүтән булмаячак, дип куркыта. Кызгандыра! Шантажлый! Ә син курыкма. Сәламәт хатыннар унар бала таба. Ә хаста хатын сиңа кирәкми!

— Лениза турында алай сөйләгәнне... — дип башлаган иде Мидхәт, Фаяз сигаретын идәнгә төкереп, башмагы белән ышкыды да:

— Ташла... — диде. — Мин аның турында бер начар сүз дә әйтмәдем бит әле. «Кияүгә чыгасы килә торгандыр», гына дидем. Аның ни начарлыгы бар? Ә менә шул кияүгә чыгу чарасы итеп шантажны сайлый икән...

— Нинди шантаж? Аның бернинди шантаж ясаганы юк!

— Ә корсак?

— Нинди корсак?

Фаяз хихылдап куйды.

— Анысын син миннән сорама инде, энекәш. Нинди икәнен миннән яхшырак беләсеңдер. Кыскасы, эшең комга терәлгән дияргә була. Монда сиңа басым көчле булачак. Кызлар ягыннан да, деканат тарафыннан да.

— Нинди басым? Юк сүз ул. Кем сөйли андый кара гайбәтне?

— Бирсен Ходай, юк сүз булсын! Мин сине на всякий случай кисәтәм. Ачык авыз булма! Әгәр андый хәл сизелсә, шау-шу купканчы, алдан чарасын күр. Ул сине шантаж белән алдырмакчы булса, син аны хәйлә белән алдыр. Көйлә, җайла, юмала, укып бетерүгә өйләнешербез, дип ант эч, теләсә ни кылан, тик ничек тә булса бүлнискә илтеп тык. Ул анда бер кич кунып әйләнеп чыгуга, дөньяларың яктырып киткәндәй булыр, менә күрерсең. Иптәш Сталин ни дигән? Хәер, сез бит яшьләр, белмисездер. «Нэт чэловэка — нэт проблэмы» дигән ул. Ә ул, зобани, акыллы булган! Безнең шартларга яраклаштырып тәрҗемә итсәң, «кызның корсагы булмаса, егетнең гаме булмый» дигән сүз. Хәер, егетнең генә түгел, үзенең дә хәсрәте бетәр! Тынычлап, иркенләп дипломын яклар. Ә болай бит биш ел укыганы җилгә очуы да ихтимал!

Күңелне наждак белән генә түгел, рубанок белән кыра торган сүзләр сөйли иде Фаяз! Тыңлап тормаска иде аны, борылып китәргә кирәк иде.

Әмма Мидхәт мәгънәсез елмаеп басып торуында булды. Аның аяк табаннарын бетон идәнгә беркеткән сумала дөреслек иде. Әйе, хак иде шул Фаязның сүзләре!

...Ул төнне тәрәзәләр яктыра башлаганчы Мидхәтнең күзенә йокы кермәде.

Лениза буйга узган дигән гайбәт кай арада шулай таралып өлгергән? Ә бәлки, бу әле үтә торган хастадыр?.. Бөтен язмышны хәл итә торган чорда — диплом якларга әзерләнгәндә — нинди бала ди ул тагын? Ул да шыр дивана түгел, алдын-артын уйларга, саклануның берәр чарасын күрергә тиеш иде. Ә бәлки, куллангандыр да... Тик әйтмәгәндер генә...

Әмма Мидхәтнең күңеленә шик кергән иде инде. Соңгы вакытта очрашу-сөешүләрнең кызуы да сүрелә төшкән, беренче кавышкан айлы төндә башны томалаган алтынсу томан таралып, зиһен ачылган иде. Һәм ул Ленизага тартылу көченең кими барганын тоя иде. Лекцияләрдә утырганда да башы элеккеге кебек ихтыярсыздан гел аның тарафына гына борылып тормый. Битенә текәлеп караганда, кызның юка ирен читләренең түбәнәеп, авызының кысылып куюы ямьсез булып тоела башлады. Һәм кичләрен йокыга китә алмый уйланып ятканда, тормышымны аның белән гомерлеккә бәйләү дөрес булырмы, аның бу кысылган ирен читләренә, соры күзләренең сынап каравына чыдап яши алырмынмы дигән уйлар башка килә иде.

Кыскасы, йөрәк кызуы сүрелә төшкәч, салкын акыл өскә чыкты. «Ашыкма», — ди Мидхәт хәзер үз-үзенә. Чыннан да, кая ашыгырга? Диплом якласыннар, эшкә урнашсыннар. Анда инде хәлләр үзгәрәчәк. Иртән торып юыну бүлмәсенә барганда ук бер-береңә юлыгасы да, лекцияләрдә бергә утырасы да булмас. Бер-береңә ерактанрак кararга мөмкинлек туар. Ерактан карасаң, яхшырак күренә, диләр. Кем белә, бәлки әле, Лениза үзе үк Мидхәткә суынып китәр...

Ә нигә шулай булмаска? Яңа урында эшкә урнашып, яңа кешеләр белән аралаша башласа... Алла кушып, берәрсе килеп чыкмас идеме шунда... Ах, ничек яхшы булыр иде!

Мидхәт моңа өметнең бик зәгыйфь икәнлеген аңлый, әмма бу хәлдән котылуның башка чарасын күрми иде.

...Ленизаның кәефсезләнүе үтми дә үтми һәм күңел күгендәге болытларны куертканнан-куерта иде кебек.

Бала туса, нишләргә? Ленизага, мөгаен, академик ял алырга туры килер. Бер стипендиягә өч җанны ничек асрарсың? Башны кая тыгарга да кемнән ярдәм көтәргә?

Ленизаныкылар ягыннан берни дә өмет итеп булмый: ул үзе әбисе кулында үскән, чөнки әтисе ташлап киткән, әнисе Стәрлетамакта башка иргә чыгып, аннан тапкан ике баласын үстереп ята.

Әгәр дә Мидхәт үзенекеләрдән ярдәм сораса? Әмма, әтисе белән әнисен күз алдына китерүгә, тәне эсселәнеп чыкты. Өйләнмәгән, туйлар ясамаган килеш балалы хатын ияртеп кайтуның ояты ни тора... Кабул итмәячәкләр...

Кыскасы, кайсы ягын уйласаң да, бу хәлдән чыгуның чарасы бер генә — шул ачы телле Фаяз әйткәне генә кала иде... Ә бәлки, Лениза моны үзе дә аңлыйдыр әле... Бөтенләй башсыз түгел ләбаса.

Коридорның караңгы почмагында Фаязның авызыннан тәмәке сасысына уралып бөркелгән киңәшләре саруны кайнаткан иде. Ә менә кара төндә ялгыз калып уйланып ятканда, нәкъ менә шулар җанны тынычландырып җибәргәндәй итте. Ахыр чиктә четерекле хәлдән котылу чарасын күрсәтте ләбаса ул!

* * *

Хәлбуки гайбәт группаның кураторы, философия укытучысы Алия Фәргатовнаның да колагына барып ирешкән иде инде. Аның турында, студентларының ничек сулаганына кадәр белеп тора, диләр. Хәер, кайсы берсен сизмирәк йөрсә, аның куе чәч белән капланган булса да сизгер, эре яфраклы колагына китереп ирештерүчеләр бар.

Гыйшык-мыйшык мәсьәләләрендә бу заманның «шәригат»е никадәр генә киңәйгән булса да, мәктәп балалары арасында да гыйффәтле кызлар аз калган икән, дип сөйләсәләр дә, барыбер бозыклык белән мактанып булмый. «Йоклашып йөриләр икән» дигән чыш-пыш сүзләр кешенең маңгаена күзгә күренми торган дегет белән кара тамга салып куйгандай итә.

Лениза белән Мидхәтнең мөнәсәбәтләре тирәнгә киткәне кураторга, каникул тәмамланып, укулар башлангач ук килеп ирешкән иде. Алия Фәргатовна күпне күргән кеше, таләпләрне каты куйса да, кеше хәлен аңлый, яшьлекнең абыну-сөртенүләрен гаепләргә ашыкмый иде.

Группаның старостасы Аня белән профсоюз җитәкчесе Гөлнар, аның янына кереп:

— Аларга берәр чара күрергә кирәк,— дигәч, Алия Фәргатовна:

— Мәҗит Гафуриның «Кара йөзләр»е заманы күптән узды бит инде,— дип, авызларын бик тиз каплады.— Үз хәлләрен үзләре беләләрдер. Безгә аларның укуы гына кирәк. Дипломнарын яклый алсалар, шул җиткән. Сезгә зыяннары тими торгандыр бит?

— Ничек итеп диплом яклый алсын ул? Бүлмәгә бала алып кайтса, безгә дә рәхәт булмас...

— Бала, дисезме? Эшләр шул дәрәҗәгә җиттемени инде?

— Дипломын барыбер яклый алмаячак ул быел. Берәр чарасын күрмәсә... Административ отпуск алсын әнә!

— Сезнең үзегезнең диплом хәлләре ничек соң әле?

— Эшләр өчен шартлар начар бит, Алия Фәргатовна. Яныңда косып йөрсәләр, дикъкать тарала шул ул...

— Сез сабыр булырга тырышыгыз инде, аңа каты бәрелмәгез,— диде укытучы.— Мондый чакта ыгы-зыгы килүдән бер файда да юк.

Кызлар куратордан башкачарак сүз көткән иде. Ләкин укытучың белән әрепләшеп булмый — шым гына чыгып китүдән бүтән чара калмады.

Башка берәү булса, теге ике укучысы белән сөйләшкәннән соң, иң элек Ленизаны чакырып алыр иде. Әмма кызның сагаюлы чыраен күз алдына китергәч, Алия Фәргатовна уйга калды. Чөнки бу кыз белән аның җеннәре туры килми иде.

Мидхәт исә бөтенләй башка. Аның елмаюлы йөзен, якты зәңгәр күзләрен исенә төшереп, Алия Фәргатовна тирән көрсенеп куйды... Мидхәткә ул һич кенә дә Лениза кебек пар теләмәс иде. Кайда бу егетләрнең күзе? Фәндә молекулаларның серләрен ача белгән яшьләрнең күбесе адәм баласының чыраенда ярылып яткан сыйфатларны нилектән күрми? Нинди пәрдә күзләрен каплый аларның, нинди тылсым сукырайта?!

Нишләмәк кирәк, дөнья шулай корылган шул инде. Язмыш дигәнең, булачак парларны укмаштырганда, «бер яхшыга бер яман, бер яманга бер яхшы» дип бүлә икән дигән мәзәк бар бит. Шулай саный торгач, сирәк кенә саташып китеп, «бер яхшыга бер яхшы» дип җибәргәли икән. Язмышның шул рәвешле ялгышуы аркасында гына бәхетле парлар барлыкка килә, диләр.

Алия Фәргатовна үзе, мөгаен, шундыйлардан булгандыр. Ире белән алар егерме ел тату яшәделәр. Кызганыч, Вахитның гомере иртәрәк өзелде. Бердәнбер кызлары исә, институтта укыганда ук кияүгә чыгып, ире белән бергә Харьковка китеп барды. Берьялгызы калган тол хатынның сүнмәгән-сүрелмәгән күңелендә башкага бирелеп бетмәгән наз калды. Шул назның нуры җай туры килгән саен күз карашы аша саркып Мидхәткә сибелә иде. Ничек дип атарга мондый кичерешләрне? Нечкәлекләрен уйлап тормыйча, «ярата» дияргәме? Ләкин бу сүз, уйлап карасаң, хис-тойгыларның, кичереш-омтылышларның мең төрле төсмерен үз эченә сыйдыра бит... Ананы йә баланы ярату бер, дусларны — икенче, сөйгән ярны — өченче... Яшьтәш булсалар, Алия Фәргатовнаның кыланыш-гамәлләре, уй-хыяллары бер төрле булыр иде, ә хәзер бөтенләй башка...

Ничек кенә булмасын, Мидхәт аңа һәрьяктан камил зат булып күренә, аның җирдә яшәве генә дә тормышны ямьли кебек. Андыйлар башка берәүгә авырлык, бәхетсезлек китерә алмый. Һәм тиеш тә түгел...

Икенче көнне үк семинардан соң Алия Фәргатовна Мидхәтне үз бүлмәсенә чакырды.

— Утыр әле, Халиков, — диде. Һәм өстәле аркылы каршысындагы урындыкка ымлады. — Ну, ничек анда, диплом эше языламы?

— Узган елгы курс эшенең темасын үстерергә дип килештек без Андрей Николаевич белән, — диде Мидхәт. Андрей Николаевич аның фәнни җитәкчесе иде.

Алия Фәргатовна, тәвәккәлләп, сүзне турыдан башлады:

— Синең шәхси борчуларың да бар икән... Мин шулай дип ишеттем.

— Юк... Берни юк...

Мидхәт, агач төсендәге элпә белән капланган арзанлы өстәлдән нидер укырга теләгәндәй, карашын аска төбәде.

— Лениза Фәхруллина белән мөнәсәбәтләрне ничегрәк җайларга ниятлисез соң?

Мидхәт бу кадәр үк маңгайга бәреп сораганны көтмәгән иде, кызарынып чыкканын тойды.

— Шәхси тормышны хәл итү турында диплом яклагач уйларбыз инде, — дип мыгырданды ул.

— Шулай дисеңме?

Алия Фәргатовна, дулкынлануын яшерер өчен, өстәлдә яткан журналны ары-бире шудыргалады.

— Һәрчакта да эш-мәшәкатьнең берсен алып, икенчесен куеп торып булмый шул, — диде үзалдына уйлангандай. — Ничек булса да хәл кылырга туры килә. Сез дә шундый кыен хәлдә калгансыз дип ишеттем.

Аннары бераз тынып торды да, җавап булмагач, башын күтәреп егетнең йөзенә туры карады һәм, гадәтенчә нык итеп:

— Сезгә бу хәлдән чыгу җиңел булмас,— диде.— Күп егетләр мондый чакта югалып, хәтта куркып кала. Җилкәләренә күтәрә алмаслык авыр йөк төшәр сыман тоела. Ничек тә булса котыласылары килә. Бәлки, сиңа да, шома гына ычкыну җаен тап, дип киңәш бирүчеләр булыр.

Мидхәт югалып калган иде, дәшмәде. Каян белгән? Ничек?

— Ә бит мәсьәләнең икенче ягы да бар әле, — дип дәвам итте Алия Фәргатовна. — Әйтик, туачак җан... Бу дөньяга килергә талпынган кешене әйтәм... Кайчандыр без дә аның кебек булганбыз... Кемнәрдер безнең язмышны хәл итү хакында уйланган... Яшәргә мөмкинлек бирергәме, юкмы... Уйлап карасаң, бик гаҗәп бу. Әгәр шунда, бу бала безгә әлегә кирәкми, аны кararга-тәрбияләргә шартларыбыз юк, дисәләр... Ул чакта безнең каршыда җиһанның ишеге ачылмас иде. Һәм моның өчен беркемне дә гаепләмәсләр иде... Әгәр туып өлгерсәң, сине болай гына юк итеп булмый. Суд каршына бастыралар, төрмәгә утырталар. Ә алданрак хәстәрен күрсәләр, моның өчен бернинди җаваплылык юк. Ә аерма нәрсәдә соң? Икесе дә җан кыю бит инде... Монда кешенең үз намусы хөкемдар булырга тиеш.

Сүзнең бөтенләй көтелмәгән мондый борылышыннан, аннан да бигрәк Алия Фәргатовнаның бик хисләнеп, күңел төбен актарып сөйләвеннән Мидхәтнең зиһене чуалып, йөрәге тигезле-тигезсез тибә башлады. Ул, укытучысының утлы карашына түзә алмыйча, башын түбән иде.

— Егет кеше үз кылганнары өчен үзе җавап бирергә тиеш, — дип дәвам итте Алия Фәргатовна, тавышын йомшартып. — Намус белән. Үз баласын пычак астына салып түгел!

Бу сүзләр башка яшен булып китереп суккандай итте. Мидхәтнең иңнәре салынды. Студентлар: «Алия Фәргатовнаның теле пычактай телә», — диләр, хак шул.

Артык каты бәрелгәнен ул үзе дә сизде, ахрысы, көрсенеп, тавышын йомшартты.

— Бер-ике айга чыдау турында гына сүз бара бит, — диде. — Ничек тә түзәргә кирәк. Бер җае табылмый калмас. Без дә ярдәм итәргә тырышырбыз.

Соңгысын һич көтмәгән Мидхәт, кыеш елмаеп, аңа күз сирпеп алды:

— Ничек итеп?

Алия Фәргатовна җиңел сулап елмаеп җибәрде:

— Күз күрер анда. Загска кайчан барасыгызны миңа алданрак әйтегез. Матур киенеп килергә кирәк булыр. Шаһит булып үзем кул куярга риза! Курыкмагыз, ятим итмәбез.

* * *

Тулай торак янындагы кечкенә бакчада аларның күнегелгән эскәмиясе бар иде. Кичен шунда чыгып утыргач, Мидхәт кызның салкын бармакларын кайнар учына алды да:

— Лениза, син хатын-кызлар консультациясенә бармадыңмы әле? — дип сорады.

Ярым караңгыда башын иеп, битен чигәләреннән салынып төшкән чәчләре астына яшергән кызга бу сорауның ничек тәэсир иткәнен сизеп булмады.

— Юк... барган булсам, сиңа, конечно, әйтер идем, — диде ул, ярым пышылдап.

— Күңелем болгана, дисең, ашавыңның рәте юк. Соңгы вакытта агарынып киттең. Андый чакта... врачка күренергә кирәктер бит...

— Куркам... — диде Лениза.

— Ә нәрсәдән куркасың? Әгәр теләсәң, үзем озатып куям. Иртәгә, лекцияләрдән соң...

— Кабул итәрләрме соң? Анда бит башта талон алырга кирәктер...

— Иртәгә барыйк, син тәртибен белешеп чыгарсың, мин көтеп торырмын. Килештекме?

Лениза ризалыгын белдереп ияген каккалады да башын Мидхәтнең күкрәгенә салды...

Хатын-кызлар консультациясенә, трамвайдан төшкәч, бакча аша кыйгачлап салынган сукмак буйлап барасы иде. Мидхәтнең беләгенә ныгытып ябышкан Ленизаның нык дулкынланганы сизелде.

— «Хатын-кыз консультациясе» дигән вывесканы күргәч, йорт эшләренә өйрәтә торган урындыр дип уйлый идем мин, — дип көлде ул. — Кызлар әле күптән түгел генә аңлатты.

Яше егермедән узган, югары уку йортында укучы кызның мондый наданлыгы сәер булса да, Мидхәткә бу гаеп булып тоелмады: гыйффәтле кызның андый җиргә ни йомышы төшсен?

Мидхәт джинсы чалбар, саргылт куртка кигән Ленизаның урам аша чыгып иске кызыл кирпеч бинага таба барганын, кыршылган ишектән кереп киткәнен бакчадан карап калды. Ямансу иде аңа. Төсен җуйган күк гөмбәзен октябрь аеның алама болытлары чуарлаган. Каеннарның шәрә ботакларында сирәк-мирәк сары яфраклар җилпенә, куе яшел яшь чыршылар да сагышка уралган шикелле. Аяк астына юеш яфрак түшәлгән, сулган үләннең әчкелтем исе, дымлы җир исе килә. Якыннан гына трамвай гүләп узды, тимер тәгәрмәчләр, борылышта рельсларга нык ышкылып, сызлангандай чыелдады. Бу шау-шуга агач башларында әвәрә килгән чәүкәләрнең эчпошыргыч «чаң-чаң»ы килеп кушылды

«Наданлык көчле шул бу Ленизада, — дип уйланды Мидхәт, кечкенә бакчаның тар сукмагы буйлап әрле-бирле йөренгәндә. — Аның бу хәлгә таруы да фәкать шул томаналыгыннан гына». Укуны тәмамлаганчы, аннан да бигрәк, ата-анадан әдәп өчен генә булса да ризалык сорап, исем өчен генә булса да туй ясаганчы, мондый хәлне булдырмаска кирәк иде. Гомерлеккә истә калырлык, булачак балаларына мактанып сөйләрлек итеп, ду кубып туйлар үткәрү турында хәзер инде уйлап та булмый. Җәен эшләп алган акча өс-башны карауга кереп бетте.

Тагын Фаязның сүзләре искә төште. Алия Фәргатовнаның бәгырьне актара торган карашы күз алдыннан узды. Нишләргә?

Мидхәт яфракларны шытырдатып әрле-бирле йөренде, уйларының очына чыга алмады. Ах, әгәр дә фаразлар дөрескә чыкмаса икән! Нинди яхшы булыр иде лә!

...Әмма бу зәгыйфь өмет акланмады. Иске бинадан чыкканда, Ленизаның кызарынган йөзен чалыш елмаю бозган, дымлы күзләрендә курку һәм ялвару ярылып ята иде.

— Кабул иттеләр, карадылар,— диде ул.— Алты атналык, диделәр.

Ул бик кызганыч һәм көчсез булып күренде. Мидхәт аның салынып төшкән кулыннан тотып, сукмак янындагы артлы эскәмиягә утыртты.

— Нишлим инде? — дип, башын күтәреп аңа карады Лениза.

— Үзең ничек уйлыйсың соң?

— Белмим инде. Башым буталган. Мин куркам, Мидхәт...

— Нәрсәдән? Бер синең башка гына килгән хәл түгел...

— Башкаларда минем ни эшем бар? Укуны дәвам итә алмасам нишләрмен?! Стыдно да бит... Кызлар сизеп алды инде. Ләйсән әйтә, котылу ягын кара, ди. Син беренчесе түгел, ди. Бер-ике көнгә күздән югалып торалар да балкып кире кайтып керәләр, кайда булганнарын, ни кылганнарын беркем белми кала, ди. Ахмак булма, миңгерәп йөрмә, вакытын ычкындырма, ди... Наверно, башка чара юктыр... Анда миннән кайбер анализларны алдылар инде. Ике атнага чыдасам...

Ул укшыгандай итеп кесәсеннән кулъяулыгын чыгарды.

— Ике атнадан ни була?

— Шуннан соң яткызырбыз, диде врач.

— Нәрсәгә?

— Кереп чыкмый булмас бит инде...

Менә шулай әвәрә итте дә куйды ул Мидхәтне! Фаяз әйткәннәрнең киресен сөйләде, шуның белән бөтен шик-шөбһәләрен таратты да ташлады. Баксаң, форсаттан файдаланып кияүгә чыгып калу турында түгел, бу хәлдән ничек тә булса котылу хакында уйлый икән бит ул!

Әмма Мидхәт, сөенәсе урынга үзәгенә карлы яңгыр койгандай хәлдә иде. Йөрәге астында яңа җан йөрткән хатын-кызның кичереш-уйларын ул башкачарак күз алдына китерә иде. Алия Фәргатовна сөйләгән төслерәк итеп. Ә монда...

Әйе, кеше күңеле — кара төн, дигәннәр... Хатын-кызларның да эчке дөньясы, Мидхәт күз алдына китергәнчә, гел бертөсле генә түгелдер. Берәүләрдә ул кояшлы көндә балкып торган гөлбакчага тиң булса, икенчеләрендә айсыз төндәге кара урман кебектер, күрәсең. Аның ешлыкларында елтыраган утлар да җылы учак түгел, ә яктырткыч койрыклы бөҗәкләр генәдер, бәлки...

Мидхәт тизрәк бу уйларыннан арынырга тырышты.

— Теләсә кем белән киңәшкәнче, башта миңа әйтергә ярамадымыни? — диде.

— Мин үзем дә ышанып җитмәгән идем бит әле... Алар инде күреп тә алган... Ләйсән әйтә, егетләргә ышаныч юк, мондый чакта күбесе йөргән кызын ташлап китә, ди. Иргә ышанма, Иделгә таянма, дигәннәр, ди.

Мидхәт аның беләген янтыгына кысты.

— Мин егетләрнең күпчелеге рәтенә керәммени, синеңчә? Синең өчен бердәнбер түгелмени?

— Бердәнбер, конечно, бердәнбер,— диде Лениза, ашыгып.— Ә син мине ташламассыңмы?

— Ташларга... Иске күлмәк түгел лә син...

— Алайса...— Лениза тураеп утырды.— Нишлибез соң?

Мидхәт аның яктырып киткән йөзенә, нурланган күзләренә карады. Таңнар атып, кояш чыкса, карурманнар да ямьләнә...

Нишләргә? Билгеләнгән көнне тагын шушында Ленизаны озатып куйсаң, барсы да элеккечә дәвам итәчәк, бернинди мәшәкать өстәлмәячәк...

Ләкин бу үз-үзен берничек тә яклый алмаган гөнаһсыз җан иясен үтерү була түгелме? Алия Фәргатовнаның күзенә ничек карарсың да үз вөжданың каршында ничек җавап бирерсең?

— Как-нибудь дипломны якларга иде...— диде уйлангандай Лениза.

— Анысы өчен кайгырма. Үзем язып бирермен. Ә безгә хәзер башканы хәл итәргә кирәк. Әйдә киттек.

Мидхәт нәрсәгәдер тәвәккәлләгәндәй кискен хәрәкәт белән аягына басты да Ленизаның кулыннан тартып торгызды.

— Кая киттек?

— Иң элек безгә язылышырга кирәк, — диде.

— Чынлапмы?

— Андый эшне шаярып эшләмиләр инде. Аннары без хәзер икәү генә түгел бит. Өченчебез бар. Үскәч ул, минем әти белән әни бергә укыганда танышканнар, фәлән айда туйлары булган, фәлән айда мин туганмын, дип сөйләячәк.

— Язылышу таныклыгыннан числосын да карар микәнни?

— Безнең әни ел саен туй көнен искә төшерми калмый, тәмле әйбер пешерә. Сездә... — Мидхәт киселеп калды.

— Бездә аның ишене искә алучы юк... — диде Лениза, карашын түбән төшереп.

— Кайбер халыкларда кешенең туган көнен кеше дөньяга килгәннән түгел тугыз ай электән санап бәйрәм итәләр. Чөнки яңа җанның гомере икәүнең кавышуыннан башлана, дип саныйлар. Ике чакматаш бәрелешсә, ут чыга бит? Менә шулай күз алдына китерәм мин аны. Аерым-аерым булганда, ул ут ташларның эченә яшеренеп яши. Бер-берсенә орынгач, чәчрәп тышка чыга. Үзенә бер төрле шартлау була, ялкын теле үрли, учак кабына...

— Точно! — дип, аңа елышты Лениза. — Мин сине чыннан да ут чыгардай яратам. Синең кебек матур итеп әйтеп бирә генә белмим. Дворец бракосочетаниягә барабызмы?

— Анысына ук үрелеп булмас шул... Беренчедән, анда чираттыр, озак көтәргә кушарлар. Икенчедән, андый җирдә зур тантана ясыйлар. Ата-ана, туган-тумача, дус-ишләр белән... Туй күлмәкләре кыйбатлы, машиналар бизәкле ул тирәдә...

— Аның өчен акча күп кирәк шул, — диде Лениза, моңаеп. — Әгәр бу юлы ашыкмасак, диплом яклаганнан соң, акча туплап... Без дә...

Күренеп тора, кызыкай туен гөрләтеп үткәрү турында хыялланган икән. Хәзер исә бу хыяллар җимерелә... Нәрсә хакына? Тумаган, күзгә күренмәгән җан хакына! Лениза икеләнеп калган иде.

— Бәби туен гөрләтеп уздырырбыз,— диде Мидхәт.— Ә хәзергә район загсы да ярап торыр. Балдакны мин сиңа эшли башлагач бүләк итәрмен. Паспортың яныңдамы?

...Загста алардан гариза яздырдылар да бер айдан килергә куштылар. Язылышу тантанасы ноябрьнең җепшек кар явып торган салкын, җилле көненә туры килде. Тантана үзенә күрә күңелле генә узды. Студентлар арасында озын итәкле кызыл бәрхет күлмәк кигән Алия Фәргатовна аерылып торды. Ул бер кулына күпшы кәгазьгә төрелгән кызыл розалар бәйләме, икенче кулына зур гына катыргы тартма күтәреп килеп керде. Тантана башланганчы эчке бүлмәгә узып, загс хезмәткәре белән нидер сөйләшеп, тартмасын калдырып чыкты. Баксаң, туганнарча кайгыртып йөрүе булган икән. Яшьләр дулкынланып тантана залына барып кергәндә, киң өстәлдә калын тышлы кенәгә белән алтынланган ручкалар янында берсенә — бал, икенчесенә май салынган ике бәллүр касә һәм зур подноста яшел-кызыл-сары монпасьелар белән бизәлгән чәкчәк тора иде. Кибетнеке кебек вак түгел, эре-эре итеп өйдә пешерелгән. Андыйларны авылларда гына ясыйлар. Кияү белән кәләш ягыннан туганнар килмәгән, бу, билгеле инде, Алия Фәргатовнаның эше иде. Түшенә кыеклап кызыл тасма таккан өлкән яшьтәге, туры сынлы апа, һәр парга әйтелә торган сүзләр әйтсә дә, тавышы рәсми түгел, җылы, йөзе якты иде. Кенәгәгә алтын каләм белән имзалар салынып, Мендельсон маршы яңгыраганда, Алия Фәргатовна кияү белән кәләшкә бал-май каптырды. Аның куллары тетрәнә иде.

Котлаучылар елмаешып мондый очракта гадәттә әйтелә торган: «Пар килгәнсез, бәхетле булыгыз, батыр уллар, матур кызлар үстерегез...» — дигән теләкләрне кабатладылар. Ә менә Алия Фәргатовна сүз алгач, колаклар тырпайды, чөнки ул бик җитди иде һәм әйткәннәре дә көтелмәгәнчәрәк булды.

— Мин сезгә, авырлыклар күрмичә, бер-берегездән гайрәтегез чикмичә озын гомер кичерегез, дип теләк тели алыр идем. Җырда җырланганча, күзләрне күзләрдән алмыйча яшәгез, дияр идем. Ләкин бу дөнья җәннәт түгел, кеше фәрештә түгел. Төрле чакларыгыз булыр. Бер-берегезнең хата-ялгышларын, кимчелекләрен гафу итә белегез! Ул ачы суган каптырса, менә шушындый балны капкандай, «татлы-татлы» дип елмаеп йотыгыз. Рәнҗегән минутларда да гомер юлдашыгызның яхшы якларын исегезгә төшерергә тырышыгыз. Шуларга тотынып яшәргә өйрәнегез.

Алия Фәргатовнаның керфекләрен яшь сарган, һәм бу үзенә бер ямансулыктан да иде. Яшь парның барыр юллары бик тә, бик тә сикәлтәле-чокырлы тоела иде аңа.

...Туй мәҗлесе ярлы студентларча узды. Табында табак-табак винегрет, ит белән бәрәңге, арзанлы шәраб шешәләре; бүләккә — чәйнек, сәгать, урын җәймәсе; өстәл тирәсендә чытлык, шаян яшьләр. Егетләр күрше бүлмәне бер кичкә бушатып, кияү келәте ясарга тәкъдим иткәннәр иде дә, Мидхәт каршы төште — иптәшләренә кыенлык китерәсе килмәде.

— Кирәксенсәк, спорт залының ачкычын алып торырбыз, — диде.

— Күнеккән урын рәхәт инде ул! — диде чакырылмаган кунак булып кергән Фаяз, майлы күзләрен елтыратып. — Андагы матлар калын, иркен шул! Бөтенесенә чыдый! Безнең тимер караватлардагы сырма ише генә түгел!

Ямьсез киная иде бу, әмма һәммәсенең күңеленә хуш килде, шаркылдап көлешеп алдылар, үзара чыш-пыш килештеләр.

Мидхәт сер бирмәскә тырышты, башкаларга кушылып көлгәндәй итте. Ленизаның исә чырае каралып чыкты. Аның ишене үткәреп җибәрә алмый да алмый инде, чын күңелдән әйтелгән тәбрикләү сүзләреннән дә астыртын мәгънә эзләде ул. Кызларның: «Кем белән каралсаң, шуның белән агару яхшы инде ул»,— дип пышылдашканнары колакка чагылып узды. Бу хуплап әйтелгән кебек булса да,

кәләшкә соклану, кызыгу сизелми, киресенчә гаепләү чагыла кебек иде. Ак күлмәк киргә бик үк хаклы түгел, чөнки үзе керләнгән булып санала иде шул ул.

* * *

Бәби тууга алар булдыра алганча әзерләнделәр. Арзанлыдан булса да кирәк-ярак хәстәрләделәр, китапханәдән сүзлек алып, исем сайлап куйдылар: малай булса — Рамил, кыз булса, Рамилә кушарга. Мәгънәсе бик матур икән: тылсым иясе, тылсымчы дигәнне аңлата.

Тик менә торыр урын таба алмадылар. Ә монысы һәммәсеннән мөһимрәк икән...

Мәгълүм ки, бала чыгарыр алдыннан кошлар да оя кора, кыргый җәнлекләр дә өн казый. Адәм балаларының бәгъзеләре исә гомеренең мондый чорында иң алдан үз куышын булдырырга кирәклеген онытып җибәрә.

Ә бәлки, сөю кайнарлыгыннан аның башы әйләнеп, зиһене чуаладыр? Бар дөньясы онытыладыр? Кешеләрнең кичерешләре башка җан ияләреннән күпкә көчлерәктер, бәлки?.. Әмма парын-ярын чакырып, өзелеп сайраган сандугач бездән ким хисләнәдер дип, кем әйтә алыр? Ә бит бу нәни кош һәммәсенә җитешә: сайравын да сайрый, оя корып, эченә мамык та түши...

Гашыйклар сандугачлардан үрнәк алсалар икән лә!

Ләкин юк шул, юк, күпләребез хисләрнең минутлык ургуына исерә, дөньяга киләсе яңа җан турында төптән уйлау сәләтен югалта. Кырыс чынбарлык исә җилбәзәклекнең үчен алмый калмый. Иң аянычы шунда ки, мондый үчнең иң авыры бер гаепсез, гөнаһсыз җанга төшә...

...Апрель ахырында яшь гаилә нәни Рамиләне күтәреп тулай торакка кайтып керде. Кая барсыннар тагын?.. Тик менә биш кыз яшәгән бүлмәдә балалы хатынны күз алдына китерәсезме сез? Ул бишәүгә тынычлык кирәк — семинарларга әзерләнәсе, курс, диплом эшләрен тәмамлыйсы бар. Әни кешенең дә төшеп каласы килми, инде биш ел укыгач, соңгы имтиханын да тапшырасы, дипломын да яклыйсы иде.

Җитмәсә, бала елак булып чыкты. Кыз бала гадәттә тыныч була, диләр. Ә Рамилә төненә өч-дүрт тапкыр уяна, сәгатьләр буе туктамый елый. Өч көн түзде кызлар, бер атна. Аннан артыгына чыдар әмәлләре калмады.

— Булмый бу болай, — диделәр. — Үзегезгә аерым бер почмак табыгыз!

Ә каян табасың ул аерым почмакны? Яшь балалы гаиләне фатирга кертергә атлыгып торучы бармы әллә?

Ярый, рәхмәт яусын, Алия Фәргатовна әйткән сүзендә торды, ярдәм итү чарасын тапты: нәнине вакытлыча, ике айга гына сабыйлар йортына урнаштырырга рөхсәт алдылар.

Билгеләнгән көнне иртүк алар, бала күтәреп, тулай торак ишегеннән чыгып киттеләр. Трамвайга утырдылар, төшкәч, чиста итеп себерелгән тын урам буйлап җәяү киттеләр.

Мул кояшлы, әмма салкынча май иртәсе иде бу. Шәһәр урамнарының — чиста, күңелләрнең тыныч вакыты. Мидхәт, кочагында йоклап яткан сабыйны уятудан сакланып, бер көйгә ипле генә атлап бара. Баланың кыймылдаганын сизеп, йөзен каплаган челтәрле ак тукыманы күтәрде дә битен аңа якын китерде. Һәм аннан килгән татлы истән башы әйләнеп киткәндәй булды. Тукымалар аркылы сабыйның йөрәк тибешен сизде. Аңа үз йөрәгенең дөпелдәп җавап биргәнен тойды. Ике йөрәк бергә тибә, дөресрәге, олы йөрәк белән аның дәвамы — кечкенәрәге сулкылдашып, бер-берсенә якынлыгын, газизлеген аңлаталар кебек иде. Бу хис шундый яңа, шундый көтелмәгәнчә иде ки, Мидхәт сулышына кабып тукталып калды.

Соңыннан, бу минутлар исенә төшкәндә, ул тетрәнеп китә һәм: «Шундый бәхет тә була икән!» — дип үзалдына гаҗәпләнә иде.

— Әйдә инде, — диде Лениза. — Сигезгә килеп җитегез, дигәннәр иде бит. Соңга калмыйк!

Мидхәт елмаеп баланың йөзен ак челтәр белән каплады да урыныннан кузгалды. Ике ягына әлегә шәрә юкәләр тезелеп баскан, зур йортларының тәрәзәләре иртәнге кояш нурыннан балкыган бу урам аның сабыен бәхет йортына илтеп кертергә тиеш иде кебек.

Менә алар уңга борылдылар да, милиция урнашкан бина яныннан узып, янәшәдәгесенең ишеген ачтылар. Каршыга ак халатлы, юан гәүдәле апа чыкты. Аның чырае җитди, хәтта кырыс иде. Рәтләп сәлам алып та тормыйча:

— Китердегезме? — диде.

— Сез беләсездер бит инде, без вакытлыча гына... Диплом яклаганчы, ике айга... — диде Лениза, акланырга тырышкандай.

— Ул сезгә вакытлыча, — диде үзалдына мыгырдагандай апа.— Мондый бала өчен ике ай үзе бер гомер ул. Сез дә без вакытны айлар, еллар белән саныйбыз. Ә аныкы минутлап-сәгатьләп исәпләнә. Имезә торгансыңдыр бит?

— Имезәм, әлбәттә... Мин килеп йөриячәкмен...

— Өч сәгатьтән өч сәгатькәме?! Ай-һай ла!..

Апа Лениза белән сөйләшә, Мидхәт тарафына күз дә салмый, гүяки аны күрми дә иде. Ул бу ирне кешегә санамый иде! Мидхәт ихтыярсыздан аннан баланы тартып алырга кулларын сузды. Апа аңа аркасы белән борылды да:

— Имезеп китәсең килсә, туфлиләреңне салып, башмаклар ки әнә, — диде Ленизага. — Хәзер халат чыгарып бирермен. Тәрбиячеләрнең эше тыгыз әле анда, сабыйларны ашаталар. Бераз бушаганнарын көт, үзләре белән сөйләшеп китәрсең.

— Мин дә... — диде Мидхәт.

— Ә син нәрсәгә? Син имезмисеңдер бит! Монда чит кешеләрне кертмиләр! Бу бала гомумән бокста ятачак әле. Ким дигәндә бер атна карантинда булырга тиеш ул.

Мидхәт урамда Ленизаны көтеп торган арада, янныннан бәрелә язып кемнәрдер узып китте, тик ул аларны күрмәде. Бу минутларда ул кызының кем кулында икәнен күз алдына китерергә тырыша иде. Чүпрәкләрен алыштыралар микән? Ул сабыеның нәфисак тәнен, кул-аяк буыннарындагы тирән йомшак сырларны, алсуланып торган йомры үкчәләрен күз алдына китерде. Карале, нишләп соң әле ул аларны назлап-назлап кинәнгәнче үпмәде икән? Хәзер йөгереп керергә дә... Аның хуш исле кечкенә тәненә баягы юан апа кебекләрнең салкын, битараф куллары орынуын теләми иде ул!

Тик йөгереп кереп, Рамиләкәйне ят куллардан тартып алып булмый иде шул. Алып кая барырсың? Кире тулай торак бүлмәсенәме?

Чарасызлыктан, кемгәдер ачудан Мидхәт тешләрен шыгырдатып куйды. Ленизага җиңелрәк, ул сабыен көненә берничә тапкыр кулына алып, кочагына кысачак!.. Шуны уйлап, Мидхәт хатыныннан көнләшеп куйды хәтта.

Шулай итеп, бичара сабый, әти-әниле була торып, бер атналык чагында үксезләр арасына кереп ятты. Һәм бу аның бөтен язмышына кара тамгасын салгандай итте.

...Әлбәттә инде, Лениза сабыйлар йорты бусагасын таптаудан арынмады. Өч сәгать саен ук бара алмады алуын, алай да күкрәгеннән аермаска тырышты. Һәм моңа иреште дә. Ике атнага якын. Ә аннары... Әни кеше семинарларда утырганда яисә зачет биреп йөргән арада, бала резин имезлектән татлы сыекча чөмерергә күнекте, күкрәкне көч белән суырудан бизде. Аннары тәрбиячеләр дә анасы килгәнне көтеп тормыйлар, еламасын өчен сабыйның тамагын туйдырып куялар иде. Рамиләгә анда игътибар аерым иде. Ни генә дисәң дә, ияле бала иде шул ул.

...Көннәрнең берсендә Лениза сабыйлар йортыннан ничектер сәер елмаеп кайтып керде дә:

— Рамилә имине ташлады, — диде.

Бу хәбәр Мидхәтнең йөрәген сызып җәрәхәт ясады. Тик ул моның бала өчен ясалган яраларның иң җиңеле, тиз төзәлә торганы икәнен белми иде әле. Бу минутта аны гажәпләндергәне хатынның чыраендагы җиңеләю галәмәте булды.

— Тәрбияче Лидия Кузьминична әйтте, хәзер инде тыныч лабрак укысаң да була, диде. Кайчан җитешәсең, шунда килерсең, без монда аны анасыннан ким карамыйбыз, диде.

— Чит күз шул син аларга, — диде Мидхәт, сыкранып. — Еш килеп йөрүеңне теләмиләрдер. Җитешмәгән якларын күрсәтәселәре килмидер.

* * *

Ничек кирәк алай бу чорны үткәрделәр, Лениза да ире әзерләп биргән дипломны яклады — ул чәйнәп биргәннәрне комиссия каршында шартлатып сөйләде. Кулга диплом белән эшкә юллама керде.

Әле генә диплом алган инженер-химикка үз һөнәре буенча эшкә урнашу бу заманда зур бәхет иде. Соңгы вакытта яшь белгечләрне кочак җәеп каршы алып торучы сирәк. Ә менә Мидхәтне чакырдылар. Чөнки ул студент чагында ук Н. шәһәрендәге зур бер заводның белгечләре белән танышып өлгергән иде инде. Шартлаткычлар эшли торган цехның инженеры Федор Никифорович үзе дә заманында шушы институтта укыган, елына бер-ике тапкыр Казанга килми калмый. Лабораториядән чыкмый яткан Мидхәтне ул бик тиз күреп алды, килгән саен аның белән очрашып, ясаган тәжрибәләре һәм яңа фикерләре белән кызыксынып торды, үзләренә эшкә чакырды. «Бер ел эчендә фатирлы итәрбез», — дип тә вәгъдә бирде хәтта.

Н. шәһәре Себер ягында, шактый ерак, фатиры да, мөгаен, завод тирәсендә булачак, Ленизаның анда барасы килми иде. Ләкин Казанда яхшы эшкә урнашу мөмкинлеге юк, аннан да бигрәк фатирлы булу турында хыялланып та булмый. Шунлыктан дипломнарны сумкага салып, бала күтәреп самолетка утырудан башка чара калмады.

Завод җитәкчеләре вәгъдәләрендә тордылар: яшь парны килүгә тулай тораккa, аерым бүлмәгә урнаштырдылар, өч айдан фатир бирделәр. Нәкъ шул чорда шәһәр читеннән генә җир алганнар, теләгәннәргә дүртәр сутыйлап өләшәләр иде. «Бик вакытлы килеп җиттегез»,— дип, аларны да исемлеккә керттеләр.

Бәхетле булыр өчен ни кирәк тагын? Чөкердәшеп яшә дә сабыеңны кадерләп үстер генә!

Ләкин... Ah, бәхет дигәнең тормышның җитеш булуыннан гына торса икән лә!

Өйдә савыт-саба шалтырамый калмый, диләр. Бу гаиләдә барыннан да элек сөт шешәләре зыңгылдый башлады. Сабыен яше тулганчы имезгән ананың гаме азрактыр, таң аткан саен, шешәләр күтәреп, балалар кухнясына чабасы юк, изүен генә ычкындырасы. Балага да рәхәт, үзенең дә җаны тыныч, чөнки: «Сөтне син алып кер!» — «Юк, син!» — дип, ире белән әрепләшәсе юк.

Лениза иртән бик авырлык белән кузгала, Мидхәткә исә барыбер торырга кирәк, эшкә барыр алдыннан йөгереп кенә бала ризыгын кертеп бирү аңа бер дә авыр түгел дип саналды.

Анысына түзеп була иде булуын. Ләкин ул алып кайткан шешәләрдәге сыекчаны суыргач, баланың эче еш кына күбеп авырта иде. Сабыйны корсагы белән иңенә салып, төннәрен шактый сәгатьләр бүлмә буйлап әрле-бире йөрергә туры килә иде Мидхәткә. Никадәр шулай йөрсә, сабые шулкадәр газизрәк була бара, хатынына исә ачу-рәнҗеш кабара иде.

Алай да беренче айларда яңа фатирга кот кертү мәшәкатьләре, дүрт сутыйлы бакчада тырманып йөрүләр бар көчне алды, әйткәләшүләр зурга китмәде. Лениза кайчакларда өчәр көн сөйләшми йөри иде йөрүен, анысына да чыдарга туры килде. Рамилә исә һөнәрләрен арттырганнан-арттыра, башта үрмәләп, теш чыгарып, аннары тәпиенә басып, әти-әнисен куандырып, араларны җылыта килде.

Әмма суына барган ир белән хатын арасын бала сулышы гына җылытып бетерә алмый икән шул.

Ничек кенә булмасын, вакыт уза торды, сирәк куанычларга һәм ешая барган низагларга уралып, кыш, яз, җәй үтеп китте, икенче кышка керер чак җитте. Үзәккә үтә торган ачы җилле, карлы-яңгырлы бер кичтә Мидхәт трамвайдан төште дә, куртка якасын күтәреп, муенын җыерып, светофор каршына барып басты. Яшел ут янгач, башкаларга бәрелә-сугыла, кабаланып урам аша чыкты: халык эштән кайта, ыгы-зыгы күп иде. Машиналарның тәгәрмәчләреннән чыжылдап бозлы су бөркелә, вак тамчылар башка-биткә сарыла.

Ишек төбенә җиткәч, ул туктап калды, ярдәм эзләгәндәй тирә-ягына каранды. Алар яшәгән урам бик киң һәм шау-шулы булып, каршы якта, биек каеннар һәм тирәкләр арасында, кызыл кирпечтән салынган борынгы чиркәү киңәеп, биегәеп тора. Алгы ишеге янына куелган лампалар аны астан яктыртканда, гөмбәзе, манарасы гадәттәгедән дә биегрәк тоела, аларның алтынланган түбәсе тоныкһәм серле ялтырый иде.

Эче поша иде Мидхәтнең, өйгә керәсе килми иде. Һәм моның җитди сәбәбе бар. Иртәгә иртүк аңа командировкага китәргә кирәк. С. карьерында фаҗигале хәл булган: шартлатулар уздырганда, зарядларның берсе исән калган да, актарылган тау токымын көрәргә кергән бульдозерның тәгәрмәче астында шартлаган. Бульдозерчы авыр хәлдә хастаханәгә эләккән. Ярый әле үлмәгән. Хәзер менә комиссия төзеп, кем гаепле икәнен тикшерәчәкләр: шартлаткыч сыйфатсыз булганмы, әллә шартлату эше дөрес башкарылмаганмы?

Монда инде карьер кешеләре аклану өчен бик нык тырышачак, гаепне заводка, ягъни Мидхәткә сылап калу өчен бөтен көчне куячак.

Бу хакта хатынга канын кыздырмаслык итеп ничек, нинди сүзләр белән җайлап-майлап әйтергә? Командировка диюгә җене котыра, ике генә көнгә күзеннән югалып торсаң да, җәнҗал куптара. Ә монда, мөгаен, бер атнасыз кайтып булмаячак.

Бер уйласаң, аны аңларга да була: әлегә кадәр эшкә урнаша алганы юк — тәкъдим ителгәнен яратмады, күңеленә ятышлысын тапмады. Бар карап торганы Мидхәт. Әгәр дә тормыш иптәшең бер генә көн дә синсез яшәргә теләми икән, аны гаепләп буламыни? Ярату билгесе түгелмени бу?

Мидхәт нинди сүзләр әйтергә, чырайга нинди галәмәт чыгарырга дип уйлана иде. Кайгырган булып кыланыргамы, әллә җиңелчәгә сабыштырып елмаергамы? Ике ел бергә яшәп, гомер юлдашының җаен алып бетермәгән иде әле ул. Сөешү үпкәләшүсез булмый — алар арасында да әледән-әле салкын җил исеп куйгалый, буранлаган чаклар да була. Баштагы чорда болар кояшлы яңгыр кебек тиз үтә иде.

Әмма тора-бара бик үк тиз үтми башлады...

Пыскып яуган карлы яңгыр аркылы тәрәзә утларын уйнатып, тагын бер трамвай узып китте. Ишек турыннан сирәк-мирәк узгынчылар үткәләде. Мидхәт, башын селкеп, сынын турайтты, күңелсез уйлардан арынырга тырышты. Аны хатыны гына түгел, кызы да көтә бит әле. Оеклы ыштан кигән тәпиләре белән тавышсыз атлап каршыга килер дә тезләрне кочаклап алыр...

Бу уйдан Мидхәт үзалдына елмаеп җибәрде. Һәм подъезднының кыршылган, какшаган, ямьсез итеп коңгыртка буялган ишеген каерып ачты.

Алгы бүлмә бик кысан, бер кеше генә сыя. Мидхәт курткасын салып, капюшонын каккалаган арада, бүлмә ишегенә аркылы Лениза килеп басты.

— Кайда йөрдең син?!

Шул шул менә, бусаганы атлап керүгә җавап алу башлана... Мидхәт чыраена елмаю галәмәте чыгарырга тырышты.

— Трамвай начар йөри. Озак көтәргә туры килде.

Ленизаның күзне ерта торган эре кызыл чәчәкле зәңгәр халат итәген бүлмә ягыннан бала тарткалый, нәрсәдер лепелди, әтисе янына талпына, әмма хатын моны сизми иде.

Мидхәт дәшмәде, елмайган килеш, аны сак кына читкәрәк этәреп, кызын күтәреп алды һәм йөзен аның сөткә чыланган бумази күлмәгенә терәде. Бала йөрәгенең еш-еш лепелдәве аның битенә-йөзенә бәрде һәм йөрәкне җылы куаныч белән тутырды.

Кызның ыштан төбе юеш һәм салкын икәнлеге аңына бераздан барып җитте.

— Ай-яй, кызым, нишләп болай какайланып йөрисең? Егетләр карамас үзеңә!

— Синдә һаман шул бер нәрсә кайгысы инде, — дип мыгырданды Лениза. — Заводыгызда җилпенгән юбкалар исеңнән чыкмыйдыр...

Мидхәт кулында боргаланган Рамиләнең астын алыштырды да юыну бүлмәсенә кереп китте. Сулы ваннада шактый кер җебеп ята иде. Кер юу машинасы алырга кирәк тә бит, әлегә хәлдән килми...

Ул көрсенеп кулын юды да аш бүлмәсенә чыкты. Лениза шап итеп аның алдына бәрәңге боламыгы белән сарделька салынган тәлинкә китереп куйды да:

— Без ашадык инде, — диде.

Ә Мидхәт үскән йортта кичләрен әтиләре эштән кайтмыйча табынга утырмыйлар иде...

Ата канаты астында үскән бала түгел шул бу Лениза. «Әти мин туганчы ук машина астына кереп үлгән»,— ди үзе. Баштарак Мидхәт моңа ихластан ышанган иде, соңрак, уйлана торгач, ә бәлки, аның әтисе исәндер дә әле, тик Лениза исемле кызы барын белмидер дигән фикергә килде. Хәер, әтисе генә түгел, әнисе дә аны дөньяда юк дип исәпли түгелме? Тансык бала булмаган ул, комачау гына булган. Нәни чакта ук әнисе, аны кечкенә шәһәрдә яшәүче әбисенә тапшырып, зуррак шәһәргә — Стәрлетамакка китеп кияүгә чыккан һәм кызы барын иреннән яшереп яшәгән.

Сәламәтлеккә бик үк туймаган карчыкның исә оныгын назлап-иркәләп кенә үстерергә акчасы да, дәрте-көче дә җитмәгән булса кирәк. Ә балалар әти-әниләренең яшь, чибәр, бай булганын ярата. Лениза әбисе өчен оялып үскәндер, шунлыктан аны чын күңелдән ярата да алмагандыр.

Салкын, сусыл бәрәңге боткасын тамагыннан көчләп уздырганда, Мидхәт шуларны уйлады. Сүз ялганмады. Ләкин ялгарга кирәк иде, командировка хакында әйтәсе бар, димәк, алда озаклап аңлашу, алай гына түгел, мөгаен, әрләшү тора иде. Кайнар, әмма тәмсез тоелган чәйне эчеп куйгач, Мидхәт хатынының күзеннән бераз котылып торырга, әрепләшүне дә күпмедер вакытка чигерергә чара тапты:

— Мин баланың керләрен юып алыйм әле, — дип, юыну бүлмәсенә кереп китте.

Рамиләнең керләрен юу җанны бераз тынычландырса да, күнеккән куллар бу эшне тиз төгәлләде. Юеш әйберләрне җылыткыч батареяларга таратып салу да ярты минутлык эш иде. Иң мөһим сүзне башларга исә һаман җай чыкмады.

Бер мәзәк искә төште: борынгы заманнарда бер хатын самавырын сусыз куеп эреткән икән дә шуны иренә ничек әйтергә белми аптырап йөри икән. Ул чорда самавыр — олы бер хәзинә, аны югалту зур фаҗига иде бит. Уйлый торгач, хәйләсен тапкан теге хатын. Йокларга ятып, утларны сүндергәч, иң дәртле минут килеп җиткәч кенә әйткән, имеш: «Карале, картым, мин самавырны эреттем бит!» — ди икән. «Ташла, чукынсын самавыры! — дип, аны тагын да катырак итеп кочагына кыскан ире.— Аның кайгысымыни монда!»

Мидхәт шушы мәзәкне искә төшерде дә командировка хакындагы сүзне шундыйрак минутка калдырып торырга булды. Тигез хокуклылык хөкем сөргән бу заманда ир-ат затына яраган хатын-кызга ярамый калмас!

Кичнең калган сәгатьләрен Лениза телевизор карап, дөнья яңалыклары белән танышып, президент Путинның безне бәхетле итү турында кайбер министрлар белән киңәшеп утырганын тыңлап уздырды.

Мидхәт исә бала белән мәшгуль иде. Йомшак аксыл чәчле, зәңгәр күзле кызчык чын-чынлап әтисенең кызы иде инде, суйган да каплаган. Яшь ярымлык кына булса да, карашы шундый акыллы, бераз гына моңлы да шикелле. Әтисе аңа яңадан-яңа уенчыклар, китап алып кайтып кына тора.

— Кызым, кая безнең сыер?

Бала бермәл генә уенчыкларына карап тора да кочагына чак сыярлык зур плюш сыерны башыннан тотып үзенә тарта.

— Кызым, сыер ни дип кычкыра?

— М-м-му-у!

— И акыллы да инде син, кызым! Акыллы бит, әйеме?!

Кыз ике учы белән башын сыйпый.

— Әйдәле, манара ясыйк! Мәле, бу шакмакны монысы өстенә куй әле! Хәзер бусын!

Әле теле дә ачыла башламаган бала әйткәнне бик яхшы аңлый, күрсәткәнне тиз ота иде. Шакмакларны бер-берсе өстенә өяргә дә, рәсемнәрдә куянны, баканы, маймылны күрсәтергә дә берничә көн эчендә өйрәнеп куйды.

— Кызым, күбәләк ничек оча?

Ул куллары белән җилпенә.

— Ә бака ничек ялмана?

Ул телен чыгара.

— Беләсеңме, Лениза, безнең Рамиләбез бик зур кеше булачак бит.

— Әйе, син аны зур химик итәрсең инде! — ди шаярткандай Лениза. Бала белән атаның уены аның да күңелен йомшартып җибәргәне сизелә.

— Юк, без аның үзенә сайларга ирек бирербез. Рәсем ясарга өйрәтербез. Музыка мәктәбенә йөртербез. Балет түгәрәгенә... Ә бәлки, тимераякта фигуралы шуаргадыр? Син ничек уйлыйсың?

— Алма түгел ул сиңа, бишкә бүләргә, — дип, шаярту аша чәнчеп ала Лениза.

— Яле, кызым, биеп күрсәт әле! Әллә-лә, әллә-лә, — дип кулларын чәбәкли Мидхәт. Кызчык та учларын бер-берсенә чәпелдәтеп таптанып ала. Иң кызыгы: ритмны бик яхшы аңлый!

Инде менә тездә уйный торгач, бала да арды, караватына ятып йокыга китте. Телевизордан нәфис дип аталган фильм күрсәтә башладылар, андагы геройлар тиз арада танышып-иснәшеп дигәндәй, киң караватларда әүмәкләшергә керештеләр, Ленизаның чыраенда уйнак елмаю пәйда булды. Телевизордагыларның кыланмышларын үзләренә дәвам итәр минутлар килеп җитте...

Адәм баласы яши-яши һәрнәрсәгә күнегә, көндәлек ашка әйләнгән сөешүнең-назланышуның да балы әчеп киткәндәй була. Моны Лениза да сизә башлаган һәм ирем читтән татлыракны тапмагае, дигән шикле уйдан вакыт-вакыт сискәнеп куйгалый иде. Ир белән хатынны бер-берсенә, асылда, ятак берекгерә, түшәктә ярашу — гаиләне ныгыткан иң көчле җилем дип уйлый иде ул. Ирне кулда тотар өчен, аш төрләндергән кебек, сөешүнең дә төрле ысулларын кулланып торырга кирәк дип өйрәтә бу шөгыльнең осталары һәм белгечләре. Бик тә нәзберек, яшерен һәм күңелнең иң нечкә кылларын тибрәтә торган бу гамәл дә безнең заманда үзенә бер фәнгә әверелеп, аның «профессор»лары да барлыкка килде бит. «Мин — сексолог!» — дип түш киереп, масаеп йөрүчеләр бар. Борынгы заманнарда бөтенләй мәгълүм булмаган, гади кешеләр карашынча, шактый сәер һәм хәтта оят булып тоелган һөнәр белән тамагын туйдыру гына түгел, баеп китүчеләр очрый, аларның калын-калын китаплары кибет киштәләрендә тулып ята һәм матур әдәбиятка караганда күпкә артыграк сатыла.

«Миңа да шыр надан булып яшәргә ярамас», — дип, аш пешерү турындагы китапларны ачып та карамаган Лениза да бу өлкәдә белемен һәм осталыгын арттыру чараларын күрүне кирәк санады.

...Менә алар өске утларны сүндерделәр, сару кайнаткыч кызыл япмалы торшерны кабыздылар. Кайсыдыр журналда, «кызыл төс җенси теләкне арттыра икән», дигәнне укыгач, Лениза үзләренә шундыйны алып куйган иде. Менә ул телевизордагы стриптиз биюче кызларның кыланмышларын кабатларга тырышып, әкрен генә халатын салды. Иллә дә кәттә тегәләр инде хәзерге заманда хатыннарның эчке киемнәрен! Челтәр белән бизәлгән, ука белән чигелгән җете кызыл атлас тукыма күкрәкләрнең яртысын һәм аннан түбәнрәк төшнең иң җаваплы ноктасын гына каплап тора. Бала тапканнан соң, башка күп хатыннар кебек симермәде Лениза, корсагы бүлтәеп чыкмады. Аяклары төз, биле нечкә, күкрәкләре, баланы аз имезгәнгәмедер, йомры, тере. Шәп, чукынмыш! Караватка сузылып яткан Мидхәтнең күңеле йомшаган, авызы ерылган иде. Мондый ымсындыргыч эчке киемнәр, бу кыланмышлар һәммәсе аның өчен бит!

Лениза караватка аркасы белән борылды да салмак хәрәкәт белән чүгәләде. Ире атлас лифчикның каптырмаларын ычкындырсын өчен. Стриптиз, биллəһи! Аның да иң кәттәсе! Чөнки мондыйны бик макталган төнге клубларда да татый алмассың: андагы өстәлләр артында хәмер чөмереп утыручы ирләргә сәхнәдә биюче кызларны үз куллары белән чишендерергә рөхсәт ителми, читтән карап ялманып утырырга гына кала.

Каптырмаларны ычкындырганда, хатынының шома тән тиресенә орынган бармаклары калтырана иде Мидхәтнең. Ул үрелеп торшерның утын сүндерде дә Ленизаны кочагына алды.

— Кил әле, — дип, кайнар пышылдады. — Туйганчы иркәлим әле үзеңне. Сагынып көтеп алырлык булсын!

Хатынның май кебек йомшарга тиешле сыны кинәт ныгып, тураеп китте.

— Каян көтеп алырга? Тагын командировкага китәсеңме әллә?!

Әйе, наздан тәкатьсез калып, дөньясын оныта торган зат түгел шул ул! Тәкатьсез итәрсең, бар, Ленизаны!

Менә ул тураеп утырды, урындыктан халатын алып, йомарлап түшенә кысты. Боздай салкын тавыш белән пышылдап:

— Кая? — дип сорады.

Әйтми котылып була торган түгел. Мидхәт аякларын салындырып карават кырыена утырды. Һәм берничә сүз белән хәлне аңлатып бирде. Карьерда бер шартлаткычның үз вакытында түгел, өстенә бульдозер баскач кына шартлавын, бульдозерчының авыр хәлдә больницада ятуын... Берәр дуска йә туганыңа сөйләсәң, хәленә керми калмас, синең өчен борчылыр иде. Ләкин Лениза түгел. Аның башындагы уйлар иренә аңлашылмый торган юнәлештә ага иде.

— Син врач түгел лә, аны терелтә алмыйсың, — диде ул.

Мидхәт авыр итеп көрсенеп куйды:

— Алар, мөгаен, электр чыбыкларын дөрес сузмаганнардыр. Ләкин гаепне безгә аударыр өчен җан тырмашачаклар. Һәм, бармасак, моңа ирешәчәкләр дә.

— Күпме буласың инде син анда?

— Комиссия составына керергә кирәк инде. Ә комиссияләрне үзең беләсең... Атна-ун көндә берәр нәтиҗәгә килә алсалар, шөкер итәрсең...

Лениза халатын иңенә салды да торшерны кабызды.

— Атна-ун көн?! Шул гомер нишлисез анда? Бер чокырдыр бит инде ул? Атна буе җыелышып шунда казынып ятмакчы буласызмы әллә?

— Чокыры нинди бит... Кешене имгәтеп ыргыткан упкын диярге була...

— Сиңа күз күрмәгән кешеләр жалко, ә безгә наплевать! Өйдән чыгып качар өчен мең төрле сәбәп табасың! Читтә рәхәтрәктер шул!..

Ah кahәр, сизгер үзе, Мидхәтнең бик яшерен рухи халәтен белеп алган! Әйе шул, аякларның үзеннән-үзе өйгә таба элдертә торган чаклары узды... Тик моңа кем сәбәпче соң?

Әмма алай дип әйтергә ярамый иде. Мидхәт тамагына төелгән ачы төенне йотарга тырышты.

— Әкрен, — диде. — Рамилә уянмасын... Сүндер утны!

— Ут комачаулыймы сиңа? Чыраеңны миңа күрсәтәсең килмиме? Яшерер серләрең күпме?

Лениза кычкырына башлады, Рамилә уянып елап җибәрде. Әнисе аны караватыннан тартып алды да кочагына кысты.

— Күр, кызым, атаңны! Безне күрми торыр өчен әллә ниләр уйлап чыгара!..

Дәвамын тасвирлап тормасаң да була, чөнки, һәркемгә мәгълүм, мондый ызгыш-талаш текә тау башыннан ишелгән ташкын кебек: түбән төшкән саен көчәя, киңәя һәм юлларны җимереп, һәммәсен күмеп китә... Бала елавы, бала кулы гына туктата торган түгел!

Дөрес, күпләр әйтер: «Һи-и, ир белән хатынның үпкәләшеп-әйткәләшеп алуы ул бит ашка борыч сибү кебек кенә! Аның ише ачылышып алулардан соң сөешү бигрәк татлы була», — дияр.

Кемгә ашка борыч сибү дә, кемгә таш өеме астында калу... Кычкырышу-әйткәләшү күпмегә сузылгандыр — андый чакта сәгатькә карамыйсың. Ахырда хәл бетте, елаудан баланың тамагы карлыгып китте. Ул ысылдый башлады. Мидхәт аны Лениза кулыннан алмакчы иде, хатын этеп җибәрде.

Һәрнәрсәнең ахыры була, ниһаять, бу фатирда да тынлык урнашты. Рамилә үз караватында тынгысыз йокыга талган, боргаланып, әледән-әле сулкылдап ала. Лениза караватка аркылы диярлек сузылып яткан, мендәргә капланып мышык-мышык елый. Урамнан төшкән яктылыкта идәндәге атлас трусикның чигүендәге укалар елкылдап куя. Мидхәт исә кысан аш бүлмәсенең идәнендә чалкан ята, астында эшкә кия торган курткасы, баш астында диван мендәре, өстендә плащ. Беркайчан да аның мондый уңайсыз урында төн уздырганы юк иде әле. Кадерле бала булды, урыны йомшакта иде. Институтка кергәч, анасы, андагы сасыган матрасларда аунама, дип, сарык йоныннан сырылган сырма биреп җибәргән иде. Хәтта туристик походларда да, үлән йә ботак җыеп, ятагын йомшак итеп әзерли Мидхәт.

Ләкин бу төндә ул бөтенләй кадерсез калды. Үз йортыңны да көйсез итеп була икән... Эштәге борчулар өстенә бит бу. Карьердагы шушы бер шартлау үзе генә дә аяктан егарлык хәл ләбаса!.. Мондый чакларда ир-белән хатын арасындагы мөнәсәбәтләрнең дусларча төсмер алуы бик тә табигый булыр иде ляса. Төннәрнең кайберләрендә, күккә ашып, ялкын телләрендә янып, бөтен җегәрне биреп сөешү урынына, үзара серләшеп, юатышып, бер-береңнең тигез-тыныч сулышын тыңлап ял итү дә җанга ял бирер иде.

Моның өчен Ленизаның тәне-каны, табигате дә бик туры килә иде. Мидхәт аның кыланмышлары ясалма икәнлекне күптәннән сизә иде инде. Тыштан никадәр уйнак булып кыланса да, эчендәге учак пыскып кына яна шул аның. Кармен да, Земфира да түгел, сөешкәндә дөньясын онытып, ләззәттән күккә ашалмый. Ләкин нәкъ менә шундый булып күренергә кирәк дип белә. Кайчакларда Мидхәт аның боргалануында, тигезле-тигезсез сулыш алуында үзенә бер ясалмалык тоеп ала, бу хатын ләззәткә чумган булып кылана гына бит дигән уй иректән башыннан чагылып уза. Хатыннарның өчтән бере мәхәббәтнең чын тәмен татый алмый, диләр бит, аларны «фригидный» дип атыйлар. Бу да шул өчтән бер исәбенә керми микән дип шикләнеп куя иде ул. Тик бу хакта әйтергә генә ярамый иде.

Бәгъзе акыл ияләре, тату яшәгән ир белән хатын арасында яшерен сер булырга тиеш түгел, диләр диюен дә, күңел төпкелләреннән шуышып узган уйларның һәммәсен дә яктыга сөйрәп чыгарып бетереп була микән? Һәм бу кирәк микән?

Әгәр дә Мидхәт, синең шашынган булып кылануларың миңа ясалма булып тоела, дисә, ниндирәк җавап алыр иде икән?

Кушылу-назлануларны көнкүрештәге күнегелгән тәртипнең бер өлеше дип кабул итәргә кирәк. Табынга да көн саен майлы бәлеш, кара уылдык куелмый, йоклаганда да гел генә татлы төшләр керми. Һәрнәрсәдә уртачага канәгать булып яшисең. Түшәк мәсьәләсендә дә шулайрак инде ул. Һәммә парлар дистә еллар буе бер-берсен өзелеп сөешеп, һәр төн саен акылны җуяр дәрәҗәдә назлашып яшиләр, дисәләр, моңа сай акыллы бәндәләр генә ышаныр. Ир-хатынның кушылуы — яшәешнең иң мөһим ихтыяҗларыннан берсе. Һәм аны канәгатьләндергәндә дә адәм баласы чама белергә тиеш. Күп көчен

хезмәт итүгә биреп, ипле яшәүче кешегә ата-бабача кылану да бик җиткән. Ач карынга үз вакытында ипи белән бәрәңге дә ризыкның иң татлысы булып тоела һәм артыгы кирәкми дә. Шул ук вакытта балны да чиләкләп чөмереп булмый!

Тик моны Ленизага ничек аңлатырга?..

Уйлар буталды, керфекләр авырайды...

Аңарчы Мидхәт чәчен ал тасма белән бәйләгән кызны исенә төшермәскә тырыша иде. Ә менә бу төнне ул кыз аның төшенә керде: ак чиләгеннән бер уч кызыл җиләк алып бирде. Мидхәт аларны иреннәренә китергән иде, сусыл, татлы тәмен телендә алдан ук тойган иде, тик каба гына алмады, уянып китте...

* * *

Ә шулай да Мидхәтнең Ленизадан яшерен сере бар иде: командировкага барганда ул Казанга сугылып чыгу җаен тапты. Барыбер кайда да булса бер очкычтан икенчесенә күчеп утырырга кирәк. Әйтик, Самара аша да барып була яисә Казанда тукталыш ясарга туры килә. Самарада аңа ни калган?! Ә Казанда... укыган институтына, кафедрага кереп чыгар...

Әмма, асылда, аны кафедра әһелләре түгел, башка кешеләр тарта иде.

...Әлифәләрнең ишеге ачылуга, борынга татлы хуш ис бәрелде. Бәлеш исе, бөтнек, җиләк исе иде бу. Мидхәтне туган йортка кайткач кына була торган бер иркенәю, рәхәтлек хисе биләп алды.

Аны күргәч, куанычыннан нишләргә белмәгән Әлифәнең йөзен күрде, сүзләрен ишетте, аңлап җиткермәде. Теле мондый очракта әйтелә торган сүзләрне әйтте, сәлам бирде, куллары апакайның иңеннән кочып, аркасыннан каккалады, күкрәге аның кочагында иркәләнде. Ә күзләре апаның баш өстеннән бүлмә эченә, алсу халатлы кызга төбәлгән иде. Ул, Әлифә яныннан эчкәрәк атлап, Әнисәнең нәфис кулларын учына алды.

— Ә син үсеп куйгансың, — диде.

— Юк, үсмәдем, — диде кыенсынгандай карашын читкә алып Әнисә. — Ундүрт яшьтә йөз алтмыш биш сантиметр идем, хәзер дә шулай.

— Үсте, үсте, тәмам җитеште, — дип такылдады һәм гадәтенчә кеткелдәп көлеп куйды Әлифә. — Үлән чәе эчереп үстерәм бит мин аны...

— Җиләк кайнатмасы беләндер әле...

— Анысы да җитәрлек. Быел да авылга кайттык, күп итеп җыйдык. Сине юксындык!

— Яшенгә эләкмәдегезме соң?

— Андый хәл ялан булып тормас инде, — диде Әлифә.— Без сине монда гел искә алабыз, сагынып беттек инде. Киттең дә югалдың. Адресыңны да белмибез. Өйләнгәнсең, кызыгыз туган икән. Соң ишеттек, сез киткәч кенә. Югыйсә котлаган булыр идек. Үсеп беткәндер инде. Туктале, нишләп торабыз без монда? Сал өсләреңне! Әнисә, чәй куеп җибәр!

Табын нәкъ туган өйдәгечә иде. Бөтнекле чәй бик тә тансык, алма бәлеше ашап туйгысыз, ә инде җир җиләге кайнатмасын әйтеп тә торасы юк.

Мидхәт Әлифәнең сорауларына уйлап-нитеп тормыйча җавап бирә, командировкага баруы, монда юлны бераз авыштырып кына керүе турында сөйли, дикъкате исә Әнисәдә, аның чыннан да җитлегеп-җитдиләнеп киткән йөзендә, иягендәге уем эченә куелган сихри тамгада иде. Кыз, мәктәпне тәмамлап, медицина училищесына укырга кергән икән.

— Курыкмыйсыңмы? — дип сорады Мидхәт.

— Нидән курыксын ул? — диде Әлифә.

— Бәндә хатадан хали түгел, диләр. Ялгышмыйча булмый. Ә медицинада хаталану — фаҗига дигән сүз...

— Безнеке сирәк ялгышыр, иншалла, — диде Әлифә.— Дәвалау эшенә кулы бик ята. Җәен дачада балалар бакчасында санитарка булып эшләде менә. Тәжрибә туплый.

Табынны җыеп алгач, Әлифә:

— Яныңда кызыңның карточкасы бармы? Күрсәт әле! — диде.

Мидхәт Рамиләнең фотосурәтен һәрвакыт пинжәгенең түш кесәсендә йөртә.

— Күз карашы олыларныкы кебек икән, — диде Әлифә, ул биргән катыргыны җентекләп карагач. — Моңлы балага охшаган. Артык уйчан. Карточкага төшергәндә фотоаппаратыңнан чыпчык очырмадыңмыни? Менә очып чыга, менә оча, дисәң, елмайган булыр иде...

— Аннан түгел ул, — диде Әнисә, ничектер күкрәк түреннән чыккан тавыш белән.

— Ә нәрсәдән? — дип сорады сагаеп Мидхәт.

— Йолдызлардан, ди инде ул, язмыш, ди, — диде Әлифә һәм сүзне шаяртуга борырга теләгәндәй кеткелдәп куйды.

— Аңа обстановка ярамый, — диде Әнисә, карашын аска төбәп. — Сулыш җитми.

— Бездә һава әйбәт үзе, — диде Мидхәт. — Картадан карасаң, субтропиклар киңлегендә бит. Дөрес, һавасы кинәт үзгәрүчән, континенталь климат. Кайчак кисәк кенә суытып җибәрә. Көзен, август башында каты кыраулар төшеп, бакчадагы кыяр-помидорларны һәлак итеп бетерә. Берничә көнгә каплап, саклап кала алсаң, аннары тагын җылыта, һәммәсе өр-яңадан күкрәп үсә башлый. Быел да помидорларны шулай саклап калдык. Ә кешегә андый һава файдалы, диләр. Ул якларда йөздән узган картлар күп.

— Мин һава димәдем бит... — диде Әнисә, сүзне кире үз эзенә кайтарып. — Обстановка, дидем. Татарча ничек әле?..

— Мохит диләр хәзер, мохит, — дип ярдәмгә килде Әлифә.— Хәтереңә беркетеп кал, мохит!

— Нәрсәдер бик каты борчый аны... Үзгәреш кирәк...

Мидхәт ирексездән авыр итеп көрсенеп куйды. Әнисә ачык әйтеп бирә алмаса да, сүз төбе яхшы аңлашыла иде.

— Әйдәгез әле, сезнең фотоларны карыйк! — диде Мидхәт.— Альбомнарыгыз бардыр бит?

Әнисә узган җәйне балалар бакчасында эшләгән чагында төшерелгән фоторәсемнәрне күрсәтте. Берсендә ул мандолина тотып утырган иде.

— Син музыкант тамыни әле? — дип гажәпләнеп сорады Мидхәт.

— Азрак кына уйныйм...

— Яле, уйнап күрсәт әле абыеңа! Мин синең абыең бит инде, шулай түгелмени?

— Уйна, уйна! — дип кыстады Әлифә дә.

Әнисә, шкафның аскы зур тартмасыннан мандолина алып, кылларын чыңлатып көйләргә кереште. Аннары медиаторы белән бөтен кылларга берьюлы бәреп, көмеш тамчылар сипкәндәй яңгыратып куйды. Һәм башын иеп, чак ишетелерлек итеп, Әлфия Авзалованыкына охшаганрак күкрәк тавышы белән җырлап җибәрде:

Как-то утром, на рассвете заглянул в соседний сад,
Там смуглянка-молдаванка собирает виноград...

Җыр бик таныш иде, Мидхәт эченнән генә аңа кушылды.

Встанем на рассвете зорьки ранние встречать...

Шунда ук күңелендә сүзләрнең чак кына башка төрлерәкләре яралды:

Чаганнарның яфраклары челтәрле,
Ал таңнарны бергә каршылыйк әле...
Күзләремә бер тутырып карарсың,
Сине өзелеп сөюемне аңларсың...

Менә җыр тәмамланды, ә Мидхәткә җитмәде, җитмәде! Ул, авызын ерып, Әнисәнең яңасын башлаганын көтеп утыра иде.

— Татарча да җырлап күрсәт инде, — диде Әлифә. — Балаларга җырлаганнарның берәрсен...

Әнисә, ал тасма белән бәйләнгән башын янә иеп, кылларны чиртте...

Әйт әле, күбәләк, сөйләшик бергәләп...

— Их, нигә мин шул бакчадагы балаларның берсе булмадым икән! — дип, үзе дә сизмәстән әйтеп куйды Мидхәт, җыр тәмамлангач.

Әлифә рәхәтләнеп, куанып көлеп җибәрде.

— Анда синнән, миннән башка да җитәрлек! Ата-аналар балаларын Әнисә эшләгән группага кертү өчен талашып беттеләр! — Һәм ул кызга сөеп карады.

Шулай итеп, вакытның узганын сизми дә калганнар икән. Мидхәт Әлифәнең:

— Сиңа урынны диванга җәярбез инде,— дигәненә сискәнеп башын күтәргәндә, дивардагы түгәрәк сәгать унны күрсәтә иде.

— Миннән оялып тормассың,— диде Әлифә.— Барыбыз да авыл балалары, бер сәкедә тәгәрәп үскән. Без икебез бүлмәдә ятарбыз, шәһәр кызы кухняда йоклар. Кеше килсә, аның урыны шунда була.

— Кунакханәгә урнаштым мин, — диде Мидхәт һәм кузгалып хушлаша башлады.

Әмма инде чыгып китәм дигәндә генә, үтереп эчәсе килгәнен тойды.

— Кайнаган су калдымы әле анда? — дип сорады ул.

— Кунакны су белән сыйламабыз инде,— диде Әлифә.— Әнисә, куй чәйнекне. Тик мин сезнең белән утыра алмыйм. Үпкәләмәгез. Иртәгә иртүк больниска барасым бар. Миннән дә сату иткән өчен медсправка сорыйлар бит. Поликлиникада иртәнге биштән чират торырга кирәк.

Шулай итеп, аш бүлмәсенең кызыл роза рәсеме ясалган клеенкалы өстәле янында алар икәү генә калдылар. Мидхәт үзенең ахмак кешедәй елмайганын тоя, әллә ничек кыенсына иде. Ул сүзне шаярудан башларга тырышты.

— Әллә нәрсә башым авыртып тора,— диде кайчандыр Әлифәнең әйткәннәрен исенә төшереп.

— Аспирин биримме?

— Сине кул белән дәвалый белә дигәннәр иде бит?

Әнисә кызарынып башын иде.

— Ул бит болай гына... Карчыкларда самовнушение көчле.

— Миндә дә көчле ул самовнушение! Башны сыйпап куйсаң, шифасы тими калмас, мөгаен.

Әнисә куе керфекләре астыннан кистереп карады да:

— Сезнең баш авыртмый, — диде. — Сезнең башка җирдә авыру...

— Кайсы җирдә?!

— Психологически...

Бу сүзләрдән Мидхәт сискәнеп китте. Әллә чыннан да күрәзәче сәләте бармы бу кызыкайда? Кешенең иң яшерен кичерешләрен беләме әллә ул? Ә бәлки, ул Мидхәтнең хатыны яныннан очынып диярлек чыгып киткәнен сизәдер?

Кыз, кыенсынгандай, карашын җиләк кайнатмасы тулы бәллүр савытка төшерде.

— Минем беләсем килә... — диде ул, кыюсыз гына. — Сорасам, сөйлисеңме?

— Нәрсәне?!

Мидхәтнең тавышы ирексездән калтыранып куйды. Теге чакта Әлифә әйткән иде бит Лениза хакында бу кызыкайның ниләр сөйләгәнен... Ул көнне табын янында Әнисә белән Ленизаның бер-берсен яратышмаганнары бик нык сизелгән иде, шуңа үч итеп әйтүе генә булганмы, әллә чыннан да берәр нәрсә сиземләгәнме?!

Тик кызның уенда башка икән.

— Мәсәлән, эшегез турында, — диде ул. — Сез заводта ниләр ясыйсыз?

Мидхәт җиңел сулап куйды.

— Завод эше кайда да бердер инде ул. Синең өчен кызык булмас.

— Миңа кызык, — диде Әнисә, керфекләрен күтәреп. Аның карашында чын-чынлап кызыксыну, хәтта үтенү ярылып ята иде.

— Шартлаткычлар буенча белгеч бит мин. Цех начальнигының урынбасары булып эшлим.

— Миналар ясыйсызмы? Әллә бомбаларны?

Кызның күзләрендә генә түгел, ярым ачылган иреннәрендә, бөтен йөзендә чалынган шомлану галәмәтләре күреп, Мидхәт көлеп җибәрде.

— Сез... сугышка дип эшлисезмени?.. — дип сорады ничектер куркынып Әнисә.

Кара син аны! Күрәзәче дигән булалар тагын. Беркатлы сабый бит бу!

— Шартлаткыч ул әле бомба яки мина дигән сүз түгел, — дип аңлата башлады Мидхәт. — Шартлау ул — гомумән тереклекнең башлангычы, нигезе.

Әнисәнең күзләре гажәпләнүдән зур булып ачылды. Йә Алла, нинди беркатлы бу бала!

— Һәр тереклек иясенең яшәеше нәрсәдән башлана?

Әнисә сүзсез аңа текәлгән иде. «Шартлаудан түгелдер бит инде!» — ди иде аның карашы.

— Нәкъ менә шартлаудан, — дип көлеп җавап бирде аның сүзсез соравына Мидхәт. — Шартлау нәрсә ул? Кинәт үзгәрү дигән сүз. Күзәнәк белән күзәнәк кушыла да, кинәт үзгәреш башлана. Күзәнәкләрнең тышчасы шартлап ярыла да, алар үрчи башлый. Әллә шулай түгелме?

Әнисә телсез иде.

— Моны бик борынгыдан аңлаганнар, — дип дәвам итте Мидхәт. — Шартлау элек-электән куаныч, бәхет, тантана билгесе булган. Фейерверклар, бенгаль утлары, салютлар шуннан килеп чыккан. Хәзерге вакытта алга киткән илләрнең иң кәттә шәһәрләрендә кирәксез биналарны шартлатып җимерүне зур бер бәйрәм рәвешендә үткәрәләр. Фейерверклар белән. Әйтик, Лас-Вегаста. Ишеткәнең бармы? Менә күрерсең мин, Казанга кайтып, Кабан күле буендагы берәр хәрабәне җир белән тигезләрмен һәм моны бөтен шәһәр өчен бәйрәм итеп башкарырмын! Күктән йолдыз коелыр, шәһәр нурга күмелер, җир тибрәнер, халык җырлар, биер. Күрерләр шунда шартлауның нинди могҗиза икәнен! — Кызның нык кызыксынганын күреп, Мидхәт отыры илһамланды. — Әгәр беләсең килсә, шартлаткычлар сугыш өчен уйлап чыгарылмаган, — дип дәвам итте ул. — Сугыш чукмарлары башкалар өчен уйлап чыгарганны үзләштергәннәр, шул гына. Гайрәтле, шул ук вакытта кеше ихтыярына буйсына торган шартлаткычларны барыннан да бигрәк төзүчеләр, казылма байлык чыгаручылар кирәксенә. Дөньяда иң авыр эш — җир эше. Адәм баласына исә җирне бик нык актарырга туры килә. Тауларны ерып юллар салганда да, елгаларны буганда да. Менә шул эшләрне шартлаткычлар бик күпкә җиңеләйтә. Гасыр башында галим Альфред Нобель кеше ихтыярына буйсына торган шартлаткыч булдыру өчен бик тырышып эшләгән...

Мидхәт, мавыгып китеп, Нобельнең башыннан кичкәннәр турында сөйләргә кереште. Тәжрибәләр үткәргәндә шартлаудан шактый кешеләрнең һәлак булганын, биналар җимерелгәнен... Галимнең дә могҗиза белән генә исән калганын... Нәтиҗәдә аны шәһәрдән куып җибәрүләрен... Шуннан соң Нобельнең тәжрибә өчен корылманы елга уртасындагы салда төзүен...

— Ахыр чиктә динамит уйлап чыгарган ул. Бу нәрсә шулкадәр күп кирәк булган ки, Нобель берничә завод төзегән, череп баеган. Бик күп миллион акча туплаган. Гомеренең соңында ул үзеннән соң калган акчага ел саен килеп торган процентларны дөньяда иң зур ачышлар ясаган галимнәргә премия итеп бирергә, дип васыять әйтеп калдырган. Шулай итеп, Нобель премиясенең башлангычы да шартлаткычларга барып тоташа.

Гажәпләнүдән Әнисәнең авызы ачылып, энҗе тешләре күренде. Сабый да сабый, ул да сабый иде...

— Ләкин барыбер шартлаткычларның мең сере ачылмаган әле, — дип сөйләде Мидхәт . — Күп очракларда аларны махсус ясау таләп ителә. Әйтик, җир токымы йомшакмы, әллә тоташ ташмы? Ә бәлки, мәрмәрдер? Аны нинди тирәнлектә куптарырга? Актарылган токымны кайсы тарафка, нинди ераклыкка күчерергә? Йортны җимерергә кирәк булганда, аның диварларын кайсы якка аударырга? Тирәсендәге корылмаларны зыяннан ничек сакларга? Шартлаткыч — кыргый җәнлек ул, арыслан кебек. Аны кулга ияләштерә белергә кирәк.

— Сез дрессировщик, димәк? Ләкин шартлаткыч...

Әнисә кашларын күтәреп сүз эзләде, шома маңгаенда сөйкемле сыр хасил булды.

— ...исән түгел! — дип тәмамлады ул җөмләсен.

Мидхәт тагын көлеп җибәрде.

— Тере дияргә кирәк, тере! — диде ул. — Син русча «живой» дигәнне тәрҗемә итеп әйттең. Ә ул сүз татарчадагы ике мәгънәне аңлата: «исән» яисә «тере».

— Шартлаткыч тереме?

— Бик тере! Бик! Әгәр эченә җан кертә алсаң.

— Ә ничек аңа җан кертергә?

Кызның йөзе балкып киткәнне күреп, Мидхәт отыры рухланды.

— Бөтен хикмәт шунда шул. Химиклар өчен күңел сизгерлеге, хисләр бик мөһим. Чөнки матдәнең иң кечкенә кисәкчекләре синең хисләреңне аңлый. Аларны яратырга, алар белән мавыгырга кирәк. Салкын акыл белән генә булмый.

— Димәк, мәхәббәт кирәк... — диде Әнисә, уйланып.

— Әйе, саташыр дәрәҗәдә ярату кирәк. Дөньяңны онытып шушы шөгыльгә баштанаяк бирелү! Яңа ачышларны саташмыйча гына ясау мөмкин түгел. Ә син беләсеңме, бик күп ачышлар төштә күргәннән соң ясалган?

— Сез дә шулай яратасызмы?.. Шартлаткычларны... саташырлык булып... — диде күзләрен зур ачып Әнисә.

— Аларны яратучы бер мин генә түгел. Көндәшләр дөнья тулы! Күз алдыңа китер: әллә ничәшәр катлы биналар. Эче тулы зур белемле, уңган, елгыр галимнәр. Һәркайсының дөньяны шаккатырырлык ачышлар ясап таныласы, макталасы, байыйсы килә. Чит илләрдә андыйларга яхшы түлиләр, бөтен кирәкне табып биреп торалар. Менә шулар белән ярышып кара син!

— Ә сезне... тәэмин итәләрме соң? Галимнәргә аз түлиләр, диләр бит...

— Алар белән чагыштырганда, хезмәтебез бик арзан бәяләнә, анысы хак. Әмма безнең башларга да чүбек тутырылмаган.

— Ә сез бу юлы нәрсә шартлатырга барасыз?

Бу сорау Мидхәтне очып барган җиреннән тартып түбән төшергәндәй итте. Аның башы иелде. Йөзендәге елмаю галәмәтенә моңсулык кушылды.

— Әнә, Норвегиядә шартлаткычның яңа төрен уйлап чыгарганнар, — диде ул, сорауга туры җавап бирмичә. — Аларның шартлаткычы капсулаларда, җир токымына зур булмаган тишекләр ясап тыгып кына куясы. Берәрсе кирәк чакта шартламый калса да, шул килеш тора, ул инде бульдозер китереп басса да кымшанмый. Чөнки махсус сигналга гына буйсына. Мондый шартлаткыч эшне дә күпкә ансатлаштыра, куркынычсызрак та. Безнең кайбер шахта-рудникларның җитәкчеләре үзләренә кирәкне Норвегиядән ала хәзер. Ә анда валюта белән күп меңнәр түлисе! Без менә аларныкыннан яхшыракны эшләргә уйлыйбыз.

— Сез әйттегез, аларда шундый шартлар...

— Безнең ният аларга барып ирешкән инде. Хәзерге вакытта хәбәр тиз йөри бит. Авыз ерып көләләр. Юкка азапланасыз, диләр... Без була торып, без бу эшкә ун ел гомеребезне салдык, диләр. Безнең илдә фәнни эш өчен шартлар югын алар да белә.

Әнисәнең карашы читкәрәк авышты, тирәнәеп китте, йөзе җитдиләнде, серлеләнде. Гүяки ул диварлар аша ерактагыны күрә иде кебек. Мидхәт сынын турайтып аңа текәлгән, тик кыз моны тоймый иде кебек. Шулай... мизгелләр үтте.

— Сез моны эшләячәксез, — диде Әнисә, ниһаять, карашын егетнең йөзенә күчереп. — Җиңел булмас. Ләкин максатка ирешәчәксез.

Саубуллашканда исә аның күзләрендә бөтенләй башка чалымнар барлыкка килде. Аларда соклану да, бик тә якын, үз итү дә бар иде. Җылы карашка сусаган йөрәк татлы җилпенеп куйды.

Баскыч мәйданчыгына чыккач, Мидхәт аякларын бетон идәннән куптара алмый бераз басып торды. Куллары үзләреннән-үзләре кызга таба сузылды. Аның да тәне тартылганы сизелә, ул менә-менә кочакка керәчәк кебек иде.

Мидхәт күз кабакларын авырттырып кысты. Ярамый... Хакы юк...

Әнисәнең күз төпләрендә ялкын телләре бәргәләнде, аннары шундук тоныкланып киткәндәй булды, гүяки учакка яңгыр тамчылары сибелде. «Төтен»нең зәһәре күзләрне ачыттырды.

— Иртәгә киләсеңме? — дип сорады ул.

— Юк шул. Иртәгә институтта эшем күп. Андагы яңалыклар белән танышырга кирәк. Төшләренә берәр нәрсә кермәде микән...

— Ә син буялган төшләр күрәсең, шулай бит?

— Ничек? Нәрсәгә буялган?

— Ну, художникларның картиналары кебек...

— Төсле диген... Төшкә бит ул уяу чакта күргән нәрсәләр керә. Агачлар яшел, күк зәңгәр, җиләк кызыл...

— Җиләк тә керәме?

— Керә. Ашап кына булмый. Авызыма алыйм гына дим, уянып китәм...

Мидхәт, артыграгын әйтеп ташлаганын тоеп, баскычка таба борылды:

— Сау бул!

Әнисә аны җиңеннән тотып туктатты.

— Ә самолет кайчан?

— Кич белән, — диде Мидхәт. — Сәгать сигездә.

...Бу сорауга ул әллә ни әһәмият бирмәгән, озатырга килерләр дигән уй башына да кермәгән иде. Аэропортта ак яулыклы Әлифә белән алсу берет кигән, муенына озын алсу шарф салган Әнисәне күргәч, беренче мәлдә үз күзләренә үзе ышанмый торды.

— Әнисәнең сине озатып каласы килде бит, — диде Әлифә.— Үзен генә җибәрергә курыктым.

— Рәхмәт инде!— диде күңеле нечкәргән Мидхәт.— Болай кадерләп, аздырып җибәрмәгез тагын. Мин бит андыйга күнекмәгән...

— Хатының озата барадыр бит? — диде Әлифә.

Мидхәт, ялгыш сүз ычкындырганын сизеп, башын читкә борды, сумкасының бавын иңбашында шудыргалады. Аңа ярдәмгә килгәндәй, иркен бинаны яңгыратып, хатын-кыз тавышы ул очасы рейска теркәү тәмамланып килгәнен игълан итте. Мидхәт ике кулын Әлифәгә сузды, Әнисәнең иңбашыннан каккалады.

— Сау булыгыз!— диде.— Ә сез барыгыз, китегез. Безне әле тагын берәр сәгать бикләп тотачаклар. Вакытны бушка уздырмагыз.

Әнисәнең керфекләре тетрәнә, аларны дым сарган кебек иде.

— Ә син нигә болай моңаясың, Әнисәкәй?

— Жалко-о... Кызганыч...

— Вакыт аз булуы кызганыч шул... Эш бит...

— Мин аны әйтмим, — диде кыз, карашын идәнгә төбәгән килеш. — Мин башканы...

— Ә нәрсә...

— Сак булырга кирәк сезгә. Зинһар, сак булыгыз...

— Самолет җиргә мәтәлер дип куркасыңмы әллә?

Әлифә Мидхәтне сумкасыннан тотып читкәрәк тартты.

— Әнисә төн буе йокламады, борсаланып чыкты, — дип пышылдады аның колагына. — Кызын сакласын, ди.

Мидхәтнең күңеленә ниндидер шом бәргәндәй булды. Ул Әнисәгә таба атлады.

— Син бүген бик ямансу әле, — диде.

Кыз үрелеп сак кына хәрәкәт белән аның күкрәгенә кулын куйды.

— Менә монда авырта, әйеме?

Аның йомшак, шул ук вакытта нык учыннан куртка аша агылып кергән җылы Мидхәтнең бөтен җегәрен алгандай итте.

— Йөрәк чире таптыңмы әллә абыеңнан? — дип сорады борчылып Әлифә. — Аны инде бу минутта әйтергә кирәкмәстер.

— Ә мин аны кайчан күрәм? — дип кинәт өзгәләнеп сорады Әнисә. — Кайчан килә ул?

Мидхәт ни әйтергә белми аның күзләренә текәлгән иде. Кайчан? Ул кызның кулын күкрәк турыннан алып, учына кысты.

— Озак тормам... Монда кызыклы идеяләр күп икән...— дип, буталып, ниләрдер сөйләнде.

— Ә сез безгә хат язарсызмы?

Мидхәт сәерсенеп китте. Бу кешеләр белән хат алышу башына килмәгән иде әле. Гомернең мондый чорында хатлар атаң-анаңа да сирәк языла.

Әмма кыз аңа шулкадәр мөлдерәп карады ки, ул:

— Әлбәттә, язачакмын, — диде. — Әлбәттә...

Кызның бит очлары янып чыккан, тулышкан ирен читләрендә нәни уймаклар пәйда булды. Ул кулларын сак кына шудырып Мидхәтнең учыннан алды.

Регистратура өстәле янында беркем юк, керәсе кеше кереп беткән, зәңгәр форма кигән хатын соңгы пассажирның кәгазьләрен алырга кулын сузган иде.

— Тизрәк булыгыз, — диде ул. — Хәзер ишекләрне ябабыз.

Мидхәт, ялтырап торган тимер тоткага ябышып, эчкә узды. Ул борылып, елмаеп башын игәндә, алсу башлыклы кыз, аңа таба талпынгандай авышып, шул ук вакытта якын килергә кыймыйча басып тора иде. Күңелдә кинәт, тимер аратаны кире бәреп чыгып, Әнисәне кочаклап бер үбәргәме әллә дигән тиле бер омтылыш туды. Бит очыннан гына булса да. Ләкин... ярамый иде.

— Хатларны главпочтага «до востребования» яз! — диде ул, тавышын күтәреп. — Карточкаңны җибәрергә онытма!

Әнисә аңлаганын белгертеп башын игәләде, елмаеп кулын болгады. Мидхәт, бөтен ихтыярын җыеп, аякларын эчкә таба атларга мәҗбүр итте.

Дөрес әйткән икән, аларны «накопитель»дә, ягъни юлчыларны туплый торган иркен, шыксыз бүлмәдә шактый озак тоттылар. Тик Әлифә белән Әнисә ул әйткәнне тыңламаганнар икән. Бинадан чыгып, каршыга килеп туктаган автобусның ачык ишегенә таба барганда, Мидхәт нидер сизеп борылып карады. Арырак биек багана башындагы лампа тимер рәшәткәне, аңа ябышкан алсу башлыклы кызны яктырта иде. Китмәгән... Мидхәтнең һавага, биеккә күтәрелгәнен күрәсе, очар кошларны озаткандай, күздән югалганчы карап каласы килә...

Менә ул рәшәткә аша сузылып, кулындагы алсу шарфын болгады. Мидхәт аннан күзен ала алмыйча тукталып калды. Янәшә басып торган форма кигән хатын аның иңенә орынды:

— Автобуска керегез! Тоткарлыйсыз...

* * *

Ул дөрес чамалаган икән: карьердагылар белән бәхәсләшү, тартышу ун көнгә сузылды. Фәнни-тикшеренү институтыннан белгечләр чакыртырга туры килде. Ахыр чиктә барыбер Мидхәт морадына иреште — комиссия, бәхетсезлеккә китергән шартлауда карьер эшчеләре гаепле дигән нәтиҗә чыгарды. Кире кайтканда җан тыныч, күңел күтәренке иде.

Әмма өйнең бусагасын атлап керүгә кәеф кырылды — Лениза аның сәламен алмады. Әле ул гынамы! Әнкәсенең чуар халат итәгенә ябышкан Рамилә: «Әти какай!» — дип кычкырып җибәрде. Яңа сүз өйрәнеп куйган...

Ул көнне дә, аннан соң да Лениза аны әтисенә якын китермәскә тырышты, үзе исә авызына су капкандай йөрүендә булды. Мондый өйдә күзгә ямь, җанга ял табам димә шул инде.

Нинди гадәттер ул үпкәләшкән саен атналар буе кара коелып, сораганга җавап бирмичә, үзең дә эндәшмичә, телсез-чукракка сабышып йөрү. Чит-ят кебек, хәтта дошман кебек. Моңа ничек чыдап бетмәк кирәк? Мидхәт үскән йортта да савыт-саба шалтырамый тормый, әтисе белән әнисенең кызып-кызып бәхәсләшкән, әрепләшкән чаклары булгалый. Әмма минутында әйтәләр дә бераздан суынгач, оныталар, мөнәсәбәтләр гадәти эзгә кайтып төшә. Дәшми йөрү дигәнне гомумән белмиләр.

Бәлки, шундый мохиттә үскәнгәдер, Мидхәт бүгенге көндә өендәге хәлне аерата авыр кичерә иде.

Кичләрнең берендә, смена тәмамланганнан соң урамга чыккач, ул юл читендә тукталып кире борылып карады. Завод капкасыннан халык агыла. Күпчелеге ирләр. Багана башындагы лампочкадан төшкән яктылыкта талчыккан караңгы чырайлар чагылып-чагылып китә. Хәер, әнә берсенең авызы ерык. Кара мыегы астыннан елмаеп, туп-туры Мидхәткә таба килә. Күрше йортта яшәүче Рәмис бу. Кул бирешеп исәнләшүгә, кесәсеннән бөгәрләнгән сигарет пачкасы чыгарып Мидхәткә сузды.

— Кабызып җибәр берне.

Мидхәт берне тартып алды да ул сузган зажигалкадан ут элдерде. Эченә суырмыйча гына авызыннан төтен өрде.

— Нәрсә син болай көзге чебеш кебек шәбәрдең? — диде Рәмис. — Эшегез бара, заказларыгыз җитәрлек. Командировкадан да җиңеп кайткансың дип ишеттем. Синең дә борын салынкы булгач, башкаларга ни кала? Әнә күрше цехлар атнага күп булса өч көн эшлиләр. Заказлар юк!

Бөтенесен белә Рәмис, чөнки завод идарәсендә тәэминатчы булып эшли.

— Тормыш эш белән генә чикләнми бит әле...

Бу сүзләр Мидхәт авызыннан зарлануга уралып чыкты.

— Аңлашыла-а-а... — диде Рәмис. — Әйдәле, кореш, бераз тамак чылатып чыгыйк.

Каршы якта кечкенә базар бар, андагы ларекларда төрле вак-төяк саталар. Аларның берсендәге сыраханә төн уртасына кадәр эшли һәм бер дә буш тормый. Биек, түгәрәк өстәлләр янында басып торыр өчен кайчакта урын җитми.

Тәмәке төтененә сасыган, өстәлләре күксел-соры таплар белән чуарланып беткән, колакны тондыргыч шау-шулы бу шыксыз урынны Мидхәт яратмый, сырага да хирыслыгы юк. Әмма бу юлы ул кесәсендәге акчаны капшады да Рәмискә иярде.

Аларның өстәле янына тагын икәү килеп басты. Якыннан ук таныш булмасалар да, күзгә чалынган кешеләр. Кружкаларның беренчесен чөмергәндә, эш азлыктан, акча юклыктан зарланышып алдылар, икенчесенең күбеген өргәләгәндә, йөзләр ачыла төште, тагын да берничә йотым кабып куйгач, сүзләр дөнья гаменнән аерылып, йөрәк тирәләренә күчте, ягъни хатын-кызга килеп ялганды. Алар турында гәпләшү — аракыга да, сырага да иң шәп кабымлык бит ул!

Ир-ат сыра йотып, тәмәкесен кабызса, сүз җебенә хәләл һәм хәләл булмаган җефетләр килеп чуалмый калмый. Хатын-кызларның күбесе үзләре турында ирләрнең ниләр сөйләгәнен күз алдына да китермидер. Тик гаепләргә ашыкмагыз, гүзәл ханымнар. Ирләрне табигать сезгә караганда дәртлерәк итеп яраткан, шунлыктан бу мәсьәлә аларны күпкә ныграк гамьләндерә. Мөселманнарга дүртәр хатын белән яшәргә рөхсәт ителә икән, бу юкка гына түгелдер. Дәрте ташып торсын да, шулхәтле тамакны туйдырырлык чамасы гына булсын — бер ир заты дүрт хатынны бәхетле итә ала. Һәм үзе дә алар белән бәхетле була ала.

Таплы түгәрәк өстәлләргә терсәкләрен терәп басып торган ирләрнең чырайларында уйнак елмаю пәйда булды, һәркайсының хыялында ямьле өй, чибәр, мут хатын гәүдәләнде. Соңгысы, бәлки, берәү генә дә түгелдер. Чын тормыш һәм өйдә көтеп торган хәләл җефетләр ерагайды, күздән югалды. Монысы үзенә бер рәхәт иде. Уйлап карасаң, өзелеп сөюгә лаекмы соң алар? Көндезләрен нужа арбасын өстерәп, кичкә хәлдән таеп, урынга барып ятуга оеп китә торган җан ияләре... Ирләрен ничек бәхетле итә алсын алар?

Чынбарлык күңелсез, хыяллар тормышка ашмаслык. Ачы ризасызлык сыраханә әһелләренең эчендә сыра күбеге булып күперә һәм авыздан бүселеп чыга. Ниләр генә ишетмисең кайчакларда!

Хатыннарның хиссезлеге, тупаслыгы, ир рәхәтен айга ике тапкыр кулга кергән акчаның мөмкин кадәр күбрәк булуында һәм тынгы белми эшләп торган кулларында гына дип белүләре турында... Эштә чамадан тыш уңган, иренә дә тик торырга ирек бирми торган, әмма түшәккә яту белән изрәп китеп, күкрәгенә кул салуга кәҗәләнә башлый торган хатыннар турында... Ир затына нишләргә? Ургылып торган дәрт-назны кая куярга? Сатлык кызлар янына барыргамы? Ләкин кая бездә андый ышанычлы урыны да, кая аның чистарак, рәтлерәгенә түләрлек акчасы?

Андый зарларны тыңлаганда, Мидхәтнең чыраенда тыенкы елмаю гына кабына иде.

— Ә синең ничек соң? Ник бер дә дәшмисең?

— Зарланырлык түгел...

— Әллә ярап бетә аласыңмы?

— Соң, тырышам инде.

— Тырышып нишлисең?

— Өйдә ярдәм итешәм... Ул өлгермәгәндә бала керләрен юам...

Моны ишеткәч, ирләр бераз сүз таба алмый аптырашып тордылар. Бераздан берәүсе үзалдына мыгырдагандай:

— Бала керен иреннән юдырткан хатынны мин аны...— дип куйды.

Икенчесе, түшәмгә төтен өреп:

— Алай димәгез, — диде. — Керен юарга да риза булырсың, идәнен дә! Соңрак теге мәсьәләдә генә татлы булсын. Төн аралаш дигәндәй үз хатыныңны тотып көчләргә туры килсәме? Андыйдан яманы юк!

— Без бит үз хатыннарыбызга сатлык хатыннарга караганда чагыштыргысыз күбрәк түлибез, ник өйләнеп маташабыз икән? — дип уфтанып куя шунда берәрсе.

Мидхәт, башын иеп, кружкасына текәлгән иде. Эче тулы зар булса да, тәмәке сасысына туенган бу ямьсез бинада, кыршылган, таплы өстәл янында, тупас ирләрнең йонлы колагына түгә торган түгел иде. Күңел ярасына тәмсез телләрдән затсыз сүзләр сибелүен теләми иде ул. Чыраена бәреп әйткәннәре юк, әмма аның артыннан, хатынының итәк астына кереп беткән, шуннан көн күрә, дип сөйләп йөргәннәре сизелә иде. Андый ирләрне ил мактамый шул инде. Әгәр йортта хатын баш икән, аны кешегә белгертергә һич ярамый.

— Ул инде, корешлар, хатыннарның явызлыгы борынгыдан килә, — диде гадәтенчә шук елмаеп Рәмис. — Юлий Цезарь әйткән, ди әнә, ил каршында нинди генә бөек шәхес булып саналсаң да, өеңә кайткач, аңгыра, надан булып каласың, чөнки мең гаебең табыла, дигән, ди.

Рәмис китап укырга ярата, шунлыктан башкалар янында белемле, мәгълүматлы булып санала. Һәммәсе дә, кружкаларын куеп, аңа текәлделәр.

— Әле менә гәзиттә бер гыйбрәтле мәкалә укыдым. Исеме дөньяга танылган галим-академикның өенә бер рәссам килгән икән. Портретын ясарга. Каршысына җайлап утырткан тегене, үзе мольберт артына баскан. Художниклар бит алар эш арасында сүз куертырга ярата. Кешенең эчендә ни ятканын беләселәре килә. Соңгы вакытта фән кешеләре политикага кысылуны мода итеп алдылар бит. Бу галим

дә зур политик буларак танылды. Рәссам ул инде фәнне тирән аңламый, политиканы исә барыбыз да беләбез. Боларның да сүзе думага, партияләргә авышкан. Шунда теге карт: «Мин политика белән кызыксынмыйм», — дип әйтеп ташламасынмы! Шул тирәдә тыңланып йөргән карчыгы килгән дә учы белән шалт тегенең пеләшенә! «Ничек кызыксынмыйсың? Без демократия өчен көрәшергә тиеш! Бөтен көчебезне биреп!» — ди икән. Художник телсез калган! Шулай булмый ни! Бөтен Рәсәй халкы Алла урынына санап йөргән кешенең башын хатыны дөмбәсләсен әле! Ярый, бусы ялгыш кына булгандыр дип уйлап, берничә минуттан тагын сүз башлый бу. Менә бездә Американы мактыйлар, үзебез кылганнарны салып таптыйлар, ди икән. Галим ык-мык килгән, хатыны янә моның пеләшенә чәпегән. Әңгәмә шул рәвешле бара, рәссам сүз арасында мольбертына сызгалый икән. Бераздан теге чәүчәләк хатын ул сызгалаганга күз салса, ни күрсен! Анда моның чырае акаеп карап тора икән. Убырлы карчык кыяфәтендә. «Бу ни?» — дип акырган ул. «Мин монда ил агасының портретын ясарга килгән идем, идән чүпрәген түгел», — дигән художник.

— Шуннан? Оят булмаганмы ул хатынга?

— Хатыннар азса, оятны беләмени!

— Андыйлар турында минем әби: «Эят дигәннең э хәрефен дә белми», — ди торган иде. Ул шулайрак сөйләшә иде, мәрхүмә.

— Ә соң академик нишләгән?

— Бернишләмәгән. Андый хәлгә төшсәң, нишли аласың... — дип, мыек астыннан елмаеп куйды Рәмис. — Хатын теге художникны пырылдатып куып чыгарган. Шул. — Аннары Мидхәткә борылды да, мәгънәле итеп: — Укы әле син аны! — диде. — Бездә булырга тиеш ул. Хатын чүпкә чыгарып атмаса...

Сыра янына бер йөз граммны да кушып җибәргәнгә күрә, ул шактый кызды. Коңгырт күзләре майланды, кара мыегы тырпайды. Шаян сүз арасында Мидхәтнең колагына пышылдап алды:

— Синең заначкада тагын бераз калмадымы анда?

Бер башлагач, тыела алмый торган гадәте бар иде шул бу җор телле, ачык чырайлы егетнең.

Мидхәт аны җайлап-көйләп алып чыгып китү ягын карады. Калдырып булмый: үз кеше, гаилә дусты дияргә була. Бер заводта эшлиләр, күрше булып диярлек яшиләр. Рәмисләрнең җиде айлык уллары бар, шунлыктан хатыннар да якыннан аралаша.

Ул исә өенә ашыкмый иде, ишек төпләренә кайтып җиткәч тә Мидхәтнең җиңеннән тотып, җибәрмичә шактый сөйләнеп торды.

— Соң инде,— диде Мидхәт.

— Ә нәрсә вакыт санап яшәргә безгә? Күз ачуга сәгатькә кара, заводта минутлар сана... Эштән соң да санаргамы әллә? Ир-егет хөр булырга тиеш! — дип, бармагын ишек өстен ышыклап торган шыксыз бетон плитәгә төбәде ул.

— Әнә хатыннар санасын! Вакытын да, акчасын да, башкасын да. Алар янына ашыгып кайтырга ярамый, кореш! Сагынып каршы алсыннар! Көтә-көтә зарыгып, елап бетсеннәр. Хатын-кызның йөрәк хисләре ачы күз яшьләре белән юылса, яңарып, ялтырап китә! Ул бәргәләнсен-өзгәләнсен, ә син нык бул! Хатынга башны да, йөрәкне дә бирергә ярамый! — Бу урында Рәмис шап итеп маңгаена сугып куйды, аннары каты итеп күкрәгенә бәргәләде. — Монысына да, монысына да үзең хуҗа булырга кирәк. Җебеп төшсәң, аяк асларында чүпрәк булсаң, кадереңә калмый. Аның өчен янып көл булсаң да, ах бәгырем, харап була күрмә, димәячәк, төтенең күзгә керә, дип тиргәячәк. Алар белән беркатлы булырга ярамый. Бер кулыңнан чыбыркыңны төшермә, икенчесенә прәннек тот. Вакытын белеп ярсаң, аннары бераздан прәннек каптырып, кочагыңа алсаң, менә шунда була аның өчен оҗмах. Анысы вакытояк өчен бәхәсләшергә дә кирәкми. Елга яна, ди икән, ие шул, бәгырькәем, мин дә күрәм янганын, диярга кирәк. Күңеле булсын! Ә зурларын әйтергә ярамый. Ю-ук, ярамый, кореш!

Мидхәт, подъезд ишеген ачып, Рәмисне, эчкә сөйрәде.

— Эшкә урнаштыр син аны, — дип һаман акыл өйрәтүендә булды Рәмис. — Барлы-юклы бер баланы карыйм дигән булып, өйдә сөрсеп ятмасын. Эшсезлек тә ялкаулык аздыра гына ул Алла бәндәсен. Бигрәк тә хатыннарны. Андый чакта, урыс әйтә, хатынның башында тараканнар үрчи, ди. Дөрес әйтә, чукынган! Син эштә чакта, баласын бакчага илтер дә, аннары нишләмәс! Тик яту яхшыга илтми ул. Ялкаулык ул — дөньядагы бөтен бозыклыкның анасы, дигәннәр, хак сүз! Бозылмасын, дисәң, хатыннарны баш күтәртми эшләтергә кирәк аларны!

Мидхәт аны, биленнән кочып, өченче катка алып менде дә уң яктагы ишек яңагындагы кыңгырау төймәсенә төртте. Бераз көткәч, бармакны төймәгә басып озаграк тотты, эчтән сузынкы зыңгылдау ишетелде, әмма хәрәкәт сизелмәде. Бу гажәп тоелды. Рәмис сүзенә ышансаң, хатыны аны көтә-көтә көтек булып беткән, күз яшьләрен түккән булырга, кыңгырау тавыш бирүгә, ишекне киң ачып, хәләл җефетен кочагына алырга тиеш иде бит югыйсә. Ә монда...

Ниһаять, ишек ачылды, вак чәчәкле зәңгәр халат кигән хатынның сыны бусагага аркылы басты, куе чәче астыннан күзлек пыялалары хәтәр ялтырады. Ул, Мидхәтнең сәламен дә алып тормыйча:

— Ник китердең син моны? — дип, Рәмискә таба йомры ияге белән ымлады. Мондыйны һич көтмәгән Мидхәт югалып калды.

— Син нәрсә, Рәйсә... Бу хәлендә урамда калдырыйммыни? Айныткычка алып китсеннәрме әллә?

— Кайда эчкән булса, шунда айнысын иде, — диде Рәйсә.

Рәмис нидер мыгырдый калды, Мидхәт, борылып, баскычтан аска йөгерде.

* * *

Атналар-айлар узды. Лениза да үз өендәге хәлгә күнегеп киткәндәй булды. Ул инде ир-хатын мөнәсәбәтләренең нечкәлекләрен өйрәткән журналларны сатып алмый, укымый. Чөнки моның белән Мидхәтнең гайрәтен генә чигергәнен белә. Матур эчке киемнәр киеп, ирең каршында боргалану оят сыман тоела башлады хәтта. Хуплап, сокланып карап торучысы, дәртләнеп кабул итүчесе булганда гына күңелле бит ул андый кыланулар. Әгәр ир кеше: «Тилергәнме әллә бу!» — дип сәерсенеп карап тора икән, шәрә тән боргалануларның ни тәэсире, ни ләззәте булсын?

Бер караватта йоклагач, сөешүләрсез дә булмый, чөнки табигать үзенекен итә. Тик алар арасындагы бу фарыз гамәл ата-бабадан калган рәвешкә кайтып калды. Атнага бер-ике мәртәбә Мидхәт, хатынының күкрәгенә кулын салып, үбәргә үрелә. Ә Ленизаның башында һаман бер уй: «Элеккечә түгел, элеккечә түгел!» Әйе, Мидхәтнең хәрәкәтләреннән теге беренче айлы кичтәге кебек тәнне өтәрлек кайнар наз бөркелми, өзек-өзек сулышыннан ялвару һәм тәвәккәллек ургылмый, очыну сизелми иде шул инде. Ул хатынының иреннәрен авырттырып, тиеш булганга гына үбә. Әгәр тиеш булмаса, үбеп тә тормас, тән ихтыяҗын канәгатьләндерү өчен болай гына кушылыр иде... Мондый уйлар Ленизага онытылып назланырга, сөешүнең тәмен-ләззәтен ахырынача татырга ирек бирми. Берничә минут үтүгә, алар икесе ике якка авышалар. Мидхәт шундук йокыга китә, һәрхәлдә сулышы бик тиз тигезләнә. Лениза исә беренче төннәрне соңгылары белән тагын-тагын чагыштыра: «Моңа гына риза булмас... Ул бит әнә нинди кайнар иде... Башканы табар... Ә бәлки, тапкандыр да инде... Семьяны саклар өчен, Рамиләне югалтмас өчен генә минем каршымда бурычын үтәведер бу...»

* * *

Заводта, Рәмисне тәэминат бүлегендә туган көне белән зурлап котлаганнар икән дигән сүз колакка чалынды. Эштән кайтканда Мидхәт, Рәмисне очратып:

— Дус булып йөргән буласың, туган көнеңә кунакка да дәшмисең, — дип үпкә белдереп куйды.

— Нишләп дәшмәсен! Шимбә көнгә ниятләп куйган идек. Әйтергә генә өлгермәдем, авызымнан тартып алдың! Икегезне генә чакырабыз, саф татарча сөйләшеп, җырлашып утырырбыз рәхәтләнеп!

Табында, чыннан да, алар ике генә пар иделәр. Дуслык өчен бер-икене күтәреп, Рәйсә пешергән токмачлы аш, гөбәдия белән нык кына сыйланып алгач, өстәл яныннан кузгалдылар. Лениза белән Мидхәт иркен кәнәфиләргә күчеп урнаштылар, Рәйсә диванда ике баланы — Рамилә белән җиде айлык Илдусны — уенчыклар белән юатырга кереште.

Рәмис бакыр бакалы кечкенә гармунын кулына алды да:

— Мондыйлар юк хәзер, миндә генә, — диде. — Фатих Кәрим язган кыңгыраулы яшел гармун бу, кореш. Безнең татар җырлары өчен шуннан иплесе юк инде. Күтәреп йөрергә дә җиңел.

Һәм кычкырып җырлап җибәрде:

Хәтердә ул тыныч, айлы кичләр,
Хәтердә бормалы су юлы...

Аңа хатынының күңелгә ятышлы, йомшак тавышы кушылды. Парлашып еш җырлыйлар, күрәсең, тавышлары бик тә яраша, икесе бердәй хисләнгәннәр. Рәйсәнең Рәмискә таба авышкан гәүдәсендә, алланып чыккан түгәрәк бит очларында, хәтта күзлек пыялаларының елтыравында да башын гармунга иеп утырган иренә соклану, бәхете белән мактану, хәтта бераз масаю ярылып ята иде. «Карагыз, күрегез, менә без нинди матур пар!» — ди иде аның бөтен кыяфәте.

Менә җыр тәмамланды, Рәмис башын күтәреп, гармун күреген нык итеп кысып куйды.

— Хәзер дә җырларның бик шәпләре ишетелә радиодан, — диде. — Кайсылары еш яңгырый, күңелгә кереп кала. Ишеткәнегез бармы?

Һәм ул, гармунын тезендә биетеп, башлап җибәрде:

Күл буенда ялгыз аккош, каерылган канатлары...

Гади генә сүзләр... Җиңел генә көй... Ләкин ник соң күңел кылларын болай сызландырып тибрәтә?

Аерылмагыз, аерылмагыз, булса да сәбәпләре,
Канатларны каера ул аерылу сәгатьләре...

Ачылды күңел бакчасының капкалары, сайрады гөлләргә кунып сандугачлары... Лениза, керфекләрен кыса төшеп, хисләрен бүлешергә теләп, Мидхәткә борылып карады. Һәм... өстенә салкын су коелгандай бөрешеп китте.

Мидхәт, авызын ерып, бөтен гәүдәсе белән алгарак авышып, Рәйсәгә текәлгән иде. Йөзендә шундый соклану, шундый хозурлану!

Ә Рәйсә... Аның күзләре баш очындагы сабыенда...

Нәрсәсе бар? Нигә селәгәе аккан бу Мидхәтнең? Аның беркайчан да үз хатынына болай итеп онытылып караганы юк бит! Һәрхәлдә, Ленизаның моны сизгәне юк!

Бу уй, көнләшү хисе бәгырьгә пычак белән сызгандай итте. Ә бәлки, алар арасында нәрсәдер бардыр? Лениза белән Рәмис кенә сизми йөриләрдер?

Ләкин Рәмис берни күрми, башын гармун күрегенә терәп, шыңгырдатып ниндидер көйне исенә төшерергә азаплана иде. «Ахмак! — дип, нәфрәт белән карады аңа Лениза. — Борын төбеңдә хатыныңа кармак салганнар, ә син!..»

Рәйсә, кинәт нидер сизгәндәй, баланы тезенә бастырды, башын иеп, башта Мидхәткә, аннары Ленизага карады. Кызганыч, калын пыялалар аша күзләрен күреп булмады...

Лениза көчәнеп чыраена елмаю галәмәте чыгарды. Кунакта чакта ирең белән әйткәләшеп булмый бит инде... Мәҗлес үз тәртибе белән барды: тагын берничә җыр жырладылар, туган якларны сагынып искә алдылар, чәй эчтеләр.

Әмма өйгә кайтып, арган-талган баланы йоклаткач, өске утларны сүндереп, кызыл торшерны кабызгач, өстен алыштырганда, Лениза эченә җыелган ачуын чыгарды.

— Күрше хатыннарына күз сала торган гадәтең барын моңарчы белми идем әле, — диде ысылдап.

Мидхәт аның сүз төбен аңлады, кызарынып чыкты. Шуның белән хатынының шиген раслады да куйды. Ә үзе:

— Мин аңа түгел бит... — дип мыгырданды.

— Ничек инде аңа булмасын... Тасыраеп утыра идең бит дөньяңны онытып! Күрше тавыгы күршегә күркә булып күренә, диләр...

— Мин бит аңа түгел... Дөресрәге, үзенә түгел...

— Ә кемнең үзенә?!

— Анда ракурс шундый иде... Фактура... Яктылык... Сәнгать әсәрендәге кебек...

— Шулаймыни-и?! Ракурсы удачный булдымыни? Моңарчы андый фактураны күргәнең юк идемени?

— Кайсыдыр рәссамның портретын хәтерләтте ул миңа... Мадонналарны шулай ясыйлар. Юкка үпкәләмә... Картиналарга сокланып караган кешене тиргәп булмый бит инде. Музейга барырга да рөхсәт итмәс идеңме әллә?

— Сиңа музейдагылар гына җитмәс шул... Сиңа тереләре кирәк!..

Китте-китте, ишелде җәнҗал ташкыны... Хатын кычкырынды, ир телен аркылы тешләде, бала уянып еларга тотынды...

Ниһаять, хәлдән таеп, тынып калгач, утлар сүндерелгәч, Мидхәт аш бүлмәсенең идәнендә, инде күнегелгән юка сырмада уйланып ята иде. Ул яңадан Рәйсәне күз алдына китерде. Сокландыргыч иде шул! Атаклы рәссамнарның картиналарындагы кебек. Баш очында кети-кети көлеп тибрәлгән йомры ак тәнле сабый мәхәббәт алласы төсле иде. Мидхәтнең карашы аскарак, ананың чиксез сөю белән балкыган йөзенә, йомшак муенына, сөттән тулышып торган күкрәкләренә күчте. Һәм, гөнаһ шомлыгына каршы, аның бөтен тәнен күз алдына китерде. Атаклы рәссам Рембрандтның «Даная» картинасындагы төследер ул. Кичләрен, утлар сүнеп, ятарга әзерләнгәч, сөю-назга сусаган тәнен Даная кебек калкыта микән? Бәлки, аңа шул минутларда тәрәзә аша ай нуры сузыладыр? Аның бу омтылышында, зарыгып көтүендә якты, кайнар хис бар, әмма чамасыз нәфес, комсызлык дигән нәрсә юк. Фәкать иң тыйнак назның да кадерен белү, башыңнан сыйпаудан гына да олы ләззәт алырга әзерлек бар...

...Ә бит Рәйсәне искитәрлек чибәр дип булмый иде. Шәһәр урамнарында йөргән хатыннарның яртысы шундый. Холкы-табигате белән дә чәчрәп күзгә керми, күктән йолдыз чүпли торганнардан түгел. Ул фәкать бар булганның кадерен-тәмен белеп яши торган хатын.

Мидхәтнең гаиләсенә нәкъ менә шул җитми иде. Менә нилектән сокланып, кызыгып карады ул Рәйсәгә! Һич тә өзелеп гашыйк булганнан түгел!

...Кемнәрдер әйтер: көнләшүгә сәбәп бирмәскә кирәк, дияр. Әгәр дә синең бер карашың, ихтыярсыздан йөзеңә бәреп чыккан елмаю галәмәте көнләшү дигән күсене котыртырга сәбәп була икән, моннан котылу чарасы бармыни? Күңелгә бер кереп ояласа, син инде ул ерткычны ансат кына куып чыгарам димә. Вакыт-вакыт тынып-посып торса да, җай туры килгән саен уяна да эчтән кимерә башлый, адәм баласын үрле-кырлы сикертә ул. Хәнҗәрдәй тешләрен авыр сүзләр рәвешендә авыздан чыгарып, иң якын кешеңнең бәгыреңә кадый.

* * *

Мондый хәлгә юлыккан парларның күбесе күрше белән аралашуны туктата. Ленизаның да башына килгән беренче уй шул булды.

Ләкин, төрле ягын уйлап карагач, ул бу фикереннән ваз кичте. Чөнки бер нәрсәне аңлады: хикмәт Рәйсәдә түгел, Мидхәттә. Әгәр дә ир кеше читтән юаныч эзли башлаган икән, барыбер үзенекен итәр: берсе белән очрашырга мөмкинлеге булмаса, икенчесен табар. Ни генә дисәң дә, бусы күз алдында әле. Әгәр син белмәгән берәрсе белән бәйләнсә? Мәңге эзенә төшә алмассың! Шуны яхшы аңлаганга күрә, Лениза өйдәгене тышка чыгармады, күршесенә йөзен бозмады, араларны өзмәде.

Көннәрнең берендә Рәйсә, аларга кереп:

— Әнинең үлгәненә биш ел тула, ирләр эштә чакта, хатыннарны гына җыеп, Коръән ашы үткәрәм әле, — диде. Аннары бик тә мәгънәле итеп: — Фирдания үзе килә! — дип өстәде. — Сәгать өчкә кер, яме!

...Затлы нигъмәт тулы озын өстәл тирәли тыгызланып утырган унбишләп хатын-кызның күбесе карчыклар иде. Башларында ука белән чигелгән ак яулык, сулган йөзләрендә тыйнаклык, сабырлык. Күбесе үзара таныш булса кирәк, шыпырт кына хәл-әхвәл белешәләр, туган-тумачаларын сорашалар. Сүзләр күңелне төшерә торган: кемдер үлгән, кемдер эштән куылган... Аерылышкан... чирләгән...

Яшь кеше буларак, Лениза ишек төбендәрәк утырды. Аңа сүз кушучы булмады, үзенең дә ятлар белән сөйләшәсе килмәде. Шома чәченнән әледән-әле шуып төшкән күксел ефәк шарфын төзәткәләп, табындагы әфлисун-алма, җимеш тулы савытларга күз йөгерткәләп хәрәкәтсез утырганга, вакыт бик әкрен узды, зарыктырды. Ә дога укуны һаман башламыйлар да башламыйлар.

Ниһаять, Рәйсә, аш бүлмәсе ягыннан кереп:

— Нишләптер Фирдания соңарды бит әле, — диде. — Сәгать уникегә ашка барасым бар, шуннан туры монда киләм, дигән иде, һаман күренми. Берәрегез укый торасызмы әллә?

— Юк инде, көтик. Фирданиядән узып булмый...

— Аның кебек булдыра алмабыз шул, — диештеләр карчыклар.

— Адресны буташтырмады микән? Чыгып каршы аласызмы әллә? — диде берсе.

...Кинәт кемдер, ярым пышылдап:

— Килде... — диде.

Сүзләр өзелде, сыннар турайды, карашлар ишек тарафына төбәлде. Лениза да башын борды. Ким дигәндә сиксән яшьлек бөкерәйгән кортканы күрермен, дип уйлаган иде ул. Ә анда... Анда озын буйлы, төз гәүдәле, урта яшьләрдәге хатын кереп баскан иде. Чибәр идеме ул? Һич юк. Эре сөякле, зур башлы. Озынча йөзен тукмак борыны бозып тора... Ләкин бер күргәч онытыла торган да түгел үзе. Озын итәкле һәм җиңле, ябык якалы, ачык яшел костюмы бик тә заманча тегелгән, андыйны мөслимәләр генә түгел, Европа кызлары да кия ала. Яшел яулыгы башына шундый пөхтә итеп уралган, сәхнәдә яңа киемнәрне күрсәтүче кызларга — манекенщицаларга да килешер иде... Алай да хикмәт аның киемендә түгел, кыяфәтендә, басып торышында иде. Затлылык, үз кадерен белү, шул ук вакытта башкаларга сак игътибар бөркелә иде аннан.

— Әссәламегайләйкем, кардәшләр! — диде ул, бераз калынрак, әмма йомшак җылы тавыш белән. — Кичерегез, бераз көттердем.

Һәммәсе шаулашып торып бастылар һәм:

— Сине алай гына көтәбез инде... Килүеңә рәхмәт...— диешеп, түргә уздырдылар.

Ленизаның икеме-өчме тапкыр гына Коръән ашында булганы бар һәм алар аның күңелендә шактый моңсу тәэсир калдырган иде. Абыстайлар гадәттә догага керешер алдыннан озын итеп вәгазь сөйли, бер тотынгач туктый алмый. Сүзләре һаман бер үк нәрсәләр: ата-ананы хөрмәт итү, фәкыйрьләргә сәдака бирү, чисталыкны саклау зарурлыгы, биш вакыт намазның фарызлыгы турында... Бер үк сүзне күп тапкырлар кабатлый. Башка кунаклар исә, табындагы авыз суларын китерерлек нигъмәтләргә карап, зарыкканын сиздермәскә тырышып, баш иеп тыңлап утыра. Мондый абыстайларның озынга сузылган нотыгы Ленизаның эчен пошыра иде. Бу да шулай күп сөйләп тәмам гарык итәр микән?

Әмма Фирдания андыйлардан түгел икән. Ул, урынына урнашып, кыска гына дога кылды да табынны елмаеп күздән кичерде.

— Ягез әле, борчуларны, кайгы-хәсрәтләрне онытып торыйк,— диде. — Өстән безгә Рәйсәнең анасы Гайшәттинең рухы карап тора. Аның тирәсендә барыбызның да газизләренең рухлары. Алар һәммәсе дә шат. Чөнки без аларны искә алырга җыелдык. Якты, тыныч күңел белән башлыйк. Әгузе биллаһи мина шайтан ирражим, бисмиллаһи...

Фирдания Коръән сүрәләрен дә бик тә җайлы итеп, көйгә салып укый, сүзләре аңлашылмаса да, бер дә ялыктырмый икән...

Сүрәләр укылып, догалар кылынып, табындагы нигъмәтләр белән сыйлана башлагач, дөнья хәлләре турында сүз китте. Фирдания бу шәһәрдәге татар җәмгыятенең оештыручысы да икән әле. Казан белән элемтә тота, мөмкинлеген табып, аннан төрле вәкилләр, артистлар чакыруны оештыра.

— Артистлар килгәндә гафил булып кала күрмәгез, безнең белән элемтәне өзмәгез, — диде ул.

Мәҗлес тәмамланып, дога кылгач, һәммәсе, дәррәү урыныннан кубып, алгы бүлмәгә чыккан Фирданияне уратып алдылар. Кайсы ашка чакыра, кайсы догалыклар сорый, кайсы мәчеттә дәресләрнең кайчан буласын белешә. Ике кулыннан, чабуыннан тотып алганнар, җибәрмиләр генә. Менә нилектән бирегә дә соңга калып килгән икән ул!.. Барган җиреннән җибәрми интектерәләр икән аны!

Бу галәмәтне читтәнрәк күзәтеп торган Лениза кызыгып куйды. Аның үзен беркайчан да бу кадәр кирәксенгәннәре юк иде шул...

Нихаять, соңгы кунак артыннан ишек ябылгач, ул Рәйсәгә табын җыештырышырга каласы итте.

— Бу Фирданиягә бал сыланган диярсең, һәммәсе ябышырга гына тора, — дип башлады ул сүзен.

— Кеше булган кешедә мең кешенең эше бар, кеше булмаган кешедә кешенең ни эше бар дигәннәре дөрес шул, — диде Рәйсә, тәлинкәләрне сулы табакта чайкаган арада. Ярый әле күтәрелеп карамады, күршесенең йөзе тартышып куйганын күрмәде.

Лениза, тамагына килгән ачыны йотып:

— Абыстайга бер дә охшамаган үзе, — диде. — Урамда очратсам, артист икән бу, дияр идем. Коръәнне каян өйрәнгән соң ул?

— Әбисеннән, аннары әнисеннән. Әбисе патша заманында абыстайларда укыган аның...

Һәм Рәйсә кыска гына итеп Фирданиянең тормыш кыйссасын сөйләп бирде. Хәтирәнең ун баласы булып, шуларның өчәве генә исән калган, башкалары бала чакта үлеп беткән. Ире дә алтмышка җитүгә дөнья куйган.

Фирданияне, институт тәмамлаганнан соң, бу якларга татар теле укытучысы итеп эшкә җибәргән булганнар. Ул елларда мондагы кайбер татар авылларының мәктәпләрендә ана теле дәресләре булган әле. Ул биредә берничә ел эшләгәч, авылда ялгыз калган анасы сукырайган, аның өстенә паралич сугып, урын өстенә егылган. Фирдания аны үз янына алган. Совет хакимияте беренче группа инвалидларны тәрбияләгән өчен эш стажын исәпли, акча да түли торган булган, ул шуңа яшәгән.

— И бичара, — диде Лениза, Фирданияне чын күңелдән кызганып. — Нишләп алай иткән соң ул?

— Башкача нишләсен?

— Инвалид ананы балалары чиратлашып караса, әйбәтрәк була, диләр бит...

— Апаларының үз гаиләсе, балалары бар. Үзләре эштә. Урын өстендәге хастага аерым игътибар кирәк бит ул. Алай да берничә ай асрадылар. Ул арада Фирдания дә баш-күз алды, бер кеше белән танышып җибәрде. Бик матур гына аралашып димме, йөрешеп димме алганнар иде. Никахлашканнар да хәтта. Без инде аларны менә-менә загска барып язылышырлар дип тә уйлаган идек. Теге кешенең законлы хатыны барлыгы соңыннан гына беленде. Фирдания моны бик авыр кичерде. Өстәвенә нәкъ шул көннәрдә әнисенең караватыннан егылып төшеп хәле авырайганын хәбәр иттеләр. Хастаны бик белеп карарга кирәк бит аны. Карчыкның уң ягы бөтенләй йөрми, сул кулы белән алырга җайлы булсын өчен, Фирдания аңа кирәкне билгеле бер тәртип белән урындыкка тезеп куя торган булган. Ә тегеләр җаен белмәгәннәр. Хәтирәтти су алырга дип үрелгән дә капланып килеп төшкән. Ник элегрәк барып алып кайтмадым икән, дип, мең үкенде Фирдания. Теге ир белән булган хәлләрне анасының каргышы төшүдән дип аңлады.

— Каргыштан түгелдер инде! Ирләр гомумән хатын-кызны алдаудан тәм таба!

— Аның тегесе, хатынымны аерам да өйләнешик, дип тә караган бугай. Фирдания үзе ризалык бирмәгән, диләр. Тегенең элекке хатыныннан туган балаларын ятим итәсе килмәгән. Анасын кире үзенә алып кайткач, ул ирнең дә хасталы өйгә йортка керәсе килмәгәндер инде... Шуннан соң Фирдания больницага кереп чыккан...

— Нервы белән чирләгәнме әллә?

— Юк ла... Хатыннар больницага өч көнгә ник керә?..

— Бала төшергәнмени?

— Нишләсен инде, бичара? Шул хәлләрдән соң бала таба алмый торган булып калган, диләр.

Ленизаның күз аллары томаланып китте. Әле генә яктырып балкыган ай тотылгандай булды...

— Хәзер ялгыз яшиме? — дип сорады Лениза.

— Анасы үлгәч, бер ир белән никахлашкан. Тегесенең хатыны үлгән, өч баласы бар.

— Кеше балаларын тәрбияләргә калган икән алайса.

— Ул аны авырга алмый. Киресенчә, Ходайның рәхмәте дип кабул итә.

Юеш тәлинкәләрне коры тастымал белән сөртеп торган Лениза, эшеннән туктап, Рәйсәгә текәлде:

— Анасы үлсә дә, авырга алмый, ире ташлап чыгып китсә дә, баласыз калса да... Ул ничек була инде?

Рәйсә дә эшеннән туктады, башын күтәреп, күзлекләре аша көлемсерәп аңа текәлде:

— Хак Тәгаләгә чын күңелдән ышанганга шулай, — диде. — Син белмисеңмени, иманлы кешеләргә яшәү җиңелрәк бит.

— Кая җиңел? Чир-чор, кайгы-хәсрәт дигәнең дин тоткан кешеләрне дә әйләнеп үтми. Аларның да башына төрлесе килә.

— Дога кылып кына бәла-казадан котыла торган булса, ул инде Алланың рәхмәтен сатып алу булыр иде. Чын күңелдән ышанган кешенең рухы нык була, шуңа күрә кайгыларны ул җиңелрәк кичерә. Чөнки үзен беркайчан да ялгыз хис итми. Ходай миңа юлдаш, ди. Хәер, Фирданиянең ялгыз булганы юк та. Абруе бик зур бит. Мәчет салганда да хезмәте күп кергән. Дин сабакларын да күбрәк ул укыта. Мулла итеп куярлар иде — итәге комачаулый... Яхшы гына йорт салып бирделәр үзенә. Байлар әйтә, шундый мөхтәрәм кешене тыгынлыкта яшәтү гөнаһ, диләр.

— Шөгыле доходлы икән үзе,— дип чәнчеп алды Лениза.

— Бу шәһәр өчен ул үзе зур табыш! Мәчеткә барып егылмаган кеше сирәк. Ахыр чиктә берәүнең дә йомышы төшми калмый.

— Син үзең дә абыстай кебек сөйлисең, — дип куйды Лениза.

Рәйсә көлеп җибәрде:

— Укытучы ич мин, элеккечә әйткәндә, шул ук абыстай... Алай да Фирданиягә җитеп булмый. Кая-а-а! Мәчеткә дә ике-өч кенә тапкыр кергәнем бар. Әмма иманым калебемдә! — Рәйсә юеш кулын күкрәгенә куйды.— Әгәр Ходайга ышанмасам, газиз әнкәемне бүген ничек искә алыр идем?.. Имансыз яшәп булмый! Мин болай уйлыйм: атам-анам миңа кан, җан биргән, исем, тел биргән. Алар миңа иманын мирас итеп калдырган. Канны үзгәртү мөмкин түгел. Исемне дә, туган телне дә алыштырып булмый. Дин дә шулай уктыр дип уйлыйм. Аллага ышану ул мәхәббәт кебек бит. Яраткан кешеңнең бу ягы яхшы, бу ягы җитешми дип уйламыйсың. Фәкать яратасың гына. Чын күңелдән ышанган кешенең Ходайга мөнәсәбәте мәхәббәт белән охшаш. Аерма шунда: кешегә булган мәхәббәтнең ялкыны вакыт узу белән сүрелә. Иман әһленең Раббысына булган хисе сүнми-сүрелми, ул гомерлек. Фәкать уңга-сулга карамыйча, икеләнмичә-шикләнмичә ышанырга гына кирәк.

...Бу табын, аннан соңгы сөйләшү Ленизаның бәгыренә шырпы кадагандай итте. Ошбу шырпы шул ук көнләшү иде. Фирданиядән көнләшү иде бу. Кара син аны, әбисеннән-әнисеннән өйрәнгән догаларның рәхәтен ничек күрә, ә! Төскә-биткә дә Ленизадан артык түгел бит үзе. Нишләп ул шулай кеше арасында кайнап, шул ук вакытта җан тынычлыгы белән яши, ә Лениза үзенә тынгы таба алмый, эчен туктаусыз яндырган сагыштан башын кая куярга белми?..

Ленизаны балачактан догалар укырга өйрәтүче булмады, бар белгәне «бисмилла» белән «Аллаһе әкбәр»дән артмады. Анысын да күрше-күлән әби-сәбидән генә отып алды. Чөнки үз әбисе партия члены, алар яшәгән кечкенә шәһәрнең активисты булган, халыкка атеистик тәрбия бирүдә катнашкан, ягъни дингә каршы көрәшкән.

Дөрес, коммунистлар хакимияте җимерелгәч, дин тоту, мәчеткә йөрү мактаулы гамәл булып санала башлады. Элеккеге коммунистларның шактые койрыкны бик тиз борып салды да, хатын-кыз җенесеннән булганнары башына яулык урап, ир-ат кәләпүш киеп, мәчет тирәсенә сырышты. Иң өлгерләре, хаҗга барып, дөнья күреп тә кайттылар. Бер ишенә мондый бәхет бөтенләй бушка тәтегән, аларның сәяхәтенә акчаны гарәпләр биргән, диләр. Элеккеге кызыл авыз коммунистлар хаҗи-хаҗия булып йөри хәзер.

Соңгы елларда Ленизаның әбисе дә бисмилласыз ашарга утырмый, дога кылмыйча табыннан кузгалмый. Догаларны аңа ата-анасы өйрәткән. Балачакта хәтергә сеңеп калган нәрсә онытылмый, онытылса да, кирәк чакта бик тиз искә төшә шул. Хаҗга барырга да җай тапкан булыр иде әбекәй, чире җибәрми...

Ничек болай үзгәрде соң әле ул?.. Нәрсә диде әле бүген Рәйсә? Аллага ышанган кеше ялгыз булмый, дидеме? Ялгызлыктан котылу чарасын тапкан әбекәй...

Алай да иманны бу рәвешле алыштырулар Ленизаны нык гаҗәпләндерә иде. Тумыштан атеистик рухта тәрбияләнгән булганга, ул үзе ансат кына каршы якка авыша алмады.

Ләкин, гомер узган саен, аның да башына уйларның төрлесе килә, уйланулар исә материалистик карашларның нигезен әкрен-әкрен какшата башлаган иде. Материя дә кайндыр барлыкка килгән бит. Димәк, ниндидер бер Иланы Көч бар! Ул җирне, күкне булдырган. Тереклек ияләренә, адәм балаларына җан иңдереп, бу дөньяга китерә. Ленизага тормыш бирүче дә шул. Яшәү көче генә түгел, янып сөю, шашар дәрәҗәдә көнләшү сәләте дә биргән ул аңа!

Иланы Көч адәм баласына җан иңдергән икән, ул аның йөрәк хисләрен, куанычларын, әрнүләрен — һәммәсен күреп, белеп торадыр. Әгәр ул кодрәт иясенә дәшеп булса, аңа баш орып, кинәш, ярдәм сорар идең. Сөйгән ярыңның сүрелә башлаган мәхәббәтен яңартуны үтенеп ялварыр идең.

Ә ул сине ишетми калмас, ярдәм итәр иде. Шулай булмый ни, иң авыр чакта да ярдәмсез калдырырлык булгач, ник китергән соң ул безне бу дөньяга?!

Тик ничек юл табарга ул Илаһи Затка? Кайда, ни рәвешле, нинди сүзләр белән мөрәҗәгать итәргә?

...Шушындый сорауларга җавап эзләп, ямансу уйларга чумып йөргәндә, Ленизага янә бер эш тәкъдим иттеләр — заводның бер лаборанты бала тапкан икән дә, шуның урынында эшләп торырга химия буенча белеме булган кеше кирәк икән. Инженер да түгел, технолог та, нәкъ менә лаборант булып. Үзең кебек югары белемле кешеләрнең йомышын үтәргә... Ул да вакытлыча...

Кызыгырлык түгел иде бу. Өйдә бер килешеп, бер тешләшеп яшәп яткан чаклары иде, кичен Лениза бу эшкә дә күңеле тартмаганын әйткәч, Мидхәт, читкә карап:

— Яхшырагы юк бит әле, — диде. — Ошамаса, чыгып китәрсең... — Аннары, үзалдына уйлангандай: — Өйдә тик яткан хатыннарның башында таракан үрчи, диләр,— дип куйды.

Лениза пырлый башлагач, каршы әйтмәде үзе. Бала белән бераз әвәрә килде дә, аны йоклатуга, баш-аягы белән химия буенча яңа чыккан журналларга чумды. Күзенә ак-кара күренми, һаман шул Норвегия галимнәре белән узышуында иде ул.

...Кышкы аяз бер көнне Лениза Рамиләне, арбага утыртып, һава суларга алып чыккан иде. Мидхәт, шимбә булуга карамастан, эшенә китте, ә хатын иренең бу рәвешле чамадан тыш эшем кешесе булып кылануын өйдән чыгып качарга бер сылтау гына дип уйлый иде. Тротуарда әрле-бирле арба тартып йөргәндә, аның күзенә кояшта ялтырап яткан кар да, ак бәс сарган агачлар да күренмәде, чөнки эче поша иде.

Менә күрше подъезд каршына куе зәңгәр төстәге «Рено» килеп туктады. Аның алгы ишегеннән саллы гәүдәле, пөхтә киенгән урта яшьләрдәге ир кеше төште дә арткы ишекне ачып эчкә кулын сузды. Ә аннан. Аннан... иң кәттә кызлар гына кия торган яшел төстәге кайры тун кигән, ак шәл бәйләгән... Фирдания килеп чыкмасынмы! Нинди ханбикә диярсең!

Коръән ашыннан соң Ленизаның бәгыренә кадалып калган шырпы кузгалып, түзә алмаслык сызландырып чәнчи башлады... Нишләп бу хатын шулхәтле абруйлы да, нишләп Лениза болай түбән? Мәчет шулай күтәрәме әллә кешене?

Ул, арбаны дыңгырдатып, трамвай тукталышына китте.

...Карагай бүрәнәләрдән төзелгән ике катлы мәчет шәһәрнең читендә, борынгыдан калган агач йортлар арасындагы бушлыкта әллә каян күренеп тора иде. Трамвайдан төшкәч, күз күреме киңәеп, сулыш иркенәеп китте. Кар белән ышкып агарткандай, күк гөмбәзенең бер ягында кечерәеп-тыйнакланып калган кояш тәлинкәсе эленеп тора, аны киң генә нурлы божра уратып алган. Аңа үрелгәндәй, мәчетнең нечкә манарасы очында урактай ай елкылдый.

Эче илаһидыр бу бинаның, юшкын баскан күңелләрне тазартырлык, тынгы белмәгән җаннарга ял бирерлек тылсымлы көч бардыр анда. Бер кулына Рамиләне күтәреп, икенче кулы белән арбасын тартып, киң, биек такта баскычтан кызгылт-сары такта ишеккә таба менгәндә, Лениза нык дулкынланган иде. Тирән сулыш алып, авыр ишекне ачты... Шыгырдаган тавышны ишетеп булса кирәк, эчке өч ишекнең берсеннән, сул яктагысыннан, башына чәчәкле шәл бәйләгән, бөрешкән чырайлы, кечкенә буйлы карчык килеп чыкты. «Исәнмесез» дигәнгә «вәгаләйкемәссәлам» дип җавап биргәч:

— Ни йомыш? — дип сорады.

Кулына бала күтәргән Лениза аптырабрак калды: ничек дип әйтергә?

— Сәдака бирәсе итсәң, менә монда сал,— дип, карчык диварга беркетелгән тар авызлы калай савытка күрсәтте.— Әрвахларыңның исемнәрен язып алып килдеңме? Юкмыни? Хәзрәт Коръән чыкканда язганнарның һәммәсен телгә ала, берсен дә калдырмый. Монда язсаң да була, кәгазь-каләм бирермен.

Нинди әрвахлар?! Ленизаның йомышы бөтенләй башка лабаса.

— Мин... Карап чыгарга мөмкинме?

— Аяк киемеңне алыштыр.

Карчык кырыйда тезелеп киткән эреле-ваклы башмакларга ишарәләде һәм уртадагы ишекне киң итеп ачып куйды.

Лениза, Рамиләне идәнгә бастырып, итеген салды, башмак киде дә, кызын җитәкләп, бусагадан эчкә атлады.

Бинаның эче өч яктагы зур тәрәзәләрдән төшкән яктылык белән тулган. Диварларында гарәп хәрефләре белән сырланган такталар эленеп тора. Идәненә тоташ келәм җәелгән иркен зал буп-буш, фәкать каршыда ике ягына култыкса ясалган кечерәк кенә күтәренке урын бар.

Арттарак торган карчык Ленизаның ниндилеген чамалаган иде инде. Гомерендә беренче тапкыр мәчет бусагасын атлаган бер ул гына түгел... Әбекәй аңлатма бирүне кирәк тапты:

— Анысы мөнбәр, җомгада, гает көннәрендә мулла абзый шунда басып вәгазь укый, — диде. — Кәгъбә шул якта.

Лениза аптырашта иде. Фәкать шушы гынамы? Ә кая тылсымлы көч?.. Лениза биредә үзен эчтән ныгып киткәндәй итеп сизми, киресенчә, югалып калгандай тоя иде. Чит-ят иде аңа бу мохит...

Ул кире өйалдына чыгып, итекләрен киеп азапланганда, тышкы ишектән салкын буга уралып, каракүл тун, шундый ук каракүл түгәрәк бүрек кигән, кечерәк кенә буйлы, түгәрәк битле, кыска сакал-мыеклы, утыз бишләр тирәсендәге кеше килеп керде.

— Әссәламегаләйкем! — диде көр тавыш белән. — Хода өүенә килдеңбә? Хоп, хоп, мәйле!

Ленизаның колакчынлы күксел кеш бүреге эченнән бүселеп чыккан чәчләренә, түшенә озын булып салынып төшкән зур ак шарфына елтыр күзләренең карашын бер генә сирпеде дә уң яктагы ишектән кереп китте.

— Хәзрәтебез шушы инде безнең, — диде карчык.

— Ни диде ул?

— Мәчеткә килеп дөрес иткәнсең, дип әйтте...

— Нинди телдә сөйли соң ул?

— Үзбәк ул безнең. Үзбәк ни дә, татар ни. Хак Тәгалә барыбыз өчен дә бер... Догалар өйрәнәсең килсә, бездә китапларның төрлесе бар. Гарәпчәләре дә, урыс хәрефләре белән язылганнары да. Татарча аңлатмасы да бирелгән. Казаннан да кайтартабыз, үзебез дә үрчетәбез. Догалар өйрәнергә ниятләсәң, исемеңне теркәп куям. Күбесенең Фирданиядә укыйсы килә. Теләсәң, аңа язармын...

Лениза, ашыгып, кесәсеннән акча янчыгын чыгарды да кулына эләккән илле сумлыкны калтыранган бармаклары белән дивардагы тартманың тар авызына кертә алмыйча азапланды. Аннары, көйсезләнә башлаган Рамиләне күтәреп, чыгу ягына борылды.

— Кая киттең? Әрвахларыңның исемнәрен язмадың бит әле! — дип кычкырып калды карчык аның артыннан.

* * *

Хәлбуки рухына терәк эзләп бәргәләнүче бер Лениза гына түгел иде. Шундый берәү завод лабораториясендә үк бар икән. Зәңгәр халатлы җыештыручы хатынга кайсы Сәгъдәнә, кайсы Серафима дип эндәшә, бу бик тә сәер иде.

Ленизаның моңа гаҗәпсенүен күреп:

— Үзебез дә буталып беттек инде без аның белән, — диделәр. — Паспортында Сәгъдәнә дип язылган, фамилиясе Исламова. Үзе әйтә, чукындырганда атакай миңа Серафима дип исем кушты, ди.

— Чиркәүгә барып чукынганмыни? — дип сорады хәйран калып Лениза.

— Ул анда гел барып йөри, бер дә эзен суытмый. Чиркәү активисты булган! Анасы оятыннан кая керер тишек тапмый, диләр. Борынгы ишаннар нәселеннән икән бит үзләре. Исемнең дә матурын кушкан булганнар: Сәгъдәнә «бәхет йолдызы» дигәнне аңлата икән. Муллалар белми кушмас. Тик моңа ярамаган, Серафима килешлерәктер.

— Ире урысмы әллә?

— Ире юк аның. Аерылышканнар. Улын берүзе үстерә.

Үзенә кырын караганнарын сизгәнгә булса кирәк, чандыр гәүдәле, җирәнсу чәчле, илле яшьләр тирәсендәге Серафиманың чырае караңгы, кыланмышлары шактый тупас иде.

Кызык, нәрсә тапты икән соң ул чиркәүдә? Анасының каргышыннан курыкмыйча, ни дип анда барып егылды икән?!

Үзләренең каршысында биегәеп утырган чиркәүгә күзе төшкән саен, Лениза Сәгъдәнәне уйлап куя торган булды. Ишан нәселеннән икән бит үзе. Мәчеткә дә баргалагандыр. Тик менә бит күңеле ятмаган. Рухына таянычны, җанына юанычны чиркәүгә барып тапкан. Күрәсең, анда бөтенләй бүтәнчәдер. Кереп карарга иде, ничегрәк икән?

Әмма тора салып барып керү ничектер уңайсыз кебек иде. Бусаганы атлауга чукыну тиеш бугай әле. Киноларда шулай күрсәтәләр. Анысын ук булдырып булмас шул...

...Андый чакта бер җае чыкмый калмый, монда да шулай булды. Иртә яз иде, кар эри генә башлаган чак. Ленизаның теше сызлый иде, эшеннән сорап китеп, табибка барды. Кайтканда чиркәү турыннан узып бара иде, тротуар кырыена автобус килеп туктады. Аннан дистәдән артык кеше төште. Күбесе өлкән яшьтәге хатыннар. Чалбар, куртка кигәннәр, муеннарына фотоаппаратлар асканнар.

— Безнең шәһәрнең соборын унтугызынчы гасыр башында ук салганнар, — дип, төркемгә борылып сөйләргә кереште яшь кенә бер хатын. Экскурсовод иде бу, төркем исә, мөгаен, читтән килгән туристлардыр.

— Әйдәгез, эчкә узыйк, — диде экскурсовод. —Чиркәү үзенең борынгы иконостасы белән данлыклы.

Болар — карарга килүчеләр генә, туристларга чиркәүгә керүгә чукыну мәҗбүри түгел. Лениза, бер-ике адым ара калдырып, төркемгә иярде.

Бик иркен бинаның эче ян-якларда күләгәгә уралган, уртасына биек гөмбәздән яктылык төшкән иде. Каршыда алтынга манылган иконостас, аның алдындагы өстәлдә бихисап шәм яна... Экскурсовод хатын, диварлардагы сыннарга, иконаларга күрсәтеп аңлатмалар биргәннән соң:

— Әгәр теләсәгез, мин руханиларның берәрсен чакыра алам,— диде. — Бәлки, сорауларыгыз булыр.

Руханины көткән арада, тыенкы тавыш белән үзара сөйләшүләр колагына кереп, Лениза бу төркемнең шәһәр янындагы санаторийдан икәнлеген аңлады. Анда күп яклардан килгән халык ял итә. Арада төрле дин әһелләре бар иде.

Түр кырыйдагы күләгәдә шәйләнгән ишектән озын кара җилән, кара башлык кигән, юка кара сакаллы, ак чырайлы, егерме бишләр тирәсендәге ыспай егет чыкты. Якын танышларын очраткан кебек, ачык йөз белән, шул ук вакытта вәкарь саклап:

— Исәнмесез! — диде. — Хуш килдегез безнең храмга. Ул сезгә ошагандыр дип өметләнәм. Әгәр сорауларыгыз булса, үзем белгән кадәр җавап бирергә әзермен.

Сораулар башта бинаның үзе хакында булды: кайсы архитектор төзегән, кемнәр хисабына, ничек ул коммунистлар заманында җимерелми калган. Биредә күп еллар китапханә булган икән. Өч ел элек кенә китапларны башка урынга күчергәннәр, бинаны өр-яңадан төзекләндереп бизәгәннәр. Иконостасы моңарчы музейның чоланнарында сакланган булган икән, хәзер менә кире кайтарып урынына куйганнар.

Егет бик гади сөйли, ара-тирә генә «слава господу» дигән сүзне кыстырып куя иде. Тавышы ягымлы, карашы җылы, бик игътибарлы.

Егет Мәскәүдә дини академия тәмамлаган икән.

— Бу заманда бик күпләр дингә ышанмый бит инде. Чөнки балаларга дини тәрбия бирелми. Хәзерге яшьләрнең ата-аналары динсез итеп үстерелде. Күпчелек чиркәүгә йөрми... Алла каршында гөнаһлары зурдыр... Теге дөньяда андыйларның һәммәсе тәмуг кисәве булыр микәнни? — дип сорады берәү.

— Бог һәммәсен күреп-белеп тора. Ул адәм баласына акыл биргән һәм сайлау мөмкинлеге биргән. Әгәр дә кеше көн саен шушы чиркәү яныннан узып йөрсә дә, аны күрмәгәндәй узып китә икән, бирегә кереп бер генә тапкыр да дога кылмый икән, ул инде үз юлын үзе сайлаган дигән сүз. Ул юл бог кушкан тарафка илтә торган булмас. Әгәр дә кеше дин турында беркайчан да, берни дә ишетмәгән булса, анысы икенче мәсьәлә. Ләкин бар микән ул андый кеше? Хәзерге вакытта биредә безнең чиркәвебез күтәрелеп балкып тора. Шәһәрнең икенче ягында мәчет. Шулай итеп, кеше үзенә бирелгән сайлау мөмкинлегеннән файдалана ала.

— Хәзер халык күп нәрсә укый, күпне белә,— диде берсе.— Алла күктә, диләр, ләкин менә күпме космонавтлар очып йөри, Айга да менеп төштеләр, беркемне дә күрмәгәннәр бит...

— Ходай безгә әйткән кадәресен әйткән, — диде рухани. — Әйткәнен әйткән, — дип кабатлады ул.

Егет бу сорауга җавапны шуннан уздырмады. Дәвамы Ленизаның күңелендә үзеннән-үзе туды: «Ә әйтми калдырганы күпме?!» Ләкин ник әйтми калдырган? Адәм баласының аңлап җиткерерлек сәләте булмагангамы? Ләкин безгә сәләтне ул биргән бит!..

— Теләсәгез, мин сезгә бер брошюра бирәм,— диде рухани.— Анда дөньяда иң киң таралган диннәр — христиан, буддизм, ислам, иудаизм турында кыскача гына мәгълүмат тупланган.

Ул, эчке яктан алып чыгып, китапчыклар өләште.

Егет белән хушлашып, чыгып барганда, арадан берничә кеше ишек янындагы тартмага акча салып, нәрсәдер пышылдадылар, башларын иеп ашыгып чукындылар.

Урамга чыккач, үзара әкрен генә сөйләшеп, автобуска таба киттеләр. Арттанрак барган ике хатын татар икән, үзара пышылдашып алдылар.

— Боларның батюшкалары көчле... Буыннары арасында өзеклек булмады шул... Христиан академияләре беркайчан ябылмады. Ә безнекеләрнең берничә буынын өзеп ташладылар... Тамырдан аердылар... Руханиларыбызның күбесенә белем җитешми...

«Ходай адәм баласына акыл биргән һәм сайлау хокукы биргән». Нәрсәгә инанырга, ничек яшәргә, нинди гамәлләр кылырга — монысы аның үз ихтыярында.

Ләкин менә Ленизага нишләргә? Әллә соң ялгызың гына шушы рухани янына кереп киңәш сорарга микән? Ярый, бардың ди, чакырып чыгардың ди. Шуннан? Ни дип сүз башларсың? «Ирем мине яратмый. Аның мәхәббәтен ничек кайтарыйм?» — дияргәме? Ходай язмаганны...

Юк, туктале, аның берәр тәртибе булырга тиеш. Ленизаның күп киноларда күргәне бар: авыр кайгылардан арыныр әмәл тапмагач, якты дөнья кара төн булып күренгәндә, иманлы кешеләр гыйбадәт йортларына барып Аллага сыгыналар. Әлбәттә, ул киноларның геройлары христианнар. Күпчелеге фаҗигагә дучар булган яшь, чибәр хатыннар... Ә чиркәүләр затлы, бизәкле. Зур, биек бинаның түрендә изге ана — Мариянең сурәте. Менә аның каршына ак яулык бөркәнгән гүзәл хатын килеп баса, догалар пышылдап тезләнә, күз яшьләрен түгеп, моң-зарларын сөйли. Шуннан үзенә юаныч, җиңеллек таба.

Христианнарда «исповедоваться» дигән йола бар. Аны шулай ук киноларда бик матур итеп күрсәтәләр. Кеше кечкенә генә куышка кереп утыра һәм бар булган әрнүләрен сөйли, җанын ачып бирә. Бу инде кайдадыр җиде кат күк өстендәге Ходага ялвару түгел. Ул ера-ак... Ә монда, куышта, диварның икенче ягында, сине ишетеп торучы бар. Зарларың, гозерләрең ниндидер сәбәпләр аркасында, күкләргә күтәрелеп, Ходага барып ирешмәсә — ә бәлки, сүзеңне аңлаешлы итеп әйтеп бирә алмасаң — ул сине төзәтер, үтенечеңне кабул итүен сорап, Ходага үзе дә мөрәҗәгать итәр.

Бу бик аңлаешлы гамәл булып тоелды. Алай да орды-бәрде эшләнә торган эш түгел... Лениза янә Сәгъдәнә-Серафиманы исенә төшерде.

...Җыештыручы хатын читтән караганда гына кырыс күренгән икән. Сүз кушсаң, тиз ачыла, сөйләшергә ярата икән үзе. «Сезнең белән киңәшәсе килә иде»,— дигәч, тәмам яктырып китте.

Шкафлар, өстәлләр белән бүлгәләнгән иркен лабораториянең бер почмагында аулак урын бар — зур чүлмәктә үскән киң яфраклы пальма артында ул. Төшке аш вакытында алар, шунда ышыкланып, урындыкларга кара-каршы утырдылар. Сәгъдәнә-Серафима сүзнең четерекле булачагын аңлап алган иде инде. Кызыксынудан күзләре яна, какча яңаклары алланып чыккан.

Иң яхшысы үгезне мөгезеннән тоту иде. Лениза әйләнеп-тулганып тормады, туп-туры:

— Сезнең исповедоваться иткәнегез бармы? — дип сорады.

Серафима елмаеп җибәрде. Алгы теше төшкән икән. «Куйдырырга, мөгаен, акчасы юктыр инде» дигән уй узды Ленизаның башыннан.

— Чиркәүдәме? Нишләп булмасын! — диде Серафима.— Исповедоваться итү — бик кирәкле, изге гамәл бит ул.

— Ничек-ничек эшләнә соң ул?

— Әллә сез дә бармакчымы?

Хатынның йөзеннән, күзләреннән хәйләкәрлек катыш сөенеч бөркелде.

— Болай гына... Беләсем килә... — диде Лениза, карашын, пальма яфрагына төбәп. — Киноларда күргән бар... Дөрес күрсәтәләр микән дим...

— Кино нәрсә ул! Үзең кылганда бөтенләй икенче! Иң элек өч көн пост тотарга кирәк. Хайваннардан алынган азыкларны — ит, сөт, йомырка, балык ишене ашарга ярамый. Тәнеңне сафландырырга, тазартырга кирәк. Юынырга, мунча керергә. Һич булмаса, ванна. Иң мөһиме, җаның чиста, саф булырга тиеш. Гел яхшыны гына уйларга, матур гамәлләр генә кылырга. Шуннан соң атакай янына барасың. Тезләнәсең. Ул синең башыңа кара тукыма ябындыра. Тукыма үзе кара, ә эче нур белән тулы... Чөнки ул синең үзеңнән, изге ниятләреңнән бөркелә. Атакай сиңнән, вөжданың нидән тынгы тапмый, дип сорый. Чын дөресен сөйлисең. Берни дә яшермичә. Аннан сер чыкмаячак. Ул синең гөнаһларыңның алла тарафыннан ярлыкалганын әйтә, догалар укый, моннан бүтән начар гамәлләр кылмаска куша. Монда иң әһәмиятлесе — ихластан ышану...

— Юк, мин гөнаһлар турында түгел...

— Бер гөнаһсыз адәм булмый инде. Исповедоваться итәргә теләк туган икән, димәк, нәрсәдер бар. Сөйләп бирерсең.

— Минем башка... Мин киңәш сорамакчы идем.

— Нәрсә турында?

— Ирем хакында... Безнең мөнәсәбәтләр...

— Алланың кодрәте чиксез... Син иреңне дә алып кил атакай янына! Икегез берьюлы исповедоваться итсәгез, гел дә әйбәт булачак. Бер-берегезне рәнҗеткән булсагыз, атакай кичерер. Килештерер. Күңелләрегезгә нур тулыр...

Лениза ачы елмаюын яшерә алмады: Мидхәтне чиркәүгә алып барыргамы?!

— Якшәмбе көнне службага кил әле син, — диде Серафима, аның икеләнгәнен сизеп. — Шунда һәммәсен аңлатырлар. Анда без бик изге эшләр башкарабыз. Гарипләргә, ятимнәргә, мескеннәргә ярдәм итәбез. Хәйрия җәмгыяте оештырдык. Киелгән киемнәрне жыябыз да, тәртипкә китереп, бик арзан хакка, аяк ялы бәрабәренә дигәндәй, мохтаҗларга бирәбез. Акчалата ярдәм җыябыз. Анысы тагын да әйбәтрәк. Әгәр мөмкинлегең булса, хәзер үк бирә аласың. Саваплы булырсың...

Лениза, сумкасын актарып, кулына эләккән йөзлекне аның учына тоттырды да, уйлап карарга вәгъдә итеп, урынныннан кузгалды. Ул көнне Серафима тарафына бүтән карамаска тырышты. «Йә инде, нәрсәгә дип аңа шулхәтле акчамны бирдем?» — дип тә үкенде.

...Кара сакаллы яшь кенә егет каршына тезләнеп, башына кара япма бөркәнеп, «иремнең күңеле сүрелде, нишлим?» дип зарлануны ул берничек тә күз алдына китерә алмады. Ярый, зарланды да ди. Аннан гына ни үзгәрер соң?..

Серафима сөйләгән йола бөтенләй дә ул күз алдына китергәнчә булып чыкмады.

* * *

...Мидхәт гадәтенчә эштән соңарыбрак кайтып керде. Зал ягында битен марля белән ураган хатынны күреп, башта танымады.

— Кунак бармыни әле бездә?

Хатын, башын аска ия төшеп:

— Чакырылмаган кунак әле бу, — диде. Аның битен ике яклап төргән марля өстеннән күзлек ырмавының саплары сузылган иде. Пыялалар аша атылган күз карашыннан, аннан да бигрәк тавышыннан Мидхәт Рәйсәне танып алды.

— Ни булды?

Аш бүлмәсе ягыннан Лениза чыкты да, шактый ук кычкырып:

— Өйләрендә савыт-саба шалтыраган. Тәлинкә тиеп киткән,— диде.

Аның тавышында һич тә урынсыз шаяру чагылып узгандай булды. Мидхәт исә тәмам аптырашта иде.

— Рәмис кыйнадымы әллә?!

— Шул инде, кем булсын...

— Үзе кая соң әле?

— Милициядә.

— Син тапшырдыңмы әллә?

— Ә нишләргә тиеш идем мин? Йөгереп барган идем, ияреп килделәр дә алып та киттеләр.

— Кайчан булды инде бу хәлләр?

— Кичә кич... Бүген милициягә шалтыраткан идем, иртүк чыгарып җибәрдек, диделәр. Берәр атна булса да ябып тотмаганнар шунда!

— Элекке кебек унбиш суткага утыртмыйлар бугай шул хәзер,— диде Лениза.

Рәйсә, Мидхәткә рәнҗешле караш төбәп:

— Ирләр бер-берсен яклый шул ул! Син дә гел аны яклыйсың бит, — диде.

Мидхәт алгы бүлмәдәге элгечкә курткасын озаклап урнаштырган булып азапланды. Рәмиснең завод каршындагы базарда сату итүче Роза исемле яшь кенә ирсез хатын белән бәйләнгәнен белә иде инде ул. Акылыңа кил, гаиләң әйбәт, хатының менә дигән, дип үгетләде дә. Җирән чәчле, акаеп торган яшел күзле Розаны балга манып бирсәләр дә ымсынмас идем, дип тә карады.

— Нигә ямьсезләнеп йөрисең? — диде.

Рәмиснең тулы иреннәре җәелә, майлы күзләре кысыла, алардан бал саркыгандай була:

— Ә без ямьсезләнмибез... Матур гына итеп, матур гына... — ди һәм куллары белән мәгънәле хәрәкәтләр ясап куя.

Кичләрен еш кына Рәйсә Мидхәтләргә телефоннан шалтырата, Рәмисне күрмәдеңме, дип сорый. Мидхәт, билгеле инде, әшнәсен коткару ягын карый:

— Бер цехта авария булды. Рәмис шунда калды, соңрак кайтыр... Ә бәлки, иртәнге сменага хәтле цехтан чыга алмас...— кебек тозсыз сүзләр сөйли.

Боларны күреп-ишетеп торган Лениза аңа чәнчеп-чәнчеп карап ала.

— Бу кадәр дә ата ялганчы икәнеңне белми идем әле,— ди.— Кеше хатынына шулкадәр ялганлагач, үз хатыныңны ничек кенә алдамыйсың икән?..

...Менә хәзер Рәйсә мөлдерәп карап торганда, Мидхәт үзен бик уңайсыз хис итте.

— Теге көнне син миңа, заводта авария булды, дигән идең,— диде Рәйсә, Мидхәтнең күзенә туры карамый гына. — Ә мин бардым анда. Авария заводта түгел, башка җирдә булган... Күптән күңелем сизеп йөри иде инде.

— Әллә берәрсе белән тоттыңмы? — диде Лениза, күзләрен зур ачып.

— Тоттым... дияргә була. Бик озак ишекне ачмый тордылар. Аннары, мин өсләренә диярлек барып кергәч, җыен юк-барны сөйли башладылар. Имеш, йомыш белән кергән. Ялгыз хатында ир кешенең нинди йомышы булуы билгеле инде. Шкаф ишеген рәтләргә кергән, имеш... Үз өендәгене рәтләмәгәнне...

— Шунда талашып сугыштыгызмы әллә?

— Нишләп сугышыйм... Алар өчен оялдым... Борылдым да йөгереп кайтып киттем. Ул кайткач, кертмәдем. Ул ишек биген тибеп очырды да миңа китереп бәрде...

— Бер бәрүдә шулай иттеме?

— Күзлеккә эләкте... Ырмавы басып, борын сөяген сындырган...

Рәйсәнең күзлек пыяласы астыннан яшь тамчысы тәгәрәде. Мидхәтнең күңелендә аның башыннан сыйпап юату теләге уянган иде. Әмма аш бүлмәсенең ишеге төбендә сынап карап торган хатынына күз салгач, дәшмәде. Юыну бүлмәсенә кереп китте.

Лениза, бәрәңге, колбаса, сыр ише ризыклар куеп, табын әзерләде. Чәй янында Рәйсә ничектер йомшап киткәндәй булды.

— Беренче тапкыр ул кайтмаган төнне бик каты елаган идем,— диде. — Бер-бер хәл булгандыр дип уйладым. Радиодан, телевидениедән көннең-көнендә юкка чыккан кешеләр турында сөйләп

торалар бит. Мин дә милициягә бардым. Астыртын гына елмаештылар да өч көннән килергә куштылар. Тәртибе шундый икән. Югалганны өч көн үткәч кенә эзли башлыйлар. Ә ул ике көннән әйләнеп кайтты. Мин елыйм, ул авызын ерып көлеп тора. Яратуың хак икән, инде ышандым, ди.

— Яратуны шулай сыныйлар микәнни? — дип сорады Лениза.

— Шулай да итәләр икән шул... Дуслары белән кайдадыр эчеп яткан булса кирәк... Берничә тапкыр шулай кабатлангач, күнеккән идем инде. Элеккечә үк борсаланмый идем. Ә бу юлы менә шушылай килеп чыкты.

— Күзен чокырга кирәк иде ул фахишәнең! — диде Лениза.

— Сугышып түбәнсенеп йөримме? Минем гомеремдә дә кешегә кул күтәргәнем юк.

— Килеп тукмый башласалар, этеп тә җибәрмәс идеңме әллә?

— Китереп органнары юк әле моңарчы...

Кыскасы, ямьле күренгән йортта бик тә ямьсез хәлләр барлыгы ачыкланды. Хәер, гел яктыдан гына торган гаиләләр бар микән ул? Кояш ничаклы якты балкыса, күләгәләр дә шулкадәр куе була. Болыт каплаган җирдә генә дөнья һаман бертөрле.

Мидхәтнең нечкә бер тамыры сулкылдап куйды. Йа Раббым, мондый хатынга орган ирнең кулы корыр!..

— Һәммәсенә чыдар идем, кимсетүенә түзеп булмый,— диде Рәйсә, әрнеп.— Кешелегемне бетерә. Әллә ничек үземне-үзем санга сукмый башладым. Тормышыңны дуңгыз белән бәйләсәң, аның белән бергә урам канавында аунарга туры килә икән. Мин шуны аңладым. Җитте! Аерылам! — диде Рәйсә, сынын турайтып, катгый итеп. — Үземне кызганмасам, баланы кызганырга кирәк. Минем дә кешелегем бетсә, ул ничек үсәр?

— Ирсез яши торган кеше түгел син, берәрсенә чыгарсың әле, — дип куйды Лениза.

— Безнең базар үткән инде...

— Берәрсенең ирен тартып алырсың. Хатыннарын яратмаган ирләр җитәрлек.

Мидхәт аларны читтән генә күзәтеп утырды. Үз сүзләренең хаклыгына нык ышанган Лениза кунагына астыртын бер көлемсерәү белән карап-карап ала, тавышында да ниндидер бер үчекләү бар. Әмма Рәйсә моны сизми, үз хәле хәл, гамьнәре зур иде...

— Бакча сараеның ишеген ничек кирәк алай әмәлләштереп куйган идем инде, — диде ул. — Биген ясый алмыйм. Көрәк-сәнәкне куяр урын юк.

— Ял көнне барырбыз да куеп кайтырбыз. Нәрсәсе бар аның, — диде Мидхәт.

...Бакчадагы күрше-күләп арасында Мидхәт иң уңганнардан санала иде. Җирне алган көзне үк һәммәсеннән алда акча тотмый гына бер сарай әмәлләп куйды. Бакчачылык җәмгыятенең биләмәсен койма белән әйләндереп алганда, бик күп такта башларын кисеп ташладылар. Мидхәт шуларны сорап алды да стеналар корыштырды, эчтән катыргы белән ышыклады. Ишек куйды, тәрәзә уйды. Түбәсен калдык-постык толь кисәкләре белән япты. Эченә ятак, өстәл ясады.

Рәйсәләрнең җире ширкәтнең икенче башында, шунлыктан сирәк очрашалар иде. Бер узып барганда, ул, Мидхәтнең сараен күреп:

— Рәмис шушындыйны булдырса, башканы сорамас та идем,— дип көрсенеп куйган иде.

Рәмиснең исә күңеле башкада — яр буенда балык тотуда, дуслар белән шашлык кыздырып ашауда, әргән тартып җыр җырлауда...

...Буш кул белән барасы килмәде, Мидхәт бакча өчен иң кирәк әйберне — бер капчык күгәрчен ашламасы күтәреп барды. Мондый хәзинәне ул үзләренең йорт чормасыннан җыеп ала... Мидхәт ишек төбендә аркасына биштәр асып азапланганда, Лениза сиздерми генә янәшә торган капчыкны кымшатып карады. «Аркасында биштәр, җилкәсендә шушы капчык... Ничек өстерәп барыр икән? — дип уйлады. — Рәйсә дигәндә көчен кызганмый!» Үзләренә шундыйны алып барганда, ирен кызгану Ленизаның башына килмәгән иде, әлбәттә...

Ләкин урынга барып, ачык һавада чирәмгә урнашкач һәм эшкә керешкәч кенә Мидхәт үзенең ялгышканын аңлады: капчык белән ашлама түгел, келәшчә, чүкеч, кадак, стамеска алып килергә кирәк булган. Корал эшли, ир мактана, дигәннәр, коры кул белән әллә ни эш майтарып булмый. Ара шактый ерак булса да, үзләренең сараена барып, кирәк-яракны алып килергә туры килде.

Хатыннар чирәмлектә учак ягып ашарга пешерәләр. Битен марля белән ураган Рәйсә ит турый, Лениза бәрәңге әрчи. Чөкердәшәләр, көлешәләр, борчаклары бик тә пешкән кебек күренә. Шунда ук бала арбалары, Илдус белән Рамилә уйныйлар. Көн аяз, җилсез, җылы, түтәлләрдә уткойрыклар чүпләнә, бакча башындагы агачлыктан кошлар сайраганы ишетелә. Дөнья матур, һәммәсенең күңеле хуш кебек иде.

Алар караңгы төшкәндә генә кайтып керделәр. Лениза чәй куярга ашыкты, Мидхәт, Рамиләнең курткасын, ботинкаларын салдырып, уенчыкларын тоттырды.

— Уйна, кызым! — диде дә ванна бүлмәсенә юынырга кереп китте.

Гөнаһ шомлыгына каршы, чәйнекне газга куеп бүлмәгә чыккан Лениза аның диванда яткан костюмын шкафка элеп куясы итте. Кулы күнегелгән хәрәкәт белән чалбар кесәсен капшады.

Мидхәтнең кесәләрен еш тенти иде ул, тик моңарчы гаеп-кыек табылмаганга, гөнаһлы гамәле сизелми килде. Ә бу юлы кесәдән конверт почмагы күренде. Хат иде бу. Лениза аны тартып алды да адресына текәлде. Хат почтага «до востребования» җибәрелгән. Язучысы — Гомәрова. Казаннан... Кем ул Гомәрова? Әгәр институттан булса, ник турыдан-туры өйгә язмаган?

Ленизаның калтыранган бармаклары конверттан вак кына зәңгәр хәрефләр белән шыплап тутырылган бер бит кәгазь һәм... төсле фоторәсем тартып чыгарды. Хатынның битен ялкын теле ялмап алгандай булды: рәсемнән аңа күзләрен зур ачып, уемлы ияге белән үртәп Әнисә текәлеп карап тора иде. Лениза, корт чаккандай, фотоны идәнгә ташлады да шытырдатып хат битен ачты.

«Кадерле Мидхәт абый! — дип язылган иде анда. — Синең бу хатың безгә зур шатлык булды...»

«Бу хатың...» Димәк «тегеләре» — элеккеләре дә булган? Мидхәтнең бу хакта теш агартып бер сүз дә әйткәне юк иде! Әйтерлек булса, килгән хатларны почтага барып алыр идемени ул?

Ленизаның күзләре ашкынып кәгазь битендәге юллардан йөгереп узды. «Соңгы сынауларыгызның уңышлы узуына бик-бик сөендек. Димәк, Норвегия белгечләренең үкчәсенә басасыз? Мин сезгә җиңү телим, Мидхәт абый! Үземнең көчемне, кодрәтемне җибәреп торам!»

Менә кем сихерләп ята икән Мидхәтне! Менә кем кергән арага! Аның карточкасы да сихерледер, мөгаен! Югыйсә күзләре бу кадәр томырылып, бәгырьгә үтеп карар идемени? Лениза ул күзләрне күрмәс өчен бармагы белән басып ышкыды. Бозган бу Мидхәтне, бозган!

«Тагын кайчан кайтырсың икән, Мидхәт абый? Синең белән сөйләшәсе сүзләр шулкадәр күп!»

Димәк, алар күрешкәләп торалар?.. Мидхәтнең Норвегия белгечләре белән узышканын да белә, эшенең ничек барганын да... Монысы инде Ленизаның башына сыймаслык иде...

Мидхәт, трикосын киеп, чәчен сөлге белән ышкыштырып юыну бүлмәсеннән чыкканда, Лениза идән уртасында таш сын булып басып тора иде.

— Бу нәрсә? — дип, хатны иренең битенә китереп терәде ул.

Мидхәт бер кулы белән башындагы сөлгене артка шудырып, икенчесе белән кәгазьне читкәрәк этте. Алланган йөзендә аптырау чагылды, ул эшнең нәрсәдә икәнен аңламыйрак торды.

— Каян алдың син моны? — дип сорады аннары.

— Кесәңнән килеп төште! Кайчаннан бирле хат язышасыз сез аның белән?

Мидхәт каушап китте, гаепле елмайды.

— Беренче хат кына... Язышса ни? Нәрсәсе бар аның?— диде. — Чит кеше түгел бит... Авылдашлар...

— Нинди авылдаш булсын ул сиңа! Сихерче чегәннең авылы буламыни?

— Нинди сихер?

— Әнә портретына кара! — дип, идәндәге карточкага башмак очы белән төртте Лениза.

Мидхәт, иелеп, карточканы кулына алды.

— Юкка кызасың, — диде. — Яшь кыз бала турында...

— Ул кызның самый кызган чагы, если хочешь знать! Апасының ниләр сөйләгәнен хәтерлисеңме?

— Нәрсә турында?

— Анасы белән яшерен хат алышканын... исеңә төштеме? Алар икәүләшеп... кем әле?

— Әлифә апаны әйтәсеңме?

— Менә шуны сихерләгәннәр. Шулай булмаса, ул чит кеше баласына шулкадәр хезмәт итәр идемени? Хәзер синдә осталыгын сынарга булгандыр. Сине аздырып, башка хатыннар белән буташтырып...

— Нинди хатыннар?!

— Ниндие туры килсә, шундый... Бозым кергән иргә теләсә кем ярый. Менә бүген дә ниләр генә кыланмадың, теге дүрткүзгә ничек кенә ярарга тырышмадың! Миңа кирәк артыннан алай галопом чапмас идең әле! Ирләре ташлап киткән хатыннар кирәк сиңа. Мин генә җитмим! Аларның әллә нәрсәсе бар дип беләсеңдер!

Мондый нахак сүзләрне һич көтмәгән Мидхәтнең күз алдын кызыл томан каплагандай итте, ярсуы ташып чыкты, ул, үз-үзен белештермичә:

— Әйе, синдә юк нәрсәләр бар анда! — дип кычкырганын сизми дә калды.

Ялгыш ычкынды, дөрес әйтелмәде. «Нәрсәләр» түгел, «сыйфатлар» дияргә кирәк иде. Ләкин сүз чыпчык түгел, авызыңнан бер чыгып очкач, тотып алып булмый.

Нәкъ менә шул кызулык белән ычкынган бер сүз Лениза өчен иренең хыянәтен раслый торган бик зур дәлил булып тоелды да инде. Хатынның чырае чалшаеп, бурлаттай кызарып чыкты. Тыны кысылды, әйтер сүзләре бугазына килеп төйнәлде.

— Ах, шулаймыни? Каян белдең әле син аның андый нәрсәләрен? Күптән күрсәттеме?!

Хатын, кизәнеп, ныкселтәнеп, Мидхәтнең яңагына сугып җибәрде.

Авыртуны сизмәде Мидхәт, әмма тынсыз калды. Хатынының кулы, аның тиресенә, сөякләренә орынмыйча, турыдан-туры эчкә, бәгырьгә китереп органдай итте. Һәм ул Ленизаның кулын тотып алды да бөтен көченә артка таба каерды:

— Гафу үтен хәзер үк! Гафу үте-ен!

— Үтерәсе-е-ң!..

Бу тамашаны моңарчы почмактан өзгәләнеп карап торган Рамилә әнисенең итәгенә килеп ябышкан, елый, әтисенә әйтеп бетерә алмаслык рәнҗеш белән текәлгән иде. Ул әнисен яклый, әнисен кызгана! Кем әйтә, балалар һәрчак хаклы, гадел дип?

Мидхәт Ленизаны караватка илтеп салды да кулын ычкындырды. Хатын, уң кулын сулы белән ышкыштырып, сулышына буылып сикереп торды да:

— Подлец! Негодяй! Бар, ычкын фахишәң янына! — дип кычкырды. — Чыгып кит хәзер үк! Эзең булмасын монда!

Һәм сикереп торды да шкафның ачык киштәсеннән кулына кергән беренче әйберне алып идәнгә томырды. Ә кул астына аларның туена бер ел тулган көнне заводтагылар бүләк иткән чынаяклар эләкте. Алар артыннан бизәкле зур чәйнек идәнгә очты.

— Кит! Кит!

Нишләгәнен белмәгән Лениза, ары-бире бәргәләнгән арада, өзгәләнеп елаган Рамиләне тезе белән төртеп екканын сизми калды.

— Нишлисең?! Үтерәсең бит баланы!

Мидхәт кызчыкны күтәреп алды да ишекне ачты.

— Калдыр баланы! Калдыр! — дип чатлап килеп ябышты аңа Лениза.

Алар шулай бер-бер артлы чабышып урамга чыктылар. Ишек төбендәге эскәмиядә һава сулап утырган карчыклар, машиналары янында әвәрә килгән ирләр барысы берьюлы алар тарафына борылды.

— Бир, диләр сиңа баланы! Хәзер милиция чакыртам! Халисә апа! Күрмисезмени?! Милициягә шалтырат әле! — диде үзенә көч-куәт өстәлгәнен сизенгән Лениза.

— Бүтән тиясе булма! Кара аны! — дип, Мидхәт мышык-мышык килгән Рамиләне җиргә бастырырга мәҗбүр булды.

Һәм, абына-сөртенә йөгереп, йортның икенче ягына китеп барды. Карчыклар аның артыннан:

— Карале, бу да эчүгә сабышкан икән... Рәтле генә күренә иде... — дип сөйләнеп калдылар.

Тирә-якта ял көнендә кичләрен була торган җан тынычлыгы хөкем сөрә, кемнәрдер соңарып бакчадан яисә кунактан кайтып килә, кемнәрдер сабыйларын һава суларга алып чыккан. Бәхетле балалар, бәхетле аталар! Бер Мидхәт кенә адаштырылган эт хәлендә...

Хәер, аның хәлендәмени хикмәт! Рамилә — бәгырь кисәге нишли икән анда? Үз-үзен белештермәс хәлгә килгән хатын иренең үчен баладан алмый микән?

Йорт янындагы яшь агачлар арасына фонарь яктысы килеп ирешми иде. Мидхәт бераз вакыт караңгыда, аулакта ялгызы әрле-бирле йөренде. Аннары аяклары үзеннән-үзе кире өйгә таба атлады. Тәрәзәләрнең бер ягы чебен кермәсен өчен марля белән генә капланган. Өйдәге тавышлар тышка аермачык ишетелә. Кемнеңдер телевизоры сөйли, кемдер музыка уйната, кайдадыр телефон зыңгылдый. Бала елаган тавыш юк. Аллага шөкер...

Төнне ул заводның кунакханәсендә үткәрде. Вакыт соң, дежур трамвайны озак көтәргә туры килде, барып җиткәнче ярты төн узды. Ярый, завод идарәсе бинасында командировкага килгән кешеләрне урнаштыра торган берничә бүлмә бар. Ярый, директор урынбасары — ирләрнең хәлен аңлый торган, тәҗрибәле кеше. Төн уртасында телефоннан шалтыраткан өчен ачуланмады, кунакханәдә кизү торучы хатынга инженер Халиковны буш бүлмәгә урнаштырырга рөхсәт бирде.

Тар караватка сузылып ятканда, ул шактый тынычланган иде инде. Аек акыл белән бер сорауга җавап табасы килде: кем гаепле?! Гаепне ул иң элек үзеннән эзләде. Ир кеше гаиләне ипле тотарга, хатынына хуҗа ук булып бетә алмаса да, үз җаена салырга тиеш түгелмени? Ничек әле ул хатын-кызга кул күтәрү дәрәҗәсенә барып җитте?!

Ләкин, гауга купкан минутны күз алдына китергәч, йөрәктә көчле ризасызлык кубып, уйларның юнәлеше үзгәрде. Чөнки аңа беркайчан да мондый мәсхәрәле рәвештә китереп органнары юк иде. Малай чагында да ул битенә суктырганын хәтерләми. Кизәнсәләр, йодрыгын каршы куя белде, берничә кеше килеп ябышса, егылганда башын томалады. Иң якын кешеңнең мондый кыланмышын ул хурлау, кимсетү, аяк астына салып таптау дип кабул итте.

Бер академик турында ни сөйләгән иде әле Рәмис? Пеләшен хатыны дөмбәсли дипме? Шуны күргәч, рәссам аның портретын ясаудан баш тартканмы? Аны кешегә санаудан туктаганмы?

Юк инде, Мидхәт андый көнгә төшмәс, хатыннан кыйнатып тормас!

Ә Лениза? Ул ничек иренә кул күтәрә? Яши белмәвенең үчен аннан алуымы әллә бу?!

Һаман ярату-яратмау турында сөйләнү, һаман ятак кайгысы шул анда... Ләкин яшәүнең сөешүдән башка да бик күп төрле мәшәкатьләре, гамьнәре, куанычлары бар. Эше-хезмәте, җыры-моңы, сагышлары, күңел ачулары... Дөрес, гыйшык дигәндә һәммәсе онытыла, диләр. Мәхәббәт бөек хис,

диләр. Әмма үз башыңа төшсә, Алла сакласын икән андый утлы хисләрдән! Мәхәббәт ул башка берәүне үзеңә кол итәргә тырышудан гыйбарәт икән. Хәер, колларның да, мөгаен, уйларына, хистойгыларына, кайчакта кемгәдер сокланып күз атуына хуҗа булып бетә алмыйлардыр. Аларның иң нечкә тойгылары, хыяллары, күңел кылларының чыңлавы иректә каладыр. Әмма сине сөям дигән берәү, синең белән гомерен загс чылбырлары белән бәйләгән кеше күңеленә хуҗа булырга теләсә, нишләргә?

Монысына риза булган ирләр тоташ ялган эчендә яшәргә дучар булалардыр. Һәм мондый тормыш аларны изә, кешелеген бетерә, шәхесен җимерәдер.

Суда тәңкәләр уйнаган кебек, җил исеп узган кебек, кояшлы яңгыр явып үткән кебек, вакытлыча күңелнең уйнап алуын ниндидер бер фаҗигагә әверелдерергә кирәк микән?

Ахмак та түгел кебек югыйсә, нишләп Лениза шушы гап-гади нәрсәләрне аңламый икән? Сөюе чынмы соң аның?

Шунда кинәт Мидхәтнең күз алдында тылсымлы лампа кабынып, үткәннәрне яктыртып күрсәткәндәй булды. Беренче тапкыр кавышу күз алдына килде. Өзелеп сөйгәнгә күрә бирелдеме аңа Лениза?! Әгәр ул кичне, тулай торакка кайтыр алдыннан, кунакта булмасалар, ул Мидхәтне үзенә шулай якын җибәрер идеме икән?! Һич юк! Әнисәдән көнләгән ул аны, югалтудан курыккан. Шуңа шулай сыланган да. Мәхәббәт түгел, көнчелек кавыштырган аларны!

* * *

Шуннан соң атна буе Мидхәт өйгә кайтмады. Ул эшли торган цех заводның читендә, лабораториядән ерак. Анда барып, ирен күзәтеп йөрергә Ленизаның горурлыгы ирек бирмәде. Яслебакчадагы тәрбияче әйтүенчә, сәгать җиделәр узгач кына анда кереп, Рамиләнең хәлен сораша икән үзе. Аннары кая китәдер, кайда төн үткәрәдер, билгесез. Лениза кебек ялгызы сагыш утына уралып аунап ятмыйдыр, үзенә бер җылы кочак тапкандыр әле!..

Ленизаның бәгырен көнчелекнең бер генә түгел, йөз күсесе кимерә иде кебек. Мең мәртәбә ул Мидхәтне башка бер хатынның кочагында күз алдына китерде. Менә кайчан аңлады ул ирләрен йә хатыннарын үтергән кешеләрнең халәтен!

Бу газаплар өчен җавап бирергә тиеш ул. Шундый итеп үч алырга кирәк, ул да чыдап булмаслык өзгәләнсен. Ленизага боз күз белән караганы өчен, аны ташлап чыгып киткәне өчен мең үкенсен! Аяк астында тәгәрәп гафу сорасын!

Ләкин ничек итеп аны шундый хәлгә җиткерергә?!

Эчендәге уттан көеп, караңгыда ялгызы яткан хатынның башына һич көтелмәгән уйлар килә. Әгәр Лениза юк булса, бу газапларга түзә алмыйча үлеп китсә, нишләр иде икән ул?! Гомеренең ахырына кадәр вөҗданы тынгы белмәс иде! Димәк... үләргә... Язу калдырырга кирәк булыр...

Үз-үзенә кул салган бәхетсез хатыннар турында шактый киноларда күргәне, китапларда укыганы бар Ленизаның. Һәммәсенең һәлакәтенә төп сәбәп — бәхетсез мәхәббәт. Анна Каренина поезд астына ташланган. Катерина биек ярдан суга сикергән. Мадам Бовари учлап-учлап мышьяк ашаган... Юк, бу ысуллар берсе дә ярамый... Институтта кайсыдыр елны бер студент та мышьяк белән агуланган булган. Җаны чыкканчы бик озак газапланган. «Юләр, — дип сөйлиләр иде аның хакында. — Химик була торып, мышьяк йоталар димени? Безнең лабораториядә эһ дигәнче күзеңне мәңгегә йомдыра торган матдәләр ясап була!»

Завод лабораториясендә контроль көчле, теләсә нәрсә болгата алмыйсың. Аңа вакыт та юк, Ленизаның җаны түзми, ниятен бүген үк тормышка ашырасы килә иде. Дөньядан китүнең уңайлы чарасын эзләү ярсып типкән йөрәкне бераз тынычландырып җибәрде. Көн яктырып, беренче трамвайның дөбердәвеннән караватжиңелчә генә тибрәлгәндә, баш бераз суынган иде инде... Үләргә үк ярамас, әлбәттә. Куркытырга гына кирәк булыр, үлгән булып кыланырга. Коты алынсын... Тәүбәгә килсен... Ә аннары, шактый вакыт узгач кына, күзне ачып, аны чиксез куандырырга...

Ныклы карарга килү көч бирде. Ул Рамиләне дуылдатып торгызды да ашыгып киендерә башлады. Кыз сызланып елап җибәрде: әнисе кабалануыннан баланың оеклы ыштанын ипләп кигезмәгән, аяк бармагының йомшак тырнагына җеп эләгеп, каерган икән.

— Тукта хәзер үк! — дип, бармагын аның борын төбендә селкеде Лениза. — Тыныңны чыгарасы булма! Атаң күзләре белән акаеп карама миңа!

Кызчыкның елавы сулкылдауга әверелде. Лениза аны җилтерәтеп бакчага алып китте. Лабораториягә телефоннан шалтыратып, чирлим, температурам утыз сигезгә күтәрелде, дип, бер көнгә отгул алды.

Көнне ул шәһәр буйлап аптекаларда йөреп уздырды. Хәйләләп, ялынып, йокы даруы җыйды.

Вакыты да бик җайлы туры килде: радиодан кат-кат суыклар килүе турында хәбәр итеп тордылар. Төнлә каты кырау төшәчәк икән. Бу якларның сәер бер үзенчәлеге бар шул: август урталарында нык кына суытып ала, бакчадагы помидор-кыяр түтәлләрен капламасаң, бетерә. Атна-ун

көннән тагын җылыта үзе, исән калган кыяр үсә, помидор сабагында кызара һәм шулай тагын ай буе диярлек дәвам итә.

Бакчасына күпмедер күңел биргән хуҗалар моны яхшы белә, кырау килгән көннәрдә түтәлләрен ышыклап каплый. Мидхәт, әлбәттә, уңган хуҗа, кагыйдәләрне төгәл үтәргә күнеккән. Бүген ул бакчага бармый калмаячак. Өйгә, бәлки, кайтмас та, ә анда барыр! Шунда ук кунып йөрми микән әле!

Ничек кенә булмасын, ниятләгән чараны анда гамәлгә ашыру дөрес булыр.

Кичкә таба автобуста барганда, Ленизага һәммә нәрсә күңел кайтаргыч булып тоелды. Халык ямьсез киенгән, чөнки күпчелеге, чыннан да, бакчага бара, телләрендә гел шул помидор да кыяр.

Автобустан төшкәч кенә, бакча күршесе Аня белән очраштылар.

— Чирләмисеңдер бит? Төсең качкан, — диде Аня, сәлам алышкач. — Больничныйдамы әллә?

— Кәефем юк, баш авыртып тора. Эштән сорап киткән идем. Кырау була, диләр бит, шуңа килдем.

— Кәефсез килеш ник интегеп йөрисең? Мидхәтең эштән соң килер иде әле.

— Син дә килгәнсең бит менә.

— Минем Николай отпускыда бит. Таңнан торып балыкка киткән иде. Дөньясын оныткандыр, кырау төшәсен дә ишетмәгәндер. Баланы әбисенә калдырып, өч кенә сәгатькә дип килүем.

Кырыктан узган Аня өч ай элек кенә кыз бала тапкан иде.

— Ә минеке... полигонда... — диде Лениза.

— Мондый көнне соңарып булса да килә инде ул!

Аня, җавап көтеп, бераз тынып торды. Саллы гына гәүдәле, алпан-тилпән атлап йөрүче, чал кергән чәчен шома итеп тарап куйган бу хатын бик игътибарлы, ярдәмчел, шул ук вакытта артыгын төпченми, гайбәт сөйли торган гадәте дә юк иде.

— Синең Мидхәтең хуҗалыкчыл шул, — диде ул. — Минем Николайга кая инде! Балык тотудан башканы белми... Синекеннән үрнәк алсын иде, ичмасам...

«Тәүбә, диген... Минекеннән үрнәк алып, әллә кайда йөрсә, ник шунда яр башында балык тотып кына утырмый икән, дип, мең уфтанырсың...»

Ләкин юк, монысын әйтмәде Лениза, тел очында тотып калды.

Аның бакчага байтактан килгәне юк иде. Мидхәт һәммәсен тәртиптә тота: чүп үлән заты юк, түтәлләрне ябарга пленкалар әзерләп куелган. Әллә чыннан монда кунып йөри микән? Ә бәлки, ялгызы гына килмидер?!

Башка вакытта Лениза Мидхәтнең уңганлыгы белән мактана иде. Хәзер исә ачуы кабарды: юри шушылай кылана, күршеләр алдында үзе генә эшләгәнен, Ленизаның ялкаулыгын күрсәтү өчен тырмаша! Аның шундый гадәте бар! Баш күтәрми эшли, эшли, эшли! Әрәмәлеккә барасы, су буйларын гизәсе урында, туфракта чокынудан, тузан йотудан арынмый. Аның аркасында Лениза да беркая бара алмый, берни күрми. Рәтле кешеләр бакча җиренә тоташ үлән чәчәләр дә су буенда кызынып яталар!..

Карлыган куагыдай биек, куе георгиннарның эре-эре ак, сары, кызыл чәчәкләре, күңелне хушландырасы урында, эчтәге ачу белән сөю катыш җәһәннәм утын тагын да ныграк көйрәтеп җибәргәндәй итте.

Лениза өйгә керде дә, сумкасын ачып, эчендәге бар нәрсәне өстәл өстенә селкеде. Кулъяулык, көзге, ирен буявы ишеләр арасыннан дару капларын аерып алды, шытыр-шытыр ачып, вак төймәләрне учына җыйды. Чиләктән чынаяк белән су чумырды.

Һәм тирән итеп сулыш алып, кулындагы төймәләрне авызына китерде. Шулчак:

— Лениза! Лениза! — дигән тавыштан сискәнеп туктап калды.

Аня кычкыра иде.

— Лениза! Син өйдәме соң?

Җавап бирми калып булмый иде.

— Өйдә...

— Чәй куеп эчмәкче идем, шырпым беткән... Ни булды?! Әллә йөрәгең тоттымы?

Күрше хатынның тавышында чагылган борчылу, кызгану, ярдәм итәргә омтылыш шулкадәр көчле иде ки, Ленизаның кинәт хәле китте. Ул урындыкка утырды да елап җибәрде. Аня аны иңеннән кочып алды, өстәлдәге кәгазь капларга, Ленизаның кулыннан чәчелгән дару төймәләренә күзе төшеп сискәнеп китте.

— Бу ни бу? Нәрсәгә ул хәтле дару? Кая, мин сиңа бөтнек кайнатып бирим. Эчәрсең дә бераз ятып торырсың...

— Их, Аня, минем йөрәк ярасын бөтнек белән генә төзәтеп булырлыкмыни? Яшисем килми минем... Ул монда килер дә, минем үле гәүдәмне күрер дә...

— Син нәрсә... Болай кыланырга... Үпкәләшмәгән ир белән хатын дөньяда юк...

— Ул мине күралмый... Әгәр мин юкка чыксам, башка хатын алып кайтыр иде дә гел бәхетле булыр иде... Ник яшәргә миңа? Ничек яшәргә?

Аня аның башын сыйпады.

— Артыгын ярсыгансың син, һәммәсен эченә җыеп күперткәнсең. Ярамый алай. Эченне бушатып, киңәш-табыш итәрдәй беркемең дә юкмыни соң?

Лениза башын чайкады.

— Минем дә кая барып, кемгә сыенырга белмәгән чакларым аз булмады, — диде Аня, Ленизаның башын йомшак күкрәгенә кысып. — Рухи таяныч кирәк шул адәм баласына, өмет кирәк. Рухи таянычы, алда өмете булмаган кеше тамыры киселгән гөлгә тиң. Аз гына җил бәрсә дә, кубарыла. Үземнән беләм.

— Әллә синең Николай да?..

— Юк. Минем башка яктан... Озак еллар балабыз булмады бит безнең. Кырыктан узгач кына буйга уздым. Шундый куанган идек. Ә ул гарип булып туды, күп тә тормый үлеп китте. Шулай итеп, бала хәсрәте килде миңа. Ә аннан ачысы юк диләр... Минем дә яшисе килмәгән көннәрем булды. Җитмәсә тагын, врачлар, бер ел үтми торып балага узасы булма, югыйсә икенчесе дә гарип туачак, дип кисәттеләр. Минем яшьтә андый сүз ишетүнең ни икәнен белмисең шул әле син...

— Балаң бар бит синең... кызың Алевтина...

— Ул кызга ирешкәнче шактый авыр хәлләр кичерергә туры килде. Мин дә төрле якка бәргәләндем. Чиркәүгә дә бардым. Сабыр ит, диделәр, табибларның сүзенә колак салырга киңәш иттеләр. Башымны кая куярга белми йөргәндә, танышларга ияреп клубка барып кердем. Анда Укытучы белән очраштым.

«Встретилась с Учителем», — диде Аня.

— Нинди фәннән укытучы? — дип сорады Лениза.

— Мәктәп укытучысы түгел. Аны зурлап шулай атыйлар. Башта бер дә исем китми генә тыңлаган идем. Аннары сизәм: җаным тынычлана, күңелем яктырганнан-яктыра.

— Нәрсә сөйләде соң ул?

— Мин аны кабатлый белмим. Үзен тыңларга кирәк... Соңыннан аның янына сәхнәгә мендем. Ул минем хәлемне ике сүздән аңлап алды. Күземә тутырып карады да, синең өчен йолдызларның торышы август аенда кулай, балаң шушы айда яралса, сау-сәламәт туачак, диде. Узган елны август аенда булды бу.

— Сүзе расланды дамы?

— Алечкам томрап тора!

Беразга тынып калдылар.

Лениза Аняның ниндидер җәмгыятьме, оешмамы белән элемтәсе барлыгын кемнәндер ишеткән, тик моңа илтифат бирмәгән иде. Хәзер шул искә төште дә, күңелдә шик туды, чөнки соңгы вакытта әллә нинди хикмәтле секта-мәзһәбләр хакында төрле сүзләр йөри иде. Телевизордан аларның яшерен урыннарда очрашканнарын, сәер, шомлы кыланмышларын күрсәтәләр. Арада зур җинаять кылганнары да бар икән. Мәсәлән, Япониядәге шундый бер мәзһәб, Токио метросында агулы газ таратып, йөзләрчә кешеләрне зарарлаган. Бу хакта шау-шу бик озакка сузылды.

Лениза шуларны уйлап утырган арада, Аня өстәл тартмасыннан шырпы табып алды.

— Боларны эчәргә беркайчан да соң түгел,— дип, өстәлдә таралып яткан кәгазьләргә ымлады. — Әйдә, чәй эчеп алыйк әле без. Бөтнек чәенең йөрәккә шифасы бик зур.

Алар Аняга кереп чәй кайнатып эчтеләр, аннары бергәләшеп аның түтәлләрен томаладылар. Өстәл янында да, түтәл тирәсендә әвәрә килгәндә дә сүз туктап тормады. Аня йомшак, уйчан тавыш белән Укытучының бик галим кеше икәнлеге, төрле илләрдәге зур философлар белән багланышта торуы, үзенең дә гыйльми хезмәтләр язуы турында сөйләде. Китаплары бик күп шәһәрләрдә тарала, тарафдарлары да меңнәр белән санала икән. Тузга язмаган хорафатларга ышана торган наданнар түгел, зыялы, укымышлы кешеләр тартыла икән аңа, арада инженерлар, галимнәр, врачлар, укытучылар күп икән... Һәркайсының үз гаме, үз борчулары бар, берсенең дә капчыгы буш түгел. Әмма бергә җыелгач, күзләр ачыла, борчулар тарала. Кеше арасында рәхәт инде ул! Бигрәк тә үз ишләрең белән булганда.

— Ничек алай бериш була соң алар?

— Фикердәшләр генә җыела бит. Укытучы алып килгән тәгълиматны кабул итә алмаганнар бер килеп тыңлап карый да китеп бара. Ихлас ышанганнар гына кала.

— Нинди тәгълимат соң ул?

— Укытучының үзен тыңлап карасаң иде син... Ул хәзер монда. — Ленизаның икеләнгәнен күреп: — Ошамаса, борылырсың да чыгып китәрсең, — дип дәвам итте Аня. — Анда берәүне дә көчләп тотмыйлар.

— Кайда... очрашасыз соң сез?

— Клубта очрашу киләсе атнада була. Иртәгә китапханәдә җыелып сөйләшәчәкбез. — Аня район китапханәсендә эшли иде.— Кеше күп булмый, актив йөрүчеләр генә.

Лениза ярыйсы гына тынычланып киткән иде инде. Ни дисәң дә, китапханә йөрәккә якын урын, институтта укыган кеше өчен бигрәк тә. Ә нигә кереп чыкмаска? Андый җирдә начар гамәл кылынмас.

...Киткәндә, ул үз бакчасына бүтән кереп тормады. Мидхәт килер дә һәммәсен җайлар дип уйлады.

Ул кайтканда, күптән караңгы төшкән, тәрәзәләрдә ут юк иде. Ә Рамилә кайда? Әтисе үзе белән бакчага алып киткәндер, мөгаен. Эштән чыккач, балалар бакчасына сугылмый калганы юк бит аның...

Берәр сәгатьтән ишек кыңгыравы зыңгылдады. Бусагада бер кулына — кечкенә арба, икенче кулына Рамиләне күтәреп Рәйсә басып тора иде.

—Уф, ярый әле кайткансың, — диде ул. — Икенче керүем инде, бая ишек ачучы булмады. Кайда йөрдең соң син? Нигә Рамиләне барып алмадың?

— Мидхәт барырга тиеш иде бит! — диде Лениза, кызын аннан алып.

— Мидхәтең командировкага киткән бит, белмисеңмени?

— Кайчан киткән?

— Көндез үк инде. Кайсыдыр шахтага җибәргән шартлаткычлары тиешле җиргә куйгач шартламаган, ди. Кире ала алмыйлар, орынырга куркалар икән. Көне-сәгате белән килегез дә үзегез казып алыгыз, дип, телеграмма сукканнар. Хәлләр харап, ди, анда. Шахтада эш бөтенләй туктаган.

— Миңа берни әйтмәде бит ул!

— Син бүген эштә идеңме соң?

— Поликлиникага барган идем...

— Сине тапмаган инде алайса... Тәрбиячеләргә әйтеп калдырган, бүген килә алмыйм, дигән. Алар безгә шалтыратты да, барып алдым менә. Иртәгә санитария көне икән, кунарга калдырмаганнар. Мин аны Илдус белән бергә әйбәтләп ашатып куйдым инде.

— Уз әйдә, нишләп бусагада торасың?

— Рәмис, озак йөрмә, дип, артымнан кычкырып калды анда,— диде Рәйсә, шаян елмаеп. — Ятар алдыннан тәмләп чәй эчә торган гадәте бар аның.

— Бәби түгел лә, чәйне имезлектән эчермисеңдер!

Авызыннан төртмәле сүз ычкынганын Лениза үзе дә сизми калды. Тик Рәйсә моны аңламады, әллә аңлап та илтифат бирмәде.

— Анысы да булгалый, бер-беребезгә кашыклап каптырабыз! — диде шаяруга борып. — Чәйнең иң татлы балы — парлашып-чөкердәшеп эчүдә, ди ул.

Рәйсә бәхетен уртаклашканны көтеп, елмаеп карап тора иде. Йөзе-күзе күптән төзәлгән, күзлек пыялалары астыннан ике бит алмасы алланып тора.

— Сулга йөрүдән туктадымыни? — дип сорады Лениза.

— Тынды, Аллага шөкер. Тиз туктады. Югыйсә ирләр алар бер тайпылса, ике елсыз игә килми.

— Нишләп ике ел?

— Аларның срогы шундый. Хатын-кызга кузгалган гыйшык дәрте ике елга гына чыдый. Шуннан соң сүрелә.

— Үз хатынына дамы?

— Гыйшык бит ул — күңел эше, загс язуына карамый! Ә аларның күңеле шулай яратылган.

— Ике елдан соң ничек яшиләр?

— Ир-хатын ике елда бер-берсенә күнегә, җайлаша. Уртак милек, фатир... Бала!.. Балага булган мәхәббәт сүнми. Ә сөяркә нәрсә... Аягың тартмаса, бармыйсың гына...

— Ул шулай икешәр ел әллә кем кочагында аунап кайтсын, ә син шуны... — Лениза сүз табалмый торды. — Пычрак өстерәлчекне кочак җәеп каршы аласыңмы? — дип дәвам итте аннары. — Ул башканы синнән артык күреп, синнән көлеп йөргән. Син шуны гафу иттеңме?

— Ә ул миннән гафу сорамады.

— Кичер мине дип тә әйтмәдемени?

— Бернинди андый сүз әйтмәде.

— Нәрсә диде соң ул?

— Кайчан?

— Ну, теге хатын янынан кайтып кергәч?

— Эштән кайтты ул. Ни дигәне истә калмаган. «Карчык, ашарга әзерме», диде бугай...

— Әзер идеме?

— Хәтерләмим инде. Әзер булмаса, бераз көткәндер. Баланы карагандыр. Шунысын беләм: ул кайткач, өйгә ямь керә, кот иңә. Аны күрүгә улыбызның ничек куанганын күрсәң син! — диде Рәйсә, Лениза кулындагы Рамиләгә сөеп карап. — Әтисенә бер авыр сүз әйтергә дә рөхсәт итми.

— Үзе шуны әйтәме? — дип чиксез гаҗәпләнеп сорады Лениза.

— Теле белән әйтә алмаса, күңеле белән шулай ди. Уйладым-уйладым да шуны аңладым әле мин: без үз тормышыбыз белән генә түгел, балабыз тормышы белән дә яшибез! Мескен сабыйлар үзләре бернишли алмый, без ни кылсак, яшәешләре шулай бара. Мин иремнән аерылсам, улым ярым ятим үсәчәк бит! Аны шундый язмышка дучар итәргә ни хакым бар минем? Юк инде, иремне беркемгә дә бирмәячәкмен!

— Гомер буе шулай яшәрсезме?

— Ул да бер аңына килер әле. Бүтәннәр аннан яхшыракмы әллә? — дип сорауга сорау белән җавап бирде Рәйсә.— Уңга карыйсың, сулга карыйсың... Берсенең дә ире фәрештә түгел, һәркайсының кимчелеге бар... Син дә Мидхәтнең җитмәгән ягын табасыңдыр...

— Бар, нигә булмасын. Сиңа гына идеал булып күренә ул, синең генә күзне кыздыра... — диде Лениза, үзе дә сизмәстән.

Рәйсәнең ияге салынып төште, калын пыяла астындагы күзләре зур ачылды.

— Авызыңнан җил алсын! Син нәрсә! Минем хакта начар уйласаң уйла, иреңә нахак бәла ягып гөнаһлы була күрмә! Булмаганны эзлиләр димени! Булганына күз йомарга өйрәнергә кирәк!.. Ай, нишләп торам соң әле мин дөньямны онытып? Сүз бозау имезә... Үпкәләп утырмасын тагын!

Ул, борылып, таш баскычтан аска томырылды, үкчәләре тыпырдаганы гына яңгырап калды.

Ул төнне Лениза бик озак йокыга китә алмады. «Алар, мөгаен, ятакта бер-берсенә бик тә ярашалардыр, — дип уйлады ул Рәйсә белән Рәмис турында. — Сөяркәсен сөйгән ир үз хатынын да сөя, диләр бит». Ләкин Мидхәт ятакта суынды! Ул Рәмис түгел, бөтенләй башка! Икене берьюлы йөрәгенә сыйдырмас. Лениза да иренең йөрәк түрендәге урынын башкалар белән бүлешә торганнардан түгел. Ә ул урынны кемдер биләгән. Рәйсә түгел, бүтән... Ә бәлки, ул «бүтән» Казандадыр? Командировкада йөргәндә анда кереп чыгу ягын тагын табар, бәлки?..

Ул төн Лениза өчен бик озын тоелды.

Ул төнне каты кырау төшеп, капланмаган түтәлләрдәге кыяр-помидорларны, ак, сары, кызыл чәчкәле гөлләрне — һәммәсен кара күмер итте.

* * *

Китапханәнең кечерәк кенә уку залында, алгы рәттәге өстәлләр артында унлап кына кеше утыра иде. Мондый җиргә гадәттә студентлар, өлкән класс укучылары йөри, китап укыйлар, конспект язалар. Биредәгеләр исә утыз белән илле арасында булып, күпчелеге хатын-кыз иде. Өстәлләре буш, үзара шыпырт кына сөйләшәләр. Аня белән Ленизаны күргәч, сүзләрен өзеп, тынып калдылар.

— Таныш булыгыз, минем күрше бу, исеме Лениза, һөнәре инженер-химик, — диде Аня.

— Исәнмесез! — диде Лениза.

— Саумысыз! Хуш киләсез безнең арабызга... — дип урыныннан кузгала төшеп алгы өстәл артыннан кулын сузды кара костюмлы, башына ак шарф ураган, чандыр гәүдәле иллеләр тирәсендәге апа.

Барысы белән дә кул кысышып, исәнләшеп чыгарга туры килде. Һәммәсе үзенең исемен һәм һөнәрен әйтте. Чыннан да, укымышлы халык җыелган икән: инженерлар, табиблар, музыкантлар, фән әһелләре. Киемнәре пөхтә, кыяфәтләре затлы. Йөзләрендә җитдилек тә, ниндидер зур вакыйга көткәндә була торган дулкынлану да чагыла. Лениза бу кешеләрдә тагын бер уртаклык барын күреп алды: хатын-кызлар һәммәсе бер үк төрле медальон таккан иде — нечкә чылбырга тагылган ырмау эчендә бишпочмаклы йолдыз. Алтын булса кирәк, ялтырап тора... Ирләрнең пинжәк-куртка якаларында да шундый ук значок бар, тик сары түгел, ак металлдан ясалган.

Лениза, арткарак узып, аерым бер өстәл артына утырды. Китап белән шыплап тутырылган киштәләр, тезелеп киткән урындык-өстәлләр — студент чактан күнегелгән бу мохит аның күңеленә бик тә ятышлы иде. Шул үк вакытта үзенә бер серлелек бар иде монда һәм бу серлелек шомландыра торган түгел, ә бәлки якты иде, гүяки ниндидер бик тә кызыклы яисә шатлыклы вакыйга булачак иде.

Һәм менә... Ишек ачылды, бусагада Ул күренде. Һәммәсе урындыкларын шудырып торып бастылар.

— Исәнмесез! Нур һәм сафлык! — диде ул, күңелгә сары май булып ятышлы куе тавыш белән, һәм уң кулын учы белән башкаларга каратып, күкрәк турында сулга-уңга селкеп куйды.

— Нур һәм сафлык, Укытучы (Учитель)! — дип җавап бирделәр бүлмәдәгеләр бертавыштан. Алар да кулларын түш турына күтәреп, салмак кына болгап алдылар. Лениза үзе дә сизмәстән алар артыннан: «Нур һәм сафлык...» — диде, кулы ихтыярсыздан башкалар ясаган хәрәкәтне кабатлады.

Зур ачылган күзләре исә, карточкага төшереп алгандай, каршыда басып торган затның бөтен кыяфәтен күңеленә уйды да куйды. Аның затлы бүрек кебек күпереп торган кыска кара чәчле йомры башын, шома итеп кырылган булуына карамастан каралып торган киң яңаклы түгәрәк йөзен, сул кашын кыйгачлап узган яра эзен, киң шакмаклы ияген, бүлтәеп торган муен төенен... Аның буйлы кара костюм кигән озын-таза, мөгаен, бик көчле буй-сынын, күзләрне чагылдырырлык дәрәҗәдә ялтырап торган бик тә кыйбатлы очлы башлы шиблетларын... Чибәр дип булмый, әмма гайрәтле ир-егет, алай гына да түгел, чын мәгънәсендә җиңүче иде бу.

Ә шулай да өнсез иткәне бу кешенең тышкы кыяфәте түгел иде. Мәһабәт буй-сын, килешле йөз-бит күпләрдә бар ул! Үз-үзен кадерләгән-караганнары, шәп киенгәннәре, чыраена акыллы кыяфәт чыгарганнары да күп. Хикмәт шунда ки: алда санап үтелгән барлык сыйфатлар бу затның кысасы гына

иде. Асылташлар өчен саф алтыннан, бик зәвыклы бизәкләр үреп, шундый кысалар ясыйлар. Ләкин ул нихәтле генә затлы булса да, әйбернең чын кыйммәте анда түгел, ә бәлки аның уртасында балкып торган җәүһәрдә. Кысалар үз эчендәге ташның матурлыгын, һиммәтен ялтыратып күрсәтү өчен эшләнә.

Бу кешенең дә киеме, кыяфәте, үз-үзен тотышы — барысы да күзләренең серле нурын, тирәнлеген күрсәтү өчен кирәк иде кебек. Ни текәлеп карасаң да, аларның төсен ачык кына әйтеп булмый иде: әллә коңгырт, әллә сорырак микән... Ул сиңа туры гына төбәлмәгән дә кебек, бәбәкләре куе зәңгәр томан белән өртелгән шикелле. Әллә бүлмәдәге һәммә кешене күрә, әллә үзенең серле уйларына бирелгән... Ләкин аннан карашны алып булмый. Ихтыярсыздан син, минем тарафка бер генә тапкыр кыска куе керфекләрен сирпеп күз салсын иде, дип эчтән ялварасың...

Менә ул, алдагы өстәл янына килеп, бүлмәгә йөзе белән басты, кулындагы портфелен куйды.

— Әйдәгез, утырышыйк, — диде.

Беренче карашка мондагы мохит, чыннан да, мәктәп классын хәтерләтә иде. Алдагы өстәл артында Укытучы утыра, башкалар зур дикъкать белән аңа текәлгән. Ләкин ул шундый ачык чырай белән йомшак итеп сөйләшә, һәркайсын шундый зур дикъкать белән тыңлый — бер сүз белән әйткәндә, үзенең башкалардан өстенлеген берни белән дә сиздерми иде. Биредә син үзеңне һич кенә дә гади укучы итеп сизмисең. Бу — сагынып-зарыгып күрешкән дусларның, фикердәшләрнең очрашуы иде. Ә каршыда Лениза алдан уйлаганча укытучы түгел, Остаз утыра. «Учитель»нең татарчада мондый мәгънәсе дә бар бит. Аралашу гади кебек тоелса да, эчке бер киеренкелек, нык дулкынлану сизелә: йөзләр алланган, күзләр елтырый, тавышларда үзенә бер куанычлы тынгысызлык, хәрәкәткә омтылыш ишетелә.

Лениза тыңлап кына утырды. Алай да Остаз ара-тирә аңа карап ала, еш кына, ул аңласын өчен, башкаларга мәгълүм булган нәрсәләрне дә кабатлый иде булса кирәк. Аның һәр сүзе Ленизаның күңеленә күптән кипшенгән туфракка яуган талгын җылы яңгыр кебек сеңеп кенә барды.

Биредәгеләр безнең чорның үсешенә тәңгәл килгән, шушы заман кешеләренең рухына яраклы яңа тәгълиматның тарафдарлары, алдынгы карашларны алга сөрүчеләр икән.

— Без бер динне дә инкарь итмибез, — диде Остаз. Бу урында берничә кеше аның сүзләрен ияк кагып хуплады һәм, борылып, Ленизага мәгънәле караш салып алды. — Безнең «Нур һәм сафлык» тәгълиматын кабул итүчеләр арасында христианнар да, мөселманнар да, яһүдләр, буддистлар да, атеистлар да бар. Чөнки без кешелекнең алга баруын, вакыт узган саен күбрәк мәгълүматка ия булуын беләбез, шуны исәпкә алабыз. Галәм өзлексез хәрәкәттә, кешелек аның серләрен өйрәнә, яңадан-яңа мәгълүмат туплый. Шуны исәпкә алып, Илаһи Зат җиргә һәр яңа чорда яңа пәйгамбәрләрен җибәреп торган. Ләкин менә берничә гасыр инде кешеләр ул җибәргән пәйгамбәрләрнең берсен дә аңлап, тиешенчә зурлап кабул итә алмадылар. Кемнәрдер Будда сөйләгәннән башканы белми, кемнәрдер Иисус вәгазеннән ары узмый, кемнәрдер Мөхәммәт пәйгамбәр әйткәннәргә инана. Тик алардан соң яшәеш бик нык үзгәрде, кешеләрнең аңы да бөтенләй икенче бит инде...

Ленизаның хәтеренә келт итеп чиркәүдә атакай әйткән сүзләр килеп төште: «Хода безгә әйткәнен әйткән...» Әйе, шул чор кешеләренең аңына барып җитәрлекне әйткән... Ләкин без чыннан да Иисус заманындагы кешеләр кебек түгел, бөтенләй башка!

«Нур һәм сафлык» тәгълиматы җиһанны, бар тереклек ияләрен, адәмнәрне бар иткән Илаһи Затның, Бөек Кодрәт Иясенең барлыгын таный. Ул югарыда, биектә, ләкин искергән диннәр раслаганча, җиде кат күк өстендә түгел, ә бәлки галәм киңлегендә. Барча җисемнәр хәрәкәтләнгән кебек, ул да урынын алыштыра. Хәзерге вакытта ул Сириус йолдызында.

Адәм балаларының һәркайсы күкләр белән, галәм белән аерылгысыз тыгыз бәйләнгән. Галәмнән килгән нурланыш безнең һәркайсыбызга килеп ирешә, бездән сибелгән дулкыннар да галәмгә тарала. Тик менә адәм балаларының бик сирәге генә Бөек Кодрәт Иясеннән килгән нурланышны тоеп, мәгънәсен аңлап, аны башкаларга җиткерү сыйфатына ия була ала. Моңа ирешү өчен тәнеңне дә, җаныңны да камилләштерергә кирәк. Остаз нәкъ менә шундый — галәмнән килгән нурланыш-хәбәрләрне кабул итә белүче, аңлаучы — эзотерик икән.

«Ул нурланыш миңа да килеп ирешә бит инде, мин дә аларны аңлый алыр идем...» дигән татлы хыял Ленизаның башын әйләндереп җибәрде.

Югарыдан килгән хәбәрләргә караганда, хәзерге вакытта җир йөзенең төрле урыннарында ахырзаман хәлләре бара. Моңа кешеләр үзләре гаепле. Кызганычка каршы, бүгенге чорда адәм балаларыннан галәмгә тискәре тәэсир итә торган дулкыннар күп китә. Соңгы елларда кешеләрнең бихисап явызлыклар кылуы, пычрак уйлар, шөгыльләр белән мавыгуы күз алдында бит. Болар һәммәсе галәмнең камиллеген боза, анда төрле гайре табигый үзгәрешләр булуга китерә. Шуннан соң һәртөрле фаҗигаләрнең көчәюенә, сугышлар башлануга гаҗәпләнергә дә кирәкми. Әгәр шулай дәвам итсә, кешелекнең киләчәге бик тә аяныч булачак.

Моны булдырмас өчен, бар көчебезне куеп, адәм балаларыннан космоска, галәмгә китә торган начар дулкыннарны киметергә тиешбез. Иң элек кешеләрнең үзләрен-үзләре сафландыруы зарур. Тәннәре дә, күңелләре дә чиста булырга тиеш аларның.

...Бик тә аңлаешлы һәм йөрәккә якын иде эзотерик Остазның сүзләре!

— Мин сезгә үземнең яңа китабымны алып килдем,— дип, портфелен ачты ул. Китап калын гына, ялтыравык тышына йолдызлар, планеталар һәм аларга кулларын сузган кыз белән егетнең сурәте ясалган иде.

— Таратырбыз, таратырбыз, — диешеп, һәммәсе кулларын суздылар.

— Сез дә укып карарсыз, бәлки? — дип, томанлы да, үткен дә карашын Ленизага төбәде ул. — Эзотерикларның берәр китабын укыганыгыз бармы? Юкмыни? Аларны аңлар өчен күпмедер күләмдә әзерлек кирәк, билгеле. Сез югары белемледер бит?

— Аңлатырбыз, ярдәм итәрбез,— диде ак шарфлы хатын.

— Аңлату җитми шул, җитми,— дип, аның сүзен хуплады Остаз.— Шуның аркасында халыкның күпчелеге томана хәлендә яши бирә. Сез биредә күпме листовка, күпме журналлар тарата алдыгыз?

Шулай итеп, сүз үзеннән-үзе халык белән эшләүнең кыенлыкларына барып терәлде. Күп кенә шәһәрләрдә «Нур һәм сафлык»ның листовкаларын, игъланнарын бастыру, җыелышып сөйләшү-киңәшү, килгән кешеләрне кабул итү өчен аерым бүлмәләре, хәтта биналары да бар икән. Ә менә Н. шәһәрендә бу мәсьәләдә кыенлык килеп чыккан. Бер кечкенә куышың да булмагач, халык белән ничек эшләмәк кирәк?

— Дәрәҗәле, бай кешеләрне җәлеп итәргә кирәк, — диде Остаз.

— Алар шул һәркайсы үзенең нәселе тоткан дингә тартыла. Урыс булса, чиркәү сала, татар булса, мәчет торгыза, — дип зарланып алды ак шарфлы хатын.

— Чын йөрәктән түгел, халык каршында гына яхшатланалар,— дип нәтиҗә ясап куйды Остаз. — Чын хакыйкатьне аңларга теләмиләр. Алар өчен Алла — акча! Долларга табыналар!

Ә Лениза калтыранган бармаклары белән китапны сыйпый иде. «Герман Светлый. Нурлы юлдан сафлыкка» дип язылган иде аның тышына. Исеме Герман, димәк...

Бер атнадан шәһәрнең зур гына мәдәният сараенда халык белән очрашу булачак икән. Шуны ничек оештыру хакында сөйләштеләр. Һәм, ниһаять, Остаз урыныннан кузгалды. Лениза аның соңгы тапкыр үзенә генә елмаеп каравын, берәр ым кагуын, һич булмаса, керфек сирпүен көткән иде. Бик теләгән, өметләнгән иде. Ләкин Остаз бушап калган портфеленең ялтырап торган биген шартлатып япты да, башын күтәрми генә хушлашып, җиңел нык адымнар белән чыгып та китте.

— Бездә бик әйбәт журналлар да бар, — диде Аня. — Теләсәң, берничәсен ал.

Лениза аның түшендәге медальонга текәлгән иде. Остазның рухын чагылдырган тамга...

— Ә мондыйны каян алып була? — дип сорады ул, Аняның түшенә ишарәләп.

— Бездә сатыла ул. Төрлесе бар: алтыны кыйбатрак, акча тимереннән ясалганы арзан гына. Әнә Рәсимә сата,— диде ак шарфлы хатынга ымлап Аня. — Күбрәк ал син аны, эшегездә күрсәтерсең. Матур бит.

Герман Светлыйның китабын, чыннан да, бер төн эчендә укып чыгу мөмкин түгел иде, чөнки ул шактый катлаулы фәнни телдә язылган икән. Астрономия, космогония, физика, медицина — күп фәннәрдән мәгълүмат тупланган иде монда. Шуның өстенә астрология, теология тәгълиматлары да бирелгән иде. Әйе, мондый хезмәтне зур галим генә яза ала!

Аның урынына Аня биргән журналлар су кебек эчелә икән. Соңгы битләреннән шул да мәгълүм булды: алар бик күп итеп берничә телгә, хәтта татарчага да тәрҗемә ителеп басылып чыккан.

Менә берсе: тышында шарлавыклы-инешле гөлбакча сурәтләнгән. Гөлләр арасында нигъмәт тулы өстәлләр; алар тирәсендә елмаешып утырган кешеләр. Олысы-кечесе, ак тәнлесе, кара тәнлесе — һәммәсе бергә, бертигез. Бер читтәрәк кечкенә кыз бала аккошның муенын кочаклаган, икенче якта бер малай бүренең сыртын сыйпый.

Оҗмах манзарасы иде бу. Баксаң, ул күкләрдә түгел, җир йөзендә булачак икән һәм дөньяның җәннәткә әверелүен көтәргә озак та калмаган инде. Тик моның өчен ашыгыч рәвештә җирне тазартырга кирәк. Барыннан да бигрәк адәм баласының күңелен сафландырырга, шакшыдан арындырып, изгелек белән тутырырга...

...Икенче көнне, Рамиләне бакчадан алып кайтканда, Лениза тагын китапханәгә сугылды. Кичәге хатыннарның берничәсе анда Остазның яңа китабы хакында сөйләшеп утыралар иде.

— Әгәр халык боларны белсә, безнең тормыш бөтенләй башкача булыр иде шул! — дип уфтаныштылар алар. — Укымый шул халык! Надан!

Сүз Остаз куйган бурычка — китап-журналларны күбрәк таратуга килеп терәлде. Ә моның өчен бүлмә кирәк иде, бүлмә...

— Ксерокс алырга акча тапкан идек инде, шуны көйләп эшкә җибәрергә генә урын булса да ярап торыр иде... — диде Рәсимә.

— Шундый зурмыни соң ул?

— Зурлыкта түгел хикмәт. Эшләтергә кирәк бит аны. Кәгазьләрне каядыр куярга, аннары таратырга. Берәү гел шунда булырга тиеш, килгән-киткәнне кабул итәргә. Үземдә генә җайлап җибәрер идем, улларым рөхсәт итми...— Ул авыр сулап куйды.— Кришнаитлар шул алар...

— Балаларыгыз кришнаит, үзегез мондамы? — дип сорады Лениза, гаҗәпләнеп.

— Ни аңлый соң әле алар? Ялгыш юлдан киттеләр, — дип башын аска иде Рәсимә. — Барып каптылар... Белмиләр шул, аңламыйлар! — дип өзгәләнеп әйтеп куйды аннары. — Аңлатып җиткерә алмыйбыз... Остаз белән очрашуга чакыру кәгазьләрен күбрәк таратасы иде бит! Кайда гына басарга соң?

— Ә монда булмыймыни? — дип, уку залын күздән кичерде Лениза.

— Ю-ук, рөхсәт итмиләр. Хөкүмәт учрежденисе бит бу. Очрашуларны да яшереп кенә үткәрәбез.

Ленизаның да бу изге эшкә үз өлешен кертәсе килә иде. Чакыру билетларын басарга гына булса да... Мидхәт командировкада. Әле кайчан кайтыр... Анда тагын комиссия төзегәннәрдер, мөгаен...

— Минем квартир зур түгел түгелен, — диде ул. — Бәлки, ике-өч көн бездә эшләп алырсыз?

— Нишләп ике-өч көн генә?

— Ирем командировкада чакта дигән идем. Берәр атнадан кайтыр ул.

— Атна эчендә башка берәр куыш табар идек әле! — диде Рәсимә, тәвәккәл тавыш белән.— Хәзер үк барып карарга буламы?

Ул шулхәтле җитез атлый иде, аның артыннан трамвай тукталышына барып җиткәнче, кечкенә арба белән бала тарткан Ленизаның сулышы капты. Фатирны күздән кичергәч, Рәсимә, иреннәрен кысып:

— Нишлисең, шуннан да әйбәте юк бит,— диде.— Алай да, Остаз үзе килеп караса, яхшырак булыр иде. Мин аңа әйтермен.

Аның бу сүзләреннән Ленизаның йөрәге кысып куйды. Ул Рәсимәнең түшендәге медальонга ишарәләде:

— Боларны син сатасың дигәннәр иде.

— Сатам. Акчасын тулысынча үзебезнең кассага тапшырам.

— Кыйбатмы?

— Алтыны мең ике йөз. Көмеше алтмыш тәңкә. Тимере егерме биш сум. Күбрәк алган кешегә арзангарак та бирәбез. Чылбыры да кирәкме?

— Чылбыры үземдә дә бар. Аня әйткән иде, бурычка да алып була, дигән иде.

— Сиңа бирәбез. Акчаң булгач түләрсең.

— Әгәр мөмкин булса, кызыма да алыр идем.

— Яследә андыйны тактырырлар микән? — дип икеләнә калды Рәсимә.

— Тәрбиячеләр күрмәслек итәрмен.

Рәсимә сумкасыннан медальоннарның сарыларын, акларын чыгарып өстәлгә сипте.

— Бишне алсам ярыймы? — диде Лениза.

— Сиңа ярый. Алган кадәресенә язу бирерсең, шул гына. Остаз монда килергә кайчан вакыт таба алыр икән инде, — дип борчылып куйды Рәсимә. — Телефоның бардыр бит? Номерын бир әле. Аның белән сөйләшүгә шалтыратырмын.

...Остаз шул ук кичне килде. Сәгать тугыздан соң Рәсимә шалтыратып бу хакта әйткәч, Ленизаның тез буыннары йомшап китте.

— Үзе генәме? — дип сорады ул, телен чак әйләндереп.

— Белмим шул. Бәлки, берәрсе белән булыр. Анысын тикшерү минем эш түгел.

Рамилә инде йоклаган, бүлмәдә кызыл торшер гына янып тора иде. Лениза, ашыгып, кием шкафын ачты. Чалбар киргә ярамас... Әллә кайчан алынып та, моңарчы рәтләп киелмәгән плиссе юбкасы бар иде. Өйдә килешергә тиеш. Ак кофта... Башка ак шарф урарга... Рәсимә юкка гына бәйләмидер, шулай тиештер... Ул, алгы бүлмәгә чыгып, диварга беркетелгән көзге каршына басты, кыяфәтен күздән кичерде дә канәгать калды. Иренен чак кына кызартып, каш-керфекләрен төзәтеп куйды. Алай да һаман нидер җитми иде кебек. Кире бүлмәгә кереп, тартмадан «Нур һәм сафлык» медальонын алып такты. Янә алгы бүлмәгә чыгып, көзгегә карады. Нечкә бөжра эчендәге бишпочмаклы йолдыз аңа килешә, шул ук вакытта күңелне һәртөрле шик-шөбһәдән, гөнаһлы теләкләрдән арындыра, хәтта башкаларның нәфесле карашыннан да саклар кебек иде.

Кыңгырау тавышына ул дерт итеп куйды.

— Кем бар анда?

— Минем киләсемне сезгә әйтеп куймадылармыни? — диде таныш тавыш.

Ишек ачылганда, ул шундый ягымлы, үз итеп елмаеп басып тора иде, Лениза да ирексездән елмаеп җавап бирде.

— Нур һәм сафлык! Хәерле кичләр!

— Нур һәм сафлык! Исәнмесез, хөрмәтле Остаз! Узыгыз! — диде Лениза, әкрен тавыш белән.— Гафу итегез, бала йоклый иде.

— Ә ник аның өчен гафу үтенергә? Баланың вакытында йоклавы яхшы. — Ул кызыл ут белән яктыртылган бүлмәгә башын сузып карады да: — Кая? — дип сорады.

— Нәрсә «кая»

— Ксерокс, кәгазьләр.

— Китермәделәр бит әле. Рәсимә бүлмәне бүген генә карап китте.

— Бер рәтле эшләре юк! Монда минем бүген үк үрчетәсе кәгазьләр бар иде!

Шулай дип, Остаз кулындагы портфельгә шапылдатып сугып куйды. Лениза гаепле кешедәй башын иде.

— Гафу итегез, — диде. — Белмәдем...

Кунак аның каршында биегәеп, бүлмә ишеген каплап тора иде. Менә ул каты бармаклары белән Ленизаны иягеннән тотып алды да баласытып башын күтәртте:

— Ә ник гафу үтенәсең? Синең гаебең юк бит монда.

Лениза, ни дип җавап бирергә белмичә һәм аның карашына түзә алмыйча, керфекләрен аска төшерде.

Остаз аның ияген ычкындырды да, үз итеп шаяргандай:

— Кунакларны шушылай бусагадан борып җибәрәләрме әллә сездә? — диде.— Бу якларда якты чырай, такта чәй дигән әйтем бар, дип ишеткән идем. Кайда якты чырай? Кайда такта чәй?

Лениза аш бүлмәсенең ишеген ачты:

— Әлбәттә, әлбәттә,— диде.— Хәзер була... Узыгыз... Утырыгыз...

Күпмедер вакыттан соң алар кара-каршы чәй эчеп утыралар иде инде.

— Менә чия кайнатмасы, монысы җиләкнеке... — дип, аңа таба савытларны этте Лениза. — Сез, Остаз, кайсын яратасыз?

— Мин чәйне шикәр белән генә эчәм. Ә нигә Остаз дип дәшәсең миңа? Исемемне белмисеңмени әле?

— Беләм, китап тышлыгында язылган бит. Ләкин ничек дәшәргә? Остаз Герман дипме, әллә Герман Остазмы?

— Якын кешегә алай чачаклап-чуклап дәшмиләр ләбаса!

Һәм ул, Ленизаның аңа гажәпләнеп текәлгәнен күреп, җиңелчә көлеп җибәрде.

— Чит-ятны өйгә чакырмыйлар, шулай бит? Бәлки, сезнең монда башкачадыр?

— Сез бит... Эш белән... Рәсимә әйтүе буенча... — дип мыгырданды Лениза.

Герман, өстәл почмагы аша кулын сузып, аның беләгеннән тотып алды.

— Ташла, — диде. — Сүзләрдәмени хикмәт.

— Ә нәрсәдә?

— Бөтен хикмәт күзләрдә, мышонок! Син минем болай дигәнемә үпкәләмә. Коты алынган тычкан баласы кебек дер калтырап утырасың. Китапханәдә очрашуны оныттыңмыни? Миңа ничек караганыңны күрмәде дип беләсеңме әллә? Карашың белән чакырдың син мине. Үтенеп, өзелеп чакырдың. Димәк, мин сиңа чит түгел. Шулай булгач, Герман дип кенә дәш. Ә менә син үз исемеңне әйтмәдең бит әле. Әйдә танышыйк!

Аның мәгънәле елмаюы җанны өтте, беләгеннән саркыган кайнарлык тамырлар буйлап йөгерде.

— Лениза исемле мин...

Шулай диде ул, карашын кунагының ак күлмәк җиңеннән сузылып чыккан куе кара төкле беләгенә текәп. Шул төкләреннән үк бу ирдән үзенә бер гайрәт, кыргый бер көч саркый иде шикелле.

— Лениза, кадерле кунакларны чәй белән генә сыйлыйлармыни соң сездә?

— Гафу итегез... Тәмле әйбер пешерергә өлгермәдем...

— Мин башканы әйтәм... Запасыгыз юкмыни?

Лениза шунда гына аңлады. Урыныннан торып, бүлмәгә керде, шкафның ябык киштәсен ачты. Анда алай-болай кирәк булса дип, Мидхәт әзерләп куйган өч шешә тора иде: шампан шәрабы, алиготе һәм гап-гади аракы. Хуҗабикә күтәреп кергән шешәләрне күргәч, Герман:

— Йөзәр грамм булса, шул җитә, — диде. — Без сәрхушләр түгел, шулай бит?

«Йөз грамм» ул аракы иде, билгеле. Лениза үзенә алиготены да салмакчы иде, кунак:

— Анысы белән авыз пычратып тормыйк инде без, — диде. — Нәрсәдән ясалганы да билгесез.

Лениза кечерәк рюмкалар алып кергән иде, Герман зурракларын сорады:

— Йөз грамм сыярлык булсын инде.

Бәллүр бокалларны мөлдерәмә тутыргач:

— Әйдә, соңгы тапкыр бер татып кал, — диде. — Моннан ары тиз генә тәтемәс.

Һәм Ленизаның йөзендә сорау галәмәте күреп, аның түшендәге медальонга ишарәләде:

— Син чынлап торып безнең сафларга басарга карар кылгансың, шулай бит?

— Әйе, чынлап...

— Алай да безнең тәртипләрне белеп бетермисеңдер әле. «Нурсафлык» тарафдарларына эчү катгый тыела. Бездә — сухой закон!

«Ә соң син үзең?..»

Болай дип турыдан-туры сорарга Ленизаның кыюлыгы җитмәде, әмма Остаз аңлады. Сөйкемле балага карагандай яратып, сокланып күз сирпеде дә:

— Бу инде югарыдан шулай кушылганга түгел, ни чарадан бичара дигәндәй, аптыраганнан куелган кагыйдә. Безнең халык эчә башласа, чаманы белми, ямьсезләнә, тәртипсезләнә. Шуңа күрә генә сафлануның бер шарты итеп хәмердән тыелуны таләп итәбез. Ә без үзебез чаманы югалтмыйбыз, шулай бит? Аннары син безнең сафка кереп тә җитмәгән бит әле.

Шуннан соң Ленизаның зиһенен ураган томан тәмам куерып киткәндәй булды. Герман аңа җан турында, тән турында сөйләде. Адәм баласының җаны мәңгелек икән, тик ул бер тәннән икенчесенә күчеп кенә йөри. Остаз үзе моннан ике гасыр элек Һиндстанда далай-лама булган, йөз ел элек — Африкада кабилә башлыгы...

— Сез гади кеше булмагансыз инде, әлбәттә, — дип хуплады аның сүзләрен су урынына эчеп утырган Лениза.

— Җан беркайчан да юкка чыкмый, ә менә тән фани. Ул кешегә газапланыр өчен дә, ләззәт алыр өчен дә бирелгән. Газапларны киметеп, ләззәтләрнең тәмен татырга өйрәнү адәм баласының үзеннән тора.

Лениза монысы белән бәхәсләшергә омтылыш ясады:

— Газапларны сорап алмыйлар бит. Чир көтмәгәндә килә. Йә машина бәреп китә. Яисә... сөйгән ярың сиңа суына, башкага гашыйк була...

— Тәне җәрәхәтләнмәгән, һич булмаса, сыдырылмаган кеше дөньяда юктыр. Менә шул җәрәхәтләрне төрле кеше төрлечә кичерә. Бераүләр җиңел генә ярадан да аңын җуя, икенчеләр үз тәненә үзе хәнҗәр белән сызып җибәрә — эһ тә итми. Бар шундый кабиләләр, андагы кешеләр тәннәренә юан-юан энәләр кадыйлар, үз-үзләрен кан чәчрәп чыкканчы камчы белән яралар... Түзәләр бит, авыртудан егылып, бәргәләнеп ятмыйлар... Киресенчә, сызлануларны җиңү аларга үзенә бер рәхәтлек, ләззәт бирә... Адәм баласына газапларны кичерү бик кирәк. Ул аларга мохтаж! Ипинең чын тәмен ачлык күргән кеше генә белә, дөньяның ямен дә кайгы-хәсрәт кичергән, газапланган адәм баласы гына тоя.

Тагын ниләр сөйләнгәндер, соңыннан аларын Лениза хәтеренә төшерә алмады. Кайсыдыр мизгелдә Герман зәңгәрсу рәшә өртелгән күзләрен аңа төбәгән хәлдә урыныннан кузгалды, аның артына килеп басты да зур, йомшак, кайнар, шул ук вакытта авыр кулларын иңбашларына куйды. Аннары... кинәт... өермә китереп бәргәндәй булды.

Германның авыр, кайнар гәүдәсе Ленизаны идәнгә кысып беркетте, гайрәтле куллары тәнен урап алды. Иреннәре битенә ялкын бөркегәндәй итте, сулышны буды, өнне алды.

Ул гүяки Ленизаны тәмам эретеп бетереп, ахырынача үзенеке итте. Тәм-томга хирыс малай туңдырманы шулай суыра торгандыр. Юк, алай гына да түгел, чүлдә адашып, чамасыз сусаган кеше, ниһаять, кулына килеп эләккән тире капчык — турсыктан суны шулай чөмерәдер. Ул, һичнәрсә белән исәпләшмичә, ерткыч җанварларча табигате кушканны гына үтәде. Ленизаны бөтенләе белән «алды», үз тәненең бер өлешенә әверелдерде.

Табигать бу кешегә башкаларның җанын үзенә буйсындыру талантын гына түгел, аларның тәненә хуҗа булу сәләтен дә мул биргән иде.

Аш бүлмәсенең идәне мондый кыланмышлар өчен кысан иде, Ленизаның боты газ плитәсенең аскы киртәнә кат-кат бәрелде. Тик ул үзе моны сизмәде, сизәрлек хәлдә түгел иде.

Герман аннан аерылып чалкан ятканда, Ленизаның аңын да, санын да җыярлык хәле калмаган иде...

— Төн буе монда аунарга уйламыйсыңдыр бит?

Германның бу соравы аның башына бераздан гына барып иреште.

— Бүлмәдә җәелмәле диван бар анда...

— Соң, нишләп монда аунап ятабыз? Әйдә, шунда керик!

Шундук бүлмәгә кереп, диванны киңәйтте, җәелеп ятты да:

— Мыс-мыс итеп алсак, зыян итмәс бит, ә? — диде. — Йолдызлар моны хуплар, мөгаен...

— Моңарчы минем иремнән башка беркемне дә якын китергәнем юк иде, — диде Лениза.

— Син сизәсеңме өстән иңгән нурны? — дип, аның башын сыйпады Герман. — Ул безне хуплый! Без бергә булырга тиеш идек. Бу безгә күкләрдән иңгән әмер иде.

Һәм озак та үтми гырлый да башлады. Ленизаның исә күзенә йокы кермәде. Уйлар буталган, ә бәгырь сызлый иде. Нәрсә булды бу? Нишләп Мидхәт белән болай булганы юк?

Болай тәвәккәл, каты кылана алмый шул ул. Артык нәзакәтле, артык сизгер күңелле. Иң хисле мизгелләрдә дә бөтенләй онытылып китеп, үз хаҗәтен генә үти алмый, һаман парын кайгырта: аңа рәхәт булсын, ул да ләззәтләнсен дип тырыша. Ә мондый чакта башның эшләве тәннең кайнарлыгын

сүрелдерми калмый шул инде. Китаплардан укыган киңәшләрне кулланырга тырышу да мондый минутларда файда итү урынына зыян гына сала икән, бу бер дә гаҗәп түгел.

Мидхәт хатынын үзендә эретеп бетерә алмады, чын ир була белмәде. Димәк, арада өченче кешенең пәйда булуына башлыча ул гаепле!

Бу уй Ленизаны тынычландырып җибәргәндәй итте.

...Герман иртә уянды. Сикереп торды да киенә башлады.

— Бәлки, чәй куяргадыр?

— Нинди чәй? Дворниклар кузгалганчы чыгып китәргә кирәк.

Шунда Лениза аның нинди зур кеше икәнен исенә төшерде. Андыйлар качып-посып йөрми...

— Мин сине ялгызың килерсең дип уйламаган идем, — диде ул. Фикерен әйтеп бетермәде, Герман гадәттәгечә аның сүз төбен шундук аңлап алды.

— Ә-ә, син тән сакчыларын әйтәсеңме? Аларга бөтенесен белү кирәкмени? Әллә син шаһитлар булуын телисеңме?

Ул чыгып киткәч, Лениза ванна бүлмәсенә кереп душ астына басты. Андагы көзгегә карагач, йөрәге тагын сулкылдап куйды: ирен читләре кызарып җилсенгән, муенында, колак астында кара таплар күзгә ташлана. Ул, аларны үз күзләреннән яшерергә тырышкандай, юеш чәчләрен тарткалады. Сөртенгәндә, күзе ботларына төште: анда да таплар ярылып ята иде.

* * *

Мидхәт командировкадан көндез кайтып төште. Озын юллар үтеп, чит җирдә шактый болганганга һәм ят кешеләр белән күп аралашканга күрә, күңел шактый үзгәргән, үпкә-сапкалар кимегән иде. Ул завод кунакханәсенә кайтып төшү турында уйламады да. Туры эшенә барып, кәгазьләрен тапшырды. Лабораториягә шалтыраткан иде, аннан, Лениза төштән соң сорап китте, диделәр. «Рамилә авырмагандыр бит?» — «Юк-юк, борчылмагыз. Кызыгыз бакчада. Бу арада Ленизаның бик ашыгыч эшләре булды әле».

Мидхәт йөгерә-атлый бакчага китте. Көн салкынча, яңгыр сибәләп тора иде, ә ул ашыгудан һәм борчылудан эсселәп, тирләп чыкты.

Агачлык эчендәге ике катлы бина тып-тын, ишек төбендә дә, коридорда да һичкем очрамады. Көндезге йокы сәгате иде бу. Мидхәт сабыйларның рәт-рәт булып тезелеп торган нәни ботинкалары янына юеш сумкасын куйды, кроссовкаларын салып, оекбаштан тын гына атлап, өске катка күтәрелде. Бар җир чип-чиста, диварларга шаян аю, куян, керпе кебек җанвар сурәтләре ясалган. Аларны күргән саен, Мидхәтнең күңеле нечкәреп, иреннәренә ихтыярсыздан елмаю бәреп чыга. Биредәге балалар, әлбәттә, бик бәхетле булырга тиеш. Әмма нигә соң ак ишек артыннан ниндидер сызланган аваз килә? Кайсыдыр сабый елый түгелме? Әйе шул, елый. Тик иркә балаларга хас булганча акырып-бакырып, таләпчән тавыш белән кычкырмый, ишетелер-ишетелмәс кенә сулкылдап сыкрана. Мидхәт Рамиләнең тавышын таныды. Сакланып кына ишекне ачты да кечкенә караватында күзләрен уып утырган нәни кызчыкка кулларын сузды:

— Кызым, сабыем! Мин килдем, балакаем!

Ул Рамиләнең йомшак тәнен кочагына кысты, бала аның муенына җылы битен терәп сулкылдады. Мидхәт кечкенә элгечләрдән аның бишмәтен табып алды, аска төшеп, ботинкаларын кигезде. Шунда гына кәяндыр ак халат кигән тәрбияче хатын килеп чыкты.

— Сез нишләп уяттыгыз аны?

Мидхәт, иелгән килеш, аңа астан өскә гаепле кешедәй елмаеп карады.

— Исәнмесез! Гафу итегез. Әле генә командировкадан кайттым. Бик сагынган идем.

— Сагынырсыз да шул,— диде тәрбияче.— Атналар буе күрешми торасыз бит.

Иңендә сумка, кулында бала булганга, Мидхәт фатир ишеген ача алмый азапланды. Ахырда ишек үзе ачылып, каршыда Лениза урынына башына ак шарф ураган ят бер хатын пәйда булды.

— Кунак бармыни әле бездә? — диде бераз аптырашта калган Мидхәт.

— Ә сез кем буласыз соң? — дип, шактый кырыс итеп сорауга сорау белән җавап кайтарды хатын.

— Без бу квартирның хуҗалары булабыз, — диде Мидхәт һәм, аны читкә этәреп, эчкә атлады.

...һәм өен танымады. Гадәттә уртада тора торган өстәл кырыйга этелгән, аның өстенә ксерокс куелган. Диван җәелгән хәлендә булып, аңа пөхтә итеп кәгазь өемнәре тезелгән иде. Өстәгесеннән Мидхәткә чәче кыска итеп алынган йомры башлы, шакмак иякле, сәер карашлы адәм чекерәеп карап тора иде.

— Бу ни бу? — дип сорады соң дәрәҗәдә гажәпләнгән Мидхәт.

— Чакыру билетлары. Берсекөнгә Мәдәният сараенда Остаз белән очрашу булачак, — диде хатын.

— Кемнең остазы белән?

— Барыбызның да!

Хатынның арык чырае төксе, яшькелт күзләренең карашы чәнечкеле, тавышы шактый ачы иде. Хуҗаның көтмәгәндә кайтып кереп эшне бүлдергәнен яратмады, күрәсең.

— Кемнәр ул «барыгыз да»? Сез үзегез безгә кем буласыз соң әле?

— Мин... Ленизаның чакыруы буенча...

Мидхәт кәгазь кисәген алды. «Нур һәм сафлык» дигән зур баш астында сәер карашлы адәмнең сурәте һәм ваграк хәрефләр белән: «Әгәр дә сез югарыдан иңгән изге нурны йөрәгегез белән кабул итәргә теләсәгез, дөньяның саф-чиста булуына ирешәсегез килсә, Остаз белән очрашуга килегез!» — дип язылган иде.

— Менә нәрсә, апакай, — диде Мидхәт. — Сез боларны хәзер үк җыештырып алыгыз әле!

Һәм тәвәккәл хәрәкәт белән кәгазьләрне бер якка сыдырып, урын бушатып, Рамиләне утыртты.

— Кая куйыйм мин бу хәтле әйберне?!

— Сумкагызга тутырасызмы, капчык табасызмы — анысы сезнең эш. Тик озакка сузмагыз. Бушатыгыз өйне. Ксероксыгызны да алырга онытмагыз. Мин юлдан кайткан кеше. Ашыйсы-эчәсе, юынасы, ял итәсе бар. Кызганычка каршы, сезгә монда урын тәкъдим итә алмыйм.

— Нишләп мин алып китим аларны? Минеке генәме әллә? Хатының белән сөйләшерсең!

Апа алгы бүлмәдәге чөйдән аксыл плащын алды да пырлап чыгып китте.

Иң беренче эш итеп Мидхәт ксероксны электрдан өзеп алып ишек төбенә куйды, кәгазьләрне диван япмасына урап, аның өстенә ташлады. Һәм аш бүлмәсенә чыгып, балага ботка пешерергә кереште.

Кайнар су килми иде, плитәгә ике чәйнек куярга кирәк булды. Мидхәт Рамиләнең зәңгәр бизәкле фланель күлмәген сабынлап ышкыганда, түшендәге җөй учын тырнады. Нәрсә бу?! Әнисе булавка кадап, шул ачылганмы әллә? Юк, энә очы күренми... Мидхәт, дивар көзгесе астындагы киштәдән лезвие алып, юеш җөйне сүтәргә кереште. Аннан ак тимер кисәге килеп чыкты. Челтәрле ырмау эчендә бишпочмаклы йолдыз. Уртасына нәрсәдер язылган. «Нур һәм сафлык», — дип укыды Мидхәт. Башта инглизчә, аннары русча. Ник тегеп куйган моны Лениза баланың күлмәгенә?! Сихерме әллә? Шул гына җитмәгән иде!

Мидхәт кабаланып тагын өч күлмәкнең изүен капшады. Һәммәсеннән шул ук нәрсәне тартып чыгарды...

Тышкы ишек ачылганы ишетелде. Ул борылып карады. Һәм беренче мизгелдә хатынын танымады.

Башына, ияк астыннан ук урап, киң ак шарф бәйләгән бу хатын Ленизамы соң?

— Син кайттың дамыни? — диде ул, пошаманга төшкәндәй.— Мин сине көтми идем әле...

— Көтмәгәнсең шул, күренеп тора, — диде Мидхәт. — Ни булды сиңа?

Лениза гомергә башына яулык-шарф бәйләмәде, килешми, ди иде. Чыннан да килешми икән... Йөзен бозып, үз яшеннән өлкәнрәк итеп күрсәтә. Ә бәлки, бу күз карашында чагылган, чыраена бәреп чыккан каушау-курку галәмәтеннән шулайдыр?

— Миңамы? Берни булмады, — дигән була үзе.

— Кил әле монда!

Мидхәт Ленизаның курткасын салып элгәнне дә көтмичә, җилтерәтеп бүлмәгә тартып кертте һәм идәндәге өемгә аяк очы белән типте.

— Нәрсә бу? Кем иде ул бездә?

— Рәсимәне әйтәсеңме? Чакыру билетлары баса иде... Ул әзерләп куя, без таратабыз...

— Син шуларны таратып йөрдеңмени әле?

— Анда без күп...

Мидхәт, мие түнгәнне басар өчен, ике учы белән чигәләренә тотынган иде, уң йодрыгындагы сәер тимер кисәге исенә төште.

— Ә бусы ни? Ник тектең аны Рамиләнең күлмәкләренә?!

Лениза, ниһаять, үзен кулга алды булса кирәк, алгы бүлмәгә борылып плащын салып элде, шарфын исә муеным ачылмадымы икән дип тикшергәндәй сыйпаштырып кына куйды.

— Хәзер барысын да сөйлим... Әйдә, утырыйк әле.

Әти-әнисенең әйткәләшүенә күптән күнегеп беткән Рамилә «түү-түү» дип уенчык машинасын тәгәрәтеп юана иде. Мидхәт, урындыкка утырып, аны тез арасына кыстырды. Лениза, диванның бер башына утырып, сынын турайтты.

— Әйе, син югында кайбер...— Лениза сүз эзләп торды да,— вакыйгалар булды... — дип җөмләсен тәмамлады һәм тынып калды. Мидхәт исә сорау бирмәде, аны ашыктырмады.

— Аня мине бик яхшы кешеләр белән таныштырды,— диде, ниһаять, Лениза.

— Кайсы Аня? Нинди яхшы кешеләр?

— Бакча күршесе. Без аның белән китапханәгә очрашуга бардык. Анда бик кызыклы кешеләр килгән иде. Һәммәсе югары белемле, бик мәгълүматлы... Кызганыч, син булмадың... Без монда үз кабыгыбызга бикләнеп яшибез, дөньяда ни барын белмибез...

— Ә нәрсә бар дөньяда?

— Мин кыскача гына аңлата алмам. Менә мондагы журналларда, китапта язылган...

Лениза, урыныннан кузгалып, шкаф киштәсеннән китап-журналлар алды.

Мидхәт таркау гына хәрәкәт белән ялтыравык тышлы китапны ачып, химикатлардан тиресе юкарган ак бармаклары белән актаргалады.

— Әллә берәр яңа секта оешканмы? — дип сорады гаҗәпләнеп.

— Нинди секта? Алар зур галимнәр! Эзотериклар! Бөтен галәмне юктан бар иткән Илаһи Кодрәт иясе белән элемтәгә керәләр.

— Хат алышалармы, әллә Интернет аша эш итәләрме? — дип, талчыккан тавыш белән сорады Мидхәт.

— Син көләргә ашыкма, укып кара. Без монда, наданлыгыбыз аркасында бөтенләй артта калганбыз. Син дә шартлаткычтан башканы белмисең...

— Әйдәле, кызым, бергәләп карыйк әле, күр нинди матур кәртинкәләр ясалган монда, — дип, журнал тышына бармагы белән төртте Мидхәт. — Карале, нинди матур кыз аккошны кочаклап алган... Синең шулай итәсең килмиме?.. Күр, ул кызның әтисе белән әнисе нинди матур итеп өстәл янында кунаклары белән бергәләшеп чөкердәшеп чәй эчеп утыралар...

Мидхәтнең болай сөйләнүләре Рамиләдән бигрәк Ленизаның күңелен нечкәртеп җибәрде.

— Беләсеңме, минем күз алларым яктырып киткәндәй булды. Сиңа Остаз белән, әлбәттә, очрашырга кирәк. Ул монда чакта...

— Килгән кешемени?..

— Ул бирегә изге миссия белән килгән.

— Каян?

— Мин аның адресын сорамадым.

— Ә сорарга кирәк иде. Кайда яши икән?

— Син һәрнәрсәне җиргә бастырасың. Ә монда илаһилык турында сүз бара.

— Илаһимы, түгелме, һәркемнең адресы бар. Хәтта Ходай Тәгаләнең дә. Җиде кат күк өстендә, ди, әнә безнең әни.

— Илаһи Зат хәзерге вакытта Сириус йолдызында икән. Эзотериклар сигналларны шуннан алалар.

Мидхәт күзләрен зур ачып аңа текәлде.

— Шулаймы-ыни? Офисы шунда, димәк, ә? Ә эзотерик дигәнең, остаз дисеңме әле?

Лениза, аның сүзен раслаганын белдереп, ияген какты.

— Ул адәм психиатрда учетта тормый микән? Тагын очратсаң, сора әле син аннан!

Ленизаның чырае кызарып чыкты:

— Син бернәрсәгә дә, беркемгә дә ышанмыйсың! — диде ул, тавышын күтәреп. — Синең өчен бөтенесе әшәке! Шул гадәтең аркасында шушы көнгә төштек инде...

Әмма Мидхәтнең тавышны зурга җибәрәсе килми иде.

— Тукта, кызма,— диде ул.— Мин бит начарлык белән түгел, шаярып кына әйттем. Ялгыш ычкынды, гафу ит.

— Син юри кыланасың, конечно! Минем белән санашмыйсың! Әйткән сүземә төкереп тә бирмисең! Болай яшәргә невозможно!

Шулай дип кычкырды Лениза һәм шушы сүзләрдән соң кинәт үзенә көч кергәнен тойды. Әйе-әйе, моннан соң ул Мидхәт белән яшәмәячәк. Шуның белән һәммәсе хәл ителә дә куя. Шарфны чишеп, муендагы тапларны, чалбарны салып ботлардагысын күрсәтәсе дә, аны кочаклап, башканы күз алдына китереп ятасы да булмаячак.

— Бар әле, кызым, курчагың белән уйна, — дип, Рамиләне янә идәнгә җибәрде Мидхәт.

— Бүгеннән мин синең хатының түгел! — дип, үз-үзен ярсытып кычкырынуында булды Лениза. — Кстати, син әллә кайчаннан минеке түгел инде. Бар, әнә миннән яхшыраклар янына кит!

Мидхәт, бөтен сабырлыгын җыеп, тыныч булырга тырышып:

— Туктале, Лениза, ипләп кенә сөйләшик әле, — диде.— Ул хәтле ярсырга сәбәп юк лабаса. Ну, китапханәгә баргансың, кемнәр беләндер сөйләшкәнсең. Анда сиңа ирең белән аерылышырга кушмаганнардыр бит?

— Китапханәнең ни катышы бар монда? Мин әллә кайчан синнән аерылырга карар кылдым инде. Әйтми генә йөрдем!

Мидхәтнең болай да кояшта янган йөзе кызарудан карасуланып китте, борын канатлары киерелеп, алар тирәсендә тир тамчылары бәреп чыкты, куллары салынып төште.

— Димәк, бу синең күптәннән уйланган ныклы карарың? — дип сорады ул, күзләрен зур ачып.

— Окончательный карарым.

— Обжалованию не подлежит дисең инде алайса...

— Юк! Кискән икмәк кире ябышмый!

Бу соңгы сүзләр Мидхәтнең башына сизмәстән килеп төшкән күсәк кебек тәэсир итте: аның сизгерләнгән зиһене аларда куркыныч мәгънә барын тоеп алды.

— Ах, шула-аймыни? — диде Мидхәт, өмете сүнгән тавыш белән. — Син мине үзеңнән кисеп ташладыңмыни инде?

— Думай как хочешь! Теләсә ничек аңла!

Колакларны чыңлатырлык киеренке тынлык урнашты. Мидхәтнең карашы машинасын «түү» итеп идәндә үрмәләп йөргән кызчыкка төбәлгән иде.

— Аерылышканда да сөйләшми генә булмый, — диде ул, мөмкин кадәр тынычлыгын сакларга тырышып. — Минем белән яшисең килми икән, мәҗбүр итә алмыйм. Тик менә уртак милекне ничек бүлешербез икән соң?

— Нәрсәне бүлешергә? Әз генә горурлыгы булган ир мондый очракта чыгып кына китә.

— Мин риза, — диде Мидхәт, аның йөзенә туры карап.— Квартиры да, башкасы да сиңа булсын... Тик син...

— Нәрсә?

— Рамиләне миңа бир. Без чыгып китәбез... Ә син теләгән чагыңда аның белән очрашырсың... Курыкма, начар яшәтмәм, син мине беләсең...

— Да ты что?! Нинди ана баласын үзеннән читкә бирер җибәрсен? Кем кулына? Синең сөяркәләреңәме? Аннары минем хакта, әшәке хатын ул, баласын ташлады, дип дөнья сасытып сөйләп йөрсеннәрме әллә?

Мидхәт башын иеп тыңлады, чөнки ни дә булса әйтүдән файда юклыгын аңлый иде.

— Әгәр балаңа тыныч булсын дисәң, үзең чыгып кит! Менә шул чакта булырсың кеше! Балакаем, газизем! Ата була белмәде сиңа бу кеше, безне бәхетсез итәргә генә йөри ул! — дип, Рамиләне күтәреп алды Лениза.

Мидхәт командировкадан кайткач бушатып өлгермәгән сумкасын алды да, кабаланып кроссовкаларын киде, элгечтән курткасын йолкып, ишектән чыгып китте.

Нишләргә инде хәзер? Башыңны ташка бәреп ватар идең дә, бала кала бит! Мидхәтнең иң зур бәхете, тормышының кояшы булган Рамилә кала!

Ут капкан өйдән чыгып котылып буладыр, әмма явыз хатын ургыткан уттан котылу юк икән. Чөнки ялкын телләре эченә үрләп, бәгыреңне ялмый. Су сибеп кенә сүндерә торган түгел!

Ул, автобуска утырып, бакчага китте. Анда аны кара көйгән, салкын яңгыр астында шәбәргән түтәлләр, сулган гөлләр яшь түгеп каршы алдылар.

* * *

Лениза баш-аягы белән Остазның кичәсен үткәрү эшенә чумды. Төннәрен ксерокста листовкалар баса, эштән соң, баланы арбага утыртып, урамнар буйлап йөри: мөмкин булган һәр җиргә листовкалар ябыштыра, очраганнарга журналлар өләшә, тыңлаганнарга «Нур һәм сафлык» турында, Остазның илаһи сәләте турында сөйли иде.

Аның күңел түрендә Сириус йолдызындагы нур тәхетендә утырган Илаһи Зат нәкъ менә Герман төсле булып җанлана, нәкъ аның кебек өздереп тә, баласытып та, чак кына үчекләгәндәй итеп тә карый, абыйларча йомшак та, нык та итеп эндәшә иде. Һәм кинәт һуштан яздырып, ут өермәсендә бөтереп ала да ташлы тауга китереп органдай итә.

...Ул кичне искә төшергән саен, Ленизаның бөтен тәне калтыранып куя, андый минутларда ул үзүзләрен кан чыкканчы кыйнаудан ләззәт алган, безгә кыргый тоелган дин әһелләренең кичерешләрен аңлаган кебек була.

Бу Илаһи Зат белән аны күзгә күренми, әмма өзеп тә булмый торган җепләр бәйли иде шикелле. Табигый ки, Ленизаның аңа лаек буласы, кылган эшләре белән мактанасы килә иде.

Мондый изге эшләр арасында бала мәшәкатьләре артык борчу булып тоела иде. Шулай бер кичне, Рамиләне бакчадан алып кайткач, өйдә рәтле ризык юклыгы беленде. Берничә урынга барып, игъланнар эләсе бар, шунда кибеткә керергә булыр иде булуын. Әмма баланы хәзер ашатырга кирәк. Лениза кабаланып бәрәңге пешереп изде, куе итеп кесәл ясады. Кызын ашыгып ашатты. Аннары чыгып китәм дигәндә генә, кызчыкның бите, бөтен тәне бурлаттай кызарып чыкканын күреп туктап калды. Гөнаһ шомлыгына каршы, нәкъ шул минутта ишек кыңгыравы зыңгылдады. Лениза ишекнең чылбырын эләктереп чак кына ачты. Аның каршысында Мидхәт басып тора иде.

— Мин сиңа, килеп йөрмә, дип әйтмәдеммени әле? — диде Лениза.

Ни могҗиза беләндер, Мидхәт эчтәрәк басып торган кызын күреп алды:

— Ни булды Рамиләгә?

— Юк, болай гына, шаярган иде...

— Шаярганнан бала шулай була димени?! Ач ишекне! Баламны күрергә минем закон буенча хакым бар!

Лениза, болай да ачуы ташыган Мидхәтне тагын да ярсыту хәерле булмасын аңлап, чылбырны ычкындырды. Мидхәт ачынып елаган кызчыкны күтәреп алды да тышка ташланды, аның артыннан Лениза чабып чыкты. Алар шулай йөгерешеп поликлиникага барып керделәр.

Дежур табиб — өлкән яшьтәге таза гәүдәле хатын — бер генә күз салды да:

— Нәрсә ашаттыгыз? — дип сорады. — Аннары, башын чайкап, Ленизага шелтә белән карады: — Күпме өйрәтәбез без сезне, күпме талкыйбыз, балаларның ризыгына игътибарлы булыгыз, дип. Тоташ углеводлар белән голкындыргансыз бит сабыйны. Сөт эчерегез, тәмле боткалар ашатыгыз! Яшелчә, җиләк-җимеш белән күбрәк сыйлагыз.

— Доктор, ә хәзер нишләтергә? Берәр дару...

Табибә, Рамиләнең алтынсу ефәк төсле чәчен сыйпап, бармакларын чигәсендә озаграк тотып алды:

— Температурасы юк, кәефе әйбәт, нәрсәгә аңа дару... Әйтәм бит, сөт эчсен. Әгәр мондый хәл кабатлана торган булса, үзегезнең участок табибына барырсыз.

Аннары үткен күзләрен өлкәннәргә төбәде дә:

— Әти кеше дә битараф булмасын, — диде. — Баланы сау-сәламәт үстерү җиңел түгел, икәүләшеп тырышсаң да бик таманга килә.

Лениза да, Мидхәт тә гаепле кешеләрдәй башларын иделәр. Табиб алар арасындагы өзелгән җепләрнең бер нечкәсен генә булса да ялгап куярга омтылыш ясагандай иткән иде. Уртак борчылу бераз гына булса да күңелләрне якынайтырга тиеш иде шикелле.

Алар өйгә кадәр дәшми-тынмый гына кайттылар. Тышкы ишек төбендә Лениза Мидхәт кулыннан баланы тартып алды да:

— Сау бул, — диде.

— Нишләп... алай?

Соңгы көннәрдә Ленизаның башыннан үткән хәлләрнең иң мөһимен белмәгәнгә күрә, Мидхәт югалып калган, ул хатынын аңлаудан гаҗиз иде.

— Слушай, әйттем ич инде мин сиңа! Ничә кат кабатларга тагын!

Бу сүзләрне Лениза шундый ныклык, ышаныч белән әйтте ки, Мидхәтнең соңгы өметен дә балта белән чапкандай өзде дә куйды.

...Иртәгесен кич кызын алырга килгән Ленизаны тәрбияче гаҗәпләнеп каршы алды:

— Рамиләне этисе килеп алып китте бит!

— Кайчан?

— Көндез үк инде. Поликлиникага барасыбыз бар, дип әйтте.

Өйдә кеше юк иде. Лениза заводның кунакханәсенә китте. Анда кизү торучы хатын:

— Халиковмы? Командировкага китте бит ул, — диде.

— Ә бала?

— Нинди бала?

— Кызыбызны бакчадан алган бит ул.

— Анысын әйтә алмыйм. Көндез үк чыгып китте, кулында сумка гына иде.

Кая киткән? Ник? Әмма завод идарәсендә эш сәгате беткән, беркемнән бернәрсә белеп булмый иде.

Шунда кинәт Ленизаның исенә төште: теге көнне, кичен баланың әти-әнисе килмәгәч, тәрбияче Рәйсәләргә шалтыраткан, Рамиләне ул барып алган иде бит!

Ә аларның ишеге артыннан гармун тавышы, аңа кушылып җыр ишетелде:

Аерылмагыз, аерылмагыз, булса да сәбәпләре...

Парлашып сузалар, кинәнеп, ләззәтләнеп! Гомергә бер дә үпкәләшмәгәннәр диярсең!

Төймәгә икенче тапкыр баскач кына кыңгырауны ишеттеләр, җыр туктады. Ишекне спорт костюмы кигән Рәмис ачты.

— Син белмисеңме, Мидхәт кая китте икән? — дип сорады Лениза, сәлам бирергә дә онытып.

— Исәнме, Лениза! Киткәнмени? Мин ишетмәгән идем.

— Командировкага киткән бит ул. Баланы сездә калдырмады микән дигән идем...

— Бакчада юкмыни?

— Юк шул, алып китте, диләр.

— Командировкага киттем, дип юри генә әйткәндер, бәлки? Монда берәр танышларындадыр?

«Баланы чыннан да сөяркәсенә алып киткәнме әллә?!» дигән уй Ленизаның миен яшен кебек көйдереп узды. Ул, хәле китеп, ишек яңагына сөялде.

Эчтән үрелеп карап торган Рәйсә, иренең сүзенә каршы төшеп:

— Алай димә әле син, яхшым, — диде. — Туганнарында дисәң, бер хәл иде.

— Монда туганнарыбыз юк бит безнең, — диде Лениза.

— Әйтми-нитми нишләп алай итеп йөри соң ул? Үпкәләткән идеңме әллә?

— Без аерылышырга булдык. Баланы үзенә аласы килә аның...

— Шуңа ук барып җиттегезмени инде? — диде Ленизаны гаепләгән сыман итеп Рәмис.

— Эшне алай зурга җибәрмәскә кирәк иде, — дип, аның сүзен җөпләде хатыны. — Кер әле син, чәй эчик. Атасы кулындагы бала өчен ул хәтле бәргәләнергә кирәкмәс.

Ләкин Ленизаның бәхетле пар янында бәхетсез булып утырасы килми иде.

— Юк, эчәсем килми,— диде. Аннары, үзалдына сөйләнгәндәй:— Аерылган ирләр балаларын менә шулай урлыйлар икән,— дип куйды да чыгарга дип ишекне ачты.

— Туктале, андый зур гаеп ташларга ашыкма әле син! — диде Рәмис.

— Ирләр алар әйләнә-тулгана да барыбер үз йортына кайта, — дип, янә иренең сүзен куәтләде Рәйсә.

Тик Лениза аларны тыңламый иде инде. Көн кебек ачык: Мидхәт Рамиләне урлап качкан... Әгәр еракка китеп, бөтенләй кайтмаса?!

Ул өй ишеген ачканда, телефон зыңгылдый башлады. Мидхәт! Лениза, сулышына кабып, трубканы алды.

— Хәерле кичләр! Син кайларда йөрисең, мышонок? — диде Остазның гамьсез, шаян тавышы.

— Хәерле... кич... Чыккан гына идем...

— Бүтән чыгасың юкмы? Югыйсә минем үрчетеп аласы кәгазьләр бар иде. Әгәр син каршы килмәсәң... Өйдә үзең генә бит син...

«Каян беләсең?» Ләкин моны сорап торуның кирәге юк иде. Ире өйдә булган хатын сөяркәсе белән башкача сөйләшә. Ә бәлки бөтенләй сөйләшеп тормый...

Мидхәт тавышын ишетергә өметләнгән Лениза башта ныкаушаган иде, берничә мизгелдән җиңеләеп киткәндә й булды. Бу шалтырату шулхәтле вакытлы иде! Әллә соң Герман ерактан ук Ленизаның хәлен тоеп тора микән? Ул килер, юатыр, акыллы киңәшен бирер. Ә бәлки әле Мидхәт белән баланың кайда икәнлеген дә беләдер?!

Плиссе итәген киеп, башына ак шарф ураганда, бу юлы инде зур бүлмәнең уртасында ашыгып табын әзерләгәндә, Ленизаның халәте бөтенләй үзгәргән иде.

...Ксероксны кузгатып тормадылар, Остазның кәгазь үрчетәм диюе сылтау гына булган, билгеле. Табынга кайнар кибет пилмәне, казылык, сыр куелды, узган юлы ярты лаш эчелми калган аракы шешәсе менеп кунаклады. Бераз йотып куюга, Лениза сабырсызланып бәгырендәге сызлавыкны тиште:

— Ирем командировкага киткән, кызыбызны үзе белән алып киткән, — диде.

Кайнар пилмәнне авызында әвәләгән Германның яралы сул кашы күтәрелеп куйды.

— Беренче ишетәм, — диде ул, бераз көттереп.

— Нәрсәне?

— Бала күтәреп командировкага йөргән ирне. Ник син аны алай интектерәсең?

— Минме?! — Лениза җавап табудан гажиз калган иде. — Ул үзе... Кызыбызны урлап киткән ул!

— Урлаган? Үз баласынмы?

— Әйе шул, урлаган. Миннән урлаган...

— Ничә яшьтә соң ул бала?

— Өченче белән бара.

— Урлаган, дисең. Кулдан төшмәгән сабыйны... Тапкан икән... Тоже мне киднайпер! Селәгәй... Андый ир белән нинди хатын торсын?.. Аерылганыгызга күптәнме инде?

Лениза аның йөзенә текәлде.

— Син... килгәч... — диде.

Герман, көлеп, башын чайкап куйды.

— Ну ты даешь! — диде. — Миңа хәтле син ир күрмичә күпме яшәгән идең инде, ә?

— Анысы бит аның болай гына... Без үпкәләшкән генә идек...

— Ә нигә соң син миңа шулай зарыгып, чакырып карадың?

— Ул бит... Ул бит... — Лениза кулын йөрәк турына куйды. — Йөрәкнең ануына түзә алмаганнан... Башымны кая куярга белмәгән чак иде.

— Ирең кем әле синең?

— Улмы? Инженер-химик. Бик талантлы уйлап табучы.

— Ә-ә-ә, күкәй башлымыни-и... Ни чыкса, шул күкәй башлардан чыга инде...

Остазның тавышында, болай да юка иреннәрен кысып куюында күкәй башлыларга, ягъни галимнәргә, уйлап табучыларга кимсетүле мөнәсәбәт чагылды.

— Ул Норвегия галимнәре белән ярышырлык ачышлар ясады! — диде Лениза.

— Андыйлар үзара ярышырга оста, бер-берсен уздырмас өчен җан тырмашалар, — диде Остаз, мәгънәле көлемсерәп. — Ә менә тормышны алып бару мәсьәләләрендә ифрат беркатлы шул алар. Күр инде, үз баласын үзе урлап йөри мескен. Монда ничек котылырга белмисең, ә аның нужасы көчәйгән.

— Ничек син алай дисең? Үзең дә шундый бит — күкәй башлы! — диде Лениза. — Миңа биргән китабыңны гына укысаң да, нинди зур галим икәнлегең ярылып ята.

— Аны мин үзем язган дип уйладыңмы әллә син?

— Герман Светлый син түгелмени?

— Ә син институтта укыганда рефератларыңны, курс эшләрен үзең яздыңмыни? Диплом эше өстендә дә ми черетеп утырдыңмы?

Әйе, бу юлы Лениза Остазның зәңгәр пәрдә белән капланган күзләрендәге мәгънәне бик ачык күрде — аларда мыскыллау чагыла иде. Бу заманда курс эшләрен, дипломын үз кулы белән язган кешеләргә карата мәсхәрәләү ярылып ята иде аларда!

— Урамнарда багана саен, игълан тактасы саен, «курс эше, диплом эше, теләсә нинди диссертация язып бирәбез», дигән язуларны укыганың юкмы әллә? Кемнәр ябыштырган аны? Синең ирең төсле күкәй башлар. Йомры башларга ялланырга атлыгып торалар, аларның учыннан җим чүплиләр! Сезгә анда, үзегезнең институтта, иҗтимагый фәннәрне, кешелекнең тарихын укытканнардыр бит? Кем башлаган Икенче бөтендөнья сугышын? Гитлер. Ефрейтор. Генераллар, күкәй башлы галимнәр аның каршында тетрәп торган. Кем белән сугышкан ул? Яшь чагында семинариядән куып чыгарылган Сталин белән. Ә ул Сталин Җир шарының алтыдан берен йодрыгында тоткан!

Герман кулын йодрыклады, ак җиңеннән беләге сузылып чыкты. Аның тыгыз тәнендә беләзеге турысыннан ук куе кара төкләр тырпайган иде. Ерткыч җәнлекнеке кебек.

— Җир шары Кояш тирәли әйләнеп торганда, күкәй башлы бәндәләр менә шушындый куллардан туеначак! — диде ул, ниндидер бер тантана белән. — Әллә син мине шундыйлардан бер китап яздырып алырлык та хәле юк дип уйлыйсыңмы? Ул чакта минем хакта бик түбән фикердә булып чыгасың түгелме?

— Киресенчә! — диде Лениза. — Шундый зур хезмәт язган дип сокланган идем.

— Син теологиядән бераз хәбәрдардыр бит? Диннәрнең тарихын аз-маз булса да беләсеңдер?

Лениза башын иде:

— Аны бит мәктәптә дә, институтта да укытмыйлар...

— Пәйгамбәрләр китапларны үз куллары белән язмыйлар, мышонок! Алар югарыдан килеп ирешкәннәрне адәми затларга телдән сөйләп бирә. Аларның сөйләгәннәрен тарафдарлары кәгазьгә төшереп куя. Без дә шулай иттек. Мин ниләр язарга кирәклеген бик яхшылап аңлаттым, алар шуларны, фәнни яктан нигезләп, компьютерга төшереп бирделәр. — Аның йөзе кырысланып китте: — Рәхмәт әйтсеннәр! — диде.

— Изге сүзләрне теркәүне ышанып тапшырган өченме?

— Мин аларны бомба ясау, агулы матдәләр эшләп чыгару, иң камил технологияләрне файдаланып, кешеләр артыннан шымчылык итү кебек начар, пычрак гамәлләр кылу өчен ялламадым. Изгелеккә, сафлыкка хезмәт иттердем!

Остазның сөйләгәннәре нигезле, ышандырырлык булып тоелды. Ленизаның күңеле тынычланып китте. Чыннан да, нинди көчле, бөек кеше утыра бит аның каршында!

— Ә мин менә нишләргә белми аптырыйм. Баланы ничек үземә кайтарып алыйм икән?

— Ә нәрсәгә? Бушап торырсың бераз.

Ленизаның тәмам коелып төшкәнен күреп, Герман шундук сүзен төзәтергә ашыкты:

— Алай бик борчыласың икән, милиция аша эзләт.

— Ничек?

— Үзең уйлап кара, кая илтә ул баланы?

Герман бераз көтеп торды. Җавап булмагач, үзе әйтте:

— Әбисе белән бабасына, билгеле. Адресларын беләсеңдер бит? Милициягә бар да әйт. Шуннан барып алып кайтсыннар.

Чыннан да, бик гади, бик тә аңлаешлы иде бит бу! Моңарчы ничек Ленизаның үз башына килмәгән. Ул, җиңеләеп, елмаеп җибәрде.

— Менә син шундый чакта сөйкемле, мышонок, — диде дә Герман, аның иягеннән тотып башын күтәрде, каты иреннәре белән авызына беректе. Һәм мендәр урынына диванга ташлады да өстенә капланды. Лениза сыкранды, ыңгырашты. Әллә сызланудан, әллә ләззәттән — үзе дә аңламады...

* * *

Кинәт өйдә бөтен утлар сүнде. Бик каты күк күкрәп, йорт селкенеп куйгандай булды. Ишегалдындагы машиналарның караклардан саклау өчен куелган сиреналары, колакны ярып, төрле тавышларга чинарга кереште. Кайдадыр этләр өрде.

— Алла-Ходаем, бу ни хәл бу? — диде Әлифә. — Сентябрь бит инде, бу нинди күк күкрәү тагын? Электрны өзде бит! Бездә генә микән?

Ул пәрдәне шудырды да, тәрәзәне ачып, караңгы урамга карады. Көчле җилдән бөгелеп бәргәләнгән биек каен-тирәкләрнең шавы күңелне шомландырды, эре тамчылар биткә бәрде. Каршы йортларда да, ишегалдында да утлар сүнгән иде.

— Бөтен районны электрсыз калдырган бу, — диде Әлифә һәм ашыгып тәрәзәне япты. — Шәмнәрне кабызмый булмас... Әнисә, шәмнәр кая икән безнең? Табып бир әле.

— Белмим... — диде битараф, хәлсез тавыш.

— Ни булды соң сиңа бүген? Иртәдән бирле үзеңә урын тапмыйсың. Әллә яшеннән куркасыңмы?

— Аннан түгел... Эчем поша.

— Яшь кешенең эче поша димени?! Әйдә, шәмнәрне кабызыйк та ашап алыйк. Аш әзердер анда.

Әлифә кармаланып шкафның аскы киштәсеннән шәмнәрне табып алды да, кечкенә банкаларга утыртып, өчне берьюлы кабызып җибәрде.

— Әйдә, кил әле, — диде. — Ашагач кәеф яхшыра ул. Хәзер бүләм.

Әнисә өстәл янына килеп утырды, әмма кашыгын кулына алмады. Шәмнең тотрыксыз саран яктысында аның күзләре җемелди, карашы ишек тарафына юнәлгән, гүяки ул кемнедер көтә иде.

— Аша инде, нишләп утырасың?

Нәкъ шул минутта шакыган тавыш ишетелде. Ишеккә килгән кеше гадәттә кыңгырауны зыңгылдата, шуңа күнеккәнгә Әлифә башта шакуның каян икәнен аңламады. Әнисә исә сикереп торды да барып ишекне ачып җибәрде.

— Кыңгыравыгыз шалтырамый, — диде таныш ир-ат тавышы. Аңа кушылып яшь баланың сыкраныпмы, сызланыпмы нәрсәдер лепелдәгәне ишетелде. Әлифә, үз колакларына үзе ышанмыйча, шәмнәрне күтәреп аш бүлмәсеннән чыкты.

Ишек катында Мидхәт басып тора иде. Костюмнан гына, тәмам шәбәреп беткән, чөнки курткасын салып, кулындагы баланы төргән. Иңендә юл сумкасы.

— Исәнмесез! Көтмәгән идегезме?

— Исәнме-саумы! Хуш киләсез!

Ул арада Әнисә баланы алып идәнгә бастырган, бишмәтен, башлыгын салдырып, юеш чәчен, битен сөрткәли иде инде. Исәнләштеме-юкмы, анысын Әлифә ишетми калды, кунакларның бу рәвешле һич көтмәгәндә килеп керүе кызны бөтенләй гажәпләндермәде дә шикелле. Әлифә исә әле һаман аңын җыя алмый, шәмне күтәреп, ишектән тагын кемнең дә булса кергәнен көтә иде.

— Нишләп хәбәр итмәдегез? Әнисе кая? — дип сорады ул.

— Әни кеше өйдә калды.

— Әллә икәү генә килдегез?

— Икәү генә шул.

Ул арада гөлт итеп утлар кабынды, яктыда Мидхәтнең бик кыенсынып, хәтта оялып басып торганы күренде. Аның бөтен кыяфәтендә ялвару ярылып ята иде.

Әнисә исә, баланы диванга утыртып, аяк киемнәрен салдырды да чәйнекне утка куйды, шабырдатып ваннага су җибәрде.

— Коры киемнәре бармы? — дип сорады.

— Запас кием алмаган идек шул, — диде Мидхәт. — Кирәк-яракны иртәгә кибеттән алырбыз инде, әйе бит, кызым?!

Кызчык дәшмәде, ул ятсыныпмы, куркыныпмы хәрәкәтсез утыра иде.

— Хәзер ашап алырбыз да, юындырырмын, — диде Әнисә.— Сөлгегә төренеп ятып торыр. Ул арада киемнәрен юып үтүкләп бирермен.

— Үзем эшлим мин анысын. Бала юындыруның рәтен белмисеңдер әле син,— диде Мидхәт.

— Белә, белмәгән кая! Каникул вакытында детсад дачасында санитарка булып эшләде бит ул, — диде Әлифә, горурлангандай.

Ни гажәпләнгән булса да, ул кызның кинәт үзгәргәнен, ачылып, дәртләнеп киткәнен күрми калмаган иде.

Бит-кулларын юып, аш янына утыргач, Мидхәт бу гажәп хәлне аңлатырга тиеш булды, билгеле. Әлифә иң беренче итеп:

— Нигә соңгы вакытта бер хат та язмадың? — дип сорады. — Әнисә әйтә, язам, ди, ә синнән хәбәр юк. Хатының авырып киттеме әллә?

— Юк, сау-сәламәт.

— Аллага шөкер, — диде җиңеләеп киткәндәй Әлифә.— Бу сабыйны кая алып барасың соң? Әниләрегезгәме?

— Юк... Аларга кайтырга ярамас... Аннан безне тиз табарлар, шулай бит, кызым? — Һәм хуҗаларның мондый хикмәтне аңламаудан гажиз булганнарын күреп: — Без аерылыштык, — диде.

Бу сүзләрне әйткәндә, Әнисәнең күзләрендә сөенеч чалымнары кабынырга тиеш кебек иде, әмма ул, киресенчә, җитдиләнеп, ямансуланып киткәндәй булды.

— Нишләп алай? Начар яшәгәнегез ишетелми иде бит? Хатларыңда да андый сүз булмады, — диде Әлифә.

— Шулай килеп чыкты. Аерым яшибез. Баланы мин үземә алырга булдым.

— Анасы бирдемени? — Бусы инде Әлифәнең башына берничек тә сыя алмый иде.

— Юк, ул бирмәскә тырыша. Ләкин Рамиләгә минем белән яшәү яхшырак булачак.

Әлифәнең ияге салынып төште.

— Эчүгә сабыштымы әллә? Азып-тузып йөриме? Бүтән кеше белән бәйләндеме?

— Юк, эчми дә, азмый да, йөрми дә... Просто характерларыбыз килешмәде.

— Тәртипле анадан мондый бәләкәй баланы тартып алалар димени! — дип, тавышын күтәрә төшеп әрнеп әйтте Әлифә. — Бигрәк тә кыз баланы. Күр дә тор, синнән алып, анасына бирәчәкләр аны. Юкка болай интегеп йөрисең. Аның дәгъвасы, шау-шуы... Телевизордан күрсәткәлиләр бит инде андый хәлләрне. Мәңге очына чыга алмаячаксың, нервыларың гына бетәчәк. Сабыйга да анасы була торып ятим яшәү...

— Нишләп ятим булсын! Минем белән бит ул!

— Уйла әле син... Кызган баштан гына кылануың бу... Юлда суынгансыңдыр, яңгыр астына да эләккәнсез. Әнә Әнисә баланы юындырсын да, аннары син коенып чыгарсың. Диванда бала белән бергә йокларсыз. Мин үземә идәнгә җәярмен. Әнисә кухня диванында да бик әйбәт йоклый...

— Идәндә без йокларбыз, — диде Мидхәт, нык итеп.— Иркенрәк тә, егылмаска да җайлы булыр.

Шул рәвешле Әлифә өй мәшәкатьләренә чумган булып кыланды, Мидхәтнең башына төшкән хәлләрнең хикмәтен җентекләп сорашырга, нинди дә булса киңәш бирергә теләк белдермәде.

Аннары шактый вакыт юыну, җыештыру, әйберләрне тәртипкә китерү белән узды.

Арган-талчыккан баланы йоклатып, Әлифә дә яткач, Мидхәт белән Әнисә аш бүлмәсенең өстәле янына чәй эчәргә утырдылар. Икесе өчен дә бик истәлекле бер кичтәге кебек...

Ләкин бүгенге сөйләшү башкачарак иде. Чөнки Әнисә бик моңсу, ниндидер зур гаме бар кебек иде. Ничек укуы турындагы сорауларга таркау гына җавап биргәләде. Һәм кинәт башын күтәреп, Мидхәткә өздереп карады да:

— Нишләргә инде хәзер? — дип сызланып сорады.

— Син... нәрсә турында?..

— Ничек «нәрсә»? Рамиләне кая куярга?

Баксаң, ул чын йөрәктән бала өчен хәсрәтләнә икән лә!

Мидхәткә кинәт җиңел булып китте. Ул ялгызы түгел икән бит! Бүлешкән кайгы кечерәйми калмый ул.

— Берәр чарасы табылыр әле, — диде ул, кызны юаткандай елмаеп. — Менә шушы авыр бер чорны гына ничек тә булса үткәреп җибәрәсе иде. Берәр айга гына түзәсе.

— Ә аннан ни була?

— Мин сиңа яңа төр шартлаткычлар хакында сөйләгән идем бит әле? Менә шуларга патент алу артыннан йөри идек. Шуның очына чыгып бетерсәк, күчеп китеп булыр иде. Башка шәһәргә. Бүтән заводка эшкә урнашырга.

— Шушы... аерылышу аркасындамы?

— Бала язмышы һәммәсеннән мөһимрәк, Әнисә! Рамилә кайда, минем өем шунда. Ә аңа әнисеннән ераграк булу хәерле.

— Мин дә шулай дип уйлыйм, — диде һич көтмәгәндә Әнисә.— Җәй көне эшләгән балалар бакчасында танышларым бар минем. Бәлки, шунда урнаштырып торырга мөмкин булыр иде.

— Ә кем илтеп, алып кайтып йөрер икән соң аны? — дип шикләнә калды Әлифәнең сүзләрен исенә төшереп Мидхәт.

— Мин үзем... Үзем карар идем.

Мидхәт икеләнеп башын чайкады.

— Бала карауның ни икәнен белмисең шул әле син.

— Минме? Мин белмимме? Ике энемне менә шушы кулларда үстердем!

Әнисә моны шундый ныклы ышаныч белән әйтте ки, Мидхәтнең җилкәсеннән тау төшкән кебек булды.

— Атналык группа бармы соң ул бакчада? — дип сорады ул.

— Бар, андые да бар! Шундый матур бакча. Парк эчендә утыра!

Мәсьәләне шулай әйбәт кенә хәл кылып булуына алар икесе дә чын күңелдән ышанганнар иде.

Әмма иртәнге болытлы көн яктысында хәлләр бөтенләй икенче төрле булып күренде. Чәй эчеп утырганда, Әнисә, тезендә утырган кызчыкның алтынсу чәчләрен сыйпаштырып:

— Апа, Рамиләне үзебез генә алып калыйк әле, — диде.

«Ботка пешеримме?» — дип сорагандай гади итеп, сүз арасында җиңелчә генә әйтеп куйды. Әлифәнең исә капкан чәе ялгыш юлдан китте. Ул чәчәде, сулыш ала алмый интекте, кызарынып-бүртенеп йөткерде. Әнисә бер кулы белән баланы тоткан хәлдә, икенчесе белән аның аркасыннан каккалады.

— Озакка түгел бит, Мидхәт абый эшен тәмамлаганчы гына. Берәр айдан үзе монда кайтачак.

— Кешеләрнең берсен тегендә, икенчесен монда әвеш-тәвеш китерергә без кем әле ул хәтле? — диде, ниһаять, Әлифә, күз яшьләрен сөртеп. — Баланы уенчык дип белдеңме әллә? Үзе исән чакта анадан сабыен тартып алырга бернинди закон да, шәригать тә рөхсәт итми! Андый эшләргә тыкшыну олы гөнаһ! — Аннары чәен кабып куйды да: — Үзеңнекеләр азмыни? — дип сорады. — Әнә Радуны чит-ятлар уллыкка алырга йөриләр икән анда. Әтиең хастаханәдә ята. Минем бүген шунда чыгып китәсемне әйтмәдеңмени әле абыеңа?

Чыннан да, үзенекеләр турында Әнисә Мидхәткә берни дә сөйләмәгән иде.

— Кичке поезд белән Мәскәүгә китәм мин бүген, — диде Әлифә, Мидхәткә карап. — Аннан Кишиневка. Синең хәлең безнекеләр белән чагыштырганда бер дә баш китәрлек түгел әле. Саташып кына йөрисез.

— Апа! Рамиләне кире җибәрергә ярамый! — дип кинәт өзгәләнеп, кычкырып куйды Әнисә. — Алып калыйк, апа! Үзем карармын!

— Укуыңны ташлап, декретка чыкмакчы булдыңмы әллә?!

Тынлык урнашты.

— Кызмыйк әле, — диде аннары Әлифә һәм сүзне җиңеләйтергә теләгәндәй кеткелдәп көлеп куйды. — Баш ярылып күз чыкмаган. Тормыш үзе барын да җайга сала ул. Мидхәт синең белән минем кулга карап тора торган түгел. Ир кеше ул! Үзе хәл итәр!

Менә шуның белән өзде дә куйды. Һәм йомшарып:

— Бүген кичкә хәтле карап тора алам балаңны, — диде. — Күрәсе кешеләрең булса, барып килерсең.

— Командировка кәгазенә кул куйдырып кайтасы бар иде шул, — диде Мидхәт.

— Ә син, Әнисә, дәресеңә соңга кала күрмә!

Һәм баланы, аның кулыннан алып, тезенә утыртты да үчтекили башлады.

* * *

— Зинһар, килми кала күрмә инде, — дип ялынды Лениза Германга. — Синнән башка бер киңәшер кешем дә юк бит.

Чыннан да, кемгә генә сүз кушса да, Мидхәтнең кайтканын көтәргә, сабыр итәргә кушалар иде. Рәйсә белән Рәмис тә тыныч бул диләр. «Сабыр иткән морадына ирешкән», — ди Аня. Милициядә исә астыртын көлемсерәделәр генә: «Атасына кунакка киткән һәр кеше артыннан чапмасак, безгә эш беткәнме әллә? — диделәр. — Бик борчыласыз икән, барыгыз үзегез. Берочтан кайнанагызны да күреп кайтырсыз!» Ленизага шул гына җитмәгән иде! Анда барып, бер Мидхәт урынына бер өй кеше белән талашырга! Өелешеп тукмап җибәрмәсләрме тагын!

Вакытны сузу исә аерата куркыныч булып тоела иде. Мидхәт аның Герман белән бәйләнгәнен сизгәндер. Шулай булмаса, мондый дуамаллыкка барыр идемени? Ә бәлки, моңа дәлилләр туплый, шаһитлар җыя торгандыр инде. Судта аерылышканда, хатыным хыянәт итте, дип исбатласа, баланы үзендә калдыру чарасын һичшиксез табачак. Аннары Рамилә аның кулында бит инде, аерылышкач, тартып алып кара!

Шуңа күрә кул кушырып утырмаска, чарасына үзе керешергә булды ул.

— Прописадан төшереп куй син аны, — диде Герман.

— Ул үзе дә фатирны миңа калдырам дигән иде диюен...

— Алай булгач, ни авырлыгы бар аның!

— «Баланы миңа калдырсаң», дигән шарты бар шул.

— Соң, баланы алып киткән бит инде!

— Юк, баланы бирмим!

Герман аңа мәгънәле итеп карады да:

— Тап җаен, — диде. — Квартирны да үзеңдә калдыр, баланы да бирмә! Шунлык та үткенлегең юкмыни? Нишләп шулхәтле җебеп торасың? Хатын-кыз бит син!

Лениза үзен кечерәеп, ямьсезләнеп киткәндәй хис итте. Җебегәнлек белән уңмаганлык берәүне дә бизәми... Ә аның Герман каршында чибәр дә, уңган да булып күренәсе килә иде.

Һәм ул тәвәккәлләде: эшеннән өч көнгә түләүсез ял алып, шәһәр буйлап чапты. Судка тиешле кәгазьләрне тапшырды, йортлар идарәсенә кереп, прописадан төшерүнең тәртибен белеште.

Мидхәт көндез кайтып төшкән икән, суд юлыннан кайтып кергән Лениза һич көтмәгәндә аның белән йөзгә-йөз калды.

— Исәнме, Лениза...

— Минем исәнлегем сиңа ник кирәк? Үлеп куйган булсам, синең өчен яхшырак булыр иде, так ведь? Нишләтеп йөрттең баланы әллә кайларда? Кызым, исән-саумы син? Чирләмәдеңме?

Лениза, бүлмәгә кереп, Рамиләне күтәреп алды да:

— Моннан ары балага якын киләсе булма! — диде. — Белеп тор, милиция учетына бастырдым мин сине! Икенчесендә утыртып куячаклар!

Мидхәт нишләргә, ни әйтергә белми ишек төбендә таптанды.

— Ненавижу! Күралмыйм! Вон отсюда! Чыгып кит хәзер үк! Эзең булмасын монда! — дип ничектер эченнән суырып, кызарынып ысылдады Лениза. — Мин разводка бирдем инде. Бу квартирда урын юк сиңа!

Бала күтәреп ерак юллар узганда күп уйланган иде Мидхәт, үз хәленең никадәр аяныч икәненә бик яхшы төшенде. Инде эш аерылышуга барып җиткән икән, ир кешенең хәленә кереп, аның ягына басучы табылыр дип өметләнмә. Шушындый гаилә дәгъвалары аркасында күпме ирләр куышсыз калып, сукбайлык сукмакларында бәргәләнеп-кыйналып йөри!

Хәер, ул үзе эшсез дә, куышсыз да калырмын дип һич тә борчылмый иде. Норвегиягә дә чакырып торалар әнә. Риза да булыр иде, бәлки, ләкин Рамиләне ничек калдырып китәсең? Аны үзең белән алып бару хакында исә сүз дә булырга мөмкин түгел иде.

— Нәрсә син, квартир да квартир дип такылдыйсың? Ни дип белдең син аны? Бетон стена бит ул! Таш! — диде ул.

— Нәрсәсе бар, дисеңме? Таш, дисеңме? Ә ник син аңа чатлап ябышып ятасың алай булгач? Ник балага тыныч кына яшәргә ирек бирмисең?

— Квартир өчен түгел!

— Шулаймы? Алай булгач, төш прописка дан! Югыйсә мин сиңа Рамиләнең чыраен да күрсәтмәячәкмен!

— Соң, мин сиңа әллә кайчан әйткән идем бит инде, квартир сиңа калсын, ә Рамилә минем янда яшәсен, дип.

— Әйткәнсең икән, эшлә.

— Ә син... бу шартны үтәрсеңме соң? — дип, гажизлек аралаш өмет тулы, яшь белән өртелгән күзләрен хатынының йөзенә текәде Мидхәт.

Бу караш Лениза күңеленең нечкә бер кылына чиртеп куйгандай итте.

— Арагызга киртә куймам, обещаю, — диде ул, сорауга туры гына җавап бирмичә. — Күпме телисез, шулкадәр аралашырсыз...

Мидхәт керфеген дә какмый һаман аңа карап тора иде әле.

— Аңла, — диде ул. — Рамилә кайда булса, минем өем шунда.

— Ә син мине аңлыйсыңмы? Мин синең белән яшәргә теләмим!

— Мин сине борчымам... Кичләрен Рамиләне яследән барып алырга рөхсәт итәрсең бит? Ял көннәрен үзем белән йөртергә...

Мидхәтнең тавышы калтырана, ул кулларын кая куярга белми угалый иде. Әллә кайларга барып, җиде ятлардан үз хокукыңны дәгъвалап йөрсәң, тапталып кына калачаксың, теләгеңә ирешә алмаячаксың. Ыгы-зыгы, ызгыш-талаш арасында балага ниләр кичерергә туры килмәс тагын! Ә болай ул күз алдында булачак. Көн саен. Мидхәт бата башлаганын белә иде, аннан да бигрәк Рамиләне суга төшкән дип хис итә иде. Шунлыктан ул саламга тотынудан башка чара юклыгын аңлады.

Бу фатирда ул үзе дә яши алмаячак иде инде. Ленизаны ул сафлыгы өчен яраткан иде. Ай нурына уралган беренче кичтәге тойгылары бөтенләй үк онытылмаган, карурмандагы яктырткыч кортларның ымсындыргыч яктысы рәвешендә генә булса да вакыт-вакыт чагылып ала иде әле.

Ләкин шундук сүнә иде шул алар. Чөнки соңгы вакытта Ленизаның чисталыгы, ихласлыгы кимеде, ә бәлки бөтенләй үк юкка чыккан кебек тоела башлады. Ниндидер шакшы урап алган кебек иде аны. Очкычларда күп сәгатьләр очканда да Мидхәт бу хакта күп уйланды һәм Рәйсәнең теге вакытта йөзе җимерелгәч әйткән сүзләре исенә төште: дуңгызга гашыйк булсаң, аның белән бергә урам күлдәвегендә аунарга туры киләчәк. Менә хәзер Лениза урам күлдәвегендә аунап чыккан кебек булып тоела иде. Хәер, абынып яисә ялгышып егылганда пычрану ул кадәр үк куркыныч түгелдер. Тәнне юып була. Тик керләнгән җанны ничек сафландырырга?

Мидхәткә Ленизаның җаны пычранган кебек тоела иде. Һәм ул бу шакшы хатын белән бер ятакта була алмый иде. Абруйлы уйлап табучының дан тоткан куллары-бармаклары гына түгел, күңеле дә ифрат сизгер иде шул!

— Ярый, мин прописка дан төшәрмен. Тик син вәгъдәңне онытмассың бит?

— Әйттем ич, очрашырсыз, дип. Бар хәзер үк йортлар идарәсенә! Паспортистка бүген сигезгә хәтле эшли.

Әмма Мидхәт ишеккә борылмады, бүлмәгә таба атлады. Аның йөзен чалыш елмаю бозган иде. Әллә сүзләре шаяру гына булганмы, әллә хәзер Герман турында, Ленизаның хыянәте хакында йөзенә бәреп әйтеп, сугып җибәрмәкчеме? Төптән уйлап карасаң, бәреп үтерсә дә, хаклы булачак бит ул!

Лениза куркынып артка чигенде. Мидхәт аның калтыранган кулларыннан Рамиләне алды да битен сабыйның түшенә терәде. Ул гына ишетерлек итеп:

— Балам... синең хакка... — диде. — Үзем өчен болай кыланмас идем... Синең өчен кушсалар, борыным белән җир сөрәчәкмен, газизем...

Аннары Рамиләне диванга утыртты да, курткасын киеп, сумкасын алып, Ленизага күз дә салмый чыгып китте.

* * *

Мәдәният сараенда очрашу алдыннан Лениза Остазның күңелен күтәрерлек берничә сүз әйтеп кулын кысмакчы иде. Ләкин аны сәхнә артына кертмәделәр. Шунда ул беренче тапкыр аның тән сакчыларын күрде. Алар өчәү иде: уклау йоткандай төз сынлы, таза гәүдәле, кырыс карашлы ике ир-ат һәм бер хатын-кыз. Утызлар тирәсендәге бу хатынга Лениза сынап карады, ыспай буйсынына килешле озын итәкле зәңгәр костюм кигән, чәчен салам төсенә буяп пөхтә итеп күпертеп куйган. Түшендә нәни генә алтын «Нурсафлык» медальоны, йөзендә баллы елмаю. Ленизаны күрүгә, аның каршына килеп басты да:

— Хуш килдегез! — диде. — Әйдәгез, мин сезне залга озатып куям. Халык күп, урынсыз кала күрмәгез.

Лениза аны әйләнеп узмакчы иде, теге ике ир-ат аңа таба атладылар. Ул, алар аша үрелеп, эчкә карады.

Буш сәхнә артында Герман ялгызы әрле-бирле йөренә иде. Кара костюм, ак күлмәк кигән, янып торган кызыл галстук таккан. Үзалдына нидер сөйләнә, кулларын изәп куя. Карашы гадәттәгедән дә томанлы, шул ук вакытта серле ялтырый. Һичкемне, һичнәрсәне күрми, җаны-тәне белән үз кичерешләренә чумган иде ул. Талантлы артистлар спектакль башланыр алдыннан шундый кыяфәттә була торгандыр.

Сары чәчле хатын Ленизаны култыклап алды да артка таба тартты.

— Мин бу кичәне оештыручыларның берсе! — диде Лениза, үзенең Остаз белән сөйләшергә хокукы барлыгын белдерергә омтылып.

Хатынның йөзенә бал тагын да ныграк сыланган кебек булды.

— Ах, шулаймыни? Алайса, сез монда бик җаваплы кеше бит әле! Әйдәгез, мин сезне яхшырак урынга утыртам. Остаз чыгыш ясаганда, аңа залдан нык таяныч кирәк булачак. Сез мине аңлыйсыздыр бит? Очрашуның ахырында взнослар җыячакбыз, сез бу хакта беләсездер инде?

Лениза анысын ишетмәгән иде, дәшмәде. Хатын моны ризалык билгесе дип аңлады булса кирәк:

— Андый чакта үрнәк күрсәтергә кирәк, шулай бит? — диде.— Сез ничек, акчалата бирмәкче буласызмы?

Лениза акчаны янында кирәк кадәр генә йөртә иде.

— Күпме бирим икән? — дип сорады.

— Юк, сез акча бирмәгез. Иң яхшысы, берәр әйбер салыгыз.

— Нинди әйбер?

— Сумкагызны ачып караган булыгыз да, күршегезгә ишеттереп, ах, акчам аз икән, диегез. Аннары, әйтик, алкаларыгызны салырсыз. Алтындыр ич алар сезнең?

Ленизаның гаҗәпләнеп текәлгәнен күреп, хатын аңлатып бирүне кирәк тапты.

— Бу фәкать башкаларны оештыру өчен генә кирәк. Үрнәк күрсәтү өчен. Биргән әйберегезне соңыннан кире алырга була.

Һәм аны, култыклап, сәхнәдән алып төшеп тә китте.

Халык чыннан да күп, биш йөз кешелек зал шыгрым тулы иде. Ни радио-телевидениедән, ни гәзитләрдә игъланнар бирелмәгән, кичәне оештыру белән шәһәр-район җитәкчеләре шөгыльләнмәгән иде югыйсә. Алар бу чараны күрмәмешкә салыштылар, фәкать шул гына. Калганын «Нурсафлык»ның үз кешеләре башкарып чыкты. Керү бушлай иде, пенсионерларның, ялгызларның хәлен яхшырту мөмкинлекләре ачылачак, хасталарны дәвалау ысуллары күрсәтеләчәк, дип, очраган бер кешегә аңлаттылар, чакыру кәгазьләре өләштеләр.

Тырышлыклары бушка китмәгән, шуңа күрә алар бик канәгать кыяфәттә төрлесе төрле җирдә чәчелеп утыралар иде. Рәсимә уртада, Аня уң кырыйда, калганнар кайсы кайда.

Сары хатын, залдагы тәртипне күзәтеп йөрүче ападан урындык китерттереп, Ленизаны урта рәтнең сул кырыена утыртты.

— Уяу булыгыз! — дип, колагына иелеп пышылдады.— Мин әйткәнне онытмагыз.

Остаз сәхнәгә очып диярлек, ашкынып килеп чыкты. Ике кулын канат кебек күтәрде, кызыл галстугы күкрәгендә шәфәкъ утыннан яралган коштай җилпенде.

— Исәнмесез, кадерле туганнар! — диде ул, йомшак, гадәттәгечә күңелгә май булып ята торган тавыш белән. — Нур һәм сафлык барыгызга да! Иманым камил, бу залда караклар да, җан кыючылар да, сугыш чукмарлары да юк. Һәммәгезнең намусы чиста, теләкләре изге! Мин сездән бөркелгән җылы хисләрне тоям, алар миңа канат куя, рухымны югарыга, биеккә күтәрә. Һәм мин күкләрдән сирпелгән нурланышта коенгандай булам, аның серен аңлый башлыйм! Без барыбыз да күктән иңгән нурларда коенып яшибез. Тик менә алар аша җибәрелгән хәбәрләрне күпләр акылы белән аңлап, теле белән әйтеп бирә белми. Андый сәләткә ия булган кешеләрне борынгыдан пәйгамбәр дип атаганнар...

Остаз беренче сүзләре белән үк, аннан да бигрәк ыспай да, гайрәтле дә, серле дә кыяфәте белән, үткен дә, томанлы да карашы белән, талпынулы хәрәкәтләре белән бөтен залны тынсыз, өнсез итте. Аның һәр сүзе рас, бөтен сөйләгәне нигезле иде бит! Ул моннан күп гасырлар элек яшәгән пәйгамбәрләрнең күкләрдән иңгән хәбәрләрне адәмнәр теленә күчерүе турында, тик ул мәгълүматларны кешеләрнең үз чорына хас фикерләве аша аңлавы хакында сөйләде. Шуның аркасында төрле пәйгамбәрләрнең сөйләгәннәре арасында аермалыклар килеп чыккан, нәтиҗәдә төрле диннәр барлыкка килгән. Һәрнәрсәнең үз вакыты булган кебек, диннәрнең, тәгълиматларның да үз чоры була.

— Уйлап карагыз, без Будда дәверендәге кешеләр кебекме? Яшәешебез Муса яисә Гайсә пәйгамбәрләр заманнарындагы төслеме? Белемебез, фикерләвебез Мөхәммәт пәйгамбәр чоры дәрәҗәсендәме? Юк бит! Юк! Җитмәсә әле, Илаһи Затның алар аша ирештерелгән сүзләрен төрлечә боза килделәр. Хәтта явыз ният белән файдалана торган булдылар. Кешеләр, нишләттеләр безне? Илләргә таркаттылар, диннәргә тараттылар. Бер-беребезгә каршы өстерәләр, бер-беребез белән сугыштыралар! Без барыбыз да атабыз Адәмнең балалары бит югыйсә! Күк — барыбызга да бер! Җир — бер! Әмма без аларның кадерен белмибез, җирне дә, күкне дә пычратабыз. Әгәр моны туктата алмасак, тиздән ахырзаман киләчәк! Аның башлангычы безнең күз алдыбызда инде! Бер иманны кабул итеп, бер максатка хезмәт итсәк кенә котыла алачакбыз без!

«Шулай бит, чыннан да шулай бит!» — дип пышылдады Ленизаның янәшәсендә утырган кәләпүшле абзый. «Әйе-әйе», — диеште бөтен зал.

Лениза татлы да, сызланулы да бер халәттә иде. Ни өчен бу кешегә бер күрүдә гашыйк булганын, ни хакына газаплы, әрнүле кавышуларны түземсезлек белән көтеп алганын ул нәкъ шушы минутларда аңлады.

Биредәге биш йөз кешене, әллә ничә шәһәрдәге меңнәрчә башкаларны үзенә җәлеп иткән, алай гына түгел, әсир иткән бу затка бик күпләр тәкатьсез гашыйк иде, билгеле.

Лениза моны да аңлады. Һәм йөрәгенә көнләшү уты капты. Бу инде Мидхәттән көнләшү генә түгел иде! Ул Германны күзләре белән сәхнәдән суырып алып, үзенеке, үзенеке, фәкать үзенеке генә итәргә тели иде. Тик моңа ирешүнең әмәлен белми иде. Остаз биегәя, ерагая бара, аның тавышы чыннан да күкләрдән килеп ирешә кебек иде.

— Оҗмах җиде кат күк өстендә булачак, дип, безне алдамасыннар. Җирдә булачак ул. Һәм аны кешеләр үзләре төзергә тиеш. Моның өчен без җирне тазартырга, иң беренче чиратта үзебезнең күңелләрне һәртөрле шакшыдан арындырырга тиешбез. Без бу бөек эшне күптәннән башладык инде. Үзебезнең бистә-поселогыбыз бар, Святонино дип атала. Анда өч мең кеше яши, арада бер генә фәкыйрь дә, эшсезлектән интегүче дә юк. Анда һичкем һичкемне җәберләми. Һәммәбез бертигез, бердәм, бергә. Авыр чакта берәүне дә ташламыйбыз. Мин сезгә аны барып карарга тәкъдим итәм. Кем тели, рәхим итегез! Килегез, кешечә яшәрсез, изге эшкә үз өлешегезне кертерсез! Әгәр бүген үк кузгалып бара алмыйсыз икән, ул чакта бөек эшкә моннан торып та ярдәм күрсәтеп була.

Кемнәрдер ниндидер сораулар бирде, аларның күпчелеге артык беркатлы, хәтта мәгънәсез иде: хасталар сырхауларыннан дәва табуны өмет итә, кемнеңдер якын кешесе кинәт үлгән, кемнедер җитәкчеләр җәберләгән. Остаз һәркайсына юату сүзләре тапты.

Ул арада сары чәчле хатын, үтә күренмәле букча тотып, ярдәм җыярга кереште. Ым белән, киная белән, кайсына исә пышылдап, активистларны да торгызды. Алар да рәтләр буйлап киттеләр. Лениза аягына торып басты да алкаларын сала башлады. Тик нигәдер бармаклар тартыша, колак яфрагы артындагы нәни шөрепләрне бора алмый иде. Башка чакта аларның борылганы сизелми дә кала иде бит югыйсә. Ни булган бу кулларга? Шунда күңелне бер кисәтү тырнап узды: «Бәлки, бирмәскәдер?» Мидхәт бүләге иде шул алар! Кызыл якут кашлы алкаларны балдак белән пар итеп бүләк иткән иде ул. «Монысы — никах балдагы, матуррак дип юри кашлысын алдым, ә алкалары Рамилә өчен!» — дигәндә, йөзе куанычтан балкый, күзләре кояш төшкән асылташ кебек нур чәчә иде аның... «Бирмә! Бирмә!» — дип сызылды Ленизаның күңелендәге бер нечкә кыл.

Ул арада сары хатын Ленизаның каршына килеп баскан да кулындагы букчаның ачык авызын битенә терәп диярлек сузган, тирә-юньдәгеләр, башларын борып, аларга текәлгән иде. Лениза тешләрен

кысып, алкаларның биген, ниһаять, ычкындырды, аларга өстәп балдагын да капчыкка шудырып төшерде. Моны күреп, тагын берничә хатын балдакларын сала башладылар.

Күп тә үтмәде, ярдәм җыючылар тоткан букчалар акчадан бүлтәйгән, акча астында алтын йөзек-алкалар елкылдый иде инде. Сары чәчле хатын җәлт кенә аларны эләктереп алды да сәхнә артына кереп китте.

Бу эш тәмамлангач та, халык тиз генә таралмады, шактые Рәсимә тирәсендә тукталып, төркем хасил итте: ул анда «Нур һәм сафлык» медальоннары сата иде.

Аня, Лениза янына килеп:

— Син алкаларыңны салып бирдең түгелме? — дип сорады.

— Теге сары чәчле хатын әйтте...

— Розананы әйтәсеңме? Оештырып йөрүчене, дим?

— Ул әйтте, башкаларга үрнәк күрсәтү өчен генә кирәк, соңыннан бирербез, диде.

— Алайса, бар тизрәк, кереп ал. Алар хәзер китәләр.

— Кемнәр?

— Остаз үзе дә, аның белән килгән башкалар да. Аэропортка илтәсе машиналар ишек төбендә тора.

Ленизаның йөрәге убылып төшкәндәй булды. Ул халыкны аралап сәхнә артына ыргылды.

Бу юлы аны бернинди тән сакчылары да туктатырлык түгел иде инде.

— Остаз мине үзе чакырды! Үзе! — дип кычкырынды ул.

Герман сәхнә артындагы кечкенә бүлмәдә ялгызы утыра иде. Иңнәре салынган, галстугы кыйшайган, йөзе сүрелгән. Алдында кәгазь каплы җимеш суы һәм бер стакан кызгылт-сары сыекча тора.

Ул Ленизага тонык күзләре белән карады да, хәлсез елмаеп:

— Ну ничек, мышонок, булдырдыммы? — дип сорады.

— Искиткеч!.. Син китәсең, диләр, дөресме шул?

— Эш бетте бит инде, монда нишләп ятыйк.

— Минем белән хушлашмыйча да китәр идеңме әллә?

— Ну, хушлашабыз бит менә.

— Ә син кайчан кайтасың?

Герман аның бу соравын аңламады.

— Кая?

— Кая булсын, монда!

— Белмим шул. Бәлки, бер елдан, бәлки, соңрак...

— Бер елдан? Бер ел?!

— Ә ник аңа гаҗәпләнәсең? Илдә шәһәрләр күп ләбаса, безне һәркайда көтәләр.

— Алайса... Алайса... мине дә үзең белән ал!

— Ник?

— Син мине болай гына ташлап китә алмыйсың... Мин синнән калмыйм, — диде дер калтыранып Лениза.

Герман, сәерсенгәндәй, башын чайкап куйды.

— Чемодан түгел бит син күтәреп йөрергә.

— Ярдәмчең итеп ал!

Германның йөзе җитдиләнеп китте.

— Минем ярдәмчеләрем җитәрлек.

— Теге Розананы әйтәсеңме?

— Менә нәрсә, мышонок, хуш, сау бул, диешеп куллар бирешик тә, аерылышыйк әле без. Күрмисеңмени, ардым мин.

— Мин синсез яши алмыйм!

Шунда Ленизаның хәтеренә келт итеп Мидхәтнең «очратсаң, адресын сора» дигән киңәше килеп төште.

— Яши торган җирең кайда соң синең? — диде ул, ялварып.

— Ну, пропискам Святонинода минем.

— Син анда еш буласыңмы?

— Мондагыдан ешрак, әлбәттә.

— Алайса... мин шунда барам.

— Теләгәнеңне эшлә. Тик шуны бел, безгә анда синең белән бу рәвешле икәүдән-икәү калып очрашу мөмкин булмаячак.

— Нишләп?

— Аңла, мышонок, мин үземне кемгә дә булса бирә алмыйм! Залдагыларның миңа ничек караганын сиздеңме? Мин аларның һәммәсенеке. Гайсә пәйгамбәрнең хатыны булмаган!

«Әһә, димәк, буйдак...»

Бу уй Ленизаны тынычландырып җибәрде. Ярый, өйләнмәсен. Тик аны сирәк кенә булса да күрергә мөмкинлек булсын!

— Мин Святонинога барам, — диде Лениза, ныклы карарга килеп.

...Шуннан соңгы көннәрне ул үзалдына урысның мәгълүм җырын көйләп йөрде:

«Җанкаем, бәгърем, алып кит мине,
Ерак җирләрдә, ярым, диярсең».
«Җанкаем, бәгърем, бик алыр идем,
Ерак җирләрдә ярым бар минем». .
«Сеңлем, диярсең...»
«Сеңлем бар минем...»
«Чит-ят, диярсең...»
«Җанкаем, бәгърем, бик әйтер идем,
Ерак җирләрдә чит-ят кирәкми...»

Соңгысы үзәкне өзә иде, Лениза күз күрмәгән якларга мәгъшугына чит-ят булып бара, әмма күңел күгендә өмет йолдызы кабынган һәм ул торган саен яктырак яна иде: күз алдында булгач, араларны ныгыту чарасы табылыр, ә бәлки, аның гомерлек яры булуга ирешергә мөмкинлек тә ачылыр әле... Тик араларны гына ерагайтмаска кирәк!

* * *

Лениза, фатирын «Нур һәм сафлык» оешмасына бер елга арендага биреп, ачкычларны Рәсимәгә тапшырды. Һәм сентябрь ахырында, чемодан өстерәп, бала арбасы тартып, Святонинога барып төште.

Тирә-якта байлыгы белән дә, серлелеге белән дә дан тоткан авыл иде бу. Аның хакында бик күп сөйләп булыр иде, әмма автор үз алдына андый максат куймый. Кешелек яралганнан бирле адәм балаларының иң акыллы һәм булдыклылары бар халыкны мул, рәхәт яшәтү чараларын булдырырга омтылды. Борын-борыннан Герман әйткән күкәй башлар моны оештыруның ысулларын тәкъдим итеп китаплар яздылар. Кызыксынган кеше Томмазо Кампанелланың унҗиденче гасырда язылган «Кояш шәһәре»н, Маркс, Ленин, Мао Цзэдун китапларын алып укый ала. Алар һәммәсе җирдә яшәүче барча адәм балаларын, шул исәптән без фәкыйрьләрне дә кайгыртып язылган. Бәгъзеләре моны риясыз, бернинди хак алмыйча, намус кушуы буенча гына башкарып чыкканнар. Кампанелла, мәсәлән, үзенең хыялый хезмәтен зинданда, сакчылардан яшереп ижат иткән...

Аларның акылына таянып, бу юнәлештә йомры башлар кешелек өстендә шактый тәжрибәләр үткәрде. Тарихта моның мисаллары җитәрлек. Маронитларның үзидарәләрен, СССРның коммуналарын, колхозларын, Израильнең кибуцларын, шәрекъ мәмләкәте Камбоджаның хакимият башлыгы Пол Пот тудырган системаны мисалга китерергә мөмкин. Алар һәммәсе изге ният белән оештырылган, әлбәттә. Нәтиҗәсе төрлечә булды: коммуналар таралды, колхоз системасы уңышсыз дип табылды. Бу юнәлештә иң алга китеп бөтен дөньяны шаккатырганы, әлбәттә, Пол Пот булды. Ул хаклы рәвештә камил җәмгыятьне яхшы кешеләр белән генә төзеп була, шуңа күрә иң элек начар гражданнардан арынырга кирәк дип санады. Каршы әйткәннәрне, эшкә ярамаганнарны үтерүне (күп очракта дөге басуында күсәк белән бәреп) җайга салды. Зур тырышлык куеп, үз халкының дүрттән берен юк иткәннән соң, хакимияттән куылды, ватандашларының мәңгелек каһәренә дучар ителеп үтерелде.

Маронит җәмгыятьләре исә, бик шауламыйча гына, һаман борынгыча яшәп яталар, кибуцларның да уңышлы гына эшләп килүе мәгълүм.

Святонинода элеккеләрнең хаталарын кабатламаска тырышалар, уңышлардан исә үрнәк алалар, һәр эшне фәнни нигездә алып баралар иде. Хуҗалык, җитәкчеләр теле белән әйткәндә, аягында нык тора, уңышны мул җыя. Район-өлкә күргәзмәләренә куелган кәбестә-чөгендерләрнең иң эреләре, сыерларның иң сөтлеләре, күркәләрнең иң зурлары шуннан китерелгән була. Аларның фермаларында, басуларында чит илләрдән алынган, ялтырап торган машиналар эшли. Шулай булмый мөмкин дә түгел, хуҗалыкның башында Америка кешесе — мистер Джонатан Смит тора иде.

Безнең илдә эшләп баеп булмый, яшәү авыр, дип әйтәләр әйтүен дә, ни хикмәттер әле анда, әле монда чит илдән килеп, заводлар корып, авылларда фермалар оештырып, нык кына мантып китүчеләр бар.

Мистер Смит шундыйларның берсе иде. Түшенә «Нурсафлык» тамгасы тагылган булса да, ул яңа тәгълимат турында сүз сөйләп йөрми, баш-аягы белән хуҗалык эшенә чумган иде. Бер сүз белән әйткәндә, йомры баш иде ул. Хәер, озын буйлы, сыек сынлы бу адәмнең яртылаш пеләш башы кыяр кебек озынча булып, аскы ирене салынып торган чырае һәрчак бик җитди иде. Яңа килгән кешеләрне дә эшкә ул үзе билгели икән. Озак сөйләшеп тормыйча, Ленизаның кулына ике бүлмәле өйнең бер ягына ачкыч тоттырды һәм:

— Химикларга бездә ихтыяҗ юк, әлегә идарәне җыештырырсың, кизү торырсың, — диде. — Эш көне унике сәгать, иртәнге сигездән кичке сигезгәчә.

— Мин бала белән... — дип, Лениза аның сүзен бүлдермәкче иде, Смит аңа әллә күксел, әллә зәңгәрсу, ниндидер төссез күзләре белән акаеп карады да:

— Бездә тәүлеклек ясле-бакча эшли, — диде. — Гомумән, сез монда ник килгәнегезне беләсездер бит? — һәм Ленизаның ни дип җавап бирергә белми югалып калганын күреп, чыраена ниндидер җирәнү галәмәте чыгарды, аскы иренен тагын да ныграк салындырды да: — Эшләргә килдегез сез монда! — диде. — Хезмәт белән сафланырга һәм дөньяны тазартырга. Шулай бит? Килгәнсез икән, эшләгез!

Лениза мистер Смитны бер күрүдә яратмады. Аны күрмәс өчен фермага барып тирес көрәргә әзер иде, әмма биредә эш сайлау дигән нәрсә юк икән. Кем кая куелган, шунда бөтен көчен биреп, көн саен уникешәр сәгать хезмәт итә. Югыйсә җитештерүчәнлекне Святонинодагы кебек текә күтәреп булыр идемени?

Чын мәгънәсендә ашау байдан, яшәү Ходайдан икән биредә. Ризык ашханәдә пешә, киемсалымны складтан түләүсез алырга була. Балалар башта ясле-бакчада, аннары озайтылган көнле мәктәптә үсә.

Дөрес, кыр эшләреннән бушагач, кышның иң салкын чакларында эш көнен кыскарталар икән. Ул айларда клуб та, спорт залы да гөрләп эшләп тора, һәртөрле ярышларда катнашу хуп күрелә.

Ләкин боларның берсе дә Ленизага кирәкми иде. Аның гайрәтен чигергән тагын бер нәрсә бар иде: ул да булса һәр иртәне авылның бер ягыннан буйдан-буйга сузылган агачлык артындагы зур буага төшеп чумып чыгу. Бу гамәл авыл халкының һәммәсе өчен мәҗбүри санала, чөнки тәнне сәламәтләндерә, рухны ныгыта, шулай итеп, адәм баласын һәртөрле кердән арындыруга ярдәм итә дип исәпләнә иде. Бу хакта да бик белдекле кешеләрнең китаплары җитәрлек, кызыксынган һәркем табып укый ала. Әмма Лениза һәр иртәне нык сыкранып кузгала һәм, Рамиләне бакчага илтеп тапшыргач, кайтыр юлда суга чумып чыгуны зур газапка саный иде. Аның белән бер өйдә, күрше бүлмәдә яшәүче карчык Дарья Петровна бу җәзадан котылу чарасын тапкан — табиблардан йөрәк сырхавы хакында белешмә алып кайткан икән. Лениза аңа көнләшеп карый, тик үзен хаста дип игълан итә алмый иде бит инде! Үзе бер хәл, ул балалар бакчасындагы сабыйларны да һәр иртәне салкын суга чумдырганнарын белә, кызын кызгана иде. Ләкин бернишли алмыйсың, бер Рамиләне генә башка балалардан аерып куеп булмый шул.

Бөтенесе чит-ят иде монда, эчне бушатырлык бер кеше дә табылмады. Күрше карчык белән дә борчагы пешмәде Ленизаның. Карадан киенеп, кара яулык бөркәнеп йөри торган, кечерәк кенә гәүдәле, иңнәре салынкы Дарья Петровна үзе дә якты чырай күрсәтмәде.

Күршегә йомыш төшми булмый, яңа җирдә бигрәк тә. Беренче көнне үк Лениза тоз сорап кергән иде, карчык сүзсез генә аның чынаягына бер уч тоз салды да, Ленизаның итәгенә ябышып, ятсынып, турсаеп карап торган Рамиләгә ишарәләп:

— Бу гражданка да монда гариза биреп килдеме? — дип сорады.

Лениза югалып калды. Берничә мизгелдән генә телгә килеп:

— Кечкенә бит әле, яза белми, — дия алды.

— Яза белсә, үзе теләп килер иде дисеңме?.. Әтисе кая соң? Нишли? Сезне куып чыгардымы әллә?

Монысы каты бәрелгәндәй тоелды.

— Юк, мин үзем! — диде Лениза, кырыс кына итеп. Ул инде ник кергәненә үкенә башлаган иде.

— Воистину, күрмәгәннең күрәсе килә шул... — дип мыгырданды карчык, аңа аркасы белән борылып.

Бу сөйләшүдән соң аралар җылынмады, икесенең берсендә дә якынаю теләге тумады. Йөзгә-йөз туры килгәндә салкын гына сәлам биреп узуына караганда, карчык Ленизаның бирегә ник килгәнен сизенә һәм гаепли кебек тоела иде.

...Шулай итеп, зиһенне ураган томан эчендә, аңгы-миңге хәлдә бер ай вакыт узып китте.

* * *

Әле кичә генә каеннар, чаганнар яшел, сары, коңгырт буяуларга манылган ябалдашлары белән мактанышып утыралар иде. Әле кичә генә юл кырыйларындагы чирәм күперенке яшел келәм кебек иде. Ә менә бу иртәне тышка чыгуга салкын һава тынны куырды. Агачлар шәрәләнеп калган, алардан коелган яфрак өемнәрен, сукмак тирәләрендәге үләнне ак бәс сарган.

Бу көнне Лениза буаның бозланган ярында аеруча авырлык белән чишенде һәм, бөтен көчен җыеп, күзен чытырдатып йомып, суга сикерде. Тик юкка курыккан икән: тәнне салкын куырасы урында, ялкын теле ялмап алгандай итте.

Кире чыгып киенгәндә, янәшәдә ыгы-зыгы килгән хатыннарның:

— Остаз кайткан бит, Остаз кайткан! — дигән сүзләре колагына килеп иреште. Бу хәбәр җанга бозлы судай бәреп керде дә ут белән өткәндәй итте. Ул кайткан! Лениза аны күрәчәк!

Дөрес, күзгә-күз очрашу рөхсәт ителми, дигән иде диюен. Ләкин Лениза аның өчен мондагы меңнәрдән берәү генә түгел бит, ә сөйгән кешесе! Эчендә җаны булса, бөтенләй онытып, исенә төшермәгәндер! Ленизаның йөрәгендә ургыган кыргый учакның бер чаткысы гына булса да аның күңеленә төшми калмас!

Эчендә ни булгандыр, әмма Герман һични сиздермәде. Мистер Смит белән бергә идарәгә килеп, алгы бүлмә аша узганда, өстәл артыннан сикереп торган Ленизага карамыйча гына:

— Исәнмесез... Нур һәм сафлык... — дип мыгырданып узып та китте.

Бөтенләй чит кеше кебек, танымаган да шикелле...

Берәр сәгатьтән соң кире чыгып барганда, янә күз салмады. Буш өстәл яныннан узып киттемени! Аңа якын килмәскә сүз биргән, ерактан гына бер күрүгә дә риза булыр идем дип уйлаган Лениза йөрәге сыкранудан нишләргә белмәде.

Көндез түзми хәлең юк, идарәдә кеше өзелми, сораганга җавап бирәсе, телефоннан килгән хәбәрләрне язып барасы, почтаны актарасы...

Җан газапларының иң ачылары төнлә килде. Рамиләне йоклатып, караватка яткач, чыдар әмәле калмаганын аңлады ул. Бу минутларда Герман ни уйлый, ниләр кичерә икән? Ленизаны бөтенләй исенә дә төшермәдеме микәнни? Шулхәтле кайнар тәнле, дәртле кеше мондый төннәрне ялгызы изрәп йоклап ята аламы? Ә бәлки, бу минутларда аның янында башка берәү бардыр? Розана түгел микән?

Тарсылдаган йөрәк менә-менә күкрәк куышыннан сикереп чыгар кебек иде.

Лениза урынынан кузгалды да, төнге күлмәге өстеннән плащ киеп, аягына чүәк элеп, урамга чыкты.

Ә төн суык, аяз, айсыз иде. Карасу-зәңгәр күк капусы түбәнәйгән, аның аркылы үтә күренмәле киң челтәр булып Киек Каз Юлы сузылган. Аксыл, саргылт, зәңгәрсу, яшькелт йолдызлар аерата чекерәеп текәлгәннәр кебек. Лениза балачактан таныш Җидегән йолдызга карады, аннан чамалап Сириусны эзләп тапты. Башкалардан яктырак янган бу йолдыз хәзерге минутларда җиргә нинди хәбәр җибәрә икән? Янган йөрәктән ургылган хисләр дулкыны анда барып җитәдер бит, җитми мөмкин түгел! Ни җавап бирә аның мең соравына Илаһи Зат? Йолдыз җемелдәп аңа текәлгән, ләкин ни әйткәнен аңлап булмый иде. Хәер, нигә аңламаска! Бар, ди ул, чыккан юлыңнан тукталып калма!

Остазның биек болдырлы, юан-юан карагай бүрәнәләрдән салынган зур йорты идарә белән янәшә, аңа шактый ерак барасы иде. Лениза караңгы урам буйлап абына-сөртенә йөгерде, кайбер капка артларыннан этләр өреп калды.

Йортның тәрәзәләрендә ут юк, болдыр өстендә генә лампочка яна иде. Бирегә килгән һәркем ерактан күренсен өчен махсус асып куйганнармыни. Ә бәлки, шулайдыр да... Ләкин кире борылып китәргә көч калмаган иде инде. Ул болдырга менде дә таза-калын такталардан ясалган ишекне башта бармаклары белән тырнаштырды, аннары каккалады. Ниһаять, аңына килеп, сузылып, тәрәзә яңагына суккалады. Эчтә ишек ачылганы ишетелде, карлыккан тавыш ризасызлык белән:

— Кем ул анда? — дип сорады.

— Мин бу, Герман. Мин, Лениза.

Ишек ачылды. Көчле куллар Ленизаның плащ түшеннән эләктереп алып эчкә тартты.

— Нишләп йөрисең монда? Якын киләсе булма, дип әйтмәдеммени мин сиңа!

— Мин тырыштым, — диде еламсырап Лениза. — Тик түзүнең дә чиге бар бит!

Герман караңгыда ян ишекне ачты да Ленизаны, күтәреп, киң ятакка томырды, плащын, төнге күлмәген йолкып алып идәнгә ыргытты. Бу юлы ул гадәттәгедән дә тупасрак иде. Башын читкә борган, үпми дә... Юл чатыннан алып кергән фахишәләр белән шулай кыланалардыр... Әмма Лениза тупаслыкны аңламый, авыртуны тоймый иде. Сагынылган тәннең исеннән исереп, тилереп, аның ихтыярына бирелде, сызланулы ләззәттән ыңгырашып җибәрде. Герман киң учы белән каты итеп аның авызын томалады:

— Тыныңны чыгарасы булма! Берәрсе ишетсен дисеңме әллә?

Лениза авырттырып иреннәрен тешләде.

...Хәл җыеп та өлгермәделәр кебек иде әле, Герман, бармагы белән аның иңенә төртеп:

— Тор! Нәрсә ятасың, — диде. — Кеше-кара кузгалганчы үз өеңә кайтып ят.

Лениза көч-хәл белән күтәрелде дә:

— Яратмыйсың син мине, — дип үксеп елап җибәрде.

— Әле генә мин сиңа ничек яратуымны исбат итмәдеммени?

— Аны шулай итәләрмени? Шулай?

— Ә ничек тагын? Ирең белән башкача була идемени?

Ир турындагы сүз Ленизаның бәгыреңә өстәмә яра ясады.

— Мин болай яши алмыйм! Яши алмыйм! — диде ул.

— Ну, анысын үзең карыйсың инде. Монда сиңа нянька юк. Миңа меңләгән кеше карап тора. Иртәгә тагын китәбез.

— Кая?

— С. шәһәрендә очрашу планлаштырылган. Көтәләр.

— Ал мине үзең белән. Ал!

Лениза идәнгә тезләнде дә Германның каты, йонлач балтырларын кысып кочаклады.

— Әгәр син мине монда калдырсаң... Әгәр үзең белән алмасаң... Мин сине көтеп ала алмаячакмын! Шуны бел!

— Кем дип алыйм мин сине?

— Озатып йөрүчеләрең бар бит синең! Әнә Розана!

— Алар алышынып тора. Бу юлы Розана бармаячак.

Бу сүзләрдән Ленизаның эченә җылы йөгерде.

— Шулай булгач, мине алсаң да буладыр бит! — диде ул, сөенгәндәй.

— Ярый. Бер генә юлга! Тик белеп тор, андый җирдә күзәтү аеруча көчле. Без аулакта кала алмаячакбыз.

— Булсын... Мин читтәрәк йөрермен... Якын килмәм...

— Вәгъдәңдә тора белмисең шул син.

— Кичер мине бүгенгесе өчен... Ачуланма... Мин башка алай итмәм.

— Әгәр эһ кенә дисәң дә...

— Димәм, димәм... — диде шатлыгыннан нишләргә белмәгән Лениза.

* * *

Ул Рамиләне атналык бакчада калдырып китте. Бала ике-өч көн инде ютәлләштереп тора, тәрбияче алып калырга авырсынган да иде, әни кешенең Остаз кушуы буенча тиз генә барып киләсе җире барын белгәч, аяк терәп каршы тора алмады.

Ике көн узгач, төн уртасында аның ишеген каты шакылдаттылар. Фатир буш иде, чыгучы булмады. Күрше ишекне дыңгырдатырга керештеләр. Ниһаять, Дарья Петровна урыныннан кузгалды.

Атналык бакчаның төнге тәрбиячесе килгән икән. Рамиләнең тамагы шешеп, сулышы буыла башлаган.

Дарья Петровна тиз генә киенде дә ашыгып шәфкать туташының өенә китте, тәрбияче кире бакчага йөгерде.

Шәфкать туташын уятып алып килгәнче, ул районга шалтыратып «ашыгыч ярдәм» машинасын чакырганчы, аның шоферы йокысыннан айнып күзләрен тырнап ачканчы, аннары төнге юлдан кырык чакрым араны узып Святонинога килгәнче һәм бала белән озатучысын алып, кире районга кайтып җиткәнче күп сәгатьләр үтте. Бу төнге маҗараларны нечкәләп сөйләп бирергә, барыннан да бигрәк Дарья Петровнаның тезендә яткан сабыйның газапларын тасвирларга минем каләмемнең көче җитми.

Баланың тынсыз гәүдәсен кабул итеп алган табиб урта яшьләрдәге ир кеше иде. Ул Рамиләнең тамагын тишеп көпшә куйды, укол кадады, шактый озак ясалма сулыш алдырырга тырышты. Ахырда тирләп-пешеп бетте... Ниһаять, өмет юклыгын аңлагач, операция бүлмәсеннән чыгып, битлеген умырып алды да коридорда басып торган Дарья Петровнага:

— Ник болай соң китердегез? — дип кычкырды. — Авыруы беренче көн генә булмаган бит инде бу баланың! Ни карадыгыз? Күзегез чәчрәп чыккан идемени? Эчегездә җаныгыз юкмы әллә?

Һәм, җавап көтмичә, кулын селтәп китеп барды. Карчык күз яшьләрен сөртеп басып калды.

...Өч көннән, мәрхүмәне җирләп кайткач, хәсрәткә баткан Лениза, аз булса да юаныч эзләп, күршесенә кереп утырды. Дарья Петровна күлмәк изүен ачып, эчтән алтын тәре тартып чыгарды. Святонинода алтын-көмеш тагып йөрү гаеп санала, килгән бер кеше андый әйберсен бухгалтериягә кертеп тапшыра. Ә менә бу кортка бирмәгән, яшергән икән. Ул тәресен үпте дә түр почмакта матурлык өчен эленгәндәй асылынып торган чигүле сөлгене алып куйды: астан икона килеп чыкты.

— Господи Иисусе Христе! Пресвятая мать богородица! — дип баш иеп чукынды ул. — Прими душу безвинно убиенного младенца, рабы твоей Рамили! Прости нам грехи великие...

— Нишләп алай «гаепсез үтерелгән» дисез, Дарья Петровна?! Үз чире белән үлгән баланы... — диде әрнеп Лениза.

— Ә син нишләп газиз балаңның рухына багышлап дога кылмыйсың?

— Мин белмим шул...

— Атаң-анаң, әби-бабаң бернәрсә дә өйрәтмәделәрмени?

— Бисмилла әйтә беләм, шул гына...

— Һич югы, шуны укы...

— Бисмиллаһи-ир-рахманир-рахим...— дип пышылдады Лениза.

— Мәчеткә барырга кирәк иде, анда өйрәткән булырлар иде...

— Бер кергән идем. Ничектер ятсындым. Буш тоелды.

— Бөтенләй буш идемени?

— Әйе. Иркен бина. Стеналарында Коръән сүзләре. Мин аңламый торган. Тәрәзәләре күп. Бик якты.

— Ә сиңа ул якты гына җитмәгән инде алайса. Караңгыга чыгып, күктән йолдыз чүпләргә кирәк булган... Баланың атасы юкмыни? Җеназада күренмәде.

— Бар... Тик мин аңа хәбәр итмәдем әле.

Дарья Петровна бер мәлгә телсез калды. Нинаять, аңын җыеп:

— Ничек алай? — диде. — Андыйны кан дошманыңа да хәбәр итәләр. Чит-ят түгел, баласын йөрәк астында йөрткәнсең... Ярата идеңме соң син аны?

— Ярата идем... Үлеп көнләшә идем...

— Яратмагансың син аны! Чын сөюне көнләшү сүндерә алмый. Минем Федорым, царствие ему небесное... — бу урында Дарья Петровна тагын чукынып куйды, — безне ташлап чыгып китте, яшьрәккә өйләнде. Ә минем мәхәббәтем сүрелмәде. Аны ерактан гына күреп калсам да, дөньям якты иде. Улыма әтисен мактап-яклап тордым. Ах, ул чакларда бик бәхетле булганмын икән лә... Господь аларның икесен дә үз янына алды шул.

— Ничек? Сезнең дә балагыз...

— Әйе, алар икесе берьюлы аварияга юлыгып үлделәр. Менә кайчан килде миңа кара төн. Менә шунда әвәрә итеп бирегә китерделәр дә инде. Пенсионер карчык идем, ялгызым калган идем шул... Чиркәүгә барып юаныч табарга өйрәнмәгән идем... Мондагыларның күбесе, минем кебек, олы хәсрәттән миләре түнгән чакта килеп капкан да инде.

— Кире кайтыгыз соң, — диде Лениза.— Теләсәң, китәргә була, диләр бит.

— Кая кайтыйм? Фатирымны аларга яздырдым шул мин... Дөнья малы күзгә күренми торган чагым иде... Син дә шулай иттеңме әллә?

— Мин арендага гына бирдем. Бер елга...

— Слава богу! Кире алып була икән. Кызганыч, балаңның кабере монда кала. Бик еш килә алмассың инде... Ә әтисенә бүген үк хәбәр ит! Хәзер үк! Каберенә барып, рухына дога кылсын. Чардуган корсын! Таш кую ягын кайгыртсын! Якты дөньяда ятимә хәлендә иде бичара бала, рухын ятимә итмәгез! О господи, татулыкны саклый алган булсагыз, сабыегыз бүгенге көндә, мөгаен, исән-сау булыр иде!

— Ник алай дисең син, Дарья Петровна! — дип сыгылып төште Лениза.— Инде син дә шулай дигәч, баламның атасы мине кичермәячәк, беркайчан да гафу итмәячәк...

— Син миңа аның адресын бир әле,— диде Дарья Петровна.— Үзем язып карармын. Мәрхүмә хакына... Бер фотосурәтен дә бирмәссең микән?

— Нәрсәгә сезгә чит кеше баласының рәсеме?

— Ул миңа чит түгел, — дип, кулын күкрәгенә куйды Дарья Петровна. — Бәгыремә кереп калды...

* * *

Җир өстен кырпак кар каплаган болытлы бер көн кичкә авышкач, Святонинодан җәяүләп ике кеше чыктылар. Аларның берсе кара пальто кигән, башына кара шәл бөркәнгән карчык булып, икенчесе кулына юл сумкасы тоткан, күксел курткасының башлыгын каш өстенә үк шудырган ир кеше иде. Алар салмак кына тигез дала уртасында тәбәнәк бетон койма белән әйләндереп алынган мәйданга таба юнәлделәр.

Святонинонының зираты иде бу һәм аңа таба баручылар Дарья Петровна белән Мидхәт иде.

— Әнисе белән парлап килсәгез, яхшырак булыр иде,— дип үзалдына сөйләнгәндәй әйтеп куйды Дарья Петровна.— Юлны ул күрсәтер иде. Ник соң аны да алып килмәдең?

Мидхәтнең чырае ирексездән сытылды, әмма сорауга җавап биргәндә ул тавышын мөмкин кадәр йомшартырга тырышты.

— Әйттем бит инде, Дарья Петровна, күргәнем юк, дип. Әле дә биредәдер дип уйлаган идем... Сезнең хатны алгач, башыма таш килеп төшкәндәй булды. Ничек инде ул алай, баланы соңгы юлга озатырга да чакырмаган?..

Мидхәт барган жиреннән туктап, гажизлек бөркелгән карашын юлдашына төбәде. Тегесе, башын читкә борып:

— Ничек алай икәнен синнән сорарга кирәк инде, — диде уйлангандай. — Син яшәгәнсең бит аның белән. Ә без аралашмадык диярлек. Җеннәребез туры килми иде.— Бераз тынып торгач, тамагын кыргалап: — Аны да аңларга була: синнән курка ул, — дип өстәде. — Гафу итмәссең, дип хафалана...

Бу рәвешле аерым-суырым йөргәч, хәсрәтләр икеләтә авырая шул ул. Бергәләшеп күтәрсәгез, җиңелрәк узар иде.

— Ник бергәләшеп? Бөтенесе яңадан кабатлансын өченме? — диде Мидхәт, үзалдына сөйләнгәндәй тавышын әкренәйтеп.

Алар зиратка килеп җиткәннәр иде инде. Тимер капканың келәсен ачып, эчкә уздылар.

— Безнең илдә мондый зиратлар бардыр дип уйламаган идем, — диде Мидхәт. — Мондыйларны чит илләрдә сугышта һәлак булган солдатларга гына ясыйлар кебек.

— Монда да армия кебек бит. Бөтен эшнең башында Джонатан Смит әфәнде тора. Америкадан килгән. Зиратта да тәртипне ул урнаштырган.

Киң мәйдан туп-туры сузылган тар асфальт юллар белән телгәләнгән, юл кырыйларында тез тиңентен биеклектәге ташлар тезелгән иде. Чит илләрдә мондый ташлар ак мәрмәр була, биредә исә мәрмәр валчыгын цемент белән катырып ясаганнар. Һәркайсына дегеттәй буяу белән исем-фамилия, туган-үлгән еллары язылган, түгәрәкләнеп килгән өске өлешендә ниндидер сәер ак тимер тырпаеп тора. Бишпочмаклы йолдыз һәм «Нурсафлык» дигән язу... Мидхәтнең йөрәге дерт итеп куйды: Лениза Рамиләнең күлмәкләренә шундыйларның кечкенәләрен тегеп куйган иде бит!

— Моннан үлгәч тә котыла алмыйлар икән, — дип, бер кабернең тимеренә җиңелчә сугып куйды Мидхәт.

— Менә монда, — дип, юлның сул ягындагы кызгылт балчык өеменә ымлады Дарья Петровна.

Монысына әле таш куеп өлгермәгәннәр, озын, тар борыс кына тырпаеп тора. Ә менә борыс очына теге кahәр суккан тимерне беркетергә онытмаганнар! Астарак кәкре-бөкре хәрефләр: «Рамиля Мидхатовна Халикова» дип язылган һәм нибарысы ике ел ярымны эченә сыйдырган саннар куелган.

Алай да бу кабернең башкалардан аермасы бар иде: борыска кечкенә генә пыялалы рам белән мәрхүмәнең фотосурәте беркетелгән.

— Анысын мин куйдым, — диде Дарья Петровна. — Кешечә булсын, дидем. Ярыйдыр бит?..

— Рәхмәт сезгә, Дарья Петровна...

— Мин монда еш киләм... Ятимә булып ятмасын дим. Сөйләшәм, серләшәм... Гомеренең соңгы минутларын минем кулларымда үткәрде бит ул! — дип, җыерчыклы учларын Мидхәткә таба сузды карчык. — Үз балам кебек ул миңа! Монда минем аннан да якын бүтән беркемем юк!

Һәм карчык, пәлтә кесәсеннән кулъяулык алып, күз яшьләрен сөртте.

Мидхәт сумкасын җиргә куйды да борыска беркетелгән тимер тамганы көч белән тарткалап карады.

— Юкка азапланма, — диде Дарья Петровна. — Ямьсезләрсең генә. Биредә бөтен эшне җиренә җиткереп башкаралар. Киләсе елга ташны үзең теләгәнчә куярга рөхсәт сорарсың. Каршы килмәсләр, бәлки.

Мидхәтнең куллары салынып төште. Ул, хәле киткәндәй, авыраеп, сумкасы өстенә утырды. Аның ялгызы каласы килә иде.

— Мин китим инде. Сау бул, — диде карчык.

— Хушыгыз. Рәхмәт сезгә...

Кабер өстендәге бозлы балчык өстенә җил каяндыр сары яфрак китереп ташлады. Өрәңге яфрагы... Әллә күкләрнең күз яше микән?

Нишләргә? Бәгырьне баскан бозлы кантарны ничек эретеп, сулышны ничек җиңеләйтергә? Бармы андый җылы сүзләр? Менә кайчан кирәк икән Аллага ышану, догалар белү... Мондый чакларда адәм баласын башка беркем дә юата алмый, дога укудан башка бернинди гамәл дә җиңеллек китерә алмый...

Мидхәт әнисе өйрәткәннәрне, әтисе укыганнарны исенә төшерергә тырышты. Әмма «бисмилла» белән «Аллаһы әкбәр»дән башкасы хәтергә килмәде. Моңарчы аның иман хакында, дингә ышану-ышанмау хакында тирәннән уйланганы юк иде. Әлбәттә инде, яшәүнең асыл мәгънәсе, гомернең чиге турындагы уйлар һәр кешенең башына килми калмый. Ләкин аларның очына чыгып булмый, шуңа күрә Мидхәт мондый газаплы уйлардан мөмкин кадәр тизрәк арынырга тырыша иде. Ул үзен мөселман саный, ләкин, асылда, Аллага чын күңелдән ышанам, дип тә раслый алмый иде. Алда гомер озын булып тоела, бу мәсьәләне ныклап хәл итәргә вакыт җитәр иде шикелле.

Минуты исә һич көтмәгәндә килде дә җитте. Нишләргә? Нинди гамәл кылырга? Нинди сүзләр әйтергә?

Мидхәт, шушы сорауларга җавап эзләп, агач борыска беркетелгән фотосурәткә төбәлде. Рамилә аңа нәрсәдер өмет иткәндәй, ниндидер соравына җавап көткәндәй мөлдерәп карап тора иде. Хәер, соравы аңлашыла бит инде: «Ник? Ни өчен? — дип сорый ул. — Нилектән минем гомерем өзелде?»

Әллә... гаеплиме ул? «Ник мине саклап калмадың?» — дип сорыймы? Ә бәлки: «Саклап, кадерләп үстерерлек булмагач, ник мине бу дөньяга чакырып китердең?» — ди торгандыр.

Кинәт Мидхәтнең битенә, беләкләренә, күкрәгенә җылы бәрелгәндәй булды. Рамиләне кочагына алып, сак кына кыскач, яңагын аның башына куйгач, шулай була торган иде. Аның тәненнән килгән

татлы ис искә төште. Нинди йомшак һәм нинди нәни иде бит ул! Әтисе аңа бик зур, гайрәтле, ышанычлы булып тоелгандыр. Әйе-әйе, ул Мидхәтне Алла урынына күргәндер. Уйлап карасаң, чыннан да шулай бит! Бу җан иясен Мидхәт бар итте... Һәм аны исән-сау үстерү, бәхетле яшәтү дә аның көченнән килә иде.

Асылда, Мидхәт аның өчен яшәде дә бит! Ул яшәячәк дөнья яхшырак, матуррак булсын, анда фейерверклар ешрак балкысын, эш-гамәлләр җиңелрәк башкарылсын өчен тырыша бит ул.

— Кызым, — дип пышылдады Мидхәт, сурәткә карап. — Син үскәч, һәммәсен сөйләгән булыр идем. Ул чакта үзем дә зур кеше булачак идем, син минем белән горурланачак идең. Мин шул көннәрне көтеп яшәдем, эшләдем... Болай буласын белмәдем шул, балам...

Мидхәт күз яшьләрен куртка җиңе белән сыпырып алды. Һәм гафу сорап янә фотосурәткә текәлде. Һәм тагын тетрәнде: сабыйның күзләреннән яшь агып чыккандай тоелды. Моңарчы күрмәгән генә, чыннан, аның күзләреннән аска дым эзләре сузылган иде...

Акылы белән ул моны шундук аңлады: рам астына яңгыр үткән иде булса кирәк. Ә менә йөрәк сызланды да сызланды.

Әйе, бу бала өчен ул чыннан да Алла урынында иде. Ләкин үзе моны аңлый идеме соң? Бу сабыйны дөньяга чакырганда ул үз җаваплылыгын тоя идеме? Мидхәтнең күз алдыннан Рамиләнең бөтен гомере чагылып узды. Бу гомер анадан туган минуттан түгел, аннан шактый элегрәк башланды бит. Тулай торакта Лениза белән бергә үткәргән төннән... Юк, аннан да элегрәк, ул кызны үзенә артык якын китереп, анда яшерен өметләр уяткан айлардан... Уйладымы соң ул шул чакларда дөньяга киләчәк яңа җан — Рамилә турында?

Кичер, балакаем! Кичер мине!..

Син туар вакытка тиешле шартлар булдыра алмаган идем шул... Мидхәт Рамиләне ничек итеп ятимнәр йортына илткән иртәне исенә төшереп сискәнде.

Лениза белән ызгышкан-талашкан көннәрдә ниләр кичергән бу бала?.. Әгәр Алла урынында булган икән, ул сабыен андый газапларга дучар итәргә тиеш түгел иде бит!

Ә соңыннан, эш белән мавыгып, анасы янындагы балага, ул-бу булмас дигән ышаныч белән айлар буе юанып йөрүе тагын... Үз янында булса, Мидхәт аны саклап калган булыр иде бит...

Үкенечләргә чыдап булыр әмәл калмады. Мидхәт башын күтәреп күккә карады. Йа Алла! Әгәр чыннан да бар икәнсең, син гадел хөкем итмисең! Бу кабердә Рамилә түгел, Мидхәт ятарга тиеш иде!

Вөҗдан газапларына күкрәк читлеге шартлап ярылыр кебек иде.

Бу газаплар күкләргә барып ирешми микәнни?

Әмма күкләрне болыт пәрдәсе сарган иде.

Мидхәт чытырдатып күзләрен йомды. Онытылырга, онытылырга, тәмам юк булырга...

Күпме шулай утыргандыр, ниндидер ым булыпмы, салкын җил бәрепме, ул күзләрен ачты. Кояш баешы ягыннан болыт пәрдәсе ертылган, аннан күк гөмбәзе буйлап кызгылт-сары нур тасмалары сузылып яткан иде. Гүяки алар кемнәндер хәбәр алып килгән, каядыр юл күрсәтәләр иде кебек.

— Кичер, кызым!..

Ул сумкасын алды да капкага юнәлде. Аннан чыккач, нур тасмалары күрсәткән якка таба атлады.

* * *

— Ул кайтты,— диде Әнисә.

— Кая? Юк ич беркем дә, — диде Әлифә.

— Шалтыратырга хәле юк аның, — диде Әнисә. Һәм барып ишекне ачты. Баскыч мәйданчыгындагы лампочкаларны гел борып алып торалар, шунлыктан караңгы иде. Әнисә диварга сөялеп торган шәүләне сулышыннан таныды.

— Исәнме, Мидхәт абый. Кер әйдә. Без монда сине көтә-көтә көтек булдык инде.

Әлифә Мидхәтнең күгәренгән чыраен, нурсыз күзләрен күреп куркып китте:

— Син каян болай?

— Зираттан... Аның кабереннән...

— Әйтәм аны, Әнисә ничә көн инде үзенә-үзе урын табалмый... Димәк, дөрес?

— Яшен сукты мине, Әнисә... — диде Мидхәт, хәсрәтле елмаеп. — Йортымны яндырды, бәгыремне көйдерде... Синең каршыңда коры кабык кына басып тора...

— Бала хәсрәтеннән ачысы юк, диләр, алай да, Мидхәт, бу хәтле бетеренмә әле, — диде Әлифә. — Яшь бит әле син, тәнеңдә бу дөньяга киләсе яңа җаннарның яралгысы бар. Алар хакына үзеңне сакларга кирәк.

— Әйдәле, Мидхәт абый, сал өсләреңне,— диде Әнисә.— Менә шулай. Кил әле, утыр менә бу урындыкка. Заманында син мине үлемнән коткарып калган идең... Ул көнне мин җыйган җиләкнең тәмен онытмадыңмы әле?

— Әле дә телемдә, Әнисә...

— Мин аның сиңа буласын белгән идем... Шуңа иң эреләрен, татлыларын гына өзгән идем...

— Син мине ул чакта белми идең бит әле!

— Иң якын кешем белән очрашасымны күңелем сизгән иде...

Мидхәт, башын күтәреп, аның тылсымлы тамга салынган уйчан да, чак кына елмаюлы да йөзенә, якты, серле күзләренә төбәлде. Әнисә үзе сөйләнә, үзе аның башы тирәли кулларын йөртә иде.

Бераздан ул Мидхәтнең йөзенә нур иңеп, күзләре яктырып киткәнен күрде дә, җиңел сулап:

— Әлхәмделлиллаһи раббил галәмин, — дип куйды.

Мидхәт, гаҗәпләнеп:

— Син андый сүзләр дә беләсеңмени әле? — дип сорады.

— Апа өйрәтә.

— Һәм ышанасың дамы?

— Ышанам. Ходай Тәгаләгә инану иң элек кальбеңдә булсын, ди. — Әнисә кулын йөрәк турына куйды. — Апа әйтә, иман безгә тән кебек, җан кебек, исем кебек үк ата-бабалар тарафыннан бирелгән, ди. Аны ихластан кабул итеп инану тиеш, ди. Ходайга ышану ул мәхәббәт кебек бит. Чынлап сөйсәң, яраткан кешеңнең гаебен эзләмисең, ничек бар, шулай кабул итәсең, диләр. Бернигә карамый инанырга кирәк...

Гади генә сүзләр Мидхәтнең күңелендәге авыр ташны кузгатып, җиңеләйтеп җибәргәндәй итте. Әйе, чыннан да, яратырга кирәк. Инанырга кирәк. Икеләнмичә-шикләнмичә яратырга, инанырга. Яратмыйча, инанмыйча яшәү яшәүмени ул?!

2005 — 2006

Шәфкать

Беренче бүлек

Тынлы оркестр уйнаган дәртле марш авазы, иркен, биек залга сыеша алмыйча, коридорларга ташып чыкты. Бүген монда яшь табиблар ант бирергә җыелган иде.

Залның ике ягындагы тар, биек тәрәзәләр артында яшьләрнең кузгалган күңеледәй тынгысыз җил куе өрәңге ботакларын тибрәлдерә. Тәрәзәләрдән өстә, түшәм астында ук диярлек, бөек табибларның портретлары эленгән. Күбесе сакаллы, кырыс чырайлы, карашларын залдагыларның баш очыннан каядыр еракка төбәгәннәр, әйтерсең лә үзләренә генә мәгълүм олы бер хакыйкать турында уйлыйлар. Аларның мәгърур кыяфәте Зәйтүнәнең күңелен шомландырып җибәрде: бу дәһиларга тиңләшү — табиб булу — гади адәм баласы өчен мөмкин эш микән?

— Зюзю, карале, нинди гладиолуслар! — дип төртте Зәйтүнәгә уң ягында утырган Лариса.

Ике кыз рәтләр арасыннан чәчәкләр тулы ләгән күтәреп бара иде. Менә алар биек сәхнәгә менделәр, кызыл бәрхет җәелгән озын өстәлдәге бәллүр савытларга гладиолусларны бүлеп утыртып куйдылар. Лариса, муенын сузып, урыныннан кузгала төшеп, аларны күзәтте. Ул бүген һәммәсен уздырган — капрон халат кигән. Эчтән чәчәкле күлмәк бизәкләре аермачык күренеп тора. Кечкенә ак башлыгы җирәнсу вак бөдрәләренә эленеп кенә куелган. Гадәттә бик пөхтә, килешле киенә Лариса, әмма берәр урында чак кына төгәлсезлек калдыра: йә өске сәдәфен эләктерми, йә якасын күтәреп куя. Бүген дә шулай: халат җиңнәрен терсәгенә кадәр сызганган. Башка берәүгә ятышып та бетмәс иде, бәлки, ә менә Ларисага мондый төгәлсезлек тә ямь өстенә ямь генә биреп тора! Ул озын, кызыл тырнаклы бармаклары белән канәфер чәчкәләрен бөтерә, атсыз бармагындагы балдагы елык-елык килә. Кызлар барысы да бертөсле ак халаттан, әмма игътибар белән караганда, киемнәрендә аермалык та сизелә: Кифаяның әнә итәгендә юылып бетмәгән марганцовка таплары бар, ә Вера башлыгына кызыл җеп белән медицина эмблемасын — озын аяклы савытка уралган елан сурәтен чигеп куйган...

Кинәт оркестр тынды, залда тирән сулыш алуга охшаш «ш-ш-ш» дигән аваз ишетелде. Ишектән пөхтә костюмнар кигән бер төркем кеше кереп, сәхнәгә таба юнәлде.

Яшьләрнең остазлары, галим-табиблар иде болар. Иң алдан сәхнәгә ачык коңгырт костюмы өстенә ак кофтасының киң якасын чыгарып салган, күперенке кыска чәчле ханым — профессор Ильясова күтәрелде. Елмая төшеп, залга җиңелчә генә баш иде, борылып, янындагы ирләргә нидер әйтеп алды, тегеләр елмаешып җавап бирделәр. Ир-ат арасында алар белән бертигез дәрәҗәдә озак еллар эшләгән хатын-кызлар, кагыйдә буларак, кыяфәтләре белән дә, үз-үзләрен тотышлары белән дә

тупасланып, кырысланып китәләр. Җәмилә Закировна исә бу йогынтыга бөтенләй бирелмәгән иде. Сәхнәдә, алсу-кызыл гладиолуслар артында, ул, көмеш йөзек кашындагы асылташ төсле, бар карашларны үзенә җәлеп итеп торды. Бу минутта аның хакында һичкем илле сигезе тулган дип уйламас иде.

Тантаналы җыелыш барысының да аягүрә басып байракларны каршы алуыннан башланды. Уртача буйлы, каратут йөзендә зур күзлеге һәм саллы ияге күзгә бәрелеп торган ректор, трибунага менеп, йомшак, ләкин буйсындыручан тавыш белән яшьләрне диплом алып мөстәкыйль тормышка аяк басулары, үзенчә әйткәндә, «безнең коллегаларыбыз булу белән» котлады.

Ниһаять, ант кабул итү минуты килеп җитте. Ректорның салмак, тантаналы тавышы диварларга бәрелеп яңгырый, ерак гасырлардан килгән, бу җиһандагы барча табиблар өчен мөкатдәс булган сүзләрне — Гиппократ антын — яшьләрнең күмәкләшеп кабатлаганын биектәге даһилар да тыңлый иде кебек.

«Табиб Аполлон, Асклепий, Гигия, Панацея белән ант итәм...» — «Ант итәм!..» — дип, тыенкы тавыш белән башкаларга кушылып кабатлады Зәйтүнә. «Ант!..» — диделәр кебек кырыс даһилар. «Табиблык сәнгатенә өйрәткән остазларымны атам-анам белән бертигез итеп күрермен...» Бу сүзләрне Зәйтүнә сәхнәдә, кызыл гладиолуслар артында басып торган профессор Ильясовага карап пышылдады. «Хасталарга һәртөрле зыян салудан һәм гаделсезлек кылудан тыелырмын... Гомеремне саф һәм керсез үткәрермен... Кайсы гына йортка керсәм дә, мин анда хасталарга ярдәм итәр өчен керермен, алдан уйланган гаделсезлекләрдән, зарарлы гамәлләр кылудан тыелырмын... Бигрәк тә хатыннар һәм ирләр белән гыйшык уены уйнаудан сакланырмын...»

Зәйтүнә белә иде бит бу сүзләрне, күптән белә, ләкин нигә алар бүген болай тантаналы яңгыраганда күңелгә утлы күмер булып төште соң әле? Гашыйк булу, мәхәббәт утында яну гаеп эшмени?..

«Сер булып сакланырга тиешле ни генә белсәм дә,— дип яңгырады ант сүзләре,— мин аны һичкемгә фаш итмәм. Бу антыма какшаусыз тугрылык саклаган өчен миңа тормышымда һәм сәнгатемдә кешеләр арасында бәхет һәм мәңгелек дан килсен, антын бозган яисә ялган ант биргәннәргә исә моның киресе булсын!»

Соңгы сүзләр дәһшәт белән яңгырагандай булды.

— Ант итәм! Ант итәм! Ант итәм! — дип гүләде зал.

Утыргычларны шыгырдатып, урыннарга утырдылар. Остазлар шәкертләргә соңгы теләкләрен әйтә башлады.

Доцент Дәүләтшин торып баскач, залдагыларның башлары тагын да югарырак күтәрелде, күзләр киңрәк ачылды. Изаил Харисович турында студент кызлар тыныч кына сөйләшә дә алмый иде. Аның кара чәчләре астыннан агарып күренгән киң йөзеннән гүяки кызларның күзенә нур бөркелде.

Ул, трибуна артына барып баскач, йөзен тәрәзәгә, яктыга борды, гүяки үзе белән сокланырга күбрәк мөмкинлек тудырды.

— Сез яшьләрнең күңеленә изге чаткы салу өчен без кулдан килгәнчә тырыштык, — дип елмаеп башлады ул сүзен. Аның ягымлы калын тавышы шулкадәр көчле иде ки, артык каты яңгырамасын өчен, тыелыбрак сөйләргә туры килә иде кебек. Бу кешенең бөтен кыяфәтеннән үз-үзенә ышаныч, егетлек, көч-гайрәт бөркелеп тора иде.

— Көчле! — диде Лариса, аннан күзләрен ала алмыйча. — Кызганыч, безнең группаны укытмады. Шулай бит, Зюзю?

Ә доцент залдан күтәрелгән соклану дулкынын тоеп тора, алай гына түгел, бу дулкында ләззәтләнеп тирбәлә иде.

— Инде хәзер бу чаткыны учакка әверелдерү сезнең үз кулыгызда. Иманым камил, сезнең арадан да медицина күгендә йолдыз булып балкырлык кешеләр үсеп чыгар әле!

Кызлар учларын кызганмыйча кул чабарга керештеләр. Профессор Ильясовага шул алкышлар яңгыраганда трибуна артына барып басарга туры килде.

Залның тынычланганын сабыр гына көтте ул. Йөзенә яктылыкның ничек төшкәнен дә уйламый-чамаламый, тавышы да Дәүләтшиннан соң шактый зәгыйфь, нечкә булып тоелды, шыбырдашып утырган яшьләрнең күбесе Җәмилә Закировнаның беренче әйткәннәрен ишетми дә калды шикелле. Ләкин ихласлык, йөрәк түреннән чыккан хис бар иде профессор Ильясованың кыяфәтендә һәм тыныч тавышында. Зал аны яхшырак ишетү өчен ихтыярсыздан тынып калды, дикъкатен туплады.

— ...Студентларга соңгы фатихамны биргән саен, мин үземнең остазымны искә төшерәм. Безнең институт белән хушлашуыбыз бүгенге тантанага охшамаган иде. Без соңгы имтиханны да тапшыра алмадык хәтта. Дипломны безгә ансыз гына бирделәр.

Кифая, Ларисага таба сузылып:

— Безгә дә шулай гына итәселәре калган! — диде.

— Ватан сугышы башланган көннәр иде,— дип дәвам итте профессор.— Күбебез фронтка китәргә ашкына. Безнең карт укытучыбыз трибунага менде дә: «Газизләрем! Мин сезгә бер генә нәрсә

телим! Исән-сау әйләнеп кайтыгыз!» — дип елап җибәрде. Мин бик бәхетле, чөнки шәкертләремә андый теләк теләргә туры килгәне булмады. Тыныч дөньяда эшләргә язсын, дип телим мин бүген. Без болай да аяусыз көрәштә. Кешелекнең явыз дошманнары белән көрәшнең алгы сызыгында без. Мин сезгә бу фронтта җиңүләр телим! Бәлки, һәр җиңүегез өчен күкрәгегезгә орден да такмаслар, әмма табибның җиңүе ул — кеше гомерен саклап калу дигән сүз! Моннан зур бүләкнең булуы мөмкин түгел. Табиб исеме ул — үзе зур бүләк. Балаларын зур тормыш юлына озатканда, аталар болай диләр: мин сиңа фамилиямне бирдем, исемне үзең яулап ал. Ә мин, без сезгә белем бирдек, табиб исемен үзегез яулап алыгыз, дип әйтәм. Кешеләрнең газапларын җиңеләйтүдән куаныч табып яшәгез, бәхетнең иң зурысы шул.

Зал алкышларга күмелде.

— Сихерче! — диде Лариса, соклану катыш көнләшү белән.

***

Тантана тәмамланып, байракларны озатканда, кинәт сискәндереп, зал артындагы оркестр уйнап җибәрде — җиз тәлинкәләр зеңгелдәп бер-берсенә бәрелде, трубалар чыңлап куйды һәм янә дәртле марш башланды.

Ректор, башын чак кына ия төшеп, профессор Ильясовага юл бирде. Җәмилә Закировна зал кырыеннан ишеккә таба юнәлде, башкалар аңа иярде. Ул җиңел адым белән атлап бара, тәрәзәдән төшкән кояш тәңкәләре аның күперенке чәчендә ялтырап китә, йөзендә исә куаныч катыш ямансулык чагыла иде. Оясыннан балаларын очырган кош ямансулыгы иде бу.

Коридорга чыккач, ул ректорга таба борылды.

— Минем сезгә сүзем бар иде, — диде.

— Рәхим итегез, Җәмилә Закировна. Теләсәгез, хәзер үк сөйләшергә мөмкин.

Алар тукталып торган арада, башка галимнәр ары узып китте, иң ахырдан доцент Дәүләтшин атлап килә иде. Җәмилә Закировна карашы белән аны озатып калды.

Әнә ул пөхтә, килешле зәңгәр джинсы костюмы аркылы мускуллары сизелеп торган атлет гәүдәсе белән коридорны иңләп бара, пинжәк якасы өстеннән, тар сызык булып, күзне камаштырырлык ап-ак күлмәк якасы чыгып тора, бу сызык аның чәчен тагын да карарак итеп күрсәтә. Каршы килгән студент кызлар, ул узып киткәч, барыр юлларын онытып, үзара пышылдашып калалар, аларның шыпырт тавышында, алланган бит очларында соклану, олылау ярылып ята.

Сокланмый мөмкин дә түгел шул доцент Дәүләтшинга! Аның очарга талпынган бөркет кебек чак кына алгарак авышкан төз сынында, коңгырт ботинкалары белән паркет идәнгә нык басып баруында ук көч, көне-ае белән арта барган гайрәт сизелә. Биек, иркен коридорны кысанлап, ашкынулы адым белән киләчәк үзе барадыр шикелле.

Аның артыннан җиңел, тавышсыз гына атлап килгән җыйнак гәүдәле профессор Ильясова, үсеп-ныгып җиткән, уңган һәм батыр улына карап куанган ана шикелле, эчке горурлык хисе кичерә иде. Адым саен гайрәте арта барган бу егет аның — профессор Ильясованың шәкерте бит!

Дәүләтшин баскычтан борылганчы, Җәмилә Закировна аның артыннан каерылып карап калды.

Кабинетына кергәч, ректор «Т» хәрефе ясап куелган өстәлләрнең түрдәгесе артына — үз урынына түгел, ян өстәл кырыена барып басты, ишарә белән каршысыннан профессорга урын күрсәтте.

— Бер атнадан мин китәм бит инде,— диде Җәмилә Закировна, икесе дә утыргач. Аның совет хатын-кызлары комитеты делегациясе составында гарәп илләренә барачагын ректор белә иде инде. Гажәпләнерлек вакыйга түгел, профессор Ильясова чит илләрдә булгалый, моннан ике ел элек ул, мәсәлән, Вьетнамга барган иде.

Бүлмәдә беразга тынлык урнашты, ачык тәрәзәдән агачлар тавышы ишетелде.

Алар дистә еллар буе бергә эшлиләр һәм бер-берсен якын итәләр иде. Мондый очракларда, ягъни Җәмилә Закировна берәр йомыш белән башкалага барганда — бу юлы да ул ике-өч көнгә Мәскәүдә тукталачак — ректор аңа бик мөһим йомышлар кушып җибәрә торган иде: министрлыкка керергә, ВАКка сугылырга, кайбер галимнәрне күреп сөйләшергә... Ахыр чиктә таныш-белешләренә сәлам күндерә иде.

Җәмилә Закировна сораулы карашын әңгәмәдәшенең күзлегенә төбәде. Күзлек пыяласында чалшаеп тәрәзә чагыла иде. Ректор, аның тел төбен аңлап, чак кына көлемсерәде:

— Атна-ун көннән Мәскәүгә Изаил Харисович та барачак. Аналарның һәм балаларның сәламәтлеген саклау институтына бер-ике атнага командировка сорый. Алар белән алдан сөйләшеп куйган, барысын да җайлаган. Молодец егет сезнең ул шәкертегез, Җәмилә Закировна! Өр-яңа өлкәдә эзләнүләр алып бара. Фәнни конференцияләрдә төпле чыгышлар ясый, зур галимнәр белән кыю сөйләшә. Теләсә нинди авыр мәсьәләне ерып чыгарлык егет!

Җәмилә Закировна ректорның әйтми калган сүзләрен эченнән дәвам итте: «Безнең йомышларны да бик яхшы итеп үти».

Профессор күңелендә ихтыярсыздан кузгалган көнләшү хисен тыярга тырышты: «Бигрәк яхшы, миңа артык мәшәкать булмас...»

Ректор бераз тынып торды да, тагын телгә килде:

— Ә шулай да Дәүләтшинны кафедрадан җибәреп хата эшләдегез, ахрысы, сез, Җәмилә Закировна. Үзегезгә менә дигән алмаш булачак иде.

— Төрле казанда кайнап чыныгу яшь кеше өчен файдалы дип саныйм мин үзем.

Җәмилә Закировна сер бирмәскә тырышты, әмма ректор аның яшерен ярасына кагылган иде. Әйе, Дәүләтшин Ильясова кафедрасында үсте, кандидатлык диссертациясен аның кул астында яклады. Тик моннан бер ел элек институтның шул ук профильдәге икенче кафедрасына күчте ул. Бу карарын: «Мин сайлаган тема белән шөгыльләнү өчен мөмкинлекләр анда күбрәк»,— дип аңлатты. Профессорның сәләтле шәкертен бер дә җибәрәсе килмәгән иде югыйсә...

Ильясова ректор яныннан чыкканда, Изаил Харисович кабул итү бүлмәсендә секретарь кыз белән сөйләшеп тора иде. Башын күтәреп, профессорга карагач, аның йөзе кинәт үзгәреп китте, күзләрендә сагаю чагылды.

— Изаил Харисович, минем сезгә бер авыруны күрсәтәсем килгән иде,— диде Җәмилә Закировна.

— Ярдәмем тиярлек булса, бик шатмын, Җәмилә Закировна. Берәр якын кешегезме әллә?

— Юк, миңа беренче килүе. Ярдәм сорап хат язган иде дә җавабымны алуга килеп тә җиткән. Үзбәкстаннан. Диләрам исемле бик сөйкемле кыз.

— Әгәр теләсәгез, мин сезнең клиникага килермен.

— Мин аның үзен сезгә җибәрә алам. Вакытын гына әйтегез.

Авыруның диагнозы, очрашу вакыты турында сөйләшкәндә, Җәмилә Закировнаның башына һич көтелмәгән бер уй килде: икенче кафедрага күчкәннән бирле, доцент Дәүләтшинның бер генә мәртәбә дә ярдәм сорап профессор Ильясовага мөрәҗәгать иткәне булмаган икән.

***

Кемдер аның бит очын назлап сыйпый иде шикелле, Зәйтүнә шул назга елмаеп уянды, берара, керфекләрен күтәрергә иренеп, назның кабатланганын көтеп ятты. Ниндидер татлы төш күргән кебек иде, тик онытылган, күңелдә сөенечле хис кенә калган. Ул, йөзенә төшкән кояш нурыннан башын борып, күзләрен ачты. Төшеннән бигрәк өне сөенечле бит аның. Әнә өстәлдә, чәчәкле клеенка өстендә, зәңгәр катыргы — диплом ята, аның янындагы пыяла савытта канәфер чәчкәләре. Урындык аркасына ак күлмәк эленгән, ак туфлиләр идән уртасында тәгәрәшеп яталар. Тулай торакның бер бүлмәсендә оештырылган тантана мәҗлесе көн яктыргач кына таралды. Киемнәрне урынына куярга да хәл калмаган иде. Бу күлмәк белән туфлиләр элегрәк Зәйтүнәнең гомерендә бер генә була торган зур бәйрәменә шаһит булганнар иде инде — ул туена да шуларны киде. Кызлар чыгарылыш кичәләренә дә, туйларына да актан киенәләр. Иң тантаналы, иң истәлекле көннәрендә алар — ап-ак. Ә менә табиблар һәр көн актан йөри. Әллә соң аларның гадәти, гади көннәре булмый да микән?

Актан киенеп, ике тапкыр ант бирде Зәйтүнә. Беренчесендә — гомеремне иремә, туачак балаларыма багышлармын, дип. Икенчесендә — акылымны, сәләтемне, тырышлыгымны кешеләрне авырулардан саклау эшенә бирермен, дип.

Ике төрле яшәеш, ике дөнья өчен бик тә җаваплы кеше ул хәзер. Аның берсе — Әнвәр, мәхәббәт белән яктыртылган өй, икенчесе — авыруларның зары тулы хастаханә. Беренчесендә ул — хатын һәм... ана да булачак бит әле. Ә икенчесендә ул бүгеннән — табиб. Бу ике дөньяны бер күңелгә сыйдыру мөмкин микән?

Зәйтүнә торды да дивардагы түгәрәк көзге каршына басты. Бүгеннән ул — дәвалаучы табиб, кешеләр аңа өмет һәм ышаныч белән текәләчәкләр. Ләкин аның кыяфәте ул өметләрне акларлык булып күренәме соң?

Урта буй, нечкә сын. Бу хәлендә, төнге күлмәктән чакта, бала сымак кына булып күренә, ак халат кигәч кенә бераз җитдиләнеп китә. Ә менә йөз... түгәрәк ак йөз, нечкә сары кашлар, зәңгәр күзләр, турсаебрак торган иреннәр... Ирен читендәге миң тагын... Чәчне кистереп, Лариса киңәш иткәнчә бөдрәләтеп җибәрсәң, олы сымаграк булып китәр идең китүен дә... Әмма Әнвәр рөхсәт итми. Зәйтүнә үзе дә ир хатыны булган кеше аның әнисе кебек, чәчен толымлап үреп йөрергә тиеш, дип саный. Кайбер халыкларда шундый йола да бар бит: кызлар бер төрле йөртә чәчен, ә хатыннар икенче төрле... «Карурманда адашкандай чәчләреңдә адаштым», — ди аңа Әнвәре.

Их, ник кенә китте соң әле ул әллә кайларга, нигә бүгенге көндә шул адашкан хәлендә Зәйтүнәсе янында түгел? Ул да ике төрле дөньяда яши шул. Аның икенче дөньясы — эше, парниклар хуҗалыгы.

Инженер Уразов ул хуҗалыкта теплицалар кору турында хыяллана. «Нефтьчеләр торба бирергә вәгъдә иттеләр әле, Зәйтүнгөл, тизрәк барып алырга кирәк».— «Тимер-томыр качмас, бер-ике көнгә соңрак барсаң да»,— дигән иде аңа Зәйтүнә. «Андый затлы малны яткыралармы соң! Эләктереп кала алсаң, бик шәп инде. Ике көннән кайтам мин, сагынып көтеп тор!»

Ник кирәк ул тимер торбалар? Карурманнарда адашкан кебек, мәхәббәт бакчаларында адашып кына яшәп булмас идемени, шушындый көннәрдә генә булса да?

Ә Зәйтүнә үзе Әнвәрнең күзенә генә карап торыр иде.

Ләкин... медицина дөньясы булмаса, ул Әнвәрне очрата да алмаган булыр иде. Минзәләдә медучилище тәмамлап, авылда өч ел эшләгәч, монда Казанга килмәгән булса... Табиб булу теләге монда китерде аны һәм мәхәббәтен дә ул шушында тапты.

Уку Зәйтүнәгә җиңел бирелә иде. Башкаларның үзәгенә үткән анатомия, хәтта латин да бер-ике кабатлауда истә кала, шигырь кебек ятлана иде. «Aliis inserviendo consumor»,— дип кабатларга ярата ул борынгы бер табибның сүзләрен, ягъни «Башкаларга якты булсын өчен, янып көл буламын».

Фәнни түгәрәкләргә йөрү, концертларда катнашу да аз тоела, күңел каядыр ашкына иде. Аэроклубта парашют белән сикерү түгәрәге барлыгын ишеткәч, ул кабынып китте, башка кызларны да үзе белән барырга үгетли башлады. «Азабың көчәйгән икән»,— диде Лариса. «Андый шөгыль ихтыярны ныгыта, ә табибка ихтыяр көче бик кирәк». Лариса Зәйтүнәнең бу сүзләренә кул гына селтәде.

Аэроклуб университет каршындагы иске бинада иде. Зәйтүнә анда ят егетләр, ят кызлар арасына ялгызы барып керде.

Парашют белән сикерү өчен алдан өч ай укырга кирәк икән. Укытучысы инструктор дип атала, ул укучылары кебек үк студент егет, аны барысы да Әнвәр дип кенә йөртә иде. Башта Зәйтүнә аны терекөмеш тамчысына охшатты. Бер аймы, ай ярыммы узгач, бөдрә чәчле, үткен коңгырт күзле бу татар малаеннан күңелгә җылы нур иңгәне сизелә башлады. Зәйтүнә аны нур шәүләсенә тиңли торган булды. Була бит шундый якты тап, әллә каян гына диварга килеп төшә дә «тот мине, тот» дип үчекли башлый. Син кул сузуга читкә сикерә үзе.

Сабакны да үртәгәндәй көлемсерәп кенә аңлата иде ул. «Парашют баулары бутalса, аларны кискәндә, пычакның йөзен үзегезгә каратып тотмагыз, югыйсә башыгыз җиргә үзегездән алда килеп төшәр». «Инде барысы да тәртиптә икәненә ышангач, парашют бауларына җайлап утырыгыз да туган илнең гүзәллегенә карап хозурланыгыз». Алдан да, арттан парашют таккан Зәйтүнәнең зал кырыендагы кечкенә самолет кабинасына керә алмыйча азапланганын күзәтеп торганда, ул, башкаларга карап: «Күккә менгәч, кабинадан чыгуы авыр түгел, кире кереп утыруы тагын да җиңелрәк, — дигән иде. — Кайберәүләр самолетның канатыннан кабинасына ничек кереп утырганын сизми дә кала. Дөрес, кызлар арасында андыйларның моңарчы булганы юк иде әле. Алар, күрәсең, күккә менгәч тә кабинага авырлык белән керә. Бәлки, сезнең арадан берәр елгыры табылыр?». Һәм ул Зәйтүнәгә шундый итеп көлемсерәп карап куйды, әйтерсең лә нәкъ менә аның бу «елгырлыкта», асылда куркаклыкта кызлар арасыннан беренче буласына ышана иде.

Утызлап кеше укып йөргән иде, аэродромга Зәйтүнә берүзе барып иреште, чөнки анысына бик зур үҗәтлек кирәк булып чыкты. Аэроклубның чибәр, әмма чытык чырайлы табибы Зәйтүнәнең авызын ачтырып карады да:

— Сиңа күккә менү турында түгел, җирдә яхшылап дәвалану турында уйларга кирәк, — диде.

Чыннан да, ул чакта Зәйтүнәнең тамагы авыртып тора иде.

Ләкин бу каршылык кына аны туктата алмады. Сикерүнең үзеннән дә бигрәк нур шәүләсенә охшаган егетнең үртәп әйткән сүзләре үҗәтләндергән иде аны.

Үзе урынына табибка барырга Ларисаны күндерү җиңел булмады булуын. Зәйтүнә аңа атна буе тәмле ризык пешереп ашатты, сирәк очрый торган китаплар табып бирде.

— Врач миңа, парашютсыз да сикерә аласың, дип әйтте, — дип мактанып кайтты Лариса аэроклубның медпунктыннан.

Бу минутта ул үзенең ни югалтканын белми, Зәйтүнә дә нәрсә тапканын аңлап җиткерми иде әле. Ул фәкать ихтыярын чыныктыру, Әнвәр каршында үзенең куркак түгеллеген раслау хакында гына уйлый иде.

Әйе, очкычтан сикерү чыннан да бик куркыныч эш булып чыкты. Аны күккә алып менәргә тиешле очучы егетләрдәй ник бәдәнле, урта яшьләрдәге хатын булып чыкты, ул, Зәйтүнәне күрүгә, җилдә каралган йөзен чытып куйды. Парашютлар авырлыгыннан алга бөгелеп, тупас ботинка башлары белән чирәмне тырнап көч-хәл атлап килгән кызның кыяфәте аңа бөтенләй ошамады, күрәсең. (Бу зур ботинкаларны Зәйтүнәгә аэродромда кигерделәр, босоножкалар белән сикерү рөхсәт ителми иде.)

Бу юлы Зәйтүнә кабинага җайлы гына кереп утырды. Биеккә күтәрелгәч, очучы хатын зур пыяла күзлеген елтыратып борылып карагач, кабинадан чыгып, канатка басарга кирәген аңлады һәм моны да шактый җиңел башкарды. Ләкин менә, кабина кырыена чатлап ябышып, канат өстендә сынын турайтып баскач һәм аяк астында, упкын кебек тирәнлектә агып яткан җирне күргәч, башы әйләнеп

китте, бармаклар тимергә эретеп ябыштыргандай беректе, кабинага кире кереп каты утыргычка сеңәсе килү теләге бөтен зиһенне биләп алды. Ул артка карап тора, аркадан каты җил этә, ә җан исә тыелгысыз булып яндагы кабинага тарта иде. Гөрелте аша кычкырган тавышка артына борылып карады Зәйтүнә. Анда гыйфрит күзе кебек акайган пыяла күз, зур ачылган авыз күренде. Зәйтүнә очучының сүзеннән түгел, кыяфәтеннән: «Сикер!» — дип кычкырганын аңлады.

— Сикер! Сикер! Сике-ер!

Сикерергәме? Бумы сикерү?! Бу бит үзеңне, һәр күзәнәге белән самолет тимеренә берегергә омтылган тәнеңне ышанычлы терәктән аерып, бушлыкка, төпсез упкынга ыргыту дигән сүз!

Ләкин үзен шулай ыргытмаса, кызларның иң куркагы дигән дан күтәрәчәк бит ул... Нур шәүләсе төсле егетнең күзенә ничек карар? Күз алдында Әнвәрнең көлемсерәүле карашы чагылып узгандай булды. Зәйтүнә күзләрен чытырдатып йомды да кабина тимеренә ябышкан бармакларын язу өчен бөтен ихтыяр көчен туплады. Шул мизгелдә тыгыз һава аны канат өстеннән йолкып алып йөзтүбән мәтәлдерде.

Инструктор аңлатканда, һәммәсе бик гади иде кебек: очкычтан аерылгач та, «бер, ике, өч...» дип, ашыкмыйча гына алтыгача саныйсың, аннары баш өстеңә күтәрелеп карыйсың. Әгәр дә шуңарчы парашютың ачылмаган булса, күкрәгеңдәге каешка беркетелгән божраны тартып аласың — запас парашютны ачасың. Ә монда кая ул санау да кая башны күтәреп карау! Эреп юкка чыккандай буласың икән. Кемдер култык астыннан тотып кисәк туктаткандай иткәч кенә исенә килде Зәйтүнә. Шунда гына күтәрелеп карый алды: баш очында ак чатыр булып парашют чайкала иде. Кинәт аның күңелен һичкайчан булмаган очыну, рәхәтлек биләп алды. Мондый ләззәтне очар кошлар гына тоя ала торгандыр. Ул киң каешларга җайлап урнашты да таганда атынгандай чайкала башлады.

Парашют бер урында тирбәлә, фәкать җир генә үзгәрә кебек иде: офык тарая, агачлар зурая, юл киңәя иде шикелле. Зәйтүнә әле якынаеп килгән аланлыкка, әле биегәеп барган күк йөзенә карады, бер көлде, бер җырлады. Бары тик урман авызы читкә шуышып, такыр чирәмлек нык ук якынайгач кына, Әнвәрнең тагын бер киңәшен исенә төшерде: парашют бауларын тарткалап, тирбәлү-атынуны туктатырга кирәк иде ләбаса! Ләкин инде соңарылган иде, җир кинәт Зәйтүнәгә ташланды, Зәйтүнә, яны белән бәрелмәс өчен, аякларын чирәмлеккә таба чак сузып өлгерде. Каты җир табаннарына килеп бәрелүгә тәгәрәп китте.

Кинәт авырайган ботинкаларның җайсызлыгын тоеп, кыенлык белән торып басты, җил уңаена сузылган парашютның бауларын тарткаларга кереште.

Тапталган чирәмлек буйлап велосипедка утырган берәү килә иде. Зәйтүнә аны ерактан ук таныды. Әнвәр килеп тә җитмичә ашыгып велосипедыннан төште, йөгерә-атлый килде дә, сулышына кабып:

— Иминлекме? — дип сорады.

— Әйбәт!

— Нишләп алай ерак илтеп ташлады соң ул сине?

— Аның гаебе түгел... Мин... куркып тордым...

Әнвәр, бу сүзләрне шаяру дип кабул иткәндәй, җиңеләеп елмайды.

Парашютны икәүләп җыйгач, алар, велосипедка утырып, болын буйлап киттеләр. Алга утырган Зәйтүнә аркасы белән егетнең кайнар күкрәген, йөрәк тибешен тоеп барды. Бу рәвешле һич уйламаганда егет кочагына керү фәкать шушындый минутта, кошлар кебек күктә талпынып очканнан соң, күңелнең канатлы чагында гына мөмкин буладыр да. Һәм бу — талпыну-очынуны икәү бергә тойганга, йөрәкләр бергә кушылып типкәнгә генә мөмкин иде.

Алар менә шулай, сүзсез генә, йөрәк тибеше аша гына беренче тапкыр аңлаштылар.

***

Кадерле хатирәләрдән арынмаска тырышты Зәйтүнә. Беренче тапкыр сүзсез генә аңлашуның яктысында күңел ныграк җылынсын иде...

Әмма, чәй эчәргә утыргач, бу яктылыкны йомшак кына күләгә каплагандай булды. Өстәл башында утырганда, бүлмәнең ике як диварында эленеп торган ике рәсем бик яхшы күренә. Аларның берсен — уң яктагы карават өстендә эленеп торганын — тулай торакта бергә яшәгән кызлар туй бүләге итеп китергәннәр иде. Пикассоның «Мадам Жаклин»ы. Кара сызыклар белән генә салган хатын-кыз сурәте. Аның йөзендә тирән моң, ятларга белдертү түгел, дуслар белән дә уртаклашып булмый торган яшерен сагыш бар. Агарынган, суырылган ул. Нәрсә изә аның күңелен, ничек җиңеләйтеп була аның сагышын? Кайгыртучы, юатучы якын кешесе юк, ахры, мадам Жаклинның. Гомумән, хәленә керүче юк, күрәсең. Япа-ялгыз ул, ялгызлыгы йөзенә бәреп чыккан.

Тик шулай булса да, хислелеге, уйчанлыгы, хәтта сагышы белән сөйкемле, мөлаем үзе... Йөзе шулай. Ә менә гәүдәсе... Мадам Жаклинның буй-сынын тасвирлаганда, мәшһүр рәссамның каләме

бөтен сизгерлеген, тылсымлы көчен кинәт югалткан диярсең. Жаклинның гәүдәсе — озынча зур шакмак, аяклары — кечерәк шакмаклар, муены — улак. Аяк бармаклары киселгән ботак калдыклары кебек тырпаешып тора. Шакмакларның берсе янына икенчесе ничек куелганга карап кына, хатынның тезләрен кочаклап утырганын чамаларга була. Нәрсә бу, кубизм стиленең чагылышы гынамы, әллә югыйсә рәссамның бу хатынга үз мөнәсәбәтен белдерүеме? Нигә шундый җансыз итеп тасвирлаган ул бу сынны?

Рәсемне бүләк итеп тапшырганда, Лариса киная белән: «Зюзю! Нәкъ синең рухта инде бу!» — дигән иде.

Шул искә төшкән саен, Зәйтүнә шомланып, уйланып куя: ни әйтмәкче булды икән Лариса моның белән? Картинаны да барлык кызлар исеменнән, мөгаен, ул сайлап алган булгандыр.

Туйдан соң берме-икеме ай узгач, Әнвәр каршы стенага тагын бер рәсем алып кайтып элде. Монысы ачык төсләр белән ясалган кыз сурәте. Авторы да танылганнардан түгел. Алмалары пешеп килгән агач янында бер кыз туктап калган да, башын бора төшеп, кемгәдер карап елмайган. Аның чәчәкле яулыгы, шома чәченнән шуышып төшеп, толымнары төбендә генә тотылып калган. Гәүдәсе шулкадәр табигый сызыклар һәм буяулар белән тасвирланган ки, сулыш алганда ачык муенындагы гәрәбә муенсасы тирбәлеп куя кебек.

Рәсемне элгәч, Әнвәр, мәгънәле итеп:

— Менә күрәсеңме, хатын-кыз нинди дә була! — дип куйды.

— Һәр рәссамның үз стиле, — дип каршы төште аңа Зәйтүнә. — Бу реализм әсәре, ә Пикассо яңа алымнар эзләгән.

— Алымны әйтәммени мин сиңа? Хикмәт күңелдә, җанның, тәннең хислелегендә!

Аннары башын ия төшеп, текә маңгае астыннан серле елмаеп карады да сәер итеп каш сикертеп куйды. Сәнгать әсәрләре хакында җитди сүз сөйләшкәндә, аның бу кыланышы Зәйтүнәгә урынсыз тоелды. Ничектер кыен булып китте хәтта.

Хәзер дә, алмагач янындагы кыз рәсеменә күзе төшкән саен, Әнвәр ничектер үзгәреп китә кебек, аннары ул шакмактан ясалган Жаклинга керфек сирпеп ала да, өченче сурәткә карагандай итеп, хатынына текәлә, ниндидер соравына җавап эзли, нәрсәдер көтә кебек. Андый минутларда аның коңгырт күзләренең көйдергеч карашыннан качасы килә.

Кичләрен, рәсемнәрне күләгәдә калдырып яшел торшер яктысында утырганда, бик рәхәт Зәйтүнәгә. Торшердан төшкән йомшак яктылык астында Әнвәр өстәлгә алсу кәгазен җәя, готовальнясын ача. Аның сизгер, нечкә, хәрәкәтчән бармаклары готовальняның кызыл бәрхете эчендә ялтырап яткан ак тимер каләмнәргә һәм җәзбәләргә жан өргәндәй итәләр. Һәм кәгазьдә төгәл, пөхтә сызыклар пәйда була.

Өстәл янына китабын тотып Зәйтүнә килеп утыра. Ул, әледән-әле башын күтәреп, ирен күзәтә. Әнвәр сызымнарны шигырь язган шагыйрь яки җыр чыгарган композитор кебек ләззәтләнеп сыза.

Әйе, тимергә жан өрә белә аның Әнвәре.

Тик менә утларны бөтенләй сүндереп, караңгыда калгач, хатыны янында аның бу тылсымлы көче юкка чыккандай була. Аның кайнарлыгы хатынының тәненә үтеп керә алмый, тынгысыз бармаклары орынуга, Зәйтүнәнең тәне агачланып киткәндәй була. Эчтә — ут, тышта — агач кабык... Туйдан соңгы беренче төндә үк барлыкка килгән бу тартыну, оялу вакыт белән үтәр дип уйлаган иде Зәйтүнә, күнегермен, гадәтләнермен дип өметләнгән иде.

Ләкин менә гадәтләнә алмый, киресенчә, тартынуы арта гына бара шикелле. Соңгы вакытта бу читләшү тагын да көчәйде кебек әле. Моңа, бәлки, аларның инде икәүдән-икәү генә түгел, ә бәлки өчәү булуы сәбәпчедер. Дөрес, өченче дигәне әлегә Зәйтүнәнең йөрәк астында гына тыпырчына. Әмма ул мөнәсәбәтләрне үзгәртә һәм ни өчендер, Әнвәрне җанга якынрак итсә дә, тәннең тартынуын киметми иде.

Менә ни өчен мадам Жаклинның агач гәүдәсенә күз төшкән саен, күңелне шомландырып, Ларисаның кинаяле сүзләре хәтергә килә: «Синең рухта инде бу, Зюзю!»

***

Әнвәр кайткач, утырып чәй эчкән табынны җыеп та өлгермәгәннәр иде әле, тышкы якта кемнәрнеңдер күңелле шаулашканы ишетелде, кыңгырау зыңгылдады. Ишек ачылуга, очып диярлек, күгәрчендәй гөрелдәп, Лариса килеп керде дә Зәйтүнәнең муенына асылынды. — Зюзю! Беләм бит мин сезнең хәзер генә нишләп утырганыгызны! — Ул, башын борып, кысан коридорга чыга алмый басып калган Әнвәргә карады: — Безне сагынып, безнең хакта сөйләшеп утыра идегез. Шулай бит, Анварчик?

Лариса артында Кифаяның давылдагы кебек тузган чәче, зур авызы күренде. Аннары, ишек уемын иңләп, зур гәүдәле, төз, нык муенлы Хөсәен килеп керде.

— Менә сезгә күчтәнәч! — диде Лариса, аның тарафына очлы бармагы белән ишарәләп.— Котыптан кайткан ак аю! Зюзю, Анварчик! Мине котыбына алып китәргә кайткан бит ул! Алып китәргә дә башкаемны харап итәргә йөри! Йолып калучы булмас микәнни?

Хөсәен аның сүзләренә тыныч кына елмайды, билен бөгә төшеп, сак кына Зәйтүнәнең кулын кысты һәм Әнвәрнең иңнәреннән кочып алды.

Кунаклар кайсы урындыкка, кайсы караватка утырышкан арада, Зәйтүнә яңадан табын әзерләргә кереште.

Димәк, Хөсәен Ларисаны алырга кайткан, дип уйлады ул. «Барыбер минсез яши алмаячак!» — дигән иде Лариса, хак икән. Әллә соң күрәзә итә торган сәләте бар инде шуның? Әнвәр турында әйткәне раска чыга күрмәсен тагын. Ничек дигән иде әле ул? «Ах, Зюзю, егетнең асылын, еракта балкып торганын эләктергәнсең! Якты утка күбәләк күп очучан, сак бул!» Бу кисәтүдә кызыгу, хәтта көнләшү дә бар иде кебек.

Нәкъ шул вакытта Хөсәен белән аның арасы суыныбрак киткән шикелле булган иде. Кичләрен Лариса егете чакырганга чыкмый, мендәренә капланып, караватында ята, Әнвәр белән озак йөргәннән соң кайтып кергән Зәйтүнәне күргәч, сикереп торып, чәйнектән салкын су эчә. Аның күз төпләрендә ниндидер бер шомлы күләгә шәйләнә иде. Ярый, күпмедер вакыттан соң Хөсәен белән аралары тагын көйләнде, Лариса тыныч ланып киткәндәй булды.

Аралары җайлануга сәбәп тә җитәрлек иде шул. Тулай торакның бер катында яшиләр, бер кухняда ашарга пешерәләр. Кичләрен коридорның караңгы башыннан гөрләшкән тавыш ишетелсә, бер дә башка түгел, Хөсәен белән Лариса булыр. Бәһадир гәүдәле, әмма карап торышка юаш холыклы Хөсәеннең күңел түренә патшабикә булып кереп урнашты бу кечерәк кенә буйлы, чөенке борынлы, җирән бөдрә чәчле Лариса. Ул үзенең агачтан бик нәфис итеп уелгандай нәзек бармагы белән кай тарафка ишарәләсә, ягымлы елмайган егет шул якка атлап китә. Кулга ияләшкән фил диярсең үзен!

Бәйрәмнәрдә Лариса күңелле мәҗлесләр оештырырга ярата. Нәкъ менә ул әзерләгән табыннарда күп кенә кызлар, шул исәптән Зәйтүнә дә гомерләрендә беренче тапкыр хәмер авыз иттеләр. Андый очракларда егетләр-кызлар акча җыя, калганын Лариса кайгырта: Хөсәенне ияртеп, базарга бара, бик оста сатулаша, алган бер әйберсен пөхтәләп төреп, егет кулындагы сумкага сала. Салат-фәләп ясаганда егеттән суган әрчетә.

Лариса белән дуслашкач, егет нык үзгәрде: өс-башы чистарды, пөхтәләнде, чалшайган ботинка башлары да тураеп китте. Югыйсә яхшы укуы, фәнни түгәрәктәге эшләре белән бөтен институтта дан тоткан Ленин стипендиаты Нигъмәтуллинның аңарчы көзгегә карарга вакыты да калмый иде бугай. Барысы да аның хакында, диплом алгач, аспирантурага керер, ике-өч елдан диссертация яклар дип уйлаганнар иде. Ә ул, институтны Ларисадан бер ел алдан тәмамлап, эшкә төньякка — Сургут шәһәренә юллама алды. Ларисаның үгетләрен, ялваруын, хәтта каһәрләвен тыныч кына елмаеп тыңлады, каршы әйтмәде, әмма үзенекен итте.

— Чын врач булыйм дисәң, тормыш казанында кайнарга, мөстәкыйль эштә чыныгырга кирәк,— диде.— Үзеңне сынарга кирәк башта!

Ул көннәрдә Лариса бөтерчектән борауга әйләнгән, таш күңелне дә тишәр кебек иде югыйсә.

Хәтердә, бер кичне Лариса, түше чигелгән төнге күлмәген киеп, чәчен бигудига урап утыра иде.

— Ничек соң, чынлап китәргә ниятләдеме инде Хөсәен? — дип сорады Зәйтүнә.

— Китсә тагын, кендегем берекмәгән әле, — дип җавап бирде Лариса. — Мин бит аны аэроклубларга барып, күкләргә менеп эзләп йөрмәдем! Аякка үзе килеп уралды. Китсә, юлына ак җәймә. Ил бетмәсә, ир бетмәс, ди торган иде минем әби.

Аның бу рәвешле ямьсез итеп тешләве урынсыз һәм аңлаешсыз иде, әмма Зәйтүнә үткәреп җибәрергә тырышты. Кәефсез чагы, ялгыш ычкындыргандыр дип юанды.

Хөсәен китеп, аралар ерагайгач һәм айлар узгач, Ларисаның ачуы басыла төште булса кирәк. Ул чакта Зәйтүнә тулай торактан чыгып киткән, лекцияләрдә генә очрашалар иде, алай да ишетте: кызыкай төньяктан килгән хатларга җавап яза башлаган, имеш... Тәмам килешкәннәр, күрәсең, менә бит Хөсәен Ларисаны алырга кайтып та төшкән.

Зәйтүнә чәйнек күтәреп кире бүлмәгә кергәндә, Әнвәр белән Хөсәен, изүләрен чишеп, үрмәләп йөриләр иде. Идән тулы кәгазь, кәгазьләрдә сызым, сызымнарда әлеге дә баягы шул теплицалар.

— Мин ул парник хуҗалыгының исемен үк үзгәрттерәчәкмен әле, — ди Әнвәр, кайнарланып. — Совхоз итәчәкмен мин аны!

Карават кырыена утырган Лариса бөтен гәүдәсе белән аска таба авышкан, ләкин сызымнарга түгел, сөйләүченең йөзенә текәлгән иде.

— Искиткеч! Гажәп! — ди үзе, тәмам мөкиббән киткәндәй.

Кифаяның исә кичәге мәҗлестән соң йокысы туймаган, күрәсең, кырыйдагы урындыкта зур авызын ачып, иснәштереп утыра. Ник дип ияртеп йөри икән аны Лариса? Бер дә пар түгелләр бит югыйсә.

Хәер, ник икәнен чамаларга була: Лариса офицер гаиләсендә үскән, илне күп гизгән, акылны шактый җыйган, дөньяның рәтен белергә өйрәнгән, Кифая кебек килешсез киемле ямьсез кыз янәшәсендә үзенең әллә каян балкып торганын бик яхшы аңлый.

— Туктаусыз эше турында гына такылдап торган ир белән яшәгән хатынга Алла ярдәм бирсен, — диде Кифая, өйне яңгыратып. — Кунакларны сызым белән генә сыйлыйлармы әллә сездә?

Әнвәр, башын күтәреп, аңа гаҗәпләнеп карады:

— Их сез! Үзегез врач тагын! Кышын-язын витаминнарның никадәр кирәклеген сез миннән яхшырак белергә тиеш!

— Анварчик! Беләбез, бик яхшы беләбез! — Лариса тирән итеп, йөрәк түре белән көрсенеп куйды. — Әйдәгез әле, дуслар, Анварчикның изге хыяллары тормышка ашсын өчен берәр бокал күтәреп куйыйк әле! Гөнаһ булмас, шулай бит? Әй, ак аю! Чыгар күчтәнәчләрне сумкадан! Зюзюнчик, ярдәм итимме?

— Юк, сез аңлап бетермисез әле, бетермисез! — диде Әнвәр, идәннән сызымнарны җыеп алганда. — Безнең хуҗалыкта эшләүче хатыннарның хәлен белсәгез иде сез! Март аенда киңлеге метр ярым, тирәнлеге ярты метрлы канаулар төбенә яшелчә үсентеләре утырта башлыйлар. Эчкә басарга ярамый, алар чокырга аркылы такталар куеп, шуларга күкрәкләре белән ятып эшлиләр. Биллəһи, андый чакта мин аларның янына барырга оялам, әйләнеп үтәм. Хатын-кызга күкрәге белән бозлы тактага ятып эшләргә ярыймыни? Шуннан соң алар сезнең янга йөри башлый да инде...

— Әгәр кулыннан килсә, безнең Әнвәр бөтен дөньяны үзгәртеп корыр иде,— диде Зәйтүнә, иренә сокланып һәм аның сәерлегенә бераз гына көлемсерәп. — Ул әйтә, шәһәрләрдә дә бер генә карыш җир дә әрәм ятмаска тиеш, ди. Газоннарга арыш чәчәргә, скверларда алмагач, чия үстерергә күптән вакыт, ди. Без әле аның белән «Арыш чәчәге» дигән ислемай чыгарганнарын көтәбез!

— Арыш серкәсенең исеннән татлырак бүтән хуш ис дөньяда юк, беләсегез килсә! — диде Әнвәр. — Парфюмерлар моны ничек аңламый, мин шуңа шаккатам.

— Әнвәр белән без шәһәр урамнарында бер машина да калмаган көннәрне күрү турында хыялланабыз әле, — дип көлемсерәп дәвам итте Зәйтүнә. — Һәртөрле кирәк-яракны, йөкләрне җир астыннан салынган торбалар буенча ташыячаклар, ә кешеләр һәркайсы үзенә аерым канат тагып очып йөриячәкләр.

Бу сүзләрдән Кифая шаркылдап көлеп җибәрде, Хөсәен үзалдына «хым» дип куйды, Лариса күзләрен тутырып тагын Әнвәргә текәлде.

— «Арыш чәчәге» дигән ислемайның беренче шешәсен үзем сатып алачакмын! Теләсә нинди бәягә, бөтен мал-мөлкәтемне биреп булса да. Ә алмагач чәчәкләренә төренгән, хуш искә күмелгән шәһәр өстеннән канат җилпеп очу... Их, татлы төш кенә шул ул!

— Ә нигә төш кенә? Озакламас, техниканың моңа көче җитәрлек булыр. Үзегез уйлап карагыз, безнең бабайларга телевизор да тормышка ашмастай хыял булып тоелган бит. Ә безнең өчен ул гап-гади әйбер.

Хөсәен идән уртасына баскан килеш бу бәхәсне тыңлап торды да:

— Анысы шулай, ә менә төньякта яшәүчеләрне витамин белән кем тәэмин итәр икән? — дип куйды. — Анда бит уңган кешеләр яши, эшли. Әгәр синең бу проектың турында белсәләр, кулыңнан йолкып алачаклар. Акчасыннан да тормаслар, материалын да табарлар. Рәхмәтен дә зурлап әйтерләр иде!

— Әйдә безнең белән, Анварчик! — дип куйды кинәт сынып киткән тавыш белән Лариса.

Бу шулхәтле хисле яңгырады ки, бүлмәдәгеләр уңайсызланудан тынып калгандай булдылар.

— Туктагыз әле, монда башлаган эшне очлап чыгасы бар, — диде кызарынып, буталып Әнвәр.

— Әйдәгез, табын янына рәхим итегез, — дип, Зәйтүнә уңайсызлыкны тарату җаен карады.

Өстәл янында Хөсәен аның сул ягына туры килде. Яннан караганда, егетнең маңгае калкурак, ияге чыгынкырак, иңбашлары киң — гомумән, бөтен бәдәне тагын да гайрәтлерәк күренә икән. Әллә соң Себернең җил-бураннары шулай чыныктырганмы? Сүзен дә әнә ничек үлчәп кенә, хуҗаларча нык итеп әйтә. Сургутта ул хастаханәнең баш табибы икән. Институтта үзенә багланган өметләрне аклый алмас, фән юлында уңышка ирешү аңа насыйп булмас, ахрысы. Фән сәнгать кебек бит ул: бар гомерне үзенә генә багышлауны таләп итә, ыгы-зыгы килгәнне, анда-монда сугылганны, кабаланганны кичерми. Ә баш табибның мәшәкате мең төрле. Иң катлаулы авыруларны карау, табибларның булдыксызларын эшкә өйрәтү өстенә, бинаны төзекләндерү, кышка ягулык белән тәэмин итү, рентген, УВЧ аппаратларын кайтарту кебек бихисап мәшәкать аның бөтен вакытын, көчен йота.

Тирә-юньдә аны хөрмәт белән «олы врач» дип атарлар атавын, әмма төшкә генә керердәй татлы хыяллар белән мавыгырга аның вакыты да, мөмкинлеге дә калмас. Боларны күз алдына китерсәң, Ларисаның бу рәвешле алгысавын аңларга да була.

— Мин хыялый канатлы кешеләр хөрмәтенә бокал күтәрәм, — диде ул.

Табын янында табибларның хезмәте хакында сүз китте.

— Бүгенге врачларның һәркайсы Әбугалисинадан яхшырак дәваларга тиеш, — диде Әнвәр. — Күпме дарулар, яңа аппаратлар сезнең кулда.

— Гиппократлар, Әбугалисиналар заманы күптән узды инде,— диде кинәт Лариса, каты гына итеп. — Специализация чоры хәзер. Медицина өлкәсендә йөз илле төрле белгечлек бар. Йөз илле! Кендекне аерым алып тикшерүче генә юк бугай әле, озакламый андыйлар да булыр, мөгаен. Әйтик, менә безнең Кифая участок врачы булып урнашты ди. Берәрсе, эчем авырта, дип зарланып килсә, ул, моның сәбәбе нидә икән, дип баш ватып утырмаячак, хирургка, инфекционистка яисә башка берәр специалистка направление язып тоттырачак.

Кифая зәңгәр буйлы итәк өстеннән кигән кызыл чәчкәле кофтасын тарткалап куйды. Бу сүзгә кушыласы килми иде аның. Ул инде, шәһәрдә калу җаен эзли торгач, бер хастаханәдән чакыру кәгазе дә юнәткән иде. Әмма яшь белгечләрне эшкә җибәрү комиссиясендә министрлыктан килгән ир уртасы кеше ул кәгазьне ике бармагы белән тотып селеккәләде дә:

— Белемле кадрларны кая кую мәсьәләсен без үзебез хәл итәбез,— диде.— Халык сезне алты ел укытты, аңа кирәк җирдә эшләп күрсәтегез әле.

Шулай итеп, Кифая авыл җиренә, анда да район үзәгенә түгел, аннан да егерме биш чакрым ары китәчәк. Аның бәхетенә, ул тирәдәге биш-алты колхоз берләшеп, өч катлы хастаханә бинасы торгызып куйганнар икән.

— Син, Кифая, бер дә аптырама,— диде Лариса, дустын үчекләп.— Мондагы авыл Себер түгел әле ул. Сургутта әнә суларга һава да җитми, диләр. Син «инолас»ны гына онытма.

Хөсәен аңа гаҗәпләнеп карады:

— Нинди «инолас» ул тагын?

— Врачка ике «ин»ны, өч «ол»ны, бер «ас»ны гына истә тотарга кирәк.

Зәйтүнә, Хөсәеннең — сагаеп, Әнвәрнең ихлас кызыксынып тыңлаганын күреп, шаркылдап көлеп җибәрүдән чак тыелып утырды.

— Авыл врачына килгән халыкның күпчелеге нидән зарлана? Йә башы, йә эче авыртудан инде, билгеле,— дип, бик җитди кыяфәттә дәвам итте Лариса.— Баш авыртканда аспирин йә анальгин бирергә кирәк. Ике «ин» булдымы? Эче авыртканга — бессалол. Менә сезгә бер «ол». Урта яшьләрдәгеләрне ике сортка бүлеп эш итү хәерле. Ирләрнең эченә аллахол килешә, хатын-кызларга норсульфазол.

— Нишләп андый аерма? — дип сорады Әнвәр.

— Җенси аерма! — дип җавап бирде Лариса, көлеп җибәрүдән чак тыелып.— Ир-ат эчеп-тартып бавырын боза. Ә хатын-кызның үз җәфасы. Өч «ол» булдымы? Карчык-корчыкка иң яхшысы — холосас. Бик яраталар.

— Ансат икән!

Зәйтүнә сискәнеп китте. Хөсәеннең мондый кырыс тавышын моңарчы ишеткәне юк иде әле.

— Әйе-е, анса-ат...— дип сүзды Әнвәр.

— Зыянсыз да,— дип дәвам итте аны-моны сизмәгән Кифая.— Анысына канәгать булмаганнарны район үзәгенә яки шәһәргә үк озатырга кирәк булачак. Килгән халыкның уннан тугызына участок врачы барыбер ярдәм итә алмый. Практикада күрдем инде: кабул итү вакытында ишек төбендә тезелешеп пенсионер карчыклар утыра. Картлык чиреннән кемне терелткәннәре бар әле?

— Әбиләрнең рәхмәте зур аларның, бер йомшак сүздән сызлануларын оныталар, бер җылы караштан шифа табалар,— диде Зәйтүнә.

— Сиңа әйтүе җиңел, әллә кайларга китеп, ятлар арасында тинтерәп йөрисең юк!

Бу сүзләре белән авызны томалады да куйды Кифая. Зәйтүнә үзенә җайлы кияү эләктерде дә, нәкъ вакытында корсакка узып, Казанның яхшы гына клиникасына акушер-гинеколог булып урнашып калды, янәсе. Дәвалау факультетының теләсә кайсы студентыннан, кем булырга телисең, дип сора син. Ул йә хирург, йә акушер-гинеколог, сирәгрәге терапевт буласым килә дияр. Ә менә Лариса белән Кифаяга кем булырга туры килер, анысы әле хәзергәчә билгесез. Ларисаның, студентларча әйткәндә, Лораның, киләчәге ачык иде кебек, аның хакында, шаярышып: «Наша Лора будет лором», — диләр иде. «Лор» дип, гадиләштереп, оториноларингологны, ягъни колак, борын, тамак авыруларын дәвалаучы табибны әйтәләр бит. Маңгаена елкылдап торган түгәрәк көзге беркетеп, кешеләрнең киң ачылган авызына хикмәтле инструментлар белән генә үрелеп утыру аңа чыннан да бик килешәчәк иде. Хасталарны чишендереп корсагын капшарга да, башка төшләрен сыйпап-сыпырырга да кирәкми. Ул шул әлеге дә баягы адәм тәненең өч йөздән бер өлешен генә карый торган белгеч. Ләкин менә төньякта алай гына утыру өчен шартлар бар микән?

Хөсәен, Зәйтүнәгә аркасын куеп, бөтен гәүдәсе белән Ларисага таба борылды.

— Сез нәрсә, институттан шул «инолас»ны гына белеп чыктыгызмы әллә?

— Йә инде, ул кадәр аю булма,— дип гөрелдәде Лариса.— Көлү-шаяру дигәнне бөтенләй онытып кайттыңмы әллә син аннан? Шаярабыз гына ич без. Аңлыйсыңмы, ша-я-ра-быз!

— Кешенең сәламәтлеге белән, әҗәл белән шаярмыйлар! Табиб исемен алганнар бигрәк тә!

— Уф Алла! Нинди әҗәл булсын ди! — Лариса егетнең күкрәгенә сыенып, бармаклары белән баш артын сыйпады. — Себер җеннәре алмаштырдымы әллә сине? Пәри алыштырган малайларны, беләсеңме, нишләтәләр? Кызган мич каршына утыртып кыйныйлар. Шунда пәри, баласын кызганып, урлаган сабыйны кире китереп куя да үзенекен алып китә. Минем әби шулай дип сөйли торган иде. Монда мич юк, ләкин мин чарасын табармын, сине кети-кети итеп, кытыклап көлдереп җәфалармын. Шундый кызганыч итәрмен, анаң пәри хатыны булса, түзә алмас, йөгереп килеп алыр, үзенеке урынына элекке чын Хөсәенне безгә биреп калдырыр. Шулай итимме, итимме?

Ә үзе егетнең кочагына сеңеп беткән, Зәйтүнәгә назлы-шаян тавышы ишетелә дә, егетнең баш артында уйнаклаган бармаклары гына күренә иде. Иң гаҗәбе шунда: Хөсәеннең горур башы иелә барды, иелә барды һәм, ниһаять, тәмам бөгелеп, Ларисаның иңенә терәлде, кыз исә егетнең башы өстеннән Зәйтүнәгә горур караш ташлады.

Әмма бу гына да аз иде әле аңа. Гайрәтле ир-атның сынын бөгүе генә дә җитми иде. Язын алмагач чәчкәләренә төренеп, җәен арыш серкәсе исенә күмелә торган гүзәл кала өстеннән канат җилпеп очу турында хыяллана иде ул. Ә соң бу Себер аюы нәрсә уйлый да ниләр сөйли? Нефтьчеләргә витаминлы яшелчә ашатып, шуның өчен рәхмәт ишетү турындамы? Ни белән шөгыльләнә ул? Хасталарның мәңге бетмәс зарларын тыңлау, Себер буранарын ерып, анда-монда чабу беләнме?.. Шундый буламы якты хыяллар да шул булдымы мәгънәле шөгыль! Ә башка берәүләр әнә илне-җирне чәчкәгә күмеп һәм хуш искә төреп, канат ярып очу турында хыяллана...

Беренче итеп үзеннән кала тагын кемгә куяр икән ул тылсымлы канатларны?

***

Иртәнге конференция тәмамлангач, табибларга соңгы киңәшләрне биргәннән соң, Җәмилә Закировна, үз бүлмәсенә кереп, өстәлдәге кәгазьләрне караштырды да җиңел сулап куйды. Бүгеннән башлап бер-ике атнага ул клиника ваемнарыннан бушап торачак. Хәзер өйгә кайтырга да юлга җыенырга. Кичке поездга хәтле шактый вакыт бар әле.

Шунда аның йөрәк түренә утлы очкын төшеп көйдергәндәй итте. Нилектән бу? Җәмилә Закировна башын күтәрде һәм сул ягына — ике тәрәзә арасына эленгән рәсемгә карап хәрәкәтсез калды.

Кызгылт-сары металлга уеп ясалган бу сурәттә сабыена иелгән ана тасвирланган иде. Профессор Ильясовага аны Ереван каласында булып узган зур бер киңәшмәдә бүләк иттеләр. Бик зурлаганнар иде анда Җәмилә Закировнаны.

— Табигать серләрен ачу юлында тагын бер мөһим адым ясаганыгыз өчен...— дигән сүзләре хәтердә калган.

Табигать серләрен ачу! Нинди мәгънәле сүзләр бу! Дөньяга яралганнан бирле кеше үзенең кемлеген һәм ниндилеген белергә омтыла. Ләкин әле хәзер дә галимнәр, без үзебезне космосны белгәнгә караганда да азрак беләбез, диләр. Ә кешенең яшәешендәге серләрнең иң бөеге ул — безнең якты дөньяга килүебездер, мөгаен.

Кызгылт-сары металлга уелган бу сурәт шул могҗизаны — тәннән — тән, җаннан җан яралуны искәртә иде. Ана белән бала икесе бердәм итеп, йомшак, нәфис, сыгылмалы, өзелмәс бер сызык ярдәмендә тасвирланганнар, яшь ананың сабыена текәлгән карашындагы наз җылысыннан күз кабаклары чак кына күпереп тора кебек.

Кайчакларда, нәрсәне дә булса исенә төшерергә тырышканда яисә зиһене таралганда, Җәмилә Закировна шушы рәсемгә карап уйлана. Ишеккә каршы эленеп торганга күрә, бүлмәгә кергән һәркемнең күзе иң элек шуңа төшә. Диләрам да бу картинага игътибар иткән иде.

Диләрам! Җәмилә Закировнаның йөрәге сулкылдап куйды. Диләрам! Менә кем өчен сыза икән бит аның күңеле!

Әйе, сабыен кочкан анага керфекләрен бер сирпеп алды да Диләрам шундук боегып киткәндәй булды, вак сипкелләр белән чуарланган озынча каратут йөзе тимгелләнеп кызарып чыкты. Урындыкка утыргач, башын түбән игәнгә, нечкә толымнарының берничәсе яңагына төште, түбәтәенең түбәсендәге аллы-гөлле чигешнең бөтен бизәкләре күренде. Ул үзбәк ефәгеннән тегелгән күлмәгенең кыска җиңнәрен озынайтырга теләгәндәй тарткалап куйды.

Башкалар өчен бик гадәти тоелган рәсем аның кимлеген искәрткәндәй бәгырен сызлатты. Балалар турындагы һәр сүз, җыр яисә рәсем аның күңелен яралый иде, чөнки Диләрамны язмыш һәр хатын-кызга тумыштан бирелә торган табигый сәләттән — ана булу сәләтеннән мәхрүм иткән иде. Дөрес, бу кимчелек тәнне сызландырмый, әмма күңелгә һич тынгы бирми иде: кыз баланың кайсысы гына гомерен корыган агач кебек уздыру турында хыялланыр икән?

Хәсрәтенең ачылыгын, бөтен өмете Җәмилә Закировнада гына икәнен аңлатырга сүзләр таба алмады Диләрам, буталды, тотлыкты. Профессор исә аның хәлен сүзсез дә, кыяфәтенә карап кына да

аңлады. Безгә килеп дөрес иткәнсез, диде ул. Сезгә ярдәм итәрдәй операцияләрне мин үзем ясамыйм ясавын, ләкин бездә ул эшнең танылган остасы бар. Берничә кешегә операция ясады инде, барысы да уңышлы узды, анда дәваланган кайбер кызлар кияүгә чыгып, бала табып та өлгерде инде.

Профессор Ильясова Диләрамны доцент Дәүләтшин янына үзе алып барып урнаштырды.

Бүген Диләрамга операция ясаячаклар. Изаил Харисовичка ышанып була — кулы оста булуы өстенә ул авыруларны операциядән соң да күңел биреп карый. Кайсыларын өстәлдән тәгәрмәчле ятакка үзе күтәреп сала, тирәсендәге хатын-кызга йөкләми. Төннәрен үзе теләп клиникада үткәргән чаклары була.

Тик нигә соң әле йөрәк түрендәге очкын һаман көйдереп тора, нигә Диләрамның чык кунган йөзем җимеше төсле күзләре күңелдән китми?

Язылмаган кагыйдәләр профессорга, башка кафедрага барып, андагыларның эшенә катышып йөрергә кушмый. Ләкин күңелендәге бу сызлавыкны ерак юлга алып чыгып китсә, әйләнеп кайтканчы тынгы белмәячәк иде Җәмилә Закировна.

Шуңа күрә ул, кагыйдәне бозып булса да, Диләрам янына кереп чыгарга ниятләде. «Өйгә кайтканда юл уңае гына бит, операция башланганмы, башланса, ничегрәк бара икән, шуны гына белешермен дә китәрмен»,— дип, үзен-үзе акларга тырышты.

Икенче клиника Казан каласының яшеллеккә күмелгән борынгы урамында, сырлап-бизәп салынган ике катлы кызыл кирпеч бинага урнашкан иде. Трамвайдан төшкәч, Җәмилә Закировна урам чатындагы чуен бюст янында адымнарын чак кына акрынайтты. Атаклы галим Вишневскийның сыны кара мәрмәр баганадан калкып чыккан кебек итеп коелган, ул, үз эченә йомылып, бар ихтыярын, рухи көчен бер ноктага төбәгән. Кулына перчатка тартып кигән чагы — операциягә әзерләнәдер, мөгаен. Җәйге җылы, якты бу иртәдә, сары тәлгәшләреннән бал коеп утырган куе юкәләр ышыгындагы бу сын кешеләргә дөньяда бәхетсезлекләр барлыгын, аларга ярдәм кирәген кисәтеп торадыр кебек.

Гинекология бүлеге клиниканың икенче катында. Аның иркен, биек коридорына сул яктагы тар тәрәзәләрдән кояш нурлары төшеп, иске паркет идәнгә киң тасмалар булып сузылып яткан. Аргы баштан Изаил Харисович килеп чыкты да, профессорны күреп алып, каршыга атлады.

— Хәерле иртә, Җәмилә Закировна! Бик вакытлы килеп җиттегез! Операциягә әзерләнәбез!

Остазының киләсен белгән, көткән диярсең, озын сынын алгарак авыштыра төшеп, тешләрен җемелдәтеп, каршыга килеп тә басты.

Елмаешып исәнләшкәч, Җәмилә Закировна доцентның халат аша бүлтәебрәк торган бил турысына ымлады.

— Үсәбезме, Изаил Харисович?

— Дәрәҗә өчен бераз анысы да кирәк, Җәмилә Закировна. Югыйсә авырулар бала-чагага саный.

— Ә мин бер генә минутка. Бүген китәм, шуңа танышым белән саубуллашырга дип кенә кердем. Биредә беркеме дә юк бит аның, күңелен күтәрергә кирәк бераз.

Чыннан да, операция бик четерекле булганга күрә, Диләрам бирегә килгәнен туганнарыннан да, якыннарыннан да сер итеп саклаган иде.

Җәмилә Закировна Дәүләтшингә чын күңелдән уңыш теләде дә коридорның күләгәле борылышына, андагы ак ишекләрнең иң ахыргысына таба юнәлде.

Диләрам кулъюгыч өстенә диварга беркетелгән көзге каршында чәч тарап тора иде. Җәмилә Закировна килеп кергәч, кулындагы сөяк тарагын идәнгә төшереп җибәрде, үз күзләренә үзе ышанмагандай, бертын профессорның көзгедәге чагылышына карап торды, аннары, бу шәүләне югалтудан курыккандай, әкрен генә борылды.

— Җәмилә Закировна... Җәмилә Закировна! Ә мин килмәссез дип курыккан идем! Шулхәтле курыккан идем, Җәмилә Закировна!

Ул профессорның кочагына ташланудан көчкә тыелып тора, чөнки аңа якын килүгә кара йөзем төсле күзләреннән чык тамчылары коела башлаячагын сизә иде.

Мондый чакларда авыруларга тәмам җебеп төшәргә ирек бирергә ярамый, шунлыктан Җәмилә Закировна, бик тә тыныч, хәтта бераз кырысрак тавыш белән:

— Борчылырга бернинди дә сәбәп юк, Диләрам,— диде.— Син авырту сизмәячәксең, йоклап кына алачаксың, ә торуыңа һәммәсе үткән булыр. Изаил Харисович бу эшкә алынган икән, сөенергә кирәк.

Доцентның исемен ишеткәч, кыз карашын аска төшерде.

— Операциягә сез дә керәсездер бит, Җәмилә Закировна?

— Мин монда бит инде, Диләрам! Мин монда...

Ашыгып шәфкать туташы килеп керде. Профессорны кыска гына сәламләде дә Диләрамга ябырылды:

— Ахунова, син нишләп аяк өсте? Мин сиңа укол ясагач әйттем бит, ятып торырга кирәк, дип. Егерме минуттан син йокыга талачаксың!

Диләрам айнып киткәндәй булды, идәннән тарагын алып, чәчен тараргa кереште. Аның нечкә беләзекле кулы баш түбәсеннән аска шуышкан саен тез астына кадәр төшкән чәч агымы чайкалып куя иде. Менә ул маңгай турыннан нечкә бер тотам аерып алды да тегәрҗептәй нечкә итеп үрә башлады.

— Син нәрсә, кырык үрем ясамакчымы әллә? — дип пошаманга төште шәфкать туташы. — Кая, үзем генә үреп бирим!

Диләрам аны йомшак кына читкә этәрде. Аның хәрәкәтләре йокымсыраган кешенеке кебек салмаклана башлаган иде инде.

— Ашыктырмагыз,— диде Җәмилә Закировна.— Үзе теләгәнчә эшләсен.

Диләрамның күнеккән нечкә бармаклары күз иярмәс тизлек белән хәрәкәтләнә иде. Чәчен ул гадәтенчә, әнисе, әбисе үргәнчә үрергә тели, гүяки бу аңа җан тынычлыгы, операциянең уңышлы үтәчәгенә ышаныч бирә иде.

Җәмилә Закировна караватларында шым гына утырган биш-алты хатынны күздән кичерде, кырый тумбочка өстендә яткан кулъяулыкларны күреп алды. Алар ал, яшел, зәңгәр ефәк җеп белән читләнгән, өстәгесенең чигешенә энә кадалып, аннан алтынсу җеп сузылып төшкән иде.

Профессор гажәпләнеп тумбочкага якынрак килде.

— Ул чигә,— диде ияге белән шыпырт кына Диләрамга ымлап янәшә караваттагы хатын.— Туйга әзерләнә. Ярәшкән егете бар икән...

Диләрам толымнарын үреп бетерде дә, барысын бергә җыеп, баш түбәсе тирәли кыршау ясап урап куйды, өстеннән ак кыекча бәйләде. Ул арада тәгәрмәчле ятакны тәгәрәтеп керттеләр. Диләрам аңа авырлык белән менеп ятты — аны тәмам йокы баскан иде инде. Кыз үзенең бөтен киләчәген, мәхәббәтен, булачак туен, туачак балаларын, гомерен — барысын, барысын да башкалар кулына ышанып тапшырган, нинди генә куркыныч янаса да, ни бер хәрәкәт ясап үзен яклый алмаячак иде.

Аның сузылып яткан нечкә сынына карагач, Җәмилә Закировнаның күңелендәге очкын көйдереп торган нокта янә сызлый башлады.

Ул палатадан чыгып барган ятак артыннан иярде. Операционный турына җиткәч, кинәт, үзе дә сизмәстән, шәфкать туташына:

— Миңа да чиста халат табылыр бит сездә? — диде.— Кулны да юарга кирәк булыр.

Бүлмәгә ул соңарыбрак керде. Изаил Харисович белән ассистент иелгән башларын күтәреп карамадылар, кайсы идәнгә, кайсы озын тәбәнәк эскәмияләргә тезелеп баскан ак халатлы, битлекле егет-кызларның кайберләре генә ишек ягына күз сирпеп алды — доцент бу операциягә дистәгә якын студентны чакырган иде. Җәмилә Закировна тавышсыз адымнар белән өстәлгә якынрак, ассистент артына барып басты. Бер карауда аның күңеле тынычланып китте: инструментлар тиешле тәртип белән янәшә тар өстәлдәге ак җәймәгә тезелеп куелган, операция сестрасы кирәклесен хирург кулына тоттырып кына тора, анестезиологлар бик игътибарлы — һәммәсенең үз урынында эшен белеп төгәл башкарганы күренеп тора иде.

Биредә дә сынатмаган Дәүләтшин, зур гына коллективның оста оештыручысына әверелеп өлгергән. Үзенең дә хәрәкәтләре төгәл, җитез һәм — профессор шунысына аеруча игътибар итте — йомшак, сак иде. Скальпель нәкъ кирәгенчә генә сыза, тамчы да артык яра ясамый. Тыныч, җиңел эшли доцент, шул арада ак битлеге астыннан бәрхет кебек ягымлы булып чыккан тавыш белән яшь табибларга аңлатма да бирeп өлгерә.

Менә операциянең иң мөһим, җаваплы өлеше башланды, Изаил Харисович скальпель белән озын гына итеп сызып җибәрде. Шунда кинәт нидер булды: һава эсселәнеп киттеме, түшәмгә асылган көчле лампаларның яктылыгы кимедеме, Җәмилә Закировнаның колагы томаландымы — доцентның тавышы ерагайды, сүзләре аңлашылмас булды. Нәрсәдер үзгәрде, ләкин моны профессордан гайре һичкем сизми иде әле. Ул, алгарак узып, ассистент белән янәшә басты да, битлек астында кызышып киткән иреннәрен авыр хәрәкәтләндереп:

— Изаил Харисович, уң якны күтәреп, эчкәрәк карагыз әле,— диде.

Доцентның саргылт резин перчатка эчендәге бармаклары яра эчендәге калын ярыга юлыкты. Аның куе кашлары арасында ике буразна уелып керде, ул тураеп басты да маңгаеннан тир тамчыларын сөртергә дип үрелгән операция сестрасының кулын этәреп җибәрде:

— Нәрсә карап торасыз? — диде яшьләр төркеменнән алдарак басып торган өлкән яшьтәге ханымга. — Хирургларга шалтыратырга кирәк, хәзер үк берәрсе килеп җитсен!

Ханым ак күләгә кебек тавыш-тынсыз гына атлап ишеккә юнәлде.

Хәзер инде операцияне алдан уйлаганча күргәзмә дәрес формасында үткәрү мөмкин түгел, гомумән, аны туктатып торырга кирәк иде, чөнки калын яры астында ни барын белү өчен эчәкләргә, башка эчке әгъзаларга кагылырга кирәк, ә моны фәкать тәҗрибәле хирург кына эшли алачак. Доцентның бармаклары таштай катыланды, ахрысы, орынган җирләрендә тап кала башлады.

Җәмилә Закировна, ни тыелырга тырышса да:

— Саграк...— дими булдыра алмады. Ул арада теге хатын борылып керде: якындагы хирургия клиникасында операция бара икән, буш хирург юк, дигәннәр. Изаил Харисович нидер мыгырданды,

сүзе аңлашылмады. Җәмилә Закировна, операция бүлмәсеннән чыгып, унбишенче больницага, профессор Петровка шалтыратты. Шөкер, ул урынында булып чыкты.

Ильясова кире әйләнеп кергәндә, яшь табиблар чыгып киткән иде инде. Диләрамның баш очындагы аппаратлар тирәсендә зур хафага төшкән ике анестезиолог кайнаша — операциянең сузылуы аларның җилкәсенә зур авырлык салган иде.

Ә профессор белән доцент икесе — зур галим табиблар — өстәлнең ике ягында кара-каршы сүзсез басып тордылар. Арада ярдәмгә мохтаҗ Диләрам ята, аның һәр сулышы, йөрәк тибеше Җәмилә Закировнаның чигәсендә сулкылдау булып чагыла иде.

Медицинада өч дәвалау чарасы бар: сүз, үлән, пычак, диләр. Профессор Евгений Михайлович Петров бу чараларга тагын берне өстәгән: кыяфәте белән дә дәвалый — аның үзен күргәч үк сызлаулар кимегәндәй була. Бу юлы да операция бүлмәсенә киң җилкәле, таза гәүдәле профессор килеп кергәч, күңелдәге авыр ташны алып ташладылармыни, сулыш алулары җиңеләеп китте. Ул өстәл тирәсендәгеләрне көлемсерәп күздән кичерде дә:

— Сез дә безгә эш таптыгызмыни, коллегалар? — диде.— Ну, нинди күчтәнәч әзерләп куйдыгыз монда миңа?

— Сюрприз! — диде Изаил Харисович шаяруны тотып алгандай итеп кенә. — Безнең эштә көтелмәгән хәлләр булып тора шул инде, үзегез беләсез.

— Дәреслекләрне ешрак кабатлап укырга кирәк, көтелмәгән хәлләргә сирәгрәк юлыгырсыз. Авыруны операциягә алганчы ашказаны-эчәк системасын тикшертергә тиеш идегез бит сез! Кара эшне яратмыйсыз, шунлыктан методиканы бозгалап торасыз, беләм мин сезне...

Евгений Михайлович боларны шаярып бармак янагандай итеп кенә әйтте, әмма сүзләренең төбендә дөреслек ята иде. Ул моңарчы да Дәүләтшинның кайбер гөнаһлары турында ишеткәләгән булса кирәк.

— Хәер, Җәмилә Закировна ассистент булып басса, без бу хәлдән чыгу чарасын табарбыз дип уйлыйм,— дип дәвам итте хирург, алдагы кинаясен җиңеләйтергә теләгәндәй итеп. Ләкин бу сүзе дә юкка түгел: шушы бер җөмләсе белән ул җиңел генә итеп Дәүләтшинны операциядән бөтенләй читләштереп тә куйды.

...Алар соңгы җөйне салып баш калкытканда, бүлмәдә доцент юк иде инде.

— Менә күпме эш ясадыгыз бит сез миңа, хәзер инде көннең көнендә авыру янына килеп йөрергә кирәк булачак,— диде Евгений Михайлович.

— Сездәй осталарны эшсез тотмаслар шул инде. Мәсәлән, әгәр дә минем үземә операция ясатырга кирәк булса, беркая да бармаячакмын, сезнең больницага гына кереп ятачакмын, — диде шаяртып Җәмилә Закировна.

Юри генә әйтелгән бу сүзләрнең ел ярымнан чынга ашачагын икесенең берсе дә башына китермәде, билгеле.

***

Лариса халык арасында әллә каян күзгә ташланып тора. Вокзал артына, перронга чыгу белән, Зәйтүнә аны күреп алды да Әнвәргә:

— Әнә безнекеләр! — диде.

Зур-зур чемоданнар янында Лариса, Хөсәен, Кифая сөйләшеп торалар иде. Кифая янында Лариса аеруча балкып күренә. Биек үкчәле кызыл туфли, кызыл чалбар, зәңгәрсу ефәк кофта, җирән бөдрәләр, битен яртылаш каплаган кара күзлек. Кофтасы арттан бик тирән итеп уелган. Кояшта янган нәфис, шома тире астында кечкенә калак сөякләре уйнаклап ала, алар арасындагы уенты, билгә таба тирәнәя төшеп, бар карашларны үзенә тарта иде. Үз мәшәкатьләре белән тыз-быз йөргән кешеләрнең күбесе аның тарафына борылып карамыйча үтә алмый. Хөсәен, кызны ят карашлардан ышыкларга теләгәндәй, Ларисаның иңеннән салынып торган сумкасын аркасына табарак шудырды. Лариса борылып карады, Зәйтүнә белән Әнвәрне күреп, күзлеге астыннан елмайды:

— Зюзю, Анварчик! Вот молодцы! Без инде сез килеп җитә алмассыз дип куркып тора идек!

Якын дуслар белән саубуллашканда ни сөйләшәсең? Иң мөһим сүзләр инде күптән әйтелгән, шул ук вакытта күңелне нечкә телле сагыш ялкыны көйдерә: дустың синең тормышның бер ямьле өлешен үзе белән алып китәдер кебек. Сәерлеген, бераз җиңел уйлавын белсә дә, ярата иде Зәйтүнә шат күңелле, хәрәкәтчән, ачык һәм пөхтә Ларисаны, аның белән яшәү кызыграк иде.

Әлегә янәшә басып торсалар да, аерылу авырлыгы күңелне изә башлаган, ләкин үзләре моны сиздермәскә тырышалар, күтәренке тавыш белән шаярышалар иде.

— Миннән ахмак кеше бар микән, Зюзю?! Кем соң инде үз ихтыяры белән Себер китә!

Көлешеп декабрист хатыннарын телгә алдылар.

— Без синең исемеңне Волконскаялар, Трубецкаялар белән рәттән тарихка язып куячакбыз, — диде Әнвәр.

— Әйе-әйе, анда нәкъ менә Нигъмәтуллина фамилиясе җитми иде!

Лариса күзлеге астыннан йомры гына булып күренеп торган сөйкемле борынын җыерып көлде.

Барысы да, дәррәү борылып, узып барган Җәмилә Закировна белән баш иеп исәнләштеләр. Профессор янәшәсендә урта яшьләрдәге хатын белән бер ир кеше дә бар иде.

— Кемне озатасыз? — дип сорады ул, туктала төшеп.— Мин унберенче вагонда,— диде аннары Лариса белән Хөсәенгә.

Вагоннарга утыра башладылар. Тар коридор буйлап кысрыкланып эчкә уздылар.

Купеда кара-каршы бер ир белән хатын утыра иде. Ишек ачылгач, хатын торып басты. Карап торуга егерме биштән узмаган бу хатынның ике чигәсендәге чәч тотымнары көмеш сыман агарып чыккан, бу аның елмаюдан балкыган яшь чыраена сәерлек бирә иде.

— Динә! — дип кычкырып җибәрде арттан килеп кергән Кифая.— Әллә син дә берәр кая барасыңмы?

Көмеш чигәле хатын сөенгәндәй көлеп җибәрде, Лариса белән Зәйтүнәне читләштереп, Кифаяның кочагына сыенды.

— Исәнме, Кифая! Юк, мин китмим, җанкайны озатам менә. Елашып, хушлашып утырабыз!

Һәм башын иеп утырган ирнең түбәсенә көлеп, үртәп ымлады.

— И-и, синме соң инде елый торган кеше! Сине елата алмаслар! Шулай бит, Мөдәррис?

— Исәнмесез! — диде Мөдәррис, башын чак кына калкытып. Маңгаена сибелгән йомшак чәче астыннан аның очлы борыны күренеп китте.

— Китә бирсен, тотмыйбыз! — диде Динә, тагын көлеп.— Гел кайтмаса да сүзебез булмаячак! Хөррият бездә!

— Мөдәррисеңә эре борчак ашаттыңмы әллә? Сөйләшәсе дә килми,— диде Кифая.

Мөдәррис кыска җиңле шакмаклы күлмәге астыннан йомры иңбашын гына сикертеп куйды. Үзе исә купеда купкан ыгы-зыгыга да, хатынының үчекләп әйткән сүзләренә дә битараф калды.

Хушлаша башладылар. Лариса, күзлеген салып, башта Кифаяны, Зәйтүнәне кочаклап үпте, аннары Әнвәрнең муенына сарылды. Әнвәр дә башын бормады, авызын Ларисаның иреннәреннән тартып алырга ашыкмады. Зәйтүнә аның күзләрендә күңелне шомландыра торган сәер елмаю кабынганын күреп алды.

Чыгып киткәндә генә искәрде ул: алдан кереп урнашкан теге ир белән хатын бу ыгы-зыгыда иркенләп хушлаша да алмадылар бугай. Мөдәррис дигәне һаман түрдә утыра, Динә исә ишек янында калган. Ул «хуш» дип җиңелчә генә кулын селекте дә беренче булып чыгып та китте.

Перронга чыккач, шактый вакыт вагон тәрәзәсе каршында басып торырга, пыяла аша аңлашылмый торган сүзләр әйтешергә, елмаешырга туры килде. Тыштагылар да, эчтәгеләр дә үзенә бер зарыгу кичерә иде, бу кыенсыну күзләрен кыса төшеп, юка ирен читләрен өскәрәк күтәреп карап торган Мөдәрриснең йөзендә аеруча нык чагылды. Ул әледән-әле бармакларын пыялада тыпырдатып нидер аңлатырга тели, ә Динә аңа көлеп кенә җавап бирә иде.

Ниһаять, вагоннар дыркылдап алдылар да алга таба шуыша башладылар. Озатучылар, ясалма елмаю белән кулларын болгап бераз янәшә баргач, кайтыр юлга борылдылар.

Динә Кифаяны култыклап алды да, читкәрәк әйдәп, көлә-көлә нидер сөйләргә кереште. Читтән карап торганда, аны анекдот сөйли дип уйларга булыр иде.

Трамвай тукталышына җитәрәк, Кифая Зәйтүнәне чакырып алды.

— Зәйтүнә! Динәне бер бәладән коткар әле, зинһар.

Динә, шаяргандай итеп, Кифаяны читкәрәк тартты, аның киң тегелгән җиңсез юка күлмәге тартылып, гәүдәсенә сыланып алды. Хатын йөкле иде. «Бу миннән алданрак табачак икән баласын,— дип уйлап куйды Зәйтүнә.— Биш айлык чамасы булыр».

— Сиңа бер сүз әйтсәң, шул булыр инде, — диде Динә, Кифаяны җиңелчә шелтәләгәндәй итеп.— Иләк авыз!

— Кирәкмәгән кешегә сөйләмим бит мин аны! Зәйтүнә клиникада эшли, бөтенесен булдыра ала. Тәжрибәсе зур аның, яшьлегенә карама!

Кифая Әнвәр ягына күз ташлап алды да, Зәйтүнәнең колагына өреп һәм кытыгын китереп:

— Котылдырып чыгар инде шуны, эшлә бер яхшылык, буш итмәс,— дип пышылдады.

— Нәрсәдән котылдырып? Шушы хәленнәнме?

— Хәле шушындый булмаса, ул синең белән миңа ялынып та йөрмәс иде инде!

Зәйтүнә артка тайпылды.

— Мин андый эшләр белән шөгыльләнмим. Нәрсә ул, үз акылындамы соң? Алданрак карасын иде!

— И-и, кыланмасана! Яхшылыгыңны кызганасың инде, фәкать шул гына! — Кифая Динәгә борылды.— Кайгырма, авылдаш! Фидая белән сөйләшеп карарбыз. Әйдә, әнә дүртенче трамвай килеп ята!

Кифая, Зәйтүнә белән төксе генә саубуллашып, Динәне трамвай ишегенә әйдәде. Аларны этә-төртә ишектән берсе өлкәнрәк, икенчесе яшьрәк ике хатын-кыз килеп чыкты. Картрагы Зәйтүнәдән:

— Харьков поезды килмәдеме икән, белмисезме? — дип сорады.

— Ишетмәдем шул.

— И Ходаем, соңга калдык микән инде! Кайчан шушы поездлар баш катырмый гына расписание белән йөри башлар икән? Алтынчәч! Әйдә тизрәк! — диде ул кулына чәчәк бәйләме тоткан күзлекле яшь хатынга.

...Ул кичне Зәйтүнә ире янында гадәттәгедән ныграк оялу сизде. Әнвәр дә ничектер тынып калган иде, сызымнарына утырмады, йөзендә теге, вагон эчендә кабынган сәер елмаюны саклаган килеш, тиз генә чишенеп урынына ятты. Нур шәүләсенең яктысы бүген Зәйтүнәгә түгел, каядыр читкә, ә бәлки, төн караңгылыгын ерып, тәрәзәләре белән балкып, күңелле тыкылдавы белән киң кырларны, урманнарны уятып, еракка ашкынган поездга юнәлгән иде бугай...

Зәйтүнә беренче тапкыр күңеленә көнләшү иңгәнен тойды. Ул, караңгыда төнге күлмәген киеп, ире янына ятты, бар кыюлыгын, батырлыгын җыеп, аңа елышты.

— Сиңа орынырга да куркыныч бит хәзер,— диде Әнвәр, пышылдап.

— Ул чаклы түгел инде... Өч айлык кына бит әле...

— Юк, барыбер онытылырга ярамый. Сакланганны Ходай саклар, ди безнең әни. Йокла тынычлап... Сезнең хәлдә йокы бик татлы була, диләр.

Һәм ул Зәйтүнәдән читләште. Сүзләрен йомшартырга теләгәндәй, учы белән хатынының иңеннән сыйпап куйды, ләкин бу нур шәүләсенең шуып үтүе кебек кенә булды, аның чын яктысы, җылысы янә караңгыга, каядыр еракка сикерде.

***

Дүртенче трамвайдан кабаланып төшкән карт хатын белән яшь хатын вокзалга нәкъ минутында килеп җиттеләр. Харьков поезды туктаган гына, вагоннарның ишеге ачылып, беренче пассажирлар төшә башлаган иде. Карт хатынның тәҗрибәсе җитәрлек икән, вокзал артына перронга чыгуга:

— Әйдә, Алтынчәч, әйдә,— дип, яшь хатынны сулгарак тартты.— Бишенче вагон менә монда ул.

Тегесе исә кинәт аягы авырайгандай атлый башлады, кулындагы чәчәк бәйләмен себерке шикелле аска төшерде, күзлегенең калын пыялалары ялтыравында ук аптырау, каушау сизелде.

— Әйдә инде, — дип ашыктырды аны өлкән хатын. — Әнә күрәсеңме, вагоннан чыгып килә җанашым! Линар! Линар! Без монда!

Халык төркеме өстеннән йомры башы шактый ук калкып торган таза гәүдәле ир кеше, чемоданын болгап, боларга таба атлады.

— Саумысыз, Мөһимә апа! Иминлекме?

— Исәнме, җанашым! Саумы! Менә Алтынчәч тә килде. Сине каршы аласымны белгәч өзгәләнде, мин дә барам, дип. Каршы килмәдем, күңеле булсын дидем.

— Әйбәт, бик яхшы, — дип, тыгыз тешләрен күрсәтеп елмайды Линар. — Ну, Алтынчәч, нихәлләр бар?

Шулай диде дә буш сул кулы белән кызның аркасыннан баласытып кагып куйды. Алтынчәч кызарынды, күтәрелеп бер генә карады да, егетнең тешләреннән күзе чагылгандай, башын аска иде.

— С приездом... — дип, кулындагы чәчәк бәйләмен сузды.

— Кая, бир чемоданыңны! — дип кулын сузды Мөһимә.— Юлда арыгансыңдыр!

— Что син, Мөһимә апа! — дип, таза муенын текә генә борды Линар. — Чемоданымны апама асып, үзем ике кулымны селтәп барырга, кем дип белдең син мине! Кызлар яратмас!

— Менә шундый инде безнең Линар! — дип, Алтынчәчкә карап, ачык шәмәхә төсле кримплен күлмәгенә чак сыйган күкрәкләрен дерелдәтеп көлеп алды Мөһимә.— Кешегә салына белми җанаш!

Аның иртә сулган киң, майлы чыраенда энекәше белән горурлану ярылып ята иде.

— Такси алабызмы соң? — дип сорады Линар.

— Ике адымга такси яллап торалармыни! Аннан башка да барасы җирләрегез булыр әле. Рәхәтләнеп икәү парлашып әйләнерсез кала урамнарын таксида!

Алар берәр-икешәр катлы агач йортлардан торган тар һәм шау-шулы, тузанлы урам буйлап киттеләр. Юл буе Мөһимәнең ирләрнеке кебек калын тавышы тынып тормады. Аның сүзләрен ара-тирә машина улавы күмеп киткәли дә Линарның тыныч, ничектер тәкәббер тавышы бүлгәли иде. Апасыннан ким дигәндә егерме биш яшькә кечерәк булса да, ул үзен аның янында олы сымак тота һәм, баланы өйрәткәндәй, һәр сүзен ныклы ышаныч, өстенлек белән әйтә иде.

Сүз нигездә фатир хакында барды. Мөһимәнең чираты җиткән дә, торак мәйданы бирәләр — ике бүлмәле фатирның кече ягына күчәргә тәкъдим итәләр икән.

— Өйдәш керү заманнары күптән үтте бит инде, — диде Мөһимә, кызып. — Әйттем әле квартбюродагы Михайлов дигән адәмгә, син монда атаң малын өләшеп утырмыйсың, дидем. Мин — хезмәт ветераны, гомер буе фабрикта эшләп саулыгын югалткан хезмәт иясе, дидем, үзәгегезгә үтәрмен, цыкага барып җитәрмен, барыбер үземнекен итәрмен, дидем.

— Куркытып тотынма син, апа! Бүкәй белән кемнең котын алмакчы буласың? Син кешенең күңелен күрергә тырыш! Көйләү җаен тап! Закон белән хәзерге заманда дурак кына йөри.

— Квартир сатып алырлык акчам юк шул минем. Булса да бирмәс идем. Закон белән куркытып үзәкләренә үтәм әле мин аларның! Хокук дип асларына су йөгертәм!

Алар ике катлы агач йортның тар, текә баскычыннан күтәрелделәр. Мөһимә өч йозакны бер-бер артлы шалтыр-шолтыр ачты да кунакларны эчкә чакырды. Коридорлы, мичле, ике бүлмәле борынгы фатир иде бу. Өстәлдә ашъяулык, урындыкларда ситсы кисәкләреннән ясалган корама япмалар, тәрәзә өсләрендә челтәрле кашагалар, түрдә түгәрәк көзге — кыскасы, оста куллы җиңгиләр җиһазлаган авыл өйләрендә генә була торган күркәмлек, ямь бар иде бу өйдә һәм мондагы гади матурлыктан күңел җылынып китә иде.

Алтынчәч, шкафтан ваза алып, чәчәк бәйләмен утыртып өстәл уртасына куйды да, ак кофтасы белән күксел юбкасы өстеннән Мөһимәнең чуар халатын киеп, көлсу бөдрәләренә тастымал урады.

— Чалмага охшаганмы? — дип сорады.

— Чын-чынлап изге зат булдың! — диде Линар.— Кил әле, пәп итим бер.

— Чү! — Алтынчәч, Мөһимә күрмиме дип, кухня ягына күз төшереп алды.

Алар Мөһимә белән икесе, тату каенана белән килен кебек чөкердәшеп, табын әзерләргә керештеләр. Тиз өлгерттеләр, салатка дигән яшелчә турап суыткычка куелган, токмач киселгән, шампан шәрабы суытылган иде.

Табын янында бу өч кеше тәмам үз булып киттеләр. Мөһимә — Украинадагы һава хәлләре, Линар Казандагы базар бәяләре белән кызыксынды. Тик менә егет торган җирен мактап куйган саен, Мөһимә, авызын бөрештереп, сирәк керфекләрен каккалап, энесенә ниндидер ишарә ясагандай итенә иде.

Менә ул, буявы саргаеп кыршылган радиоланы ачып, татар көйләре уйната башлады. Линар диванга кырын яткан килеш «Сандугач»ны, «Гөлҗамал»ны, «Шахта»ны тыңлап-тыңлап торды да, кузгала төшеп:

— Ну, монда дөнья һаман шул килеш икән әле,— диде.— Син дә, апа, искереп беткәнсең... Радиолаң да кадими заманныкы, җырларың да. Хәзерге заманда кем җырлый да кем тыңлый инде моның ишене!

Һәм, чемоданын ачып, магнитофон тартып чыгарды. Шарт-шорт баскалаган иде, аннан карлыккан бер ир тавышы тыгыз ритмлы көйгә җырлап та җибәрде.

Линар Алтынчәчне биергә чакырды. Алтынчәч гәүдәгә җиңел, хәрәкәтләренең нәфис икәнлеген дә белә, әмма хәзерге кызларның иң кәттәләре төсле бөтенләй үк таралып китә алмый, тыенкы кылана. Линар исә, биергә бик үк оста булмаса да, үзен иркен тота, ни кылансам да килешә дип уйлый. Мөһимә, майлы чыраен электр яктысында елтыратып, яшьләргә сокланып утыра.

...Алар киенеп чыкканда, урамда ыгы-зыгы кимегән, шәһәр серле кыяфәт алган иде. Мондый сәгатьләрдә вакыт та үзенең агышын әкренәйткән кебек тоела. Алар, бу тынлыкны бозарга курыккандай, әкрен генә атлап киттеләр...

— Әйдә бергә көньякка барабыз,— диде Линар.— Анапага. Анда диңгез, ком, кояш. Аннан Новороссийскига, Абрау-Дюрсога барып була. Абрау-Дюрсода булганың бармы синең?

— Юк.

— Тау башындагы күл ул. Суы диңгез кебек зәп-зәңгәр, яр буйларында өянкеләр үсә. Ботак-тармаклары шундый ишле, куе, аска бөгелеп, очлары җиргә түшәлгән, суга чумган. Чын чатыр ясаганнар. Асларына кереп үбешергә була, һичкем күрмәячәк.

Шулай диде дә, Алтынчәчне сыңар кулы белән генә күтәреп, каты итеп иреннәреннән үбә башлады. Алтынчәч күзләрен чытырдатып йомды, тәнен — ялкын, күңелен оялу хисе көйдергәндәй итте... Киноларда күргәне бар: кызлар үбешер алдыннан күзлекләрен салалар. Бу рәвешле күзлек киеп үбешү көлкедер...

Менә Линар аның иреннәреннән аерылды, тик җиргә бастырмады, киресенчә, югары күтәреп, иңбашына утыртты.

— Карале ныгытып, Абрау-Дюрсо күренмиме анда?

Чыннан да, бик-бик югарыга менгәндәй хис итте үзен Алтынчәч. Күз күремендә шәһәрнең серле манзарасы киңәеп киткәндәй булды. Кремльнең биналары өстендә күккә ашкандай калкып торган Спас манарасының тәрәзәләрендә нәкъ шул мизгелдә гөлт итеп кызыл ут балкыды. Ул бер кабына, бер сүнә — сәгать унике булганны белдерә иде. Ә бәлки, бу сәгать сугуы түгелдер, борынгы биналарның йөрәк

тибешедер? Ә бәлки, алай гына да түгелдер, караңгы күк фонында яктырып-сүнеп торган бу ут — маяктыр! Гүя ул диңгезләрдәге корабларга юл күрсәтә, аларны, сак булыгыз, бу тирәләрдә хәвеф бар, дип кисәтә. Ә бәлки, ул аны, Алтынчәчне, кисәтәдер? Юк-юк, киресенчә, юл күрсәтә ул. Бәхеткә илтә торган юлны... Һәм Алтынчәчнең шул юлдан кораб кебек тирбәлеп баруы бу...

— Күренәме? — дип шаяртып сорый Линар.

— Күренә... Төнге диңгез, маяк...

— Ошыймы?

— Бик ошый!

Линар аны җиргә бастырды.

— Барабызмы соң диңгезгә, ә аннан Абрау-Дюрсога, дүрт су тарлавыгына?

— Минем чираттагы ялым ноябрь аена туры килә шул быел,— диде көрсенеп Алтынчәч.

— Сора соң яхшылап. Мондый форсат тагын кайчан була?

— Нинди форсат? Күл урыныннан күчмәс бит?

Линар, сул кулы белән галстугын бушатып, башын боргалап куйды.

— Путевка табу кыен хәзерге заманда. Быел табып була. Ә киләчәкне кем белгән?

Алтынчәчнең бармаклары Линар йодрыгы эчендә тыпырчынып куйды. Аларның заводында кемнең кайчан чираттагы ялга чыгасы ел башында ук билгеләнеп, расланып куела һәм бик төгәл үтәлә. Баласы булганнар җәйге каникуллар чорында ял бирүне сорый. Ялгыз башы яши торган Алтынчәчнең исә мондый үтенеч белән йөрергә нигезе юк. Гаилә хәле үзгәреп куйса гына инде...

Алар яныннан яшел утлы такси машинасы узып бара иде. Линар сызгырып аны туктатты. Машина, буш урамнардан гадәттән тыш тизлек белән чабып, Ленин районындагы биш катлы йорт янына килеп тә туктады. Линар шоферга акча сузганда, Алтынчәч:

— Җибәрми тор! — диде. — Шуның белән үк кайтырсың.

Ләкин егет бу сүзләрне ишетмәде дә кебек, машина китеп баргач кына борылып карады:

— Нишләп әле? Син мине бөтенләй сагынмадыңмыни?

Алтынчәчнең тамагына утлы төен килеп тыгылгандай булды. Сагынмаган кая? Тик аны менә шушылай гади генә итеп әйтеп буламыни?

— Күршеләрдән оят...

— Йоклыйлардыр инде. Һәммәсен күреп-күзәтеп тормасалар да ярар. Узган юлы берни булмады бит әле.

Соңгысын егет аеруча каты итеп, тавышына шик салып әйтте. Алтынчәч, аяк очларына күтәрелеп, аның күзенә туры карарга тырышты, ләкин Линарның күзләре багана башындагы лампочкадан төшкән яктылыкны гына чагылдыра, аларда йомшаклык та, аңлау-кызгану да сизелми иде.

— Булды... Узганында да булды...

— Ни булды? Кем алар сиңа? Бик тыкшына башласалар, җибәр син аларны... ераккарак! Бетмәс монда ханжалар.

Алтынчәчнең тар иңбашлары туңып киткәндәй бөреште, гәүдәсе кечерәеп калгандай булды.

— Аларда түгел хикмәт, миндә, үземдә... Яна менә монда, көйдерә... — Ул кулларын, йомарлап, йодрыкларыннан да кечерәк күкрәк алмаларына кысты. Бу хәрәкәт егетнең күзен ихтыярсыздан нәкъ менә шул ноктага җәлеп итте.

— Ну ярый, иртәгә кайчан килим соң? — диде ул, салкын гына.

— Иртәгә шимбә бит. Әйдә, Локомотив пляжына барабыз!

— Шунда очрашырбызмы?

— Әйе. Сәгать унбердә.

Линар каты куллары белән аны иңбашларыннан тотты да авырттырып үпте. «Тагын күзлегемне салалмадым,— дип уйлады Алтынчәч.— Салсаң да уңайсыз. Әрсезләнеп, үпкәнен көткән кебек буласың... Ә болай көлкедер...»

Ул шактый вакыт аның артыннан карап калды. «Борылып кара! Борылып кара!» — дип эченнән ялварды, карашы белән егетнең киң җилкәсен тишәрдәй булып. Ләкин Линар борылмады, олы юлга чыгып, такси машинасы туктатырга ашыкты.

«Юлдан арып килгән шул!» — дип, аны акларга тырышты Алтынчәч. Линарның бу рәвешле артык ялынып тормыйча гына китеп баруына һәм соңгы тапкыр үпкәндә сизелгән битарафлыгына хәтере калган иде аның. Аларның очрашмаганына дүрт ай бит инде. Ниләр генә уйлап бетермәде дә ни генә кичермәде бу вакыт эчендә Алтынчәч.

Ул, күршеләрен уятмаска тырышып, баскычтан сак кына менде, ишекнең ачкычын бик әкрен генә борды. Җәй көне бишенче катта су булмый интектерә. Төнлә су килгән икән, ул кранны чак кына ачып коенды, аннары бүлмәсенә кереп, тумбочка эченнән шыгырдап торган җәймәләрен алды да диванга урын җәйде.

Алсу абажурлы лампа яктысында урын-җир бигрәк ак, чиста күренде. Моннан дүрт ай элек кышкы бер төндә шушы җәймәләр өстенә шалкан кебек таза, ак, тыгыз тәнле ир-егет яткан иде. Диван-караватны киңәйтеп, иркенләп яткан иде ул монда... Бу күренеш исенә төшкәч, Алтынчәч үз-үзеннән оялып, җәймә чите белән йөзен каплады. Аннары, утны сүндереп, салкынча, бераз катырак җәймәләр эченә чумды. Башыннан ук капланып, истәлекләрен куарга, онытырга теләде, әмма кузгалган күңел тиз генә тынычлана алмады.

Менә дүрт ай инде аның тынгы күргәне юк, дүрт ай инде күңелен әле утка салган, әле боздай өшеткән тойгылардан арына алганы юк.

Бу уйлану газаплары Мөһимәне туган көне белән котларга барган кичтән башланды. Тиз генә тәбрикләргә дә телевизордан фильм башланганчы кире кайтып җитәргә иде аның нияте.

Ләкин ул кино башлангач та, тәмамлангач та кузгалып чыгып китә алмады. Нәкъ шул көнне Мөһимәнең туганнан туган энесе Линар кайтып төшкән булып чыкты. «Мактап кына йөрисең икән, иң якын кешеләрем җыелды бүген», — дип, диванга энесе белән янәшә утыртты аны Мөһимә. «Эчмәсәң, үпкәлим, минем хөрмәткә бер бокал шампанский да күтәрмәскә!» — дип кыстый-кыстый эчерде.

Ул кичне «Белгечләр тикшерү алып бара» дигән фильмның чираттагы сериясен күрсәтәләр иде. Кино белән мавыгып киткән Алтынчәч сизми дә калган, берзаман исенә килсә, аның иңбашы егетнең беләгенә терәлгән һәм үзен бу хәлендә бик рәхәт хис итә икән. Ул кылдай тартылып читләште, борылып Линарга карады, егет тә аңа текәлде һәм аларның карашлары якыннан, бик якыннан очрашты.

Шул мизгелдә Алтынчәч гадәттәге кыюсызлыгын онытып җибәрде: кич буе сизми утырган — егетнең уң күзе пыяла икән ләбаса. Дөрес, ул шундый матур ясалган һәм оста куелган, нәкъ сул күзе төсле, ләкин барыбер җансыз, нурсыз...

Алтынчәч, гажәпләнүен сиздермәс өчен, тизрәк экранга борылды, тетрәнгән бармаклары белән итәген рәтләштерде һәм бу юлы инде аңлы рәвештә иңбашын егеткә таба авыштырды.

Ул үзе унөч яшеннән күзлек киде, класста бердәнбер күзлекле кыз булды, яхшы укып, алдан йөрергә, бөтен җирдә алдынгы булырга тырышкан кызга бу кимчелек бик нык комачаулый иде. Гел кимсенә иде ул начар күрүе аркасында, ничә еллар буе Дүрткүз дигән кушамат тагып йөрде!

Линарның да кимчелеге бар икән... Ул да Алтынчәч кебек үк кимсенеп үскәндер, малайлар-кызлар аңа да берәр ямьсез кушамат такканнардыр...

Бу уртаклык хисе Алтынчәчнең гадәттәге шикчәнлеген, тарсынуын киметте, шуның өстенә Мөһимә электән үк, институтны тәмамлаган Алтынчәч аңарда фатирда торган чакта ук, Линарны яратып һәм кызганып бик күп сөйли торган иде. «Бәхете булмады шул, атасы эчте, анасы холыксызланды, шуның аркасында әллә кая чит җирләргә чыгып китәргә мәҗбүр булды бәгырь парәсе, аннары килеп хатыннан уңмады... Менә аерылышалар инде... Менә аерылышканнар инде... Хатыны, җүнсез, бүтәнгә чыгып киткән... Синең кебек ипле-тыйнак, телсез-тешсез бер кызга тап булган булса, гөл арасында яшәтәчәк егет иде югыйсә...»

Бу кыйссалардан Алтынчәч күңелендә шулай ук үз язмышына охшаш язмыш — яшьтән кыерсытылган, үсеп җиткәч үз тиңен таба алмаган бер образ туды.

Дөрес, чынбарлыктагы Линар — шалкан кебек тыгыз, ак тәнле, туры муенлы ир-егет — ул образга охшамаган иде. Ләкин бу тышкы кыяфәт кенә бит дип уйлады Алтынчәч, ә бәлки, ул эчке сызланулары яшерер өчен махсус киелгән битлек кенәдер...

Һәм Алтынчәч үзенең хыялый җаны белән бу битлек астында башкаларга күренми торган нечкә күңелне, кызгануга һәм яратуга сусаган ялгыз җанны күрергә тырышты. Аны шундый итеп күрде, шулай икәнлегенә үз-үзен тәмам ышандырды.

Төн уртасында, кала урамнарында тыгыз карны шыгырдатып җитәкләшеп барганда, бу ышаныч артканнан-артты. Егет үзенең бик җаваплы эштә — зур заводның тәэминат бүлегендә эшләвен, командировкаларга еш йөрүен, кала читендә үз йорты белән яшәвен — гомумән, гап-гади нәрсәләр турында сөйли, ә кыз аның кыйссасында әйтелмәгәнне — яхшылыкка сусавын, үзен аңлаган бер нечкә күңелне гомере буе эзләп тә таба алмавын ишеткәндәй булып бара иде.

Ул чакта да Линар узып барган машинаны туктатты, ул кичне дә, Алтынчәчнең йорты янына кайтып җиткәч, шоферга акча сузды һәм, тураеп басып, кызның терсәгеннән тотып алды.

— Ник җибәрдең? — дип сорады ул чакта да Алтынчәч. — Үзеңә кайтырга җайлы булыр иде бит.

— Ничек инде, шушылай аерылышыйкмыни? — дип гажәпсенеп сорады Линар. Чыннан да, алар иң мөһим сүзләрне бер-берсенә әйтмәгәннәр иде бит әле! Уртак язмыш, балачакның рәнҗешләре, күңелләрнең ялгызлыгы хакында сөйләшәсе бар иде бит әле аларның. Һәм Алтынчәч егет белән төн буе шәһәр буйлап йөрергә әзер иде.

Тик Линарның уе башкада икән.

— Бу салкын төндә мосафирга бер чынаяк чәй дә эчермәс идеңме әллә? — диде. Һәм ул ялтыравык ботинкалары белән карны каты шыгырдатып таптанып алды. Харьков тирәсендә кыш

миһербанлырак, күрәсең, аның башында бу як өчен ятышсыз эшләпә, өстендә кыска замша пальто иде.
— Бер стакан Идел суын да жәллисеңме әллә миннән?

Алтынчәч аның кыяфәтен күздән кичерде дә ишеккә юнәлде.

Кара-каршы утырып, алсу абажур астында шыпырт кына сөйләшкәч, егет чыгып китәр дип уйлаган иде Алтынчәч. Әмма ул кузгалырга уйламады, киресенчә, диванга тагын да җәелебрәк урнашты, көчле куллары белән Алтынчәчне тартып китереп, тезенә утыртты. Әллә нишләде Алтынчәч, әллә ни булды аңа... Күзлек киеп үбешкәнгә оялудан, буйсындыручан, гайрәтле кулларның күкрәкләрне пешерүеннән хәле китте. Шуның өстенә шакылдаудан, тавыш чыгарудан, күршеләрне уятудан курыкты. Йа Алла, аннан соңгысын искә төшергәндә, бөтен тәнне ялкын чорнагандай була. Аннары... Линар торып утырган иде. Ул, йөзтүбән капланып яткан Алтынчәчнең аркасыннан сыйпап, колагына иелеп, кайнар пышылдады:

— Йә, керпе, нигә энәләреңне тырпайттың? Кайчан да булса, кем белән дә булса булырга тиеш идең бит инде син! Рәхмәт, мине көткәнсең. Без бик бәхетле бүген, шулай бит? Намусыбыз да саф, беркемгә дә хыянәт итмәдек. Әйдәле, урынны әйбәтләбрәк җәйик!

Алтынчәч торып басуга, ул диванны киңәйтте, аннары ак җәймәгә аякларын киң ерып чалкан ятты да изрәп йокыга талды. Алтынчәч аңа комачауламас өчен диванның кырыена ук шуышты. Аның уйлары буталган иде...

Әйе, ул чыннан да беркемгә дә хыянәт итмәде. Ләкин нигә соң йөрәк авырттырып чәнчи, нигә ул вөҗдан газабына охшаш утта яна? Үз тәненә үзе хуҗа, беркем каршында да йөзе кара буласы юк бит югыйсә!

Ләкин йөзе каралганын тоя иде ул, барыбер сизә иде. Хыянәт итте ул төндә Алтынчәч, башка берәүгә түгел, үз-үзенә, хыялларына хыянәт итте. Тормышында мондый борылышны ул бу рәвешле булыр дип күз алдына китерми иде. Һич юк.

Аның уенча, бу вакыйгага бик зур әзерлек белән, тантана, бәйрәм ясап килү тиеш иде. Кичләрен бүлмәсендә ялгызы йокысыз ятканда, аның хыялында мондый күренеш күзаллана иде: ул аяк очларына төшкән озын ак күлмәк киеп, җан сөйгән яры белән янәшә басып тора. Алар биек, иркен бина эчендә. Бинаның диварлары оста рәссамнарның картиналары, сыннар белән бизәлгән, түшәме күккә ашкан. Тирә-юньдә бихисап шәмнәр яна, илаһи музыка яңгырый. Бәйрәмчә киенгән егетләр аларның баш өстендә энҗеле тажлар тотып торалар, укалы киемнәр кигән ыспай агай:« Бәхет килгәндә дә, кайгы-хәсрәт, чир-чор булганда да, гомер кичкәндә дә, җан биргәндә дә бергә булыгыз», — дип, күңелне җилкендерә, бераз шомландыра торган тылсымлы сүзләр әйтә һәм балдак алышырга, аннары үбешергә куша. Бераздан аларны салмак атлатып ачык ишеккә таба алып китәләр. Биек баскыч төбендә пар ат җигелгән көймәле арба көтә. Атлар аларны ялгыз йортка алып китә. Ә анда әзер табын һәм кардай ак, йомшак ятак көтә.

Хыяллары бу ноктага килеп җиткәч, янбашларының, аякларының кызышып авырайганын тоя, аннан да гайресен күз алдына китерергә куркып, мендәр почмагын тешли торган иде ул.

Аннан соңгысын хыял белән генә күзаллау мөмкин дә түгел икән шул... Башның бөтенләй бушап калуын, тәннең утта януын, ләкин бу януның искиткеч ләззәтле булуын, бер мизгелдә башка берәүнең тәнендә эреп бетүеңне һәм йөрәгең туктап, инде башка яшәмәскә дә риза булырлык дәрәҗәгә җитүне ничек күз алдына китермәк кирәк?

Менә ул — аны тулысынча үзенә буйсындырган, үзе өчен җан бирер хәлгә җиткергән зат янәшә ята. Ләкин нигә соң әле бу төндә гамьсез йоклап ята ул? Хәтта җиңелчә генә гырылдаштырып та җибәрә? Күршеләр ишетсә? Алтынчәч өчен аңлашылмас каршылык иде бу. Таң атканчы әллә ниләр уйлап бетерде ул.

Күршеләр кузгалганчы дип, аннары сагышына да түзә алмыйча, Линарны бик иртә уятты. Егет киерелеп торды, бүлмә буйлап кулларын селеккәләп йөренде. Аның кәефе шәп иде. «Бүген кич туры монда килимме?» — дип сорады ул, гади генә. Ничек кенә текәлеп караса да, Алтынчәч аның исән сул күзендә дә, үз-үзен тотышында да дулкынлану әсәре сизмәде.

Линар чыгып киткәч, ул башын тотып өстәл янына утырды.

Күрше хатын Нәкыя эшкә китешли аның ишеген ачты да:

— Соңга каласың түгелме? — диде. Аннары көлемсерәп өстәп куйды: — Төн бик күңелле узды, ахрысы, синең...

Шул көннән Алтынчәчнең тормышы да, уйлары да икегә бүленгәндәй булды. Аның тышкы кабыгы гадәтләнгән юл буйлап эшкә барды, иреннәр күнегелгәнчә елмаеп, лабораториядәге кызларга сәлам бирде, куллар таныш эшне башкарды. Ә күңелдән ак, тыгыз, кайнар тәнле егет китмәде.

Аның төннәре, әле йөрәге тибүдән туктаса да, үкенмәслек дәрәҗәдәге ләззәтле минутлары искә төшүдән ялкынга чорналып, әле миен көйдергән шик һәм газаплардан кара сагышка уралып уза торган булды.

Линар аны шул ике газап арасында калдырып китеп барды. Шикләреннән дә арындырмады, өметләрен дә сүндермәде, ни яктылыкка чыгармады, ни төнгә кертмәде. «Озакламый киләм мин, көт!»

— диде. Алтынчәч аның бу сүзләрен бик мәгънәле итеп, «килгәч бергә булу хакында сөйләшербез» дип аңлады.

Вокзалда саубуллашканда, Линар, пинжәк кесәсеннән блокнот чыгарып, аның адресын язып алды. Алтынчәч үрелеп, «ул. Строетлная» дигән сүзне күреп алды. Бер сүздә ничә хата... Дөрес, Мөһимә аның турында, ата-анасы юньсез булу аркасында рәтләп укый да алмады, дип сөйли торган иде. Ләкин «Строительная» сүзен бишенче класс баласы да дөрес яза лабаса!

Алтынчәчнең рухына тагын бер газап өстәлде. «Андый шыр надан белән минем нинди уртаклыгым булырга мөмкин?» — «Мин аңа үсәргә, белемен арттырырга ярдәм итәрмен,— дип тынычландырды ул үзен.— Бергә генә булыйк, бөтенләй башка кеше итәрмен мин аны. Зиһенле бит ул, сөйләшкәндә бер дә ялгышмый».

Хатлар көтте Алтынчәч, әмма Линар бер хәбәр дә бирмәде. Түзмәде Алтынчәч, Мөһимәгә барды. «И-и, ир затының кайсы хат язарга ярата соң! — диде Мөһимә. — Алай да миңа 1 Май белән котлап открытка җибәргән әнә, сиңа сәлам күндергән».

Алтынчәч өч тиенлек открытканы суд криминалисты кебек тикшерде. Линар хәрефләрне бер-берсенә тыгызлап кысып, тигезсез яза икән. Сүз саен ике-өч хата...

Шунда аның эче җылынып китте. Линарның ни сәбәптән хат язмаганы билгеле: үзенең наданлыгыннан ояла ул! Язуын күрсәтәсе килми!

Бичара, юкка кимсенә ул, бер дә юкка ояла. Менә килсен генә, алар бу хакта җитди сөйләшерләр. Бу эштә аларның мәхәббәте ярдәм итәр...

Ниһаять, кичә Мөһимә аның өенә килеп, Линарның телеграммасын күрсәтте. «Киләм, каршы алыгыз», — дип хәбәр биргән егет. «Сине чакырган, сез диярлек тагын кеме бар соң җанашымның?» — диде Мөһимә. Һәм Алтынчәчне вокзалга барырга күндерде, хәтта базардан чәчәк алырга да ияртеп барды.

Инде менә зарыгып көткән очрашу булды. Ләкин Линар Алтынчәч кебек үк түземсезләнеп, янып-көеп көтмәгән, ахрысы, бу көнне. Югыйсә болай ансат кына борылып кайтып китмәс иде, болай салкын үпмәс иде. Алтынчәч аның башны миңгерәтеп, кочагында эретерлек итеп, ялкынга чорнап үпкән чакларын бик яхшы хәтерли ләбаса!

Хәер, теге чакта ул аның саф кыз икәнен белми кергән иде бит. Хәзер Алтынчәчкә мөнәсәбәте яхшырган, ихтирамы арткандыр. Ул аның йөз аклыгын саклый, күршеләр алдында оятлы итәргә теләмидер... Чыннан да, кая ашыгырга? Аларның бөтен гомере алда бит әле...

Кыштырдап торган җәймәләр арасында бер коега төшеп, бер кояшка күтәрелгәндәй тирбәлеп ятты Алтынчәч...

***

Җәмилә Закировна Мәскәүгә чаклы кызы Ләйлә белән бергә бара иде. Поезд кузгалуга, Ләйлә юлдашлары белән танышып та өлгерде. Алар купесына тагын бер кыз белән бабай утырган иде. Бабакай өске киемнәрен салып куйган, җылы күлмәк белән киң төпле ак ыштаннан гына калган килеш, кечкенә өстәл кырыена кадаклап куйгандай, ныклап урнашкан иде. Аның тезләре арасына салынып төшкән ак бауны күргәч, Ләйлә, пырхылдап көлүдән көчкә тыелып, проводница янына китте. Янәшә күпеда өч ир-ат арасында бер хатын бара икән, Ләйлә аны үзләре янына күчереп, бабайны аның урынына озатып куйды.

Җәмилә Закировнаның исә зиһене таралган иде, юл мәшәкатьләренә кулы бармады, коридорга, тәрәзә янына чыгып басты.

Поезд текелдәп Казаннан ерагая барган саен, аның иңендәге йөк тә җиңеләя иде шикелле. Йөгереп узган чакрымнар әйтерсең лә аның борчуларын берәм-берәм йолкып алып калалар иде. Фәкать бер генә уйны алар да оныттыра алмады — ул авыр уй бүген иртән булган хәлләр турында иде. Борчылуы Диләрам өчен генә дә түгел иде профессор Ильясованың — аны карарлар, клиника врачлары да аңа аеруча игътибарлы булырга вәгъдә иттеләр. Евгений Михайлович та көн саен барып торыр. Профессор Ильясовага тынгы бирмәгән кеше — доцент Дәүләтшин, дөресрәге, аның белән операциядән соң булган сөйләшү иде.

Клиникадан чыгып киткәнче, Җәмилә Закировна аның бүлмәсенә сугылды. Дәүләтшин өстәл артында авыру тарихы тутырып утыра иде, профессор кергәч, аягүрә басып, халатын тарткалады.

— Ялыккансыздыр, Җәмилә Закировна. Берәр стакан чәй китерикме әллә?

Бу минутта ару-талчыгу турында, чәй турында сөйләшергә әзер түгел иде Җәмилә Закировна. Доцент аңа башка сүзләр әйтергә — бүгенге аяныч вакыйганы ничек тә аңлатырга, авыруның хәлен, операциянең ничек тәмамланганын сорашырга, һич булмаса, кызарынып башын иярге тиеш иде шикелле. Ә ул остазының йөзенә туп-туры карап тора, агы зәңгәрсуланып торган коңгырт күзләре төбендә борчылу, үкенү, кыенсыну кебек хисләрнең әсәре дә чагылмый иде.

Изаил Харисович профессорның сүзсез торуын үзенчә аңлады, өстәл артыннан чыкты да, сеңлесен юаткандай, өстән аска карап, иелә төшеп:

— Артык авырга алмагыз инде, Җәмилә Закировна,— диде.— Кечкенә генә хата өчен сездәй зур галимгә кем сүз әйтә ала? Кем белә бит алай буласын, мондый очрак миллионга бер туры килә. Евгений Михайловичны чакырып бик дөрес иттегез, сезгә мөнәсәбәте яхшы, сер саклый белә. Ә мин инде, үзегез беләсез, сезне беркайчан да подводить итмәячәкмен!

Профессор баштарак доцентның тел төбен аңламый торды. Үз колакларына үзе ышанмый иде ул: Диләрамны тиешенчә тикшереп бетермичә операциягә салуда Дәүләтшин аны — Ильясованы гаепли түгелме? Әйе шул, бөтен гаепне аның өстенә аудара. Ул гына түгел, профессор Петровны да астыртын ният белән, хатагызны йолып калыр өчен чакырдыгыз, димәкче була.

Ә доцент һаман сөйли иде әле, ак башлыгын түгәрәк башына кыңгыр салып, бүлмә буйлап йөренә-йөренә сөйли иде:

— Сезнең бер нәрсәгә игътибар иткәнегез юкмы, Җәмилә Закировна? Була шундый хасталар, ни генә кыландырсаң да, бөтен эшең гел киребә генә китеп тора, бер дәва да шифа бирми. Андыйларны дәвалау ифрат кыен. Халыкта «кара эчле» дигән сүз бар бит әле. Хак сүз, минемчә. Андыйларның кара эчлелеге операция вакытында да үзен сиздерә. Бу... кем әле... Ахунова да шундый түгел микән?

— Бәлки, кайберәүләр операцияне кара күзлек киеп ясыйдыр, шуңа шулай тоеладыр? — диде Җәмилә Закировна.

Изаил Харисович тагын аңа гамьсез караш ташлады. Җәмилә Закировна, аның күз төпләрендә моңарчы сизелмәгән яман шеш күргәндәй, тетрәнеп китте.

***

— Булды, әни, төнлә тыныч лап йокларбыз, бабакайның гырылдавыннан котылдык.

Ләйлә әнисе янына чыгып басты да, битен вагон тәрәзәсеннән бәргән җилгә каршы куеп, рәхәтлектән күзләрен кысты.

Ә тышта җәйнең иң ямьле чагы. Агачлыклар, авыллар, бәрәңге кишәрлекләре, алмалары тулышып килгән бакчалар, түтәлләрдәге гөлләр — һәммәсе кайнар кояш астында җәйрәп, яшәешнең һәр күзәнәктән тулып ташыган тантанасы булып, күкрәп утыралар. Бер-бер артлы алышынып торган гүзәл манзараларга карап туймаслык иде.

— Әни, мин сине әсирлеккә алам бүген,— диде Ләйлә. — Студентларга да, аспирантларга да, авыруларга да бирмим. Монда телефон юк, машина белән дә килә алмыйлар. Бүген син — минем әнием, баштанаяк фәкать минеке генә. Профессорлыгыңны онытып тор!

— Бик онытыр идем дә, Ләйлүгем, менә мондагы уйларны кул белән генә алып ташлап булмый шул! — Җәмилә Закировна учын баш түбәсенә куйды.

— Уйларыңны миңа сөйлә, үзем таратышырмын.

Диләрам хакында Ләйлә белә иде инде. Җәмилә Закировна бүгенге хәлләрне кыскача гына сөйләп бирде.

Ләйләнең әтисенә охшаган, шәрык тибындагы чыгынкырак яңаклы, ияк уртасы чокырлы йөзе, озынча соры күзләре әнисен тыңлаган арада күләгәләнеп алды, анда сискәнү, курку, нәфрәт чагылды, коңгырт бөдрәләр белән яртылаш капланган маңгаен вак җыерчыклар сырлады.

Җиңел, хәрәкәтчән, тере гәүдәле Ләйләне беренче күрүдә, кырыкка җитеп килә торган хатындыр бу, кафедра җитәкчеседер, дип һичкем әйтә алмас иде. Хәлбуки ул — Англиянең Оксфорд университетында, Франциядә, Американың Мичиган университетында белем алып кайткан зур укытучы. Бу юлы да Мәскәүгә мөһим эш белән бара: техник вузларда инглиз телен укыту буенча өч курс өчен дәреслекләр язган иде ул, шуларны бөтен ил институтлары өчен басып чыгарыр алдыннан редактор белән соңгы тапкыр карап чыгарга кирәк иде.

Ләйләнең шәрык кызларына хас булганча кысыбрак уелган үткен күзләре кайбер очракларда әнисе күрмәгәнне күреп ала һәм ул профессор Ильясовага һич көтелмәгән киңәшләр биреп куя иде.

— Әни, син үзеңә килгән авыруларны юкка Дәүләтшинга җибәрәсең, — диде ул.

— Бу аның темасы бит, Ләйлүк, аның докторлык диссертациясе. Мин андый операцияләрне үзләштермәдем, ә Дәүләтшин аларның остасы санала.

— Әни, мин аптырыйм, ничек һаман аңламыйсыз сез: куркыныч кеше бит ул! Коточкыч куркыныч! Үзеннән бүтән һичкемдә бер гаме дә юк аның. Чөнки ул зур дәрәҗәгә ирешү, дан казану, күп итеп акча эшләү турында гына уйлый. Синең урынга үрмәләргә маташа! Ә сез — элекке буын кешеләре, беркатлы идеалистлар, явыз адәмнәрне чалыш авызлы, тонык күзле, караңгы чырайлы итеп күз алдына китерергә күнеккәнсез. Җиргә яңа буын килде, яхшылары да, яманнары да яңача хәзер, әни! Их, «һәр заманның була үзенә күрә сволочы, кайәр суккыры» дип шагыйрь юкка гына әйтмәгән шул! Хәзерге заман сволочларының бер ише чибәр, тәмле телле, уңган, өлгер, елгыр, әни! Үзләренә җай

килгәндә алар яхшылыкны да эшлиләр, тик юлларына аркылы төшәргә генә язмасын. Таптап үтәләр, елмаеп, тәмле сүз әйтеп, басып сыталар алар, әни! Сезнең Дәүләтшиныгыз нәкъ менә шундый камырдан әвәләнгән!

— Бер ялгышкан өчен кешене баштанаяк карага буярга ярамый алай, — диде Җәмилә Закировна.

— Ялгышуда түгел хикмәт, кешенең тормыш позициясендә! Үз хатасын башка берәүгә аударырга маташуында! Моны болай гына калдырырга ярамый, әни. Фаш итәргә тиеш син бу кешене, аның әхлакый йөзе турындагы мәсьәләне гыйльми советка куярга!

— Уйлап сөйлисеңме соң син, Ләйлүк, юкмы? Чит кафедра эшендә казынып, гаеп эзләү булып чыгачак бит бу!

— Кеше үтергәнен көтәргә кирәкмени?

Ләйләнең Дәүләтшинны ни өчен бу хәтле яратмавы Җәмилә Закировнага аңлашылып җитми иде. Хәлбуки мондый фикер Ләйләдә моннан шактый еллар элек туды.

Заманында студент Дәүләтшин Ләйләдән инглиз теле дәресләре алып йөргән иде. Булачак галим чит телләрдә басылып чыккан медицина басмалары белән танышып барырга тиеш, ә институт биргән белем белән генә бу өлкәдә әллә ни майтарып булмый дип саный иде ул. Җәмилә Закировна, шәкертләре белән фамильяр мөнәсәбәтләргә керергә бик үк яратмаса да, Дәүләтшинның теләгән хуплады, Ләйлә белән үзе үк таныштырды. Ләйлә каршында Дәүләтшин үзенең профессорга мәгълүм булмаган яклары белән ачылды. Икәүдән-икәү генә калганда, иркенәебрәк утыра, алдын-артын бик үк уйлап тормыйча сөйләшә, чөнки Ләйләне үз тиңе итебрәк саный иде ул. Аның саксыз ычкынган сүзләре, кинаяләре, мыскыллы яки тәкәббер көлемсерәүләре яшерен үзәген, чын асылын ачып бирделәр. Өстәвенә тагын шунысы: егетнең күзләре майлы, күңеле уенчак иде. Ул хәтта үзеннән шактый өлкән, инде кияүгә чыгып, әни булырга өлгергән Ләйләгә дә мәгънәле карашы, баллы тавышы белән ниндидер ишарәләр ясаудан тартынмады.

Изаилнең буйдак чагы иде әле. Ул шактый соң — утыздан узгач кына бер яшь студентканы алды һәм өйләнгәч тә элеккечә үк уенчак булып калды, ирекле, гамьсез яшәвен дәвам итте. Чит телләргә сәләтле булып чыкты үзе. Сөйләм телен тагын да ныграк чарлауны сылтау итеп, һаман килгәләп йөрергә теләк белдергән иде дә, Ләйлә кырт кисте: «Курс тәмам. Инглиз телендә мөстәкыйль шөгыль табыгыз. Мәңгелек студентларны яратмыйм мин».

Ир кешенең кемлеге хатын-кызга мөнәсәбәтендә бик яхшы күренә, әгәр дә хатын-кызга кимсетеп карый, аларны рәнҗетүне егетлеккә саный икән, ул башкаларга да миһербанлы була алмый дип саный иде Ләйлә һәм бу карашының хәзергәчә үзгәргәне юк.

— Сабый күңелле шул син, — диде ул, кызганулы тавыш белән әнисенә. — Хыянәт итүләрне, астан кисүләрне моңарчы белми яшәгәнсең. Язмыш сине андыйлардан саклап килгән.

— Төрлесе булды инде, Ләйлүгем. Өметләрем өзелгән чаклар да, хыялларым алдаган вакытлар да булды. Мәсәлән, бик якын бер кешем, иң якыным... минем өметләремне акламады. Яшьләрне аңлап җиткермәвем хактыр да, син дөрес әйтәсеңдер...

Җәмилә Закировна кызына мәгънәле итеп, озак итеп карады.

— Әни...— Ләйлә кызарынып чыкты.— Әни... Әйдә, җитди сүзләрне туктатып торыйк әле. Кайткач иркенләп сөйләшербез. Син минем әсирем бит бүген, мин сиңа фәкать сәяхәтең турында гына уйларга әмер бирәм. Утыр әле! — Ләйлә стенага терәп куелган утыргычны җайлап, кулы белән сыпырып алды, әнисенә таба иелде. — Эчеңдәгең тышыңда синең, әни, ә бу заманда алай беркатлы гына яшәп булмый. Урыны-вакыты белән уйный белергә дә кирәк. Чит илләрдә гомумән артык гади булырга ярамый, чөнки анда гадилекне мескенлеккә саныйлар. Урыны белән тәкәббер булу да килешә. Килгән-киткән кешегә карап, алар бөтен ил халкы турында фикер йөртәләр, ди торган идең бит үзең дә. Менә болайрак йөр син! — Ләйлә башын артка ташлады да, чокырлы ияген алга чыгарып, күзләрен кыса төшеп, әнисенә горур караш салды.

— Болай итепме? — Җәмилә Закировна як-ягына карап алды да, якындагыларның тәрәзәгә карап торганын күргәч, торып, Ләйләгә охшатып сынын турайтты.

— Ә син көлмә! — диде Ләйлә, купега таба борылып.— Ние көлке булсын аның? Мин бүген сиңа кофе эчерәм, американча сендвичлар ясыйм, заграница тормышына күнегә торырсың.

— Чәй пешер, куе итеп чәй яса миңа! — дип сокланып һәм горурланып карап калды Җәмилә Закировна кызы артыннан.

Әйе, кая барса да югалып кала торганнардан түгел аның Ләйлүге. Ә кем тәрбияләде аны шушындый итеп? Әтисе белән әнисе. Хәзер менә ул үзе әнисенә акыл өйрәтә. Өйрәтерлеге дә бар шул. Чит илләрдә дә әллә нинди хикмәтләр уйлап чыгарып йөри.

Америкада Ләйләләр төркеме белән барган ун кешенең унысына да аерым папка — «досье» ачкан булганнар. Укудан бушап торганда, ял көннәрендә аларның һәркайсын аерым бер гаиләгә алып китәләр — «гади америкалыларның тормышы белән таныштыралар» икән, ә ул йортта киләсе кунакның кемлеген белеп торсыннар өчен, шул папканы — «досье»ны бирә торган булганнар.

Бер тапкыр шундый «кунак»ка барганда, тышына «Миссис Мансурова» дип язылган папканы үзе алып укыган Ләйлә. Анда һәммәсе теркәлгән: кешенең милләте, нәсел-ыруы, торган җире, белеме, хезмәте... Холык-фигыленә аерым бит багышланган, анда Ләйлә турында: «Бик бай, кыйммәтле мехлар җыю белән мавыга. Четерекле, нәзберек», — дип язып куйганнар.

Ләйләнең кыйссасы бу урынга җиткәч, Җәмилә Закировна тыела алмый көлеп җибәргән иде:

— Синме четерекле? Синме нәзберек? Нинди мех җыю турында ул тагын?

Ә хикмәт менә нәрсәдә икән: анда баруга һәр кешедән: «Нинди шөгыль белән мавыгасыз?» — дип сорап чыкканнар. Дөресен генә әйткәндә, Ләйләнең бөтен мавыкканы — эше дә гаиләсе — ире белән улы. Ләкин алай дисә, дәрәҗәсе төшәр иде. Күп уйлап тормаган ул: «Мехлар яратам, затлы мехлар коллекциялим»,— дип җавап биргән. «Нинди мех ул?» — «Аеруча чәшке мехын яратам. Төрлесен җыям: көмеш сыманын, зәңгәрсуын, сорысын, агын».— «Каян аласыз ул хәтле мехны?» — «Күп ул бездә. Безнең Татарстаныбыз затлы мехлары белән бөтен дөньяда дан тота. Ишеткәнегез юкмыни?» — «Кая куясыз аларны?» — «Бүрекләр, туннар, пальто якалары тектерәм, кышкы күлмәкләремә дә куйдырам».

— Нигә, дөрес түгелме әллә? — диде Ләйлә, моны әнисенә сөйләгәч.— Якасыз-бүрексез йөргәнебез юк бит әле. Ятларга сер бирмибез!

Һәр илдә йөрүнең үз җае, үз хикмәте бар. Англиядә Ләйләне һаман бер сорау белән интектергәннәр: «Сез татармыни? Әниегез дә татармы? Әтиегез дәме? Сезнең анда татарларны кырып бетермәделәрмени әле?» Сүз белән генә ышандырып булмый, андый сорау бирүчеләрне Ләйлә кунакка чакырган да, өчпочмак, чәкчәк-бәлешләр белән сыйлаган. Чигүле читек-башмаклар, китап-альбомнар, йөзек-беләзекләр һәм башындагы бүреген дә куеп, кечкенә генә күргәзмә дә ясаган. Андый эшкә оста ул, ни кирәк буласын алдан чамалап, Казаннан ук бер чемодан тутырып киткән иде, хәзер менә әнкәсе чемоданына да әллә никадәр әйбер салды. «Анда безнең исемебезне шундук онытачаклар, ә менә совет кешесе, татар хатын-кызы икәнебез хәтерләрендә калачак,— ди ул.— Чит илгә чыккан һәр кеше — үз халкының көзгесе ул. Шуңа күрә, анда баргач, кибетләргә чабып, вак-төякка мөкиббән киткән кешеләрне җенем сөйми!» Ә ул үзе кайчан нишләргә икәнен төптән уйлап хәл итә, кирәк чакта четерекле дә, нәзберек тә була белә. Америкада бер прием вакытында официант һәр кешедән: «Ни телисез: кофемы, чәйме?» — дип сорашып йөри икән. Безнекеләр гади, ни булса да ярый, дип җавап бирәләр, хуҗаларга артык мәшәкать ясыйсылары килми, янәсе. «Мин күз кырые белән генә күзәтеп утырам: официантның ирен читләренә мыскыллы көлемсерәү бәреп чыкты берзаман,— дип сөйләде Ләйлә бу хакта.— Әһә, мин уйлыйм, гадиләрне санга сукмыйсыңмы? Каршыма килеп баскан иде, мин моңа эре генә: «Куе кофе пешерегез,— дим.— Йөз граммына бер балкашык сөт өсте, ике балкашык шикәр салынган булсын!» Күрсәң иде шунда аның ничек ялагайланып бөгелгәнен!

Ләйләнең «четерекле, нәзберек» дигән даны шул вакыйгадан соң туган да икән инде.

Җәмилә Закировна кызы аның юлын дәвам итәр дип хыялланган иде. Ул Ләйләдә кечкенәдән табиб хезмәтенә мәхәббәт тәрбияләргә тырышты. Ләкин Ләйлә үз язмышын әнисенең башына да килмәгәнчә хәл кылды: мәктәпне тәмамлагач, педагогия институтының чит телләр факультетына укырга керде.

Гомере буе, үзе уйлаганча, кешеләр өчен иң мөһим эшне башкарып килгән Җәмилә Закировна өчен аңлашылмас бер хәл булды бу. Чит тел, ни генә дисәң дә, чит бит инде ул! Дәресләрдә утырганда, «инфинитив», «перфект», «герундий»лар кемнең генә үзәгенә үтмәгән дә, мәктәп ишеген ябып чыгуга, кемнең генә башыннан очып чыгып китмәгән! Ләйләнең дә бөтен хезмәте шулай җилгә очып барырмы? Нилектән, ни сәбәптән әнисе хезмәтеннән гайрәте чикте соң аның?

Дөрес, еллар узгач, Ләйлә үзенең хак юл сайлаганын исбатлады, бу юл аны дөнья киңлекләренә алып чыкты. Безнең илдә беренчеләрдән булып, ул чит телләргә тиз арада өйрәтү методларын үзләштерде, зур галим булып үсеп җитте, кафедра җитәкчесе дәрәҗәсенә иреште.

Ә шулай да... Әгәр дә менә хәзер Дәүләтшин урынында үз каны — Ләйлә булса, бүгенге көндә кафедраның киләчәге өчен профессорның җаны тынычрак булыр иде... Диләрам белән дә, мөгаен, мондый хәлләр килеп чыкмас иде...

Тәрәзә артыннан бер-бер артлы шуышып узган манзараларга болыт күләгәсе төште.

— Әни, син мине ишетмисең инде әллә? — Ләйләнең каз канатыдай йомшак учы Җәмилә Закировнаның баш түбәсенә ятты.

— Чәй әзермени, кызым? Йөз граммына ике балкашык шикәр, бер балкашык сөт өсте салып яса миңа.

Көлештеләр.

Чәй янында, Җәмилә Закировнаның янә уйга чумганын күреп, Ләйлә:

— Әни, син үзең минем янда, ә күңелең әллә кайларда,— дип куйды. — Гомергә шулай булдың син, миңа иң кирәк чакларда ташлый идең дә чыгып китә идең!..

Шаярулы тавыш белән әйтелгән бу сүзләрдә бик тирән яшеренгән үпкә бар иде.

Җәмилә Закировна үзе дә борчуларын Гарәбстанга кадәр алып барырга теләмәгән иде дә бит, ләкин эчкә кереп оялаганнар шул алар, артта калмыйлар. Башларыңа исәп төшсә, качып кына котылам, димә икән.

***

— Ну, Зәйтүнгөл, без барасы юллар ачык хәзер! Икебезгә ике диплом, бер загс язуы. Төп мәсьәләләр хәл кылынган, яшәргә дә эшләргә генә!

Шулай диде Әнвәр беркөн иртән.

Зәйтүнә эшкә күптән күнеккән инде. Медучилище тәмамлаганнан соң авылда эшләп килгәнгә, ул институт клиникасында еш кына шәфкать туташы вазифаларын башкара иде, операция сестрасы да булды, ашыгыч төнге операцияләр вакытында ассистент булырга да туры килде аңа.

Башкалар, диплом алгач, ялга таралды, Зәйтүнә өчен исә тормыш үзгәрмәде дә кебек: трамвай аны күнегелгән юл буйлап алып китте дә борынгы урамнарның берсенә китереп куйды. Зәйтүнә туктаусыз машина йөреп торган тар урам чатына килеп басты. Монда һәрчак гөрелдәү авазы, төтен-сөрем, якын-тирәдәге заводларның биек торбаларыннан аксыл-зәңгәрсу пар бөркелеп, сабын-селте исе тарата.

Урам аша чыгып, өч катлы озын фабрика бинасын узгач, кечкенә генә бакча янына килеп җитәсең. Бакча артында «П» хәрефе ясап салынган ике катлы иске бина. Бүген Зәйтүнә шушында — институтның акушерлык-гинекология клиникасында төнлә кизү торачак.

Ул алгы бүлмәдәге зур шкаф янында халат киеп тора иде, эчке яктан лаборант Сөембикә апа килеп чыкты.

— Төн тыныч үтәчәк икән бүген, — диде Зәйтүнә, аның белән исәнләшкәч.

— Әйе шул, аягым җиңел минем.

— Гөберчәкләрегез ни хәлдә кала анда?

Сөембикә үзенең кечкенә лабораториясендә, тәрәзә төбендәге пыяла банкаларда бакалар асрый, аларны назлап «гөберчәкләр» дип атый иде.

— Гөберчәкләр сайраша, тамаклары тук... Ә синең улың булачак, Зәйтүнә. Ачы тавышлы, тиктормас малаегыз булыр, әйткән иде диярсең. Чибәрләнеп, ачылып киттең, йөзеңә тап та чыкмады... Әллә кәефең кырылды инде?.. Икенчегә кыз табарсың, бер дә аптырама. Кыз балага абый белән үсү рәхәт.

Сөембикә халатын, ак башлыгын салып, шома кара чәчен сыпырды да, плащын киеп, алтын тешләрен җемелдәтеп, тыныч төн теләде.

Аның очравын, чыннан да, хәерлегә юрап була иде: бүген авыр операцияләр булмаган, шәһәр буенча да алар дежур түгел — «ашыгыч ярдәм» авыруларны бирегә китермәячәк. Ординаторлар бүлмәсенә кереп, авыру тарихларын кулына алгач, Зәйтүнә шуны уйлады.

Хәер... Менә Хәйруллина бар бит әле. Ике көн элек, иртәнге обход вакытында, алтынчы палатада аны күрүгә таныды Зәйтүнә — Ларисаны озатканда, вокзалда очраган ак чигәле хатын Динә иде бу. Кифая сүзендә торган, палата врачы Фидаяны ярамаган эшкә күндергән. Дөрес, авыру тарихында терапевтның, бала табарга ярамый, дигән белешмәсе бар барын. Йөрәге таза түгел, имеш, Хәйруллинаның. Хак микән? Беренче баласын тапкан бит, ул чакта яраган. Бәлки, йөрәк чире шуннан соң беленгәндер? Алай булуы да ихтимал.

Зәйтүнә зәңгәрсу куш бит арасына кыстырып куелган тагын бер кәгазьне тартып алды. Анда Фидая кулы белән — эре хәрефләр койма тактасы кебек туры утыртылган — бу кичне Хәйруллинаны дәвалау тәртибе бәйнә-бәйнә язылган иде: «ярты сәгать саен укол», иң соңыннан — «21 сәг. йокы». Димәк, шул вакытка Динә котылырга тиеш.

Уколларны Анна Ивановна тиешенчә ясап бара икән, берничәсе турына тамга куелган. Урта яшьләрдәге бу шәфкать туташы коридорларны дер селкетеп, дың-дың басып йөри, калын тавыш белән кычкырып сөйләшә, әмма үз эшен яхшы белә, оста, намуслы, кайбер мәсьәләләрдә дипломлы врачларны төп башына утыртырлык тәҗрибәсе бар.

Шулай уйлап, Зәйтүнә Хәйруллина янына керергә ашыкмады, кичке обходны өске каттан башлады.

Палатаның ишеге янындагы караватта нечкә сынлы яшь хатын ята. Ябык йөзендә күзләре генә утырып калган. Ул Зәйтүнәне ике фонарь белән яктырткандай итеп карады. Моннан биш ел элек ул да башка хатыннар белән мәзәк сөйләшеп, көлешеп, биредә бер кичен үткәреп чыккан булган. Бала үстерергә тормышның көе җитеп бетми дип уйлаган ул чакта. Инде менә тормышы җайга салынган, бала кирәк икән. Бик-бик кирәк икән... Ләкин теге төннән соң аның ныклыгы бетеп калган... Инде карындагы баланы ничек тә саклап калу өчен тырышуы...

Зәйтүнә, карават кырыена утырып, хатынның нечкә беләген кулына алды:

— Хәлебез ничек безнең бүген, Рәзилә?

— Искечә инде...

— Тыныч үткән һәр көн безнең файдага, Рәзилә.

Палатада урнашкан тынлыкта кинәт кенә астан бака кычкырган тавыш ишетелде. Хатыннар көлешеп алдылар. Рәзилә дә сүрән генә елмайды.

— Ишетәсеңме, бакалар да синең күңелеңне күтәрергә тырыша,— диде Зәйтүнә.— Матур төшләр күреп, изрәп йокласаң, иртәгә алмагачларның алмалары тагын да тулышкан булыр, алар кызарып пешкәндә, без, мөгаен, сине бәби белән озатырбыз.

Рәзилә тар учларын күкрәге турында аз гына аерып күрсәтте:

— Ирем әйтә, менә шушындый гына кыз тапсаң да, мин сине учымда гына биетеп йөртер идем, ди.

— Ә бәлки, без аңа бahадир егет бүләк итәрбез? Үзебездән генә тора бит!

Зәйтүнә Рәзиләнең нечкә бармакларын сыйпады.

Бу палатада тагын бер ишек бар — аның артындагы өч кешелек бүлмәдә операциядән чыккан авырулар ята. Утыз биш яшьләрдәге хатын, Зәйтүнә якынаюга, аның кулын тотып алды да күз яшьләренә чылатып үбәргә кереште:

— Рәхмәтләр яусын сезгә! Бүген коридорны урап кердем! Үз аякларым белән!

Зәйтүнә кыенсынып кулын тартып алды.

Бу хатынны аңа килендәше Кәүсәрия җибәргән иде. Ел буе аяклары сызлап җәфаланган, йөри алмас хәлгә килгән, невропатологта дәваланган, файдасы булмаган. Зәйтүнә анда шеш барлыгын ачыклады, хатынга операция ясадылар. Врач өчен гадәти эш — ә башка берәүнең язмышында нинди зур үзгәреш... Юк, тыныч була алмый врачның эше, палата саен күңелне кузгатып торалар.

Аскы катка төшкәндә, бакалар тавышы ачыграк ишетелде. Алар монда изге вазифа башкаралар, катлаулы очракларда диагнозны ачыкларга ярдәм итәләр. Бик авыр хәлдәге хатыннарны коткарырга ярдәм итә Сөембикәнең «гөберчәк»ләре. Әмма үлемнән котылган хатыннар врачларга рәхмәт укыганда, Сөембикә дигән кешенең дөньяда барлыгын да белми калалар. Ә бит бакаларны ул Кабан күленнән үзе тотып ала, үзе асрый. Студентларга күргәзмә әсбаплар әзерләүче лаборант бу эшне үз өстенә алмаса да, сүз әйтүче булмас иде югыйсә.

Терелеп өйләренә киткәндә, кайбер хатыннар шәфкать туташларына тартмалы конфет яки торт бүләк итәләр. Бу күчтәнәч чәй эчкәндә табын уртасына куела. Тик Сөембикәгә аларны авыз итү дә сирәк тәти.

...Ә шулай да алтынчы палатага аяк тартмый иде. Ләкин керергә кирәк.

Карават янында басып торган Анна Ивановна, кереп баскан докторны күрмәмешкә салышып, Динәгә таба иелде дә, Зәйтүнәне янбашы белән читкәрәк эткәндәй итте. Авырлы хатынның монда керүен күңеле кабул итми иде аның. Зәйтүнәдән бераз калышып палатадан чыкканда, шәфкать туташы, шактый ук кычкырып:

— Алты айлык баланы юк итәргә тотынсаң, шул була ул менә! — диде. — Беләбез без андый очракларда йөрәк начар дигән белешмәләрнең ничек алынганын! Җәмилә Закировна гына юк, ул барда бездә мондый эшләр белән шөгыльләнмиләр иде.

...Динәгә бик авыр булды. Ниһаять, сәгать уникенче киткәч кенә, ул, шешенке иреннәре белән елмаеп, Зәйтүнәгә карады. Аның бу карашында җиңеләю чагылды. Ләкин кызарынган күзләренең төбендә оялу, ялвару да бар иде.

Зәйтүнә аның яныннан тудыру бүлегенә ашыкты.

...Бу дөньяда һәр кешенең үз холкы, үз фигыле. Берәүләр тупас, холыксыз, чыдамсыз, икенчеләр үшән, аңгыра, өченчеләр елгыр, тырыш, булдыклы. Берәүләр үз тормышындагы иң мөһим вакыйгага — бала тудыруга бөтен яшәеше һәм акыл үсеше белән әзерлекле килә, икенчеләр — бөтенләй әзерлексез. Берәүләр үз-үзләренә дә, якыннарына да кадерле һәм иркә, икенчеләренең кадерен үзләре дә, якыннары да белми.

Монда берәү дә чын йөзен яшерә алмый, бар күңелләр ахыргача ачыла.

Ләкин килә бер минут, бер мөкатдәс мизгел, син әле генә дөньяга килгән кешене күтәреп, ананың йөзенә якын китерәсең, җирдә яңа аваз — сабый тавышы яңгырый. Шушы минутта әйтерсең лә бер кодрәт белән ана күңелендәге барча керле таплар юып алына һәм йөрәк түрендә яткан якты, саф хис калкып чыга. Бу хис — яңа җан тудырган кешенең тантанасы, куанычы. Безне бар иткән, үстергән, яшәткән ул хис барлык аналар күңеленә буыннан-буынга күчеп килә. Бу тойгыны кичергәндә, һәммә хатыннар да сөйкемле һәм гүзәл, аларның сафлыгы һәм куанычы башкаларны да үстерә, канатландыра.

Төн эчендә дүрт ананың шатлыктан балкыган карашын күрде Зәйтүнә, һәм алар гаепле, ялварулы күзләрнең карашы калдырган авыр хисне юып төшергәндәй иттеләр.

***

Больницада сер сакланмый. Кайчак кешенең беркемгә дә сиздермәскә теләгән хәлләре врачларга гына түгел, янәшәдә яткан хатыннарга да фаш була.

Динә үзен чыннан да авыру дип, бүтән бала табарга ярамый дип, буйга узганын беренче айларында сизми йөргән итеп күрсәтергә теләгән иде, сораганнарга шулай дип сөйләгән иде. Ләкин аның сүзләре тыңлаучыларга, ниндидер трансформатор аша узган электр тогы шикелле, үзгәреп барып иреште. Аның ире белән ачуланышып, шуңа үч итеп, кинәт монда керергә ният иткәнен дә, ялган белешмә алганын да, бу эшкә Фидая Галимовнаның катнашы барлыгын да беләләр.

Динә берәр сәбәп белән палатадан чыкса, артыннан гаепләп карап калалар, үзе юкта гайбәтен саталар, ул керүгә кинәт шым булалар. Кайберәүләр елмаеп сүз кушкан була, әмма аларның елмаю балы астында, бәлеш камырына катнашкан әрем кебек, яратмау һәм кызгану ачысы сизелеп тора.

Ул исә сер бирмәскә тырыша. Идән юучы Хәтимә апага акча биреп, базардан тәм-том китертте, күршеләренә чикләвек, алма, җиләк өләште. Тик барыбер арада күңел җылысы кабынмады. Хатыннарның яратмавы гүяки врачларга да йокты. Иртәнге обход вакытында Фидая Галимовна, аның янына килгәч, сүрелеп киткәндәй булды. Динәнең: «Чыгарыгыз инде мине», — диюенә: «Чыгарырбыз, монда аунап ятудан ни мәгънә хәзер», — дип куйды. Аның тавышыннан боз суыгы бәргәндәй булды.

Ләкин күңелне иң кыйнаганы Динәнең үз йөрәк төбендәге сызлану иде. Газаплы төннән соң йокыга талгач, аңа гаҗәеп төш керде: бала үлмәгән, исән туган, имеш. Менә ул мөлдерәп карады, тәпиләренә басып якын килде дә әнисенең йөзенә төкерде...

Динә шабыр тиргә батып уянды.

Тизрәк бу төшне онытырга, малай турында хыялланган Мөдәрриснең күзләренә карау турында уйламаска иде. Дөрес, монда кереп ятар алдыннан Динә һәммәсен ныклап уйлаган иде кебек югыйсә. «Син мине авыр чакта ташлап киттең, минем белән тамчы да исәпләшмәдең. Янмас иде әле гомер урынында торган заводың! Бер-ике ай эчендә генә әллә ни булмас иде әле андагы эшчеләргә! Ә мин монда көйсез каенана белән, яшь бала белән йөкле килеш бөтен тормышны тартып барырга тиеш идеммени?» — дип каршы алырга ниятләгән иде ул ике айдан кайтачак ирен. Һәм аның ачынганын күреп кинәнермен дип уйлаган иде. Әйе, аның да үзәгенә үтсен әле, киләчәккә сабак булсын!

Шулай уйлаган иде ул, шул рәвешле үч алып, күңелен басарга теләгән иде. Әмма менә хәзер, үч алынгач, рәхәтлек хисе урынына сызлану гына килде.

Кечкенә көзге каршында озын чәчен тараганда, ул үз-үзенә күңел кайтаргыч булып күренде. Чигә турындагы ак тотамнар — олыгаю яки хәсрәт тамгасы түгел, табигать шуклыгы гына: көмеш чәчләр миңнәрдән үсә. Ләкин электән шундый булмасалар да, алар шушы төн эчендә агарган булыр иде, мөгаен.

Ул палатадагылар белән тизрәк хушлашырга ашыкты. Киенү бүлмәсендә кабаланып киенде. Ләкин тиз генә чыгып китеп булмады, нилектәндер аның белешмә кәгазьләрен озак бирми тоттылар. Ул кысан бүлмәдә утырган арада, көн бозылып китте, ишек ачылганда, салкынча һава бәреп керә, яңгыр шавы ишетелә иде. Көннең кәефе киткән, ул да елый иде шикелле.

Ниһаять, кирәкле кәгазьләрен алгач, Динә бераз ишек төбендә туктап торды. Юка күлмәктән, Италиядә тегелгән матур, әмма юешкә чыдамсыз туфлидән генә булганга, шундук туңып китте, беләкләренә каз тәне бәреп чыкты. Ләкин күкне салынкы болыт каплаган, яңгыр тиз генә үтәр сыман күренми, ә җан бу йорттан ераклашырга ашкына иде. Динә ишек төбендәге күлдәвекнең нәкъ уртасына китереп басты. Өйдән чыгып киткәндә, өч көнгә авылга кайтып киләм, дигәч, каенана аңа: «Юл хәлен белеп булмый, аягыңа ипле туфли ки, өстеңә плащ ал», — дигән иде диюен. Әмма ул чакта карчыкның янда чуалуы ата чебен выжлавы кебек ачуны гына кабартты.

Динә урамнан барганда җиңел машиналарга кул күтәреп карады — туктаучы булмады. Ул таныш урамнарны бутап адашты, трамвай тукталышына әллә каян урап килеп чыкты. Вагонга кергәндә аның өстендә коры җеп бөртеге калмаган иде. Плащ кигән, зонтик тоткан кешеләр аңа гаҗәпләнеп карадылар. Ләкин Динә үзен кызганмады: «Шул кирәк миңа, шул кирәк!» — дип пышылдый иде аның күгәренгән иреннәре. Ә күз алдында төшенә кергән сабый шәйләнә, гүяки болытны да ул китергән, Динәне дә яңгыр астында ул адаштырып йөрткән иде.

Ә бит мондый хәлләр кичергән хатынга туңарга, аякларын чылатырга һич ярамый иде. Врачлар бик тә, бик тә сакланырга кушканнар иде аңа.

***

Зәйтүнәгә әнисе Гөлзәйнәп бер кыйсса сөйләгән иде. Ул кыйсса-риваять кызның күңелендә, Габдулла Тукайның күбәләк турындагы, Гали белән Кәҗә турындагы әкиятләре кебек, нәни чакларның матур хатирәсе булып саклана.

... Илгә яу килгән.

Кара болыттай ишле, давылдай көчле, яшен утыдай аяусыз дошман явы килгән Болгар иле өстенә. Ярсу йөрәкле батыр егетләр, җилдән җитез атларга менеп, үткен кылыч болгап, дошманга каршы чыкканнар. Әмма дә ләкин давылны ук белән, яшенне кылыч белән туктатып буламыни? Илнең асыл ир-егетләре яу кырында ятып калганнар, аларның аналары, хатыннары, балалары, дәррәү урыннарыннан кубып, дошманнан качып киткән.

— Җиңдек! — дип тантана иткән дошман, буш калган калаларга, авылларга басып кергәч. — Бу байлыклар һәммәсе безнеке хәзер! Боларның хуҗалары җир йөзеннән юк ителде! — дип куанган, алтын-көмеш тулы казналарны, көтү-көтү малларны күргәч.

Һәм гаскәр башлыгы, качып киткән хатын-кызларны, бала-чагаларны кырып бетерергә фәрман биреп, укчыларын җибәргән. Алар шулкадәр аяусыз булганнар ки, төн булып төн качакларны кызганган, киң кара канатын җәеп, аларны дошман күзеннән яшергән.

— Ерак китә алмаслар! — дигән укчылар.— Иртәнге таң нуры төн канатын эретеп юк итүгә, без ул качакларның берсен дә исән калдырмабыз!

Ә хатын-кыз, бала-чага, ераккарак китәргә тырышып, төн буе йөгергән. Таң нуры төн канатын юкарта башлаганда, яшь хатын Гөлҗиһан Идел ярына барып егылган.

— Бүтән бер адым да атлый алмыйм,— дигән ул.— Карынымдагы балам бу газапларга түзә алмыйча урыныннан кузгалды, вакыты җитмәгән килеш дөньяга килергә талпына...

Аның янына ыруның иң өлкән әбисе килгән.

— Түз,— дигән ул яшь хатынга.— Адәм баласы дөньяга килгәндә дә, дөньядан киткәндә дә иң якын кешеләренә газап-әрнү китерә. Түз, тавышыңны чыгарма! Дошман ишетә күрмәсен!

Шәфәкъ нуры торган саен көчәя, дошман килер юлны ныграк яктырта икән. Ләкин киң Идел үзенең ярлары буенда кан коелуын теләмәгән, качакларны ак томан пәрдәсе белән каплаган. Гөлҗиһан да тавышын чыгармаган. Укчылар аларны күрми читләтеп үтеп киткән.

Яр буенда Гөлҗиһан карлыгач баласыдай арык, кечкенә ир бала тапкан. Аның зәгыйфь тавышын ишеткәч:

— Балам җитлекми дөньяга килде, гомерле булмас инде,— дигән.

— Кара төн сине йомшак канаты астына алып, дошман күзеннән яшерде, киң Идел, ак томаны белән каплап, һәлакәттән коткарды. Син — ана кеше, үз канатың астында сабыеңны саклап кала алмассыңмыни? — дигән кендек әбисе. Һәм, иңеннән тунын салып, Гөлҗиһан өстенә япкан, сабыйны исә яулыгына урап, тун җиңенә тыгып куйган.

— Балаң канат ярган бөркет булып җитешкәнчегә кадәр аңа тән һәм җан җылыңны бир,— дигән.

— Әткәсе яуда һәлак булды, үзем дә бик хәлсезмен, яши дә алмам, ахрысы,— дип зарланган Гөлҗиһан.

— Син сабыеңны тыңла. Аның тавышы сиңа көч бирер, аягыңа басарга, яшәргә мәҗбүр итәр, яклаучың да, саклаучың да булыр,— дигән кендек әбисе. Һәм яшь анага Иделдән су алып эчергән, якындагы урманнан җимешләр өзеп китергән.

— Бу суны эч, бу җимешләрне кап. Сабыеңа күкрәк сөтеңне имез. Синең сөтең аша аның тәнә-җаны шушы туфракка берексен, бу аның туган җире,— дигән.

Көннәр, айлар үткән, бала инде тун җиңенә сыймый башлаган, үз вакытында әнкәсенең тезенә менеп утырган, үз вакытында, әнкәсенең бармагына тотынып, Идел яры буйлап тәпи киткән.

Менә бер язның кояшлы көнендә кендек әбисе малайны җитәкләп авыл очына алып чыккан.

— Тыңла, улым,— дигән. Болын өстендә тургай сайрый, аннан ары урманда күке кычкыра икән.— Ишетәсеңме? — дигән кендек әбисе. — Һәр кош үзенчә сайрый, һәркайсының үз җыры. Алар ул җырны ата-аналарыннан отып алганнар. Синең әткәңнең дә үз җыры бар иде. Хәзер мин өйрәтәм сиңа аны.

Малайның тавышы, тургайлар җырына кушылып, чәчәкле болын өстендә яңгыраган.

Тагын күпмедер вакытлар узган. Малай егет булып җиткән. Тавышы шундый көчәйгән, ул җырлый башласа, тургайлар, күкеләр тынып, хәйран калып тыңлый торган булган.

Егет өйләнгән, аның җиде улы, бер кызы туган. Уллары асыл егетләр булып, кызы илнең сылуы булып җитешкән.

Шулчак дошман, бу халыкның яңадан терелеп аякка басканын, мантыганын күреп, янә яу белән килгән. Тик бу юлы инде аңа каршы бер урынына җиде батыр чыккан. Алар явыз дошманны куып, ата-бабаларының җирләрен азат иткәннәр.

Хәзер анда Гөлҗиһанның батыр иреннән калган җыр яңгырый, һәр язда яңа балалар, кендек әбиләренең кулларына ябышып, урман-болыннарга чыгалар, ыру җырларын өйрәнәләр. Аларның тавышы былбылларга, тургайларга кушылып, Идел буйларында яңгырап тора, ди.

...Менә шундый кыйсса сөйләгән иде Зәйтүнәнең әнисе. Әкияткә охшатып сөйләгән иде. Әмма бик тә чынга охшаган үзе.

***

Институтта чакта Алтынчәч химиядән бер егеткә ярдәм иткән иде. Тулай тораКта бер бүлмәдә яшәүче Тәслимә күндерде аны бу эшкә.

— Химияне синнән яхшы белгән кеше юк, минем бер танышка булыш әле,— диде.— Армиядән кайткан егет, белеме саегып киткән.

Бу — озын гәүдәсенә караганда кечерәк тоелган башын алга сузып йөри торган Нәркис исемле егет булып чыкты. Алар атнага ике-өч тапкыр очраша торган булдылар. Нәркис тырыш, дикъкатьле, үзен бик кечелекле тота, ләкин һәрнәрсәне кат-кат аңлатканны ярата иде.

Сигезенче март бәйрәменә ул Алтынчәчкә гажәеп бүләк китерде: йодрыкка сыярлык тимер шар матур итеп челтәрләнгән, аның эчендә шулай ук челтәрләнгән тагын бер шар тәгәрәп йөри.

— Станокта үзем ясадым,— диде Нәркис.— Тоташ тимер кисәгеннән.

— Нәрсәгә ярый соң ул?

— Ачкычка тагарга була. Андый әйбер бүтән беркемдә дә юк!

Егет түгәрәк күзләре белән Алтынчәчнең йөзенә текәлгән, әллә мактау көтеп, әллә сынап карап тора иде. Алтынчәч рәхмәт әйтергә ашыкты. Ачкычына андый зур, авыр әйбер тагып йөрмәс ул йөрүен, ләкин егет тырышкан бит. Аннары колга кебек ир-атның Нәркис исемле булуы Алтынчәчне сәерсендерә, хәтта кызгану хисе уята иде. Ул үзе дә гомере буе шулай кыяфәтенә ятышмый торган сәер исем күтәреп йөри бит!

Шул көннән микән, әллә аннан да элегрәкме, алар химиядән тыш бүтән нәрсәләр хакында да сөйләшкәли башладылар. Егет китәргә җыенып, китап-дәфтәрен бил каешына кыстырып куйгач та — аның бу гадәтен Алтынчәч яратмый, тик әйтергә яхшысынмый иде — алар тәмләп чәй эчәләр һәм дөнья хәлләренә кереп китәләр иде. Сүз күбрәк кино, китап турында бара иде. Соңрак, ачылып китеп, таныш-белеш, тормыш-көнкүреш хакында да фикер алыша торган булдылар.

Нәркис Алтынчәчне кино-мазарга чакырмады, аулакта очрашырга тәкъдим ясамады. Ләкин аның китәсе килмичә озаклап утыруыннан, һәр сүзне теләктәшлек белән тыңлавыннан бик тә якын иткәне сизелеп тора иде. Әкренләп кыз үз күңеленә дә егетнең бик якын булып китүен тоя башлады. Тора-бара аны сагына торган булды, ул килмәгән көннәрне ямансулады. Ахырда, чын мәхәббәт менә шушындый булырга тиештер дип уйлый иде ул, Нәркисне озатып, чәчен бигудига ураганда һәм йокыга китә алмый яткан сәгатьләрендә.

Дөрес, башкалар яратуны бүтәнчәрәк аңлый. Әнә күрше карават һаман буш, Тәслимә тиз генә кермәс әле, КАИ егете Тәфтил белән берәр караңгы почмакта торалардыр...

...Бер кичне, Нәркис чыгып киткәч, Тәслимә:

— Алтынчәч, син бик мавыкма, Нәркис синнән көлә генә, баласыта ул сине, — диде. — Хәзер кая китте дип беләсең син аны? Рамиләсе янына китте ул.

— Булмас! — диде Алтынчәч, урыныннан кубып. — Булмас! Ул андый түгел!

Бу төнен ул йокысыз үткәрде. Һәм шунда газапның иң ачысын кичердем дип уйлады. Мәхәббәт газапларының ачылардан ачылары барын белми иде шул әле ул.

Ике көннән Нәркис килгәч, ул таныш булмаган Рамилә турында сорамакчы, һич югында киная белән генә булса да берәр сүз әйтмәкче иде. Ләкин егет аңа шундый саф, беркатлы итеп, һәр сүзенә инангандай карап утыра иде ки, Алтынчәч аның гөнаһсызлыгына сүзсез дә ышанды. Мондый карашның алдавы мөмкин түгел иде. Сизә иде бит ул Алтынчәчнең күңелендә ниләр кайнаганын! Әгәр дә йөргән кызы булса, башка берәүнең күңелен болай кузгатырга нигез бирер идемени? Кешене җәлладларча җәзалау дигән сүз бит бу! Юк, Нәркис күңел җәллады була алмый, намуслы ул.

Шулай дип юатты үзен Алтынчәч.

Ә җәй башында, укулар тәмамланыр алдыннан, кичен, Алтынчәч чәчен бигудига урап азапланганда, сак кына ишек какты лар.

— Алтынчәч, чык әле, — диде курсташ егет Җәүдәт.

— Чыкмыйм. Сүзеңне шуннан гына әйт.

— Чык инде... Алма бирәм... Ишек аркылы сөйләшә торган сүз түгел...

Алтынчәч башына яулык урап чыгарга мәҗбүр булды. Баш түбәсенә сыя алмагандай тырпаеп торган куе, каты чәчле Җәүдәт чыгынкы маңгае астыннан сынап карады, алма сузды һәм:

— Син борчылма, гадәти хәл дип кабул ит, — диде. — Бүген Нәркис Рамилә янына күчеп китте.

Алтынчәч тын гына борылып керде дә урынына менеп ятты.

Мәхәббәт газапларының чыны менә шунда башланды...

Иртән торгач, ул төймә-сәдәфләрен, брошкиларын саклый торган тартмадан Нәркиснең бүләген эзләп алып, икенче каттан тышка ыргытты. Тимер шар асфальтка барып төшүгә урталай ярылды. Тоташ түгел, кисәкләрдән укмаштырылган икән. Нәркис аны шунда да алдаган. Әллә сынавы гына булганмы? Әгәр шулай икән, күңеле дә шушындый тимер кисәкләреннән торадыр!

«Ник алай иттең?» — дип сорыйсы килде Алтынчәчнең. Әмма очрашкан чакларда тән куырыла, юкка чыгасы, күзгә күренмәс буласы килә башлый, ул хәтта Нәркис барган трамвайга утырмаска тырыша иде.

Менә хәзер алар икесе бер заводта эшлиләр. Нәркис Нәгыймович Бадамшин зур кеше бүген, баш механик. Гәүдәсе турайды, юанайды, башы иелмәс булды. Тик Алтынчәчнең күңеле генә шул килеш калды. Каршысына баш механик килеп чыксa, заводның чакрымнарга җәелгән мәйданы кинәт тараеп китә, кереп яшеренер урын бетә...

Ә бәлки, чыннан да, Тәслимә хаклыдыр, егет белән кыз арасындагы мөнәсәбәт ачык, гади булырга тиештер, барысын да турыдан-туры сөйләшергә һәм теләгәнеңне эшләргә кирәктер? Ә бәлки, Алтынчәчнең ихтыярына каршы килеп булса да, ике арада Линар урнаштырган мөнәсәбәт табигыйдер, аңа күнегергә генә кирәктер?

Нәркис белән булган хәлләрдән соң күп вакытлар үтте бит инде. Алтынчәч беркемне дә күңеленә якын итә алмады. Ниһаять, менә аның тормышына Линар бәреп керде...

Аның турында уйлаган чакларында, Алтынчәч Нәркисне исенә төшерә, аның белән булган мөнәсәбәтләрне чагыштырып, ике егетнең үзләрен капма-каршы тотуларын күрә, бу капма-каршылык киләчәккә өметне ныгыта иде.

Линарның нияте җитди, әлбәттә, монда икеле-микеле уйларга урын юк. Ул хатыны белән аерылышуын законлаштырыр, йортын сатып, эшеннән чыгып, Казанга күчеп килер.

Әгәр дә нияте шундый булмаса, ул монда килеп, атналар буе яшәп ятар идемени? Бөтен халык алдында парлап пляжга йөрер идемени?

Идел буенда, таллар күләгәсендә утырганда, шуларны уйлады Алтынчәч. Линар, кул-аякларын таратып ташлап, комга чалкан яткан да күзләрен йомган. Кояшта янып каралуны белмәс ак тәне алсуланып чыккан, корсагы калкыбрак, сулыш алган саен тибрәлеп тора. Йөзендә дә гамьсезлек, туклык, күңел тынычлыгы чагыла. Фәкать җанга якын кеше янында гына үзеңне шушылай гамьсез, рәхәт хис итеп буладыр.

Барысы да яхшы, тик менә аның янына куелган магнитофон гына аңлашылмас телдә өзек-өзек көйләр җырлап ачуны китерә, сөйләшергә ирек бирми.

Алтынчәч, тезләрен бөгә төшеп, кайнар комнан таучыклар ясый, аннары аларны ишеп ташлый. Уйлары да бер оеша, бер тарала аның.

—Каяле, күзлегеңне биреп тор!

Линар, җавап көтмичә, Алтынчәчнең маңгаеннан күзлеген тартып алды да, башта яткан килеш, аннары торып утырып, як-ягына каранды.

— Күзне авырттыра бит бу! Кара-кара, җирне күкәй кабыгы кебек кабартып күрсәтә үзе! Ә кешеләрне тукмак хәтле генә итеп калдыра!

Алтынчәч аннан күзлеген алырга ашыкты. Ә магнитофон һаман әллә ни акыра. Нәрсә җебеп утырырга соң әле? Алтынчәч үрелеп магнитофонның төймәсенә басты да җырны ярты юлда туктатты.

— Дөнья хәлләрен сөйләшик әле, — диде.

Яңадан җәелеп яткан Линар, башын күтәреп, аңа гажәпләнеп карады.

— Ниен сөйләшәсең аның?

— Ничек яшисең, нишләргә уйлыйсың.

Линар кире ятты.

— Кайтуга ишегалдына багана утыртам әле. Урамдагы төсле биекне, кәкре башлыны. Белсеннәр Шиһаповның кемлеген!

— Кем белсен?

— Бөтенесе! Тирә-күршедә андый баганалы кеше юк әле.

— Ә нигә кирәк ул?

— Уңганлыкны күрсәтергә. Булган кешенең бөтен әйберсе югары сортлы була. Быел өй түрендә шундый түтәлләр ясадым, биллəһи, сезнең Ирек мәйданындагы гөлләрдән ким түгел!

Алтынчәчнең күз алдында кояш тотылгандай булды. Багана артыннан йөри икән, димәк, нигезеннән кузгалырга нияте юк дигән сүз! Алтынчәч урыныннан кузгалып суга керде дә колач салып йөзеп китте. Линар берничә селтәнүдә аны куып җитте.

— Нишләп болай эреләндең әле? Минем яндарак йөр, юкса бата башласам, кем коткарыр?

— Хатының бар бит синең, — диде Алтынчәч, чәнчергә тырышып.

Линар чумып алды, аннары пырхылдады да:

— Әйдә, көннең ямен җибәрмик әле, — диде. — Бала хакында сүз бара, аңлыйсыңмы? Кызым бар бит минем!

Әйе, Алтынчәч моны белә: Линарның җиде яшьлек кызы бар. Баганасы, гөлләре дә, моңарчы шул калада яшәп ятуы да кызы хакынадыр... Әгәр дә ул, баласының язмышы турында уйламыйча, аны ташлап, бөтенесенә кул селтәп монда килсә, бу аның тарафыннан мәрхәмәтсезлек булмас идемени?

Алтынчәч Линар белән янәшә йөзеп китте, кояш нурында тәңкәләнеп ялтыраган Идел киңлеген күрде, тәне суның салкынча назын тойды.

Алар бер-берсен күңелләре белән аңлый, бу аңлашу чын рухи якынлыкка әверелсен өчен бөтен көчен куяр Алтынчәч. Тәннәрнең бер-берсенә омтылып та, күңелләрнең аңлашмавы, рухларның

каршылыгы — ул мәхәббәт фаҗигасе дигән сүз бит! Алтынчәч бу фаҗигагә юл куймас. Егетнең белемен, рухын үз дәрәҗәсенә күтәрергә ярдәм итәр ул.

Һәм Алтынчәч бу изге эшне кичекмичә башларга булды. Ул сумкасына бер шешә «Яблочная» дигән су, өсләренә юка гына сыр кисәкләре куелган ике телем арыш икмәге белән бергә Антуан Сент-Экзюпериның «Нәни шаһзадә» исемле китабын да салып килгән иде.

— Әйдә, әкият укыйбыз, — диде ул, китапны алып.

— Валяй.

Линар комга капланып яткан иде, шыбырдашкан тал яфракларына күз төшереп алды да башын кулларына салды. Тал күләгәсе аларны ят күзләрдән саклый, егетнең алсу тәненә челтәрле күләгә төшкән, җылы су исе, әчкелтем яфрак исе килә — гомумән алар әкияттәге кебек матур мохиттә иделәр һәм бу хәл, Алтынчәч фикеренчә, әкиятнең тәэсирен көчәйтергә тиеш иде.

«Алты яшьлек чагымда мин кеше аягы басмаган карурманнар турында укыган идем», — дип башлады Алтынчәч хисләнеп. Егет дәшми, кыймылдамый, йөзе күренмәсә дә, кыяфәтенә караганда игътибар белән тыңлый иде.

— «Мин шундый бер планетаны беләм, анда кызыл чырайлы бер кеше яши. Ул гомере буена бер тапкыр да чәчкә иснәмәгән. Бер мәртәбә дә йолдызларга күз салмаган. Бервакытта беркемне яратмаган. Беркайчан да берни эшләмәгән. Аның бердәнбер шөгыле — саннар кушу. Иртәдән кичкә хәтле ул бер үк сүзне кабатлый: «Мин җитди кеше! Мин җитди кеше!» Тәкәбберлегеннән шардай кабара үзе. Ә чынында исә, кеше түгел, гөмбә ул!»

Алтынчәч шушы урында туктап тын алды. Линар әйләнеп чалкан ятты да, иснәп:

— Әкият шундый буламыни! — диде.

— Ләкин бик образлы бит... Шигъри... Хисле... Тирән мәгънәле...

Алтынчәч бу сүзләренең егет зиһененә барып җитмичә, тал яфракларын шыбырдаткан акрын җилгә очкандай юкка чыкканын тоеп, тынып калды.

— Санамыйча яшәп булмый. Чәчкә иснәп, йолдыз санап кына яшәр иде һәркем дә... Әлсерәтте әле, тамак кибеп китте...

Алтынчәч кабаланып сумкасыннан шешә белән ипи телемнәрен чыгарды.

— Шушы гынамыни? — диде гаҗәпләнеп Линар.

— Минем эчәсе килми. Азмыни?

Алтынчәчнең үзенә бу ризык көндезгә дә, кичкә дә җитә иде.

— Ир туйдырган кеше түгел шул син,— диде Линар, аның гаебен гафу иткәндәй. Һәм шешә капкачын таза теше белән каерып ачты да, башын артка ташлап, голт-голт эчә башлады. Бу рәвешендә ул зур һәм гайрәтле кыргый җанварны хәтерләтә иде.

Алтынчәч, нәрсәдәндер оялып, күлмәген киеп куйды. Алай да бирешергә исәбе юк иде әле аның.

— Анекдот сөйләшикме соң әллә? — диде ул.

Линар җанланып китте.

— Әйдә, сөйләп җибәр. Синең белән бер дә анекдотлар травить иткән юк бит әле.

— Берзаман авылдан шәһәргә бер абзый килгән, ди. Симфоник оркестр концертына алып барганнар моны. Абзый, дирижерны күреп: «Бу адәмгә шушы рәвешле орчык изәп торган өчен күпме түлиләр?» — дип сораган. «Биш йөздән дә ким түгелдер»,— дип җавап биргәннәр аңа. «Кит аннан! — дигән абзый, исе китеп. — Ул хакка орчык, түгел, бастырык болгап торырга була!»

Лабораториядә сөйләгәндә бу анекдот бик кызык булып тоелды, кызлар тәгәрәшеп көлгәннәр иде. Әмма бу юлы Алтынчәчнең иреннәренә кунган елмаю курыккандай юкка чыкты, чөнки Линар җитди калды.

— Гади халыктан көлгәнне яратмыйм мин,— диде ул, аксыл кашларын җыерып.— Орчык селкеп торган дирижерлар түгел, бастырык белән эш иткән абзыйлар туендыра халыкны.

Шундый үртәлеп әйтте ки, әйтерсең лә үзе дә халыкны туендыручы иде!

— Алайса, үзең сөйлә!

— Берзаманны Чапаев янына Петька йөгереп килгән,— дип башлады Линар.— «Василий Иванович,— ди икән бу,— анда Анька...»

— Ә мин менә Чапаев кебек кешеләр турындагы анекдотларны яратмыйм, — дип бүлдерде аны Алтынчәч, үчлелек белән.— Гади халык арасыннан күтәрелеп, изге көрәштә шәһит киткән кешедән көләргә ярыймыни?

Линар, «тешләшә дә беләсеңмени әле син?» дигәндәй, аңа гаҗәпләнеп карады.

Сөйләшер сүз беткән иде.

***

Алар Әнвәр белән кич театрга барырга сөйләшкәннәр иде. Ләкин Зәйтүнә эштән вакытында китә алмады, янына кеше килде. Гамьсез карашлы, аксыл керфекле бу яшь хатынны Зәйтүнәгә килендәше Кәүсәрия җибәргән иде.

Гадәти хәл: һәр табибка, үзенә тиешле авырулардан тыш, таныш-белеш, туган-тумачасын, танышларының туганнарын һәм туганнарының танышларын да кararга туры килә.

Хатын Илзирәк исемле икән. Зәйтүнә аны арткы ишектән кертеп, студентлар укый торган бүлмәдә тар өстәл артына утыртты да хәлен сораша башлады.

Хатынның сөйләгәннәре — заманның елдан-ел ешрак очрый торган зары иде. Биш тапкыр балага узган, берсен дә ахырынача күтәреп бетерә алмаган, инде менә алтынчысын йөртә. Монысына да ышаныч зур түгел... Сораша торгач, Зәйтүнә бу хатынның шушы хәлендә үзен ничек тотарга, ниләрдән сакланырга кирәклекне бөтенләй белмәвен ачыклады.

— Сез менә, бухгалтер булып эшлим, дидегез. Укыгансыздыр инде? — дип сорады Зәйтүнә.

— Хәзерге заманда андый җаваплы эшкә дипломсыз алырлар, бар. Техникум тәмамладым.

— Ә әни булыр өчен нәрсәләр укыдыгыз?

Илзирәкнең моңарчы ваемсыз күренгән йөзе җитдиләнде, күзләре түгәрәкләнде:

— Аның өчен дә... уку кирәкмени?

— Ә сез ничек уйлыйсыз? Саннарны кушу, тапкырлау өчен техникум белеме кирәк, ә ана булу, кеше үстерү өчен наданлык та ярыймы?

— И-и, Зәйтүнә Мәҗитовна! Андый эшне дипломсыз да бөтен кеше булдыра лабаса. Беренчесе без түгел, ата-баба һөнәре.

— Ләкин менә наданлыкның зыяны тигән бит әле! Гади генә нәрсәләрне белсәгез, мөгаен, мондый хәлгә тарымаган булыр идегез!

Һәм Зәйтүнә аңа мондый вакытта нәрсәләрне истә тотарга кирәклеген бәйнә-бәйнә аңлатырга кереште. Илзирәк күзләрен зур ачып тыңлый, ләкин клиника ишеген ябып чыгуга, табиб сөйләгәннәрнең күбесе аның түгәрәк башыннан чыгып җилгә очачагы көн кебек ачык иде.

Зәйтүнә аңа һәр хатын-кыз белергә тиешле гап-гади кагыйдәләрне аңлата. Ләкин ни өчен соң боларны табиб һәр кешегә аерым сөйләп утырырга тиеш? Менә хәзер һәммәсе ачык һәм аңлаешлы итеп бәйнә-бәйнә язылган китап кул астында булсын иде дә Илзирәккә шуны гына тоттырып җибәрәсе иде. Ул аның үзенә кирәк битен теләгән вакытында ачып, кат-кат укый алыр иде.

Авылда эшләгәндә дә, монда яшь хатыннарны караганда да, Зәйтүнәнең башына бу уй еш килә иде. Китап кирәк, аны һәркемгә таратырга кирәк. Югыйсә күпме генә тырышсаң да, бер утыруда теләгәнеңнең барысын да аңлатып бетереп булмый.

Шулвакыт, эчке якта ишек ачылып, куркынган тавыш:

— Зәйтүнә Мәҗитовна, сезне уникенче палатага чакыралар! — диде.

Зәйтүнә, Илзирәккә тагын ике атнадан килергә кушып, ашыгып өске катка менеп китте. Ишекне ачуга, аның карашы Рәзиләнең шом баскан күзләре белән очрашты. Аның караваты янына Анна Ивановна тезләнгән иде.

— Зәйтүнә Мәҗитовна, кан тамырына эләгә алмыйм,— диде ул, кулындагы шприцны күрсәтеп.

— Ни булды, Рәзилә?

— Эчем, эчем...

Зәйтүнә шәфкать туташыннан шприцны алды да бармакларын Рәзиләнең нечкә беләге буйлап шудырды. Бармак битләре белән тиресен үтәли күргәндәй булды, тимер энә әйтерсең лә кулның дәвамына әверелде, тамырга бик җиңел керде.

...Иренең теләге кабул булды: ул көнне Рәзилә бияләй хәтле генә бәби тапты. Ир бала.

— Ник еламый ул, ник еламый? — дип үрсәләнде Рәзилә.

Бала тереклек иясенең иң йомшак чагында — шытымның үсентегә, бөренең гөлгә әверелгән вакытында иде. Инде тырыша торгач, җан керткәннәр иде аңа, сабыйлар бүлегенә илтергә дип күтәргәч, тагын сулышы сизелми башлады. Зәйтүнә аның юка тире белән өртелгән нәни күкрәгенә учын куеп, битлек белән каплаган авызын иреннәренә терәде. Ясалма сулыш биреп, йөрәгенә массаж ясау озак дәвам иткән кебек тоелды. Ниһаять, баланың йөрәк тибеше янә сизелә башлады.

...Зәйтүнә урамга чыкканда, эңгер-меңгер иңгән иде инде. Ул ашыгып кайтып керде, бусагадан атлауга, Әнвәргә бүгенге хәлләрне сөйләргә дип авызын ачкан иде, аның каралган йөзен күреп, сүзләре тамак төбенә утырып калды.

Шунда гына исенә төште: алар театрга соңга калганнар иде.

Бу көнне алар беренче тапкыр сүзгә килделәр. «Син үзеңнең кемлегеңне бөтенләй онытып җибәрәсең кайчакта, — диде Әнвәр, каты итеп. — Өйдә ирең көтеп тора, йортың бар, җил куып кына яшәп булмый лабаса!» Зәйтүнә бүген бер кешегә тормыш биргәнен, орлыкның — шытымга, бөренең гөлгә әверелүенә ярдәм иткәнлеген әйтергә теләгән иде. «Больницада син генә түгел, башка врачлар да бар!» — диде Әнвәр. Зәйтүнә Әнвәрнең дә, эше белән мавыгып, теплицалардан кайта алмый ятуын исенә төшерде. «Семьяда берәү эше белән мавыкса, шул бик җиткән! — дигән җавап алды ул моңа. —

Миңа нәкъ үзем төсле кеше кирәкми! Хатын кирәк миңа! Рәтле генә яшисең килсә, җайлырак эшкә күч!»

Кыскасы, бик каты үпкәләштеләр алар. Зәйтүнә беренче тапкыр сүзләренең ире күңеленә барып ирешмәвен, барып җиткән кадәресенең дә ризасызлык, хәтта ачу кузгатканын күреп аптырады, рәнҗеде, курыкты.

Иртәгесен ял көне иде. Әмма Әнвәр йокыдан торгач дәшми-тынмый киенде дә чәй дә эчмичә чыгып китте.

Борчулы чакларында күңелен тынычландыра торган бер чарасы бар иде Зәйтүнәнең — ул да булса кул эше. Табиб өчен бик тә кирәк шөгыль бу: тегү-чигү бармакларның ныклыгын, сизгерлеген арттыра. Зәйтүнә булачак бәби өчен күлмәк-башлыклар чигәргә утырды. Кызыл төс — кыз балага, зәңгәре — ир балага, диләр. Нинди җепләр сайларга икән Зәйтүнәгә? Бу киемнәрне кем кияр? Ул җайлабрак утырды да, бер мәлгә күзләрен йомып, туачак сабыен күз алдына китерергә тырышты. Кинәт аның бөтен тәне буйлап ләззәтле дулкын йөгереп узды — ул карынындагы баланың тибенгәнен тойды.

Без һәммәбез кайчан да булса бу дөньядан китәчәкбез һәм моны белеп яшибез. Ләкин кешенең гомерендә үзен мәңгелек итеп хис кылган минутлар да була. Сөйгәне белән кавышканда һәм карынында бала тибенгәндә үзен мәңгелек дип хис итә адәм баласы. Мәңге яңарып, мәңге яшәреп торган табигать нәкъ менә шушындый минутларда безнең рухыбызда үзен аеруча ныклы сиздерә, күрәсең.

...Күпмедер шулай онытылып торганнан соң, Зәйтүнә, кемнеңдер карашын тойгандай булып, кинәт айнып китте. Сискәнеп күзләрен ачты һәм диварда эленеп торган кыз рәсемен күрде. Җан иңгән диярсең, томрап карап тора...

Әнкәсе Гөлзәйнәп Зәйтүнәгә бу өйдә эленеп торган ике рәсем хакында бик кызык сүзләр әйткән иде.

— Кара кайгыга баткан бу шакмак гәүдәле хатын — диде ул, мадам Жаклинны күргәч. — Тәнең агач булып, иреңә хаҗәтең калмаса, нибуч каралыр чыраең!

— Нишләп алай дисең, әни? Нишләп иренә хаҗәте калмасын аның?

— Ир кеше ясаган моны, хатын-кыз болай сурәтли алмый. Һәм яратмыйча, үчләнеп сурәтләгән. Ярык балта сабы шикелле, үзен утларга атардай булган бу бичара!

Шулай дип гәрәбәле кыз каршына барып басты да:

— Элекке заманнарда Гөлҗиһан сабыннарының тышына ясый торганнар иде мондый киленнәрне, — диде.— Эштән арып кайткан иренә сабын-сөлге биргәндә шушылай елмая торганнар иде безнең заманның яшь киленнәре... Бер елмаю белән дөньяны яктырта беләләр иде шул!

Гөлҗиһан... Бу исем Зәйтүнәдә балачак истәлекләрен уятты.

— Хәтерлисеңме, әни, син миңа җиде айлык бала тапкан хатын турында сөйли идең. Исеме Гөлҗиһан, ди идең.

— Гөлҗиһан инде, Гөлҗиһан. Югары оч Шакир кавеменнән.

— Ничек инде югары оч булсын?.. Кайсы авылныкы?

— Үзебезнең авылныкы! Аның малае Җантимерне әле дә хәтерлим. Анасы Гөлҗиһан исемле булган. Шундый баһадир адәм иде, мин сиңа әйтим, печән җыйганда кибән башларыннан җырлап җибәрсә, әллә кайларга ишетелә иде. Урманда җиләк җыйганда адашып китсәк, аның тавышыннан болын ягын чамалый торган идек. Минем әби әйтә торган иде, шул малай җиде айлык булып туды, үзем кабул итеп алдым, тун җиңенә тыгып куйдым, ди торган иде. Җиде улы, бер кызы үсте шул Җантимер абзыйның, сигезен дә аерата безнең әби ярата иде, урамда очратса, башларыннан сыйпамый узмый иде. Җиде егет бер йорттан сугышка киттеләр. Икесе әле дә исән.

— Ә син миңа әкият итеп сөйләгән идең, — диде Зәйтүнә, чак кына үпкәләгән сыман итеп.

— Соң андый хәлләр борынгыда да булып торган инде ул. Минем үземә аны әбием сөйләде, аңа да әбисе сөйләгән. Шул Җантимер абзый хакында, әкияттәге шикелле булды бу хәл, ди торган иде үзе дә. Бөтен хикмәт тун җиңендә. Сез белеп җиткермисез әле борынгыларның гыйлемлелеген. Менә берзаман берәр галим тун җиңенең сабыйга шифасы турында китап язар да, бала тудыру йортларында гел шуны файдалана башларсыз.

...Шулай диде Гөлзәйнәп карчык. Ә бит хикмәтнең чыны тун җиңендә түгел, Гөлҗиһанда, аның мәңгелек булуында. Күрәсең, рәссам бу хакыйкатьне яхшы аңлаган. Әнә ничек тасвирлаган бит ул яшь хатынны. Иңенә шуып төшкән яулыгын тотарга дип күтәрелгән кулы ярты юлда туктап калган. Өзелеп сөйгән ярына каршы атлаган назлы хатын бу!

Кинәт Зәйтүнәнең күңелен бер уй көйдереп узды: аның беркайчан да Әнвәргә болай елмайганы, аңа таба бөтен барлыгы белән талпынып болай атлаганы юк бит әле! Дөрес, ул ирен ярата, аның янында үзен тыныч, рәхәт хис итә. Әмма Гөлҗиһандагыча балкуның, андагыча кайнарлыкның алар арасын яктыртканы, җылытканы юк әле.

Әнвәрнең кичәге сүзләре төбендә, күз карашында Зәйтүнәгә аңлашылмас эчке бер мәгънә бар иде шикелле. Хәзер бу мәгънә кинәт ачылды. Театрга соңга калган өчен генә түгел иде Әнвәрнең үпкәләве. Аның төбендә, мөгаен, башка нәрсә ята иде...

***

Дивардагы рәсемдә ана сабыена элеккечә үк чиксез наз белән төбәлгән иде. Бүлмәгә кергәч, Диләрам аңа карамаска тырышты. Ильясова каршына килеп, урындыкка җайсыз итеп, яны белән утырды.

Операцияне җиңел кичерде Диләрам, тиз терелде. Инде хәзер кайтып китсә дә була, алты-җиде айдан килер, яңадан операция ясарлар.

Шулай диде аңа Җәмилә Закировна. Дәүләтшинның кирәксезгә ясаган ярасы хакында дәшмәде, билгеле. Ә ул яра аркасында киләсе операциянең шактый кыенлашуы ихтимал...

— Иң мөһиме, син борчылмаска тырыш. Үзеңне сау-сәламәт, ваемсыз бер кыз дип хис ит. Миңа хат язып тор.

Беркатлы син, эчеңдәге тышыңда, ди Ләйлә әнисенә. Әмма авырулар янында хисләрен яшерә белә профессор. Авыру кеше табибның йөзендәге, күзендәге һәр үзгәрешне дүрт күз белән күзәтеп тора, аз гына борчылу сизсә дә шиккә төшә. Табиб күпмедер дәрәҗәдә артист та булырга тиеш. Профессор Ильясова Диләрамга бик шат һәм канәгать кыяфәттә карап утыра иде.

— Их, Җәмилә Закировна, ничек борчылмыйсың! Тагын операциягә керәсе исемә төшкән саен, Изаил Харисович күз алдыма килә дә жаннарым өшеп китә. Әллә ничек караңгы чырайлы бит ул, кырыс...

— Сиңа бу операцияне ясамый булмый иде, Диләрам. Доцент дөрес эшләде.

— Ике айдан туй буласы иде. Монда отпускыга гына дип килгән кеше бит мин. Ни йөзем белән күренермен инде хәзер аның күзенә, ни әйтермен?

Диләрам чигүле түбәтәен салып, күз төпләрен сөртеп алды.

Җәмилә Закировна аны ничек кирәк алай юатты юатуын, әмма үз күңелендәге шомны таратып бетерә алмады. Әгәр авыру кеше табибка — кара эчле булып, табиб авыруга караңгы чырайлы булып күренә икән, дәвалаудан өмет көтмә. Табибка ихлас күңелдән ышанган кешегә генә дәвалауның шифасы тия.

Кабинетка кешеләр кереп-чыгып тордылар, профессор аларга киңәшен бирде, авыруларны карарга вәгъдә итте, иртәгесе көнгә операция билгеләде, ләкин күңел түреннән һаман да Диләрамның чык кунган йөзем җимеше төсле күзләре китмәде. Нишләргә?

Диләрамны икенче тапкырында Дәүләтшинга илтеп тапшырырга ярамый. Башка берәүгә дә кушып булмый, чөнки Казанда андый операцияләр ясаучы бүтән кеше бөтенләй юк. Хәер, булса да Җәмилә Закировна Диләрамны башка берәүгә бөтенләе белән үк ышанып тапшыра алмас иде. Ул аны дәвалауны үз кулына алды, операция өчен җаваплылык та, асылда, аның җилкәсенә төште...

Ялгызы гына калган арада ул, телефонны алып, Мәскәүгә, аналар һәм балалар институтына шалтыратты. Мондый операцияләрне анда да ясыйлар, профессор Ильясовага белемен күтәрергә шунда барырга кирәк булачак иде. Яңа төр операцияләрне үзләштерү тиз генә эшләнми. Диләрам әйләнеп килгәнче, шактый күп әдәбият укырга, анатомия кафедрасына йөрергә һәм, әлбәттә, доцент Дәүләтшинның операцияләрен карап торырга туры киләчәк. Әйе-әйе, остаз үзенең шәкертеннән сабак алыр, әгәр дә бу гамәл авыруны терелтергә ярдәм итә икән, мин-минлек белән санашып торып булмый.

Боларны уйлагач, Җәмилә Закировна авыр сулап куйды. Аның күп еллардан бирле эшләп килгән фәнни темасы бар, чирне башланган чорында ук ачыклау һәм дәвалау юнәлешендә эшли ул. Вакытын-көчен башлыча шуңа багышларга тырыша, башка мөһим проблемалар белән шәкертләрен кызыксындырырга һәм мавыктырырга омтыла иде.

Яшьрәк чагында аңа сайланып торырга мөмкинлек булмады, һәммәсенә алынырга туры килә иде. Баштарак ул гомеремне дәвалау эшенә генә багышлармын дип уйлады, галим булуны максат итеп куймады. Фән юлына аны авырулар этәрде, гыйльми эшкә тотынырга алар мәҗбүр итте диргә була.

Хәтерендә, тудыру йортында ул кизү торган бер төндә, носилкага салып, бер яшь хатынны китерделәр. Аңа күз салуга, Җәмилә куркынып китте: хатынның йөзе күгәреп чыккан, күзләре йомык иде. Ул керфекләрен көчкә күтәреп:

— Доктор, — диде,— баланы... баланы... коткарыгыз... Ул исән калмаса, миңа да яшәү юк...

Хатынның тулгагы башланган, ә көчәнерлек хәле юк иде. Мондый очракларда табиб беренче чиратта хатынның үзен коткарып калу турында кайгыртырга тиеш. Баланың тормышы бәрабәренә булса да... Медицина кагыйдәләре шулай куша.

Ләкин бу ана күзен ачкач, Җәмилә аның йөзенә ничек карар, «балаң юк инде» дип ничек әйтер? Бу сүзләр ул хатынны һәлак итү булмасмы?

Җәмиләнең өендә ике сабые көтеп утыра иде, бала югалтуның нинди ачы хәсрәт икәнлеген фараз итеп кенә булса да күз алдына китерә ала иде ул. Кешегә андый күтәрә алмаслык фаҗига ясарга һич ярамый! Ләкин нишләргә соң?

Хәзерге кебек, телефоннан шалтыратып кына берәр галим-табибны чакырып китереп тә булмый. Үз җилкәңә төшкәнне үзең күтәрергә тиеш чор — сугыш вакыты иде бу. Җәмиләнең ире Мөбарәк фронтта иде, бу хатынның да гомер юлдашы шунда булгандыр. Балаларыгыз тагын булыр әле дип юатып та булмаячак. Әллә кайта аның ире ут эченнән, әллә юк...

Булырга тиеш моның чарасы, булырга тиеш! Һәм Җәмилә тәвәккәлләде: китаптан укыган, ләкин кулланганнарын күрмәгән бер чараны кулланды. Бер укол (фәкать бер укол!) ясарга туры килде, калганына акушерка белән икесе ярдәм иттеләр. Һәм бала исән туды.

Иртәгесен күзен ачкач, яшь ана иң беренче сүз итеп сабыен сорады. Җәмилә аңа бәбиен үзе алып кереп күрсәтте. Ана баланың тыныч мыслаган борынына, йомык күзләренә, йокы аралаш имгәндәй мимылдаган авызына карады да елмаеп җибәрде. Аннары шул ук елмаюлы карашын Җәмиләгә күчерде.

Ул хатынның төсен-кыяфәтен үткән еллар, аккан сулар күптән инде хәтердән юып алып киттеләр. Ләкин менә елмаю җылысы күңел түрендә һаман саклана. Яңа ачылган гөл чәчәгенең сафлыгы, чисталыгы, матурлыгы, яшәү тантанасы һәм чиксез бәхет бар иде ул карашта.

Мондый елмаю яңа туган сабыена караган һәр ананың йөзендә балкый. Һәм шул карашның үзенә дә сирпелгәнен тойган саен, Җәмилә Закировнаның күңеленә куаныч дулкыны бәреп керә. Бу караш аның өчен иң зур рәхмәт сүзләреннән, иң олы бүләкләрдән дә кадерлерәк.

Ә теге хатынның баласы кыз иде. Кайларда, ничек яши икән ул хәзерге вакытта? Утыздан узгандыр, үз балалары җитеп киләдер инде. Исән-сау дөньяга килүе белән яшь табиб Җәмиләне фән юлына этәргәнен белә микән ул?

Каян белсен! Ул чакта Җәмилә үзе дә моны башына китермәгән иде әле. Авыр хәлдәге хатыннар аның кул астына кергәләп торды, Җәмилә бер кулланган чараны тагын-тагын кулланмый булдыра алмады. Даруны куллануны ныклы нигезләргә, нинди очракта кайсы дарулар белән бергә кулланырга яраганын, ә кайсылары белән — ярамаганын ачыкларга, кеше организмының үзенчәлекләренә карап, микъдарын билгеләргә кирәк иде. Моның өчен аңа препарат турында басылып чыкканнарны табып укырга, клиник тикшеренүләр, күзәтүләр алып барырга кирәк булды.

Бу эзләнүләр тора-бара аның докторлык диссертациясенә нигез булып ятты. Хәзерге вакытта бу чараны куллануның төпле методикасы эшләнгән, ул «профессор Ильясова методы» дип атала һәм киң кулланыла.

Профессор Ильясованың медицина әдәбиятына кергән һәм кулланышка алынган тагын берничә методы бар. Алары да үлем чигенә килеп җиткән хатыннарны коткарып калу теләгеннән туды. Аналар сабыйларына яңа ачылган гөл чәчәге кебек карасын өчен булдырылды ул чаралар...

...Кичкә таба Җәмилә Закировна кызына шалтыратты:

— Эштән туры безгә кайт әле, Ләйлүк.

Ә үзе, китапханәгә сугылып, ике кулына ике төргәк китап күтәреп кайтып керде. Берсен ишек ачкан Ләйләгә сузды:

— Болары сиңа, кызым, мин билгеләгән төшләрен тәрҗемә итеп бирерсең.

— Нишләп бу хәтле күп?

— Яңадан сабакка утырам мин, кызым. Безнең эштә башкача булмый, чөнки врачның наданлыгы кеше үтерә. Әйдәле, миңа көч керсен өчен, өчпочмак пешереп ашыйк!

Әниләре белән бергәләп пешеренү Ләйлә белән Равил өчен һәрвакыт күңелле бәйрәм. Кызганычка каршы, андый көннәр сирәк була. Инде тәвәккәлләп, җиң сызганып, алъяпкыч бәйләп, кулны камырга тыгалар гына, алгы бүлмә диварына элеп куелган кара телефон сискәндереп зыңгылдый башлый. Бик ашыгыч рәвештә тудыру йортына яисә берәр хастаханәгә чакыралар. Әни кеше, кулларын юган арада, өйдәгеләргә нәрсәне ничек эшләргә икәнен аңлата...

Хәзер инде Җәмилә Закировнаны алай еш борчымыйлар, чөнки шәкертләре үсеп, остарып җитте. Әмма бергәләшеп җыелышу барыбер сирәк эләгә, чөнки Ләйләнең дә, Равилнең дә үз тормышы, үз гаиләсе бар. Бүгенге табын янында кызлары булу Мөбарәк Таһирович белән Җәмилә Закировна өчен күңелле вакыйга иде. Эштәге борчулар турында күп сөйләшмәскә тырыштылар. Мөбарәк Таһирович танылган галим, олы кеше, ләкин шуңа карамастан, хатыны әйтмешли, «яшь-җилкенчәк кизүе элэктергән» — «Жигули» машинасы сатып алган, хәзер шофер булырга укып йөри.

— Булдыксыз шәкерт синең әтиең, «өчле»ләр алып кайта, —диде Җәмилә Закировна, шаярып, кызына.

— Мин гаепле түгел, юл күрсәткечләре гаепле, — диде Мөбарәк Таһирович аларның үз итеп көлемсерәүләренә.— Юл күрсәткечләре өскә эленгән, ә аста халык йөри. Кайсына кararга тиеш соң мин? Аска да, өскә дә берьюлы карап булмый бит!

— Шофер булу — галим булу гына түгел ул сиңа!

Табынны жыештыргач, Җәмилә Закировна борынгы кара пианиноны ачты да әйләнмәле урындыкка утырды. Лагы бераз тоныкланган бу пианино Ләйлә өчен туган йортның ямьле бер бизәге булып күренә, балачак истәлекләрен саклый иде. Җәмилә Закировнаның сизгер бармаклары клавишлар буйлап сак кына йөгереп узды. Бик күп музыкантларны тыңлаганы бар Ләйләнең, әмма әнисе уйнагандагы кебек хисләнгәне сирәк. Музыка коралларында уйнау бармакларның хәрәкәтчәнлеген, төгәллеген арттыра, ди әнисе. Шуны уйлап, үзлегеннән уйнарга өйрәнгән, вакыт табып, азга булса да пианино янында утырып алырга тырыша.

Ләйләдә ул нәни чактан халык җырларына мәхәббәт уятты. Менә хәзер дә таныш җырны башлап җибәрде:

Кара да гынай урман, караңгы төн,
Яхшы атлар кирәк лә узарга...

Еллар узган саен Ләйләнең әнисенә сокланuы арта бара. Каян килгән аңа мондый олы күңел, ихтыяр көче, талант? Гади семьяда үскән кыз бит ул. Ләйләнең әбисе яза да белмәгән, бабасы үзлегеннән генә укырга өйрәнгән. Алар борынгыча яшәгәннәр, борынгыча туй иткәннәр: кәләш үзенең киявен зөфаф кичендә беренче тапкыр күргән. Шуңа карамастан тату гомер иткәннәр, биш бала үстергәннәр. Җәмилә — уртанчысы.

Каян килгән аңа мондый моң, музыка мәктәпләрендә укып та өйрәнеп булмый торган борылышлар, хислелек?

Борынгыдан, каяндыр бик ерактан, буыннан-буынга күчеп килгән моң-хисләр бу. Җәмилә күңелендә алардан килгән талант, алардан күчкән байлык яши.

Соңгы елларда Җәмилә Закировнаның уенында һәм җырларында ямансулык көчәйгән кебек тоела. Бу кичне кызын озата чыккач, хушлашыр алдыннан ул:

— Никтер вакыт-вакыт күңелем сәбәпсезгә борчыла, — диде.— Тормышым шулкадәр түгәрәк, менә бу ягы яхшырсын иде, дип теләрлек тә түгел. Ә тормыш үзгәрешсез булмый. Бер-бер хәл булмагае дип шомланып куям.

Ул боларны елмаю аша әйтте. Ләйләгә әнисе кечерәеп киткәндәй тоелды. Кайчан гына әле ул, әнисенең итәгенә сарылып, юату, наз көтеп, күзләренә карый иде. Хәзер менә әнисе аннан күңелне тынычландырырдай сүзләр көтә. Ләйлә аны иңнәреннән кочып алды.

— Әни, без әле бик озак, бик күп еллар нәкъ менә шушылай яшәячәкбез. Болай гына да түгел, куанычларыбыз күп булыр әле безнең. Синең яңадан сабакка утыруың, яңа эшкә тотынуың бер дә юкка түгел бит!

Җәмилә Закировна башын күтәреп, кызы белән тигезләнергә теләгәндәй, тураебрак басты.

Икенче бүлек

«Уникенче июньдә 425 нче рейс белән Сургуттан очам. Лариса»,— диелгән иде телеграммада. Каршы алыгыз, димәгән, ләкин анысы сүзсез дә аңлашылды.

Кышын язган хатларының берсендә ул: «Җәй башында Казанга кайтам, гостиницада урын алып куя алмассызмы?» — дип сораган иде. Зәйтүнә: «Кил, үзебездә торырсың», — дип язып җибәрде.

Инде менә каршы алырга да кирәк икән. Җайсызрак чакта килә килүен. Яшь бала, Гөлзәйнәп карчык, үзләре икәү — бер бүлмәле фатирда кысанрак булачак иде.

— Күңелең киң булсын, — диде бу хәлләрне белгәч, картайган йөзендә яшь, нурлы күзләрен балкытып, Гөлзәйнәп карчык.

Самолет килгәч, багажны озак бирми торганнармы, әллә машина таба алмаганнармы — Лариса белән Әнвәр аэропорттан төнге бердә генә кайтып керделәр.

Җитлегеп туган, сау-сәламәт Тимербулат ниндидер билгесез сәбәптән сыны катып елый, бер тотынса сәгатьләр буе туктый алмый иде. Бала күтәреп ишекле-түрле Зәйтүнә йөренә, аның артыннан нишләргә белми әнисе иярген. Ниһаять, бала тынып, ана белән кыз хәлдән таеп кайсы кая хәл алырга дип ятканнар иде, тышкы ишекнең ачылып ябылганы, гаҗәп көр, дулкынланган тавыш белән сөйләшкән авазлар ишетелде, кыңгырау шалтырады. Лариса ишектән төньякның тыннарны куыра торган салкын, саф җиле кебек ургылып килеп керде. Керүе булды, Зәйтүнәне кочагына бөтереп тә алды, иреннәреннән суырып та үпте.

Зәйтүнә кухня ягында чәй яңарткан арада, ул ванна бүлмәсендә су шыбырдатырга кереште, табын әзер булуга, кызарынып, кайнарланып килеп тә чыкты. Аның өстендә буйлы йөнтәс халат, киң җиңе эченнән куллары терсәккә кадәр чыгып тора, биленә уралган озын билбау гәүдәсенең сылулыгын күрсәтә иде. Ул артсыз утыргычка утырганда, итәге ачылып, ак, тыгыз ботлары ялтырап куйды. Лариса

аларны капларга ашыкмады. Ул инде җирән бөдрәләрен юеш килеш тәртипкә салган, калку яшькелт күзләре сөенеч, тынгысызлык бөркы иде.

Зәйтүнә берничә тапкыр бүлмәдә әби белән бәби йоклаганын әйтеп караса да, Лариса вакыт-вакыт дөньясын онытып кычкырып сөйләшә башлый. Моңа табын уртасына менеп утырган шәраб шешәсе дә сәбәп булды. Лариса бер рюмка эчәргә Зәйтүнәне дә кыстый башлады, аның бала имезгәнен белгәч:

— Ништяк! — дип кычкырып җибәрде. Бу — аның төньяктан өйрәнеп кайткан яңа сүзе иде. — Һаман имезәсеңмени әле? Җиде айлык дисеңме? Бу заманда кем инде баланы шулхәтле имезә? Аер син аны, Зюзю! Замана баласына кибет сөте ярамаган тагын! Үзеңне сакла! Ирләр алар таза-сәламәт хатыннарны гына ярата, бөтен сүлен баласына бирәп, үзе корып калганнарны түгел!

Үзе шундый итеп, шаярып та, үртәп тә, якын итеп тә карый Әнвәргә, һич кенә дә үпкәләрлек түгел! Чыннан да үзенекен итте бит, кыстый торгач әни кешегә бер рюмка шәраб эчерде. Һәм шундук Зәйтүнәне йокы басты. Ларисаның исә күзләре торган саен киңрәк ачыла, очкынлана барды, ул иркенәеп, табынны үзенчә көйләргә кереште. Ак күмәчне юка телемнәргә турап, май ягып, төче торма кисәкләре, яшел суган кыяклары тезде дә, «фирменный бутерброд» дип, өстәл аша Әнвәргә сузды. Тегесе аның тырпаеп торган кызыл тырнаклы чәнти бармагына карап сәер елмайган иде. Аларның икесе арасында күзгә күренмәс җеп сузылгандай булды, йокымсырап утырган Зәйтүнә табын янында артык һәм чит тоела башлады.

Лариса юлда кичергәннәрен мәзәк итеп сөйләде. Свердловскида самолетның озак утырганын, шунлыктан Казанга соңарып килгәнен, үзенең, каршы алмаслар инде, дип пошаманга төшкәнен, ниһаять, килеп җиткәч, Әнвәр белән аймылыш булганнарын кат-кат кабатлады.

— Инде берәр гостиницага китим дип чыккач, тагын бер карыйм әле дип, аэропортка кире кергән идем, танылым бит моны! Чәчен кыска кискәнгәдер инде, караңгыда гел бүтән булып күренгән икән. Тәмам күңелем төшкән иде. Ништяк, мин әйтәм, дуслар оныткан мине! Шуннан күреп алгач, сөенечемнән нишләгәнемне белмәдем. Берзаман исемә килсәм, мин моның муенында асылынып торам... Син, Зюзю, ачуланма, гөнаһ дип уйлама, ялгыш килеп чыкты. Минем кебек ел буе сөргендә булсаң, хәлемне аңлар идең...

Зәйтүнә кинәт бастырыла башлагандай сискәнеп куйды, кузгалып бүлмәгә чыкты да җәелмә ятакка урын әзерләргә кереште.

Ә кухняда Лариса Әнвәр белән аның саен җанланып сөйләшә иде:

— Бишенче буын интеллигент бит мин. Зюзю сиңа әйткәндер инде.

«Кайчан һәм ник сөйләргә тиеш идем икән мин бу хакта иремә?» — дип уйлады бүлмәдән боларны ишетеп торган Зәйтүнә.

— Безнең нәсел борын-борыннан зур калаларда гомер сөргән,— дип дәвам итте Лариса.— Урбанистлар каны ага миндә.

— Кан калага тарта, димәк.— Әнвәрнең тавышында көлемсерәү сизелә, тик бу яратып, үз итеп көлемсерәү иде.

— Кан үзенекен итә ул, бернишли алмыйсың!

— Ә Хөсәеннең каны ничек соң?

— Анда саф татар каны. Татар ул борын-борыннан кайда туры килсә, шунда яши. Кайда әҗәл күренсә, аны шунда чакыралар. Доктор Нигъмәтуллинның даны анда төньяк балкышыннан яктырак яна.

— Ник бергә кайтмадыгыз соң, ял итеп китәр иде, — диде Зәйтүнә, алар янына кереп һәм пышылдап кына. Ул ничек тә булса Ларисаны әкренрәк сөйләштерергә тырыша иде. Баланы уята күрмәсен тагын!

— Әүлия ялга чыгамыни! Әүлияга отпуск юк аңа! Акыллы башлар җәй җитү белән көньякка, диңгез буена кача, алар салган камытны әүлиялар киеп кала. Доктор Нигъмәтуллин хасталарны ташлап китәме соң!

— Синдә дә дәваланучылар бардыр бит? — дип сорады Зәйтүнә, сак кына.

— Бер семьяга ике әүлия күбрәккә китмәсме? Хөсәен җыйган савап икебезгә дә җитәр әле. Дурак ул! Әллә кемнәрнең ирләрен-хатыннарын күз-колаксыз калдыра алмый, ә менә үз хатынын ялгыз җибәрә ала! Анысына вөҗданы каршы килми! — дип, ул, хуплау көтеп, Әнвәргә текәлде.

...Ул килгәч, өйдә тормыш шау-шулырак, ыгы-зыгылырак булып китте. Лариса бүләк иткән уенчыклар белән идән тулды, ул тараткан хуш истән баш әйләнде. Иртән ванна бүлмәсеннән прическа ясап, иннек сөртеп, ак мех белән бизәлгән йомшак башмакларын киеп чыга: «А-а, батыр!» — дип, Тимербулатны күтәреп ала. «Яхшы йокладыңмы, апа?» — дип, Гөлзәйнәп карчыкның хәлен белешә, аны тыңлап та бетермичә, кухняга кереп, савыт-саба шалтырата башлый. Артыннан бала — гүләп, карчык елмаеп карап кала.

Кич Зәйтүнә кайтуга өйдә ят ризыклар пешкән була: йә кузгалак ашы, йә гөмбә белән бәрәңге. «Аша, апа, аша, урман җимеше, гөнаһысы юк», — дип, гомере буе гөмбә капмаган Гөлзәйнәпне дә кыстап ашата алды ул.

Вазадан – чәчәкләр, шкафтан коньяк өзелмәс булды. Табын әзерләгәч, Лариса белән Әнвәр шкаф янында мыштым гына берәр рюмка эчеп куялар, аннары гына карчыкны ашарга чакыралар. Ә кайчакта берәр рюмка гына җитеп бетми, берәмләп-берәмләп бүлмәгә чыгып керергә туры килә, бу кыска сәяхәттән соң Ларисаның тавышы тагы да көчәя, авызы ерыла. Беркатлы карчык берничә көннән генә кызына: «Синең бу кунагың әллә төшергәләп тә ала инде?» — дип куйды.

Башкаларга гафу ителмәслек кимчелек — кызмача булу да Ларисага килешеп кенә тора, хәтта шул хәлендә дә ул күңелне кайтармый иде.

Ә бер кичне ул әби белән бәбине урамга чыгарып җибәрде:

— Свежий һава кирәк, апа! Олыга да, кечегә дә кирәк!

Алар чыгып китүгә, бала әйберләрен юарга дип, ванна бүлмәсенә юнәлгән Зәйтүнәне кулыннан эләктереп алды да өстәл янына утыртты.

— Фу , кулларың! — диде. — Фермада эшлисеңмени! Син врач һәм зур кеше хатыны. Чәчеңә прическа ясалган, тырнагың кызартылган булсын! Кичләрен бизәнеп-ясанып куй да иреңне елмаеп-көлеп каршы ал. Тамагын туйдыр. Шуннан соң ул ничек итеп ванна бүлмәсенә кереп киткәнен, ничек итеп бала әйберләрен юып атканын сизми дә калыр!

Ул кухнядан җамаяк белән кайнар су алып чыкты да, сыек сабын салып, Зәйтүнәнең бармакларын батырды. Чемоданыннан күн савыт алып ачты. Анда, кызыл бәрхет эчендә, ялтырап, тырнак тазарту әйберләре ята иде. Алар Әнвәрнең сызу әсбапларын искә төшерде.

— Синең белән бер мәсьәлә турында киңәшәсе бар иде бит әле, Зюзю. Беләсеңме, китмәскә кайттым бит мин.

— Ничек китмәскә?

— Кафедрага урнашасы иде. Мин зур гына фәнни эш башладым. Бик актуаль темага.

Зәйтүнәгә бу гаҗәп тоелды. Институтта укыганда Лариса фәнни эш белән бөтенләй кызыксынмый иде.

— Шул арадамы? — дип сорамый булдыра алмады Зәйтүнә.

— Ну, андагы мөмкинлекләрне моннан торып күз алдына китереп тә булмый. Бернинди конкуренция юк. Мондагы шикелле, нишлим икән, нинди мөгез чыгарып шаккатырыйм икән дип, баш ватып йөрисе юк.

Шушы рәвешле һич көтмәгәндә чәнчеп куя торган гадәте бар Ларисаның. Зәйтүнә аның кинаясен үткәреп җибәрергә тырышты.

— Миңа хәзер абруйлы галим кул астында эшне төгәлләп куярга гына калды. Зур исемле җитәкче кирәк. Үзең беләсең, хәзерге заманда киң күкрәге белән алдан сиңа юл ярып баручы кешең булмаса, әҗәл даруы уйлап чыгарсаң да бар дип тә белмәячәкләр. Ачыш ясаганыңны зур кеше авызыннан әйттерү мөһим.

— Нинди тема соң ул? — Зәйтүнәнең күңелендә җиңелчә көнләшү хисе уянды. Ул үзе студент чагыннан бирле бер заводта һавага бүленеп чыга торган матдәләрнең хатын-кыз организмына тәэсирен өйрәнүдә катнаша. Ләкин мөстәкыйль хезмәт белән үзен күрсәтә алганы юк әле.

— Токсикозларны өйрәнәм мин,— диде Лариса, Зәйтүнәнең сул кулын җамаяктан алып, йомшак сөлге белән сөрткәндә. — Токсикозларның көчен кан составына карап билгеләү методын.

— Нинди токсикозлар?

— Соңгы токсикозлар. Канда аларның билгеләре бик иртә беленә.

Зәйтүнәнең сыны турайды. Ул, бала тудыру йортында шактый эшләгән кеше, бу мәсьәләнең мөһимлеген бик яхшы белә иде. Бала тапканда һәлак булган хатыннарның үлеменә элек-электән нәкъ менә шул соңгы токсикозлар сәбәп булган да инде. Дөрес, хәзерге вакытта үлемгә үк җиткермиләр, һәрхәлдә андый очрак сирәк була, шулай да токсикозларны вакытында дәвалау мөмкинлеге табылса, күп бәхетсезлекләр булдырылмый калыр иде.

— Миндә материал җитәрлек,— диде Лариса, гади генә итеп.— Йөзләрчә авыру тарихлары. Һәммәсенең каны даими тикшерелеп торылган, дәвалау нәтиҗәләре җентекләп язып барылган.

— Бер ел эчендә йөзләрчә токсикоз күзәттеңме?

— Кызык кеше син, Зюзю. Беләсең бит инде, фәнни нәтиҗәләрне галимнәр үзләре күзәткәннән генә китереп чыгармыйлар. Утыз ел эшләгән бер гинеколог белән дуслаштым мин анда. Хәзер ул пенсиягә чыкты да Белгородка китеп барды. Җыйган материалларын миңа биреп калдырды. Болай алар барыбер файдасыз юкка чыгачак, мин үзем фәнни эшләр белән шөгыльләнергә соңардым инде, ди. Посылка белән салдым мин аларны монда. Сигез килодан артык тартты, почтада алмыйбыз дип карышып маташтылар. Миңа хәзер берәр галим ярдәмендә аларны эшкәртеп, гыйльми хезмәт рәвешенә китерергә генә кирәк... Зюзю, сезнең клиникага урнашып булмас микән? Белеш әле, ә?

— Ә эшеңнән җибәрәләрме соң?

— Җибәрерләр! Мин үземнең гражданлык бурычымны үтәдем дип саныйм. Һәрберегез берәр ел шунда барып эшләп карагыз әле!

Зәйтүнә монысын да күңеленә якын алмаска тырышты.

— Ә Хөсәен?

— Ул декабрист түгел, мин декабрист хатыны түгел. Яратуы хак булса, үзе минем арттан кайтсын.

Зәйтүнә Ларисаның җирән бөдрәле йомры башына карады. Моңарчы ул дустының җорлыгын, уңганлыгын, пөхтәлеген генә күрә иде, хәзер ул яңа яклары белән ачылып киткәндәй булды. Таулар да шулай беренче карашка карлы түбәләре белән яктырып, күңелне ымсындырып, ялтырап тора, якынрак килгәч кенә андагы кыялар арасындагы упкыннарны күрәсең. Ниләр ята икән Ларисаның күңел упкыннарында? Эремәс бозлармы? Салкын таш өемнәреме?

— Балагыз да булмаган икән, — дип куйды Зәйтүнә.

— Бу рәвешле икеле-микеле яшәп ятканда, ничек бала булдырасың!

— Бала дөньяны бөтенләй үзгәртә икән бит ул. Беләсеңме, Лариса, Тимербулат туганнан бирле мин киләчәк турында бик борчылып уйлана торган булып киттем. Илләр арасында дәгъва чыкканны ишеткән саен, күңелне шом баса. Элегрәк мин сәясәткә бик үк игътибар итми идем. Хәзер менә дөньяда булган һәр яңалык шәхсән миңа килеп кагыла кебек. Мин аңа тормыш бирдем, мин үземне аның киләчәгә өчен җаваплы дип саныйм. Шундый уйлар белән борчылып, төн йокламый чыккан чакларым була. Бала үзгәртә икән кешене, бөтенләй башка итә икән.

Лариса аңа гажәпләнеп карады:

— Ништяк! Тапкансың хәсрәтләнер нәрсә! Сугышны башлыйкмы-башламыйкмы дип синнән-миннән сорап тормаслар! Әниләр безне тапкан бит әле, еллар җиңел булмаса да. Яшибез менә! Һәм начар яшибез дип тә булмый!

— Ләкин син үзең үк киләчәк өчен тырышасың бит. Эзләнәсең, ачыш ясарга омтыласың.

— Син миңа шуны әйт: Ильясова белән сөйләшүдән мәгънә бармы? Кайчан барсам җайлырак булыр икән?

— Мин белешермен. Ләкин...

— Ул мине җайлы вакытта кабул итсен, — диде Лариса, тагын аны бүлеп. — Калганын үзем карармын.

***

Галимнәрнең үзләренә аерым бишьеллыклары бар: биш елдан биш елга кафедра мөдирлегенә конкурс булып тора.

Узган юлы сайлангач, Җәмилә Закировна, бу соңгысы булыр инде дип уйлаган иде. Ул чакта биш ел бик озын булып тоелган иде.

Хәзер менә артка борылып карагач, аның кай арада узганына хәйран каласың. Олыгайган саен, елларның йөгереше кызулана бара: чылк — бер ел узган, чылк — икенчесе... Ул арада синең тормышыңда берни дә үзгәрмәгән шикелле.

Хәер, кайберәүләр өчен бу еллар мәгънәле булды. Доцент Дәүләтшин өчен, мәсәлән. Күзгә күренеп үсте ул. Хәзер инде аны Казанда гына түгел, Мәскәүдә дә яхшы беләләр икән. Узган елны аналарның һәм балаларның сәламәтлеген саклау институтына тәжрибә уртаклашырга баргач, профессор Ильясовага моны бик ачык сиздерделәр:

— Сез Казаннанмыни? Изаил Харисовичны беләсездер инде алайса? О-о, менә дигән специалист, зур галим булачак!

Профессор Ильясованың нинди проблема белән кызыксынганын белгәч, гажәпкә калдылар.

— Ә нигә Изаил Харисовичка мөрәҗәгать итмәдегез? Ул барлык яңалыклардан хәбәрдар тора һәм операцияләрне дә бик яхшы ясый.

Арада, тырнак астыннан кер эзләп йөрмиме бу, дип, профессорга шикләнеп һәм өнәмичә караучылар да булды.

— Сезнең анда талантлы яшьләрне үстерергә бик үк тырышмыйлар булса кирәк, — диде сары чәчле, чыра кебек ябык, озын буйлы яшь бер галимә. — Изаил Харисович булып, ул да әле профессор түгел икән!

Бу сүзләрне ул профессор Ильясовага шәхсән үпкәсе бар сыман итеп әйтте. Доцент Дәүләтшин фән юлыннан гына түгел, яшәешнең башка сукмакларыннан да җиңүле адымнар белән бара иде, күрәсең. Сары чәчле галимәнең ачуын аңлап та була, чыннан да, дөньяда шундый остазлар да очрап тора бит: мактый-мактый үстергән шәкертләре үзләрен узып китә башласалар, түбәләрен төяргә керешәләр.

Хәлбуки Дәүләтшин профессор Ильясовадан үзе китте һәм һич көтмәгәндә китеп барды. Җәмилә Закировна үз вакытында моны шактый авыр кичерде. Кайта-кайта уйлана торгач, Изаил Харисовичның электән үк килгән сәерлекләре искә төште: ул, мәсәлән, заводларга барырга яратмый, шефлык эшләренә катнашмаска тырыша иде. Төннәрен клиникадан шалтыратсалар, гадәттә, телефонны алмый, соңыннан, өйдә түгел идем, дип аклана. Дөрес, үз темасына туры килгән авыруларны зур игътибар белән карый, әмма аның карашынча гадәтиләрен башкаларга авыштыру ягын чамалый иде.

— Урамнан килеп кергән һәр кешене дәвалап кына ерак китеп булмый, — дигән иде ул бервакыт. — Алай ваклансаң, район врачы дәрәҗәсеннән югары күтәрелә алмассың. Галимнәр теленә керерлек эш башкарырга кирәк!

Иң беренче чиратта телгә керү, исем казану турында уйлый иде доцент Дәүләтшин. Шуңа күрә аңа кафедраның тоткан юнәлеше гомумән ошамый иде.

Авырулар турында онытып җибәрә иде ул кайчакта. Шуңа күрә Җәмилә Закировна аңа Диләрамны икенче тапкыр җибәрә алмады. Ярты елдан соң аңа операцияне үз ясады.

Хәзер Диләрам аңа рәхмәтләр әйтеп хат язып тора, кияүгә чыкты, әни булырга әзерләнсә, тагын Казанга килергә тиеш.

Бер авыруның язмышын ышанып тапшыра алмаганны, тулы бер кафедраның киләчәген Дәүләтшинга ышанып тапшыра ала идеме соң профессор Ильясова?

Ә Дәүләтшинга профессор булу бик кирәк, нәкъ менә Казанда, даны илгә таралган медицина үзәгендә зур галим исемен казанырга кирәк аңа. Мәскәү институтының урам кебек озын, иркен коридорларында йөргәндә, дөньядагы иң яхшы приборлар һәм аппаратлар белән җиһазланган лабораторияләренә кергәндә, ниһаять, андагы кешеләрнең туктаусыз чит ил галимнәрен телгә алып сөйләгәннәрен тыңлаганда, Җәмилә Закировна Дәүләтшинның бу теләген бик яхшы аңлады. Аңа профессор булу шушы институтка үрмәләү, аннары, бәлки, дөньякүләм аренага омтылу өчен кирәктер дә.

Ә хәзер Дәүләтшинның баш өстендә, икенче кафедрада, илле яшендәге галим утыра, ул әле тиз генә китмәячәк, шулай итеп, бөтен өмет профессор Ильясова урындыгында иде.

Җәмилә Закировна исә, зиһене ачык, көче җитәрлек чакта, җитәкчелек мәшәкатьләреннән арынып, күп еллар элек башлаган фәнни хезмәтен тәмамлау хакында хыяллана иде.

Әмма ул хәзер китсә, кафедра башына Дәүләтшин менеп утырачак, беркемгә дә юл куймаячак.

Бу турыда ныклап уйлагач, Җәмилә Закировна катгый бер карарга килергә тиеш булды. Гаризалар кабул итүнең соңгы көнендә ул ректор янына керде.

Бу юлы ректор аны «Т» хәрефе ясап куелган өстәлләрнең түрдәгесе артына басып каршы алды. Профессор Ильясова аңа яны беләнрәк утырды да, сүзне турыдан башлады:

— Кафедра мөдирлегенә мин тагын үз кандидатурамны куярга ниятләп торам әле.

Ул текәлеп ректорның шакмаклап ясалган кара кысалы күзлегенә карады, әмма калын пыяла күз алмаларын зурайтып күрсәткәнгә, алар һәрвакыттагыча гажәпләнгән кебек тоелалар, асылда, бу кешенең ни уйлаганын белеп булмый иде.

— Сезне әле яңа гына сайлаган идек кебек, биш ел үткән дә киткән,— диде ул.— Гомерләр уза, без олыгаябыз...

Ректор әле генә ишеткән сүзләргә мөнәсәбәтен белдерергә ашыкмады. Хәлбуки бу катлаулы мәсьәлә иде. Институт тарихында Ильясова яшендәге хатын-кызның мондый югары урынга сайланганы юк иде әле. Шуның өстенә ректор үзе дә җаваплы постларга ирләрне куюны хуп күрә, институтка да егетләрне күбрәк алырга кирәклеге хакында трибуналардан кычкырып әйтә иде.

— Гаризамны тапшырганчы, бу хакта сезнең фикерне беләсе килгән иде, — диде Җәмилә Закировна.

— Кафедраның эшчәнлеге моңарчы яхшы бәяләнеп килде бит, Җәмилә Закировна. Дөрес, Дәүләтшин да гариза бирде, әмма гыйльми совет сезнең көчегезне, энергиягезне исәпкә алмый калмас.

Эшен яхшы алып барган җитәкчене гадәттә тора салып урыныннан кузгатмыйлар. Бу очракта гыйльми советның карары уңай булачагына алдан ук ышаныч зур иде.

Әмма профессор Ильясова кем юлына аркылы басканын аңлап бетерми иде әле.

***

Ял көнне, барысы бергә җыелышып, Аккош күленә киттеләр. Зәйтүнә белән Тимербулат, Гөлзәйнәп карчык, Әнвәр һәм Лариса бер машинага сыйдылар, такси аларны урман юлыннан җилтерәтеп, унбиш минутта күл буена илтеп тә куйды.

Биек нарат ышыгына җәймә җәеп, иркенләп урнаштылар. Кояш нурында ялтырап яткан судан, хәтфә үләннән, наратлардан аңкыган хуш ис сулышны иркенәйтә, күз күременең киңлеге карашларны

үзгәртә иде. Тимербулат җәймә буйлап үрмәли, көлә, шаяра башлады. Гөлзәйнәп, кардай ак чәче өстеннән арткарак шуышкан ак яулыгын төзәтеп, күл суыдай ялтыраган карашын Зәйтүнәгә төбәде дә:

— И рәхмәт, монда да алып чыктыгыз,— диде.— Урман күрмәгәнгә бик күптән бит инде. Безнең авыл тирәсендәге болыннар, әрәмәлекләр сагынып сөйләргә генә калды. Мондый сахраларны күрсәң, шул кала тирәсендә генә күрәсең.

Ул арада Лариса сарафанын нарат төбенә салды да ачык бизәкле коену костюмыннан гына калды. Әнвәр дә чишенеп ташлаган, зәңгәр трусиктан гына, тик кыенсына бугай, читтәрәк тулгана. Әнә ул агачлар арасында күренеп торган яшел будкага таба китте. Зәйтүнә аңа сокланып карап калды. Әнвәр, буйга уртача гына булса да, гәүдәсе төз, шома тиресе астында мускуллары уйнап тора. Әнә ул җиңел адымнар белән кире килә, нарат ябалдашлары аша төшкән нур аның йөзендә уйный. Ерактан ук:

— Су велосипеды бар, әйдә йөзәбез, — ди.

Зәйтүнә Тимербулатны күтәреп баскан иде, әнисе:

— Баланы нишләтмәкче буласыз тагын?— диде. — Су чәчрәр, салкын тияр, ялгыш күлгә чумдырырсыз, Алла сакласын. Үзегез генә йөрегез! — һәм ул Тимербулатны елатып диярлек алып калды.

Әнвәр белән Зәйтүнә күл уртасыннан бер әйләнеп килделәр.

Кызык үзе: су чәчри, тәгәрмәчләр әйләнә, ләкин әни кеше минут саен артына борылып карамыйча түзә алмады. Анда бала әтисе белән әнисенә таба талпына, елый, әбисе аны тыярга азаплана, ә читтәрәк Лариса кулларын җәеп кызынып ята иде. Интегә иде Гөлзәйнәп, җаны кыйнала иде аның, чөнки шәрә кешегә кararга ояла, пляжларны «шүрәле оясы» дип атый, шәһәр халкының бу кыланмышын кыргыйлык дип саный иде.

Зәйтүнә тизрәк ярга чыгарга ашыкты.

— Әйдә, әни, чәй эчик,— дип, термостан чәй салды.— Ә син кунакны йөртеп кил,— диде Әнвәргә.— Миңа чыланырга ярамый.

Әнә алар икесе янәшә утырып йөзеп тә киттеләр. Лариса җыйнак гәүдәсен артка каерыбрак утырган, тыгыз, йомры балтырлары тамчылар арасыннан елтырап, педальләрне кызу әйләндерә. Алар бер-берсе белән ярышып, йөрешне тизләттеләр, көлешкән, шаярышкан тавышлары гына ишетелеп калды.

Аргы ярга җитәрәк, велосипед янтаеп китте, алар икәүләп суга сикерделәр һәм узыша-узыша йөзә башладылар. Гөлзәйнәп күлгә аркасы белән борылып утырды, озак кына итеп каршындагы наратка карады, аннары, шул агачка текәлгән килеш:

— Үзләрен генә... җибәрмәскә иде, — диде.

— Аның ишегә игътибар итмә син, әни!

— Итәргә кирәк, бик итәргә кирәк! — Карчык күлмәк итәгеннән нидер чүпләгәндәй итенеп, тыелырга тырышып карады, ләкин әйтәсен әйтми кала алмады. — Тормышыгыз бик түгәрәк, кызыгучылар күп булыр. Үз хатынын яраткан иргә башка хатыннар ялманып карый. Мәрхәмәтле, нечкә күңелле, кулыма төшерә алсам, мине дә рәнҗетмәс, баш иеп кенә торыр дип уйлый. Их, үз акылларым булса! — диде карчык, кинәт йөрәк түреннән чыккан кисәтүле тавыш белән. — Үз акылыңны теләгәнчә итеп балаңа да бирә булмый шул. Авызын ачып йоклаган кешенең эченә елан керә, бер йотым су эчкән кебек кенә иттерә, диләр. Бу да бик юха, ай-һай юха!

Һәрнәрсәне күңел түреннән кичерә торган гадәтен белгәнгә, Зәйтүнә әнисенең бу сүзләрен юкка хафалану дип санарга тырышты. Аның уенча, көнләшү — ямьсез гадәт, яраткан кешеңә ышанырга кирәк, ышанмау кешене кимсетә иде. Ул, бу сөйләшүгә чик куярга, тегеләргә дә игътибар итмәскә тырышып, Тимербулатны кулына алды да, яулык белән капланып, изүен чиште. Сабые йомшак иреннәре белән күкрәккә орынуга, үзеннән балага сулкылдап яшәү көче агылганын тоемлау гына калды, аргы яктан чытлыкланып көлешкән тавыш ишетелмәс булды. Әкрен генә тирбәлгән нарат ябалдашлары арасында, яр буендагы чәчәкләр өстеннән очкан күбәләк, су читенә сикереп чыккан бака малае янында — шушы гүзәллек, сафлык эчендә алар гүяки сабые белән икәүдән-икәү генә калдылар.

Кире әйләнеп килгәндә, Лариса белән Әнвәр икесе дә бик тыенкы иделәр. Елмаюсыз, сүзсез генә табын янына утырдылар, гомумән, үзләрен бик тыйнак, дусларча ачык һәм әдәпле тоттылар, хәтта Гөлзәйнәпнең сынаулы карашы да алардан гаеп табарлык түгел иде.

Бераздан күмәкләшеп көймәдә йөзеп килергә булдылар. Ачык түшле чуар күлмәген киеп куйган Лариса алга утырды. Артка баланы күтәргән Гөлзәйнәп белән Зәйтүнә урнашты. Әнвәр аларга йөз белән утырып ишкәкләргә тотынды. Көймәнең бер башында тигез гаиләнең бергә урнашуы Гөлзәйнәп карчыкның күңелен шундук тыныч landырып та җибәрде, ул тирә-ягына карарлык хәлгә килде. Урман уртасында уелып яткан күл чыннан да сокланып туймаслык матур иде шул.

Менә алар каршы як ярга җиттеләр, инде көймә борыны ярга терәлә дигәндә генә, алда ерым барлыгы беленде. Аның читләрендә агачлар ботакларын суга төшергәннәр, аларның шәүләләре ерымда үзләре кебек үк ачык булып чагыла иде. Яфраклар арасыннан тәңкәләнеп төшкән кояш нуры су

өстендә тибрәлеп уйнап тора һәм аны төпсез, серле итеп, төбендә су кызларын һәм су патшаларын яшергәндәй күрсәтә иде.

Барысы да тынып калдылар. Әнвәр ишкәкләрне салмак күтәреп, тавышсыз төшерергә тырышты. Көймә таллар арасыннан, суда уйнаган нур шәүләләре өстеннән тын гына шуды.

Менә ерым тәбәнәк агач күпер янына китереп чыгарды. Зәйтүнә белән Әнвәр, ике яктан мүкләнеп беткән, лайлалы агач субайларга тотынып, көймәне аргы якка этәрделәр. Күпер артында тагын урман белән әйләндереп алынган зур күл ачылды. Аның уртасында, балык сыртлары кебек бүлтәеп, ике-өч утрау күтәрелгән, анда куаклар, алсу һәм сары саз чәчәкләре үскән иде. Утрауларга якын килеп булмый, ярлары ләм икән.

— Бу атауларны без беренче булып ачтык! — диде Әнвәр. — Аларның исеме дә юк бит әле. Әйдәгез, без исем кушабыз!

Бу уен күңелләрне тагын да күтәреп җибәрде. Атауларга «Изге Зәйтүнә», «Изге Лариса» һәм, әбинең каршы килүенә карамастан, «Изге Гөлзәйнәп» дип исем куштылар.

Ниһаять, ярга чыгып, җәймәне җәюгә, Гөлзәйнәп «ах» итеп, кытыршы һәм җылы нарат кәүсәсенә аркасын терәп утырды. Тимербулат изрәп йокыга талды.

Калганнар өчесе бергә йөреп килергә булдылар. Лариса озын баулы сумкасын үзе белән алды. Яшь усаклар арасыннан үтеп, карчыкның күзеннән ычкынгач, ул туктады да:

— Минем монда бер сюрприз бар бит әле, — диде.

— Кирәкми иде, — дип каршы төште Зәйтүнә.

— Ништяк! Син бала имезгәч тә, Әнвәр белән без бала имезмибез бит әле. Мин гомумән отпускадагы кеше.

Әнвәр каршы килмәде. Зәйтүнәдән аермалы буларак, аларның менә шундый уртаклыгы да бар иде бит әле! Стакан да, кабар нәрсә дә юк иде, алар икесе бер шешәдән шәраб эчтеләр. Кара шешәнең тышына сөзәргә дип башын игән симез һәм көчле үгез сурәте ясалган иде. Лариса шешәне күтәргәндә, үгез, башын иеп, тояклары белән күккә кизәнде.

Шешәне бушатып, зелпе куагы астына яшергәч, Әнвәр:

— Әйдәгез, мин сезгә мәхәббәт агачы күрсәтәм, — диде.

Җавап та көтмичә, очынып каршыдагы калкулыкка менеп китте.

Мәхәббәт агачы дигәне калкулык өстендәге ачыклыкта икән. Ике яшь агач — каен белән усак — бер тамырдан чыккандай, бер-беренә сарылып үскәннәр. Хәер, үсүдән бигрәк уралышканнар, әйтерсең лә кемдер аларны бау урынына чәбәләгән. Бу чәбәләнү шундый тыгыз ки, кайсының кәүсә-ботагы кайда икәнен белерлек тә түгел. Аларның тамырларыннан күтәрелгән дым да адашып, берсеннән икенчесенә күчәдер сыман тоела. Урыны-урыны белән ботаклар кулларны-аякларны хәтерләтә, дикъкать белән караганда, бу ике тереклек иясенә җан иңгәндер дә, аларда мәхәббәт хисе кабынгандыр һәм алар, бер-берсенә бирелгән мизгелдә оеп калгандыр кебек тоела. Бу хис шулкадәр көчле ки, алар хәтта барча үсемлекләрнең катгый кагыйдәсен — кояшка таба үрелеп үсәргә кирәклеген онытканнар, башларын түбән игәннәр.

Әнвәр агачларны кат-кат әйләнеп чыкты, аның күзләре гадәттән тыш ялтырый, йөзе тимгелләнеп чыккан, хәрәкәтләре артык иркен һәм бу рәвешендә ул ямьсезләнеп киткән иде.

— Бу яктан карагыз әле! Нәрсәне хәтерләтә, ә? — дип сорады ул.— Сезнең кебек медикларга гына күрсәтеп була моның ишене!

Лариса агачларны әкрен генә әйләнеп чыкты да, хисләнеп, әкрен генә сузып:

— Ништя-ак! — диде. — Инде агач белән агач болай кыланышкач, тәнендә кайнар кан аккан адәм баласы ничек түзәргә тиеш!

Әнвәр белән Зәйтүнә Аккош күленә еш киләләр, ләкин бу калкулыкка менгәннәре, бу агачны күргәннәре булмады. Кайчан күргән Әнвәр бу агачны, кем белән эзләп тапкан һәм ни өчен нәкъ менә бүген күрсәтергә булган?

Оятсыз ләззәттән бөгелеп төшкән каенның кәүсәсе гадәттәгечә ак түгел, күгелҗем иде. Аның каен икәнлеген дә яфракларыннан гына белеп була. Аклыгын югалткан иде каен.

***

Лабораториядә һәркемнең урыны киштәләр белән бүленеп куелган. Алтынчәчнең өстәле ишектән кергәч тә сулда, түр почмакта. Ак пластик белән капланган озын өстәл, ялтырап торган пыяла пробиркалар, төрле приборлар, киң тәрәзә төбендә чәчәк атып утырган яраннар һәм миләүшәләр, больницаларга хас чисталык һәм фенол исе, бигрәк тә урынның аулаклыгы — барысы да күңелгә күптән якын. Монда килеп, өс киемнәреңне салгач, ак халат белән башлыгыңны киеп куясың да шәхси тормыш ваемнарыннан арынып торасың, гади күзгә күренми торган, үзгәрүчән һәм катлаулы дөньяга — табигатьнең иң вак кисәкчекләре дөньясына үтеп кергәндәй буласың. Бу дөнья үзенең төзеклеге, законнарының тайпылышсыз һәм төгәл үтәлүе белән сокландыра. Атомнар, молекулалар үз

законнарына, табигатьләренә һәрвакыт тугры булып калалар, беркайчан да алдамыйлар, алар, ышанычлы һәм гадел дусларың кебек, икейөзләнүне белмиләр. Табигать үзенең чын асылында кагыйдәләренә тугры һәм ихлас, ә алдау-ялганны, икейөзлелекне кешеләр уйлап чыгарган. Начар кешеләр... Линар кебекләр...

Молекулалар һәм атом-электроннар дөньясында рәхәт Алтынчәчкә. Ул карап торышка күренмәс җисемнең пробиркадагы катлаулы хәрәкәтен, кисәкчекләрнең бер-берсенә тартылышын һәм бер-берсеннән читкә этәрелешен күңеле белән тоя кебек. Аның кечкенә, әмма нык, сөякчел куллары бу хәрәкәтне үзенә буйсындыра белә.

Химиклар арасында «куллары яхшы» дигән сүз бар. Хәрәкәтләрне төгәл ясый, реакцияләрне пөхтә үти дигән сүз генә түгел бу. Химикларның лабораториядәге эше ул — музыкантның пианинода уйнавы кебек. Берәү, бәлки, клавишларга тиешле тәртиптә басадыр, ул уйнаган нәрсә көйгә дә охшыйдыр, тик уйнаганының моңы юк, күңелләрне тетрәтерлек көче юк. Көйне моңлы итү, кеше күңелләренә җиткерү өчен үзенә аерым талант, йөрәк хисе кирәк. Химиядә дә шулай. Кайберәүләр матдәләрне кирәкле микъдарда үлчәп ала, тамчыларны нәкъ тиешенчә тамыза, әмма матдәләрнең вак кисәкчекләре ул кушканны үтәргә теләми. Реакция бармый. Син аны теләсә нишләт — бармый.

Андый чакларда гадәттә Алтынчәчне ярдәмгә чакыралар. Лаборатория җитәкчесе Нәҗия Нәкыйповна аның алтын куллы икәнлегенә ышанган. Әнә ул ишекне ачты да:

— Алтынчәч! — диде. — Бүген телевидениедән киләләр. Шаккатырырлык прибор әзерләп куй әле.

Алтынчәч борылып караганда, ул инде ишекне ябып маташа иде, күпереп торган кызгылт чәчләре генә күренеп калды. Катгый сөйләшә җитәкче: сүзен әйтте, җавапны тыңлап тормады. Моннан берничә ай элек ул нәкъ менә шушылай ишектән башын тыгып:

— Алтынчәч! Инглизләр янына барып кил әле, эшләре бармый, — дип кычкырган иде.

Сәгать биш тулып килә иде инде. Алтынчәч халатын салып, икенче каттан өченчегә, чит илдән килгән белгечләр өчен махсус җиһазланган бүлмәгә менеп китте. Өстәл янына җыелган берничә ир кеше аңа гаҗәпләнеп карадылар: кечкенә буйлы, калын күзлекле бу хатын-кыз аларга ошап бетмәде булса кирәк. Алтынчәч, русча сәлам биреп, йөзләренә карамый гына алга узды.

— Никароши прибор! — диде шунда нечкә бармагы белән өстәлдәге фотоэлектрокалориметрга күрсәтеп, озын буйлы, арык гәүдәле егет.

— Нишләп никароши булсын! — Алтынчәч аның ябык ак йөзенә шелтә белән карады. Егетнең изүе чишелгән, кыска халаты таушалган, мамык кебек йомшак, юка чәче чуалган — гомумән, ул тышкы кыяфәтенә әллә ни игътибар бирмәгән кебек күренә иде. Ә зәңгәр күзләре эчкерсез карый.

Тәрҗемәче китеп өлгергән икән инде. Алтынчәч прибор өстенә иелде. Чит илләрдә, шул исәптән Англиядә эшләнә торган шундый ук приборлардан төзелеше белән бераз аерылса да, бу — алардан бер дә ким түгел иде. Ә-ә, хикмәт менә нәрсәдә икән! Бу егет ясалма катнашмада сульфат микъдарын ачыклый, заводтан чыккан суларның составын тикшерә, күрәсең. Андый очракта приборга өстәмә яктылык фильтры куярга кирәк, ә егет аны оныткан.

Алтынчәч прибор астындагы кюветны — озынча савытны алырга үрелде. Аны алгач, фильтрны кую бик ансат, ләкин иелергә кирәк. Ә ул бүген, үч иткәндәй, ачык изүле күлмәк кигән иде. Иелгәч, ул тагын да ныграк ачылачак, ә арттан бу кешеләр карап тора... Ул борылды да, кулы белән изәп:

— Китеп торыгыз! Китегез, кит! — диде. Өч ир-ат аптырашып арткарак чигенделәр. Мизгел эчендә фильтрны урнаштырып, башын күтәргән Алтынчәч, артында ук торган арык егетне күреп, кызарынып чыкты. Кай арада килеп баскан диген!

Егетнең исә дикъкате аның түшенә түгел, приборга юнәлгән иде.

— Менә болай...

Алтынчәч эчкә куелган яктылык фильтрына күрсәтте. Егет тә сузылды, ләкин кулы зур, сыймый иде. Алтынчәчкә кызык булып китте.

— Син алай булдыра алмыйсың,— диде ул.— Сиңа өске капкачын ачып куярга кирәк иде.

Егет аңлады, рәхмәтен белдереп башын каккалады. Кюветны кире урынына куеп, титрованиене башладылар. Алтынчәч өстәлдән кәгазь-каләм алды да:

— «BaCl-0, 001»? — дип язды.

—Да, да! — дип ияген какты егет.

Акыл белән, йөрәк хисләре белән аңлашу өчен телләрнең төрлелеге комачаулый алмый. Кеше үзенең акыл казанышлары белән уртаклашканда формулалар, символлар белән аңлаша. Хистойгыларын авазлар, ноталар, төсләр белән, елмаю, хәрәкәтләр белән аңлата. Алтынчәч титрованиенең ничек барганын бераз күзәтеп торды да ишеккә юнәлде. Прибор яхшы эшли иде. Әмма ябык егет аның артыннан килеп, сак кына иңенә орынды. Алтынчәч борылып карагач:

— Оливер! — дип, үзенең күкрәгенә төртте.

— Алтынчәч.

— Алтынчәч,— дип кабатлады егет үзе өчен ят исемне.— Алтынчәч! — диде зур ихтирам һәм соклану белән.

Дөресен генә әйткәндә, моңарчы Алтынчәчнең исемен болай олылап һәм сокланып әйткән кеше юк иде әле. Кем белән генә танышсаң да, иң элек башыңа карыйлар. Ә Алтынчәчнең чәче — көл төсле, юка, кыска. Карый кеше, көлемсери. «Туганда минем чәчем сап-сары булган, әти белән әни сөекле кызларына беркемдә юк исем кушарга тырышканнар», — дип, кеше саен аңлатып йөреп булмый бит инде!

Шуннан атнага ике тапкыр булмаса да, бер тапкыр Нажия Нәкыйповна ишекне ачып:

— Алтынчәч! Сине инглизләр чакыра! — дип ярып сала торган булды. Чакыручы гадәттә Оливер була. Кайдадыр бик ераста, диңгезләр, таулар артында, күз күрмәгән илдә туып үскән бу егет үз һөнәрен Алтынчәч кебек үк ярата һәм, иң мөһиме, бу эштә осталыкны, талантны бәяли белә иде.

Аңарчы Алтынчәч завод ишегалдында эчке бер сагаю белән йөри торган иде. Чөнки лабораториядән цехларга барганда, киң асфальт юлны ике яклап ышыклап торган агачлык артыннан, берәр борылышта баш механик Бадамшинның озын гәүдәсе килеп чыгуы ихтимал. Ул синең яныңнан узып киткәнче, куак булып торасы, яки сукмак читендәге сары чәчкәле пәйгамбәр тырнагына әвереләсе, яисә күбәләктәй очып китәсе — кыскасы, күзгә күренмәс буласы килә, ләкин син күренәсең, кире борылып йөгерергә аяклар ирек бирми, алар, ниндидер мотор ярдәмендә хәрәкәткә китерелгәндәй, алга таба атлый бирәләр. Алтынчәч бик текәлеп асфальттагы ярыкларга карый, ә үзе баш түбәсендә Нәркиснең көйдергеч карашын тоя. Мондый очрашулардан калган хис атна буе йөрәкне сызландыра, бу сызлану икенче очрашуга кадәр җитә иде.

Бигрәк тә Линар белән танышканнан соң йөзе кара итеп тоя башлады ул үзен. Теге чакта, тулай тораКта, егете белән үбешеп йөргән өчен Тәслимәне ничек гаепли иде бит ул! Ә хәзер үзе дә шундый булып чыкмадымыни? Аның йөз каралыгы тиздән бөтен заводка фаш булачак, очрашканда, баш механик аның баш түбәсенә генә түгел, гәүдәсенә текәләчәк. Чөнки киләсе кышка ана булачак Алтынчәч, һәм, мөгаен, бу сүз алдына «ялгыз» дигәне дә өстәләчәк. «Ялгыз ана Алтынчәч Вафина» булачак ул киләсе кышка.

Бу хәле аны ике төрле хис арасында йөртә. Бер яктан, ул горурлана: менә бит, мин башкалардан ким түгел, әни булачакмын! Икенче яктан, кимсенә: ул бүтәннәрдән ким, чөнки кешечә гаилә корып, баласын әтиле итә белмәде. Шулай да бу кимсенүне киметә торган бер өмет яши күңелдә. Ә бәлки, сабый әтисез калмас әле. Мөһимә һаман юатып тора, Линар ялгыз, ди, тик менә урыныннан кубып, бөтенләйгә күчеп килергә җае гына чыкмый, ди. Андый эш дәррәү генә эшләнми бит ул, дип куя. Менә баланы күргәч, җаны түзмәс, килер, Аллаһы боерса, дип юата. Чыннан да, Линарның таш бәгырьле булуы мөмкин түгел. Кызы бар бит аның, ә кыз баласы булган ирләр хатын-кызның хәлен аңларга тиеш, чөнки башкаларның язмышын үз кызларына үлчәп карамый булдыра алмаслар...

Алтынчәч, уйларын шунда бүлеп, телевидение кешеләре килүгә әзерләнә башлады. Катлаулы реакция үткәрә торган прибор әзерләргә кирәк. Әйтик, менә дефлегматор. Катнашмадагы матдәләрне ифрат яхшы аера. Тыштан караганда колбага тоташкан пыяла көпшә кебек кенә үзе...

Лабораториядәге кызлар Алтынчәчнең хәлен күптән сизәләр инде, тик тел белән сорарга гына кыймыйлар.

Ә менә Оливер аның кыяфәтенә бер дә игътибар белән карамый иде, ул бары тик «алтын куллар»ның осталыгын, сәнгатен, җырын отып алырга гына тырыша иде. Мөнәсәбәтләрнең гади һәм эшлекле булуы, бер-берсенең күңелләренә тирән керергә омтылмау кешеләрнең чын бәһасен белергә мөмкинлек бирә икән. Инглиз инженерының ихтирамы Алтынчәчнең дәрәҗәсен үстереп җибәрде. Бу чорда Алтынчәч заводта иркенәеп йөри башлады, хәтта Бадамшиннан да элеккечә коты очып тормый иде инде.

Моннан бер ай элек инглизләр, эшләрен тәмамлап, үз илләренә кайтып киттеләр. Әллә шул да бераз сәбәп булды инде, әллә хәле үзгәрә баргангамы, Алтынчәчнең пошынуы соңгы вакытта аеруча көчәйде...

Ишек артында шау-шу, дөпелдәгән, кычкырып сөйләшкән тавышлар ишетелде, сакал-мыеклы яшь бер кеше ияртеп, Нажия Нәкыйповна килеп керде.

— Менә безнең тәжрибәле инженерыбыз Алтынчәч Вафина. Әзерме, Алтынчәч?

— Биш минутлык сюжет ясыйбыз, телевидение өчен бу бик күп, — диде сакаллы адәм5 калын тавыш белән. Әллә каян сизелеп тора: күп төрле халык арасында айкалып, ул инде тарсынуның, оялуның ни икәнен дә оныткан, аягы кая басса, шунда үзен хуҗа итеп хис кылырга күнеккән иде.

— Шушымы? — дип сорады ул5 дефлегматорга төртеп.— Эшләтеп күрсәтегез.

— Эшләп тора ул, — диде Алтынчәч, кырку гына. Бу кеше прибордан да бигрәк Алтынчәчнең кыяфәтеннән риза түгел иде, ахрысы, карашыннан шул сизелде.

— Бумы эшләп тора? Без тамашачыга нәрсә күрсәтербез соң? Бер пыяла колбамы?

— Әгәр беләсегез килсә, бу колба үзе бер завод кадәр эш башкара.

— Карагыз әле, безнең вакыт санаулы. Хәзер камераларны кертәбез дә...

Ишектән озын тимер торбаларга беркетелгән софитларны сөйрәп кертә башлаганнар иде инде. Алар артыннан кара елан булып резин көпшәләр идәнгә сузылып ятты.

— Кая монда розетка? — дип як-ягына каранды таза гәүдәле ир кеше.

Лабораториядә моңарчы беркайчан да булмаган ыгы-зыгы купты.

— Син аларга су өчен дистиллятор куй! — диде Нәҗия Нәкыйповна.

— Дистиллятор? Кеше алдында оят бит, Нәҗия Нәкыйповна! Химиклар күрер!

Начальник кул гына селтәде:

— Акыллы химик күрсә дә көләр дә бетерер, ә тилегә барыбер түгелмени!

Чыннан да шул тилеләр өчен генә булса инде. Дистиллятор — зур колба, астына спиртовка куеп, шуның эчендә су кайнатасың. Тизрәк кайнасын өчен аңа калий перманганаты, ягъни марганцовка да өстиләр. Карап торышка гел харап була инде: пыяла савыт эчендә үрле-кырлы сикереп, ачык шәмәхә төстәге сыекча кайный!

Чыннан да режиссерның йөзе ачылып китте:

— Менә ичмасам, бу чыннан да химиянең кодрәтен күз алдына китерә!

— Химия түгел бу, физика, — диде Алтынчәч.

Тик аның сүзенә колак салучы булмады, чөнки өстәл тирәсендә гыйфрит күзе кебек объективларын акайтып, телевидение камерасы шуышып йөри иде. Режиссер операторга күрсәтмәләр бирә башлады.

Алар чыгып киткәч, Алтынчәч, тәрәзә төбендәге гөл чүлмәкләрен кырыйгарак шудырып, ишегалдына карады. Камераны асфальтка җайлап куйганнар, завод күренешен төшереп маташалар. Аннан ни күренә соң? Ә-ә, градирнялар! Чыннан да, харап бит кыяфәтләре: биниһая зур чүлмәк рәвешендә үзләре, өсләреннән төрле тарафка пар бөркелә...

Тыштан караганда алар заводның иң шаккатыргыч корылмалары булып тоела шул. Ә чынында исә бары тик парны суга әйләндерә торган җайланмалар гына алар.

Заводның төп эшен башкара торган колонналарның исә кыяфәте тыштан караганда бик гади. Алар цехлар эчендә тавыш-тынсыз гына үзләренең катлаулы һәм бик мөһим вазифаларын үтиләр.

Алтынчәч чая режиссерның мәгънәсезлегенә көлемсерәде. Ләкин шундук җитдиләнеп: «Мин үзем дә шундый түгелмени? — дип уйлап куйды. — Кешенең чын асылын күрмим, шул градирня кебек кәпрәеп пар бөркегәннәренә кызыгам түгелме? Күзне кызыктыра, алдый белә шул алар!»

***

Институтта укыганда Зәйтүнә бер завод поликлиникасында эшләүче врачлар белән берлектә фәнни тикшеренүләр алып баруда катнашкан иде. Алар һавага бүленеп чыга торган газ катнашмасының хатын-кыз организмына тәэсирен өйрәнү белән шөгыльләнделәр.

Бу эш белән профессор Ильясова җитәкчелек итте. Зәйтүнә заводта еш була, шунлыктан анда үз кеше булып беткән иде инде.

Ләкин менә Тимербулат белән өйдә утырган арада шактый читләште. Тикшеренүләрнең нәтиҗәсе югары оешмаларга җиткерелгәнен, бер цехта тулысынча реконструкция ясалганын ишетсә дә, барып күрә алганы юк иде әле.

Цехта һаваның чистаруына ирешә алдылармы икән? Зәйтүнәнең моны үзе барып беләсе килә иде. Беркөнне, клиникада эш тәмамланганнан соң, ул заводка сугылырга булды.

Элекке пропускысының срогы чыккан икән. Ул проходнойдан заводның поликлиникасына шалтыратты. Әмма анда кабул итү сәгатьләре беткән, врачлар киткән иде. Зәйтүнә цехның телефонын сорады. Анда начальник алышынган икән, нечкәрәк кенә ят тавыш җавап бирде. Зәйтүнәнең кемлеген аңлап җиткермәсә дә, пропуск яздырырга вәгъдә итте.

Завод ишегалдында да көз үзен сиздерә. Сукмак кырыйларындагы өрәңгеләрнең яфраклары яшел әле, ләкин, ныклабрак карасаң, алар да төс сала башлаган, коңгыртланганнар, катыланганнар, салкынча җил килеп бәрелгәндә, йомшак кына лепердәшмиләр, калайдан ясалгандай каты бәрелешеп кыштырдыйлар. Әнә цехның бетон тартманы хәтерләткән яңа бинасы каршындагы түтәлләрдә дә җәйге гөлләр корыган инде, фәкать кашкарыйлар, кызгылт-сары бәрхет гөлләр генә балкып утыра.

Бинага якынрак килгән саен, ят ис — тәмсез газ исе күңелгә ныграк тия башлады. Зәйтүнә чәчәкләргә үрелде. Кашкарыйлар иссез, ә менә бәрхет гөлнең исе, якынрак килсәң, хәтта газның күңел болгаткыч сасысын дә күмеп китә икән. Ләкин бу — түтәлгә иелгән мизгелдә генә шулай, тураеп басуга, тәмсез ис янә борынны ярды.

Әйе, цехны бөтенләй өр-яңадан эшләгәннәр икән. Эче иркен, биек. Уң якта тезелеп торган чаннар өстеннән шуышып краннар йөри, алар үзләренә беркетелгән формаларны чаннарга чумдырып кына алалар — төп эшне шул рәвешле автоматлар башкара. Сулдагы өстәл янында ике хатын сөйләшеп утыра иде, цехта бүтән кеше күренмәде. Зәйтүнә, эчкә керүгә, саргылт плащының сәдәфләрен ычкындырды: биредә җылы, теге хатыннар да кыска җиңле күлмәкләрдән, ялан балтырлы иделәр.

Килеп керүгә тәмсез ис күңел кайтаргыч булып тоелса да, бераздан күнегәсең икән, шуңа күрә хатыннарның да аңа исе китми, калын оеклар, озын җиңле күлмәкләр киярге кирәклеген дә онытып җибәргәннәр. Менә аларның берсе, кранның түрдәге чанга таба шуышканын күреп, ашыкмыйча гына шунда таба китте, чан эчендәге сыеклык өстенә утырган элпәне таяк белән сыдырып алып, кырыйдагы савытка ташлады. Тәмсез ис тагын да көчәйде, кран түбәнәеп, зур тукмактай формаларны чан эченә чумдырды...

Формаларга резина ябышып чыга, кран артка чигенгән арада, резина кибеп, шар хасил була...

Зәйтүнә боларны күзәтеп торганда, артында кемдер:

— Ничек соң, врач иптәш, ошыймы?— дип сорады.

Зәйтүнә сискәнеп борылды һәм кара диагональдән тегелгән костюмлы кеше белән кара-каршы басып калды.

— Исәнмесез! Сез кем буласыз?

— Цех начальнигы Хәйруллин булам.

Начальник өчен Хәйруллин яшьрәк күренә иде, бигрәк тә элекке начальник Галиулла абзый белән чагыштырганда. Җитмәсә, балалар шикелле борынын тартып, җиңелчә генә иңбашларын сикертеп куйды. Әмма җилкәләре киң, таза, җиң эчендә нык мускуллар уйнаганы сизелеп тора.

— Мин клиникадан, Зәйтүнә Мәҗитовна, — дип кулын сузды аңа Зәйтүнә. Хәйруллин аның бармакларын эләктереп алып кисәк кенә кысты да:

— Мөдәррис Сәләхович, — диде. — Әйдәгез, өскә менеп сөйләшик.

Үзе, җавап та көтмичә, борылды да, эре һәм нык басып, ишеккә юнәлде. Ул, җилкәләрен алгарак авыштырып, тәжрибәле өлкән кеше кебек атларга тырыша, ә йомшак чәч белән капланган йомры башы малай-шалайны хәтерләтә иде.

Лифтка утырып, өченче катка сөйләшмичә генә менделәр. Цех начальнигының кечкенә генә бүлмәсендә тагын ике хатын-кыз утыра икән. Хәйруллин түр тәрәзә буендагы өстәл артына кереп утырды да, Зәйтүнәгә каршысындагы урындыкны күрсәтте.

Тәрәзәдән завод корпуслары, җил уңаена авышкан сыек төтен тасмалары күренеп тора. «Күпме һаваны агулыйлар!» Зәйтүнә аркасы белән хатын-кызларның карашын тоеп, тартынып утырды.

— Мин бу цех һавасындагы зарарлы матдәләрнең хатын-кызлар организмына йогынтысын тикшерүдә катнашкан идем,— дип аңлата башлады ул начальникка.— Шактый көч куелды бу эшкә. Менә реконструкция дә ясалып беткән икән... Җитәкчеләр безне, реконструкциядән соң хәл тамырдан үзгәрәчәк, дип ышандырганнар иде.

— Ну, вәгъдә биргән хәтлесен эшләдек без, — дип, аның сүзен төксе генә бүлдерде Хәйруллин. — Цех бинасы иркенәйтелде, вентиляторлар эшли, производство мөмкин булганча механикалаштырылды.

— Ләкин һава! Һавада үзгәреш сизелми бит. Ничек алай булды соң?

Зәйтүнә бу сүзләрне һич тә Хәйруллинга үпкә рәвешендә әйтергә теләмәде, врачларның, инженерларның шушылай берләшеп тырышуы нәтиҗәсез калуга гажәпләнеп, фәкать шушы аяныч хәлнең серенә төшенергә генә тели иде. Ләкин начальникның кырыс карашы аны каушатып җибәрде, шунлыктан соравы дорфарак чыкты, ахрысы. Өстәвенә ул арттан ике хатын-кызның көлемсерәп күзәтеп утырганын һаман тоеп тора иде.

— Һава! Һава! Без кулдан килгәнен эшләдек. Әгәр дә хатын-кызга бездә эшләү зыянлы икән, китсеннәр! Башка, зыянсыз эшкә урнаштырабыз, пожалуйста! Менә шулай дип карагыз әле сез аларга, авыз ачарга да ирек бирмиләр. Утызар ел шушында эшлиләр, чөнки эш хакы яхшы, пенсиягә дә иртә чыгалар. Сез врачлар, үзегез үк, беркемнең дә монда эшләгәннән инвалид булганы юк, дисез бит.

— Гел карап, дәвалап торганга гына шулай инде ул.

— Анысы сезнең эш. Һәммәгез дә безнең кебек һәрбер вәгъдәсен үтәп торсын иде әле! — Начальник бу сүзләрне аеруча үчекләп, иреннәрен яңа туган ай рәвешенә китереп әйтә башлаган иде, өстәлдәге кара телефон зыңгылдады. — Хәйруллин тыңлый, — диде ул, трубканы алып.

Бу юлы аның фамилиясе бик таныш булып ишетелде. Кайда күрде соң әле бу кешене Зәйтүнә? Йөзе дә бик таныш шикелле бит!

Трубканы куйгач, Хәйруллин Зәйтүнәгә каш астыннан карап, күзләрен бозлы су кебек елтыратып:

— Шул ук сезнең клиникадагылар монда килеп күрсәтмә биреп йөрергә иренмиләр, ә төп эш урыннарында үз бурычларын һәрвакытта да намус белән үти белмиләр. Нәрсә ди әле Гиппократ? Ничек әле аның беренче васыяте? — диде.

Зәйтүнә Хәйруллинның тел төбе кая барганын аңлаудан гажиз иде. Җитмәсә, арттан ике тамашачы карап һәм, мөгаен, авыз ерып утыра!

— Зыян китермә, дигән Гиппократ, шулай бит? — диде начальник, надан укучыга сабагын искәрткән укытучы тавышы белән.— Сез адәм баласына зыян китермәскә ант иткән кешеләр. Ә соң клиникагызда гел файдалы эш кенә башкарасызмы? Бер дә зыян китермисезме?

Зәйтүнә күзләрен зур ачып, шаккатып карап утырды. Бу Хәйруллин... теге былтыр клиникада яткан Хәйруллинаның ире бит! Шул үзе! Зәйтүнә аларның икесен бергә поездда, Ларисаларны озатканда күргән иде.

Ләкин нигә рәнҗи ул Зәйтүнәгә, ни өчен гаепли? Теге газаплы төндә аның кизү торганын белә микәнни?

— Берәүнең эшеннән гаеп табу икенченең гаебен акламый әле, — диде Зәйтүнә. — Кимчелегебезне күргәнсез икән, турысын гына әйтегез. Ләкин цехтагы һаваның бу хәлдә калуына без ризалашып торырга тиеш түгел.

Ул, каушаганын сиздермәскә тырышып, кул куярга дип пропускысын Хәйруллинга таба шудырды.

Икенче көнне клиникага эшкә килү белән, ул алтынчы палата врачы Фидая Галимовнадан Динә хакында сорады. Фидая Галимовна сөйкемле озынча чырайлы, дулкынланып торган кара чәчле, утызлар тирәсендәге хатын:

— Ах, ул Хәйруллина белән әвәрә булып беттек бит без,— диде.— Син декретта чакта тагын керде бит ул безгә. Носилка белән китерделәр. Тырнаклары күгәреп чыккан иде. Аналыктан читтә йөклелек буенча бик авыр операция булды. Аның эшләре бөтенләй кире киткән, дип ишеттем әле мин. Баласы да үлгән икән.

— Баласы үлгәнмени?!

— Әйе, бер килсә килә бит ул. Операциядән соңгы чорны бик авыр кичерде. Алай да йөрәге таза икән. Җәмилә Закировна үзе карады.

Профессор Ильясова йөрәк-кан тамырлары системасын кайсыбер терапевтлардан да яхшырак белә иде.

— Ә шулай да зарланмады, — диде Фидая Галимовна Динә хакында. — Бер дә чыраен сытмады, көлә дә шаяра иде үзе.

Зәйтүнә, аның теге төндә сызлану аша елмайганын исенә төшереп, тетрәнеп куйды.

***

Оста кул белән ясалган һәм ачык төсләргә буялган агач уенчык төсле бу кыз студент чакта ук профессор Ильясовада яхшы тәэсир калдырган иде. Сайлап алган темасы бик мөһим, кыска гына вакыт эчендә үзе дә шактый материал туплаган, башкаларның тәҗрибәсе белән дә танышырга өлгергән. Кыскасы, Җәмилә Закировна Лариса Сөнгатовнаның эшенә өметле дип карый иде.

Зур заводның поликлиникасында аена бер тапкыр профессор Ильясова авыруларны кабул итә. Шундый бер көнне график буенча аның белән бергә Нигъмәтуллина барырга тиеш булгач, Җәмилә Закировна аны бу эштә дә сынап карарга мөмкинлек туганын уйлап куйды.

Зур завод ерак, каланың бөтенләй икенче читендә, ә профессорның махсус машинасы юк. Алар башта трамвайда, аннары троллейбуста бардылар. Җәмилә Закировна утырган, Лариса аның янына баскан, икесе дә тәрәзәгә карап, яңгыр чылаткан урамнарны, көзге кыраулардан көйгән агачларны күзәтә, һәркайсы үз уйларына чумган иде.

Менә ун ел инде ай саен бу озын юлны уза Җәмилә Закировна. Шушы еллар эчендә кала бик нык үзгәрде. Казансу аша салынган дамбаны үтүгә, тәрәзәләренә кадәр җиргә сеңгән өйләр тезелеп утыра иде. Аларны сүтеп, урынын сөрделәр дә, үлән чәчеп, агач утырттылар, калку итеп чәчәк түтәлләре ясадылар. Эчтәрәк фонтан атып утыра, аннан да арырак яшьләр үзәгенең күксел бетон бинасы. Уңда исә тезелеп киткән тәрәзәләре белән унөч катлы нәшрият бинасы калыккан. Урам киң, күз күреме иркен, биек йортлар бер-берсеннән ерак утыртылган.

Әйе, дөнья бик нык үзгәрде, тик Җәмилә Закировна үзе генә үзгәрмәгән шикелле. Заводка ул һаман элеккечә теләп бара, якынлашкан саен кәефе үк яхшыра.

Элек-электән авырулар галим-табиб янына үзләре килә торган булганнар. Тәмам сабырлыгы төкәнгәч, башка өмете калмагач кына килгән адәм баласы профессор янына. Һәм еш кына аның бу килүе инде соң булган.

Ә менә профессор Ильясова үзе кешеләр янына бара. Сау-сәламәт дип саналган, станокларда дөбердәтеп эшләп торган хатын-кызлар белән очрашырга бара ул. Баштарак аның бу нияте кайберәүләргә сәер тоелган иде. Кафедра бер заводта профилактик эш алып бара иде бит инде. Хәлбуки профессор Ильясованың нәкъ менә бу заводка килеп йөрүе очраклы түгел иде. Анда хатын-кызлар күп эшли, алар химик матдәләр белән эш итәләр һәм өстәвенә директор Лукьянов Җәмилә Закировнаның ире Мөбарәк Таһировичның күптәнге танышы иде.

Инде өлкәнәеп килүенә карамастан яшьлек елгырлыгын саклаган, заводтагы хатын-кызларның ким дигәндә яртысын мәхәббәт утында яндырган Лукьянов та баштарак сәерсенеп куйган иде:

— Безнең заводның поликлиникасы бик яхшы бит, бөтен төр белгечләр бар, — диде ул.

— Алар авырган кешеләрне дәвалый, ә без авырмасыннар өчен тырышачакбыз.

— Ярый, сез бездә махсус кабинет ачасыз, ди, ә бездән моның өчен ни сорыйсыз?

Директорның тирән акыл чагылган күзләрендә хәйләкәр көлемсерәү кабынды.

— Сез договор белән безгә акча түләрсез.

— Күпме?

— Хәлегезгә карап.

Директор көлеп җибәрде:

— Хәйләкәр сез.

Завод шәһәрдәге иң бай предприятиеләрнең берсе иде.

— Ә без ул акчага клиника өчен яңа җиһазлар алачакбыз,— диде Җәмилә Закировна.

Ә ярты елдан, бер мәҗлестә очрашкач, Лукьянов Җәмилә Закировнага шаяртып бармак янады:

— Сез миңа авыруларны киметергә вәгъдә биргән идегез, ә үзегез дистәләгән эшчене больницага салгансыз. Алай иткәч, безнең планнарны үтәп булмый бит!

— Әгәр дә сез еллар буе ремонтламаган станокларыгызны берьюлы ремонтлый башласагыз, планнарыгыз нишләр иде икән? Әллә кешеләрнең бөтенләй ватылып беткәнен көтеп торыйкмы?

Чыннан да, баштарак алар шактый кешене эштән азат иттеләр, чөнки аларда башланып килгән авырулар табылды. Ә бер елдан соң больничныйга чыгучы хатын-кызларның саны чыннан да кимеде. Профессор Ильясовага моның өчен бил бөгеп рәхмәт укучы да, кочак-кочак чәчкә китерүче дә булмады. Ләкин нәкъ менә шушы казанышы — күпләрне авыр чирдән, куркыныч операцияләрдән саклап калуы Җәмилә Закировнага куаныч бирә дә инде. Ул һәр операцияне табибларның эшләп җиткермәвенең нәтиҗәсе дип саный иде. Киләчәктә авыр операцияләр сирәк ясалачак, чөнки кешеләр үз-үзләрен карый белергә өйрәнәчәкләр.

Яшь врачларны да эшнең нәкъ менә шушы юнәлешенә өйрәтергә кирәк.

Җәмилә Закировна күз кырые белән генә Ларисага карап алды. Бил озынлыгындагы кара күн пинжәк, эре шакмаклы, киң, озын итәк, бәйләгән берет кигән, муенына салган шарф очлары тезләренә төшеп тора. Троллейбустагыларның кайберләре аңа текәлгән. Аңлашыла: Лариса модный киемнәрне иң беренчеләрдән кия.

Поликлиниканың шәфкать туташы, яшь, оялчан Вәсилә аларны проходнойның ишек төбенә чыгып көтеп тора иде. Эчкә кереп, ян коридорга борылгач, яннарыннан күзлекле яшь хатын узып китте, аның күгәренке йөзе сагышлы иде.

— Кем бу? — дип сорады Җәмилә Закировна Вәсиләдән.

— Бумы? — Вәсилә турникет аша үтеп барган хатынга текәлеп карады.

— Ә-ә, Алтынчәч апа. Үзәк лабораториядән. «Алтын куллы лаборант» ярышларында гел комиссиядә утыра, кызлар аннан куркып, дер калтырап торалар.

—Ул сезгә учетка баскандыр бит инде?

Кемнеңдер күзгә күренмәс кулы Вәсиләнең йөзен алга мангандай итте.

— Ю-ук, — диде кыз, сузып. — Алтынчәч апаның безгә килгәне юк. Ну... ул ялгыз бит. Шуңа килми торгандыр, дибез. Үзебез барып әйтергә яхшы түгел.

Вәсилә, ялгыш сүз ычкындыргандай куркып, профессорның йөзенә текәлде.

— Менә нәрсә, Вәсилә, син Алтынчәч апаңны минем янга чакыр әле. Прием бетүгә керсә, яхшы булыр иде.

...Ул ишектән, алга таба авышыбрак, кыюсыз гына килеп керде. Бусага янында ук тукталып, калын күзлек пыялалары аша профессорның йөзенә керфек тә какмый текәлде. Әйтерсең лә карашы белән: «Йөземә кара, йөземә генә, гәүдәмә күзеңне төшермә!» — дип ялвара иде.

— Утырыгыз,— диде профессор, каршындагы урындыкка ишарәләп.

Алтынчәч өстәлнең икенче башында язып утырган Ларисага аркасы белән урнашырга тырышты. Профессор бер хакыйкатьне аңлады: бу хатынның күңелендә шеш булып сагыш утыра, кисеп җибәрмичә, ягъни авырттырмыйча гына ул шешне дәвалап булмый. Ә җаны сизгер, күңеле нечкә, сабырсыз, анестезия чаралары файда бирмәячәк. Һәм Җәмилә Закировна скальпель белән кисәк сызгандай итеп:

— Сез авырлы, — диде. — Бу хәлегездә сез врачның игътибарын җәлеп итәсез. Учетка бастыгызмы инде?

— Өлгерермен әле. Ашыгыч түгел...— Алтынчәч, борылып, җилкәсе аша Ларисага сагаюлы караш ташлады, аның йөзен күргәч, куырылып килгәндәй булды. Профессор аның хәлен аңлады.

— Лариса Сөнгатовна, онытып җибәргәнмен, минем директорны күрәсем бар иде. Секретарьдан белешеп килегез әле, монда микән? Булмаса, кайчан килә.

Лариса профессорга мәгънәле караш ташлады да бүлмәдән чыгып китте.

— Хәзер иң мөһиме — карыныгыздагы баланың нормаль үсеше, шулай бит? — диде Җәмилә Закировна Алтынчәчкә.— Аның өчен иң беренче чиратта сезнең тәнегезнең сәламәт, җаныгызның тыныч булуы кирәк. Күңелегез төшенке күренә, эшегездә бер-бер хәл булдымы әллә?

Алтынчәч юк дигәнне аңлатып башын чайкады.

— Ананың кәефе карындагы балага бик нык тәэсир итә,— дип дәвам итте Җәмилә Закировна. — Сезнең мондый хәлдә йөрүегез аңа файдага түгел. Әйтегез әле, нинди борчуыгыз бар? Бәлки, мин ярдәм итә алырмын?

Алтынчәч, башын иеп:

— Дөньяда бәхетсез мәхәббәт дигән нәрсә дә бар бит,— диде.— Әйтик, кыз егетне ярата, ә егет икенче берәүгә гашыйк...

— Була андый хәлләр. Ләкин андый мәхәббәт өченче берәүнең яралуына нигез була алмый бит әле, — диде Җәмилә Закировна, сак кына.

— Аны салкын акыл белән сөйләү җиңел. Ә янган йөрәк нигезен-ниен тикшереп торамыни? Егет башка берәү янына, ераккa китеп бара...

Алтынчәч бутала-бутала араларының мәңгегә өзелгәнен аңлатырга тырышты. Җәмилә Закировна аны бүлдермичә тыңлады. Ул инде скальпельнең өстән генә шуып үткәнен, хәсрәт шешен төбенәчә яра алмаганын аңлаган иде. Бусы — өстәрәк ятканы, сөйләп була торганы. Иң эчке серен, Алтынчәч, бәлки, берәүгә дә чишмәстер.

— Кызганычка каршы, андый хәлләр бер сездә генә түгел, булгалап тора шул. Ләкин бирешергә ярамый. Сез бик сөйкемле кеше, күңелегез саф икәнлеге йөзегездән күренеп тора. Халыкча әйткәндә, сөйкемле сөягегез бар. Гомерегез алда бит әле, бәхетегезне табарсыз... Тик бу авыр чорны гына сынмыйча-сыгылмыйча узарга кирәк. Шулай бит?

Профессорның шушы җылы сүзләре әкренләп Алтынчәчнең йөзенә нур иңдергәндәй итте. Күренеп тора: сәламәтлеге шәптән түгел иде үзенең. Ләкин куркытырга ярамый, Җәмилә Закировна сак, шул ук вакытта нык тавыш белән аңа тикшерелергә, кирәксә дәваланырга киңәш итте.

Лариса зирәк хатын, һәммәсен аңлаган иде, бүлмәгә Алтынчәч чыгып киткәч кенә керде.

— Директор иртәгә генә була, диделәр, — диде ул, мәгънәле итеп.

Алар киенеп чыгып барганда, проходнойда Алтынчәч тора, кулындагы кәгазь кисәгенә стенадагы игъланны күчерә иде. «Инглиз сөйләм телен тиз арада үзләштерү буенча курс... Чит ил белгечләре белән эшләүче барлык инженер-техник персоналга мәҗбүри... Институт бинасында... доцент Мансурова... » — дип укып алды Җәмилә Закировна узып барышлый. Лариса да бер мәлгә игълан янында туктап калды, юлдашын урамга чыккач куып җитте.

— Җәмилә Закировна, безнең кафедрада да шундый курслар оештырылмас микән?

— Планда андый нәрсә юк иде әле.

— Сез ничек уйлыйсыз, әгәр мин Ләйлә Мөбарәковнага барып, шушындый бер курска алуын үтенсәм, каршы килмәс микән? Ниндирәк ул, бик кырыс түгелме?

— Минем аның студенты булганым юк бит әле, — дип, бу сүзләрне шаяруга борды профессор.

— Артта калабыз бит, Җәмилә Закировна, бу заманда инглизчә сөйләшә белмәү наданлык билгесе. Әгәр мин үзем кызыгыз янына барып сөйләшсәм, сез каршы килмәссезме?

— Ник каршы килим? Үзегез килешәсез икән, бик яхшы.

Шулай диде Җәмилә Закировна. Күңеленнән исә шәкертенең бу теләген хуплады.

***

Уенны балалар гына яратамыни? Юк, уенны адәм баласы җитлеккәч тә, олыгайгач та ярата. Ләкин еллар узган саен без уйнарга ояла башлыйбыз, аннары аның рәтен бөтенләй онытабыз. Уен дигәне дә җитди эшкә охшап кала. Чөнки һәр кылганыбызны тырышып, көчәнеп башкарырга күнегәбез.

Хәлбуки күп кенә очракларда безгә уйнау бик тә килешер иде. Уйнап кына эшләнгән эш рәхәт башкарыла, җиңел бирелә.

Ләйләнең укыту ысулы, нигездә, уенга корылган иде. Дәрестә ул «леди Ләйлә», аның тирәсендәгеләр — шаһлар, министрлар, атаклы артистлар, сәяхәтчеләр. Гади кеше юк монда.

Курсларны леди Ләйлә үз кафедрасында үткәрергә ярата. Биредә аның ике дистә елга якын эш дәверендә булдырылган үз мохиты, үз рухы. Коридорга керү белән үзеңне яңа бер дөньяда итеп тоясың. Стенага зур стенд ясалган: уртада — Лондон каласында Темза елгасы аша салынган күпер, анда, бер-берсенә сыенып, егет белән кыз басып тора. Ә тирәли инглиз мәкальләре: «Яхшы ирне кулга төшерер өчен хатын-кыз сукыр булырга тиеш», «Телсез хатын белән чукрак ир генә яхшы пар була ала». Дөнья халыклары шаяра белә!

Аудитория дивары на Вестминстер сарае, Зур Бен манарасы ясалган. Һәркемгә таныш бу силуэтларда эчке бер мәгънә, үткәннәрнең истәлеге һәм сагышы, киләчәккә өмет бардыр кебек, якынрак килсәң, андагы күгелҗем томан артында Шекспир һәм Вальтер Скотт геройларын күрерсең шикелле тоела.

Бу рәсемнәр, стендлар, күргәзмә әсбаплар һәммәсе студентлар кулы белән ясалган. Кайчак йомыкый гына күренгән егет-кызлар да ачылып китеп, берәр хикмәтле әйбер ясап куялар.

Бүген укытучының күңеле аеруча күтәренке: Мәскәүдә өченче дәреслеге басылып чыккан, бер нөсхәсе аңа килеп тә җитте. Ничә еллык хезмәтнең җимешен күрү, кулыңда тоту дигән сүз бит бу!

Ләйлә баскан урынында тик тора алмый, аудитория буйлап әрле-бирле йөренә, урындык-өстәлләрне ары-бире күчерә. Гомумән, һәр очракта ул аларны башкача тезә. Чөнки һәр дәрес — үзенә бер яңа тамаша, бүлмәдәге җиһаз — шуңа декорация булырга тиеш. Килеп кергән бер курсант шундук аңа булышырга керешә.

— Сез монда үз өегездәге кебек гел бертөрле мохиткә ияләнеп утырырга тиеш түгел, — ди ул. — Яңа тел өр-яңа дөньяның капкаларын ача. Өч айлык курсны тәмамлауга, сезне җирнең теләсә кайсы почмагына илтеп ташларга мөмкин булачак. Сез анда адашып, интегеп йөрмәячәксез, кемгә юлыксагыз да, ипи-тозлык, юл сорарлык аңлаша алачаксыз. Инглизчәне бөтен җир шарында аз-маз пупалыйлар. Алай да аң булырга кирәк: бер үк сүзне төрле халык төрлечә аңлый!

Һәркемгә мәгълүм: чит тел өйрәнү шактый читен һәм ялыктыргыч шөгыль. Кафедрага укытырга килгәч, Ләйләнең моңа аеруча эче пошты. Ул дәресләрнең күңелле, мавыктыргыч булуын тели иде. Студентлар үзләрен теле ачылып килгән бала кебек хис итсеннәр, ялгышсалар да укытучы алдында оялып тормасыннар, ничек тә фикерләрен аңлатырга тырышсыннар. Сабыйның теле бер ел эчендә ачылып бетә диярлек. Ә нигә соң күптән акыл туплаган яшьләр яңа бер телне башта мәктәптә, аннары институтта унар ел тукып та иркен сөйләшүгә ирешә алмыйлар?

Тел үзләштерүгә сәләт елдан-ел кими бара, дип аңлата кайберәүләр. Ләйлә моның белән ризалаша алмый: җаен белеп керешсәң, яшең ничәдә булуга карамастан, теләсә кайсы телне сабый баладан да тизрәк үзләштереп була. Тик ысулларын гына белергә кирәк.

Ләйлә менә шундый ысулларны уйлап тапты шикелле. Бүген ул яңа укучылары белән дүртенче дәресен үткәрә. Урындыкларны түгәрәкләп тезеп куйгач, уртага чыгып басты да, кулларын чәбәкләп:

— Башлыйбыз, — диде.

Һәммәсе яңа берәр әкәмәт көтеп елмаештылар, Алтынчәч исемле хатын гына гадәттәгечә җитди калды.

Шулчак ишек ачылып, Нигъмәтуллина килеп керде. Үзе генә түгел, бер ир кеше белән.

— Һау ду ю ду, леди Ләйлә! Мин сезгә тагын бер шәкерт алып килдем.

— Леди инглизчә генә аңлый, — дип инглизчә җавап бирде Ләйлә һәм шулай дәвам итте дә. — Юлдашыгыз минем белән ничек аңлашыр икән соң? Сэр, сез бирегә чакырылмаган кунак булып килгәнсез. Аңлыйсызмы мине? Мәктәптә, институтта инглиз теле өйрәндегезме? Ягез, сөйләшик!

Тирә-юньдәгеләр бөдрә чәчле, урта буйлы, эчтән яктырып торгандай якты йөзле ир кешегә елмаешып текәлделәр. Ул исә югалып калды, ни дияргә белми, кызарынып чыкты. Ә Ләйлә аның каршында горур кыяфәттә басып тора, башы югары, сыны төз, шоколад төсендәге күлмәге бик килешле. Эре итеп бөдрәләткән чәче аны биегәйтеп күрсәтә. Көнчыгыш хатын-кызларына тартым йөзендә гадилек белән бергә үз дәрәҗәсен белү дә сизелә.

— Алып килгәнсез икән, аны миңа тиешенчә тәкъдим итегез инде, — дип карашын Ларисага күчерде Ләйлә.

— О, мәрхәмәтле леди...

— Гадирәк кирәк. Инглизләрдә япон этикетына хас төчелек юк.

— Хөрмәтле леди... рөхсәт итегез... минем юлдашым...

— Инженер Әнвәр Уразов, — дип телгә килде ир кеше һәм, уенга катнашканын белдереп, вәкарь белән Ләйләгә якынрак килде дә кулын үбәргә иелде.

— Рәхим итеп узыгыз, утырыгыз, — диде Ләйлә. — Гомуми әңгәмәгә катнашыгыз.

Һәм уртага ике егетне чакырып, химик элементлар турында әңгәмә корырга тәкъдим итте.

Бу дөньяда кызыклы нәрсәләр шулкадәр күп, азын гына белергә дә ун гомер җитмәс. Кеше акылы ирешкән нәрсәләр һәр өлкәдә таң калдыра.

Химия белән кызыксына башлагач, Ләйлә моңа тагын бер тапкыр хәйран калды. Аларның институты химик-инженерлар әзерли, шуңа күрә ул дәресләренә шушы фән буенча шактый текстлар кертте. Моның өчен институт китапханәсендә тезе белән шуышып күп йөрергә туры килде, чөнки инглиз телендәге химия китаплары аскы киштәләргә тезелгән иде. Аларны укый торгач, Ләйлә бу фәнгә шәрык кайнарлыгы белән гашыйк булды. Менделеев таблицасы гына да «Мең дә бер кичә» кебек икән, һәр элемент турында әкият, поэма, кыйсса язып була. Химиядәге ачышларның тарихлары үзенә бер детектив әсәр кебек.

Ләйлә, ул китаплардан чыгып, чит тел дәресләрендә уйнау өчен текстлар төзеде. Менә хәзер ике егет шул әңгәмәләрнең берсен уйныйлар. Берсе — химиягә гашыйк кеше, икенчесе — битараф. Ләйлә рольләрне капма-каршы холыклы кешеләргә тапшырырга ярата. Оялчаннан — чаяны, дәртлерәктән сабырны уйната ул. Алай кызыграк, кешенең холкы да тәрбияләнә.

Бу әңгәмә тәмамлануга, ул читтәрәк торырга тырышкан Алтынчәчне уртага чакырды. Егетләр аның каршына өстәл китереп куйдылар, буш тормасын өчен, аның өстенә Ләйлә үзенең әле генә чыккан китабын китереп салды.

— Сез — тәэминат министры. Ә сез, леди Лариса, аннан пенсия сорарга киләсез.

— Пенсия өчен мин яшьрәк әле, — диде Лариса, русчалап.

— Ә сез — биюче. Җиде яшьтән башлап унбиш ел буе биедем, закон минем якта, диегез. Сезнең эшләми генә акча аласыгыз килә, җитмәсә, кияүгә чыгарга җыенасыз!

— Ну инде, без утыздан узган һәркемне дәүләт җилкәсенә атландыра башласак,— дип, ватажимерә каршы төште Алтынчәч.

— Леди Вафина, һәркемне түгел, мине генә! Миндәй бүтән илдә юк! Әле тагын биермен, тик менә бәби табарга кирәк бит! Берничә ел эшләми торырга туры киләчәк, ә иргә таяну, үзегез беләсез...

Лариса киная белән бөдрә башлы инженерга күз сирпеп алды.

— Бәлки, Англия ирләре башкадыр? — диде кемдер.

Китте гадәттәгечә көлү, шаяру. Лариса үзсүзле иде, ләкин министр да тиз бирешә торганнардан түгел. Нинаять, ул, сүзнең тәмамланганын аңлатып, урыныннан торып басты:

— Кичерегез, леди Нигъмәтуллина, минем кабул итү сәгатем тәмамланды. Тагын егерме елдан рәхим итегез!

— Сез әле егерме ел шушы урындыкта утырмакчымы? Мин сезне бу урыннан алдырту чарасын табармын!

Карале, бу Вафинаны Ләйлә йомыкыйга санап йөри иде, минуты җитсә, кыяфәте нинди горур була ала икән. Ларисаның соңгы сүзләрен санга сукмаганын белдереп, ияген күтәреп, күзлек пыялаларын гына елтыратып куйды.

— Шәп министр бу, моңа ышанырга була, — диештеләр тирә-якта. Ләйлә исә Ларисаны уртадан чыгармады.

— Ә хәзер сез менә бу шәехнең дүрт хатыны арасында иң сөеклесе. — Ул Әнвәргә ишарәләде. — Ул сезне үзе белән чит илгә сәяхәткә алып чыккан. Шәех әфәнде, сезнең Гарәбстанда тагын өч хатыныгыз, алардан туган шактый күп балаларыгыз, чүлләрдә бихисап куй һәм дөя көтүләрегез, берничә сараегыз бар. Гарәп шәехе — бик бай һәм горур кеше. Сезнең хатыныгыз... ай-яй, гарәп шәехе хатынын болай йөртәме? Җиң сәдәфләрен каптырырга, түшне капларга кирәк булыр. Ә башыгызга пәрәнҗә ябыгыз. Бу юлга яулык бөркәнсәгез дә ярап торыр...

— Хатын шәп, шәехнең зәвыгы бар икән, — диде шактый ишеттереп кемдер.

Ларисаның башына яулык бөркәделәр, бер егет алар каршына басып:

— Ә бу кем? Ни өчен ул чик аша яшеренеп узмакчы була? Йөзен ачып күрсәтсен! Кем узганын мин ачык белергә тиеш, — диде. Ул паспорт контролен үткәрүче, имеш.

Инженер Уразов әле беренче тапкыр гына булганга, уенга бик үк кереп бетә алмады, буталды, оялды. Алай да тырышты:

— Ноу, — диде, — минем хатын...

— Ә мин каян беләм? Бәлки, сез хатыным дип берәр шпион йә җинаятьчене ияртеп барасыздыр! — дип, егет Ларисаның яулыгына сузылды

— Ярамый... Намәхрәм! — диде Әнвәр.

— Марихуана түгелме? — диде тикшерүчене уйнаган егет.

Һәммәсе шаркылдашып көлеп җибәрделәр.

Алтынчәч тә башкаларга ияреп көлә, бу минутларда ул кыенсынуын бөтенләй оныткан иде.

***

— Карале миңа, карале!

Лариса, биленә таянып, урам фонаре яктысына кереп басты.

— Ныгытып кара!

Гәүдәсен кысып тоткан күн пинжәк, киң итәк, йөнтәс берет кигән Лариса әле генә мода журналыннан сикереп төшкән кебек күренә иде. Яшь, чибәр, чая! Урам фонареның алдавыч яктысы аны курчак кебек күрсәтә.

— Әйт, минем кай җирем аннан ким?

— Кемнән, Лорочка?

— Леди Ләйләдән кимме мин?

— Ну, Лора, таптың чагыштырыр кеше... Ул бит... Ул бит...

— Нәрсә, хатын-кыз түгелме әллә ул?

— Бөтенләй икенче дөнья кешесе бит ул! Бу инде пешкән җир җиләген... ничек дип әйтим... — Әнвәр як-ягына каранды, — ну, тулган ай белән чагыштырган шикелле.

— Ә мин нәрсә, синеңчә? Җиләкме, аймы?

Әнвәр тамак төбе белән генә көлеп куйды.

— Әйдә, аныклап бетермик әле. Син минем өчен тулган ай да, татлы җиләк тә. Мин сине беркем белән дә чагыштырырга җыенмыйм.

— Мин аннан ким түгел, шулай бит?

— Юк инде, юк инде, — дип шаярып аның аркасыннан сыйпады Әнвәр.

— Ә нишләп аның бөтен эше шулай көйле генә бара да, нишләп минеке гел генә тупикка барып терәлә?

— Ну, Лорочка, инде син дә зарлансаң! Егетләрнең менә дигәннәре гашыйк үзеңә, сайлап ал. Күпме кешеләр керергә хыялланып та керә алмаган институтта укыдың, нинди мактаулы профессор кул астында эшлисең. Канәгать була белергә кирәк!

— Ништяк! Инде син дә минем хакта болай уйлагач, кемгә зарымны сөйләрмен! Иргә чыктым — ялгыштым... Үзең беләсең бит инде... Һөнәр сайладым — ялгыштым! Профессорда — анысында да ялгыштым!

— Нишләп алай? Кешеләрне дәвалау ошамыймыни? Аларның газапларын җиңеләйтү канәгатьлек бирмимени?

— Үз ихтыярың белән гомереңне хасталар арасында уздырасың инде, шул! Сызлану, сыкрану, шакшылык! Кайберсенең янына барасы килми. Тир исе аңкый, тешләре тазартылмаган, чәчләре тузган, халатлары керле! Үзеңнән һәрвакыт больница исе килә! Фу!

Алар урамнан баралар иде. Бу сүзләрне әйткәндә, фонарь турысыннан узып киткәнгә, Ларисаның йөзе күләгәдә калды. Әнвәр аңа аптырап карады, сүз табалмый берничә адым атлады. Аннары, гажәпләнүен бик үк сиздермәскә тырышып:

— Ә миңа врачлардан бөтенләй башка сүз ишетергә туры килә, — диде.

— Шул бер ягы бар инде: хасталар арасында айкалып кайткач, яшәүнең кадерен ныграк белә башлыйсың. Бер йотым су эчү дә олы бәхет булып тоела. Бу Ильясова да бик вакчыл булып чыкты. Инде бөтен нәрсә ачык бит югыйсә, ә ул яңадан-яңа тикшеренүләр таләп итә, фәнни эшне дөньяга чыгарырга рөхсәт бирми, әллә кая заводларга барып йөрергә мәҗбүрмен.

— Бала табарга кирәк сиңа, — диде кинәт Әнвәр. — Э-э...— Ул бераз тотлыгып торды, — врачлар әйтә, ана булгач, кешеләргә мөнәсәбәт бөтенләй икенчеләнә, ди. Авыруларны үз балаң кебек күрә башлыйсың икән. Бала нинди хәлендә дә күңелгә газиз бит ул.

— Санын җыя алмаган карт, ямьсез хатыннарны үз балаңдай күрү өчен акылдан шашкан булырга кирәк! Кем әйтте сиңа андый сүзне? Ә-ә, Зәйтүнә, әлбәттә!

— Кем булыр идең соң син? — дип ашыгып аның сүзен бүлдерде Әнвәр.

— Хәзерге акылым булсамы? Чит телләр институтына керер идем. Тәрҗемәче булып китәр идем. Йә манекенщица. Матур киенеп, чибәр кешеләр арасында бөтен дөньяны гизеп йөрер идем рәхәтләнеп. Әллә булдыра алмас идемме?

Лариса, башын күтәреп, тагын каршыга чыгып басты. Фонарьларның күзне алмаштырган яктысында, күңелне иләсләндерә торган дәрт, хис бөркелә иде аның йөзеннән.

Әнвәрнең иреннәре кипшенде.

— Төрле милләт егетләренең йөрәкләре түшәлгән юлдан гына йөрер идең, — диде ул.

— Әйт әле, Анварчик, әйт дөресен генә, нигә берәүләрнең бәхете аягына уралган да, нигә минем тормыш һаман чалыш-чолыш бара? Бала чагымда әти белән әни икесе ике якка китеп, мине әле әбиемә кайтарып ташлап, әле үзләренә алып башымны катырдылар. Ул чакта кайсына карарга белми идем. Ә бу Ләйлә ата-анасын да үзе сайлап алган диярсең. Атасы профессор, анасы профессор. Ильясова да хәйләкәр, медицина ягына тартмаган, чиста, затлы һөнәр сайлаган кызына!

— Җаны теләгәнне үзе сайлагандыр, әнисе авызына карап тормагандыр, бәлки, — дип, Ләйләне яклады Әнвәр. — Һөнәрдә түгел хикмәт, минемчә, кешенең үзендә.

Һәм сүзне икенчегә борырга тырышты.

— Бир әле сумкаңны, иңеңне баса. Нишләп бу хәтле авыр, таш тутырдыңмы әллә?

— Әйе, яши белә кешеләр. Акыл белән яшиләр!

Әнвәр, йомшак сумканы капшап, эчендә шешә барын чамалады.

— Запас белән йөрисең икән.

— Премия ул миңа, яхшы эшләгән өчен, — диде Лариса.

— Сезгә премияләрне натуралата бирәләрмени?

— Акчалата алмыйбыз, ришвәт була. Ә мондые — чәчәк, конфет ишесе — гөнаһ түгел.

— Күпме вакыт врач белән яшәп, мондый премия бирелгәнен белми идем әле.

— Нәрсә беләсез соң сез? Ни беләсез?

Алар трамвай тукталышына килеп чыктылар. Икесенә бер якка барасы, чөнки Зәйтүнә Ларисага фатирны каршы йорттан табып биргән иде. Бер студент кыз белән кечкенә генә бүлмәдә яши Лариса.

Баш тыгар урыны бар, әмма шунысы җайсыз: теләгән кунагын алып кереп булмый. Әнвәр трамвайдан төшмичә ары китәргә булды.

— Мин синең белән шушында хушлашам инде, Лорочка. Моннан үзең генә кайтырга курыкмассың бит?

— Ә син кая?

— Теплицаларга җылыны бүген генә җибәрдек. Торбалар чыдармы, карап кайтырга кирәк. Төнлә төрле хәл булуы ихтимал. Үзе юкның күзе юк.

Лариса үпкәләгәндәй итенде:

— Минем сыйдан баш тартасыңмыни?

Ул сумканы алып, озын бавын иңенә элде.

— Башка вакытта, Лорочка.

— Анварчик, мин сине үзем белән чакырдым бит бүген, нинди күңелле дәрескә алып бардым. Әйдә, син дә мине чакыр!

— Кая?

— Теплицага. Минем гомеремдә бер тапкыр да теплица күргәнем юк. Ә күрәсе килә. Кыяр-помидорлар ничек үсә икән анда?

— Хәзер анда кыяр да, помидор да юк әле. Утыртырга әзерләнәбез генә.

— Минем белән күңелсез булыр дип куркасың инде.

— Әйдә алайса, — дип әйтеп ташлады Әнвәр, үзе дә сизмәстән.

Лариса иңе белән аның күкрәгенә сыенды. Аның бу хәрәкәтеннән тән эсселәнеп китте. Әнвәр, трамвайдагыларның күзеннән яшеренергә теләгәндәй, курткасының башлыгын күзенә төшеребрәк киде. Ул күзе майлы елтыраганын, иреннәрендә мәгънәле елмаю кабынганын үзе дә сизә, моны янәшәдә басып торучылар күрәләрдер дип шомлана, тик карашын да, елмаюын да үзгәртә алмый иде. Акылы каршы килсә дә, тәне Ларисага тартыла иде аның.

Трамвайдан төшкәч, урам аша чыгып, троллейбуска утырдылар. Шәһәр читенә чыккач, ниһаять, ул кап-караңгы бер төшкә килеп туктады. Уң якта җирдән шактый күтәртеп сузылган юан-юан торбалар шәйләнә, алда завод утлары җемелди.

Әнвәр Ларисаның туңган кулын каты итеп кысты да сулга, биек коймага таба алып китте. Капка каршыда гына иде, шактый озак шакыганнан соң, эчке якта лаштыр-лоштыр аяк тавышлары, аннан карт кешенең: «Кем анда?» — дип сораганы ишетелде.

Капканы ачкач, каравылчы юлга аркылы басып, Ларисага текәлде.

— Мин теплицаларны карап чыгам әле, — диде Әнвәр һәм сәер күренгән юлдашын карттан ышыклап эчкә уздырды. Алар караңгыда агарып күренгән озын корылмага таба киттеләр. Теплица ишеге төбенә җиткәч, Әнвәр коры гына:

— Аягыңны сөртеп кер, — диде. — Безнең мастерлар гомумән чит кешене теплицага кертмиләр.

— Алайса кермәм.

Әнвәр аны көйләп маташмады, моны сизгән Лариса аягын бусага алдында яткан тимер челтәргә ныгытып ышкыды.

Эчкә кереп, гөлт итеп ут кабынгач, ул бераз күзләрен челт-челт йомып торды. Аннары як-ягына каранды. Теплицаның эче ямьсез, күңелсез булып күренде. Полиэтилен түшәм, пыяла стеналар, ике яктан сузылган торбалар, тезелеп киткән баганалар, кара җир. Җитмәсә, эссе, бөркү, берничә мизгелдән бит-кул, кара күн пинжәк дымланып чыкты.

— Шушымыни инде синең җан атып йөргән теплицаң?

— Март айларында күрсәң иде син аны! Кара урман кебек була. Яфрак арасында качкын ятарлык. Сабаклардан озын-озын кыярлар асылынып тора. Менә былтыр уртага бер рәт булып райком секретарьлары тезелеп баскан иде. Ниндидер бер зур киңәшмә вакытында аларны бирегә экскурсиягә алып килделәр. Күзләре дүрт булды начальник абзыйларның... Рельска абына күрмә. Берәр кыяр өзеп алырга рөхсәт иттек без боларга. Балаларына күчтәнәчкә.

— Ник берәрне генә?

— Җиткән. Мастерлар аны, беләсеңме, күпме хезмәт куеп үстерә? Һәр үсентене сабый бала кебек тәрбиялиләр.

Теплица хакында сөйли башлагач, Әнвәр тынычланып, дәртләнеп китте.

— Романтично, — диде Лариса. — Тик артык бөркү. Тагын да бераз шушылай торсак, мин тәмам пешеп җитәчәкмен, син мине шушы килеш тотып ашый алачаксың. Яңа төр урожай булачак!

— Әйе шул, бөркүрәк, — диде күңелсезләнгәндәй Әнвәр. — Үсемлекләргә дым кирәк, җылы кирәк. Нишлисең, мастерлар чишенеп эшлиләр.

— Егетләргә кызлар күзләргә җайлыдыр инде.

— Юк, әйтәм ич, монда ешлык, берни күренми. Алар ишекне эчтән бикләп куялар. Былтыр кышкы салкыннарда күзгә йокы кермәде инде. Әгәр шунда утырткан әйберләребез өшесә, хур була

идек. Ике көн карыйбыз, өч көн — җылы! Пыяла астындагы суганнар өшеп бетте, мондагылар калды. Шундый көннәр өчен генә булса да дөньяда яшәргә була, Лорочка.

Әнвәр аны иңнәреннән кочып, күкрәгенә кысты. Лариса аяк очларына басты да егетнең иреннәренә үрелде. Вокзаллардагы ише генә түгел, каты итеп, озак итеп, тынны буып үпте ул аны бу юлы.

— Узган елгы җиңүең белән котлап, — диде аннары, тирән сулыш алып.

Әнвәр аңа җавап бирмәде, тизрәк арырак узу ягын карады. Икенче бүлемнең ишеген ачты да, утны кабызып, урта сукмактан ашыгып узып кына китте, өченчесенең янында берничә мизгел тынып басып торды, башка бүлемнәргә кермәде.

— Ярый, сине ялыктырып йөртмим инде,— диде.— Ул-бу булса сизелер иде.

— Алар барысы да шушылай ук бушмы?

— Суганны утырттык инде. Озакламый тишелеп чыгачак. Суганга да иртәрәк әле, бер өлеше генә тишелә, шактые уянып җитмәгән була. Аларын кире җыеп, яңадан утыртырга туры килә. Андыйны недогон диләр.

— Уянмаган? — Ларисаның тавышында зур кызыксыну ишетелде. — Суганның да уянганы-уянмаганы буламыни?

— Була шул.

— Суган да шулай булгач, кешегә ни кала? — дип көрсенде Лариса. — Суган башларының да һәркайсының үз вакыты, үз җылылыгы, димәк. Алар өчен дә төгәл генә кагыйдә юк. Ә кешеләр өчен закон куелган! Кызлар унсигездән алда кияүгә чыкмасын, аннары ирен генә сөйсен, башкаларга күз салмасын... Ә йөрәк, ә кешенең табигате андый законга туры киләме? Ә бәлки, минем йөрәгем, шундый недогон шикелле, уянмагандыр әле! Ә бәлки, мине иртәрәк утыртканнардыр! Хәзер генә вакытым җиткәндер минем!

Һәрнәрсәдән шундый бер көтелмәгән нәтиҗә чыгара белә Лариса, кеше башына килмәс рәвешле уйлый. Чыннан да шулай бит. Зәйтүнә белән Әнвәрнең мөнәсәбәтендә дә шундый недогон кебегрәк нәрсә бар. Җитлекмәгән аларның мәхәббәте, җанланмаган. Уянмаган әле Зәйтүнә... Шулай да... Шулай да Әнвәр аның уяначагына ышана. Аның да язы шаулап килер һәм гөрләвекләр булып гаилә тормышына бәреп керер. Сабыр итәргә кирәк. Күңелне кузгата торган, күз карашыңны кешеләрдән оялырлык дәрәҗәдә үзгәртеп, иреннәреңдә ят елмаю тудыра торган бу хатыннан читтәрәк булырга кирәк. Хыянәткә барырга ярамый. Әле дә соң түгел, капка төбенә чыгарга да троллейбуска утырырга, өенә озатып саубуллашырга... Капкадан гына чыгарга кирәк, калганы үзеннән-үзе эшләнер...

— Бу шешәне кая куябыз соң? — диде Лариса.— Кире ташып йөрмәбез бит инде. Синең теплицада үскән уңышың өчен бокал күтәрәсем килә. Дөрес, закусканы әзерләп куймагансың икән.

Җитди сәбәп иде бу. Әнвәр кайнарланган мие белән шуны уйлады. Закуска юк, ә Лариса кебек нечкә табигатьле хатын закускасыз гына, аягөсте шешә авызыннан хәмер чөмермәс.

— Янымда син булганда, закускага аптырамабыз анысы,— диде Лариса.— Баш инженерның биредә бер почмагы бардыр бит инде?

— Бар,— диде Әнвәрнең иреннәре ихтыярсыз.— Ничек булмасын, бар, әлбәттә.

Моны әйткәндә ул эченнән, баш инженер буларак абруемны күтәрәм, шуның өчен генә әйтәм, дип уйлады, шуның белән акланырга тырышты. Ләкин йөрәк шашып тибә, йөрәк моның ни өчен әйтелгәнен яхшы белә, ул алданмый иде.

Кечкенә бүлмәнең стеналарына ямьсез яшькелт-соры обой ябыштырылган, кыршылып беткән өстәлдә тәртипсез рәвештә сызым битләре, кәгазьләр аунап ята. Әнвәр беренче тапкыр бүлмәсенең күңелсезлеген күреп оялды, ләкин Лариса стенага түгел, ян яктагы иске диванга караган иде.

— Начар түгел,— диде ул. — Җылы, ләкин тегендәге ише бөркүлек юк. Начальство үзен кайгырта белә!

Ул сумкасыннан биш йолдызлы коньяк тартып чыгарды. Әнвәр почмактагы тумбочка өстеннән стакан, яртылаш су салынган графин алды. Стакан таплы, графин да күптән юылмаган иде, әмма Лариса борынын җыермады, кәгазь сорап алды да, коньяк белән чылатып, стаканны ышкып ялтыратып та куйды.

— Бокаллар тотарга кирәк, иптәш баш инженер. Зур начальниклар килә үзегезгә, каршыгызда пионерлар кебек тезелеп райком секретарьлары басып тора, ә сез аларны кунак та итмисезмени соң?

— Кирәк булса, күңел ачарга моннан яхшырак урын табарлар әле.

Әнвәр стаканга яртылаш коньяк салды.

— Тутырып! — диде Лариса.— Икебезгә дә җитәрлек булсын. Утны да сүндерергә вакыт. Караңгыда мине тапмам дип курыкмыйсыңдыр бит? Качыш-качыш уйнарбыз, кызык булыр. Йә, кил, яныма утыр әле.

Коньяк ачы булып тоелды. Ә менә закуска — Ларисаның иреннәре татлы да, утлы да иде. Алай да Әнвәрнең аңы бөтенләй үк томаланмаган иде әле.

— Тешләмә... — дип пышылдады ул.

— Чын ләззәт сызланулы була ул, — диде Лариса һәм, каршы әйтергә ирек бирмичә, янә егетнең авызын сулышы белән томалады. Әнвәрнең күз алдында һаман әле Зәйтүнә белән Тимербулат шәйләнә: «Китәргә кирәк, әле соң түгел», — дигән уй айкала иде.

Лариса аның иңенә йомшак кына сыенды да, бөтенләй моңарчы булмаганча итеп:

— Әнвәр, әйт әле, теге чакта аэроклубка Зәйтүнә белән мин дә килгән булсам, син безнең кайсыбызны сайлаган булыр идең? — диде.— Ул мине үзе белән чакырган иде бит. Соңыннан мин аның өчен медсправка да алып йөрдем әле. Их, шунда ник бармадым икән мин? Бәхетеңне кайда табасыңны алдан белсәң иде! Белмәдем шул, белмәдем! Хәзер шуның газабын күрәм инде менә!

Әнвәр аның бөдрәләрен сыйпап, кулын аска шудырган иде, бармаклары яшькә чыланды. Лариса елый иде.

— Соңрак та бу хатаны төзәтеп була иде, ә син тулай торакка килгән чакларыңда мине күрмәгәндәй кыландың. Ничек газапладың син мине, Әнвәр, нинди утларда яндырдың! Син минем бердәнберем идең бит! Һәм гомерлеккә шулай булачак идең! — Лариса аның муеныннан кочып алды да, күкрәгенә ятып үкси башлады. — Син мине бер бозык хатын дип уйлыйсыңдыр инде. Минем башка чарам юк бит, Әнвәрем, йолдызым! Син мине үзең чакырмас идең бит... Әбием әйтә торган иде, Әнвәр — йолдыз дигән сүз ул, дип. Авылда безнең Әнвәр исемле кардәшебез бар... Син минем өчен гомерлеккә буй җитмәс йолдыз булып калырсың микәнни инде? Ерак йолдызым булырсың микәнни? Синең белән шушылай бер утыру өчен жүләргә сабышырга туры килде бит миңа. — Ул кинәт башын күтәрде дә, Әнвәрне иңнәреннән тотып селекте. — Нишләп утырасың инде болай? Куып чыгар мине! Сугып җибәр! Гайрәтемне чигерерлек берәр нәрсә эшлә ичмасам! Гомер буе бу утларда яна алмыйм бит инде мин!

Моңа кадәргесенә Әнвәр түзә иде әле. Монысы соңгы тамчы булды. Әнвәр аны кочагына алды да бөтен дөньясын онытты...

***

— Күзеңә ни булды синең? — дип сорады Зәйтүнә иртә белән.

— Ә-ә, бумы? — Әнвәр тышкы ишек янына беркетелгән көзгегә карады. Чыннан да күзләре кызарып чыккан икән.— Бу шул салкын тию бәласе инде. Теплица бик эссе бит, урамга чыгуга каптырып ала.

— Үзең ул теплицаларны сәламәтлек чыганагы дип мактыйсың тагын.

— Мастерларга чыннан да шулай. Алар бер кергәч чыкмый эшлиләр. Ә миңа кереп-чыгып йөрергә туры килә. Бер эссе, бер салкын...

— Каты чәй белән юып җибәр,— диде Зәйтүнә.— Әнә чәйнектән салып ал.

Ул инде үзе киенеп куйган, Тимербулатны киендереп азаплана иде. Иртәнге сигезгә баланы яслегә илтеп җиткерергә кирәк, ә ара ерак, трамвай белән барасы.

— Һаман да шул теплица да теплица,— диде Зәйтүнә.— Миңа да җиңел түгел бит. Кичен баланы яследән алыр идең ичмасам.

Аның ире белән сөйләшер сүзе күп иде, ләкин Әнвәр соң кайта. Теплицаларны көйләп җибәргән чорда былтыр да шулай көнне төнгә ялгап эшләде. Ул кайтканда Зәйтүнә йоклаган була. Сөйләшәсе килгәнне бер-ике авыз сүз белән генә әйтеп бирә торган түгел. Өстәвенә берничә көн инде үзен начар хис итә, өченче көнне эштән кайтканда температурасы утыз сигезгә җиткән иде. Дарулар эчеп яткач, тән эссесе иртәнгә сүрелде сүрелүен. Өйдә ятарга туры килмәвенә сөенеп, җыенып эшкә китте. Ә менә йөткергәләве бетми дә бетми.

Тик зары бу түгел, бөтенләй башка. Хикмәт шунда: аңа шактый авыр күңел ярасы ясадылар.

— Миңа бик зур гаеп ташладылар бит әле,— диде ул, көйсезләнгән Тимербулатның пальто төймәләрен эләктерергә тырышып.— Бер авыру хатын турында сөйләгән идем бит мин сиңа узган елны? Биш айлык баласын төшерде.

— Андый хәлләр сездә булгалап тора инде,— диде Әнвәр. Аның башы авырта иде.— Улым! Улым! Кил әле миңа!

— Шуның ире әйтә, сез, ди, авыруларга зыян саласыз, ди.

— Браксыз эш буламыни хәзерге заманда? Җыен ахмакның сүзен тыңласаң, башың катар. Тыңлама син андыйларны. Төкер... Минем улым түү-түү бара. Бәбиләр янына, тәтиләр белән уйнарга. Кочакла әле, улым, әтиеңне. Менә шулай, менә шулай...

Әнвәр белән аңлашып булмады.

— Кая, китер, соңга калабыз,— диде Зәйтүнә. Көзгегә карап, шома чәчен сыпырып, толымын беретына тутырып киде дә, саргылт плащын бала ботинкаларыннан сакларга тырышыбрак, улын кулына алды.— Бәлки, бүген Тимербулатны яследән син алырсың?

— Беләсең бит инде, Зәйтүнә, торбаларның бер җөе генә ярылса да күпме хезмәт юкка чыгачак.

— Кайтып ашап китәрсең.

— Алай итсәң була булуын... Сау бул, улым. Хуш-хуш диген. Менә шулай, менә шулай...

Ярледә Тимербулат тагын елап калды. Зәйтүнә чыгып киткәндә, аның бөтен битен авыз гына тәшкил итә иде шикелле. Бичара сабый. Нихәл итәсең, әбиең авылга кайтып китте шул. Өч ай эчендә оныгын бик күп һөнәрләргә өйрәтергә өлгерде: кул-аягын күрсәтергә, кулын чәбәкләргә, чүлмәккә утырырга, диванга менәргә. Тагын күпкә өйрәткән булыр иде, тик менә көзгә таба карчыклар шәһәрдә аеруча күңелсезләнә. Ишегалдындагы эскәмияләрдә ак яулыклы әбиләр тезелешеп утырмый шул инде. Гөлзәйнәп карчык үз ишләре янына батыраеп барып утыра иде дә, дөнья хәлләрен, узган гомерләрне сөйләшеп керә иде. Инде хәзер бала белән дә озаклап тышта йөреп булмый — суытты, яңгырлар башланды. «Авылда мин ичмасам, ишегалдына чыгып, тавыкларым белән сөйләшәм, казларга сәлам бирәм, бозау муенын сыйпыйм»,— дип сагынып-сагышланып сөйләнде карчык. «Бер генә күзәнәгемнең дә монда торасы килми», — дип куйды беркөнне, тирән көрсенеп. Өстәвенә килене Мөнирәдән чөгендер ала башладык дигән хәбәр дә килеп төшкәч, уттай эш өстендә алар минсез яши алмый, дип, көненә кыздырып самолетка билет алдырды да очып кайтып та китте. Җитмештән узган карчык эшнең иң кызу җиренә ашкына, әле кызына, әле киленә ярдәм итәргә ашыга иде. Тимербулатны яслегә урнаштырырга туры килде.

Зәйтүнә эшенә трамвайдан трамвайга күчеп бара. Көн болытлы, өстән явып тормаса да, җилле, салкынча — күңелне изә торган һава иде бу. Тагын Хәйруллиннар искә төште.

Әнвәргә, төкер, дип әйтү җиңел. Әмма Хәйруллинның сүзендә хаклык та бар бит. Чыннан да, зыян салды бит Зәйтүнә. Дөрес, бу гамәлне ул үзе теләп түгел, башкалар ихтыярына буйсынып кылды. Әгәр Динә үзе моны теләмәсә, Кифая аңа ялган белешмә алуда булышмаса, Фидая үзенең палатасына салып, иң көчле чараларны күрә башламаган булса, Зәйтүнә беркайчан да мондый эшкә бармас иде. Ләкин болар да аның гаебен акламый. Динәне палатага салгач та күрде бит ул. Аның зур хата ясарга теләгәнен дә ачык аңлады. Нигә соң шул чакта ук аның белән ныгытып сөйләшмәде? Нигә бу эшнең никадәр куркыныч икәнлеген аңлатмады, үгетләмәде, ниятеннән ваз кичтерергә тырышмады?

Шушы үкенечнең ачысы менә ничә көн инде Зәйтүнәгә һич тынгы бирми. «Үткән эш кайтмый, үкен син, үл, ела»,— дигән шагыйрь. Ләкин киләчәк бар бит әле. Алдагысы ышанычлы түгел шул. Теге чактагы хәлләрдән соң берничә ай узгач, Хәйруллина аналыктан тыш йөкле булып, авыр операция кичергән инде. Яңадан да шундый бер операция ясарга туры килсә — ә андый хәлләр булгалый, хастаханәгә бер кергән кеше, тагын-тагын әйләнеп килүчән! — ул чакта аның ана булуга өмете тәмам өзеләчәк.

Мондый үкенечле уйларның һәр табиб башына килгәнен дә белә Зәйтүнә. Күпләр моннан аянычрак хаталар да ясый. Кайсы гына табиб әгәр башкача эшләгән булсам, мондый фаҗига булмас иде дигән газаплы уйлар белән башын иеп, табут янында басып тормаган?!

Андый хәлнең кайчан да булса үз башыннан кичәчәген аңлый Зәйтүнә, әмма күңеле моның белән ризалашырга теләми иде. Нәрсәдер эшлисе, ничек булса да аянычлы хатаны төзәтәсе килә иде аның.

Нишли ала ул хәзер? Бәлки, Динәне чакырып китерергә, сәламәтлеген ныклап тикшерергә, кирәк булса, яткызып дәваларгадыр? Моны эшләп була бит! Һәм бу — аз түгел!

Эзләп тә торасы юк, ире аша гына чакыртырга кирәк. Зәйтүнә бүген үк заводка, Хәйруллинга шалтыратырга булды.

Ләкин клиниканың бусагасын атлап керүгә, көндәлек мәшәкатьләр урап алды, телефон янында утырырга җай чыкмады. Аннары Зәйтүнә, эштән алданрак китеп, заводка сугылып чыксаң, Хәйруллин белән күзгә-күз сөйләшсәң яхшырак булыр дигән фикергә килде.

...Аның киләсен белеп торган диярсең, проходнойга керүгә, каршыга турникеттан Хәйруллин үзе килеп чыкты. Маңгаен күксел эшләпә белән каплап куйганга, очлы борыны елтырап күренә, ирен читләре үртәгәндәй өскә күтәрелгән.

— Исәнмесез, доктор! Тагын килдегезме?

— Сөйләшәсе бар иде.

— Онытмыйсыз безне, ә? Хәзер әйтермен, пропуск язарлар.

Ул тар коридорга таба борылды. Зәйтүнә аның артыннан куып җитте дә:

— Миңа шәхсән сезнең белән сөйләшергә кирәк иде,— диде.

— Мин китеп барам шул инде.

Хәйруллин шактый коры сөйләшә иде. Зәйтүнә ник килгәненә үкенә башлады. Бу кеше аны аңламас, көләр генә, мөгаен.

— Алайса, миңа пропуск кирәкми. Мәшәкатьләнмәгез.

Зәйтүнә тышкы ишеккә таба борылды. Бу юлы Хәйруллин аны куып тотты:

— Сез кая кайтасыз?

— Сезгә барыбер түгелмени?

— Әйдәгез, мин сезне озатып куям.

Тышка чыккач, ул читтәрәк, бетон мәйданчыкта торган машиналар арасындагы чия төсле «Москвич»ка таба юнәлде. Кыска күн пальтосының кесәсеннән бер бәйләм ачкыч чыгарды.

Машинаны хәтәр йөртә икән. Әңгәмәнең җебен өзми үзе, салмак сөйләшә.

— Сез тагын шул мәсьәлә буенча килгәнсездер инде,— диде ул.— Цех һавасындагы зарарлы газларны киметергә, эшчеләргә респираторлар кигезергә...

— Юк, мин сездән гафу үтенергә теләгән идем, — диде Зәйтүнә ныкитеп.

— Гафу?! Нәрсә өчен?

— Сез үзегез теге көнне миңа әйттегез бит... Бик зур гаеп ташладыгыз безгә... Ул төнне мин дежур идем. Барысы да минем күз алдында булды.

— Нинди хәл? — дип, Тукай почмагында машинасын кинәт туктатты Хәйруллин. Ул Зәйтүнәгә гаеп ташлаганын, шуның белән аның бәгыренә яра ясаганын гүяки бөтенләй онытканиде!

Әмма Зәйтүнә сүзне ахырына җиткерергә булды.

— Без һәммәсен дөрес эшләдек, — диде ул.

Мөдәррис Сәлаховичның күзләре күк, керфекләре кыска булса да куе икән. Һәм, әгәр дә үчекләгәндәй өскә күтәрелгән юка ирен читләренә карамасаң, карашы беркатлы икән.

— Хатыныгыз безгә тиешле белешмәләрен китереп биргән иде. Формаль яктан караганда, без аңа нәкъ шундый ярдәм күрсәтергә тиеш идек. Ләкин шулай да миңа Динә белән ачыктан-ачык сөйләшергә, бу адымның никадәр куркыныч икәнлеген аңлатырга кирәк булган. Тик мин моны эшләмәдем.

Хәйруллин аңа гаҗәпләнеп текәлде.

— Ах, сез менә нәрсә турында сөйлисез икән!

Ул машинасын сак кына кузгатты да, каршыга килгән трамвайны уздырып җибәрде. Аның карап торуга шактый ук каты, әмма җыйнак куллары руль тәгәрмәчен йомшаграк тоткандай тоелды, машина йөрешен әкренәйтте.

— Кызык,— диде ул, алга караган килеш.— Бу арада мин дә сезне искә алгаладым, доктор Зәйтүнә. Сезгә исемегез белән генә дәшәргә ярыймы? Ә миңа Мөдәррис кенә диегез. Яшькә бер чамадыр бит без.

Ул тынып калды. Рөхсәт сорап тормыйча, кесәсеннән сигарет алып капты, машина кабызгычыннан ут элдерде. Алар дамба буйлап бара башладылар. Ярга чыккач, Мөдәррис машинаны Яшьләр үзәге каршындагы мәйданчыкка, судан бушап калган бассейн каршына борып туктатты.

— Инде без шушылай берничә көн буена бер үк нәрсәләр турында уйланып йөргәнбез икән, әйдәгез, тыныч та сөйләшеп алыйк.

Шулай дип, ул машинаның ишеген ачып куйды. Сул якта, елга ярындагы иңкүлектә, агачлар шәрәләнеп калган, саргайган яфраклар да анда-санда гына күренә. Уңдагы биек гөл түтәлләре кап-кара итеп казып ташланган. Өстән соры болыт юрганы күңелне басып тора, тирә-юнь ямансу иде. Бары тик Яшьләр үзәгенең күксел бетон бинасы янына утыртылган зәңгәр чыршылар гына, ел фасыллары белән исәпләшмичә, үзләренең гадәти төсен саклаган.

Зәйтүнә күптәннән инде үзенең шушындый аулаграк урында тукталып, кем белән булса да тыныч кына серләшмәгәнен уйлап куйды. Аның барлык борчулары караңгы бүлмәдә, урын өстендә, күзенә йокы кермичә, янында яткан иренең җиңелчә гырлавын һәм үзенең талчыккан аякларының гүләвен тыңлап ятканда кабат яңара.

Ә табигать шундый мәһабәт, тыныч һәм шушылай сулып барган чагында да күңелне иркенәйтеп җибәрерлек матур бит!

— Доктор Зәйтүнә, Зәйтүнә,— диде Мөдәррис, аңа таба борылып.— Сез кичерегез мине! Теге чакта үртәгәнем өчен гафу итегез!

Зәйтүнә аның үткен якты күзләренә тутырып карады. Әйе, бу кеше биредә тукталып, аны азга гына булса да тормыш ыгы-зыгысыннан аерып, бераз ял иттерергә уйлаган икән, сүзнең дә көтелмәгәнен һәм күңелгә җиңеллек китерә торганын әйтергә тиеш иде, әлбәттә...

— Сез хаклы, доктор, мин сезне үчекләргә тиеш түгел идем. Цехның һавасы зарарлы, бигрәк тә хатын-кыз өчен. Ләкин бит ул менә ничек килеп чыга. Бу шарларны ясау ысулын тапканчы, аның төгәл технологиясен булдырганчы, инженерлар мең төрле катлаулы мәсьәләләрне чишәргә тиеш булганнар. Латекс ныкбулсын, шул үк вакытта сузыла торган булсын. Әйберне тиз арада күпләп эшләп чыгарырлык ысул булсын. Арзанга да төшсен. Боларның һәммәсен хәл кылып бетергәнче, инженерлар үзләре ул сыек латекста еш кына баштанаяк коенып беткәннәр, билгеле. Сәламәтлегебезгә зыян килә дип тормаганнар. Аның зарары да кемнәрдер чирли башлагач кына беленә бит. Атом нурланышының зарары да Кюри-Склодовская сукырайгач кына беленгән.

— Һәр яхшылыкның бер начар ягы була димәкчеме әллә сез?

— Медицинадагы кебек инде. Һәр дару бер яктан шифа бирсә, икенче яктан зыян сала, диләр бит.

— Күпкә китсә.

— Күпкә китмәсә, сез аның зыянлы икәнен белми дә калыр идегез, шулай бит?

— Мин сезне аңладым,— диде Зәйтүнә.— Нәрсәнең дә булса зарарлы икәнлеген без зыян күргәч кенә беләбез.

— Хәзер, тулы заводларны эшләтә башлагач, үзгәртү кыен шул инде, — диде Мөдәррис. — Мин бу хакта күп баш ваттым, төрле заводларда да булдым. Без күргән чаралар гына файда бирми. Яңаларын уйлап табарга кирәк.

— Ә сез ул чаннарны каплап тора торган итегез.

— Башыгыз йомры икән! — Мөдәррис көлеп куйды.— Аннан хәл үзгәрми шул, капкач астында да элпә хасил була. Аны барыбер сыдырып алырга кирәк, шунсыз форманы манчый алмыйсың. Элпәне алганда газ аеруча көчле бүленеп чыга. Нәкъ шундый моментта, безгә үч иткәндәй, сез килеп, һаваның анализын аласыз да инде.

Ул күңелсез генә көлеп куйды.

— Ул элпәне машина сыдырсын соң, кеше якын килмәсен!

Мөдәррис машина ишеген япты.

— Рәхәт сезнең белән, доктор Зәйтүнә. Үземнең булачак рацтәкъдимемнең соавторы итеп алырга инде әллә үзегезне? Мин дә нәкъ шул хакта баш ватып йөрим бит. Ләкин аның бер кыенлыгы бар: чандагы сыеклыкның күләме, ягъни биеклеге үзгәреп тора.

— Үзгәрми торган итегез!

— Сезнең ирегез инженермы әллә?

— Нәкъ өстенә бастыгыз! — диде Зәйтүнә, көлеп.— Инженер. Тик башка өлкәдә эшли, теплицалар кора.

— Ну, ул инде гел зыянсыз ачышлар гына ясый торгандыр.

— Алай ук түгел шул. Элек андагы эшчеләр суыктан җәфалана иде, хәзер, теплица коргач, эсседән интегәләр.

— Менә күрдегезме? Һәрнәрсә ике яклы була шул... Хәзер кая барабыз?

— Сез мине тыңлап бетермәдегез бит әле. Динә безгә килсен иде. Киңәшләшергә, кararга, күзәтергә кирәк аны.

— Әгәр аңа сүз үтә торган булса икән! Сездән алда психиатрга җибәрер идем мин аны!

Каты итеп, болай да юка иреннәрен кысып әйтте моны Мөдәррис. Зәйтүнәнең җанына боз тиеп киткәндәй булды. Иренең бәгырен шушы хәтле катырыр өчен нишләргә тиеш икән хатын-кыз? Зәйтүнә Динәнең теге төнне кичергәннәрен хәтеренә китерде.

— Ул үз хатасы өчен җәзаның катысын алды инде,— диде.— Сез, ирләр, хатыннарның хәлен аңламыйсыз шул.

— Ә сез безнең хәлне аңлыйсызмы соң? — диде Мөдәррис, тавышын күтәреп. Янәшә утыргычтагы Зәйтүнә артка чайкалып куйды.

— Гафу итегез.— Мөдәррис эшләпәсен салып йомшак аксыл чәчен сыпыргалады. Аның маңгаенда кызарып калган эшләпә кырының эзе хәсрәт сызыгы булып тоела иде.— Кичерегез. Мин сезгә тагын кеше гаебен йөкли башладым бугай... Бәлки, барлык хатыннар да андый түгелдер. Бәлки, сез бөтенләй башкадыр...

Зәйтүнә, ишекне ачарга теләп, машина тоткасын тарткалады.

— Мин сезне илтеп куям,— дип, аның кулыннан каты итеп тотты Мөдәррис. Аның бармаклары калтырана иде.— Хәзер илтеп куям...

***

Алтынчәч кич укуга бармады. Болай да ул анда күңелен күтәрү өчен генә йөри иде. Аның инглизчә сөйләшүе кемгә кирәк хәзер?

Тел кайгысы калмады әле монда. Акушер-гинеколог аңа бүген үк хастаханәгә ятарга кушты. Кабинетыннан да чыгармыйча, ашыгыч ярдәм машинасы чакыртып утыртып җибәрмәкче иде. Андый чакта хатын-кыз табиблары күп сөйләшеп тормыйлар. Алтынчәч аннан көчкә котылды. «Юынмыйча кермим больницага,— диде.— Теләсә нишләтегез, бу килеш бармыйм. Анда бүген әйбәтләп юыну мөмкинлеге әллә була, әллә юк. Беләм мин больница хәлләрен». Табиб аннан язу яздырып алып калды: «Бүген үк профессор Ильясова клиникасына кереп ятарга сүз бирәм».

Коену бер сылтау гына иде, билгеле. Алтынчәчнең Мөһимәне күреп сөйләшәсе килә иде. Линардан берәр хәбәр юк микән? Ул больницада чакта, килеп, күзгә-башка чалынмый гына китеп бармасын тагын...

...Мөһимәнең тәрәзәсендә ут юк иде. Урамда көтеп йөрергә Алтынчәчнең сабырлыгы җитмәде, ул вокзал янындагы кибеттән әйләнеп чыгарга булды. Нәниләр өчен кирәк-ярак сатыла торган бүлек янында озак кына басып торды. Акушерлар кайбер әйберләрне алдан үк хәстәрләп, яңа булсалар да, юып-түгкләп куярга кушалар. Ләкин шул үк вакытта халык арасында ырым да бар. Алдан әйбер-кара әзерләп кую хәерлегә булмый, имеш. Дөрес түгелдер, бәби көткән кайсы хатын нәни күлмәк-башлыклар текмәгән дә, кайсысы гына аларга аллы-гөлле бизәкләр чикмәгән? Тик Алтынчәч кенә бу ләззәтле шөгыльдән үзен мәхрүм итә, ырымнарга ышанып үк җитмәсә дә, ә бәлки, туры килер дә,

соңыннан үкенермен, чигүле нәни күлмәкләр белән ачы күз яшьләре сөртергә туры килмәгәе, дип, юк-юк та шикләнеп куя. «Бала исән-сау туса, ялангач йөртмәм әле, лаборатория кызлары булса да әзерләп китерерләр»,— дип юатты ул үзен бу юлы да.

— Бик яхшы күлмәкләр бар менә, мондый җылы-йомшаклары ялан булып тормый, — диде аңа сатучы хатын.

— Куркам, — диде Алтынчәч.— Алдан әзерләргә кушмыйлар.

— Халык аңа карап тормый, әзерли. Үкенгән кешене күргән юк әле. Хәзер сабыйларны бик карыйлар бит. Исән калмаганы меңгә бер дә юктыр.

Алай да Алтынчәч әйбер-кара алмады. Сокланулы карашын нәни күлмәкләрдән аерып, ишеккә борылды.

Мөһимәнең уты кабынган иде. Өй эче бу юлы бөтенләй башкача булып күренде, тынчу, ташландык ис килә, ә корама япмалар ялгызлык, фәкыйрьлек билгесе булып тоела иде.

Мөһимәнең чырае да шактый караңгы иде. Дөрес, чәй куйды куюын, әмма хәл-әхвәл сорашмады, үз зарын түгәргә кереште. Йортка кергән улыннан, килененнән зарланды, хәзерге заман яшьләрен игелексез, мәнсез дип каргады.

Табын да шактый ярлы иде: чәй янына акмай белән сыр гына куелды. Алтынчәч Линар турында сүз кату өчен вакытның җайсызлыгын чамалый, Мөһимә исә энесен бөтенләй оныткан сыман кылана иде. Инде Алтынчәч ике чынаяк чәй эчеп бетерде. Хәлбуки аңа сыеклык эчүдән тыелырга кирәк, бер чынаяктан артыгын кабарга да ярамый иде. Аннары да шактый утырдылар, киленен каргый-каргый Мөһимәнең тамагы карлыкты. Ә кирәк темага алар бөтенләй якынлашмаганнар да иде әле. Мөһимә төсен җуйган халат төймәсен ялгыш эләктергән, шунлыктан изүе ямьсез җыерылып тора, чәче тузгыган, крем сөрткән симез бите майлы коймак кебек ялтырый иде.

Сорамаска кирәк иде Линар турында! Ләкин сорамый да булмый иде.

Китәргә дип кузгалгач, Алтынчәч, ниһаять, тәвәккәлләде:

— Линар кайчанрак килер икән?

— Белмим шул, бер дә бу арада гына килер сыман күренми. Ә хатлары килгән иде. Мине кунакка чакырганнар. Хатыны язган.

— Хатыны?!

— Ие шул, кайткан мөртәт. Тәмам башын катырды мескенемнең. Нихәл итәсең, асыл ирләрнең башын шундый аждаһа хатыннар ашый шул инде... Безнеке дә бернишли алмый, кызын бик ярата шул бәгырь парәсе. Ул юк җирдә ямь тапмый...

Мөһимә шундый итеп шартлатып сөйли, әйтерсең лә Алтынчәчне монда чакырып китереп Линар белән үзе таныштырмаган, әйтерсең лә хәзерге минутта кунагының кыяфәтен күрми, аның хәлен бөтенләй белми!

— Минем аның белән сөйләшәсем бар иде, — диде Алтынчәч.

— Бик сөйләшер идең дә, ничек күрерсең икән соң? Белмим шул инде, белмим. Бер килеп чыгар килүен дә, кайчан икәне генә билгесез. Хатка да язып булмый. Хатыны кулына эләксә, көн күрсәтмәс үзенә. И-и, юньсез хатын белән башын бәйләгән ир заты көн күрми шул инде ул!

Бусы инде кыеклап Алтынчәчкә дә бәрелгәндәй булды. «Чыннан да, мин хәзер үземне рәтле кешеләр рәтенә кертә аламмыни?» — дип уйлады ул, караңгы урамга чыккач. Трамвайда баручылар, урамдагы узгынчылар, хәтта багана башларындагы лампочкалар да аның начар хатын икәнлеген, кеше иреннән корсак күтәргәнен беләдер кебек тоелды.

Аның күршесе, арык, озын буйлы Нәкыя, соңгы вакытта гадәттәгедән дә катырак басып йөри, зур кулларында савыт-сабаны аеруча нык шалтырата иде. Баштарак ул күршесенең ир кеше белән танышуын хуплагандай күренгән иде. Әгәр дә Алтынчәч кияүгә чыгып куйса, бу тар, кысан бүлмәдә мәңге яшәмәсләр, ничек тә булса җайлырак фатир табу җаен карарлар, дип уйлаган иде ул. Ләкин егет айлар буе күренми торгач, ә Алтынчәчнең гәүдәсе күзгә күренеп калынайгач, күршенең мөнәсәбәте үзгәрде. Яшь балалы ялгыз хатын белән бер фатирда яшәү кемгә рәхәт?

Алтынчәч өстен алыштырды да урын өстенә ятты. Аның күршесен түгел, үз-үзен дә күрәсе килми иде.

Әгәр дә мондый хәлләр башка берәр кызның башына килсә, Алтынчәч, мөгаен, аны гаепләр иде. Үзенә тиң булмаган, хатынлы, балалы ир белән ничек шулай бозылып йөрү мөмкин? Башка кызны Алтынчәч гаепләр иде, ә үзен ул гаепләп кенә калмый, үз тәненә үзе нәфрәтләнә!

Яратмый иде бит ул Линарны! Алар арасында ул күз алдына китергән, ул көткән мәхәббәт кабынырга вакыт та булмады, булса да, Линар кебек ярлы күңелле, бар хыялы — ишегалдына биек багана бастырып куеп, аның башына урам лампасы асу булган, Экзюперины аңламый торган, хәтта рәтле анекдоттан көлә дә белмәгән адәмне ярату мөмкинмени?

Нигә соң Алтынчәч аның белән очрашты? Очрашкач та беренче карауда кемлеген танымады? Ярый, анысы шулай да булсын ди. Бер тапкыр очрашып, ялгышканын аңлагач, нигә соң ул аның белән тагын күрешергә риза булды, нигә?

Менә шушы тәне, кайнар тәне аның ихтыярына буйсынмады. Кирәкми, очрашырга бармыйм дияргә тиешле иреннәр акылны тыңламадылар, дәшми калдылар; куллар, Линарны читкә этәрәсе урынга, аның учында йомарланып назландылар, иреннәре аның каты иреннәренә кысылып сызлануны түземсезлек белән көттеләр. Аның тәне Линар кочагында эреп бетәргә һәм шул минутта юкка чыгарга риза иде.

Әгәр моңарчы кем дә булса Алтынчәчкә мондый хәлнең — тән белән рухның бер-берсенә каршы халәттә булуын сөйләсә, ул ышанмас иде. Моңа ышану мөмкин түгел. Кеше болай бер төрле уйлап, бөтенләй икенче төрле яши алмый!

Акылга буйсынмаганы өчен, зиһенне томалап ләззәт ялкынында янганы өчен күрәлмый Алтынчәч үзен. Аның тәне мондый гөнаһ белән җирдә яшәргә хаклы түгел. Ләкин ул хәзер чиста, гөнаһсыз бер җанга кабык булып хезмәт итә. Фәкать шушы мөһим вазифаны үтәр өчен генә яшәргә хакы бар аның бу якты дөньяда...

Менә ул гөнаһсыз җан иясе — тәнне тибрәндереп тибенә. Алтынчәчнең иреннәрен елмаерга мәҗбүр итә, күңелне баскан ташның авырлыгын оныттыра. Ул кыз булыр, әнисеннән сафрак яшәр. Кызы сәламәт булсын, бәхетле үссен өчен, беркайчан да мондый газапларга дучар булмасын өчен бөтенесен эшләр Алтынчәч.

Иртүк профессор Ильясова янына барыр ул.

***

Иртәнге рапорт вакытында Фидая Галимовна кесәсеннән хат чыгарып Зәйтүнәгә бирде. Адресы ят кул белән язылган, фамилиясе куелмаган. Табибларга сирәк кенә булса да рәхмәт хатлары килгәли. Зәйтүнә конверттагы штемпельгә күз төшерде: хат Казаннан иде. Ул, рапорттан соң ачып укырмын дип, аны халат кесәсенә салды.

Бүген Вафина Алтынчәч дигән хатын турында шактый озак сүз булды. Утыз биш яшендә буйга узган, йөклелеге егерме тугыз атна. Хәзер токсикозның авыр формасы белән ята. Врачларның киңәш-үгетләренә сүзе һаман бер: «Баланың исән тууына җавап бирә аласызмы?» Андый гарантияне мондый очракта Ходай Тәгалә үзе бирсә генә инде!

Доктор Нигъмәтуллина, аягүрә басып, бу авыруның канындагы үзгәрешләр һәм дәвалауның барышы хакында бәйнә-бәйнә сөйләп бирде. Сүзе нигезле, төгәл, ышанычлы иде. Аны тыңлаганда профессор Ильясованың карашында хуплау чагылды.

— Вафина янына ире килә калса, әйтерсез әле, — диде ул.

— Аның янына ир-ат килгәне юк, диләр...— диде Резеда Фәритовна.

Лариса, утырган урыннан калкына төшеп:

— Җәмилә Закировна! Хәтерлисез микән, теге чакта, завод поликлиникасында прием алып барганда, сез аның хәлен сораштырган идегез. Ялгыз икәнлеге билгеле иде бит.

— Хәтерлим. Ләкин аннан соң шактый вакыт узды бит инде. Ә бәлки, ир кешенең намусы уянып, туачак баласы белән кызыксына башлагандыр. Төрле хәлләр була. Очрашып, үгетләп карасак, зыян итмәс иде.

— Монысы куып та тота торган түгелдер, ахрысы. Вафина моны бик авыр кичерә, күңеле ифрат төшенке, шунлыктан дәвалау тиешле нәтиҗәне бирми дә инде.

— Әйе, тискәре кичерешләр, күңел төшенкелеге дәвалауны кыенлаштыра,— дип, Ларисаның сүзен хуплады профессор.— Бүгенге әңгәмәнең темасы да шушы булыр.

Җәмилә Закировна һәр чәршәмбе көнне иртәнге рапорттан соң ярты сәгатьлек әңгәмә үткәрә.

— Беркемнең дә тормышы тигез генә бармый, һәркемнең башыннан төрле хәлләр уза, — дип дәвам итте ул сүзен. —Кәефсезләнү, чамадан тыш ару-талу, кайгы-хәсрәт, көнләшү организмга бик авыр йөк булып төшә.

Зәйтүнә уң ягында утырган Ларисага борылып карады. Лариса, дикъкатен профессорга юнәлтергә тырышып, күзләрен зур ачкан, әмма керфекләре авыраеп, әледән-әле йомылалар, Җәмилә Закировнаның сүзләре аның зиһененә барып җитә алмый иде. Аның тонык күзләре Сөембикә апаның банкаларда асрый торган бакаларын хәтерләтте. Бу чагыштырудан Зәйтүнә үзе сискәнеп куйды: «Нишләвем бу? Ни өчен бу кадәр яратмый башладым әле мин аны? Эше уңышлы барганга көнләшәм түгелме?»

— Бервакыт Әбугалисина мондый тәжрибә ясаган, — дип сөйли иде профессор, — ике кәҗәне ике абзарга бикләп, берсенең каршына, почмакка бүре кертеп бәйләп куйган. Шуннан соң ике кәҗәне дә бертигез ашаткан, тәрбияләгән. Буш абзардагы кәҗә күзгә күренеп көрәя барган, ә менә каршысында бүре торганы тиз арада ябыккан, хәлсезләнгән, озак та узмый, егылып җан биргән. Йөрәкне яндырып, бәгырьне талаган кайгы-сагыш, ярсулар кешегә нәкъ менә шул каршысында тешен шыгырдатып басып торган бүре кебек тәэсир итә дә инде... Андый чакта канга күп микъдарда адреналин бүленеп чыга.

Зәйтүнә янә Ларисага карады. Тәмам оеп-оеп китә теге, төнен йокысыз уздырган, ахрысы. «Менә мин аңа карадым да канына адреналин бүленеп чыкты инде», — дип уйлады Зәйтүнә.

— Тискәре эмоцияләр никадәр көчле булса, аларның зыяны да шулкадәр зуррак. Шуңа күрә үз-үзеңне тыярга, кайгы-хәсрәткә бирешмәскә кирәк. Тыгызлап ябып су кайнатсаң, чуен казан да шартлый. Халыкта «Ачуымнан шартлый яздым» дигән сүз бар. Тәмам шартламау өчен төрле кеше төрле чара куллана. Кайберәүләр кешеләрдән үч алып, башкаларны борчуга, хәсрәткә, газапка салып, үз күңелен бушата.

Зәйтүнә кызарынып чыкканын тойды. Соңгы сүзләрен профессор махсус аңа төбәп әйтте кебек. Ул да Ларисага ачуланып, үз борчуларын җиңеләйтергә маташа түгелме?

— Кайгы-хәсрәт килгәндә, күңел сызланганда нишләргә соң? — дип, тыңлаучыларга күз йөртеп чыкты Җәмилә Закировна. Җавап көткәндәй бераз тынып торды да: — Иң элек хәрәкәтләнү җаен табарга кирәк, — дип дәвам итте. — Саф һавада йөреп керсәң, баскычтан йөгереп менеп төшсәң, кеше арасында айкалсаң, йөрәк тынычлана төшә. Борынгыдан халык моны аңлаган, кешеләргә күрсәтми генә, мендәренә капланып елаган кызларны гаепләмәгән. Кайчакта елап алу да файдалы.

Лариса сискәнеп тураеп китте, авыр керфекләрен күтәреп, профессорның йөзенә текәлде.

— Ачулану, күңел сызлану гомерне кыскарта, — дип сүзен йомгаклады Җәмилә Закировна. — Сөенеч, шатлыклар, ихлас күңелдән көлү сәламәтлекне ныгыта. Җыр-бию, матур картиналар карау, дәртле-моңлы көй-җырлар тыңлау, башкалар кылган яхшылыкка сокланы күңел яраларына шифа бирә.

«Көлү шифалы, димәк, — дип уйлады Зәйтүнә. — Менә мин, Әнвәр соң кайтты дип тавыш куптармыйм, аның күңелен җәрәхәтләүдән тыелам. Елмаеп-көлеп каршы алган чаклар да була. Ләкин күңел сызлануының аннан гына җиңеләйгәне юк шул».

Ашыкмый гына таралыша башладылар. Җәмилә Закировна тудыру бүлегенә, Вафина янына менеп китте. Лариса Зәйтүнәгә иярде:

— Синең палатада бер хатын токсикоз белән ята, шуны икәү бергә карыйк әле.

Алар коридор буйлап янәшә атлап киттеләр.

— Фән өлкәсендә талантлы безнең профессор, ләкин тормыш мәсьәләләрендә арттарак калып бара, бигрәк беркатлы,— диде Лариса. — Хәзерге чор кешесе кәҗә түгел, бүре белән дә куркыта алмыйсың! Әрсезләр заманы бу. Шәһәр кешесе өендә әрлән асрый, белә ул үзенең кемгә охшаганын!

Нишләптер аның һәр сүзе Зәйтүнәнең ачуын кабарта иде. Ләкин ул бу халәтен сиздермәскә тырышты. Эчтән гасабиланып кулын халат кесәсенә тыкты һәм андагы кәгазьне йомарлады. Нәрсә бу? Ә-ә, хат! Иртән хат бирделәр бит, ә ул аны һаман укымаган. Ул туктап конвертны ертты. Лариса аның җилкәсе аша кәгазьгә күз салды:

— Менә хәзер синең гомерең озая инде. Рәхмәт хаты укыйсың бит.

«Кадерле Зәйтүнә Мәҗитовна! — дип язылган иде почмагына чәчәк төшкән ак кәгазь битенә кара каләм белән. — Без, элекке авыруларыгыз, хәзер инде сәламәт хатыннар, сезгә мең рәхмәтләр укыйбыз».

— Әйттем ич! — дип, Лариса алгарак китте. Аның өчен хатның кызыгы беткән иде инде. Ә анда, тагын берничә врачка һәм шәфкать туташларына рәхмәт сүзләреннән соң: «Сез кешеләргә зур яхшылыклар эшлисез, без сезнең үзегезнең дә бәхетле булуыгызны, тигез-имин яшәвегезне телибез,— диелгән иде.— Шушы хис безне кулыбызга каләм алырга этәрде дә инде».

Зәйтүнәнең күңеле сыза башлады. Профессорның киңәшләре бүген үк кирәк булмагае!

«Сезнең гаиләгезнең иминлеген чагарга агулы угын сузган зәһәр елан шуыша, Зәйтүнә Мәҗитовна! Сезгә мәңге төзәлмәслек йөрәк ярасы салырга, балагызны әтисез, сезне бәхетсез итәргә килә ул елан. Уяу булыгыз, ирегезне ул еланнан коткарыгыз! Ә сез беркатлылыгыз белән аны һаман үз яныгызга сыендырасыз. Ничек инде сез, башкаларның сызлануына шулкадәр сизгер була торып, үзегезгә янаган куркынычны сизмисез? Инде һаман да белә алмасагыз, без аның инициалларын куябыз: ЛСН». «Лариса Сөнгатовна Нигъмәтуллина,— дип өстәде Зәйтүнә үзеннән.— Мине чыннан да белми дип уйлыйлар микәнни?»

— Әйдә инде, рәхмәт сүзеннән хәлең киттеме әллә? — диде коридорның аргы башында, баскыч астындагы караңгылыкта туктаган Лариса.

«Йөрәгемә кан сауды», — дип кем беренче әйтте икән? Сез хаклы түгел, Җәмилә Закировна, канга адреналин бүленеп чыгу гына түгел бу, — нәрсә ул адреналин! — бу нәкъ менә йөрәккә кан саву. Нинди киңәшләр бирдегез әле сез бүген, шөһрәтле профессор иптәш? Нишләргә тиеш инде Зәйтүнә шушы минутта? Икенче катка йөгереп менеп төшәргәме? Ләкин аякларның атлар хәле юк. Җырлап җибәрергәме? Ләкин тамактан тавыш чыгарлык түгел, төер тыгылган. Мендәр почмагын тешләп, тавышсыз гына еларгамы? Ләкин күздә — яшь, янда мендәр юк. Ах, Җәмилә Закировна, сез сөйләгәндә һәммәсе шулкадәр аңлаешлы иде, үз башыңа төшкәч, бер чарасыз каласың икән лә!

Ярый әле коридорның бу башында тәрәзә юк, баскыч астыннан узганда, йөзнең агарып катканы күренми, тез буыннарының йомшаганы сизелми.

— Чынлап торып ярдәм күргән кеше рәхмәтне сирәк әйтә ул,— диде Лариса аны көтеп алгач.— Хасталар сәер халык, сихәтләнсә, мин врачсыз да терелер идем дип исәпли, дәвалауның файдасы тимәсә, врачлар ялгыш дару биргән дип уйлый. Беләсеңме, бер онколог миңа нәрсә сөйләде? Күкрәгенә операция ясатып рактан котылган бер хатын аңа бәйрәм саен открытка җибәреп тора икән. Һаман бертөрле сүз яза, ди: «Миндә бернинди рак булмаган, сез миңа операцияне ялгыш ясадыгыз, мине гомерлеккә имгәтеп калдырдыгыз. Ачы каргышым төшсен сезгә!» Ун ел буе шундый открытка алып кара әле син! Яңа елга да, 8 Мартка да, Май бәйрәменә дә. Әгәр теге врач операция ясап интекмәгән булса, үз башына мондый каргыш алмаган булыр иде.

— Чөнки ул хатын күптән кабердә булыр иде инде, — диде Зәйтүнә.

— Анысы инде хатынның үз эше.

— Ул врач андый открытканы алган саен куанырга тиеш. Рактан котылган пациентың ун елдан артык яшәсен әле! Үзен сау-сәламәт хис итеп! Бу үзе зур бәхет ич!

«Минем белән күзгә-күз карашып тынып калмас өчен шушылай такылдый бит бу, — дип уйлады үзе Лариса турында.

— Ништяк! Сине өзми-куймый каргасыннар да, бәхетле бул, имеш!

— Зәйтүнә Мәҗитовна,— дип кычкырды коридорның аргы башыннан шәфкать туташы Анна Ивановна.— Сезне сорыйлар!

Аның янында кызыл күлмәкле хатын-кыз күренде. Ул, башын кырын салыбрак, елмаеп басып тора иде. Зәйтүнә ерактан ук аның ике чигәсеннән сузылып киткән көмеш тасмаларны күреп алды.

— Сагындыгызмы? Тагын кунакка килдем менә. Чакырылмаган кунак шушындый була ул!

— Әле үзем чакырырга тора идем, — диде Зәйтүнә.

— Күңелем сизгән икән.

Динә Зәйтүнәгә түгел, аның җилкәсе аша караган; иреннәре елмаерга тырыша, әмма түгәрәкләнеп килгән күзләрендә кисәтүле сагаю чагыла иде. Ларисадан шикләнә, аның алдында сөйләшәсе килми иде аның.

— Лариса Сөнгатовна, гафу итегез, без теге авыруны соңрак карарбыз инде, — диде Зәйтүнә, башын артка бора төшебрәк. Ул авыру яныннан үзенең коллегасын куа, бу деонтологиягә — табибларның һәм авыруларның үзара мөгамәлә кагыйдәләренә берничек тә сыймый иде. Коллегаңны авыру каршында кимсетү иде бу! Зәйтүнә эчке бер үчләнү белән Ларисаның күзләрендә кабынган гажәпләнүне күзәтте.

— Авыру белән икәүдән-икәү генә сөйләшәсе сүзебез бар,— дип кабатлады Зәйтүнә.

— Менә ничек! Сер, димәк!

— Сер!

Һәм Зәйтүнә аңа аркасы белән борылды.

— Мин направление белән килдем, — диде Динә. Һәм Зәйтүнәгә кәгазь кисәге сузды. Учка сыярлык бу кәгазьгә хәтәр сүз язылган: участок врачы Динәдән шеш тапкан икән. Зәйтүнәнең аяк астында идән чайкалып киткәндәй булды.

...Бераздан, Динәне кабинетка алып кереп карагач, ул участок врачында мондый шик тууга сәбәп барлыгына ышанган иде инде. Алай да Динәгә үзенең хафалануын сиздермәскә, көр күңелле булып күренергә тырышты.

— Хәзер өстегезне алыштырыгыз да, палатага кереп, тыныч кына ял итегез. Анализлар алырбыз, мин сезне бүген үк профессорга күрсәтергә тырышырмын. Аннары нишләргә икәнен хәл кылырбыз.

Тизрәк Җәмилә Закировнаны табарга кирәк иде, китеп баруы ихтимал. Зәйтүнә тудыру бүлегенә юнәлде. Коридорда аңа Сөембикә апа очрады.

— Сөембикә апа, бишенче палатадан Хәйруллинага анализ ясагыз әле, — диде Зәйтүнә. Мондый анализ ясау Динәгә бөтенләй кирәк тә түгелдер, бәлки, Зәйтүнә моны ничектер үзе дә сизмәстән әйтеп ташлады.

— Минем гөберчәкләрем пионерлар кебек һәрвакыт әзер,— диде Сөембикә апа, алтын тешен елтыратып.

Зәйтүнә тудыру бүлегенә кергәндә, каршысына ак халатлы ике кыз килеп чыкты. Икесе дә, терсәкләрен бөгеп, озынча төргәкләр тотканнар. Яңа туган сабыйларны балалар бүлегенә илтүче акушеркалар иде болар. Зәйтүнә аларга юл биреп, диварга елышты. Мондый хәлне күп күргән булса да, гаять мөһим вакыйганың шаһиты булганын тоеп басып торды.

Менә тагын җирдә ике кешенең гомер юлы сызыла башлады. Тын, буш коридорда басып торган Зәйтүнәдән башка һичкем бу бөек вакыйганы күрмәде. Шулай да акушеркалар, меңнәрнең карашын тойгандай, башларын югары тотып атлыйлар, чөнки үзләре башкарган вазифаның зурлыгын аңлыйлар иде.

Без гомер юлыбызның башын да, ахырын да кеше кулларында узабыз. Әйе, адәм баласы үзенең гомерен башкалар кулында башлый, башкалар кулында тәмамлый.

Никадәр мәрхәмәтле, рәхим-шәфкатьле булырга тиеш без бер-беребезгә!

***

Балаларны имезергә иркен арбалар белән тараталар. Аларга, бер-берсенә терәп, озынча саргылт төргәкләр тезелгән. Күбесе тавыш-тынсыз, хәрәкәтсез, кайсылары кыймылдый, шыңшый, сирәге кычкырып елый.

Кайберәүләр яңа туган сабыйларның һәммәсе бертөсле буладыр дип уйлый. Ләкин бу һич тә алай түгел. Туганда ук һәр адәм баласының үз кыяфәте, үз холкы. Берсе чырылдап елый, икенчесе калын тавыш белән таләпчән итеп кычкыра, өченчесе пых-пых итеп кыймылдый, ләкин еламый. Кайсының бите озынча, кайсының түгәрәк. Кайсы кара керфекле, кайсының керфеге бөтенләй юк. Берсенең өске ирене чыгыбрак тора, икенчесенең аскы ирене бүлтәйгән. Чагыштырып карасаң, күбесендә ата-анасының чалымнары ярылып ята.

Ә читтәге берсенең, иң кечкенәсенең, ниндилеген белеп булмый, чөнки бите чүпрәк почмагы белән капланган.

— Нишләп болай капладыгыз? — дип сорады Алтынчәч балаларны өләшеп йөрүче яшь кенә шәфкать туташыннан.

— Ул иртәрәк туган, — диде кыз, йомшак кына итеп. Әйе, «җитлекми туган» димәде, йомшартып, «иртәрәк туган» дип әйтте.

Алтынчәч, башкалардан аерылып торган ул төргәккә тетрәнеп карады. Юк-юк, аның сабые, аның кызчыгы, аның Газизәсе мондый булып тумас! Әнә, кашлары сызылып киткән, керфекләре тырпайган, калын тавыш белән кычкыра торган зур кызыл авызлы бала кебек булыр ул! Әйе, шундый җитлеккән, хәрәкәтчән, таләпчән булыр, томрап торыр аның баласы. Ана карынында тиешенчә яткан, җитлеккән балалар гына каш-керфек, тырнак белән, куе чәч белән туа. Алтынчәчнең сабые шундый булыр.

Менә шушындый... Алтынчәч түшенә «35» ле клеенка кисәге тагылган сабыйга озаклап карап тора, кырыйдагы бите ябулы төргәккә ялгыш кына да күз төшерүдән саклана. Менә шәфкать туташы, ике кулына ике төргәкне алып, палатага кереп китте. Ачык ишек аша Алтынчәч аның караватта янтаеп күтәрелгән хатынга баланы биргәнен карап торды. Хатын битлекле, әмма ак, шома маңгаеннан, күзләреннән үк бик яшь икәнлеге күренеп тора. Ул сабыен мендәргә җәелгән клеенкага салды да, халатының изүен ачты, йомры күкрәгенең уртасында күгелҗемләнеп торган төймәне сабый авызына китерде. Алтынчәч, бала иреннәренең үз күкрәгенә орынганын тойгандай, татлы бер хистән күзләрен йомды.

— Сез нишләп һаман монда йөрисез? — дигән тавышка сискәнеп күзен ачты ул. Шәфкать туташы, бүлмәдән чыгып, икенче сабыйларны алырга үрелгән иде. — Барыгыз, үз палатагызга кереп ятыгыз!

Алтынчәч теләр-теләмәс кенә үз бүлмәсенә таба борылды. Тирә якта өч сәгать саен кабатланып тора торган илаһи тынлык урнашкан иде. Бу тынлык зур мәгънәгә ия, олы бер тантана булып яңгырый иде шикелле: әниләр бәбиләрен имезәләр иде.

Алтынчәч, палатасына кереп, караватына утырды да мендәрен сыйпады. Аның мендәрендә дә беркөнне гомеренең саф, бәхетле дәвамы ятачак. Алтынчәч аңа гади һәм халыкчан, олы мәгънәле һәм бала чакта да, олыгайгач та килешә торган, матур яңгырашлы исем кушар — Газизә дип атар. Беркайчан да, беркемнән дә ул исемне бозып әйттермәс, ул исемне ишетүгә һичкем сәерсенеп көлемсерәмәс.

Аның шушы уйларын раслагандай, карынындагы баласы тибенә башлады.

Табиблар:

— Балаңның йөрәк тибеше бик ачык ишетелә, — дип мактыйлар, тик менә аның малаймы-кызмы икәнен генә ачык итеп әйтмиләр. Хәер, алар каян белсен? Алтынчәч үзе белә, үзе кыз булуын тели!

Табиблар аның өчен нык борчылалар, төрле хәл булуы ихтимал дип уйлыйлар. Йөгеннән алдан котылдырырга тәкъдим итәләр, югыйсә исән калуың икеле, диләр. Алтынчәчнең бу хакта ишетәсе дә килми. Врачларның ялгышкан чаклары азмыни? Борчылулары юккадыр әле. Әнә озын кичләрне хатыннар ниләр генә сөйләми! Бар төрле бәхетсезлек Алтынчәчкә генә килмәс бит инде! Шәфкать туташы биргән даруларны эчә, табибларның күз алдында ята. Кәефе начар түгел, бер җире дә сызламый, башы әйләнгән чак сирәк. Ә йөрәк кагу, тын бетү, аяклар җилсенү ишесе мондый чакта күпләрдә була.

Алтынчәч урынында утыра алмады, аяклары иреке здән аны коридорга алып чыкты. Шәфкать туташы балаларны кире палаталардан алып чыгып арбага тезеп сала иде. Тынлыкны бер ачы итеп елаган сабый тавышы ярып үтте. Палата ишекләрендә әниләр күренде.

— Утыз бишенче, тагын шул утыз бишенче, — диештеләр алар. Берсе, бая Алтынчәч игътибар иткән шома маңгайлы яшь әнигә карап:

— Балаңның тамагы туймый бит! — дип куйды.

— Ни-ишләп? Туктаусыз суыра бит үзе!

— Ә йотамы соң? Йотамы?

— Аның йотканын-йотмаганын каян беләсең?

— Сөтең җитмидер синең!

Хатыннар, яшь әнине әйләндереп алып, һәркайсы үз киңәшен бирергә кереште.

«Мин мондый булмам, — дип уйлады Алтынчәч, — күп итеп сөт эчәрмен, Газизәмне туйганчы имезермен!»

Тудыру бүлегенә беркемне дә кертмиләр. Фәкать Алтынчәчкә генә бер-ике тапкыр бергә эшләүче кызлар белән очрашып сөйләшергә мөмкинлек бирелде.

Менә бүген дә, балаларны алып киткәч, аны өлкән шәфкать туташы бүлмәсенә чакырдылар. Анда ак халат кигән Мөһимә басып тора иде. Ул Алтынчәчкә күчтәнәч тутырылган полиэтилен капчык сузып:

— Исәнме, ни хәлләрең бар? — диде.

Алтынчәч аңа яшерен өмет белән текәлде, әмма Мөһимәнең кечкенә күзләре туры карамый, читкә төбәлгән иде. Алар янәшә урындыкларга утырдылар. Алтынчәч, соңгы баруында кимсенгәнен исендә тотып, Линар хакында туры бәреп сораудан тыела, ә шуннан башка Мөһимә белән сөйләшер сүз юк иде. Апакайның исә теле тик тормый, тегене-моны сораша. Аннары ул Алтынчәчкә якыная төште дә, сулышын өреп:

— Үз кызым кебек якын бит син миңа,— дип куйды.— Күңелдән бер дә чыкмыйсың. Әле менә врачлар белән дә сөйләштем. Алар әйтә, безнең киңәшне тыңламый, һаман үз туксаны туксан, соңрак ул-бу хәл килеп чыкса, без аның исәнлеге өчен җавап бирә алмаячакбыз, диләр. Ник карышасың, Алтынчәч? Алар галим кешеләр, белми әйтмәсләр. Гомерле булып туса, балаң да яшәр...

— Минем хәлем әйбәт, — диде Алтынчәч салкын гына. Аның эче поша башлаган иде. Бу хатын шул сүзне тәкрарлар өчен генә килде микәнни соң монда? — Бер дә курыкмасыннар, мин үзем өчен үзем җавап бирәм.

— Токсикоз бик астыртын нәрсә, ди профессор. Аның кайчан аяктан егасын без дә әйтә алмыйбыз, кеше үзе дә белми, ди.

— Беләләр. Көн саен тикшереп торалар.

Алтынчәч кузгала башлады.

— Туктале,— диде Мөһимә.— Эх, мин үзем дә ана кеше бит, йөрәк түрләремнән китмисең. Әйтергә дә кирәкмәстер инде, шулай да күңелем түзми: Линар килә бит, Алтынчәч! Тагын заводыннан командировка биргәннәр. Киңәшәсең килә иде бугай... Тик монда, больниска керергә җае булырмы, анысын гына әйтә алмыйм. Эш кешесе бит. Бергәләп тагын бер тапкыр уйлашсагыз, начар булмас иде диюем. Күрешә-нитә калсагыз, минем әйткәнне аңа җиткермәссең инде, яме!

— Рәхмәт, Мөһимә апа,— диде Алтынчәч, аның кулына орынып.

Ул шундук бөтен үпкә-сапкаларын оныткан иде инде.

Линар килә, димәк. Бик яхшы. Дөрес, хәзер ул Алтынчәчтән читләшә, араларны бөтенләй өзәргә үк ниятли булса кирәк. Ләкин баланың атасы бит ул! Тегендәге кызын ярата, димәк, бала җанлы, бусын да бөтенләй үк чит итмәс, шәт. Әгәр Алтынчәч белән чыннан да бер-бер хәл була калса, сабыйны ташламас, ятим итмәс. Кайсы яктан гына уйласаң да, балага әти кирәк, исем өчен генә булса да.

— Кайчан килә соң ул?

— Бүген кичкә көтәм, — диде Мөһимә, бу сүзне ник башлаганына үкенгәндәй итеп.

— Алайса китми тор әле, мин хәзер үк синең белән чыгам. Няня китеп өлгергән булса, киемсалымны алып булмас, шушы халат белән кайтырга туры килер. Син миңа плащыңны биреп торырсың бит?

— Ай Алла! Кая шулкадәр кабаланасың? Бүген үк кире китмәс әле. Иртәгә чыксаң да соң булмас!

Алтынчәч аны тыңлап тормыйча бүлмәдән чыгып китте. Коридордан борчулы кыяфәт белән Резеда Фәритовна узып бара иде. Ул бераз вакыт зиһенен туплый алмады, Алтынчәчнең әйткәнен аңламыйча торды.

— Алай җиңел генә хәл кыла торган мәсьәлә түгел бу, Вафина, — диде, ниһаять. — Сезне врач күзәтүе астыннан чыгарырга ярамый, аңлагыз шуны!

— Мин хәзер расписка бирәм. Кешене больниста көчләп тотарга дигән закон юк лабаса!

Алтынчәчнең ныклы гасабиланганын, теләсә нинди тәвәккәллеккә әзер икәнлеген күреп, Резеда Фәритовна аның тупаслыгын үткәреп җибәрде, киресенчә, йомшарып китте.

— Бу чорда сиңа тыныч лык кирәк. Болай ярсыган хәлдә кеше арасында болганып йөрү — баланы да, үзеңне дә куркыныч астына кую дигән сүз ул. Әйдә, без болай итик: иртәгә иртән хәлең ничек булыр, яхшылап карарбыз, яңадан бер тапкыр анализлар алырбыз, нинди очракта нишләргә икәнен аңлатырбыз, тиешле даруларны бирербез, шуннан соң хәл итәрбез. Ә хәзер тыныч ланыгыз, әйбәтләп йоклагыз. Әгәр хәзер чыгарып җибәрсәк, җаваплылык барыбер безнең өскә төшәчәк! Аңлагыз шуны!

Ул борылып киткән иде, Алтынчәч аның артыннан иярде.

— Ә сез сүзегездә торырсызмы? Иртәгә чыгарырсызмы мине?

— Анализларыгыз нормаль булса, мин ярдәм итәргә тырышырмын.

Алтынчәч, шуннан артыгына ирешә алмаячагын аңлап, кире борылды. Аның хәзер генә чыга алмаячагын белгәч, Мөһимә дә, җиңел сулап, саубуллашырга ашыкты.

***

Профессор бүлмәсендә республиканың баш акушер-гинекологы утыра иде. Мәскәү өчен отчетлар әзерли, юл уңаеннан киңәшеп чыгарга дип кергән. Гадәттә, алар институтта очраша торган иделәр, бу юлы Талия Гафаровнаның бирегә килүе Ильясованы бераз сагайтты.

Шикләнүе юкка булмаган икән. Талия Гафаровна стенадагы ана белән бала сурәтенә карап авыр сулап куйды. Чал чәче, сулган йөзе аны үз яшеннән өлкәнәйтебрәк күрсәтә, шуңа күрә һәм урыны да югары булганга, үзеннән өлкәнрәк профессорга чак кына өстәнрәк карый иде ул.

— Әйтәсе килми килүен дә, әйтмичә дә булмый, Җәмилә Закировна. Мәскәү сезнең кандидатураны һаман расламады бит әле.

Чыннан да, гыйльми советның профессор Ильясованы яңадан кафедра мөдире итеп сайлаганына шактый вакыт узды инде, Мәскәүдән исә раслау кәгазенең әлегәчә килгәне юк. Шулай да Җәмилә Закировна борчылмый, чөнки моңа нинди дә булса җитди сәбәп бардыр дип уйламый иде.

— Җитәкчеләрнең эше күп була, җитешә алмыйлардыр,— диде ул, җиңелчә генә.

— Сезнең өстән жалоба ята анда, Җәмилә Закировна. Бик озын һәм җитди жалоба.

— Мөгаен, анонимкадыр инде.

— Юк, анонимка түгел. Авторы кулын куйган.

«Дәүләтшин...» — дип нечкә генә бер тамыр сулкылдап куйды Ильясованың күңел түрендә. Тик бу исемне кычкырып әйтергә теле тибрәлмәде. Остазына кул күтәргән шәкерт... Мөмкинме бу?

— Дәүләтшин, — диде Талия Гафаровна.

Җәмилә Закировна җылытырга теләгәндәй итеп кулларын угалады.

— Миңа шундый зур үпкәсе бар микәнни?

— Кафедрада яшьләргә үсәргә мөмкинлек юк, чөнки Ильясова берәүне дә үзеннән уздырырга теләми, дигән. Яшьләр аннан китә, дип мисаллар китергән. Үзен... Мине...

— Сезне дәмени?

Заманында Талия Гафаровна шушы кафедрада аспирантура тәмамлаган иде. Ләкин диссертациясен тиз арада гына яклый алмады, чөнки кияүгә чыкты, бала тапты, аварияга эләккәннән соң өч ел авырып урын өстендә яткан ирен кәрарга-тәрбияләргә тиеш булды. Фатирны аларга Ленин районыннан биргәннәр иде, Талия Гафаровнага өенә якынрак урынга эшкә күчәргә туры килде. Еллар узып, баласы үскәч һәм ире дә ныгып аякка баскач, аның фәнни эшкә дәрте сүрелгән иде инде. «Язу-сызудан болай да тәмам гарык, кәгазьдән күзне күтәреп авыруның үзенә кәрарга вакыт бик аз кала», — ди ул. Табибларның күп вакытын язу ала шул, нишлисең. Өстәвенә хатын-кызның күп көчен йорт мәшәкатьләре суыра. Дөрес, Талия Гафаровна уңган һәм кешелекле табиб, югалып калмады, диссертациясен соңлап булса да яклады, зур дәрәҗәгә иреште.

Хәзер менә аның, шундый зур мөмкинлекләре булган талантлы белгечнең, теге вакытта кафедрадан ник киткәнен мәскәүләргә аңлатып кара син!

— Үземә кагылган кадәресенә мин үзем җавап бирермен бирүен, — дип дәвам итте Талия Гафаровна.— Ә менә Дәүләтшин, Ильясова озак вакытлар буе мине эзәрлекли, дип бара. Авторитетымны төшерер өчен, минем авыруларны үзенә ала, дип язган, Ахунова фамилиясен телгә алган.

— Анысы хак. Ахунованы мин аннан алдым.

— Сез алай димәгез инде, Җәмилә Закировна! Мәскәүдә Дәүләтшин турында бик яхшы фикердә торалар. Белгеч буларак та мактыйлар, сүзе дә үтә.

Ильясова Мәскәүдәге очрашуларны күз алдына китерде дә ачы көлемсерәде:

— Беләм, беләм...

— Көлмәгез әле сез, Җәмилә Закировна!.. Бу хатка ничек җавап бирәсен бик җитди итеп, төптән уйларга кирәк. Анда әле кафедраның клиникасында тәртип юк, тиешле булмаган кешеләрне койкага яткыру очраклары бар, диелгән. Анысы чеп-чи ялган, мөгаен.

— Ю-ук, Изаил Харисович бер дә булмаганны язмас! — Ильясова янә көлемсерәп башын чайкады. — Аны алай ансат кына каптырып булмас. Тикшереп кәрарга кирәк.

— Җәмилә Закировна! Сез ни сөйлисез?!

Профессор Ильясованың бу рәвешле үз-үзен үчекләгәндәй сөйләшеп утыруы Талия Гафаровнаның башына сыймый иде. Ул һаман мәсьәләнең җитдилеген, йөз аклыгы өчен көрәшергә кирәклеген аңлатырга тырышты.

Аны озатканда да, киенеп урамга чыкканда да, Җәмилә Закировнаның йөзе шат, адымнары җиңел иде. Бакча янында зәңгәрсу машинасында аны Мөбарәк Таһирович көтеп тора, алар, аэропортка барып, бер танышларын каршы алырга тиешләр иде. Хатыны машина ишеген ачкач, Мөбарәк Таһирович гаҗәпләнеп:

— Ни булды сиңа? — дип сорады.

— Ә нәрсә?

— Төсең качкан.

— Болай гына... Безнең эштә була инде. Алтынчы роддомга сугылып чыгыйк әле. Бер генә минутка.

— Беләм мин синең минутларыңны, — диде Мөбарәк Таһирович, канәгатьсез тавыш белән.

— Тиз әйләнеп чыкмасам, көтеп тормассың, үзең генә барырсың.

Татарстан урамына борылгач, Мөбарәк Таһирович кисәк кенә тормозга басты:

— Әнә Изаил Харисович килә, — диде. — Бәлки, юл уңаедыр, аны да алыйк.

Дәүләтшин аларның өенә килеп йөргән чактан ук ул бу ачык чырайлы тырыш егетне яратып калган иде. Соңгы вакытларда Җәмилә Закировна бу кешегә карата фикере үзгәрүе хакында әйткәләп караса да, ире аларны зурга алмады. Диләрам белән килеп чыккан вакыйганы белгәч, бәндә хатадан хали түгел, диде. Кафедра мөдирлегенә Дәүләтшинның гариза бирүенә дә артык исе китмәде — яшь кешенең үсәргә теләве табигый, ә син эшне аннан яхшырак башкара аласыңа нык ышансаң гына урыныңда кал, диде. Кыскасы, бу хәлләрне тормышның гадәти каршылыклары дип кабул итте.

Шулай итеп, мөнәсәбәтләрнең чын асылы аның өчен караңгы булып калды. Ләкин Дәүләтшин һәммәсен бик яхшы белә иде бит! Ильясованың машинасын читләтеп үтәргә тиеш иде ләбаса!

Әмма ул аларны күрмәмешкә салышырга уйламады да. Ерактан ук елмаеп, адымнарын кызулатып килде, тәрәзәгә иелеп, гадәттәгечә ачык чырай белән сәлам бирде. Мөбарәк Таһировичның тәкъдименә рәхмәт әйтеп, машинаның ишеген ачты да арткы утыргычка кереп утырды.

Ирләр һава хәле, юлларның начарлыгы турында сөйләшәләр, сүзләре алгы утыргычтагы Җәмилә Закировнаның зиһененә томан аша гына килеп ирешә иде. Каршысындагы көзгедә ул доцентның шома, үз-үзеннән канәгать йөзен, агы зәңгәрсуланып торган коңгырт күзләрен, яңа төр җәнлеккә карагандай, кызыксынып күзәтте. Изаил Харисовичның бөтен кыяфәтеннән вөждан сафлыгы бөркелә иде.

Шунда Җәмилә Закировнаның күз алдында яшен яшьнәгәндәй булды: бу кеше профессор Ильясова каршында — остазы алдында! — үзен тамчы да гаепле санамый иде. Оялу да, кыенсыну да, бу миңа рәнҗеми микән дигән шик әсәре дә сизелми иде анда. Менә ул барасы җиренә килеп җитте, машинаны туктатуны сорады, рәхмәт әйтеп китеп барды. Аның артыннан ишекне яхшылабрак ябарга үрелгән Мөбарәк Таһирович тагын борчылып:

— Карале, Җәмилә, авырыйсың түгелме син? — дип сорады.

— Авырганнан түгел ул...

— Ә нәрсәдән?

Мөбарәк Таһирович машинаны кузгатты. Ул әледән-әле хатынына борчылып карап ала иде.

— Үзеңне дә кайгыртырга кирәк бераз. Менә хәзер баруга кан басымыңны үлчәтеп кара әле...

Машина Профсоюз урамына керде. Тудыру йортына килеп җиттеләр дияргә була. Бер генә урамны аркылы чыгасы калды. Әнә юл чатындагы йортның почмагына , җирдән ике метр чамасы биеклектә зур түгәрәк көзге беркетелгән, аркылы урамнан килгән машиналар шуннан күренә. Җәмилә Закировна анда күксел «Волга»ның чагылышын күреп алды, ул зурайганнан-зурая иде. Ә Мөбарәк Таһирович борчылып хатынына карый.

— Туктат... — дияргә теләде Җәмилә Закировна.

Тик әйтергә өлгердеме-юкмы, анысын белми калды, дөнья караңгылыкка чумды.

***

Наил Хәйдәрович килеп кергәндә, Зәйтүнә авыру тарихларын укып утыра иде.

— Яңалыклар бармы, Зәйтүнә Мәҗитовна?

Беренче карашка бу кешене һич тә табиб дип уйламассың. Аның шакмактан ясалгандай киң, билсез, тәбәнәк гәүдәсендә, кыска муенга утыртылган йомры башында, мичтә пешкән ак күмәч кебек түгәрәк ачык чыраенда ныклык, крестьян сабырлыгы ярылып ята, йомшак тавышында күңел киңлеге сизелә. Әйтерсең лә ул монда очраклы кеше, терелеп килгән хатынына сөенечле хәбәр китергән, бу бүлмәгә исә, ак башлыгын түгәрәк башына кырын салып, халатының төймәләрен эләктереп тә тормыйча, табибларга рәхмәт әйтү өчен генә кергән. Аны күрүгә, күңелне борчып торган уйлар онытылып тора, яшәүнең күңелле яклары күзгә ныграк күренә башлый. Табибларның да, авыруларның да кәефен күтәрә белә ул. Хәер, аның һөнәре шундый бит: операция вакытында сызлануларны

оныттыручы, кешенең җан сагында торучы — анестезиолог Наил Хәйдәрович. Сугыш елларында хирург булган, ә тынычта медицинаның яңа өлкәсен сайлаган.

Зәйтүнә аңа борылып, ямансу гына елмайды.

— Менә яңа авыру керде әле безгә, Наил Хәйдәрович. Шеш белән.

— Кая, авыру тарихын күрсәтегез әле.

Зәйтүнә коридордагы шкафтан Динәнең элек яткан чагында тутырылган авыру тарихын алып керде. Наил Хәйдәрович урындыкка береккәндәй җайлап утырды да зәңгәрсу кәгазь өстенә иелде.

— Син мондамыни әле? — дип ишекне ачып сорады Сөембикә. Наил Хәйдәрович аның ире иде. — Кайтканда ипи ала кайт димәкче идем.

— Туктале, карчык. Зиһенне чуалтасың.

Сөембикә бүлмәгә, Зәйтүнә янына узды.

— Анализ булды, Зәйтүнә Мәҗитовна. Минем гөберчәк Хәйруллинаны йөкле итеп күрсәтә.

— Йөкле итеп? Ялгышмыйсызмы?

Сөембикәнең юкка-барга үпкәли торган гадәте юк, шулай да йөзе сүрелеп китте. Кабан күлендә һәм Болак суында үскән гөберчәкләр һичкайчан ялгышмый. Һәрхәлдә андый очракның моңарчы булганы юк. Ә бәлки, бу — аларның беренче тапкыр хаталаныдыр? Күп тәжрибәләр күрсәткәнчә, мондый тикшерүләрнең йөздән туксан сигезе дөрес, икесе ялгыш нәтиҗә бирә. Ә бәлки, бу очрак шул йөздән икегә керәдер? Ярый ла шулай булса... Ләкин әгәр дөрескә туры килсә?

— Тагын бер тапкыр тикшереп карыйсызмы әллә, Сөембикә апа?

— Анысын эшлибез инде. Гадәттәгечә.

Ул чыгып киткәч, Наил Хәйдәрович уфылдап урыныннан кузгалды.

— Алайса, мин авыру белән танышып чыгыйм әле. Әгәр операция ясарга ниятләсәгез, төнгә калдыруда мәгънә булмас, шулай бит?

Мондый очраклар булганда профессор Ильясова шундук үзенә әйтергә куша. Аның башка тудыру йортына киткәнен Зәйтүнә белә иде. Димәк, шунда шалтыратырга кирәк. Зәйтүнә телефон трубкасын күтәрде. Теге баштан озак җавап бирми тордылар, аннары, профессорның фамилиясен ишетүгә, трубканы кире куйдылар. Зәйтүнә яңадан шалтыратып баш врачны сорады. Карлыккан тавышлы хатын-кыз, кемнең нинди йомыш белән шалтыратканын белешкәннән соң, авыр итеп көрсенде дә:

— Бу мәсьәләне сезгә мөстәкыйль хәл итәргә туры килер шул инде, — диде. — Җәмилә Закировна авыр хәлдә унбишенче больницада ята.

— Ничек... авыр хәлдә? Ул моннан әле генә китте. Башка берәү белән бутамыйсызмы?

Теге баштагы хатын-кыз ялыккандай итеп: «Без сезнең клиникага әле генә шалтыратып әйттек бит инде,— диде.— Аварияга эләкте ул. Ире үлгән, үзе реанимациядә».

Тиз генә башка сыя торган түгел иде бу. Шуннан соңгысы томан эчендәге кебек... Врачлар, шәфкать туташлары ах итештеләр.

Аяныч хәбәр беренче булып тудыру бүлеге мөдире Резеда Фәритовнага килеп ирешкән, ул инде Ильясова янына китеп тә барган икән. Башкаларның да күңеле шунда ашкына иде, ләкин доцент Виктор Ефимович: «Барыбыз берьюлы чыгып китә алмабыз бит инде! — диде.— Мондагыны кем эшләр? Мөмкин булганны анда бездән башка да җиренә җиткереп үтәрләр». Һәм аерып Хәйруллинаны телгә алды. Бая Наил Хәйдәрович әйткән фикерне кабатлады — операцияне кичекмичә ясарга кирәк, югыйсә эчкә кан савуы ихтимал.

Коридордагы кечкенә өстәлдә, кайнар сулы кәстрүлдә «мунча» ясап, каннарның катнашу-катнашмавын тикшереп торганда, Фидая:

— Бәлки, бу— миллионга бер була торган үзенчәлекле очрактыр? — дип сөйләнде. — Бер кагыйдәгә дә буйсынмыйдыр? Бер анализ белән дә беленмидер? Операциягә салмасаң, соңга калуың бар, салып та диагнозың расланмаса, кешенең тәнен юкка кисүең бар...

— Ә шулай да син Хәйруллинага икенче тапкыр операция ясаудан котыла алмассың, ахрысы, — диде Зәйтүнә.

— Хәйруллинаның янына бару түгел, исемен генә ишетсәм дә кулымнан әйбер төшеп китә минем.

Ә доцент Виктор Ефимович тудыру бүлегеннән китә алмый икән.

— Үзегезне сынап карагыз, Зәйтүнә Мәҗитовна, — диде ул, тыныч кына. — Тәжрибәгез җитәрлек, кулыгыз ятып тора. Мин сезнең мөмкинлекләрне беләм бит инде. — Доцент Зәйтүнәне ассистент булып торган чакларында гел мактап килә иде. — Ул-бу килеп чыкса, шундук мине чакырырсыз. Ә Фидая Галимовна ассистент булыр.

— Бернишләр хәл юк, анысына тырышырмын инде,— диде Фидая.

Яшь табибның теләсә кайсы мондый ышанычны куанып кабул итәр, үз язмышында зур борылыш дип санар иде. Зәйтүнә моны яхшы аңлады, әлбәттә. Ләкин көне, көне нинди бит! Ниләр генә кичерергә туры килмәде аңа бүген!

Наил Хәйдәрович белән сөйләшкәннән соң, Динә тынычланып киткән иде китүен. Әмма, елмаерга тырышса да, иреннәре генә ерылган, күзләре түгәрәк күл кебек мөлдерәмә, чайпалып түгелергә генә тора.

— Бик күп мәшәкатьләдем инде мин сезне, доктор. Монысы, мөгаен, соңгысы булыр. Миңа хәзер барыбер инде...

Тавышыннан шундый зар саркыды ки, Зәйтүнә, Тимербулатны елаганда юаткан кебек, бик якын итеп аңа таба иелде.

— Чыкмаган җанда өмет бар, Динә. Барысы да яхшы булырына ышанып тотыныйк без.

Зәйтүнә Динә яныннан чыгуга, Анна Ивановна юка стакан белән куе чәй китереп бирде:

— Операция алдыннан хәл җыегыз, доктор!

Зәйтүнәнең шактый күп операцияләрдә катнашканы булды, шәфкать туташы булып та, ассистент булып та. Тик беркайчан да ул бу бүлмәгә гамьсез, тыныч күңел белән атлап керә алмады. Бүген исә бусаганы аеруча дулкынланып атлады.

Операция ясаучы табибларны гадәттә шикәрдәй ак киемнән дип күз алдына китерәләр. Авыруның баш очындагы сулыш аппараты һәм кан салу җайланмасы янында басып торучы Наил Хәйдәрович белән анестезия сестрасы Анна Ивановнаның халатлары чыннан да чем-ак. Ә менә хирургларның киеме карап торуга иләмсез һәм салам төсле саргылт. Идәннән сөйрәлеп торган халат, башларында күз туры гына уелган бөркәнчек. Бу киемнәр стерилизацияләгәндә шушындый ямьсез төскә керә. Хирургның киеме матур булу мөһим түгел, әмма хатын-кыз күңеле мондый ямьсезлек белән барыбер ризалашмый, тән җайсызлык тоя. Резин перчаткалар эчендә кул тирли. Махсус лампалар эсселекне арттырып, сулыш алуны кыенлаштыра. Зәйтүнәне барыннан да бигрәк эчке дулкынлану яндыра иде: алар куйган диагноз дөресме? Ул үзе барысын тиешенчә башкарып чыга алырмы? Аның кулындагы скальпель бер генә миллиметр да артык җәрәхәт ясарга тиеш түгел, шул ук вакытта зарарланган күзәнәкләрне калдырырга да ярамый.

Башта сүзсез генә эшләделәр. Иркен бүлмәдә фәкать сулыш аппаратының тигез ритм белән эшләгәне, инструментларның бер-берсенә бәрелеп чыңлаганы гына ишетелеп торды. Хирургия сестрасы кирәкле коралны хирургның учына салып тора, каршы якка баскан Фидая Галимовнаның бармаклары җитез, төгәл хәрәкәтләнә иде.

Зәйтүнә дулкынлануын басарга, ныклык белән эш итәргә тырышты. Ниһаять, бар булган сорауларга ачык җавап бирер мизгел җитте — Динәнең карынындагы төер аермачык күренде.

— Менә ул!

Фидая Галимовнаның күзләре саргылт тукыма арасыннан шатлык белән балкыды. Алар ялгышмадылар: Динәдә чыннан да шеш түгел, аналыктан читтә урнашкан йөклелек иде. Диагнозны да дөрес куйдылар, операцияне дә вакытында ясадылар. Әгәр азга гына соңарган булсалар да, хәлнең ныкмөшкелләнүе ихтимал иде. Зәйтүнә белән Фидая сөенечләрен күз карашы белән аңлаштылар да, янә авыруга иелделәр. Билгеле методиканы төгәл үтәп, тыныч күңел белән операцияне дәвам итәргә була иде.

Ләкин скальпельне ярага якын китергәндә, Зәйтүнәнең кулы үзеннән-үзе туктап калды. Ул Динәнең: «Миңа барыбер инде»,— дип, елмаерга тырышып, мөлдерәп караганын күз алдына китерде. Ничек барыбер булсын! Менә хәзер Зәйтүнә кулындагы пычак аның соңгы өметен юкка чыгарачак. Галим-табиблар тәкъдим иткән ысул зарарланган тукымаларны кисеп алганда, алар тирәсендәге карап торуга сәламәт күренгән тукымаларны да бераз эләктерергә куша. Күпме алырга икәнлеген дә анык күрсәтә. Операциядән соң төрле өзлегүләрне булдырмау өчен шулай кирәк.

Әмма бу очрак китапта күрсәтелгәннән бераз үзгәрәк. Әгәр зарарланган урынны бик төгәл, пөхтә итеп кенә кисеп алсаң, ул чакта өмет калачак әле. Киләчәктә ана булу өмете...

Тик бу — китапта күрсәтелгәннән тайпылу булачак. Фидая Галимовна Зәйтүнәнең ниятен сүзсез аңлап алды, сагаеп:

— Әгәр бер-бер хәл булса?! Методиканы бозганыбыз өчен...— диде.

— Җавабын үзем бирермен,— диде Зәйтүнә һәм шәфкать туташына йөзен бормый гына учын сузды:

— Тампон!

Марля төене кыстырылган тимер кыскыч аның учында иде инде. Фидая Галимовна күз иярмәс җитезлек белән кан тамырларын бәйли иде. Зәйтүнәнең маңгаеннан тир тамчыларын сөртеп алдылар. Динәнең баш очыннан Наил Хәйдәровичның җанны тынычландыра торган гөрелдек тавышы ишетелде:

— Безнең хәлләр әйбәт. Йөрәк тибеше дә, сулыш та нормада.

Бүлмәдәге киренкелек кимеде, һәммәсе үзенә тиешле вазифаны күңел биреп башкара иде. Зәйтүнә соңгы җөйләрне бик пөхтә итеп салырга тырышты. Узган юлы да Фидая Галимовна Динәнең ярасын оста теккән булган, эзе нечкә генә сызылып тора. Матур булсын Динәнең тәне, насыйп булса, ул әни булачак бит әле.

Нинаять, Зәйтүнә сынын турайтты да, гомерендә беренче тапкыр, үзе өчен бик олы, бик мәгънәле тоелган сүзләрне әйтте:

— Операция тәмам. Барыгызга да бик зур рәхмәт.

Һәммәсенең йөзендә елмаю балкыды. Операция сестрасы зур ак эмаль тазга шалтыратып инструментларны тутыра башлады. Анна Ивановна Динәнең өстенә җәймә япты да баш очына басып, җиңелчә генә яңакларын чәбәкләде:

— Диночка! Диночка! Уян инде! Курыккан идең, менә котылдың да.

«Котылды микән?» — дип уйлап куйды Зәйтүнә. Операциянең чын нәтиҗәсе шактый вакытлар узгач кына беленәчәк иде.

***

Зәйтүнә киенеп тышкы ишектән чыгуга, каршысына бер ир кешенең килгәнен күрде.

— Хәерле кич, доктор Зәйтүнә. Әйдәгез, мин сезне өегезгә илтеп куям.

Мөдәррис иде бу. Аның башын иеп, күзләрен кыса төшеп, каравында электән таныш соклану һәм ялвару галәмәтләре күреп, Зәйтүнә гажәпләнеп куйды. Бүген бөтен дөнья үзгәрмәдемени соң? Әлегә кадәр кичәгечә яшәүчеләр дә бармыни? Бу кеше бүгенге вакыйгалардан бөтенләй гафил булганга гына үзен шушылай тотадыр.

— Сез бүген мине илтеп йөри алмассыз инде,— диде Зәйтүнә.— Хатыныгыз янына керсәгез яхшырак булыр. Төнне аның янында үткәрсәгез, бигрәк тә әйбәт.

-— Хатын-кыз больницасында кунаргамы?

Аның Динә турында берни сорамыйча, хаста хатыннар белән бер бүлмәдә төн уздыруның читенлеген уйлавы Зәйтүнәгә ошамады. Хәер, ир-атның күңелен аңлап бетереп буламыни? Хастаханәдә ятучыларның төнлә караучысыз калмасына ышангандыр, шуңа җаны тынычтыр. Ләкин болай ук битараф булу яхшы түгел иде. Алай да Зәйтүнә бу уйларын белгертмәде.

— Борчылырга урын юк кебек, — диде. — Операция уңышлы узды, хәле әйбәт. Хәзер аны яхшылап карарга гына кирәк.

— Операция?! Тагын шундый укмы әллә?

— Сез белмисезмени әле?.. Әйе, элеккесе төсле үк... Аналыктан читкә урнашкан йөклелек аркасында...

— Бөтенләй өмет беткән икән алайса...

Мөдәррис башын иде, эшләпәсе астында ничектер кечерәеп киткәндәй тоелды.

— Вакытында операция ясамасаң, мондый очракларның ахыры бик аяныч була. Исән калганына шөкер итәргә кирәк,— диде Зәйтүнә, Динә өчен үртәлгәндәй.— Ә өметне өзәргә ашыкмагыз әле.

Тик Мөдәррис аны ишетми иде кебек, башын күтәреп карамады. Кечкенә, көчсез, чарасыз булып тоелды ул бу минутта. Зәйтүнә үрелеп аның каты, салкын бармакларын тотып алды.

— Кич ашадыгызмы әле сез?

— Бер кире китсә китә шул инде ул, — диде Мөдәррис, сорауны ишетмәгәндәй. — Бәхетсезлек ялгыз йөрми, диләр шул.

— Әйдәгез, болай сөйләшик: сез хәзер ашап килегез. Аннары килерсез, арткы як тәрәзәне чиртерсез дә дежур сестра сезгә шундагы ишекне ачар. Мин аңа әйтеп куйдым, кизү торырга ире килсә, кертерсең, дидем. Арткы ишекне беләсезме? Әйдәгез, күрсәтәм.

Мөдәррис урыныннан кузгалмады.

— Болай ярамый, — дип үгетләргә кереште аны Зәйтүнә. — Хатыныгыз, сезнең мондый чыраегызны күрсә, һуштан язачак. Бүген сез — аның табибы, ә табиб аз гына булса да артист ул!

— Янында кеше бардыр бит?

— Анестезия сестрасы утыра. Үз сменасыннан соң калып!

— Тагын бер сәгатькә генә түзәр әле.

Мөдәррис Зәйтүнәнең кулыннан тотып алды да урам ягына тартты.

— Сез дежур сестраны күрмәдегез бит әле, — диде Зәйтүнә.— Ишекне кем ачар?

— Үзем керәсе ишекләрне сездән ачтырган юк бит әле моңарчы, табармын!

Һәм ул Зәйтүнәне җитәкләп бакча аша алып китте, аяк астында карга каткан яфраклар гына шыгырдап калды.

***

Авыруларга күчтәнәчләр, кирәк-ярак бирү, аларның хәлен белү өчен бирелгән вакыт бетеп килә, сәгать алтынчы киткән иде инде. Шулай да «П» хәрефе ясап салынган иске бинаның урта өлешендә, тудыру бүлеге каршында кеше һаман өзелми иде әле. Берсе китте исә, аның урынына башкасы килеп баса, башын күтәреп, икенче катка текәлә. Ә анда, ут балкыган тәрәзәләрдә, бумази халат кигән

хатыннар бер-берсен алыштырып тора, алар, учлары белән яктылыктан ышыкланып, тыштагыларга елмаялар, иреннәрен әкрен хәрәкәтләндереп нидер әйтәләр, әмма пыяла аркылы сүзләре ишетелми, аңлашылмый иде. Уңда, «П» хәрефенең бер аягын хасил иткән өлештә, арткы ишек өстенә иллеле лампа асылган. Көндезләрен хатыннарының хәлен белешергә килгән ирләр биредән башларын иеп, бөрешеп килеп чыгалар һәм як-якка карамыйча, тиз-тиз атлап урам якка ашыгалар. Аларның, тудыру бүлеге каршында басып торган ирләрдән аермалы буларак, мактанырлык чагы түгел шул. Кечкенә бакчада, шәрә агачларның күзне адаштыра торган ышыгында басып торган Әнвәр шулай дип уйлап куйды. Ул, бакча аша кыйгачлап салынган сукмактан бозлы яфракларны кыштырдатып берәрсе узган саен, куакларга елыша иде. Аңа гинекология ягына узарга кирәк, әмма ул күләгәдән чыгыйм дигәндә, тудыру бүлеге каршында басып торучыларның берәрсе бу тарафка юнәлә иде.

Болай йөрисе калмаган, дип уйлады ул, Лариса белән очрашу өчен башка урын табасы калган. Ләкин бүген вакытны тәгаен билгеләү кыен булды шул. Әнвәрнең укытучы булып эшләүче бер танышы мәктәптә теплица корырга ниятләгән икән дә, бик үтенеп киңәшкә чакырган иде. Мәктәп моннан ерак түгел. Лариса белән телефоннан сөйләшкәндә, Әнвәр, бушагач, сине үзем кереп алырмын, дип вәгъдә биргән иде. Зәйтүнәнең эше биштә үк бетә, ул инде киткән булыр, эчтә калган дежур табиб белән шәфкать туташының күзенә чалынмый гына үтеп китү кыен булмас дип уйлаган иде ул.

Менә, ниһаять, ишегалды бушап калды, тәрәзәдә хатыннар да күренми, уңдагы зур ишек тә ачылмый. Әнвәр бакчадан чыгарга дип адым ясаган иде, койма янына кызыл «Москвич» килеп туктады. Эшләпәле ир кеше, машина ишеген шартлатып ябып, тиз-тиз атлап бакча аша узды һәм зур ишектән чыккан хатын-кыз белән бәрелешә язды. Алар кызып-кызып нидер сөйләшәләр, әмма сүзләре Әнвәргә килеп ирешми иде.

Ак якалы кара пальто, ак бүрек кигән бу хатынның Зәйтүнә икәнлеге Әнвәрнең башына бераздан гына барып җитте. Ул, гажәпләнүеннән саклыкны онытып, алгарак атлады. Менә Зәйтүнә теге кешенең кулына ябышты, аны бинага таба тартты. Тегесе, аңа карышып, артка каерылды. Алар ни турындадыр бәхәсләшәләр иде булса кирәк. Ниһаять, ир кеше, Зәйтүнәнең кулыннан тартып машинасына таба алып китте. Алар куаклар арасында басып торган Әнвәр тарафына күз дә салмыйча уздылар да, «Москвич»ка утырып китеп тә бардылар. Машинаның кызыл утлары Әнвәрне үчекләп җемелдәгәндәй ераклашты һәм олы урам борылышында күздән югалды.

Әнвәрнең зиһене таралып китте: бу ни дигән сүз? Зәйтүнә баланы яследән алып, өйгә кайткан булырга тиеш иде бит инде!

Мөгаен, ул соңаргандыр да, шушы кешедән машинасы белән илтеп куюын үтенгәндер. Ләкин... ник соң Зәйтүнә аны бинага таба тартты, ә тегесе, аңа карышып, машинасы ягына әйдәде? Кыланмышлары да бик якын кешеләр кебек иде бит. Кем ул?!

Бакчада Әнвәрнең кабыгы гына басып калды, күңеле машина артыннан ашкынды. Беләсе иде, ни сөйләшәләр, кая баралар икән?

Әллә соң, машина тотып, артларыннан куа барыргамы? Һи, бу сәгатьтә Казан урамында машина тотканчы, алар инде әллә кайларга барып җиткән булырлар. Тотарсың куян койрыгын... Гарьлеге дә ни тора бит әле аның — үз хатынын кала буйлап эзләп йөргән ирдән дә көчсез һәм көлке кем бар тагын?

Әнвәр бакча почмагыннан кире борылды да, саклыкны онытып, туп-туры бина артына чыкты. Түрдәрәк кечкенә болдыр шәйләнә, ишек янындагы тәрәзәдә тонык ут яна иде. Әнвәр, перчаткасын салып, учын салкын пыялага куйды. Пәрдә ачылып, Ларисаның елмайган йөзе күренде, ул шундук кире чигенде — ишек ачарга китте.

Әнвәр бусаганы атлауга, Лариса аның кочагына кереп, күкрәгенә сеңде. Аннары бармакларыннан кысып тотып, бүлмәгә алып керде, егетнең куртка сәдәфләрен ычкындырганда, муенын кытыклап алды:

— Туңып беткәнсең бит, йолдызым! Җылынырга кирәк сиңа. Җылытырга кирәк сине!

Әнвәр курткасын аның кулына биреп, артсыз урындыкка утырды. Тимер абажурлы тәбәнәк өстәл лампасы гына янганга, бүлмә иркен булып, күләгәле почмаклар серле булып тоела иде. Әнвәр озын, тар өстәлнең караңгыда калган аргы очына, анда шәйләнгән штативларга, пыяла савытларга шикләнеп карады. Бу башка — яктыга ниләрдер куелып, өстенә кәгазь ябылган, кырыйдарак, юка стаканда кызгылт-сары һәм ачык сары кипкән чәчәкләр тора иде. Шушы кечкенә генә мәйданда да Лариса күзгә ямь бирә, күңелне кузгата торган мохит булдырырга тырышкан.

— Йом күзеңне, йолдызым! Хәзер мин могҗиза ясыйм... Тылсымлы ашъяулык, җәел!

Әнвәр күзен ачканда, өстәлдән кәгазь алынган, җыйнак кына табынның өсте ачылган иде. Колбасаның юка телемнәре, сыр кисәкләре чәчкә ясап тезелгән, нәфис итеп туралган кара икмәк сыныклары да, күзәнәкләре белән ымсындырып, авыздан сулар китерә иде. Ә уртада, ут яктысында тылсымлы балкып, үтә күренмәле сыеклык тулы колба утыра. «Спирт», — дип уйлады Әнвәр.

— Тагын авырулар премия бирдеме әллә?

— Кешедән генә көтеп тормыйбыз, үзебез дә таба беләбез!

Лариса өстәлнең аргы башыннан йөзәр грамм гына сыешлы ике кечкенә стакан алып килде.

— Анализ ала торган савытлармы соң бу синең? — дип сорады Әнвәр.

— Болары яңа, кулланууда булмаганнары.

Лариса стаканнарга яртылаш спирт салды, графин белән су алып килде.

— Син шушылай басып торырсыңмыни? — дип сорады Әнвәр.

— Монда урындык бер генә шул. Әйдә, мин кадерле кунагымны йола кушканча аягөсте торып сыйлармын.

— Утыр монда.

Әнвәр тезенә күрсәтте.

— Авыр булмаммы соң?

— Моннан авырракларын да салдың инде син миңа.

— Чын сөю җиңел булмый шул ул, йолдызым! Янмасаң-көймәсәң, сызланмасаң-газапланмасаң, ярату буламыни ул!

Лариса җиңел, хисле хәрәкәт белән аның тезенә менеп утырды. Ул бүген бик тыйнак киенгән: кара свитер, күксел итәк. Бу киеме аның буй-сынының сылулыгын аеруча ымсындырып күрсәтә иде. Ул яңагын Әнвәрнең башына терәде, алкасы егетнең чигәсен сыдыргалады, әмма бу да бик рәхәт иде.

— Беләсеңме, Анварчик, минем үз гомеремдә брудершафт эчкәнем юк бит әле.

Лариса стаканын ут яктысынарак сузып әйләндергәләде.

— Тәкъдим итүчеләр булмадымыни?

— Хәтерләмим... Тәкъдим итсәләр дә эчмәгән булыр идем. Ә менә хәзер...

Әнвәр аның нечкә беләгеннән тотып, үзенә таба тартты. Спирт аңкауны өтте, уйларны чуалтып җибәрде. Ул Ларисаның иреннәренә үрелде, шулчак аның күз алдын кызыл тап томалады, ул тап машина рәвешенә керде. Брудершафтны машинада да эчеп була бит... Әйтик, кызыл «Москвич»та... Әнвәр аңына килергә тырышып башын селекте: Зәйтүнәгә тагын! Болай кайнарланып, бер йомарлам май булып куенда эреп бетә аламыни соң ул, бөтенләй синеке булып бетә беләмени?

Әнвәр, сыр алырга үрелгән булып, Ларисаның тар аркасыннан учын алды да сак кына читләштерде.

— Лорочка, сезнең врачлар арасында кызыл «Москвич»лы кеше бармы?

Лариса, иелә төшеп, аның йөзенә текәлде:

— «Москвич»? Кызыл? Ә нәрсә?

— Син башта минем сорауга җавап бир.

— Ильясовалар машина алган, дигәннәр иде. «Жигули» бугай. Әйе, зәңгәрсу «Жигули». Ә «Москвич»... Күргән юк. Ай-һай, безнекеләрдә булыр микән? Врачның хезмәт хакына машина алырсың, бар. Кайда күрдең син аны?

Әнвәр әйтергәме-юкмы дип бертын уйлап торды да тәвәккәлләде:

— Әле генә минем хатынны кызыл «Москвич»ка утыртып алып киттеләр.

— Ә-ә, эш менә нәрсәдә икән...

Лариса, егетнең тезеннән төшеп, бүлмәнең аргы башыннан, күләгәдә тонык шәйләнгән пыяла савытлар яныннан әйләнеп килде:

— Синең шуңа эчең бик пошты инде, ә?

— Уйлап кара: әгәр Хөсәен шулай эшләсә, син ни дияр идең?

— Таптың чагыштырыр нәрсә! Әгәр Зәйтүнә риза булса, мин сезне бүген үк алыштырыр идем! Их, бар булган мөлкәтемне өстәп бирер идем әле! Син үзең әйтәсең бит, хатыным мине абыйсы урынына күрә, дип. Абый янына башка берәү сыя ул!

— Лариса!

— Алайса сорама миннән! Ялганлый белмим, дөресен әйтсәм, юри сөйли диярсең...

Шулчак колак төбендә диярлек каһкаһәләп көлгәндәй ят тавыш яңгырады. Әнвәр урыныннан сикереп торып аргы баштагы пыяла савытларга текәлде: аларга җан кергән кебек тоелды. Тавыш тагын кабатланды: «Ба-ка-ка-ка! Ба-а-ка-ка!» Лариса, авызын каплап, тавышын чыгармаска тырышып, Әнвәрнең кыяфәтеннән көлеп җибәрде.

— Ни ул? — дип сорады Әнвәр.

— Бака. Гап-гади бака!

— Каян килгән ул монда?

— Безнең бер тилемсә лаборант бар, шул асрый.

Калын тавышлы беренче бакага нечкәрәк тавышлы икенчесе кушылды. Әнвәр, каушавын сиздермәскә тырышып, өстәлдәге колбага үрелде:

— Шушындый җирдә дә ирләр белән очрашу җаен табасыз, ә?

— Әгәр дә син яхшырак урын тапсаң, без монда утырмас идек.

Лариса моны йомшак итеп, әрнү белән әйтте. Әнвәр, аны кыстап тормыйча, стаканыннан спирт кабып куйды, чыраен сытты.

— Син «Доктор Франсуаза Гайан» дигән фильмны караган идеңме? — дип сорады Лариса.

Әнвәр ул фильмны Зәйтүнә белән бергә караган иде. Зәйтүнә фильмны яратмады. «Франсуаза иренә хыянәт итеп, пациенты белән йөри, ә табиб үзенең пациентлары белән гыйшык-мыйшык уйнарга тиеш түгел,— диде ул.— Гиппократ антын бозу бу».

Ә менә Лариса бөтенләй башка фикердә икән:

— Франсуаза бик сөйкемле хатын һәм нечкә күңелле кеше, шулай бит? Ә менә хисләрен йөгәнли алмый, шунлыктан кануннарны боза...

— Сезне аның белән чагыштырып буламыни? Ул ирләрне дә дәвалаган. Сез исә хатын-кызларны гына. Бик теләсәгез дә, үз пациентларыгыз белән әкеш-мәкеш уйный алмыйсыз.

— Без дәвалаган хатыннарның ирләре бар бит, алар бу тирәгә күп килә.

Менә ничек. Мондагы табиблар үз пациентлары белән чуала алмый, ә менә аларның ирләре белән бәйләнүләре ихтимал дигән сүз бит бу... Әнвәрнең эче суынып киткәндәй булды. Кирәкми иде Ларисага һаман бер ноктага бәрергә! Болай итеп Зәйтүнәне каралтып кына калмый, үзенә дә күләгә төшерә ләбаса ул. Җитмәсә, бу үртәгәндәй бакылдаган бакалары тагын!

Әнвәр каш астыннан сөзеп карады да:

— Сиңа да киләләрме? — дип сорады.

Лариса аңа таба бер адым атлады, ләкин якын килеп елышырга базмады, йодрыкларын күкрәгенә кысып:

— Анварчик, йолдызым, нигә син минем йөрәгемне парә-парә телгәләп һаман-һаман аның хакында сөйлисең? — диде. — Ни генә булмасын, ул минем дустым бит! Миңа җиңел дип уйлыйсыңмы әллә? Беләм, ярамый сине яратырга, ярамый! Тик яратам шул, нихәл итим! Ялгыштык без, Анварчик, ялгыштык! Теге чакта минем үземә синең яныңа килергә кирәк булгандыр. Ә мин кыймадым. Инде ул да бу хатаны аңлыйдыр, бәлки...

Шундый хисләнеп, күңел түреннән актарылган тавыш белән сөйли, бу рәвешендә ул мәхәббәтне раслаучы, аңа баш орырга өндәүче фәрештә кебек күренә иде.

— Минем бөтен гаебем яратуымда. Мин үз ихтыярымда түгел. Син минем җирем, күгем, кояшым аем, йөрәк тибешем! Мин синең колың... Син минем йөземне каралта да, агарта да аласың...

Һәм ул, сынган тал кебек биленнән сыгылып, Әнвәрнең кочагына ауды.

— Кайчанга хәтле болай газапларсың икән син мине? Гомер буе шушылай өчәүләп яшәрбез микәнни инде? Сиңа мин генә җитмим, ул да кирәкмени? Синең миннән башка берәү белән яшәвең үзе зур бозыклык, әхлаксызлык, чөнки чын мәхәббәт юк сезнең арагызда! Ул синең сеңлең урынында калсын, ләкин ярың, парың, бердәнберең, хатының мин генә! Мин генә!

Кипкән чәчәк тажлары Әнвәрнең күз алдында ал, кызыл, сары таплар булып биеште.

— Ә Тимербулат? — диде ул, суга батканда саламга ябышкан шикелле.

— Бала үз урынында булыр. Ул синеке булып калыр. Зәйтүнә ата белән бала арасын бозмаячак, киң күңелле бит ул. Әйдә, иртәгә үк хисләребезне бөтен кешегә белгертик тә бергә яши башлыйк!

Лариса идәнгә тезләнеп, астан үрелеп, Әнвәрнең күзләренә карады, ике яңагыннан кысып тотты да:

— Вәгъдәме? — диде. Аның күзләренә карау авыр, ләкин ул карашны читкә җибәрми, тылсымлы кодрәт белән үзенә төбәлдереп тота иде:— Вәгъдәме?!

Ул Әнвәрнең кочагында утлы кисәү булып бөтерелде. Мәхәббәт утында рухы янып көл булган беренче егет Әнвәрмени? Шундый риваять тә бар бит — бер егеткә мәгъшукасы: «Сөюең хак булса, анаңның йөрәген китереп бир миңа!» — дигән һәм егет аның бу теләген үтәгән.

— Вәгъдә. Ял көнне абыйларга кунакка барырбыз, — диде Әнвәр, саташкан кеше сыман. Туганыңа парлашып кунакка бару ул инде Ларисаны хатының дип игълан итү булачак иде. Бу минутта Әнвәр Зәйтүнәне күз алдына китереп кинәнде хәтта: аның да үзәге өзелсен әле дип уйлады.

Кинәт тышкы якта бик каты итеп ишек шакыган тавыш ишетелде. Икесе дә шым булдылар. Коридорда эчке як ишек шыгырдады, кемдер тышкы ишеккә таба узды:

— Хәйруллина янынамы?

Ишегалдыннан ир кеше тавышы җавап бирде. Коридордагы хатын-кыз лаборатория ишеген тарткалады:

— Лариса Сөнгатовна, тышкы ишекнең ачкычын бирегез әле, авыру янында дежур торырга килгәннәр, — диде.

Лариса, Әнвәрне тар аркасы белән ышыкларга тырышып, ишек ярыгыннан гына ачкычны сузды. Әнвәр бөрешеп килде, бу минутта аның бөтенләй юк буласы килә иде. Оят, әйтеп бетергесез оят иде аңа. Якында гына, стена артында кемдер үлем белән көрәшә, ә алар монда... Нинди эшкә этәрә аны Лариса? Менә нинди бит бу хатыннар — берсенә дә ышаныч юк, берсенә дә!

Ул торды да ишек янындагы кадактан курткасын алды.

— Хәзер, хәзер! — дип, Лариса өстәлдәге әйбер-караны каплаштырды. Ак кәгазь янында кызыл, ал, сары чәчкәләр генә җемелдәшеп калды. Кипкән чәчкәләр!

Алар тышкы ишекне ябып чыкканда, янә бакалар бакылдашты. Алар каһкаһә белән көләләр иде кебек.

Әнвәр ашыгып алдан атлый, Лариса аның артыннан килә иде. Бакча янында кызыл «Москвич»ны күргәч, Әнвәрнең эчен утлы шырпы өтеп алгандай итте: бу шул, Зәйтүнә утырып киткән машина иде.

Лариса йомшак кына терсәгенә тотынгач, Әнвәр кулын тартып алмады.

***

Авызың тулы кан булса да, кеше алдында төкермә, дигәннәр. Ләкин һәр очракта да ярый торган кагыйдә түгел бу. Табиб янына килгән хаста авызындагыны гына түгел, йөрәк түрендәгесен дә яшермәскә тиеш. Югыйсә аны ничек дәвалыйсың?

Ә менә табибларның үзләре өчен бу кагыйдә бик дөрес. Алар тән сызлануларын да, тән газапларын да кеше күзеннән яшерә белергә тиешләр. Син аларны эш урынында күр, авыру кеше өстенә иелгән минутларында күзәт, хәтта коридор буйлап ничек атлап узганнарына игътибар ит. Биредә алар башкалардан биегрәк, гәүдәлерәк булып күренә, чөнки бүтәннәр белмәгәнне беләләр, гади кешеләр күрмәгәнне күрәләр, аңлыйлар. Йөзләре җитди дә, якты да, күзләреннән шәфкать нуры сирпеләдер шикелле. Яшәү белән үлем чигендә эшли торган бу затларга башка бүтәннәргә гафу ителә торган кимчелекләр, ялгыш-хаталар кичерелми, гадәти тормышта була торган вакчыллык, урынсыз шаярулар, уйламый әйткән сүзләр килешми, чөнки без аларга өмет һәм ышаныч белән текәлгәнбез. «Кешеләрнең таләпчәнлеген безгә һәрвакыт истә тотарга кирәк, больницада, авыруларны караганда гына түгел, урамда да, кунакта да, ял иткәндә дә без үзебезне ак халат кигәндәй итеп тотарга тиешбез», — дип кабатларга ярата иде Җәмилә Закировна.

Табиб үзенең табиб икәнлеген беркайчан да онытмаска тиеш. Ләкин, халатын салып урамга чыккач, халык төркеме арасында ул күпләрнең берсе булып кала. Трамвайда аның аягына басалар, кибет чиратында, мин монда тора идем, дип, этә-төртә алдына керәләр, сатучыларның дорфалары, товарның хакын-сыйфатын сорасаң, күзең чыкмагандыр бит, үзең кара, сез монда күп, мин берәү генә, дип тиргәп ташлыйлар. Андый чакта нишләргә? Халат белән берочтан табиб абруен да эш урынында калдырып, дәрәҗәңне онытып, этешергә-төртешергә, тиргәшергә-әрләшергәме? Әллә тын гына чигенергәме?

Андый очракларда Зәйтүнә дорфа-тупас кешеләргә, авыруларга карата булган сабырлык белән кызганып карый, бу хис аның үзенә җиңеллек бирә, кызып китеп дуамаллык эшләп ташлаудан саклый иде.

Ләкин менә Мөдәррис мәҗбүриләп диярлек машинага утырткач, ул үзен ничегрәк тотарга белми югалып калды. Рульгә ике куллап ябышкан, ирен читләреннән төтен бөркеп барган бу кеше каршында кем ул хәзерге минутта? Табибмы, әллә бер көн эчендә бер кеше гомеренә җитәрлекне кичереп, арыган-талган хатынмы?

Чын табиб үз горурлыгын-абруен саклау белән генә чикләнми, башкаларны үз ихтыярына буйсындыра, күпмедер дәрәҗәдә алар белән идарә итә. Зәйтүнәнең исә бу минутта андый көче калмаган, табиб буласы да килми, хатын-кыз, фәкать хатын-кыз гына булып каласы килә иде. Җанга якын һәм көчле берәүнең киң күкрәгенә сыенып, бүген кичергәннәрнең һәммәсен: иртән килгән хат, гомерендә беренче тапкыр ясаган мөстәкыйль операция турында, үзенең башка сыймас тәвәккәллеге, Җәмилә Закировнаның фаҗигагә юлыгуы хакында сөйлисе, күз яше аша зарланасы, мактанасы килә иде.

Мөдәрриснең дә гаме зур, чөнки ул өмете киселгән дип уйлый. Моңлы-зарлы ике кеше, машинаны туктатып, бер-берсенә елышып эч серләрен бүлешсәләр, икесенә дә җиңелрәк булыр иде, мөгаен.

Ләкин туктарга ярамый. Яследә сабый көтеп тора. Авызын ачса, моң-зар буасы ишелер дип курыкты, ахрысы, Мөдәррис тә ясле капкасы янына барып туктаганчы дәшмәде.

Капка артындагы ике катлы бинаның аслы-өсле ике тәрәзәсендә генә ут яна, тәрбиячеләр китеп беткән иде инде. Тимербулат коридорда каравылчы карт янында утыра иде. Бүреген кырын салган бабай аның кулына шырпы кабы тоттырган, сөйләштермәкче була, ә сабыйның йөзе бик моңсу иде. Гадәттән тыш гамьсез, ваемсыз, үз бурычын оныткан ата-ананың баласы гына шушы рәвешле боега торгандыр!

— Бәбекәччәем!

Зәйтүнә улын күтәреп күкрәгенә кысты.

— Гафу ит, улым! Үпкәләмә, бәгърем!

— Балалар китеп беткәч, елап алды беравык, — диде каравылчы. — Аннары нишләсен, тыелды.

— Рәхмәт, бабай!

Баладан Мөдәрриснең йөзенә дә нур күчкәндәй булды, ул, иреннәрен урак-ай кебек бөгеп, бит очларын чокырайтып елмайды. Тимербулат нәни кулларын рульгә таба сузгач: «Әһә, шофер буласың киләмени? Дөрес итәсең, чын егетләр эше бу!» — дип сөйләнде. Машина эченә кереп оялаган борчу-гамьнәр, сабый сулышыннан курыккандай, караңгыга чыгып качтылар һәм артта калдылар.

Алай да берсе Зәйтүнәнең күңелен тырнап тора, анысыннан да котыласы килә иде.

— Унбишенче больницага барып килик әле,— диде ул.— Безнең профессор Җәмилә Закировна авариягә эләккән бит бүген.

— Шулаймыни-и...

— Хәлен беләсем килә.

Больницаның биш катлы зур бинасы шәһәр урамнарыннан читтәрәк, зур бакча эченә салынган. Ул аермачык булып, зураеп, калкып тора. Ачык капканың дүрткырлы биек, киң баганалары арасыннан узып, авыр ишекне ачканда, кеше кечерәеп киткәндәй була, ихтыярсыздан шомлану катыш дулкынлану кичерә иде. Хастаханәләргә күптән күнеккән Зәйтүнәне дә бүген бу ямансу тойгы биләп алды.

Җәмилә Закировнаның хәле яхшыргандыр, ул аңына килгәндер, дип юатырга тырышты ул үзен. Шулай булмый мөмкин түгел, чөнки аны биредә иң яхшы табиблар кайгырта бит. Мондый шартларда кешенең хәле сәгать эчендә яхшыга үзгәрү бер дә гаҗәп түгел. Якты вестибюльнең сулындагы гардеробта торучы ак халатлы, йомшак чүәкле апа да аның өметен ныгытты. Киемнәрне кабул итеп алганда, Зәйтүнәнең кем янына килгәнен белгәч:

— Рәхим итегез, профессор икенче катта, уналтынчы палатада, — диде. Аның тавышы тыныч иде.

— Хәле бик авыр дигәннәр иде... — дип үзе дә сизмәстән әйтеп куйды Зәйтүнә.

— Монда үләргә ирек бирмәсләр. Бездә врачлар бик яхшы. Читтән дә әллә ничәү килде инде.

Уналтынчы палата аргы башта ук икән. Зәйтүнә сак кына ишекне шакыды. Бераз көттереп ишек ачылды, ак халатлы, ак башлыклы хатын-кыз бусагага аркылы басты. Сәламгә чак ишетелерлек итеп кенә җавап бирде дә, пышылдап:

— Биредә сезнең кафедрадан килделәр бит инде, — диде. — Гафу итегез, мин сезне кертә алмыйм. Бүлмә кечкенә, тиешле ярдәм күрсәтелә... Хәл белү өчен генә кереп йөрүнең кирәге юк. Ул һушына килмәде әле...

Шунда гына Зәйтүнә Җәмилә Закировнаның кызы Ләйләне танып алды. Әллә коридор ярым караңгы булганга, әллә аңарчы аны халат-башлыктан күрмәгәнгә, әллә зиһене чуалганга, беренче мизгелдә ул аңа бөтенләй чит кеше булып күренгән иде.

Зәйтүнә аның көнчыгыш кызларына хас булганча кыйгачлап уелган күзләренә, ак йөзенә туры карады, юату сүзләре әйтергә теләде, тик күңелендәгесен әйтеп бирерлеген таба алмады. Бу хатын өстенә төшкән авырлыкны бүлешергә, ничек тә җиңеләйтергә теләк көчле, әмма чарасы юк иде.

Ләйлә бөтен кыяфәте белән юату сүзләрен тыңларга теләмәвен белгертә — иреннәре кысылган, йөзе кырыс, сыны туры иде.

Коридорда аяк тавышлары ишетеп, икесе дә шул якка борылып карадылар. Аргы баштан, халат итәкләрен җилбәгәй җибәреп, очып барган кош кебек җиңел адымнар белән мәһабәт гәүдәле ир кеше килә иде. Зәйтүнә ерактан ук Изаил Харисовичны танып алды. Доцент шундый атлыгып, талпынып килә иде, әйтерсең лә барча сызлаулардан, хәсрәтләрдән арындыру чарасын китерә иде.

— Ләйлә Мөбарәковна! — диде ул, гөрелдәвек тавыш белән ерактан ук. Аның бөтен кыяфәтендә үзен көтә-көтә көтек булганнарына һәм ул килгәч сөенәчәкләренә шиксез ышаныч ярылып ята иде. — Ишеткәч тә килә алмадым, кичерегез! Кайгыгызны чын күңелдән уртаклашам! — Ул озын бармаклы, зур матур кулларын күкрәгенә куйды. — Ашыгыч операция! Һичкемгә ышанып тапшыра торган түгел. Әле генә бушадым. Инде менә төн буена мин сезнең карамакта.

— Исәнмесез, — диде Ләйлә. — Хәзергә әни янында реаниматорлар тора. Аннан башка да әнинең коллегалары дежур торуның чиратын язып куйдылар инде.

Изаил Харисовичның ишек тоткасына сузылган кулы һавада асылынып калды, йөзендә сәер елмаю кабынды. Ләйлә аңа юл бирергә уйламый иде. Зәйтүнә аңа ярдәм итәргә теләп:

— Изаил Харисович! — диде. — Мин машина белән. Әгәр кайтырга теләсәгез...

Ләкин доцент аның сүзләрен ишетмәде, хәрбиләрчә үкчәләрендә борылып китеп барды. Зәйтүнә, теләктәшлеген һәм кайгысын уртаклашуын белдереп, Ләйләнең кулын кысты. Бу минутта ул Җәмилә Закировнаның хәлен җиңеләйтү өчен бөтенесен бирергә, Ләйләне баскан авыр хәсрәтне күтәрешергә әзер иде. Ah, теләк туган һәр очракта ярдәм итеп булса икән! Шушындый минутларда чарасызлык җаннарны кыйный шул.

Тыштан өзек-өзек итеп машина чинаганы ишетелде. Зәйтүнә чыкканда, Тимербулат күкрәге белән рульгә яткан да, сигналга басып уйный, ә Мөдәррис радиодан соңгы хәбәрләр тыңларга тырыша иде.

Зәйтүнә улын кулына алды.

— Ничек соң? — дип сорады Мөдәррис.

Зәйтүнәнең күз алдында Ләйләнең агарынган, шул ук вакытта сабыр йөзе җанланды. Аның хәсрәтен башка берәүгә ансат кына сөйләп бирү мөмкинме?

— Аңына килмәгән әле, — диде Зәйтүнә.

Радио хәбәрчесе шомлы тавыш белән шәрык илләрендәге тынгысызлык, дөньяның төрле тарафларындагы канлы бәрелешләр, аларда бер гаепсез адәм балаларының һәлак булуы хакында сөйли иде.

— Бер уйласаң, башка сыймый,— диде Зәйтүнә, радиодан соңгы хәбәрләр тәмамланып, музыка яңгырый башлагач.— Кешенең гомере шулхәтле кыска, соңгы көннәре, ә кайчак еллары шулхәтле аянычлы, хәсрәтле, аннан котылу чарасы да юк. Без һәммәбез бу җиргә вакытлыча гына килгәнбез. Ләкин ник соң без, кешеләр, тыныч кына яши белмибез, нигә бер-беребезгә хәсрәт артыннан хәсрәт китерәбез? Нигә? Кешелекнең уртак дошманнары да күп бит югыйсә, чир-чор, картлык, үлем... Җир тетрәүләр, туфан, давыллар, корылык... Шулардан котылу өчен бергәләп тырышырга, яшьлекне озайту, үлемне чигендерү турында уйларга тиештер бит адәм балалары! Кемнәрнеңдер сугыш ачарга тырышуы, кеше үтерү кораллары ясавы минем башыма сыймый! Кешелек меңнәрчә еллар буе гаделлек, дуслык, мәрхәмәт-шәфкать турында сөйли, ә шулай да бу хакыйкатьне барча балаларына сеңдерә алмый...

— Чөнки кеше — дөньяның үзе кебек катлаулы һәм каршылыклы ул, — диде уйчан тавыш белән Мөдәррис.— Аның күңелендә яхшылык та бар, явызлык та җитәрлек.

— Һәркемдә дәме?

— Бу дөньяда нәрсәнең тигез бирелгәне бар соң? Адәм балаларының бар кара явызлары, бар керсез күңелле игелек ияләре. — Мөдәррис иреннәрен кысып тынып торды да: — Сезнең кебекләре, — дип өстәде. — Олы җанлы, бәхетлеләре.

Аның тавышында кызыгу, хәтта көнләшү сизелде.

— Сез минем хакта шулай уйлыйсызмы әллә? — дип сорады Зәйтүнә.

— Кочагында сабые тыпырчынып утырган ана бәхетсез була алмый. Тик кайберәүләр моның кадерен генә белми.

Алар Зәйтүнәләрнең өе турына кайтып җиткәннәр иде инде. Мөдәррис үрелеп караңгы тәрәзәгә карады. Аның соңгы сүзләре әле дә өенә кайтмаган, хатынына авыр чакларында да ярдәм итми торган ир кеше — Әнвәр турында иде.

Зәйтүнә Мөдәррис белән хушлашып машинадан чыгарга ашыкты. Каян белгән бу кеше караңгы тәрәзәле буш өйгә кайтып керүнең ифрат читен икәнен? Әнисе монда чакта Зәйтүнә бик бәхетле булган икән...

Йортның бусагасын ул менә шундый халәттә атлап керде. Арылган кулларның хәле юк, күкрәк эченә кайнар ком сипкәннәрмени — нидер авырттырып, кырып тора. Ләкин ятып хәл алырга вакыт юк, мең төрле эш көтә. Һәммәсе дә күнегелгән чират белән: баланы чишендерергә, су эчерергә, кулына берәр төрле ризык тоттырырга. Итне ваклап турап, шулпа пешерергә... Ипи алырга вакыт тимәде инде, ярар, токмачлы ашны ансыз да ашап була. Кухня идәнен сөртеп алырга, аннары бала киемнәрен юарга...

Хәер, соңгысына кадәр тагын бер вазифа бар әле — анысы иң рәхәте, тәнне-җанны ял иттерә торганы. Зәйтүнә улын караватына сала да, култыксага беләген куеп, тәнендә рәхәт бер талчыкканлык, җанында ял тоеп, сабыена таба иелә. Тормышның барча кере-карасы — чир, үлем, хыянәт, көнчелек — барысы, барысы ераклаша, торшерның яшел абажурыннан төшкән яктылык эчендә ана белән бала икәүдән икәү генә кала. Ак мендәрдән Зәйтүнәгә үз җылысы, киләчәге, мәңгелеге карап ята.

Әлли-бәлли ит, балам,
Сине йокыга салам,
Син йокыга киткәнче
Үзем яныңда калам,—

дип, әйтеп бетермәслек наз белән әкрен генә җырлый Зәйтүнә. Күптән, бик бәхетле көннәрендә ишеткән назлы тавышны, таныш җырны кабатлый ул. Әнисе җырын өр-яңадан кабатлый ул бу минутларда.

Сабыйның сулышы салмаклана, керфекләре авыраеп йомыла. Аны инде йокы баскан, әмма ул әледән-әле күзләрен ачып куя, әнисенең янында икәненә тагын бер тапкыр ышанасы, тавышын тагын бер тапкыр ишетәсе килә аның.

Кинәт ул нидәндер сискәнеп китте. Күзләрен зур ачып, куркынып түшәмгә карады, иреннәрен турсайтты. Бөдрә башын мендәрдән күтәрә төшеп, нәни кулларын әнисенә сузды.

— Кил, бәбкәм, кил миңа, нидән курыктың болай?

Зәйтүнә аны кочагына алып, аркасын терәп караватка утырды.

— Курыкма, балам, әниең яныңда чакта бернидән дә курыкма.

Сабый җылы йомгак булып аның кочагына сыенды.

Ә тышта җил тынып калган, чалт аяз күк йөзенә эре йолдызлар сибелгән, аларның кыйпылчыгы кебек, урам баганаларындагы утлар яктысында җемелдәп сыкы коела иде. Тын иде төн, мәңгелек кебек серле һәм кодрәтле, тантаналы иде. Җемелдәшкән серле йолдызлар, каядыр ашыккан кометалар арасында Җир шары үзенең мәңгелек юлын дәвам итә, салкын һәм чиксез галәмдә ул яшәешнең җылы чаткысын алып бара, үзендәге барлык сабыйларның уртак бишеге булып тирбәлә иде.

***

Тынлык шартлап ярылды — тышкы ишек ачылып ябылды. Кемдер, Зәйтүнәнең чигәләренә баскандай дөпелдәп, баскычтан менә башлады. Менә аяк тавышлары ишек турына җитте, менә тукталмыйча узып китте, ерагайды — өскә менеп китте. Йөрәк, хәлсезләнеп, тибешен әкренәйтте.

Зәйтүнә, сак кына кузгалып, йокыга оеган Тимербулатны ятагына салды.

Тормыштан беркая да качып булмый икән шул. Кайчакларда янган йөрәгеңне кисеп ташлардай буласың... Нигә кирәк иде аңа дөреслекне белү? Үлем түшәгендә яткан хастага тиздән үләсен әйтергә ярамаган кебек, кешегә сөйгән ярының хыянәтен дә белгертергә кирәкмидер, мөгаен. Дөрес, баштарак Зәйтүнә үзе үк чын дөреслекне белергә тели иде. Төннәрен теплицага шалтыраткан чаклары да булгалады, тик андагы телефон йөрәкне өшетә торган салкын һәм битараф тавыш белән сузып-сузып чиный, гүяки туктаусыз: «Ю-ук, ю-ук», — дип кабатлый иде. Әнвәр бик соң кайта, шалтыраткан идем, ник җавап бирмәдең, дигән сорауга: «Телефон саклап утырмыйм ла мин анда, — дип җавап бирә, — теплицаларны карап-тикшереп йөрим. Исеңдәме, узган елны торба тишелеп, кыяр-помидорларның шактыен кайнар су пешерде. Күпме хезмәт юкка чыкты. Мастерлар утырып елардай булдылар». Бүген дә кайткач шул сүзләрен кабатлар микән?

Мондый кичләр Зәйтүнәнең бөтен көчен ала. Аякларының хәле бетә, тезләре сыгыла, кухня белән бүлмә арасында үрмәләп йөрисе килә башлый. Алай җиңелрәктер, сабыйлар юкка гына дүрт аяклап йөрмидер... Суларга һава бетә, урамга чыгасы килә.

Җанга якын кешенең газапларын күңел ерактан сизә, диләр. Әнвәр аны чит күрәдер, мөгаен, югыйсә бу хәлгә ничек түзәр иде?..

Зәйтүнә ашык-пошык киенеп ишегалдына чыкты. Ә тышта — төн, адәм балаларының газап-ялуларына битараф тулган ай, каты җир өстенә галәм суыгын иңдергәндәй, боздай яктысын түгә, аның нурын әҗәткә алган урам фонарьларының күз яшедәй аксыл сыкы коела.

Әнә трамвай тукталышы ягыннан икәү узып китте. Егет кызны иңеннән кочып алган. Әкрен атлыйлар, ашыкмыйлар. Җаннары тынычтыр, чөнки башка берәүләрнең бәхетен таптамыйлардыр. Рәхәт аларга!

Әнә тагын икәү килә, болар да парлы... Хәер... Зәйтүнә арткарак, ай нурыннан читкә, өй күләгәсенә чигенде. Буйга калкурак, капюшонлы куртка кигән ир кеше Әнвәр иде, адымы, йөреше аныкы. Менә алар җай гына атлап килгән җирдән туктап калдылар, менә ике урынына бер кара шәүләгә әверелделәр — кочаклашып үбештеләр. Менә аерылышып икесе ике тарафка юнәлделәр: Әнвәр Зәйтүнәгә таба, Лариса — кыеклап, каршы якка. Тик ул ерак китмәде, туктап борылды да: «Тукта!» — дип кычкырды. Һәм ике кулын канат итеп җәеп, кире йөгерде. Менә килеп җитте, Әнвәргә беректе, сеңде... Зәйтүнә чытырдатып күзләрен йомды.

Әнвәр аны, ниһаять Ларисадан аерылып, ишек төбенә килеп җиткәч кенә күреп алды. Бу минутта ул югалып калырга, аклана башларга тиеш иде кебек. Ләкин аның тавышы бик тыныч яңгырады:

— Нәрсә, кунагыңны озаткач, керәсең килмичә йөрисеңме әллә?

— Нинди кунакны?

— Сине кем китереп куйды соң? Һәм беренче тапкыр гына да түгел!

— Ул бит... Ул бит...

Ләкин Әнвәр хатынының сүзен тыңлап тормады, ишекне ачып, эчкә узды, Зәйтүнә, гаепле бала шикелле башын иеп, аның артыннан иярде. Һәм шунда бик зур мөмкинлекне кулыннан ычкындырганын аңлады: ул иренең гаебен сиздереп, аның вөҗданын кузгата алмады һәм шуңа күрә Әнвәрнең хыянәте бик тә аңлаешлы, табигый гамәл шикелле килеп чыкты. Ул фәкать хатынының гөнаһына каршы тиешле җавапны гына биргән. Һәрхәлдә, Әнвәр мәсьәләне менә шушылай итеп куйды.

Әнә ул, торшер яктысында иркенәеп чишенә, бөтен кыланмыш-хәрәкәтләреннән үзен гаепле дип түгел, гаепләүче итеп хис иткәнен сиздерә. Хатынының сөйләгәнен колак турыннан уздырып кына җибәрә гүяки аның ничек-ничек ялганлаячагын алдан ук белеп тора. Зәйтүнә, ачыргаланып әйткән сүзләренең ире колагына эләкмичә дә очып киткәнен тоеп, тынып калды. Йа Хода, синең белән бер уртак тормыш корып, бер бүлмәдә яшәгән кешенең бу хәтле дә чит һәм мәрхәмәтсез булуы мөмкинме?

Зәйтүнәнең өйне дер селкетәсе, яшен яшьнәтәсе, күк күкрәтәсе, иренең йөзендәге гамьсезлекне йодрыклары белән төеп куасы килде.

Ләкин тавыш купса, Тимербулат куркып уяначак иде. Зәйтүнә таяныч эзләп, бала караватына чытырдап ябышты.

***

Билгесезлектән дә авыр нәрсә дөньяда юктыр. Алтынчәч төн үткәнен көтә-көтә тәмам гажиз булды. Чыгарырлармы аны, юкмы? Чыкса, Линарны күреп булырмы, күрсә, күңелен йомшарта алырмы? Ул егеткә ниләр әйтәсен кат-кат күңеленнән кичерде, үтемле сүзләр эзләде. Бәгырьне көйдергән ялкын телләренең кайнарлыгын сеңдергән, таш күңелне дә эретерлек сүзләр кирәк иде аңа!

Төннәрен хастаханәдә вакыт үзе тукталып, ял итеп ала дип белерсең. Ниләр генә уйлап бетермәде Алтынчәч! Ләкин бу юлы бер нәрсә — кылганнарына үкенү хисе аның күңелен кыйнамады. Әгәр ул гөнаһ кылмаса, карынында бала яралмаган булыр иде, җирдә яшәячәк бер кешенең гомере башланмас иде. Бер җан каршында гомер капкаларын ачкан өчен үзеңне гаепләү дөрес эшмени? Әгәр дә баласының хакын ахыргача хакларга көче җитмәсә, Линарны үз сүзләренә ышандыра алмаса, менә шул булачак аның йолып бетермәслек гаебе һәм ярлыканмас гөнаһы.

Шуңа күрә Алтынчәч бу очрашуга бик ныклап әзерләнде. Иртән хәтта сабыйларны карарга да чыкмады, Линарга әйтер сүзләрен кат-кат кабатлады.

Менә, ниһаять, бүлмәгә аның зарыгып көткән кешесе — Лариса Сөнгатовна килеп керде. Ул барында палата ничектер үзгәреп киткәндәй була, аның пөхтә кыяфәтеннән, керсез халатыннан, ак башлыгы астыннан бүселеп чыккан җирән бөдрәләреннән, нечкә үкчәле туфлиләреннән үзенә бер җиңеллек сирпелә, дару сасысын затлы хушбуй исе күмеп китә. Авыруларның йөзендә дә җилбәзәк елмаю кабына, әйтерсең лә көйсезләнгән сабыйларга затлы уенчык күрсәтеп юаталар. Ул үзе дә кешенең саулыгына, гомеренә бәйле мөһим эш башкарып түгел, ә бәлки, бала-чага уены корып кына йөри сыман тоела, шуңа күрә хастаханәнең бөтен җитдилеге беразга онытылып тора иде.

Хатыннар моның өчен аны гаепләмиләр, әмма уенга үзләре катнашырга да атлыгып тормыйлар: чөнки Лариса Сөнгатовнаның кулы каты икәнлеген, укол кадаганда, кан алганда авырттырып чәнчегәнен беләләр. Дәвалау эшендә кул яту дигән нәрсә бар бит: шәфкать туташларының берише уколны сиздерми генә ясый белә, икенчесе исә шөпшә чакканнан болайрак итә. Бер табиб тәнгә иркәләп кенә орына, икенчесе кагылса, авыртмаган җирне сызландыра. Лариса Сөнгатовна шул икенчеләреннән иде. Аның күтәренке тавыш белән һәммәсенә берьюлы: «Ну, назлыкайлар, һаман иркәләнеп ятасызмы әле, ирләрегез янына кайтасыгыз килмиме?» — дигән соравына шаярышып җавап бирәләр, әмма башка табибларга сөйләгән кебек тормыш хәлләрен ачып салырга ашыкмыйлар иде.

Бу юлы да ул Алтынчәчнең караваты кырыена килеп утыргач, палатада тынлык урнашты. Ул кулындагы штативны тумбочкага куйды да ялтырап торган кечкенә пәке алды. Бу юлы Алтынчәч бармак битен чәнечкәнне бөтенләй тоймады. Менә Лариса аның нәни җәрәхәтенә кечкенә пыяла көпшәнең очын куйды, көпшә буйлап кызыл кара менеп киткәндәй булды. Менә ул көпшә штативка нәкъ шундый башкалар белән бер рәткә куелды. Ни әйтер андагы кызыл кара? Алтынчәчне Линар белән очраштырырга ярый диярме, әллә юкмы? Йа Алла, кайчакта безнең язмышлар нинди кечкенә нәрсәләргә бәйле булып кала!

Алтынчәч врачның йөзенә текәлеп карады. Лариса Сөнгатовнаның чырае караңгы, күз төпләре күгәреп чыккан: төн йокламаган, исәпле кеше кебек күренә иде ул бүген. Көпшәләрне чирканган кыяфәт белән тота, менә нәни пәкесен идәнгә төшереп җибәрде, иелеп, аны ала алмый шактый азапланды. Таркау иде бүген Лариса Сөнгатовна. Бер мизгелдә Алтынчәч аның белән берничә авыз булса да сүз алышырга теләгән иде, ни дисәң дә шактый аралашкан кеше бит, инглиз телен өйрәнү курсларына да бергә йөрделәр; әмма врачның караңгы чырае сөйләшергә теләкне сүндерде.

«Һич булмаса, дәгъвалашып, расписка биреп булса да чыгармын», — дип уйлады Алтынчәч.

Табибә чыгып киткәч, палатадагы дүрт хатын бергә җыелышып, больница хәлләрен, дөресрәге гайбәт сөйләшергә керештеләр. Лариса Сөнгатовна кереп чыкканнан соң, ни хикмәттер хатыннар үз хәлләрен онытып торалар, кешенекен тикшерә башлыйлар иде.

Алтынчәч аларның сүзенә катнашмады, ул түземсезләнеп анализ нәтиҗәсен көтә иде.

Берәр сәгатьтән палатага зәңгәр штемпельле кәгазь кисәге тотып Резеда Фәритовна килеп керде.

— Анализыгыз ярыйсы бүген, — диде ул, кәгазьдән күзен алмыйча. Аның йөзендә икеләнү галәмәте ярылып ята иде. — Озак дәвалауның нәтиҗәсе кинәт сизелгән очраклар да була шулай. Алай да ашыкмаска иде, бер генә көн булса да сабыр итәргә, анализны тагын бер тапкыр кабатларга иде.

Тик Алтынчәч үз сүзендә нык торды: аңа бүген, менә хәзер үк чыгарга кирәк — бик мөһим мәсьәләне хәл кыласы бар. Ахырда Резеда Фәритовна киңәшләрен бирә башлады: даруларны үз вакытында эчәргә, аз гына үзгәреш сизелсә, шундук бирегә кире килергә, һич булмаса, телефоннан шалтыратырга. Иң мөһиме — нервыларны сакларга, борчылмаска. Тик Алтынчәч рәтләп тыңламый иде, аның күңелендә сулкылдап бер үк сүзләр кабатланды: «Без очрашабыз! Очрашабыз, очрашабыз... Бүген иң мөһиме хәл ителәчәк!»

Урамга чыккач, дөнья аңа өр-яңача күренде. Аяз, салкынча, сулыш алуы җиңел, күз күреме иркен. Бина эчендә борчулар да диварларга бәргәләнеп зурая икән, тышта таралып киткәндәй булдылар. Клиника каршындагы кечкенә бакчаның шәрәләнгән агачлары, туң җирне каплап та бетермичә керләнеп өлгергән кар, каршыдагы фабриканың озын-озын биналары — һәммәсе җанга якын булып тоелды.

Трамвайга керүгә, аңа урын бирделәр, ә төшкәндә, яшь кенә бер егет, йөзенә кайгыртучан кыяфәт чыгарып, терсәгеннән тотып алды. Аннары тротуарга бастырды да эре-эре атлап китеп барды. Алтынчәчнең күзенә яшь килде. Моңарчы аның очраклы кешеләрдән мондый кадер-хөрмәт күргәне юк иде. Көзгегә караса, ул үзен ямьсезләнгәндәй күрә, ә менә кешеләрнең аңа күзе төшкәч, йөзләре яктырып киткәнен сизә иде. «Хатыннарның бөтен матурлыгы, бөтен күрке ана булуда», — дигәндә, шагыйрь корсаклы хатыннарның тышкы кыяфәтен күз алдында тотмаган, кешеләрнең аларга карата якты мөнәсәбәтен уйлап әйткән булса кирәк. Йөзләрне ача, күңелләрне пакьли торган бу хис булачак аналар янындагы һәр игелекле кешенең карашында чагыла.

Алтынчәч шушы якты хисне Линарда да кабызырга тиеш иде. Яшь егетнең юл уңаенда күрсәткән кайгыртучанлыгы моңа өметне ныгытты.

Күршеләр эштә иде, Алтынчәч өйдә тулы хуҗа булып йөрде. Ял итә-итә идәннәрне юып чыгарды, кухня плитәсен, юынгычларны тазартты, ваннада юынды, чәчен бигудига урады. Ә бәлки, Линар бирегә килер? Нигә килмәсен? Килер, әлбәттә! Алар Мөһимә янында түгел, күзгә-күз сөйләшергә тиешләр ләбаса. «Кичкә кадәр генә булса да өмет белән яшим әле!» — дип Алтынчәч күңеленнән бөтен шикләрне куды. Мөһимәнең ишеге бикле булса, күңеле төшәсен белгәнгә күрә, ул аңа кич кенә барырга булды.

...Ишекне Мөһимә үзе ачты. Эчтән ят телдә өзеп-өзеп җырлаган тавыш ишетелә — магнитофон уйный, димәк, Линар биредә иде. Чыннан да, әнә ул диванда иркенәеп, кырын ятып тора, ишек ягына башын да борып карамады.

— Кунак килде, кунак! — дип, шактый кычкырып дәште аңа Мөһимә, магнитофон тавышын басарга тырышып. Шуннан соң гына Линар урыныннан кузгалды, саргылт күлмәгенең чалбар өстенә чыгарып салынган итәген тарткалап куйды. Аның йөзендә сөенү дә, каушау да сизелми, ике күзе дә тоныкялтырый, кайсы пыяла, кайсы чын икәнен аерырлык түгел иде.

Үзе өчен булса, Алтынчәч шундук борылып чыгып китәр һәм башка беркайчан да бу өйнең бусагасын атлап кермәс иде. Үлсә үләр иде, килмәс иде ул монда!

Ләкин бала! Хәзерге минутта карынында тибенеп, йөрәгенә хәл кертеп куйган бала! Аңа әти кирәк. Исем өчен генә булса да кирәк. Бала зинадан туган булып саналмасын. Ул тумыштан ук башкалардан ким булырга тиеш түгел!

Шуның хакына Алтынчәч үзенә ике ук төбәгәндәй — йөрәккә төзәгәндәй! — карап торган кешенең, бу минутта бөтенләй чит-ят тоелган ир-атның каршына елмаеп бара. Аның таш күңелен йомшартырга кирәк. Ул үзеннән яралган балага исемен бирсен. Фамилиясен генә бирсен ул аңа, документларда «атасы» дигән юлга үзенең исемен яздырсын. Алтынчәч бу адәмнән башка берни дә сорамас, сабыйны үзе тәрбияләп үстерер. Тик ул ата баласы гына булсын!

Линар аның хәлен сорашуны кирәк тапмады. Тезләрен киң җәеп, кире диванга урнашты. Аның бу кыяфәтен утырды дип тә, ятты дип әйтергә дә була иде. Моның белән ул Алтынчәчне санга сукмавын, ихтирам итмәвен күрсәтә иде кебек. Мөһимә кухняга кереп киткән иде, Алтынчәч, пальтосын чөйгә элеп, аның янына узды. Ярдәм итәргә омтылыш ясаган иде, хуҗабикә:

— Юк, юк, үзем карыйм, син рәтен белмисең, — дип, аны якын җибәрмәде. Алтынчәч, залга чыгып, диванның буш калган башына бөрешеп утырды. Линар аңа сүз кушмады.

Чәйләр эчеп, эш беткәч, Мөһимә тыр-тыр йөреп табын җыя башлагач, бер яктан магнитофон уйнатып, икенче яктан телевизорда хоккейчыларның чапканын караштырып, диванда корсагын бүлтәйтеп яткан Линарга карагач, Алтынчәч сөйләшер өчен шушыннан да уңайрак форсатның булмаячагын аңлады. Линар үзе сүз башламаячак, озатырга чыкмаячак — бу көн кебек ачык иде.

— Синең белән сөйләшәсе сүз бар иде, — диде Алтынчәч.

— Да, лапочка, тыңлыйм, сөйлә.

— Икебез генә.

— Монда башка кеше юк бит.

Чыннан да Мөһимә кухняга чыгып, савыт-саба шалтыратырга кереште.

— Монда өй тулы кеше, — диде Алтынчәч, идәндәге магнитофонга һәм түрдәге телевизорга ымлап.

— Ә син аларга игътибар итмә. Мин сине ишетәм бит. Алай да үзе, янтая төшеп, магнитофон тавышын әкренәйтте. Һәм телевизорга текәлгән килеш: — Тыңлыйм, — диде.

Шул рәвешле, бала язмышын, кеше язмышын хәл итә торган, Алтынчәч айлар буе хыялланып йөргән сүзне «адью, адью, адью» дип көрсенеп һәм астыртын мәгънә белән җырлаган сүзләр фонында һәм телевизор экранында әвәрә килгән таза егетләр каршында башларга туры килде.

Алтынчәч анысына да риза иде. Бала хакына дигәндә ул үзенең горурлыгын, кешелеген, гомерен шушы адәмнең аяк астына салырга, борыны белән җир сөрергә, теләсә нинди кимсетелүгә түзәргә әзер иде.

— Озакламый безнең балабыз булачак, — дип башлады ул һәм сүзләренең мәгънәсезлеген шундук аңлап алды. Хыялында бу сөйләшүне ул бөтенләй башкача башларга ниятләп куйган иде югыйсә. Линарга сыенып утырырга, аның аксыл чәчен сыйпарга, иңнәренә сарылырга һәм: «Нинди исем кушарбыз икән?» — диярга тиеш иде ул.

Ләкин аңа якынлашып булмый. Әйтерсең лә ул ниндидер акыл ирешмәс кодрәт белән үзеннән читләштереп тора иде. Тик шул рәвешендә дә Алтынчәч аны бөтенләй үк чит итә алмый, чөнки ул барыбер аның өчен бердәнбер булып кала.

— Линар, — диде ул, диван уртасына таба авышып, — миңа Мөһимә апа әйтте, син монда күчеп килү ниятеңнән ваз кичкәнсең икән, — диде.

Һәм, егетнең күңелен йомшартырга омтылып, кулы белән аның иңенә орынды. Теге исә кигәвен чаккандай артка тайпылды.

— Курыкма, миңа синнән берни кирәкми,— диде Алтынчәч.— Фәкать бер генә үтенечем бар: балага исемеңне бир, ул әтиле булсын. Синеке бит ул!

Линар әкрен генә башын борып, аның йөзенә текәлде:

— Алимент аласың киләмени?

Алтынчәчнең сулышы кысылды:

— Юк-юк, ант итәм: акча сорамам! Бирсәң дә алмаячакмын! — дип кинәт кычкырып куйды ул. Аннары үз-үзен кулга алырга, йомшак сөйләшергә тырышып: — Бала атасыз булмасын, фәкать шул гына,— дип өстәде.— Бала кадерен белә торган кеше бит син!

— Ну, лапочка, минем хәлне дә аңларга кирәк. Минем урынга үзеңне куеп кара! Без синең белән икеме-өчме тапкыр очрашканбыз икән, аннан гына мондый җитди нәтиҗәләр чыгару кыен. — Линар башын телевизорга борды да эчендә кайнаганын әйтеп салды: — Юк кына нәрсә аркасында муенга гомерлек камыт киярга ахмак дип белдеңме әллә син мине?

Алтынчәч тынсыз калды. Тегенең исә сүзе бетмәгән иде әле:

— Сабый түгелсең, алданрак уйларга кирәк иде. Ирләр кулыннан килми торган эшләр дә бар бу дөньяда. Врачка синең урынга мин бара алмыйм!

Алтынчәч соңгысын, төннәрен башына килеп тә, теленнән ычкындырырга ниятләмәгәнне әйтеп салды:

— Синең кызың бар бит. Күз алдыңа китер: әгәр ул буй җиткәч синең шикелле берәүгә юлыкса? Минем хәлдә калса? Ни диярсең ул чакта?

Линар кинәт пружинадай тартылып сикереп торды. Аның күзләре Алтынчәчкә ике көпшәле мылтык булып төзәлгән иде, алардан ут бөркелгәндәй булды:

—Җитте сиңа! Җыен җилбәзәк хатын минем кызым белән авыз чайкамый торсын әле!

Алтынчәчнең дөньясы сүнде, ул кинәт юкка чыккандай булды. Диван култыксасына янтыгы белән бәрелеп, идәнгә шуышып төшкән хатынның авызыннан күбек килә, башы өстәл аягына бәргәләнә иде.

— Апа! — дип кычкырды Линар. — Апа, кил тизрәк! Үлә!

Кухнядан йөгереп чыккан Мөһимә өстәлдән кашык алып, Алтынчәчнең теш арасына кыстырды.

— Бар, йөгер, «скорый» чакыр тизрәк!

— Моннан ярар микән? Урамнан озатсак яхшырак булмасмы? — диде Линар.

— Син күзгә-башка чалынмассың, үзем озатып җибәрермен.

— Ну, апа, рәхмәт сиңа! Минем башны бума хатынга бәйләргә йөргәнсең икән!

Линар ишекне дыңк итеп ябып, баскычны дер селкетеп чыгып китте. Өйдә магнитофонның ирләр тавышы белән чинап җырлаганы гына ишетелеп калды.

***

Аңына килеп карашы яктыргач, ул кызын күреп елмайды, күз алмаларын йөртеп тирә-ягына каранды:

— Ә Мөбарәк? Әтиең кайда?

Ләйлә аңа иелде:

— Хәлең ничек, әнием?

— Ни булды? Бу нинди урын? Әтиең кайда?

— Сез машинага бәрелгәнсез бит, әни. Хәтерлисеңме?

— Машина? — Җәмилә Закировна, күзен йомып, бераз аңын җыеп ятты. — Юк, берни хәтерләмим. Әтиең ни ди?

— Борчылма, әни. Хәзер инде бар да үтте. Син ике тәүлек һушсыз яттың...

Җәмилә Закировнаның йөзендә канәгатьсезлек чагылды. Ул ире турында сүз көтә иде. Мөгаен, күңеле нидер сизә иде.

— Машина син утырган яктан бәрелгән, әни. Әтигә бөтенләй диярлек зыян тимәгән. Тик аның йөрәге генә... Юк, юк... син әйтеп бетергәнне көт... Микроинфаркт булды аңа. ГИДУВта ята. Ул да гел сине сораштырып тора. Тик үзе килә алмый, торырга рөхсәт итмиләр.

— Янында кеше бармы?

— Равил гел шунда утыра. Ул — анда, мин менә синең янда. Үзебез шулай яхшырак булыр дип уйладык.

— Бар, тизрәк шалтырат Минем хәл яхшырганны әйт. Борчылып ята күрмәсен!

— Хәзер, әни.

Бүлмәдән чыккач, Ләйлә бертын коридор диварына сөялеп, хәл җыеп торды. Гомеренә бер тапкыр да аның әнисен алдаганы юк иде. Әйтми калган серләре булды, ансыз мөмкин түгел, әмма күзенә карап ялган сөйләгәне булмады. Хәзер менә елмаеп, шат кыяфәт белән әнисенә ялган сөйләү ифрат авыр иде аңа. Үзе өчен ул моны беркайчан да эшләмәс иде, ләкин сүз әнисе турында, аның исәнлеген саклау хакында бара бит! Ләйлә, бүлмәдә тыңланып яткан әнисе шиккә калмасын өчен, коридор буйлап читкәрәк китте, аннары кире әйләнеп килде. Аяк тавышларының ерагайганы, якынайганы ишетелеп торсын. Бераздан ул бүлмәгә кире керде. Йөзендә тынычлык сакларга тырышты. Аның керфеге дә ялгыш тибрәнергә тиеш түгел. Ләйләнең әнисе бигрәк сизгер, җанны үтәли күрә сыман.

— Әти үзе телефон янына килә алмый әле, әни. Равил белән сөйләштем. Әтине үзен яхшы хис итә, синең хәлең яхшырганны белгәч, бигрәк тә күңеле күтәрелер, диде.

Җәмилә Закировна кызының күзенә текәлеп карады, ярый аны-моны сизмәде, тынычланып, мендәренә башын җайлабрак салды. Ире өчен борчуы кимегәч, ул үз тәненең сызлауларын ныграк тоя башлады, ахрысы, маңгае җыерчыкланып чыкты.

— Сул янбашым бик сызлый,— диде.— Аякка баса алырмын микән?

— Врачлар әйтте, сөякләре исән, тиз арада аякка басачак,— диделәр.

— Тиз кирәк шул. Әтиеңне беркем дә минем кебек карый алмый.

— Аның өчен синең үзеңә аякка басарга кирәк бит әле. Борчылма. Үзең әйтәсең бит, уйларның матурын уйларга кирәк, җан тынычлыгы бик шифалы, дип. Шулай түгелме?

— Бар әле син, әтиеңне күреп кил. Минем сызланганны әйтә күрмә, хәле әйбәт, диген.

Ләйлә кизү торучы шәфкать туташын чакырып кертте дә, әнисен елмаюлы карашы белән юатып, чыгып китәргә җыенды. Җәмилә Закировнаның сөйләшерлек хәле калмаган иде, ак җәймә өстендә үтә күренмәле булып тоелган бармакларын тибрәтеп кенә ишарә ясады: «Бар тизрәк!»

Ләйләнең барыр юлы ерак түгел, ветеринария институтының ак бинасы янәшәдә, бәс сарган, тездән карга чумып утырган агачлык артында гына. Дөнья шундый ак, пакь, оеп-тирбәлеп ябалак кар төшкәли, якындагы тимер юлдан, тәрәзәләрен тонык кына елкылдатып, яшел поезд йөгереп узды. Урамнарда машиналарның өзлексез каядыр ашыкканы күренә, ә сирәк узгынчылар, якаларына, бүрекләренә кар мамыгы җыеп, салмак кына атлыйлар.

Йокысыз узган төннәр Ләйләнең хәлен алган, соңгы минутларда әнисе янында шат, хәрәкәтчән, ваемсыз булып күренергә тырышуыннан җаны-тәне талчыккан иде. Хәзер менә әнисенең дә, башкаларның да карашыннан читләшкәч, аңа һәммәсе төш кебек тоела башлады. Зиһене ярым томаланып, хыялый дөньяга чумгандай итеп сизде ул үзен. Берни уйламый агачлык аша салынган сукмактан узды. Институтның ишегалдына кергәч, ныклыгын кайтарырга теләп, иелеп учына кар алды, яңакларын, маңгаен ышкыды, салкын дымны теленә тигерде. Тамагына кайчан ризык капкан иде соң әле ул? Шәфкать туташы чәй керткән иде, анысын да эчәсе килмәде.

Институтның актлар залыннан урындыкларны алганнар, уртасына биек ятак ясап, табут куйганнар. Ул чәчәк такыялары белән уратылган, ишектән аларның яңадан-яңаларын кертә торалар һәм дивар буена тезеп куялар. Халык күп, әкрен тавыш белән сөйләшү тоташ гөжләүгә әверелә. Бу тавышка үзәк өзгеч скрипка тавышы килеп кушыла.

Ләйлә залны күздән кичерде, танышлар бик аз булып күренде. Кемнәрдер аның кулын кыса, кайгылы тавыш белән нидер әйтә, тик йөзләре дә, сүзләре дә зиһенгә барып ирешми, баштагы томанга уралып, шундук юкка чыга иде. Табутның дүрт ягында почетлы каравыл тора. Ләйлә чәчәкләр арасыннан үрелеп этисенең йөзенә карады. Ул тыныч, тик хәлсез булып күренде. Шушы рәвешендә аны җиргә илтеп күмәргәме? Ләкин бу ул — әти бит! Бите, чәчләре, кашлары, борыны шулхәтле газиз, тик күзләре генә йомык, иреннәре генә күгәргән. Ә бәлки, әнине һушына китергән кебек, аны да бу хәленнән айнытып буладыр? Мөмкиндер андый эш, тик бүгенге көнгә кадәр чарасы гына табылмагандыр. Әгәр дә Ләйлә табиб булса, ул шундый чараны эзләр иде һәм табар да иде. Бөтен гомерен шуңа багышлар, барыбер морадына ирешер иде!

Шунда ул ишек катында бүреген кулына тотып торган Равилне күреп алды. Башын игән, шунлыктан маңгай чәче нык сирәкләнгәне аеруча күзгә ташлана. Аркасы беләи ишек яңагына терәлгән, менә-менә авып китәр шикелле. Ләйлә, кинәт айнып киткәндәй булып, энесенә таба атлады.

— Равил, нык бул, без дә егылсак, әни ничек түзәр!

Равил апасына таба авышты, күзләреннән яшь бөртекләре тәгәрәп чыкты. Күптән инде аның елаганы юк иде. Соңгы тапкыр кайчан күрде соң әле Ләйлә аның күз яшен? Балалар бакчасына илткән чакта булса кирәк. Әллә урамда явыз малайлар таш атып башын тишкәчме? Ләйләнең шул чактагы кебек аның башын күкрәгенә кысасы: «Хәзер мин ул явызларның кирәген бирәм!» — диясе килде.

Тик әҗәлне куып тотып үчне алып булмый шул. Иң авыры — чарасызлык иде дә инде.

— Гомер кичкәндә адәм баласының башына килә шул мондый кайгылар, нихәл итәсең... Мин дә күптән түгел әтиемне җирләдем...

Кем әйтә бу сүзләрне?

Алар янына Изаил Харисович килеп баскан икән. Ләйлә нидер әйтмәкче булып авызын ачты. Ни сөйли бу адәм? Аның әтисе үз үлеме белән үлгәндер, ә Ләйләнең әтисе көтмәгәндә һәлак булды, вакытсыз, очраклы рәвештә! Аның әйтелмәгән соравына Изаил Харисович:

— Минем әти дә кинәт вафат булды,— дип җавап бирде.— Яшь иде әле.

Аның гадәттә ялтырап торган күзләре тирәннән, йөрәк ярасын күрсәтеп карыйлар, аларда чын-чынлап олы кайгы чагыла иде. Ләйлә аның үзләренә килеп йөргән чакларын исенә төшерде. Ничек сокланып, зурлап, кызыгып карый иде бу кеше профессор Ильясовка! Аның белән сөйләшеп утырырга, ничек эшләгәнен, нинди ачышлар ясаганын, чит ил галимнәре белән ни рәвешле элемтә тотканын сорашырга ярата иде. Андый чакларда ихлас иде ул, һәм бүгенге югалтуны да бик авыр кичерә кебек күренә иде.

Дөрес, бу фаҗига аңа файдага — алга барыр юлны ача иде. Бер генә мизгелдә Ләйлә, йөрәк түрендә бертөрле сөенечле җиңеләю кичерми микән бу кеше, дип үз-үзеннән сорап куйды. Ләкин бу сорау җавапсыз юкка чыкты. Хәзер инде анысы ул хәтле үк мөһим түгел кебек тоелды.

Изаил Харисович үзен биредә бик якын кеше итеп тота иде: ул, сул беләгенә кызыл тасма бәйләп, почетлы каравылга басып торды, матәм җыенында сүз алып, мәрхүмне башка күп галимнәргә үрнәк итеп мактады. Ләйләнең башында кайгы сөреме аша гаҗәпләнү чаткысы чәчрәп-чәчрәп киткәндәй булды: «Күр син моны! Шушындый чакларда да икейөзлеләнеп була икән!» Тик бу чаткылар чагылып уза да күңелне биләп алган караңгылыкка чума иде.

Кайгылы тавыш белән сөйләнгән сүзләр, җыелган халыкның йола үтәп, бер-бер артлы тезелешеп мәрхүм тирәли әйләнеп узулары — һәммәсе Ләйләгә сагышлы төштә күргән кебек тоелды.

Урамга чыккач, кинәт яңгыраган музыка аны сискәндереп, айнытып җибәрде. Ул тураеп куйды, кинәт уянгандай күзләрен киң ачып, юлның сул ягына баскан оркестрга карады. Болытлы көндә елтырап торган торбалар, баш очына күтәрелгән киң тимер тәлинкәләр, барабаннар хәзер аның кайгысын көчле яңгыратып ераклларга чәчәләр, тирә-юньдәге һәммә кешенең күңеленә шом салалар. Бу хәсрәтле моң агачлык артындагы хастаханә бинасына да барып ирешәчәк бит! Ләйләнең әнисе дә ишетер, сискәнеп куяр: «Матәм маршы бит бу! — дияр.— Кайда уйныйлар? Кемне шулай зурлап озаталар?!» Соравына җавап алмыйча, күңеленә кергән шикнең төбенә төшмичә калганы юк, монда да сәбәбен белмичә тынычланмас. «Якында гына уйныйлар, — дип уйланыр. — Ә монда иң якыны— институт бинасы... Кемнең, кайсы мәрхүмнең женазасын шушылай зурлап үткәрәләр икән?..»

Ләйлә оркестр каршысында кулын болгап торган ир кешенең беләгенә ябышты:

— Туктагыз! Уйнамагыз!

Дирижер аңа гаҗәпләнеп текәлде.

— Әнием ишетер... Ул белми бит әле...

Ләйлә сүз таба алмыйча ярдәм эзләп артына борылды. Янына Изаил Харисович килеп баскан икән. Ул алгарак узды да ике-өч сүз белән хәлне аңлатып бирде.

Ләйлә, башын күтәреп, йөзен кар бөртекләренә каршы куйды да күзләрен йомды. Карлар җиргә төшеп, калын юрган булып ята. Вакыты җиткәч эрер. Бүген бәскә төренеп утырган агачлар җылы яңгырлар астында юынып, яфракка төренер. Җир яшәрер, күктән кояш көләр. Тик Ләйләнең әтисе генә булмас... Ансыз дөнья була ала микәнни?

Юк, бу хакта болай күп уйларга ярамый. Чөнки еларга ярамый. Күзләре кызарып, иреннәре җилсенеп чыкса, әнисе ни уйлар?..

...Зираттан Ләйлә туры хастаханәгә кайтты. Процедуралар бүлмәсенә керде дә:

— Миңа берәр хәл кертә торган укол ясагыз әле, зинһар, — диде. — Көчлерәген!

Шәфкать туташының йөзе ничек үзгәргәнен күрмәде, чөнки ул күз алдында ак тап булып кына шәйләнә иде.

«Әгәр үзем табибә булсам, даруның көчлерәген сайлар идем,— дип уйлады ул,— әнигә дә ныграк ярдәм итә алган булыр идем. Әгәр табибә булсам...»

Берничә минуттан аңа әнисе янына дәртле адымнар белән, шат кыяфәттә, елмаеп барып керергә кирәк иде.

***

Иртән тәрәзә пәрдәләрен ачкач, Зәйтүнә шактый вакыт ишегалдына карап торды. Тышта оеп йомшак кар ява, көн соңарып, бик әкрен килә, дөнья серле һәм пакь иде. Мондый чакларда яшь күңелләрдә дәрт кузгала, картларны исә сагыш баса, хасталарның чире көчәя.

Ямансу да, ярсу да иде Зәйтүнәнең күңеле. Аның артында Әнвәр Тимербулатны түшәмгә чөеп уйната, баланың көлгәне, гөрелдәгәне ишетелә. Бүген ял көне, Әнвәр өйдә булыр, шушы рәвешле бала белән генә сөйләшеп, үзара сүз кушмыйча, бер-берсенә күз салмаска тырышып узар микәнни көннәре?

Алай да тышка карап, ямансулап торып кына булмый. Ял көненә өйдә мең төрле эш җыелган була. Шуның өстенә яңа килгән медицина журналын караштырасы иде, күптән башланган фәнни хезмәтне төгәлләп, мәкалә рәвешендә язып бетерәсе бар. Җитлегеп килгән кыз балалар өчен махсус яза башлаган китапчыгы да көтеп тора. Һәммәсенә өлгерергә кирәк!

Зәйтүнә көрсенеп кухняга чыкты, балага ботка пешерде, чәй кайнатты. Әнвәр аның белән сөйләшми, ләкин Зәйтүнә таш атканга таш атып җавап бирү ягында түгел: өстәлгә өч чынаяк куйды.

Әмма ул кухнядан чыкканда, Әнвәр киенеп ишек төбендә басып тора иде инде. Тимербулатка: «Сау бул, улым, сау бул!» — дип кул изәде дә чыгып та китте. Бала баштарак аны уйный гына дип белде, менә-менә кире керер дип ишеккә карап көтте, аннары ныгып җитмәгән тәпиләре белән чыгу ягына талпынды, абынып егылды да елап җибәрде. Башка вакыттагыча иркәләнеп, юри кычкырып түгел, бер чарасыз калгандай нечкә тавыш белән әкрен генә елый, ике бит очыннан мөлдер-мөлдер яшь бөртекләре тәгәри. Зәйтүнә аны күтәреп күкрәгенә кысты: «Елама, бәбкәчем, елама... Әтиең хәзер кайта, мәми алып кайта...»

Иң газиз кешеләреңне шушы рәвешле газапка салырлык гамәл кылырга ярыймы? Моны акларлык сәбәпнең булуы мөмкинме? Нинди көч алып чыгып китте Әнвәрне өеннән?

Эчкечене — аракыга, тәмәкечене — тәмәкегә, бозык гашыйкны сөяркәсенә тарта торган көч иде бу һәм баланың нәни кулларында да, Зәйтүнәнең үпкә-рәнҗешле карашында да аңа каршы торырлык кодрәт юк иде.

Әмма ни генә булмасын, бала кочып, яшь түгеп кенә утыра алмый ул. Эчендә ут янса да, елмай, көл, балаңны уйнат, өй мәшәкатьләренә чум. Ана эш белән мәшгуль чакта бала да үзен тыныч хис итә, уен белән мавыга, гамьсез була. Җәмилә Закировна хаклы: хәрәкәтләнсәң, кайгылар җиңелрәк кичерелә. Сагышлы уйларга чумып тик утырсаң, пыскып яткан кисәү кебек сызып кара күмер булырсың. Ярый әле эш күп: өйне җыештырырга, кибеткә барырга, баланы урамда йөртергә кирәк. Аннары уку-язу эшләре белән утырырга мөмкин булыр. Үзеңә тын алырга да ирек бирмәскә кирәк!

И оеп та ява соң карлар, адашкан адәмдәй ак көртләрне ерып, кая китте икән Зәйтүнәнең Әнвәре?

Кинәт телефон зыңгылдады. Кәүсәрия килендәш икән.

— Син нишлисең әле? — ди.

— Юам, җыям, тазартам.

— Бөтен эшеңне ташла, матур итеп бизән, балаңны курчак итеп киендер дә хәзер үк безгә килеп җит!

— Хәзер үк бара алмам бит, Кәүсәрия, эшем күп.

Зәйтүнәнең бу хәлендә кеше күзенә күренеп йөрисе килми иде.

— Эш бетмәс ул, үлгәндә дә өч көнлек кала, диләр. Ә менә шушы сәгатьтә безгә килмәсәң, үкенеп бетә алмассың. Ишеттеңме: гомер буе үкенәчәксең! Идәнеңне юарсың, китабыңны укырсың, язасыңны язарсың, ә бу көнне кайтарып ала алмассың!

Кәүсәрия бераз тынып торды да сүзләренә җавап булмагач:

— Гөл итеп киенегез дә елмаешып килеп керегез,— дип кабатлады.— Тик абыеңа мин чакырганны әйтмәссең, хәлегезне белергә килдем, диярсең.

Соңгы сүзләр Зәйтүнәне сискәндерде дә, ышандырды да. Гаилә тормышын көйле алып бару өлкәсендә Кәүсәрия чын профессор иде. Өстәвенә килендәшен бик тә үз итә, аңа һәрчак теләктәшлек күрсәтә. Инде болай чакыра икән, җитди сәбәбе бардыр. Ә бәлки, кунаклар килгәндер дә, табынга килендәшен дә чакырып, күңелен ачарга теләведер. Шулайдыр. Чөнки Әнвәр белән аралары кытыршыланганын белми калмагандыр, мөгаен.

Тышта дөнья тәрәзәдән күргән кебек кенә түгел, тагын да ямьлерәк булып тоелды. Ябалак кар күбәләк булып очына, аяк астына мамык булып түшәлә иде. Күкләрдән иңгән бу пакьлектән бар мохит чистарган, җиңелчә ак буран күзне адаштыра, авыр уйларны тарата иде.

Ишекне Әнвәрнең абыйсы Әзһәр ачты. Кыяфәте, йөз сызыклары белән ул энесенә охшаган, тик бераз юантыграк, тәбәнәгрәк, чәче дә сирәгәйгән, йөзеннән җылы нур да ул хәтле мул сирпелми. Зәйтүнәне күргәч, кыенсынып киткәндәй булды, артка чигенеп, гажәпләнгәндәй:

— Ә-ә, килен, синмени әле бу? — дип, сызганулы җиңнәрен төшерә башлады. Зәйтүнә, аның иңбашы аша эчкә күз салды: зал уртасында табын әзерләнгән иде.

— Вакытсыз килдекме әллә? — диде ул, каенагасын кыен хәлдән чыгарырга теләп.

Ул арада кухнядан кызыллы-зәңгәрле алъяпкыч бәйләгән, бөдрәләткән кара чәчен шундый ук кыекча белән җыеп куйган, түгәрәк бит очлары алланган Кәүсәрия килеп чыкты:

— И-и, көтелмәгән тансык кунаклар килгән икән! Мактап йөрисез, бәхетле авызлар икәнсез, мичтән бәлеш чыгуга өлгердегез генә! Әйдә чишен, түргә уз, килендәш!

— Кунак көтәсез, ахры, ә без белмәгән идек, бер күреп чыгыйк дип кенә кергән идек.

Зәйтүнә үзенә тапшырылган рольне ышандырырлык итеп башкарырга тырыша иде. Тик Әзһәр аны рәтләп тыңламый, кая басарга белмәгәндәй ишек төбендә таптана, күлмәк җиңнәрен бер күтәрә, бер төшерә иде. Кәүсәрия кысан коридорга чыгып, ирен эчкә таба этте:

— Син бар, кереп тор, кунакларга чишенергә ирек бир.

Беренче карашка аны чибәр дип булмый: буе кыска, болай да йомры башы, чәчен күпертеп куйганга, зур булып күренә. Түгәрәк йөзендә киң борын, калын иреннәр, чыраен су чәчәгеннән калган нәни уемнар чуарлаган. Таза тормыш һәм ваемсыз холык аны шактый ук түгәрәкләндереп җибәргән иде. Тик шулай да ул бер карауда үзенә карата мәхәббәт уята: башын артка ташлап, тигез тешләрен җемелдәтеп елмаюында, күтәренке тавыш белән сөйләшүендә гадилек, эчкерсезлек, ярдәмчеллек чагыла иде. Тормышның һәртөрле көйсезлекләрен җиңел үткәрә, башка-бүтәннәрнең хәсрәтләрен кыска бармаклы йомшак куллары белән таратып кына ташлагандай итә. Кыскасы, килендәшләр, кыяфәт-фигыльләре белән төрле-төрле булсалар да, ә бәлки, шуның аркасындадыр, баштан ук килешеп яшәделәр.

Каенагасын исә Зәйтүнә моннан берничә ел элек вафат булган каенатасы урынына күрә, аңа карата татар хатыннарының борынгыдан килгән йоласы — тел яшерү кебегрәк мөнәсәбәт саклый иде. Һәр сүзен зурлап кабул итә, сораганына төгәл җавап бирә, аның алдында юкны-барны сөйләшми — олылавын һәрдаим сиздереп тора иде.

Кәүсәрия Тимербулатның тунын салдырырга кереште:

— Иң кадерле кунагым менә шушы инде минем!

Алар чишенеп эчкә үтүгә, Әзһәр алгы бүлмәгә чыгып ашыгып аягына киде. Каракүл якалы пальтосын иңенә генә салды да бүреген кулына тотып чыгып та китте.

Кәүсәрия табын уртасындагы аяклы пыяла савыттан алма алып Тимербулатка сузды.

— Мә, улым, ашый тор. Әрчеп бирәсеңме әллә, килендәш?

Савытның ике ягында ике шешә — аракы белән коньяк тора. «Безнең өчен әзерләгән табын түгел бу», — дип уйлады Зәйтүнә аларны күреп. Алар өчен булса, аракы гына куелыр иде — Әзһәр белән Әнвәрнең коньякка исләре китми. Зәвыгы билгесез кешеләр өчен, ятлар өчен әзерләнгән табын иде бу...

Кәүсәрия, аның күзенә туры кararга кыенсынгандай, артыгын каударланып кухня белән ике арада йөри башлады. Менә ул, табын уртасындагы тәлинкәләрне читкәрәк этәрде дә, таба белән шулпалы бәлеш китереп утыртты. Тәмле ис таралып, өйне тагын да ямьләндереп җибәрде, авыздан сулар китерде. Гадәттә кунак табынына бәлешне алдан ук куймыйлар, аштан соң гына китерәләр. Йорт хуҗасы Әзһәр аны аягүрә басып, матур бер йола башкаргандай итеп турый иде. Бу юлы исә Кәүсәриянең кыланмышларында, без монда үзебез генә, башка беркемне дә көтмибез, диясе килгәне сизелде.

Тышкы ишекнең ачылганы ишетелде, җылы курткасының изүен ачып җибәргән Әнвәр килеп керде.

— Син каян монда килеп кердең әле? — дип, Зәйтүнәнең йөзенә ачу белән текәлде ул. Зәйтүнә аны-моны аңлап өлгергәнче, арага Кәүсәрия кереп басты.

— Килендәшнең миңа сүзе бар икән, якын итеп килгән,— диде ул, гамьсез кыланып.

Әнвәр аны читләштереп эчкәрәк узды:

— Ю-ук, синең янга килмәгән ул... Мине эзләп йөрүе! Үзе барасы килгән җиргә машина белән чаптырып кына барып кайта да, аннары минем арттан шымчылык итәргә керешә. Көн дими, төн дими, мине эзәрлекли. Һич котылыр әмәл юк!

Зәйтүнә Тимербулатны кулына алды да, сынын тагын да ныграк турайтырга тырышып, иренең йөзенә текәлде. Тукта, бу соң аның ireme? Нур шәүләсенә тиң Әнвәрме, керфегеннән нурлар тамган сөйгән ярымы? Караңгы, усал, шул ук вакытта куркынган чырайлы бу адәмне Зәйтүнә беренче тапкыр күрә түгелме?

Кем үзгәрткән Әнвәрне бу рәвешле, кем аның йөз нурын качырган, кем шушы хәлгә китергән?

Иренең бу кыяфәтеннән Зәйтүнә өнсез калган иде.

Аның урынына Кәүсәрия телгә килде:

— Ни сөйлисең син? Килендәшкә килү гаеп эшме әллә? Син монда әллә кемнәрне ияртеп килер дигән уй каян килсен аның башына?

Бу сүзләрдән Зәйтүнәнең уйлары яктырып китте. Әһә, хикмәт менә нәрсәдә икән: Әнвәр бирегә кемнедер алып килмәкче булган. Кемне?! Анысы күптән билгеле бит инде! Менә нинди икән бит аларның бәйләнеше: йөзне каралта, күңелне таш итә торган тойгылар бәйли икән бит аларны... Чын сөю шундый була ала микәнни? Зәйтүнәне яраткан чагында, аның йөзенә нур сирпеп караганнан соң, берничә адымга ерагаюга, икенче берәүгә шушы рәвешле каралып, үчләнеп, ярсып текәлүе мөмкин идеме аның? Туганнарын, якыннарын, баласын шушылай чит итүе мөмкин идеме?

Чыннан да Әнвәрме соң бу? Зәйтүнә аны ничек тә тынычландырырга, йөзеннән бу усал ярсуны сөртеп алырга теләгәндәй, үзе дә сизмәстән кулын күтәрде. Әнвәр кисәк артка тайпылды — китереп бәрә бу дип уйлады булса кирәк. Ул хәтта шуны да мөмкин дип саный иде, чөнки күңел түрендә бу минутта үзенең хаксызлыгын, түбәнлеккә төшкәнен аңлый иде. Әмма бирешергә теләмәде, кулы белән булмаса, сүзе белән кизәнде:

— Сулыш алырга җай калмады, — диде, күлмәк изүен ычкындырып. — Минем арттан чапканда, трамвай да басмый, ичмасам, үзеңне!

Бу инде чыннан да аяктан егарлык итеп сугу иде. Әгәр кочагында Тимербулат булмаса, Зәйтүнә егылып китәр иде. Ул баланың йөзенә карады. Малайның күзләре зур ачылган, әтисенең сүзләрен аңламый, әмма тавышыннан шулкадәр курыккан, хәтта елавын да оныткан, күзләре коры иде. Ә бит иртән әтисе артыннан ничек өзгәләнеп елап калган иде ул!

Биредә инде эш елаудан узган иде шул. Зәйтүнә башын күтәрде дә, керфек кагарга да онытып, иренең нурсыз калган, упкын төсле күзләренә төбәп карады. Һәм чарасызлыгыннан ярсуын, хаксызлыгын аңлаудан бәргәләнгән вөжданының сызлануын күргәндәй булды.

Бүлмә һавасы эсселәнгәндәй тоелды, һәммәсенә оят булып китте. Моңарчы арттарак дәшми генә басып торган Әзһәр тәвәккәл хәрәкәт белән энесенең җилкәсеннән тартты да, үзенә таба борып:

— Җиттеме сиңа, юкмы! — диде. — Кемне каргыйсың син болай? Кемгә бәхетсезлек телисең? Менә синең гомерлеккә дип сайлап алган хәләл җефетең, менә синең газиз балаң! Моннан ары минем алда Зәйтүнәгә авыр сүз әйтәсе булма!

Шулай дип, ул ботинкасы белән идәнгә тибеп куйды. Әнвәр берни дәшми чыгып китте.

— Бар-бар, кәнтәең каршында дула, монда килеп табынның ямен җимереп йөрмәсен! Ха-ха-ха! — дип көлеп калды аның артыннан Кәүсәрия.

— Ә син нәрсә дип авызыңны ерасың? Шулхәтле кызыкмыни? — диде ачуланып Әзһәр.

— Кызык шул! Көләбез! Намусыбыз чиста чөнки. Пычранганнар еласын! Шулай бит, килендәш?

Әзһәр кулын селтәп чыгып китте. Аңа да оят, килене каршында басып тору читен иде.

— Кара син аларны! — дип башын селкеп калды Кәүсәрия.—Аерылышабыз, дип минем бозауны тәмам ышандырып бетергән бит синең тилең. Эш судта, имеш, көнен генә көтәсе калган. Хәзер безгә киләләр дә ярәшү кичәсе сыман нәрсә үткәрәләр, янәсе. Килми торсыннар әле! Җыен кәнтәйне тыгындырырга артык ризыгым юк! Тапкан! Ирләрнең асылына асылыналар үзләре, койма янында аунаган артык-портыкка күзләре төшми!

Ул Зәйтүнәгә сынап карады: бик бетерешмиме, еламыймы, янәсе. Килендәшенең баласын тезенә алып, өстәл янындагы урындыкка утырганын күргәч, җиңеләеп:

— Әйдә, килендәш, рәхәтләнеп сыйланыйк әле,— диде.— Ашауның тәнгә мең дә бер шифасы бар, диләр. Сезнең медицина фәне ни әйтә бу хакта?

Зәйтүнә үзен тыныч тавыш белән сөйләргә мәҗбүр итте:

— Башкасын белмим, син пешергән бәлешнең шифасы ифрат зур була.

— Чыннан да шулай бит, килендәш,— дип, уенны күтәреп алды Кәүсәрия. — Мин пешергән бәлешләр чырайга төс кертә. Кайчакта менә кара коелып кайтып керә инде Әзһәр эшеннән. Заводта мастерның нервысын ике яклап ашыйлар бит аның: бер яктан — җитәкчесе, икенче яктан — эшчесе. Кулларын юып, мин әзерләгән табын янына утыруы була, бөтен гамьнәре ком урынына коела да төшә, йөзе кояш чыккандай була моның... Әйдәле, килендәш, уймак хәтле генә берәрне җибәрик әле! Аларга ачы булсын, безгә татлы булсын!

Кая татлы булсын ди! Ярыңның-парыңның сиңа үлем теләвеннән дә ачырак ни булсын бу дөньяда!

Бу уй Зәйтүнәнең бәгыренә пычак белән сызгандай итте. Тик ул авыртуга бирешмәскә кирәген аңлады: сине — тол, балаңны ятим итәргә тырышалар, шуның өчен астыртын көрәш бара — син җебеп төшәрсеңме, егылып ятарсыңмы? Сызлануларны онытып, акыл белән, ныклык белән эш итәргә кирәк! Ләкин ничек?!

— Мондый чакта бик файдалы бер дәвасы бар аның барын,— диде Кәүсәрия, аның уйларын аңлагандай. Мәгънәле итеп тынып торды, тәмләп кенә рюмкадан бер йотым коньяк кабып куйды.— Әйбәт кенә, ипле генә, сөйкемле генә бер кеше белән сөйләшкәләп йөрергә кирәк. Тик кеше-кара күрмәсен, үзең генә бел. Зерә юата. Шифасы бик зур.

Зәйтүнә чиркангандай йөзен җыерды.

— Ай Алла, мин сиңа әшәкеләнеп йөрергә кушмыйм лабаса! — диде Кәүсәрия моны күреп.— Үзеңнең дә төшеп калганнардан түгел икәнлегеңне белеп торыр өчен кирәк ул. Дәрәҗәңне үстерер өчен, төшенкелеккә бирелмәс өчен кирәк!

— Юк андый кеше! — диде Зәйтүнә, Кәүсәриянең сүзләреннән бигрәк ире ташлаган гаепне кире кагарга теләп.

— Әй, юкны сөйләмәсәнә! Шушындый яшь, чибәр, ягымлы, акыллы, талантлы хатын өчен ут йотып йөргән кеше булмый димени!

Шулай дип, Кәүсәрия Зәйтүнә каршында торган озын аяклы, су тулы бокалга рюмкасын китереп бәрде дә, башын кырын салып, бәллүрнең чыңын тыңлап торды, ә үзе куе керфекләре арасыннан килендәшен күзәтте.

Зәйтүнәнең күз алдыннан Мөдәрриснең башын кырын салып, кыенсынып карап торган чагы, аннары машинада Тимербулатны тезендә тибрәндереп уйнаткан мәле чагылып узгандай булды.

Әйе, бүген Зәйтүнәнең йөрәген яралап, дәүләтен басып алдылар. Ләкин ул көрәшәчәк әле. Бу көрәштә Мөдәррисне үзенә ярдәмче итә аламы ул?..

Тукта, тукта, ашыгырга ярамый, аңа әле хәл җыярга, көчен тупларга кирәк. Бераз вакыт үтсен...

— Кәүсәрия, хәтерлисеңме, син миңа бер хатынны җибәргән идең? Илзирәк исемле, — диде ул, сүзне икенчегә борып. — Кызы туган иде бит аның. Ничегрәк үсә икән?

Аның бу соравын ишеткәч, Кәүсәрия бертын зиһенен туплый алмый утырды. Аннары урыныннан торды да, янына килеп, иңеннән кочаклап алды:

— Зәйтүнә, газиз килендәшем, бәгырь кисәгем, мондый минутларда ничек исеңә төшерә аласың син аны? Терекөмеш кебек кызы, тәгәрәпләр үсеп килә! Үзе икенчесенә корсаклы инде, бусын бик җиңел күтәрде, табар чагы җитеп киләдер. Их, изге җан бит син, Зәйтүнәкәй, Әнвәрнең күзләрен шуны күрмәслек итеп нинди сихер белән томаладылар икән соң? Бу ир дигәннәре бөтенесе ахмак! Ниләр генә күрсәтмәде минеке дә!

Кәүсәрия авыр гәүдәсен килендәшенең иңенә салып, күз яшьләрен сөртеп алды. Зәйтүнә бер кулы белән улының башыннан сыйпады, икенчесе белән Кәүсәриянең беләген кысты.

...Кайтырга дип урамга чыккач, ул тукталып башын күтәрде, күзләрен йомды. Кар күбәләкләре йомшак, салкынча канатлары белән кызган маңгайны, кипшенгән иреннәрне сыйпадылар, гүяки юатырга теләделәр. Ах, шулар арасында эреп юкка чыксаң иде, башка беркайчан да күзләреңне ачмасаң иде!

Ләкин Тимербулат кулдан тарта, нәрсәдер бытылдый. Зәйтүнә аны кулына күтәрде дә, калын киемнәр аркылы саркыган җылысын тоеп, тәненә хәл кергәнен сизде. Трамвай тукталышына барыр юлның сулында буш уйсулык бар, аның турыннан узганда ул беразга тукталып калды. Уйсулык читендә үскән карасу-күгелҗем чыбыкларга тезелешеп... тал бибиләре чыккан иде. Зәйтүнә үз күзләренә үзе ышанмыйча, аларга кулы белән орынды: әйе, болар чыннан да тал бибиләре — йомшак, назлы, җылы бөреләр иде. Бозланып каткан җир өстендә, ак давыл арасында алар яз сәламе, яшәеш тантанасы булып ачылган иде.

***

Бала тудыру йортының башка хастаханәләрдән бик зур аермасы бар: биредә хасталар түгел, сәламәт кешеләр ята. Алар бу йортка табигать тапшырган олуг вазифаны башкару — яңа тормышка башлангыч бирү өчен кергәннәр.

Шунлыктан монда башка хастаханәләрдә булмый торган күтәренке рух хөкем сөрә, сүзләр дә чир-чор, дарулар хакында түгел, сәламәт тормыш мәшәкатьләре: бала тәрбияләү, мәхәббәт, каенана-каената, туган-тумача белән үзара мөнәсәбәт турында бара.

Палаталарда иртәнге биштән алып төнге сәгать бергә кадәр ыгы-зыгы, җанлы хәрәкәт тынмый диярлек.

Фәкать Алтынчәч кенә бу куанычлы мәшәкатьләрдән читтә кала. Биредә ул олы, таза гаиләнең аяктан егылып яткан бер хастасы кебек. Коридордан үтеп-сүтеп йөргән хатыннарның ачык ишектән күз салганда йөзләре сүрелеп китә, тавышлары әкренәя.

Линар белән очрашкан кичне Алтынчәчне «ашыгыч ярдәм» машинасы белән бирегә китергәннәр һәм шундук бәбиен таптырганнар. Рөхсәт-ни сорап тормаганнар, ярым һушсыз кеше белән сөйләшеп буламыни?

Берничә сәгатьтән, аның зиһене тәмам ачылгач, табибә кояштай балкып:

— Котылдың бит, сеңлем! — диде. — Ә без синең өчен бик курыккан идек. Менә бит, хәлең яхшыра. Улың да бик тере. Юып-төреп салуыбыз булды, чүпрәк аша бармагын тапты да, авызына кабып суырырга тотынды. Бер дә андыйны күргән юк иде. Өлгер-уңган егет булыр, мөгаен.

Табибә куанычыннан балкып көлде, ә Алтынчәч ямансу гына елмайды.

— Сусаган булгандыр ул, — диде. Соңгы атналарда аның үзенә сыеклыкны тәүлегенә нибары дүрт стакан гына эчәргә куштылар, шунлыктан ул гел сусап яшәде. Карынындагы бала да аның белән бергә интеккән икән!

Башка әниләргә бәбиләрен унике сәгатьтән соң имезергә бирәләр. Бу мизгелне һәркем әзерләнеп, дулкынланып каршы ала. Иң элек шәфкать туташы яшел клеенкадан тегелгән капчык кертеп, карават башына асып куя. Капчык эчендә башка бәйләр өчен ак кыекча, битлек, бала чүпрәге зурлыгындагы клеенка. Сабыйны башка яулык бәйләп, битлек киеп, мендәр өстенә чиста клеенка җәеп каршы алырга кирәк. Яшел капчыкның карават башына эленеп куелуы — һәр ана өчен зур сөенеч. Тик менә Алтынчәчкә бу куанычны тиз генә татырга туры килмәс, ахрысы. Иртәнге обход вакытында табибә: «Башта сезнең үзегезгә ныгырга, сәламәтләнергә кирәк әле», — диде. «Әллә минем сәламәтләнмәвем дә ихтималмы?» — дип сорады Алтынчәч. «Сез шуны аңлагыз, хәзер без өчәү: сез үзегез, мин һәм чир. Әгәр дә сез минем белән берьяклы булып, чиргә каршы бергәләп көрәшсәк, әлбәттә, җиңәрбез. Ә менә төшенкелеккә бирелеп, көрәштән туктасагыз, миңа сезнең икегез белән көрәшү авыр булачак. Әйдәгез, көчләрне берләштерик!»

Алтынчәч аның йөзен томанлы гына күрә иде. Мөһимә өендә егылганда, күзлеген төшереп ваткан, шунлыктан ул бик начар күрә, башы авыртуын шуннандыр дип белә иде.

Алай да табибәнең ягымлы, йомшак, шул ук вакытта ышанычлы таләпчәнлек белән әйткән сүзләре аның күңеленә кереп утырды. Ялгызы калгач ул, күзләрен йомып, уйларын күңелле нәрсәләргә юнәлтергә тырышты. Мәсәлән, балачакка.

Алтынчәч — сугыш чоры баласы. Бердәнбер абыйсы белән яшь аермалары зур булганга, урамда да, мәктәптә дә , башка балалар арасында да үзен ялгыз хис итте. Ул бәләкәй чакларда мәктәп балаларын басуга алып барып, урган җирдә коелып калган башакны җыйдыралар иде. Укуда алдынгы Алтынчәч бу эштә дә артта калмаска тырышты. Басу кырыннан берничә эзне иңләп ала иде дә, иелеп, җиргә текәлеп бара иде. Ул шулай һәр камылны бөртекләп дигәндәй күзеннән үткәргән арада, иптәшләре сикергәләп-йөгергәләп әллә кайларга китеп бара. Уйнап-көлеп кенә йөриләр сыман, ә укытучы янына килеп бизмән белән үлчи башласалар, капчыкларындагы башак икешәр-өчәр кило тарта. Бер Алтынчәч кенә ике йөз грамм белән кала. Ул моңа шулкадәр ояла иде! Аның күзе начар күргәнен беркем игътибарга алмый, чөнки моны ул үзе дә белми иде әле.

Кичләрен еш кына әнисе аңа көтүдән кайтмаган малларны эзләргә куша иде. «Син, кызым, урам буйлап әлсерәп йөрмә, ындыр артындагы үргә генә менеп кара, — дип өйрәтә торган иде ул. — Безнең бер сарык кара битле бит, әллә каян күренеп тора». Баласының хәлен ул да аңламый иде!

Кич болынга сыер сакларга чыгалар, анда уен белән мавыгып, малларның таралышып беткәнен сизми калалар иде. Караңгы төшкәч кенә төрлесе төрле якка үз сыерларын эзләргә сибелә. Алтынчәч берәрсенә ияреп йөри. Ул кеше сыерын куышып кайтканда, үзенеке әллә кайда кала. Иртән яктыргач, әнисе малкайны берәрсенең ындырыннан табып алып кайта.

Балачактан ук Алтынчәч үзен җитәкләп йөрүчегә мохтаҗ булды. Бу хәлләрне исенә төшергәч, аның күзләренә яшь килде. «Тукта,— диде ул үз-үзенә,— күңелле нәрсәләр турында уйларга тырыш...»

Җиденче класста укыганда, алар «Кызыл галстук» дигән пьеса куйганнар иде. Алтынчәчкә төп рольне бирделәр. Тик көне җиткәч кенә аны бизгәк чире аяктан екты. Әле туңудан дер калтырап, әле утта янгандай кызышып ятканда, укытучы Мәрьям апа хәл белергә килде. «Синең рольне Ләйләгә бирергә туры килер инде», — диде ул. «Үзем барам, үзем уйныйм!» — дип торырга талпынды Алтынчәч. Һәм, чыннан да, барды, уйнады. Сүзләрне яхшы белә, рольгә шәп кергән иде. Тик соңыннан малайлар: «Алтынчәчнең артына гер асканнар иде бугай, сәхнәдә гел урындыкка утыру ягын карады», — дип сөйләп йөрделәр.

Боларны искә төшергәч, янә күңеле тулды.

Ишектән озынча ак шәүлә булып җыештыручы апа килеп керде дә таяк башына уралган чүпрәк белән идәнне сөртә башлады.

— Ни кайгың бар? Ник елыйсың? — дип сорады ул.

— Баланы имезергә бирмиләр,— диде Алтынчәч. Апаның йомшак тавышы аның тамагына бөялеп торган буаны нык ук ерып җибәргәндәй итте, яшь тамчылары бит очларын пешереп тәгәрәштеләр.

— И-и, җаный! — дип сузды апа.— Түз беразга! Аера алмый гажиз булырсың әле.

Ул чыгып киткәч, дежур табибә керде, Алтынчәчнең караваты кырыена утырып, хәлен сорашты.

— Иртәгә сезне башка больницага күчерербез, мөгаен,— диде. — Анда бик яхшы белгечләр, менә дигән аппаратлар бар. Ә без үз вазифабызны үтәдек, бәбине кулга алдык бит инде.

— Улымны күрәсем килә, — диде Алтынчәч.

— Анысын иртәгә сөйләшербез. Ә хәзер тыныч йокларга тырышыгыз.

Аннан соң шәфкать туташы кереп укол ясады да, янә тыныч йокы теләп, утны сүндереп чыгып китте.

Кичке сәгать уникедә, сабыйларны соңгы тапкыр имезергә тараткан да, Алтынчәчнең күңеле бик тә ярсый башлады. Менә сабый елаган тавышлар якынайды, коридорда чаж-чож йөренгән тавышлар ишетелде. Менә мәгънәле тынлык урнашты: җир йөзендә мөкатдәс бер эш — тормышны, яшәешне дәвам итә торган, безнең кан кайнарлыгын киләчәккә илтә торган эш башланды.

Башкалар өчен башланды... Ә менә Алтынчәчнең улы — сабые коридорның аргы башындагы ишек артында ялгызы калгандыр. Шәфкать туташлары биредә балаларны әниләренә өләшә, ә ул анда нишли? Ятим итеп сизми микән үзен?

Алтынчәч урыныннан калкына төшеп кычкырып җибәрде:

— Сестра! Сестра!

Палатада ут кабынды.

— Ни булды? — дип сорады ишектән кергән яшь кыз.

— Миңа да баламны китерегез!

— Врач рөхсәт итми бит.

— Минем балам! Үзем җавап бирәм! Китерегез!

— Аны ашаталар бит. Имезәм дип ник шулхәтле өзгәләнәсез?

Сабыйларча нечкә тавыш белән әйтелгән бу сүздә таш битарафлыгы сизелде.

— Сеңлем! Әгәр дә син шуны да аңламыйсың икән, биредә эшләмә. Ә миңа балалар сестрасын чакыр! Бар, юкса хәзер торам да үзем эзләп китәм!

Ишектә киңрәк шәүлә шәйләнде. Балалар сестрасы өлкәнрәк яшьтә булса кирәк, тавышы да калынрак иде.

— Минем баланы да китерегез инде, башкалар әниләре янында, ә ул анда берүзе,— диде Алтынчәч, зарланып.

— Мин аның тамагын туйдырып куйган идем шул инде,— диде апа.

— Янымда гына ятып торсын бераз. Бик күрәсем килә.

— И, ачулансалар ачуланырлар, китерәм, — диде апа, кинәт тәвәккәлләп. — Ананың балага зыяны тимәс әле. Аңламассың бу врачларны да! Мә маска ки!

...Алтынчәч тетрәнгән куллары белән баланы күтәреп алды:

— Улым, газизем, бәхетем...

Битен битенә терәде, аны төргән чүпрәккә учын чак кына тигезеп, буеннан-буена сыйпап чыкты, тәпиләрен учына тотып җылытты.

— Күз нурым, йомшагым, бәгырь кисәгем...

Сабыйның күзләре йомык, саргылтрак төстәге нәни битендә каш урыннары чак кына калкынып тора, керфекләре юк иде.

— Бәхетең белән үс, балам. Гомерең иминлектә, тынычлыкта узсын!

Бала тыныч сулый, ә йөрәге кош баласыныкыдай лепелдәп тибә иде. Зәгыйфь, көчсез иде әле бу тормыш, аны яклау, саклау өчен ана кулы, ана йөрәге кирәк иде. Алтынчәч аны кочагына алып, күкрәгенә терәде.

Бер сәгать бәхет бишегендә тибрәлде ул. Сәгать буе үзен сәламәт, көчле хис итте.

Сабыен шәфкать туташына биргәндә:

— Балам белән күрештергән өчен бик зур рәхмәт сезгә,— диде. — Мин аны әллә күрәм бүтән, әллә юк, — дип өстәп куйды, үзе дә сизмәстән.

— Авызыңнан җил алсын! Баланы ятим итәләр димени! Ана кешенең үләргә хакы юк, шуны белеп тор!

Ул утны сүндереп чыгып киткәч, Алтынчәч башын мендәргә салып, күзләрен йомды. Аның тәнен татлы бер хәлсезлек биләп алган иде.

«Бераз үскәч, ул миннән әтисен сорар, ә мин аңа ул Англиядән килгән иде, монда эшен тәмамлагач, үз иленә кайтарып җибәрделәр, дип сөйләрмен. Ул шулай дип күңеленә беркетеп куйды һәм Оливерны күз алдына китерде.

Бу кичтә ул Линар турында уйларга теләмәде, аны бөтенләй искә алмады. Әйтерсең лә сабыйның орынып кына торуы да аның кайчандыр башка сыймастай гөнаһлы һәм ләззәтле янган тәнен тәмам ярлыкаган, кердән арындырган иде.

Алтынчәч яшь аралаш елмайган килеш йокыга талды. Аның төшенә лаборатория керде. Тәрәзә төпләрендә кыналар, кактуслар, яраннар һәммәсе берьюлы чәчәк аткан, имеш, ә ул гаҗәпләнеп кызларга әйтә: «Нишләгәннәр болар? — ди. — Кактуслар декабрьдә чәчәк ата, яраннар язын, кыналар җәй көне. Ничек болай бөтенесе берьюлы туры килгән?» — «Синең улың туу хөрмәтенә шулай туры китергәннәр алар, — дип көлә, имеш, кызлар. — Аның бәхетенә бу!» Ул арада, ишектән бөдрә башын тыгып, Нажия Нәкыйповна кычкыра, имеш: «Алтынчәч! Бар әле, заводтан аккан суларның анализын алып кил!» Алтынчәч мензурка алып чыга һәм күл буена килеп суга иелә. Ә су тонык, төбендә ялтырап кояш тәңкәләре уйный, алар арасында кызыл канатлы эре балыклар йөзеп йөри. «Кай арада шушы хәтле чистарган соң әле безнең заводның сулары? — дип гаҗәпләнә Алтынчәч. — Ә-ә, минем улым

туды бит! Шуңа бу, шуңа!» Ул кулын суга тыга, ә балыклар җим сорап аның учына төртеләләр. Борыннары йомшак, җылы...

Бу төн язмышның Алтынчәчкә биргән соңгы бүләге иде.

***

Палатага кояш төшми — тәрәзәләр көнбатышка караган. Шулай да көннең аяз, матур, якты икәнлеге сизелеп тора.

Караватта яткан Җәмилә Закировна кызына шундый ук якты, җылы карашын төбәгән.

Әле кайчан гына ул сызлаган кул-аякларын кая куярга белми борсалана иде, бүген менә торырга, тизрәк моннан чыгып китәргә ашкына.

— Күпме ятарга мөмкин, эш күп бит,— ди. — Әтиеңне дә тизрәк аякка бастырырга иде.

Бүген аның күңел күге аяз, кояшлы. Әмма тиздән кара болытлар ябырылачак — аңа иренең һәлакәтен әйтәчәкләр. Хәзергә исә Ләйлә әнисенең кояшын озаккарак сакларга тырыша.

— Нишләп әле Равил күренми? Аңа ул-бу булмагандыр бит?

— Әти янныннан институтына чаба, аннары заводка. Яңа компрессорларын һаман көйләп бетерә алмыйлар.

— Эше бик җаваплы шул,— диде Җәмилә Закировна.— Минем кан анда, җанын-тәнен биреп тырыша. Үземнең дә клиникада көн саен булганда гына җаным тыныч.

Ләкин Равилнең әнисе янына килә алмавының сәбәбе бөтенләй башка. «Мин уйный белмим, апа, — ди ул. — Күземә бер карау белән әни бөтенесен сизәчәк». Чыннан да, кайгыга нык биреште егет: агарынып, хәлсезләнеп калды, ябыкты. «Уйный алмыйсың икән, килмә, — ди аңа Ләйлә үзе дә. — Чыннан да, әнинең күз карашы бөтен күңелне операция лампалары белән яктырткандай итә».

...Ләйлә сүзне башкага борырга ашыкты.

— Әйдә, әни, яшь чакларыңны сөйлә әле.

— Минем сүзем шул инде: әтиең турында.

Күңеле нидер сизенә, «әтиең» димичә авызын ачмый ул бу көннәрдә.

— Табиб булырга да мине ул рухландырды. Яңа өйләнешкән чагыбыз иде, беркөнне әтиеңнең танышы килеп керде. Сөйләшеп утырдылар. Теге кеше дә әле генә өйләнгән икән. «Хатыным врач минем», — дип мактанды. Әтиең дә аның сүзен җөпләп: «Өйдә врач булу бәхет инде ул», — дип куйды. Аның бу сүзләре минем күңелемә кереп утырды бит. Ул чакта ветеринария институтының аспирантурасында укып йөри идем инде. Шуннан соң башыма уй төште. Уйладым-уйладым да медицина институтының икенче курсына укырга кердем. Күрдеңме, мәхәббәт нишләтә?

Ләйлә аңа йомшак кына каршы төште:

— Мәхәббәтен мәхәббәттер, тик бер кешегә карата гына түгел, — диде. — Минемчә, табиб булыр өчен гомумән кешеләрне ярату кирәк. Шулай түгелмени?

— Бәләкәй чагымда мин аягын имгәткән маэмайларны, канаты каерылган бәбкәләрне бик кызгана идем. Берзаман безнең бер оя үрдәк бәбкәләре борчак ашаган. Аннары су буена төшеп киткәннәр. Әле дә күз алдымда: тәмам күбенгәннәр, аяк атлар хәлләре калмаган, ә үзләре томшыкларын сузып һаман тамчы-тамчы су каба. Әни берсенә операция ясады — бүксәсен тишеп борчагын койды. Тик ул барыбер үлде, бичара. Еллар узгач кына белдем, аларга су эчермәскә, абзарга ябып куярга гына кирәк булган икән. Эчләрендәге борчак бүртмәгән булса, исән калырлар иде. Мин хәйран калдым: ансат кына ярдәм итеп булган икән бит ул җан ияләренә!

— Шуны уйлап ветеринария институтына кердең инде, әйеме?

— Яши торгач, мин адәм балаларының тагын да кызганычрак чакларын, ярдәмгә мохтаҗ вакытларын күрдем.

— Шул шул менә. Ә син әти аркасында, дисең.

— Кешеләргә мәхәббәт ул ата-анаңны, иреңне, балаларыңны яратудан башлана. Ата-аналарына дорфа булган, ир-хатыннарының данын саткан, балаларын рәтләп карамаган бәндәләрдән рәтле табиб чыкмый.

Җәмилә Закировна, сүзләрен ныгытырга теләгәндәй, башын калкытып торырга талпынып куйды. Кайбер мәсьәләләрдә үтә дә катгый шул ул.

— Ата-ананы ярату табигый, ә менә иргә йә хатынга мәхәббәтнең сүрелүе гаҗәп түгел бит, — дип йомшак кына аңа каршы төште Ләйлә. — Бар шундыйлар: синең җылы хисләреңә шлангтан бозлы су койгандай итә.

Бу сүзләр белән килешмәгәне Җәмилә Закировнаның йөзенә чыкты.

— Үзең сайлап алып, гомерлек пар иткән гомер юлдашыңа да хисләреңсуына торган булгач, чит кешеләрне ничек күңел биреп карамак кирәк! Хасталарның төрлесе бар бит: карты, ямьсезе, көйсезе... Һәммәсе өчен бертигез яныпкөеп торсаң гына дәвалауның шифасы тия.

Ишек шакыдылар. Ләйлә ялт итеп артына борылды. Кем икән бу? Ишекнең тышкы ягына эре хәрефләр белән «Тукта! Бүлмәгә кергәнче, якыннары белән киңәш!» дигән язу эленгән эленүен, ләкин берәрсенең аны укып тормыйча гына килеп керүе ихтимал бит. Җәмилә Закировна ул язу турында белми. Башын күтәрә төшеп булдыра алган кадәр кычкырып:

— Керегез, кер! — диде.

Ашарга китергәннәр икән.

— Хәзер, әни, сыйланабыз, — диде Ләйлә, җиңел сулап.

— Бер дә ашыйсым килми әле.

— Безнең хакка, әни. Минем өчен берне кап, Равил өчен тагын берне. Без бәләкәй чакта үзең шулай дип ашата торган идең бит.

Кечкенә табынны әзерләгәндә һәм капкалаган арада Җәмилә Закировна бая башлаган сүзне дәвам итте:

— Урыныма кем калырын уйлаганда, мин шул ягын да карыйм: белеме, осталыгы, таланты өстенә намуслы да булсын, гаиләсендә дә матур яши белсен, дим.

— Менә син, әни, балаларын яратмаган кеше яхшы табиб була алмый, дисең. Башта балаларны алга куеп сөйлисең. Ләкин эшкә килгәндә, бүтәннәрнең гамен безнекеннән өскә куйган чакларың еш була иде бит!

Ләйлә моны шаяртып әйтергә тырышса да, балачактан калган үпкәләүнең чагылышы сизелгәндәй булды.

Җәмилә Закировна, кашыгын куеп, аңа текәлде:

— Мин кешеләрне үлемнән коткару өчен китә идем, кызым.

Ләйлә тирән сулап кузгалды да чынаякларга чәй салды.

— Кечкенәдән мин телефон аппаратын яратмадым, — диде. Чөнки ул шалтыраганнан соң син ашыгып чыгып китә идең.

— Бик кирәк чакларда гына бит ул...

Ләйлә нидер эзләгән булып тумбочка эченә иелде.

Төннәрен телефон шалтыраса, иң элек әтиләре кузгала торган иде. Трубканы алып бераз тыңлагач, әкрен тавыш белән: «Хәзер, машина җибәрегез», — ди торган иде. Аннары киенә дә чыгып китә. Өстәл лампасы яктысында тавышсыз хәрәкәтләнә, ишекне сак кына ачып яба. Урамда машинаны каршы ала. Бераздан әйләнеп кергәч кенә изрәп йоклап яткан хатынының маңгаеннан сыйпый: «Сине алырга килделәр», — ди. «Ничә тапкыр әйттем бит инде, Мөбарәк, телефон шалтырауга уят, дип».— «Әз генә булса да йокласын, дигән идем». — «Минуты кадерле бит!» — Шулай дип сикереп тора да кабаланып киенә хатыны.

«Кем шулай синең йокыңны саклар, әнием, кем маңгаеңнан сыйпап уятыр?»

— Ни эзлисең син анда, кызым?

— Ә, менә таптым. Күчтәнәч конфет бар иде... Әйе, әни, кара дошманыбыз иде ул безнең кара телефон. Хәтерлисеңме, Яңа ел кичәсендә карнавал ясарга әзерләнгән идек. Әти — хан малае, син — хан кызы, мин — куян, Равил — соры бүре... Уйный башлыйк кына дигән идек, тагын телефон бүлдерде.

— Әйе шул, Әгерҗегә санитар самолет белән очарга туры килде, — диде Җәмилә Закировна.

— Бәйрәм итә торыгыз, барып җитү белән шалтыратырмын, дигән идең. Бәйрәмнең яме китте, синсез уенның рәте калмады. Әтигә урларга хан кызы юк иде шул. Без һаман синең шалтыратканыңны көттек. Ә телефон, үч иткәндәй, тып-тын иде.

— Ул кичне янымда телефон юк иде шул, — диде Җәмилә Закировна, аклангандай.

— Даң-доң итеп сәгать уникене суга башлагач, мин әллә нишләп киттем. Чыршы каршына кулларымны кушырып бастым да: «Мин врач булмаячакмын, мин беркайчан да врач булмаячакмын!» — дип ант иттем.

Җәмилә Закировна күзләрен зур ачып, кызына карап торды. Ул төнне самолет билгеләнгән вакытта тиешле урынга барып җитә алмады, мотор кинәт сүнеп, алар буш ялан уртасына төшеп утырдылар.

— Ул чакта мин исән-сау әйләнеп кайтканыма шөкрана иттем, кызым, — диде ул. — Авыру янына ничек кирәк алай барып җитеп, ярдәм күрсәтә алдык хәтта.

— Ләкин ул төнне синең һәлак булуың ихтимал булган бит! Әгәр без ятим калган булсак?!

— Тәвәккәлләми генә кешеләргә яхшылык кылып булмый шул...

Ләйлә әнисенең мөлдерәп торган күзләренә карады да бу сүзне ник башлаганына үкенеп куйды. Җиңелчә генә сөйләшергә теләгән иде бит үзе, балачакны сагынып искә алырга гына уйлаган иде. Ә менә әнисен ямансулатты. Ләйлә сүзне үзләренең кафедра хәлләренә күчереп, әнисенең йөзендәге күләгәне куарга тырышты.

Бераздан шәфкать туташы кереп укол кадагач, Җәмилә Закировна йоклап китте. Ләйлә эшенә барып килергә булды.

Хастаханә тәрәзәсенең ике кат пыяласы аша караганда гына көн матур күренгән икән. Урамда ачы җил исә, аяк асты бозланып, тайгакланып каткан иде. Ләйлә баскычтан атлауга егылып китә язды, яланкуллары белән бозлы култыксага тотынды. Башын күтәреп карады: аксыл рәшә эчендә җансыз һәм битараф түгәрәк булып, кояш тәлинкәсе эленеп тора иде.

Бервакыт сөйләшеп утырганда, Ләйләнең әтисе: «Сез, балалар, безне гафу итегез инде, дөньяны төзәтеп бетереп булмады. Бездән соң да бу җирдә бик күп җайсызлыклар кала»,— дигән иде. «Ничек ул — сездән соң?» — дип сорады Равил. «Ну... Кайчан да булса без китәрбез бит инде... Әйтик... пенсиягә. Мин дә, әниең дә җирдә сугыш афәте булмасын, чир-чор калмасын өчен бик тырыштык, максатка ирешеп бетерә алмадык. Сез бу эшне дәвам итәрсез, балаларыгызга дөньяны яхшыртыбрак тапшырырсыз».

Бу сүзләрнең чын мәгънәсен, зурлыгын, җаваплылыгын Ләйлә менә хәзер генә төшенә башлады кебек. Әтисе китте, әнисенең көче-гайрәте нык кимеде. Элеккечә нык итеп аягына баса алырмы ул, эшенә кире кайта алырмы?

Моңарчы Ләйлә үзенең зур терәге булуга ышанып яшәгән икән. Ни генә кылса да, кая гына барса да, юнәлеш күрсәтүчесе, кылганнарын гадел бизмәнгә салып бәяләүчесе, көч бирүчесе булган аның. Дөньяның торышы өчен аның каршында үзен җаваплы санаучы булган.

Хәзер бу җаваплылык тулысы белән Ләйлә җилкәсенә төште.

Йомшап төшәргә, зарланырга, еларга хакы юк иде аның.

***

Резеда Фәритовнаның офыктан күтәрелеп килгән кояш кебек түгәрәк алсу йөзен бу көннәрдә болыт каплаган кебек булды. Табигате белән йомшак һәм мәрхәмәтле бу хатын Җәмилә Закировнаның кечкенә, ләкин нык гәүдәсенә ышыкланыбрак яшәргә күнеккән һәм гомере буе аның канаты астында эшләр кебек иде. Тик көтелмәгән фажига аның йомшак иңнәренә зур авырлык салгандай итте. Клиникада, профессор Ильясова кире кайта алмас инде, дигән сүзләр йөри башлады. Нәкъ шул көннәрдә анда сирәк очрый торган бер авыр хәл булды.

Иртәнге конференциягә Резеда Фәритовна турыдан-туры алтынчы хастаханәдән килде: ул төнне шунда кизү торып үткәргән иде. Профессор Ильясова урынында утырган Виктор Ефимовичка гаепле кешедәй мөлдерәп, уңайсызланып карады һәм карлыккан тавыш белән:

— Таң алдыннан Вафина үлде... — диде.

Соңгы вакытта мондый җыелышларда сүзне Вафинадан башлауга күнегеп беткәннәр иде инде. Ул үзе дә, баласы да күңелләргә нык кереп урнашкан, шунлыктан бу хәбәр бәгырьгә авыр таш булып төште. Башка вакытта, бер-бер хәл килеп чыккан саен: «Хәтерлисезме, теге чакта...», яки: «Фәлән елны бер хатын кергән иде бит әле...» — дип, шуңа охшашлы вакыйгаларны искә алырга керешәләр иде. Бу юлы исә сүзне ялгап китүче булмады. Ни әйтәсең? Вафина хакында болай да күп сөйләшенде бит инде һәм алда да сүз күп булачак әле. Хәзерге вакытта бала тапканда хатыннар бик сирәк үлә, андый һәр очрак республика күләмендә күңелсез вакыйга, табибларның эшләп җиткермәвенә мисал булып санала һәм министрлык төзегән махсус комиссия тарафыннан җентекләп тикшерелә.

— Теге чакта аны чыгарасы калмаган, — диде, ниһаять, бер тавыш. Зәйтүнә иде бу.

— Кем белә бит аның болай буласын, — диде Резеда Фәритовна. — Бик нервыланган иде шул, тыярлык түгел иде. Көчләп тотып та булмый бит. Аннан файда булмас, дидек. Аннары Лариса Сөнгатовнаның заключениесе...

Ишек янындарак утырган Лариса, пружинасы ычкынган уенчык кебек, кинәт сикереп торды:

— Ништяк! Чыгарып җибәрергә кирәк, дигән заключение бирмәдем лә мин! Кан составын гына тикшердем, ә нәтиҗәне башкалар ясады.

Виктор Ефимович башын чайкап куйды:

— Без монда гаеплене эзләмибез бит әле, Лариса Сөнгатовна. Мондый хәл бүтән кабатланмасын өчен фажиганең сәбәбен ачыклап, үзебезгә сабак алырга тырышабыз, фәкать шул гына.

— Кем хаталанган, шул сәбәбен дә ачыкласын, сабагын да алсын. Гаепне башка берәүгә сыларга маташмасын.

Резеда Фәритовна Ларисага гаҗәпсенеп карады: әллә ызгыш-талаш чыгарырга маташа инде бу хатын? Профессор бар чагында бер дә болай чәчрәп чыкканы юк иде. Кара ничек кылана, тавышы бөреннән чыга! Җәмилә Закировна алдында болай кылану мөмкин түгел, чөнки ул әкрен тавыш белән шундый итеп әйтә, аннан да бигрәк үзәгенә үткәреп шундый итеп карый, иң сабырсызларны да урынына утырта, бик чаяларны да телен тыярга мәҗбүр итә. Әйе, аның юклыгы көннән-көн үзен ныграк сиздерә башлады...

Виктор Ефимович сүзне башка авыруларга күчерергә ашыкты.

...Берничә көннән соң иртәнге якта Резеда Фәритовнаны тышкы ишек янына чакырдылар. Анда аны янып торган түгәрәк битле җирән бөдрә чәчле бер хатын көтеп тора иде. Вафина эшләгән

лабораториянең җитәкчесе Нажия Нәкыйповна иде бу. Резеда Фәритовна аны профессор бүлмәсенә чакырды. Бусагадан атлауга, Нажия Нәкыйповна стенадагы рәсемгә — тоташ бер сызык белән ясалган ана белән бала сурәтенә карап алды. Бүген бирегә шушы бөтенлекнең югалуы хакында — ятим калган бала турында сөйләшергә килгән иде ул.

Резеда Фәритовна профессор урынына узмады, өстәлгә яны белән урнашты да кунакка каршысыннан урын күрсәтте. Нажия Нәкыйповна төлке бүреген салып өстәлгә куйды, сумкасыннан кулъяулык алып, тирләгән маңгаен сөртте, кабинетка хуш ис таралды.

— Вафинаның әтисе — сугыш инвалиды, әнисе дә авыру,— диде ул. — Абыйсының үз балалары күп икән. Вафинаның улын алырга теләкләре сизелми.

— Баланың әтисе дә юк икән шул,— диде Резеда Фәритовна.— Бик яшьли үлеп киткән икән.

Нажия Нәкыйповнаның йөзендә гажәпләнү чагылды.

— Үлмәгән, кая үлсен! Ул юньсез Алтынчәч гомерен дә яшәр әле!

— Алтынчәч миңа үзе сөйләде бит, баланың әтисе ерактан килгән кеше иде, пляжга коенырга баргач, суга батып үлде,— диде.

Нажия Нәкыйповна, бүреген сыпыргалап, ямансу гына елмайды.

— Гомер буе бергә эшләп тә белеп булмый икән кешене. Инде Алтынчәч тә шушындый булгач, башка-бүтәннәр турында ни дисең? Баланың әтисе кемлеген сорашып белдек инде без. Кызлар бергә пляжда ятканнарын күреп алганнар, күршесе дә танып калган. Ник аны яшерде икән, ник исемен, адресын үзе әйтмәде икән соң ул, бичаракай?

— Мин сорадым, — диде Резеда Фәритовна. — Авыр чагында янында озаклап утырырга туры килде бит. Баланың әтисе дип авыз ачсам, миңа аркасы белән борылып ята иде. Ул кешегә сабыйны күрсәтәсе дә килмәгән, күрәсең.

— Йә тегесе күрергә теләк белдермәгәндер, йөз чөергәндер, — диде Нажия Нәкыйповна, нокта куйгандай. — Их, шул баланы берәр туганы алсын иде дә, фатирын сакласын иде. Үскәч өйләнүгә үз куышы булыр иде. Ятимнәр йортына тапшырсагыз йә билгесез кешеләргә уллыкка бирсәң эзен югалтсагыз, фатирыннан колак кага инде ул бичара!

Резеда Фәритовна аңа сәерсенеп карады: сабый, фатир... Бу җирән чәчле хатынның озак елларга карап фикер йөртүе гажәпләндерде. Тик ни генә дисәң дә аның сүзләрендә үзенә бер төплелек, тормыш җаен аңлау бар иде.

Алар бер фикергә килергә өлгермәделәр, ишекне каерып ачып, кара кайры тун чабуларын җилбәгәй җибәргән Изаил Харисович килеп керде.

— Кем хуҗа монда хәзер? Кунакны кем кабул итә?

Хатыннар хушлашкан арада, ул тунын салып куйды да кәнәфигә иркенләп утырды.

Биредә бергә эшләгән чакларда, Резеда Фәритовна баштарак аңа кызыгып һәм сокланып карый иде. Ләкин тора-бара бу хискә сагаю, шикләнү килеп кушылды. «Артык шома, артык эре, — дигән иде ул бервакыт иренә аның турында.— Елгыр, салкын. Күзне кызыктыра, тик җылысы юк».— «Замана кешесе инде»,— дигән иде ире.

Соңгы вакытта шактый үзгәрде Изаил Харисович, тазарды, тагын да ныграк шомарды кебек.

— Минем халатлар сакланды микән әле монда? — дип сорады ул, астыртын мәгънә белән. — Бу араларда килеп тә булмады. Эш өстенә эш чыгып кына тора, борылырга да җай юк. Министрлык мондагы хәлләрне тикшерү өчен махсус комиссия төзи икән, бүген иртән шуны җитәкләргә тәкъдим итеп шалтыраттылар. Тулы бер комиссия белән килеп кергәнче, башта үзем хәлегезне белеп чыгарга булдым.

Һәм ул үз итеп елмайды.

Резеда Фәритовна дәшми-тынмый гына чыгып китте дә, түш кесәсенә «А.Р.Ф.» дип үз инициаллары чигелгән халат алып керде. Доцент Дәүләтшинның халатлары кайда икәнен белмәгәнлектән, үзенекен биреп тора менә. Бераз кечерәк булса да, иңгә салырга ярый.

Өске каттагы уникешәр кеше ята торган палаталарны караганнан соң, Изаил Харисович:

— Һаман шул тыгызлык икән әле монда, — диде. — Фән өчен бу авыруларның ни кызыгы бар? Күбесен предприятиеләрнең медсанчастьларында да дәвалап була бит. Төрле вак-тояк белән шөгыльләнеп, биредәге врачлар вакланып бетә. Без сезнең белән чит кешеләр түгел, дөресен генә әйтегез әле, Резеда Фәритовна, монда төрле хәлләр була бит, әйеме? Ялган белешмә күтәреп килгән хатыннар кереп ята, кайбер врачлар авырулардан күчтәнәчләр дә алгалый.

Резеда Фәритовнаның бите алланып чыкты.

— Кафедрадагы хәлләр турында сез миннән күбрәк хәбәрдар икәнсез, — диде ул.

— Клиника үзе бер катлаулы организм бит ул, Резеда Фәритовна. Җитәкче — аның табибы. Үз кул астындагы кешеләрнең тышындагысын гына түгел, эчендәгесен дә яхшы күрергә тиеш.

Аскы катка төштеләр. Процедуралар кабинетында доктор Уразова чуар халатлы бер хатын белән сөйләшеп тора иде. Ишектә күренгән Дәүләтшинны күреп җитдиләнде, аның сәламенә салкын гына җавап бирде дә:

— Әгәр мин кирәк булсам, ярты сәгатьтән бушыйм, — диде.

Бу сүзләр, бимазалап йөрмәгез, ишекне ябыгыз, дигәнне аңлата иде. Изаил Харисович елмайды, ләкин аның бу елмаюы ачы иде: «Бурычлы булып калмабыз, исәпләшербез», — диде аның карашы.

Тар өстәлләр, эскәмияләр тезелгән уку залына кергәч, ул тәрәзә төпләрендәге сулы банкаларда тыпырчынган бакаларга карап ачы көлемсерәде:

— Хан заманындагыча мондагы хәлләр, — диде. — Кафедра дип аталабыз үзебез!

Аннары эре атлап түргә узды, кечкенә лаборатория бүлмәсенең ишеген хужаларча хәрәкәт белән киң итеп ачып җибәрде. Өстәл янында Лариса Сөнгатовна штативындагы көпшәләр, пробиркалар белән булышып утыра икән. Ишек тавышын ишеткәч, ризасызлыгын белдереп, кашын-күзен җимереп борылган иде, Изаил Харисовичны күргәч, кинәт үзгәреп китте, тигез тешләрен җемелдәтеп елмайды. Аның кыяфәте кибетләрдә сатыла торган «Врач» исемле курчакны хәтерләтә иде. Доцентның чыраенда уенчыкка кызыккан малай елмаюы кабынды.

— Доктор Нигъмәтуллина токсикозның башлангыч стадиясендә диагноз кую методларын эзли, — диде Резеда Фәритовна, бик тә рәсми тавыш белән. Әмма аның сүзләрен ишетүче юк иде бугай. Доцент белән ординатор арасында минут эчендә бер-берсенең уртаклыгын тою хисе урнашты. Алар диссертациянең темасы, кан составы, төрле матдәләр хакында сөйләшәләр, ә күз карашлары, тавыш үзгәрешләре үзенчә аңлаша иде. Бүлмә эсселәнеп киткәндәй булды, Резеда Фәритовна бу икәү янында үзенең артыклыгын тойды, аның бу сөйләшүгә шаһит булып басып торуы үзе үк әхлаксызлык сыман иде.

Әмма борылып чыгып китмәде. «Берләшмичәрәк торыгыз әле!» — диде эченнән. Тегеләрнең сүзен бүлеп:

— Лариса Сөнгатовна, сез онытмадыгызмы, — диде,— бүген заводта безнең кафедраның прием көне бит.

— Профессор юк ич, — диде Лариса, гаҗәпләнеп.

— Ләкин авырулар бар. Аларны карап, консультация бирергә кирәк.

— Кайсы завод, нинди прием? — дип сүзгә кушылды Изаил Харисович. — Аның ише юк-бар мәшәкатьләрдән күптән арынырга вакыт! Яшь галим җитди тикшеренүләр белән мәшгуль, ә сез аны гап-гади врач башкарырга тиешле эшкә җигәсез!

— Авыруларга ярдәм күрсәтүнең гади эш булганы бармыни? — диде гаҗәпләнгәндәй Резеда Фәритовна. — Профессор Ильясова безне гади күренгән очракларда да бик җитди, җаваплы булырга өйрәтте.

Изаил Харисович баланың ахмаклыгын кичергәндәй елмаеп, башын чайкап куйды:

— Заманалар үзгәрә, Резеда Фәритовна. Ә без чордан артка калырга тиеш түгел. Элегрәк, врачлар җитмәгәндә, профессор да кем туры килсә шуны дәваларга мәҗбүр булган. Хәзер гади врачлар һәркайда җитәрлек, галимнәр үзләренең бар көч-акылын җитди эшкә багышлый ала. Хәер, картайган кешедән эш стилен үзгәртүне таләп итеп булмый шул.

— Минем күптәннән инде сезнең белән очрашып киңәшәсем килә иде, Изаил Харисович,— диде Лариса, бик тә җитди, төпле итеп.— Тик моңарчы кыюлыгым гына җитмәде. Сез бу өлкәдә бөтендөнья галимнәренең казанышларын беләсез. Аннары мин бүгенге көндә фәнни җитәкчесез калдым бит...

— Кулымнан килгән кадәр ярдәм итәрмен, әлбәттә. Гомумән, кафедраның тоткан юнәлеше турында барыбыз бергә җыелып җитди сөйләшәсе бар әле...

Резеда Фәритовна моңа ни әйтергә белмичә эчтән сызып басып торуында булды.

***

«Көннең иң ямансу чагы — икенде белән ахшам арасы,— ди торган иде Динәнең әбисе.— Нәкъ шул сәгатьләрдә, кояш түбәнәеп баеп барганда, күңелгә моң, үзенә бер ямансулау кереп оялый. Шуңа күрә дә кичкә таба намазны ешрак укыйлар. Иртәнге намаз бер генә, ә кичкеләре өчәү: икенде, ахшам, ястү».

Бервакыт Динә инглиз язучысы Джек Лондонның «Кадими шагыйрь» исемле шигырен укыгач, анда әбисенең шушы фикере кабатланганын күреп гажәпләнгән иде. Җирдәге иң беренче шагыйрь дә үзенең иң беренче шигырен баеп барган кояшка карап язган икән: «Көн үтте, йолдызлар калыкты, аһ, миңа ямансу, ямансу, ямансу...»

Бу халәт хастаханәдә дә нык сизелә. Иртәнге сәгатьләр дәвалану, врачлар белән сөйләшү, якыннарының килгәнен көтү белән үтеп китә. Кичкә таба бу эшләр бетә дә, йөрәк түрендә яшеренеп, посып яткан моңсу хис, үкенечле уйлар калка башлый.

Еш кына Динәнең хәтерендә теге чакта төшенә кергән сабый җанлана. Аның йомшак тәпиләренә басып, әүмән-тәүмән якын килгәне һәм иреннәрен бүлтәйтеп «тфү» дип төкергәне аермачык күз алдына килә. Динәнең йөрәге жу итә. Төрле хорафатларга, ырымнарга ышана торган кеше дә түгел үзе.

Укытучы бит ул, башкаларда да тормышка аек караш тәрбияләргә тиеш. Ләкин менә шул төшне күргәннән соң, дөньяда безнең акыл ирешмәгән нәрсәләр күптер дигән фикергә килә башлады. Мисалы күз алдында: аның үзенә дөньяга килеп тә өлгермәгән сабыйның каргышы төште бит. Каргыш төшү димәсәң, соңгы елда башка килгән хәлләрне тагын нәрсә белән аңлатып була?

Югыйсә намусы чиста бит аның, hичкемгә зыян салганы булмады, авыр гөнah кылганы юк... Бала төшерүне бу заманда кем гөнahка саный? Дөрес, Мөдәррисне рәнҗетте ул. Беренче балалары тугач, сүзгә килешкән чакларда: «Бүтән бала тапмаячакмын!» — дип ычкындыргалый иде. Бу сүзләрдән иренең чырае күгәреп киткәндәй була, юка ирен читләре аска төшә. Хатынының икенчегә буйга узганын белгәч, ул: «Әгәр кул тидертсәң, мәңге бәхиллегем булмаячак!» — дигән иде. Таләп куеп кына калмады үзе, хатынын юмаларга, аңа яраргa тырышкан чаклары да булмады түгел, булды. Алай да барыбер ахыр чиктә ярап бетә алмады. Завод, диде, эш, диде, Динәгә иң кирәк чакларында озак-озак командировкаларга йөрде. Авырлы Динә килен эшеннән гаеп табарга үтә дә маһир, чая телле каенана белән йөзгә-йөз калып яшәргә тиеш иде. «Мин синең балаңны карыйм!» — дип күпме теңкәгә тиде ул! Башка вакытта колакка да элмәс идең, ләкин авырлы чакта серкә су күтәрми башлый, юк кына сүз дә күңелгә авыр таш булып төшә, юктан да сагыш баса, үз-үзеңне кая куярга белмәгән чаклар була. Динә иренә: «Бу айларда гына булса да өйдә тор, озакка китмә!» — дип әллә ничә ялынды. Юньле ир гаиләсе хакына эшен дә, хәтта hөнәрен дә алыштыра! Ләкин Мөдәррис аның сүзенә колак салмады, поездга утырды да китеп барды. Динәне убырлы карчык белән калдырды да китте.

Йа Алла, күр син табигатьнең бу могҗизасын! Бер карауда җанны эретә торган, үзе юк чакта да күңелдән китми торган Мөдәррис, дөньяда бердәнбер Мөдәррис, менә шул сөйкемсез карчыктан туган бит, ә! Җентекләбрәк карасаң, араларында охшашлык та бар кебек үзе, ләкин каенана нихәтле күңел кайтаргыч булса, Мөдәррис шулхәтле җанга якын. Берсе дөньяның бөтен ямен качыра, икенчесеннән башка яшәп булмый...

Мөдәррис үзе исә хатынының хәлен-кичерешләрен аңламады. Ир белән хатын кайчан бер-берсен ахыргача аңлап бетерә ала соң!

Мөдәррискә рәнҗү, каенанага ачу Динәнең эчен казандагы пар кебек тутырды. Тагын да бала булса, каенана аны да авызын шапылдатып ашарга, сүзләрнең азагын йотып сөйләшергә өйрәтер, телен дә «әннә» дип түгел, «әббә» дип ачтырыр дип уйлады. ...Һәм хастаханәгә керде.

Ул чакта һәммәсе бик гади һәм аңлаешлы булып тоелган иде. Ул фәкать иреннән үч ала, аның хәсрәтләнгәнен күреп кинәнә, аны акылга утырта. Ә инде Мөдәррис аңа мөнәсәбәтен үзгәрткәч, аралар бөтенләй яхшыргач, бала кирәксенсәләр, тагын булыр әле — орлыгы Бохарада түгел, яшь чаклары!

Тик чынбарлык алдан күз алдына китергәнчә булып чыкмады. Үзенең бәгыре парә-парә телгәләнгән Динәгә иренең авыр кичерешләре җиңеллек китермәде, ә бәлки, аның үкенечләрен көчәйтте генә кебек. Ике арадагы җылылык кимеде. Мөдәрриснең күз карашы ук үзгәрде, вакыт-вакыт ул хатынына бик текәлеп, үтәли күрергә теләгәндәй сынап карый торган булды.

Шулай да ике арадагы бу киеренкелекне Айгөл киметә, аның лепелдәп йөрүе өйне ямьли, җылыта иде.

Һәр бәхетсезлеккә сәбәп табылып тора. Нәкъ шул көздә алар парлашып Төркиягә барырга булдылар. Тиктормас, тынгысыз Мөдәррис гомумән ялны кырын ятып кына үткәрә белми. Динәгә дә аның янында шөгыльсез тору читен, икесе дә ерак юлга чыгу мөмкинлеген хуплап каршы алдылар. Ераклarга барып карасаң, тормышның көйсезлекләре, вак-төяк ыгы-зыгылар кечерәеп киткәндәй була, күз күреме белән бергә фикер офыклары да киңәя бит ул. Чит җирдә алар бер-берсенә янә якынаеп киткәндәй булдылар, студент чагында кабынган мәхәббәт гүяки яңадан терелде. Кичләрнең берендә, кунакханә бүлмәсенең балконына чыгып, шәрык каласының шау-шулы, чуар урамына карагач, Динә иренә борылып, аңа таба авыша төшеп: «Бар икән матурлык! Әкият дөньясына алып килдең бит син мине!» — дигән иде.

Тик барыбер дә җитми икән туган илләргә! Эссе иде чит җирдә. Берничә сәгать самолетта очканнан соң, үз илеңә кайтып төшеп, туган якның салкынча hавасын күкрәк тутырып сулау бик рәхәт булган иде. Әмма өйдә чүл эссесе бугандай итте. Алар кайтып кергәндә, Айгөл ут эчендә ята иде.

Соңыннан врачлар һәммәсен аңлатып бирделәр, «Менингитның авыр формасы, коткарып булырлык түгел иде»,— диделәр. Ләкин Динә үзе белә: теге сабыеның каргышы иде бу. Мәет үзе артыннан башкаларны да тарта, диләр бит.

...Ишек ачылды, Динә, уйларыннан арынып, мендәреннән башын калкытты. Палата врачы Зәйтүнә Мәҗитовна икән. Яшь, сөйкемле, бераз гына моңлы кебек. Сары чәчләрен шомартып артка тараганга, маңгаендагы ике нечкә сыры аермачык күренә, уң як ирен читендәге түгәрәк миңе ак йөзенә сабыйларча эчкерсезлек төсмере бирә. Гаҗәп: шушы яшь врач белән Динәнең юлы әледән-әле кисешеп килә.

— Хәлләрегез ничек? — диде табибә, бөтен палатага мөрәҗәгать итеп.

— Доктор, менә минем...

Түрдәге өлкән яшьтәге хатын аны үз янына чакырды. Динәнең дә сөйләшәсе килә бу яшь табибә белән, аларның ниндидер уртак моңнары бар шикелле тоела. Тик ул моң-зарларны монда, башка хатыннар алдында түгә торган түгел. Шуңа күрә Зәйтүнә аның янына килгәч тә Динә аны-моны әйтмәде.

Табибә чыгып киткәч, ул одеалын күтәрә төшеп, ак тукыма белән капланган гәүдәсен күздән кичерде. Менә ул, Динә үзе. Калкып торган күкрәк алмалары, батыбрак торган эч, башкалар әйтүенә караганда, төз матур аяклар. Ул аларны теләгәнчә хәрәкәтләндерә ала, берәр нәрсә тисә, авыртканны тоя. Әмма аларның эчендә ни барын белә алмый. Анысын әле генә чыгып киткән табибә генә белә ала. Ак йөзле, сагышын эченә яшереп елмая белгән ул хатынның әйткән сүзләре рас килерме? Киләчәктә Динә тагын да әни була алырмы?

Ничек сәер һәм гаҗәп бу хәлләр!

— Хәйруллина, әйдәгез!

Ишектән башын тыгып, шәфкать туташы дәшә, Динәне физиотерапия бүлмәсенә чакыра. Ул икенче катта, тудыру бүлеге белән янәшә. Елтырап торган аппаратлар белән тулы бүлмәгә сәяхәт Динәнең сызланган җанына ял бирә. Сары бөдрә чәчле мөлаем шәфкать туташы Динәне тар ятакка яткыра да, кулына озын саплы кечкенә чүкеч төсле прибор тотып, иркәләп кенә аның эч турын сыйпый. Үзе бертуктаусыз сөйләнә. Сүзе күбрәк тудыру бүлегендәге хәлләр турында. Элегрәк ул бер хатынның ирсез килеш корсакка узуын, токсикоз белән ятуын сөйләгән иде инде. Бүген сүзен:

— Теге Вафина үлгән бит! — дип башлады. — Ни генә кыланмадылар врачлар, тирәсендә ничә профессор бөтерелеп йөрде, әҗәле җиткәч, барыбер алып кала алмадылар шул.

— Ә бала? — дип сорады Динә.

— Бала исән. Кыз көткән булган икән, мескен, малай туган. И сабыр иде үзе, и түзем иде, бер генә дә зарланмады. Үлгәндә дә баласын гына сораган, диләр. Ә була бит шундый хатыннар, берәр җире әз генә авыртса да, әллә ниләр кыланып кычкыра, бәргәләнә. Авырта, имеш. Авыртмый нишләсен! Яңа бер кеше тәнеңне ярып чыксын әле!

— Баласы кайда соң аның? — дип сорады Динә.

— Кая булсын, бездә ята. Юрист балалар йортына тапшырырга кәгазьләр җыеп йөри, диләр. Менә сиңа кеше язмышы. Туганда ук бәхетсез, бичара. Язмышың үз кулыңда, диләр тагын. Булыр, көт!

...Гинекология бүлегендә утларны иртә сүндерәләр. Коридорда шәфкать туташының әрле-бирле йөргәне, шприцларны шалтыратып юганы һәм стерилизаторга салганы ишетелеп тора. Менә, ниһаять, палатада тынлык урнашты. Кемнәрдер җиңелчә гырлый ук башлады. Динәнең генә күзенә йокы кермәде. Тәрәзә артында шәрә ботаклар чайкала, сирәк кенә узган машина фараларыннан ботаклар аша челтәрләнеп төшкән яктылык тасмасы карават башларыннан, хәрәкәтсез яткан гәүдәләрнең өстеннән шуып уза.

Динәнең күзләре шар ачык. Колак салып тыңлана торгач, аңа аргы баштан, тудыру йорты ягыннан өзми-куймый бала елаганы ишетелгәндәй тоела башлый. Ятим калган бала елыйдыр. Ир бала... Беркемгә кирәксез, кадерсез җан иясе... Аның белән беркөнне туган сабыйларны, ак җәймәләргә төреп, атлас тасмалар белән бәйләп, кочактан кочакка алып, бетмәс-төкәнмәс мәхәббәт нурына коендырып үстерергә дип алып китәрләр.

Бу сабыйны исә тамга суккан казна юрганына урап, приютка илтеп тапшырырлар. Анда аның килүенә һичкем кош тоткандай сөенмәс, фәкать тәрбияче хатын гына, башка балалардан беразга аерылып: «Ә-ә, яңаны китердегезме?» — дип әйтеп куяр. Дөрес, аны да башкалардан ким итмәсләр, юындырырлар, киендererләр, ашатырлар-эчертерләр, вакыт тигәндә башыннан сыйпап узарлар. Тик беркайчан да ул ана назын тоймас. Ир баланың эче авыртучан була, диләр. Төннәрен сызланып елаганда күтәреп йөрүчесе булыр микән? Егерме-утыз балага бер караучы, кайсын гына күтәреп йөрсен соң ул!

Приютта үскән балалар яшьтәшләреннән соңрак тәпи китә, соңарыбрак телләре ачыла, акыл үсеше белән арттарак кала, диләр. Ә күңелләре нишли? Ата-ана назыннан мәхрүм калган баланың күңелендә нинди хисләр тумый һәм үсми кала икән?

Ятимлек кайчан да, кайда да ятимлек шул инде ул!

Бу бала, бәлки, ятим үсмәс. Бәлки, аны тәрбиягә алучы табылыр. Хәзерге вакытта баласыз гаиләләр күп бит.

Хәзергә ул үз язмышының башкалардан аермалы икәнен белми әле. Ләкин бүтәннәр төсле түгел, ятим ул. Башкаларның тавышын әниләре колак торгызып тыңлый, аларны тиешле сәгатьтә аналарының кочагына китереп салалар, ә аның елаганын ишетеп үзәге өзелүче юк, аны сагынып-зарыгып көтеп алучы юк.

Нигә шундый бу язмыш, нигә шулай тигезсез бу дөнья? Динә үз кылганнарының әҗерен ала, сабыйның соң ни гаебе бар? Без кылганнарның, безнең хаталарның җәзасы төшә сабыйларга...

Башта туган уйларның очы очка ялганмый, карават башларыннан, идәннән шуышып узган яктылык шәүләсе кебек айкала да чайкала. Бу хастаханәдә ике ялгыз җан бар — Динә белән ятим

калган сабый. Берсе елый, икенчесе эчтән сызлана. Язмышлары охшаш — иң газиз кешеләрен югалттылар: берсе — анасын, икенчесе — баласын...

Тышта корыган ботакларны чайкалдырып, эчтә күләгәләр шудырып, кышның озын төне бик ялкау гына узып бара. Динә керфеген керфеккә тидерми, бала елаган тавыш ишетелмиме, дип тыңланып ята...

Иртән обходка кергәч, Зәйтүнә:

— Динәгә ни булган безнең? — дип сорады.

— Йоклый алмадым.

— Борчылырга сәбәп юк. Анализлар яхшы, дәвалау курсы тәмамланып килә, шушы арада без сезнең белән саубуллашырга ниятләп торабыз.

Зәйтүнә башка хатыннар белән сөйләшеп бетергәч, Динә аңа ияреп коридорга чыкты да табибәне почмактагы суыткычка таба әйдәде.

— Сез белмисезме, теге баланы уллыкка сораучы бар микән?

— Кайсы баланы?

Зәйтүнә аны бераздан гына аңлады.

— Юк, баланың язмышы ачыкланмаган әле. Андый эшләр тиз генә эшләнми бит ул, якын туганнары белән хәбәрләшәсе, документлар җыясы бар...

— Күрсәтегез әле миңа аны!

Алар бер буйда диярлек, шуңа күрә күзләре бер-берсенә бик текәлеп, туры карадылар. Динәнең күз кабаклары шешенке, кызыл. Зәйтүнә аның бу төндә кичергәннәрен сүзсез аңлады, гажәпләнүе юкка чыкты.

— Тудыру йортындагы балаларны чит кешегә күрсәтү өчен махсус рөхсәт кирәк, — диде ул.

— Әгәр берәрсе аны уллыкка алырга теләсә?

— Ул чакта аларга врач сүзенә ышанырга туры килә.

— Мин аны күрергә тиеш, — диде Динә, катгый итеп.

— Кичкә таба дежур врач белән сөйләшеп карасак кына инде, — диде Зәйтүнә.

Кичке сәгать алтыда, клиникада кизү торучы табиблар гына калгач, балаларны имезгән сәгатьтә Зәйтүнә Динәне чакырып чыгарды, ак халат, битлек бирде. Башлык урынына мендәр тышын бөкләп бәйләргә туры килде. Алар дәшми-тынмый гына озын коридор буйлап үттеләр, аннары өске катка күтәрелделәр.

Өлкән яшьтәге апа, сабыйларны имезергә әниләренә өләшеп бетергәч, арба кырыенда калган бердәнбер озынча төргәкне алып, алар янына килде дә кулында килеш кенә Динәгә йөзе белән борып күрсәтте.

Динәнең йөрәге сулкылдап куйды: бу — ул иде. Теге чакта аның төшенә кергән бала иде бу.

***

Мөдәррис өчен иң читене — шушы гинекология бүлегенә килү иде. Динә үзенең бирегә кереп ятканын таныш-белешкә белгертмәде, шунлыктан көн саен диярлек Мөдәррискә килеп йөрергә туры килде. Бу юлы Динә аның белән башка вакыттагы кебек алгы ишек янында, гадәти очрашу бүлмәсендә сөйләшмәде, арткы ишектән керергә чакырды. Кыяфәте ничектер серле иде.

Алар мәктәп классына охшаган бүлмәдә тар өстәл артына янәшә утырдылар. Ярый әле утырдылар, югыйсә Динәнең сүзен ишеткәч, Мөдәрриснең егылып китүе ихтимал иде.

Кеше баласын тәрбиягә алырга... Мондый дуамал уйның фәкать Динәнең генә башына килүе мөмкин!

Ә үзе иренең йөзендәге үзгәрешләрне күрми, чөнки аңа карамый. Бумази халат кесәсеннән шакмаклы дәфтәр бите чыгарып, анда язылганнарны укырга кереште. Аз да түгел, күп тә түгел, уникә пункт икән: зәңгәр юрган, зәңгәр тасма, юка чүпрәк, бумази чүпрәк, бәби күлмәге, юка башлык, калын башлык... Бәбине әтисе кулына китереп тоттырган шәфкать туташына акча...— кыскасы, моннан чыгу өчен кирәкле нәрсәләр иде болар.

Бу хатын ахыргача Мөдәррис өчен табышмак булып калыр, мөгаен. Бергә гомер иткән кеше белән серләрең килешә, уйларың бер була, диләр тагын. «Кеше баласын карарга алынганчы, үзеңне карарга өйрән башта!» — димәкче булды Мөдәррис, әмма хатынының операциядән соң әле ныгып җитмәгәнлеген исенә төшереп, телен аркылы тешләде.

— Зинһар, документларны тизрәк әзерләргә тырыш! — диде Динә. — Бездән алда берәрсе алып китә күрмәсен!

— Ата-анасы кемнәр икән, белештеңме? Нәселдән килә торган чире булмасын тагын.

— Чирле баланы бигрәк тә яхшы карарга кирәк түгелмени? — дип, уйламый-нитми әйтеп салды Динә. Аннары иренең күзләре түгәрәкләнгәнне күреп: — Ата-анасы сәламәтләр, белештем, — дип

ашыгып өстәде. Ялганы тавышына чыкканын сизеп, чын ихласлык белән, күңел түреннән суырып: — Ул безнең балага охшаган! — дип өстәде. — Нәкъ безнеке төсле!

Ничек инде кеше баласын үзеңнеке белән чагыштырырга мөмкин? Тик Мөдәррис моны уйлады гына, хатынының йөзенә карады да дәшмәде. Чөнки аның күзләрендә сыкранудан туктамаган җан җәрәхәтен күргәндәй булды. Ни генә булмасын, сызланулары уртак иде шул аларның!

Хатыны яныннан чыккач, ул клиника каршындагы бакча сукмагы буйлап әрле-бирле йөренде, тәмәке кабызды. Болай гына кайтып китә алмый, бер акыллы кеше белән киңәшәсе, сере сыя торган берәү белән гамьнәрен уртаклашасы килә иде аның.

Әнә ул кеше ян яктагы ишектән чыгып килә. Ак бүрек, ак яка фонында йөзе нур сибә кебек. Аны күргәч, Мөдәрриснең күңеле назлы хис белән тулды. Ул, тәмәкесен ташлап, аңа каршы атлады.

— Сез тагын килгәнсез, — диде Зәйтүнә аның сәламен алгач, шелтәле тавыш белән. — Яхшы түгел.

— Ә мин врач янына килдем. Врач буларак, сезнең миңа ярдәм итүдән баш тартырга хакыгыз юк. Гиппократ кушмый.

— Врачны урамда аулап йөрмиләр, кабинетына керәләр.

Зәйтүнә моны йомшак итеп, әмма үпкә белән әйтте. Мөдәрриснең күңеленә җылы җил исеп куйгандай булды: чит кешегә үпкәләмиләр, җанга якын кешегә генә шушылай йомшак итеп үпкәләп була.

— Доктор, минем йөрәгем авырта, — диде Мөдәррис.

— Әгәр белгән булсам, мин сезгә валерьян тамчылары алып чыккан булыр идем.

Алар бакча сукмагы буйлап янәшә атлап киттеләр. Мөдәррис дәшмәде. Бу хатын аның хәлен әйтмичә дә аңларга тиеш: бик гайрәтле ир-егетләрнең дә фәкать хатын-кызга гына чишәрлек серләре була. Аларның да нечкә күңелле бер зат каршына барып, язмышның ачылыгыннан зарланасы, үзен кызгандырасы һәм шул затның «өф» дип өргән сулышыннан җиңеллек табасы килә.

Зәйтүнә дәшми-тынмый барудан уңайсызланды булса кирәк, аңа борыла төшеп:

— Йөрәкне борчу басканда, елап алу файдалы, ди безнең профессор, елап алыгыз булмаса, — диде.

— Акыллы сезнең профессорыгыз. Дөрес әйтә. Ләкин үзең генә елауның шифасы аз шул. Моны бәләкәй малайлар да белә, күз яшьләрен сөртеп торучы булганда ешрак елыйлар.

Мөдәррис, кинәт нидер исенә төшкәндәй, сәгатенә карап алды:

— Сез Тимербулатны алырга соңармыйсызмы? Мин дә җәяү генә бүген. Машинаны ремонтка куйган идем.

— Аны бүген күрше хатын алам, диде. Үз кызы белән бергә. Мин эштә тоткарланган көннәрне шулай ярдәм иткәли ул.

Мөдәррис көрсенеп куйды. Малайны күрәсе килә иде аның.

— Алайса, ашыгыч булмаса, бәлки, бераз җәяү барырбыз? Сезнең белән киңәшәсе бар иде.

Мөдәррис адымнарын Зәйтүнә атлавына яраклаштырырга тырышты.

— Тәмам буталып калдым әле мин, доктор Зәйтүнә,— диде ул.— Сез инде адәм баласының тән төзелешен яхшы беләсез, ә менә хатын-кыз күңелен аңлау мәсьәләсендә ничегрәк? Миңа шуның серләрен аңлата алмассызмы? Әйтик, менә без бер-беребезне ярата идек шикелле, аңлаша да идек кебек. Ә хәзер мин аның җиңел акыллылыгына, дуамаллыгына хәйран калам. Беркем белән исәпләшү-санашу юк, башына ни килсә, шуны кыла. Гажиз мин бу хәлләрдән. Узган елны командировкадан кайткач, мин аның сезнең клиникага кереп чыкканын белеп өнсез калдым. Кайчан елаганымны да онытканидем инде, ә бу юлы күз яшьләремне тыя алмадым... Әйе, сезгә генә әйтәм, утырып еладым мин ул көнне. Бала яратам мин, доктор Зәйтүнә, иң зур хыялым — ким дигәндә ун бала үстерү. Эштән кайтуыма уратып алсыннар, кайсы иңемнән кочсын, кайсы ботыма уралсын, кайсы кулыма менсен. Кайсы җилкәмә атлансын иде... Ә ул мине бер бөртектән мәхрүм итте.

— Сез хаклы түгел! Ул теләгәнчә генә булмады бит!

— Ләкин барысы да аның җиңел акыллылыгы аркасында килеп чыкты түгелмени? Уйлап эшләсен иде! Алдын-артын уйламыйча теләсә ни кылана бит ул! Хәзер менә кеше баласын уллыкка алырга ашкына. Минем белән сөйләшмәгән, киңәшмәгән, һәммәсен хәл итеп тә куйган. Мин аның янында бер пешкамыни! Кемнеңдер баласы безнекенә охшаган, имеш! Тапкан сылтау!

Зәйтүнә бераз тынып барды.

— Әгәр хатыннан башка гына бала булдыра торган булса, мин аңа ялынып та тормас идем,— дип дәвам итте Мөдәррис.— Ә ул табигать тарафыннан бирелгән өстенлегеннән файдаланып, минем хыялларымны җимерде, бәгырьгә төзәлмәс яра салды. Хатын-кызны ирләргә караганда мәрхәмәтлерәк диләр тагын!

— Димәк, ул чакта сез үз-үзегезне кызганып елагансыз, — диде Зәйтүнә аңа борылып. — Ә аның хәлен аңладыгызмы соң?

— Нәрсә булган аның хәленә? Ул үзе теләгәнне эшләгән иде инде!

— Аңа да җиңел түгел бит. Авырлы хатынның хәлен ирләр күз алдына китерә алмый. Сез, минем белүемчә, аның сүзенә колак салмыйча, командировкага китеп баргансыз. Нигә шул чакта аның янында булырга тырышмадыгыз?

— Хатын итәгенә ябышып утырып кына яшәп булмый бит инде! Цехтагы хәлләрне үзегез беләсез. Анда да хатын-кызлар эшли, сезнең тырышлык белән эшне туктатсалар, алар ничек яшәр?

— Барысы да үзегез теләп алган йөк. Һәммәсенә җитешергә кирәк булгандыр... Ул чакта санашмагансыз икән, инде хәзер аны аңларга тырышып карагыз. Әгәр ул баланы үзенеке дип кабул иткән икән, бу — бик җитди нәрсә. Сез каршы килсәгез, аның өчен тагын зур югалту булачак.

Мөдәррис авыр сулап куйды.

— Сезне дә аңлап бетереп булмый, — диде. — Әгәр безнең гаилә хәлләренә медицина катнашмаса, әйтик, теге чакта Динәне ике көнгә клиникага салмаган булсагыз, безнең башка бу ваемнар төшмәс иде. — Урам лампасы турыннан узганда, Мөдәрриснең ирен читләрен күтәреп ачы көлемсерәгәне күренде. — Безнең әби-әниләр мондый гамьнәрне белмәгән. Унар бала тапканнар, сәламәт картайганнар. Медицина зуррак уңышларга ирешкән саен, бу мәсьәлә катлаулана бара.

Монысына Зәйтүнә түзеп тора алмый иде. Аның кыйбласына, иманына — медицинага гаеп ташлау иде бу.

— Шулай микән? — диде ул.— Ун баланың ничәсен генә исән-сау үстерә алган соң ул әбиләр? Элек хатыннар, беләсезме, ничек яшәгән: корсак күтәрә, бала имезә, бала күмә, тагын корсакка уза... Аңарчы үзе исән калса... Күпмесе бала тапканда үлгән аларның! Хәзерге вакытта хатыннарның хәле чыннан да нык үзгәрде: алар баланы үзләре теләгән вакытта табалар һәм исән-сау үстерәләр. Шуңа күрә ирләрдән калышмыйча эшли алалар, иркен сулыш белән яши алалар. Болай яшәүче без икенче буын хатыннар гына әле. Баланы үзең теләгән вакытта гына табу мәсьәләсен хәл итми торып, хатын-кызның җәмгыятьтә тигез хокуклы булуы турында сүз алып бару да мөмкин түгел иде. Әгәр дә хатыннар корсак күтәрү, бала табу, бала күмү хәсрәтенә күмелеп кенә яши торган булса, ул ничек ирләр белән тигез хокуклы була алсын ди? Менә нәрсә эшләде медицина — ул хатын-кызларны чын-чынлап ирләр белән тигез хокуклы итәргә мөмкинлекләр тудырды! Ул безне кеше рәтенә бастырды, беләсегез килсә!

— Ышандырдыгыз,— диде Мөдәррис, көлемсерәп, әмма тавышы җитди иде. — Тик менә хатыннарны ул мөмкинлекләрдән дөрес файдаланырга кем өйрәтер икән соң?

— Анысын медицина гына эшли алмый шул.

Алар трамвайга кереп, иң артка утырдылар. Вагон буш диярлек, аларның сүзенә колак салучы юк иде, алай да Мөдәррис Зәйтүнәгә сыеныбрак утырды.

— Монда урыны түгел кебек, ләкин мин сезне кайда очратам әле? Шуңа күрә әйтәсемне әйтәм, — диде ул. — Кайчак мин төннәр буе сезнең белән сөйләшеп чыгам. Мин болай, дип әйтермен, ә сез тегеләй җавап бирерсез, дип фараз итәм. Дөрес, чынлыкта сезнең сүзләр бөтенләй башкача була... Сез мин уйлаганнан акыллырак, сизгеррәк, тирәнрәк... Гафу итегез, әгәр без ешрак очрашсак... әгәр бергә булсак... Сез мине аңлар идегез кебек тоела...

Зәйтүнә аннан читкә тайпылды, сулышы кысылганын тойды. Аның бу хәрәкәтен сизеп, Мөдәррис башын иеп тынып калды. Зәйтүнә дә сүзсез иде, ул бозланып каткан тәрәзә пыяласын учы белән эретеп, чагылып узган утларны карап бара башлады.

Трамвайдан төшкәч, алар шулай ук бераз дәшми бардылар. Инде өй янына ук килеп җиткәч, Мөдәррис:

— Тагын бер генә сүз әйтим инде,— диде.— Тукайның бер шигыре бар, хәтерлисездер: «Бар ишектән сөрде углыңны мәхәббәт сакчысы...» — дигән. Бу юлларны укыгач мин хәйран калдым. Аның хакындагы истәлекләрне җентекләп укып чыктым. Ул хак дөресен язган икән. Аны бөек шагыйрьгә лаек булганча яратучы, аңа тормышын, язмышын багышлаучы берәү булмаган. Булмаган андый хатын-кыз! Иҗатына илһам бирүче, кадерен белүче, мәхәббәте белән җылытучы, язганнарын бөртекләп җыеп баручы, сырхаулаган чакларында тәрбияләүче булмаган бөек шагыйрь Тукай янында! Ә шул ук чорда җирдә күпме олы җанлы кызлар яшәгәндер! Тик алар башкаларны яратканнар, күңел җылысын бүтәннәргә биргәннәр, аларның сызлануларын җиңеләйткәннәр. Кемнәрне сөйгәннәр ул саф күңелләр, мөкатдәс хисләрен кемнәрнең аяк астына салганнар? Уйлап карасаң, ул чакта безнең татар халкында чын мәхәббәткә Тукайдан да лаеграк, аннан да мохтажрак башка берәү булды микән? Минемчә, изге җанлы берәүнең мәхәббәтенә юлыкмау Тукайның гомерен кыскарткан сәбәпләрнең иң җитдиедер дә.

Зәйтүнә гаҗәпләнеп тынып калды. Аның бу хакта болай тирәннән уйланганы юк иде.

— Мәхәббәт хисе күңелдә яхшы кеше очраган саен түгел, ә бәлки, яратыр вакыт җиткәч кабына бит ул, — диде ул, үзалдына уйлангандай. — Нәкъ шул чакта синең янда зур хискә лаек шәхеснең булмавы да ихтимал... Тукайга лаек кыз каядыр читтә йөргән, шагыйрьнең дөньяда барлыгын белмәгән, алар очрашмаганнар дигән сүз.

— Ничек инде ул алай? Халыкның күз өстендәге каш кебек шагыйрен кызлар белми димени? Юк, монда ниндидер башка бер сәбәп бар. Хатын-кызның әлеге дә баягы шул сәерлегеннән, тормышны

аңламавыннан, кешеләрнең кемлеген танымавыннан киләдер бу. Әйтегез әле, кызлар нинди егетләргә гашыйк була? Нилектән бик күп очракларда кызларның асыллары иң матур хисләрен өч тиенгә тормаган бәндәләрнең аяк астына салып таптаталар, яннарында йөргән егет солтаннарын күрмиләр? Моның сәбәбе нәрсәдә?

— Ә сез, егетләр, һәрвакыт үзегезгә лаекларны гына сөясезмени?

Соңгысы шулхәтле ачынып әйтелде, Мөдәррис иректән тынып калды. Бу сорауга бик зур мәгънә салынган иде.

Зәйтүнә үзенең артыграк ачылып киткәнен тоеп, башын читкә борды. Мөдәрриснең әйткәннәре турыдан-туры аңа да кагыла түгелме? Ә бәлки, ул да нәкъ менә шундыйларның — иң мөкатдәс хисләрен бөтенләй лаек булмаган кешедән таптатучыларның берседер? Таптый бит Әнвәр аның мәхәббәтен, ике аяклап таптый, кешелеген изә...

Эчке сызланудан Зәйтүнәнең башы әйләнеп китте. Менә хәзер бу кешенең күкрәгенә капланып, моң-зарларын түгәсе килде. Ә аннары... Аннары яшәү җиңелрәк булыр иде. Әнвәр аңа үлем теләп кaһәрләгәндә дә, якын итүчесе, яратучысы барын уйлап, юаныч табар, көч алыр иде. Бу — хатын-кыз буларак та Зәйтүнәнең үз-үзе каршында абруен саклар иде.

Шунда Әнвәрнең теге көнне, Әзһәр абыйларына килеп кергәндә, каралып чыккан йөзе аермачык булып күз алдына килде. Нурсыз иде аның чырае, кая карарга белми иде ярсудан тонган күзләре. Чөнки үзенең хыянәтче икәнен аңлый иде ул! Зәйтүнә дә кайчан да булса аның каршында шулай йөзеннән-күзеннән нур качкан хыянәтче хәлендә басып торырмы?

Юк-юк, бу мөмкин түгел!

Һәм ул Мөдәррис белән хушлашырга ашыкты.

***

Мәхәббәт — иң матур, иң көчле, бөек хис, шагыйрьләрнең аңа дан җырлавы юкка гына түгел. Әгәр икәүнең йөрәгендә бу хис кабынган икән, аларның юлына аркылы басарга беркемнең дә хакы юк. Алар бергә булырга тиешләр. Хәтта соңарыбрак очрашкан булсалар да. Чын сөю моның өчен бөтен хокукларны бирә.

Шулай дип уйлый Лариса һәм бу ышанычын Әнвәргә дә сеңдерергә тырыша. Тик нигә соң парлашып-култыклашып урамнарда йөргәндә, Әнвәр таныш-белешнең күзенә чалынудан курка, нигә үзен кечерәеп, вакланып киткәндәй тоя?

Бу хис — гаепле булу, вагаю тойгысы — теге көнне абыйсы Әзһәрләрдә очрашканнан соң аеруча көчәйде. Йөзе кара иде Әнвәрнең, бу каралык аңа Ларисадан йога иде. Шул ук вакытта Әнвәр ансыз яши алмый, кич җитүгә тыелгысыз тарту көче аны бөтерчек кебек хәрәкәтчән, кайнар тәнле, шат күңелле хатын янына алып китә иде.

Чыннан да, гыйшыкка каршы торырлык көч юк, күрәсең.

— Инде кыяр өлгергәндер, ник мине сыйламыйсың? — дип сорады Лариса.

— Алып килермен.

— Ә минем сабагыннан өзеп ашыйсым килә. Хәзер теплицалар урман кебек булгандыр инде, ә? Тропиклардагы шикелле: тастымал-тастымал яшел яфраклар арасында, бөркү эсседә, маймыллар төсле шәрә хатыннар йөри. Экзотика! Минем дә шундый урманда адашасым килә. Синең белән бергә. Әллә барып адашабызмы?

Ларисаның бу рәвешле шаяруы Әнвәрнең эчен пошыра башлады: кем белә бит бу хатынның күңел түрендә ниләр ятканын! Әллә чынлап торып адашасы килә аның, әллә инде Зәйтүнәгә, ирең тагын теплицага чит хатыннар алып килә, дип гайбәт ишеттерәсе килә! Ә бәлки, үзенә рәхәт күрү генә аздыр, ул әле башкаларны газаплап та рәхәт табадыр! Нәрсә дигән иде әле ул: ләззәт сызлану белән бергә була, дидеме? Ә бәлки, сызландыру белән бергәдер?

Әнвәр аны култыклаган кулын тартып алудан чак кына тыелып калды. Кулның шуышканын сизеп, Лариса аны терсәге белән тыгыз тәненә китереп кысты.

— Тамак ачты, кыяр белән генә туеп булмас, — диде Әнвәр.— Әйдә, ресторанга керәбез.

Трамвай көткән арада, Лариса кечкенә, тыгыз, хәрәкәтчән кулын аның беләгe буйлап аска таба шудырды. Әнвәрнең бөтен тәненә кайнар дулкын таралды, һәммә шикләр эреп юкка чыкты, икәүләп янәшә басып торуның рәхәте генә калды.

Лариса аның күзләренә сөеп, тәмам аныкы гына икәнлеген аңлатып карады. Ләкин бу карашта эчке бер тантана да бар иде. Ул үзендә бу үзсүзле, горур егет белән идарә итәрлек көч булуына куана иде.

Трамвай баскычыннан икәү янәшә менү уңайсыз, ләкин Лариса кулын алмады. Алар вагонның арткы мәйданчыгына узып, терәлешеп бастылар. Вагонда кеше аз, артка карап баручы да юк иде. Әнвәр берни уйламыйча, хисләргә генә чумып барды. Аларның әле бу кичтә рәхәтләнеп

сөйләшәселәре, парлашып караңгы урамнарны гизәселәре, ә аннары икәүдән-икәү генә каласылары бар. Ахыр чиктә кешеләр бу җирдә гомернең татлы минутлары һәм сәгатьләре хакына яшиләр бит, шулай түгелмени?

Җәннәтнең үзендә булудан да бигрәк, аңа илтә торган юллардан бару рәхәттер. Алар шәһәр читендәге кечкенә, иске ресторанга кереп утырдылар. Биредә танышлар очраудан куркырлык түгел, әмма сакланганны Ходай саклар, дип, Әнвәр ишеккә аркасы белән урнашу ягын карады. Кем белә, ә бәлки, кеше күзеннән качып йөрүчеләр тагын бардыр?

Ресторанда рәтле вино да, теләгән ризык та юк иде. Ит салаты, «цыплята-табака», коньяк сорадылар. Ларисаның бит очлары алланып чыкты, күзләре очкынланып елтырады. Ул Әнвәргә ярдәм сорагандай итеп, балаларча моңаеп карады:

— Минем эшләр гел артка китеп бара бит әле, Анварчик, — диде. — Теге көнне син вәгъдәңне үтәмәгәч, китте дә китте инде.

— Ну, Лорочка, әйттем бит, көтелмәгән хәл килеп чыкты...

— Көтелмәгән хәлләрдән тора шул инде безнең язмышлар,— дип көрсенде Лариса, алдындагы тәлинкәгә карап. — Ильясованың көтмәгәндә аварияга юлыгуын әйт... Эшне төгәлләп килә идем бит инде. Хәзер кайтмас инде ул.

— Кайберәүләр... өметен югалтмый әле...

— Кая инде, шундый имгәнүдән соң... Көтмәгәндә генә безнең тудыру бүлегендә яткан бер хатын үлеп китте. Гаепне миңа сыларга маташалар. Анализны дөрес бирмәгәнмен, имеш. Бу вакыйга минем методыма күләгә төшерә, диючеләр бар!

— Нинди анализ? Син тудыру бүлегендә түгел идең бугай бит? — дип, һич көтмәгәндә төпченә башлады Әнвәр.

Ларисаның буталчык җавабын тыңлагач, ул чын-чынлап кызыксынып китте:

— Ничек алай килеп чыкты соң ул? Методың дөрес булса, авыруның хәле начараерга тиеш булмагандыр бит?

— Әллә син дә миннән шикләнәсең инде? — диде Лариса, ялварулы елмаеп.

— Үпкәләмә, Лорочка, тик мин бу мәсьәләгә бөтенләй башка яктан карыйм бит. Авыру ягыннан карыйм, чөнки мин больницага эләксәм, хаста буларак кына барып керәм. Без, инженерлар, әгәр берәр нәрсәнең очы-очка ялганмый икән, кат-кат тикшереп, сәбәбен ачыкларга тырышабыз. Сиңа да, бәлки, анализ көтелмәгәнчә килеп чыккач, тагын бер кат тикшерергә кирәк булгандыр. Ә бәлки, син берәр нәрсәне бутагансыңдыр, ялгышкансыңдыр?

Ларисаның йөзе агарынды, күзләре түгәрәкләнде.

— Мин дә фәрештә түгел, кеше! Ялгышуым, хаталануым да ихтимал. Ләкин мин аны больницадан чыгарырга кушмадым. Безнең күздән киткәч, аның нинди хәлләргә дучар булганын кем белә? Ә син, хәтта син дә миннән шикләнәсең! Хәле авырайган һәркем өчен врачларның башын ашый торган булсалар, кая китә ул?

— Андый очракта дәшми калып та булмый шул, — диде Әнвәр.

— Ничего, — диде Лариса, кулындагы рюмканы әйләндергәләп. — Хәзер кафедрада зур үзгәрешләр булачак әле. Фәнни эш белән шөгыльләнүче яшьләргә юл ачылачак.

Ул бераз тынып торды да, каядыр почмакка карап, таш диварлар, зур урамнар аша үзенең максатын күргәндәй итеп, әкрен, ләкин катгый тавыш белән:

— Башларыннан басып үтәрмен, барыбер үземнекен итәрмен! — дип куйды.

***

Бу афәттән котылу, Әнвәрне элекке нур шәүләсе хәленә кайтару чарасы да булгандыр. Тик Зәйтүнә андый ысулны белми иде. Аның күңелендә хәнҗәр булып һаман бер уй айкалды: ул Әнвәргә кирәкми, кирәкми, кирәкми...

Яшәүнең бөтен мәгънәсе юкка чыккан кебек иде. Ләкин Зәйтүнә берни күрергә теләмичә йомылырга әзер күзләрен зур итеп ачылырга мәҗбүр итте. Ул яшәргә тиеш, ул улына кирәк, аны кайгыртырга бурычлы. Эшендә аны сорау һәм өмет тулы караш белән хасталар каршы ала. Аларга ярдәм итү өчен аяк өстендә булу кирәк иде.

Һәм ул шушы бурычларны үтәп яшәү өчен үзенә бер мәйдан булдыргандай итте. Бөтен көчен туплап, шул түгәрәктә көн итә башлады.

Сагышка бирелеп, мендәр почмагын тешләп күз яше түгеп кенә яшәп булмый иде. Эштә чакта җиңелрәк, кичләрен Әнвәрнең кайдадыр башка берәү белән очрашканын күз алдына китереп утыру бик авыр. Сагышлардан саргаймас өчен, Зәйтүнә уйларын башкага юнәлтергә тырыша иде.

Ул һәр көнгә, һәр минутын исәпләп, катгый план төзеп куя торган итте. Һәм, башка берәүгә кушкандай, үзен шушы планны тайпылышсыз үтәргә мәҗбүр итте. Заводлардан чыга торган кайбер

зарарлы газларның организмга тәэсире турындагы тикшеренүләренең нәтиҗәләрен гыйльми хезмәт рәвешенә китереп, тәмамлап куйды. Ләкин ул, мәйданны урап чыккан чабышкы ат кебек, туктап калырга тиеш түгел иде. Һәм үз алдына яңа бер максат куйды, зур эшкә алынды: ел фасылларының, көн сәгатьләренең кеше организмына, аерым алганда төрле даруларны үзләштерүгә йогынтысын өйрәнүгә кереште. Озак елларга сузылачак һәм бик күп көч сорый торган эш иде бу.

Кеше — табигать баласы һәм ул Табигать-ана белән аерылгысыз бәйләнгән. Хәлбуки медицина практикасы күпчелек очракта табигатьтәге үзгәрешләрне тиешенчә исәпкә алмый. Хасталарны җәен-кышын, иртәсен-кичен бер үк даруларны бер үк микъдарда бирәп дәвалыйлар. Әгәр дә табигатьтәге үзгәрешләрнең организмга йогынтысы ныклап өйрәнелсә, ул чакта даруларны азрак кулланып, яхшырак нәтиҗәләргә ирешү мөмкинлеге туар иде. Бу — бала табучы хатыннарга ярдәм итү өчен дә бик мөһим.

Зәйтүнә шушы темага язылган фәнни хезмәтләрне табып укырга, авыру тарихларын өйрәнергә, метеорологлар белән элемтәгә кереп, алардан күпьеллык күзәтүләрне алырга булды.

Кичләрен эштән кайткач та ул үзенә тын алырга да ирек бирми иде. Баланы көйләп йокларга яткыра, өй эшләрен карый, аннары китапларын алып, яшел лампа яктысына кереп утыра. Кайчандыр алар Әнвәр белән утырган лампаның яктысы эченә... Ләкин ул бу хакта уйламаска тырыша, дикъкатен китапка юнәлтә һәм чыннан да бераздан йөрәгенең сыкравы кимегәндәй була иде.

Алар Әнвәр белән бер фатирда, әмма аерым яши башладылар шикелле. Бер-берсенең күзләренә туры карамыйлар, фәкать бала хакында гына сүз алышалар.

Алай да бер кичне Әнвәр аерылышу хакында сүз кузгатмакчы иде, Зәйтүнә, тыныч булырга тырышып:

— Ник ашыгасың? — диде. — Минем белән ялгышкан кебек аның белән ялгышудан курыкмыйсыңмы? Мин синнән бер нәрсә дә таләп итмим бит. Бала әтисез калмасын, фәкать шул гына. Мин аңа әтине үзем сайладым, ялгышуымның җәзасын да үзем күрәм, аңа йөкләмим. Син дә аны ярым ятим итәргә ашыкмассың, бәлки?

Әнвәр бу сүзләрне колагына алдымы-юкмы, анысы билгесез калды, чөнки җавап булмады. Ул бик соң кайта, кухня идәненә матрас салып төн үткәрә дә иртүк чыгып китә. Рәхәтне башка җирдә таба, әлегә баш тыгар урыны булмаганга гына төннәрен берничә сәгатькә идәнгә кайтып ава иде. Фатир эзли торганнардыр, табарлар, шуннан соң ул чыгып китәр, аерылышырга судка бирер.

Ялыну-ялвару да, ызгышу-талашу да файдасыз иде. Зәйтүнә дәшмәскә, бөтен сабырлыгын туплап түзәргә тырышты.

Ни хикмәттер мондый чакта кешегә эш-мәшәкать көч бирә. Беләкне дә, башны да шөгыльсез тотмаска кирәк. Профессор Ильясова мең мәртәбә хаклы — моң-сагышларга чумып, кул кушырып утырсаң, эчтән янып үләрсең!

Тик моны әйтүе генә ансат, эшләве җиңел түгел шул.

Алай да Зәйтүнә үзен тиргәп, мәҗбүр итеп, укырга, язарга, уйларга тырышты. Шулай бер кичне, язарга кулының җегәре, уйларга башының көче беткәч, колаклар баскычтагы аяк тавышларын ишетер өчен тырпайгач, күңелнең сызлавына түзәр хәл калмагач, ул нишләргә белмичә «Вокруг света» дигән журналның урта битләрен ачты. Анда борынгы майя һәм инк халыкларының гаҗәеп сәнгать әсәрләре, калалары, пирамидалары турында язылган, аларның рәсемнәре урнаштырылган иде. Зур үсешкә ирешкәннәр бу халыклар, таң калырлык корылмалар төзегәннәр, бизәнү әйберләре ясаганнар, ләкин менә ни хикмәт — тәгәрмәч ясый белмәгәннәр. Шундагы берәүнең дә моңа башы җитмәгән. Әгәр аларның тәгәрмәчләре дә булсамы?! Европадан килгән басып алучыларга бирешеп торырлар иде микән? Һәм алар белән бәрелештә җиңелеп, юкка чыгарлар иде микән?!

Менә бит ул ничек... Кайчакта бөтен бер халыкларның язмышы гап-гади тәгәрмәчкә бәйле булып кала. Бер кеше уйлап чыгара ала торган тәгәрмәчкә... Ә бәлки, Зәйтүнә үз өлкәсендә тәгәрмәч уйлап чыгаруга тиң ачыш ясый алыр?!

Бу дөньяда фәкать ул гына башкара ала торган эшләр бар. Кеше кешегә охшамаган кебек, аның булдыра алганы да башкалардан аерылып тора. Ул бүтәннәрнең кулыннан килмәгәнне эшли ала. Тик нишләргә икәнен генә белергә кирәк!

Ах, әгәр Җәмилә Закировна аварияга эләкмәгән булса иде! Ул чакта эшкә каян, ничек тотынырга икәнлеге ачык булыр иде. Дөрес юлдан барганыңны белсәң, күпкә җиңел бит ул. Мөгаен, семья хәлләрен дә сөйләп, эчне бушатып булыр, ул акыллы киңәшен бирми калмас иде.

Әмма гамьнәреңне аның җилкәсенә салып булмый шул. Дөрес, соңгы вакытта профессорның хәле яхшырганнан-яхшыра бара, Зәйтүнә Резеда Фәритовнага ияреп берничә мәртәбә янына кереп тә чыга алды. Әмма янында кизү торырга кертмәделәр. Мөгаен, иренең вафатын белдермәгәннәр иде әле.

...Беркөнне Резеда Фәритовна:

— Сине Җәмилә Закировна чакырды,— дигәч, Зәйтүнәне шактый вакыттан инде кичерелмәгән сөенеч хисе биләп алды. Ул эшеннән алданрак сорап китте һәм хастаханәгә ашыгып барып керде, үзе белән алып килгән халатын коридорда барганда кабаланып киде, җиңнәрен таба алмый буталды.

— Керегез! — дигән тавыш ишетелде таныш ишек артыннан.

Җәмилә Закировна аякларын салындырып караватта утыра, янына култык таягы сөяп куелган иде. Зәйтүнәне күргәч, агарынган йөзендә моңсу елмаю кабынды, күзләрендә җанның сызлануы чагылды. «Иренең үлгәнен әйткәннәр...» дип уйлады Зәйтүнә.

Кырыйдагы өстәл янында Ләйлә утыра иде, ул чак ишетелерлек итеп кенә исәнләште, аны-моны әйтмәде, нәрсә турындадыр кисәтергә омтылыш ясамады.

Зәйтүнә юл уңаеннан алган күчтәнәчләрне, полиэтилен капчыгы-ние белән өстәлгә куйды да остазына таба атлады. Калтыранган тавыш белән аның чиксез зур кайгысын уртаклашуын әйтә башлады. Җәмилә Закировнаның йөзе теше сызлагандай тетрәнеп куйды. Ул, тыңлап бетермичә:

— Йә сөйлә, эшләрең ничек бара? — диде.

Зәйтүнә дивар янындагы урындыкны алып, аның янына барып утырды. Һәм сумкасыннан кәгазь битләре алып, профессорга сузды. Бу аның заводтагы зарарлы газлар турындагы тикшерүләре иде.

— Тыныч вакытта укып чыгармын, — диде Җәмилә Закировна. — Ә практик нәтиҗәләр ничек соң?

— Әлегә җитди үзгәреш юк. Яңа чараларын эзлиләр. Ә мин бүтән темага керештем. Сезнең белән киңәшергә дип якынча план да төзеп алып килгән идем.

Артта Ләйләнең тамак кырганы ишетелде.

— Безнең әни больничныйда бит әле, — диде ул, йомшак кына кисәтеп.

— Син комачаулама, Ләйлүк. Остазны шәкертләреннән аерып тота торган больничныйлар юк дөньяда.

Җәмилә Закировна планны җентекләп карап чыкты, берничә киңәш бирде. Һәм клиника хәлләрен сораша башлады.

— Монда килгәннәр һәммәсе ал да гөл, дип сөйлиләр. Ай-һай, шулай микән?

Динәгә икенче тапкыр операция ясалганын, Зәйтүнәнең операция вакытында тәвәккәллек кылганын белгәч, сагаебрак калды.

— Аны күздән ычкындырма инде син, — диде. —Тотынгансың икән, ахырынача илтеп җиткерергә тырыш. Операциядән соң ялкынсынуларны булдырмый кала алсаң, бәлки, өметегез чынга да ашар. Тәрбиягә бала алу мәсьәләсен исә ире белән икесе хәл кылсыннар. Аныңа басым ясый күрмә.

Авыру кешене борчырга ярамый иде, әмма Зәйтүнә дөресен яшерә алмады, комиссия төзелгәнен дә, Дәүләтшинның килеп йөргәнен дә әйтте.

— Морадыма ирештем, дип сөенә торгандыр, — диде Ләйлә.— Дөньяны шаккатырырлык операцияләр ясап дан казанасы килә. Профессор Бернарларның даны тынгы бирмидер аңа.

Җәмилә Закировна, караватыннан торып, таягына таянып, бүлмә буйлап әрле-бирле йөреп килде. Сул ягына янтаеп атлагангамы, әллә кызылга ак бизәк төшкән бумази халаттан булгангамы, ул кечерәеп калгандай тоела иде. Үзалдына бераз уйланып йөренгәч, Зәйтүнәгә таба борылды да:

— Әйдә соң, комиссия үз бурычын үтәсен,— диде ул.— Безнең күз күп нәрсәгә күнеккән, кайбер кимчелекләрне күреп җиткермибездер. Читтән килгәннең күзе очлы була. Тыңлап карарбыз, ни әйтерләр. Кара дошманның сүзендә дә хаклык була, чөнки ул иң йомшак җирдән тотып ала. Хакны нахактан аерып кабул итәргә, сабак алырга гына кирәк.

Зәйтүнә остазына тагын бер тапкыр хәйран калган иде: бу арада килгән хәсрәтләр өстенә ул үзенә яңа мәшәкатьләр өяргә, яңа борчулар алырга әзер иде!

— Эшкә чыгуга, мин җыелышка кафедраның отчетын куячакмын, — дип дәвам итте профессор. — Кайбер мәсьәләләрдә эшне бөтенләй башкача алып барырга кирәктер, бәлки. Ләйлүк, ничек уйлыйсың, берәр атнадан аксавым бетәр микән? Коллегалар каршына таякка таянып барып керү килешмәс бит.

— Әни, син кая барып керәсеңне түгел, моннан нинди хәлдә чыгарыңны уйла!

— Ә син эшеңә соңармыйсыңмы?

— Ярый әле сорадың, китәм, дип әйтергә кыенсынып утыра идем. Мин иртәгә генә килә алырмын инде, әни.

Ләйлә чыгып киткәч, Җәмилә Закировнаның йөзе сулып киткәндәй булды. Йөрәген кайгы талый да талый, тик ул моны кызына сиздермәскә тырыша икән. Әмма үз зарын түгәргә теләмәде:

— Өегездә хәлләр ничек соң? — дип сорады. — Малай ничек үсә?

Кайгы пәрдәсе аша әйтте кебек ул моны, ләкин соравы сүз өчен генә түгел, ихластан иде. Аңа җавапның да дөресен бирергә кирәк иде.

— Улыбыз үсә... Ә әтисе... Әтисенең ятка күзе төшкән, Җәмилә Закировна!

— Алаймыни-и-и?! Кемгә икәнен дә беләсеңме?

— Сез дә беләсез аны... Лариса Нигъмәтуллина...

Җәмилә Закировна караватына утырып, керфекләрен аска төшерде. Берничә мизгел тынсыз утыргач, башын күтәреп, шәкертенең күзләренә туры карады:

— Иреңә авыр чир йоккан, димәк. Ә хастаны гаепләп булмый. Сәбәбен белеп, чирне ничек йоктырганын ачыклап, дәваларга гына кала. Аңа бу чир йокмасын өчен син бөтен чараларны күргән идеңме? Анысын да уйла. Ә хәзер бөтен көчне аны терелтүгә салырга кала... Ә сихәтләнгәч, беркайчан да бу хакта аның исенә төшермәскә. Онытырга...

— Андыйны онытып буламыни, Җәмилә Закировна?

— Бөтен нәрсәне төзәтеп була, Зәйтүнәкәй, үлгәнне генә кире кайтарып булмый. Мәхәббәткә дәва бар, әҗәлгә чыннан да дәва юк икән... — Җәмилә Закировна күз яшьләрен күрсәтмәс өчен йөзен читкә борды. — Ансыз яши алмам шикелле иде. Төннәрен йоклый алмаган сәгатьләрдә бигрәк авыр. Машина бәрелгәндә ник исән калдым икән, дигән сәгатьләрем була. Кырык елга якын бергә яшәп, мин аны соңгы юлга озата да алмадым...

Зәйтүнә, аягөсте басып, аның иңенә кулын салды. Һәм беренче тапкыр үзен остазын юатырлык, аңа көч бирерлек итеп тойды.

— Чын табиб беренче чиратта ярдәмгә мохтаҗ башка кешеләр хакында уйларга тиеш, дип өйрәтте безнең остазыбыз профессор Ильясова, — диде ул.

— Әйе, әйе, эшләргә кирәк. Бар көчеңне эшкә бирергә. Яшәтсә шул эш кенә яшәтәчәк инде мине...

Ул хушлашып чыгып киткәннән соң, Җәмилә Закировна, терсәкләре белән тәрәзә төбенә таянып, аның ишегалды аша китеп барганын күзәтеп торды. «Җиңел атлый, очынып бара, канатлары бар диярсең, — дип уйлады ул. Аннары тирән итеп көрсенде дә үзалдына: — Минем яшьлегем бит бу! — дип куйды. — Минем ныгып, чыныгып килгән чагым!»

***

Суларның да җайсыз юлдан аккан чаклары була. Күпме парлар җайсыз итеп яши! Моны үзләре дә аңлый бит югыйсә, тик күңелдә яткан ташлар тормыш агышын көйле юлга салырга ирек бирми.

Әмма гел генә болай яшәү мөмкин түгел, нәрсәдер — давылмы, җилме суларның агышын көчәйтер, авыр ташларны куптарып ташлар, йә булмаса алар өстенә яңаларын китереп өяр кебек иде.

Һәм шулай булды да.

Бик авыр көн булды бу. Җәмилә Закировнаның эшкә чыкканына атна да узмаган иде әле, тик моның белән исәпләшеп тормадылар, җыелыш җыеп, комиссиянең тикшерү нәтиҗәләре турында сөйләштеләр. Министрлыкның вәкиле булып баш гинеколог Талия Гаффаровна килгән иде.

Җыелышны ул ачты һәм беренче сүзне комиссия җитәкчесе Дәүләтшингә бирде. Президиум өстәле артыннан ул торып баскач, Зәйтүнә эчтән бөрешеп килде: Вафинаның үлемендә клиниканы гаепле дип тапсалар, профессор Ильясовага карата да, авыруны дәвалаган башка табибларга карата да каты чаралар күреләчәк иде. Һәм, чыннан да, кереш ясап, берничә җөмлә әйткәч, доцент Вафина белән булган хәлләргә тукталды. Һәммәсе шым булдылар. Тик куркулары юкка булган икән, нәтиҗә алар уйлаганча булып чыкмады. Баксаң, Вафинаның фаҗигасендә, иң беренче чиратта заводның медсанчастенда эшләүче табиблар гаепле икән.

— Алар ни караган? — диде доцент һәм аның соравы бик урынлы булып тоелды. — Ни өчен электән үк сәламәтлеккә туймаган Вафина вакытында тикшерелмәгән, дәваланмаган? Министрлык, шәһәрнең сәламәтлек саклау бүлеге моның сәбәпләрен тикшереп, гаеплеләргә карата чара күрергә тиеш. Клиникага исә Вафина бөерләренең эшчәнлеге бөтенләй зәгыйфьләнгәч кенә килеп эләккән. Мондый очракта нинди генә ысуллар куллансаң да, авыруның агышын уңай якка үзгәртү кыен шул.

Шулай итеп, доцент авыруны клиникада ничек дәвалаулары хакында сүз куертмады, табиблар күргән чараларга бәя бирмәде һәм хәлиткеч анализны ясаганда хата җибәргән Нигъмәтуллинаны да телгә алмады.

Зәйтүнә артына борылып, гадәттәге урынында, ишек янындарак утырган Ларисага күз ташлап алды. Аның йөзендә мәгънәле елмаю балкый иде. «Карга күзен карга чукымый шул» дип уйлады Зәйтүнә.

Ә доцент сүзен дәвам итә иде әле. Бу фаҗиганең сәбәпләрен ачыклаганда, юл уңаеннан клиниканың эшчәнлегендә бүтән төрле гаеплә тапкан икән. Вакытны-көчне таныш-белешләрне карауга сарыф итү аркасында җитди авыруларга игътибар җитмәү, тиеш булмаган очракларда аборт ясау — болары инде катгый тавыш белән, бәгырьгә төртерлек итеп әйтелде.

Президиум өстәле артында Талия Гаффаровна белән янәшә утырган профессор Ильясова доцентны, карашын аска төшереп, кулларын угалап тыңлады. Авыруларны карар алдыннан бармакларын җылытыр өчен шулай итә торган гадәте бар аның. Башыннан узган авыр хәлләрдән соң Дәүләтшинның бер утка, бер суга сала торган нотыгын ничек чыдап тыңлап утыра икән ул? Бүлдермичә, хәтта борылып та карамыйча түзәргә ничек сабырлыгы җитә?

— Кафедраның эшен тамырдан үзгәртергә кирәк. Шунсыз булмый! — дип тәмамлады Дәүләтшин сүзен.

Йөзләр сүрелде, башлар иелде. Табиблар рәхмәткә һәм мактауга күмелеп кенә яши дип уйлаучылар булса иде шунда! Уңышлары бөтенләй телгә алынмыйча, нәни генә кимчелек-хаталары да чебеннән фил ясагандай күпертеп күрсәтелгән менә шушындый җыелышларда сөйләгәннәрне ишетсәләр иде! Бу һөнәрнең авырлыгын, вакыт-вакыт йөрәкне талаганын аз булса да чамаларлар иде.

Сүзне, кафедра җитәкчесе буларак, Җәмилә Закировна йомгакларга тиеш иде. Ул, чак кына чайкалыбрак торып баскач, Зәйтүнәнең йөрәге тибүдән тукталгандай булды. Теге көнне, хастаханәдә икәүдән-икәү генә сөйләшкәннәрне кабатлар микәнни? Бар гаепне үз өстенә алыр, хезмәттәшләре, шәкертләре каршында мескен булып, көчсез булып басып торыр микәнни? Үз хәле хәл бит әле аның...

Зәйтүнә, үз егәрен остазына бирергә теләгәндәй, күзләрен зур ачып, алга таба авышты.

— Мин, комиссиянең эшен канәгатьләнерлек, дип бәяләргә тәкъдим итәм, — дип башлады Җәмилә Закировна. Тавышы калтырамый, тыныч, әмма әкрен иде, һәммәсе тынсыз калдылар. — Министрлыкка шушы фикеребезне җиткерсәк, дөрес булыр дип уйлыйм.

Йөзләр тагын да моңсуланды. Әгәр министрлыкта шушы фикер өстенлек алса, биредә җитәкчелек алышыначак, кемнәргәдер китәргә туры киләчәк. Үз теләге белән түгел, эшли белми, дигән тамга белән!

«Ни сөйли ул? — дип эчтән өзгәләнде Зәйтүнә. — Дөрес түгел бит бу! Гадел түгел!»

Җәмилә Закировна исә сынын турайтты, башын югары күтәрде дә тавышын күтәрә төшеп:

— Доцент Дәүләтшин комиссия җитәкчесе буларак үз вазифасын үтәгән, без моны танырга тиеш, — диде ул.— Аның алдына бер ананың үлү очрагын тикшерү бурычы куелган иде. Ул бу бурычны намус белән башкарган, безнең гаеп юклыкны ачыклаган. Бу — гадел нәтиҗә. Әмма доцент Дәүләтшин министрлык йөкләгән вазифа белән генә чикләнмәгән, үз өстенә өстәмә мәшәкать йөкләгән, безнең эшчәнлегебезне һәрьяктан җентекләп тикшергән. Энә күзеннән үткәргән, дияргә була. Моның өчен...

Зәйтүнәнең йөрәге дөпелдәгәне колагына бәргәндәй булды. «Моның өчен — нәрсә? Үпкәме? Шелтәме?»

— Моның өчен дә рәхмәт әйтик без аңа, — дип, нык тавыш белән дәвам итте Җәмилә Закировна. — Тагын да ачыграк итеп әйтсәк, Дәүләтшин клиниканың сәламәтлеген ныклап тикшергән, аның организмындагы какшаган урыннарны тапкан, анализлар ясаган, диагнозын куйган. Һәм операция ясарга тәкъдим иткән. Ул инде авыруны өстәлгә салдым дип уйлый һәм кулларын юа кебек.

Җитди тавыш белән әйтелгән, әмма һич көтелмәгән бу чагыштырудан башта һәммәсе сәерсенеп калдылар, аннары елмаешып, бер-берсенә карашып алдылар. Сулыш җиңеләеп китте, әйтерсең лә тынчу бүлмәнең тәрәзәләре ачылып, саф һава бәреп керде.

— Әйдәгез, без үзебезне консилиумда дип хис итик. Диагнозны тагын бер кат ачыклап, дәвалау чараларын бергәләп билгелик. Бала тапкан ананың үлемендә безнең гаеп юк. Бусы — иң мөһиме. Ә калганнары... Аларын операция ясап дәвалау шулай ук котылгысыз микән? Ә бәлки, терапевтик чаралар да ярдәм итәр?

— Профилактика да җитеп торыр! — диде залдан Виктор Ефимович.

Һәммәсенең җилкәсен баскан авыр йөкне алып ташладылармыни! Кайсылары бер-берсенең кулларын кысыштылар хәтта.

— Сыкраган урыннар биредә күпертеп күрсәтелде. Бу очракта шулай тиештер дә, чөнки алардан вакытында котылу чараларын күрергә кирәк. Авыруның гомуми хәленә килсәк... Сез ничек уйлыйсыз?

Җәмилә Закировна залга елмаеп карады.

Аңа шаулашып җавап бирделәр:

— Канәгатьләнерлек...

— Бер дә начар түгел!

— Яхшы!

— Баш кына исән булсын! — дип нокта куйгандай итте берсе.

Һәммәсе көлешеп алдылар. Чөнки соңгы сүзнең асыл мәгънәсен бик яхшы аңладылар.

Бер Дәүләтшинның гына чырае җитди калды, иреннәре кысылды. Ул үткен күзләре белән залдагыларны сөзеп чыкты, дәшмәде. Һавасы сафланган мохиттә аның сүзләре кибәк кебек очып кына китәчәк, беркемнең дә колагына кермәячәк иде.

Әйе, тантана итәргә артык ашыккан икән доцент Дәүләтшин. Төркем алдыннан очкан кыр казы урынын аңа бирмәячәк иде әле.

...Җыелыштан чыкканда Зәйтүнәнең күңелен кайнар, йомшак томан мөлдерәмә тутырган кебек иде. Бик рәхәт тә, шул ук вакытта хәлне дә ала. Озакка сузылган киеренкелектән соң, кинәт куаныч килсә шушылай хәлсезләнә адәм баласы. Бер эшсез-гамьсез ял итәсе килә аның.

Тик андый мөмкинлек булмады. «Ашыгыч ярдәм» машинасы носилка белән кан эчендәге бер хатынны китерде. Фидая Галимовна белән Зәйтүнә кабаланып анализлар ясарга, кулларын юарга керештеләр, аннары ашыгып операция бүлмәсенә кереп киттеләр. Ярый өлгерделәр. Тагын ярты сәгатькә генә соңарсалар да, хатын күп кан югалтачак, аны коткарып калу икеле булачак иде...

Кичен клиникадан чыкканда, Зәйтүнәнең тез буыннары юньләп тотмый кебек иде. Бакча аша узгач, тукталып, бетон коймага сөялде дә, күзләрен йомып, салкын һаваны күкрәк тутырып сулады ул. Якында гына адымнар ишеткәч тә башын күтәрмәде. Тик адымнар туктады, кемдер аның беләгеннән тотып алды:

— Ни булды сезгә, доктор Зәйтүнә?

Мөдәррис икән. Зәйтүнә керфекләрен күтәрде. Егетнең йөзе борчулы иде.

— Авырыйсызмы әллә?

— Юк... Арыдым гына...

— Шундый хәлгә җитәргә ярыймыни?.. Хәлегезне күрүче юкмыни соң? Ә без сезгә һаман-һаман үз сырхауларыбызны ташыйбыз... Эгоистлар шул без...— дип сөйләнде Мөдәррис. Һәм Зәйтүнәне нык итеп беләгеннән тотып, машинасына таба алып китте.

— Хәзер илтеп куям... Өегездә дарулар бардыр бит?

Күптәннән мондый кайгыртуны тоймаган Зәйтүнә тулысынча аның ихтыярына бирелде. Һәм бу аңа бик тә, бик тә рәхәт иде...

Алар сөйләшмәделәр. Сүзләрнең кирәге юк, күңелләр бер-берсен җылыта иде. Күптәннән инде ныклы кулга таяна алмаган Зәйтүнә, янында аны чын күңелдән кызганучы, иңенә төшкән, күңелен изгән авырлыкларны бер селтәнүдә алып атып, шуның белән үзен бәхетле сизгән берәү булганын тоеп, чын хатын-кызларча үзенең көчсезлегеннән тәм таба иде.

Ул шушы татлы томан эчендә, йөзендә елмаю саклаган хәлдә яслегә барып җитте, анда кереп, Тимербулатны киендерде. Ишектән чыгуга, Мөдәррис баланы аның кулыннан алды.

Өй каршына кайтып туктагач, машинадан төшкәндә, Зәйтүнә күтәрелеп карамады, тәрәзәдә ут барын-югын тикшереп тормады. Ул кайтканда өйнең караңгы булуына, Әнвәрнең өйдә юклыгына күптән күнегелгән иде.

Баскычтан Мөдәррис бер кулына Тимербулатны күтәреп, икенчесе белән Зәйтүнәне беләгеннән тотып алып менде. Аның бармакларыннан тамырларга сулкылдап кайнар агым үтеп керә, тик ул көчне арттырмый, киресенчә бөтен вөҗүдне йомшарта кебек.

Менә хәзер Зәйтүнә ишекне ачар да, өйгә керерләр... Тимербулатның өстен салдырырга кеше бар... Тик ачкыч кына табылмый, сумканың кайсы кесәсенә салынганы истән чыккан...

Шул вакыт ишек кинәт ачылып китте, бусагада Әнвәр күренде. Тәрәзәдән карап торган булса кирәк, ишек төбендәгеләр аңнарына килергә дә өлгермәделәр, ул Тимербулатны Мөдәррис кочагыннан суырып алды, икенче кулы белән Зәйтүнәне җилкәсеннән тотты да көч белән эчкә тартты һәм шарт итеп ишекне ябып куйды.

Әллә сугып җибәрә инде? Ихтыярсыздан Зәйтүнәнең муены җыерылды.

Әмма Әнвәрнең йөзе ачулы булудан бигрәк борчулы иде.

— Нәрсә булды? Рәтләп атлый да алмыйсың, машинадан күтәреп диярлек чыгардылар. Йөзең качкан... Кая, пальтоңны салдырам...

Тик Зәйтүнә бар булган көче белән читкә этәрде:

— Баланы чишендер әнә... Ә миңа кагылма. Орынасы булма миңа!

Бу минутта ят иде бу кеше аңа, чит иде! Үз дигәне ишек артында калды...

Әллә борылып чыгаргамы? Ләкин бала... Әнисен итәгеннән тарткалап, аякка уралган бала...

Зәйтүнә киемнәрен салды да, сынын туры тотарга тырышып, бүлмәгә узды.

***

Шул көннән соң Әнвәр эштән туры өйгә кайта, баланы да яследән ала торган булды. Үзең сулга йөрү бер хәл, ә менә хатынына кул сузсалар, бөтенләй башка икән! Ир булган кешенең ирлегенә бигрәк каты бәрә икән бу. Хәтта үз күңелең башкада булса да. Әнвәрнең күңелендә: «Тимә! Минеке!» — дип, милек иясенә хас тойгы уянды.

Зәйтүнәнең исә карашы салкын, йөзе кырыс калды, бөтен кыяфәте белән ул гүяки: «Орынасы булма!» — дип кисәтә иде.

Аралар шундый тотрыксыз хәлдә тагын берничә көн үтте.

Кайсы якка булса да авышу өчен берәр этәргеч, кечкенә генә сәбәп, көтелмәгән вакыйга да җитәчәк иде. Әлбәттә инде, андый вакыйга озак көттермәде. Аның беренче хәбәре телефон аша килеп иреште.

Трубканы гадәттәгечә Әнвәр күтәрде. Бәлки, эштән шалтыраталардыр? Юк икән.

— Хәерле кичләр, — диде ят ир тавышы. — Сез Әнвәрме?

— Әнвәр. Ә сез кем?

Үзе дә сизмәстән тавышы артык төксе чыкты. Кем булыр бу? Теге кызыл «Москвич»ның хуҗасымы әллә?..

Мизгел эчендә Әнвәрнең башыннан ут өермәседәй уйлар дулап узды.

— Ни кирәк? — диде ул, карлыккан тавыш белән.

— Гафу итегез, вакытсыз борчыдым, ахрысы, — диде ир кеше. Тавышыннан елмайганы сизелде. — Наил исемле абыегыз мин, Зәйтүнәнең хезмәттәше. Бергә эшлибез.

— Хәзер үзенә бирәм, — диде Әнвәр, йомшый төшеп.

— Туктагыз әле, минем сүзем сезгә иде.

— Ни турында?

Әнвәр зиһенен тупларга тырышты. «Саташам бугай инде, — дип уйлады ул. — Кем инде сөяркәсенең иренә шалтыратсын? Андый чакта кая качарга белмәссең... Ничек мин бу абыйның тавышын танымадым соң әле?.. Күз күргән кеше ләбаса... Телефоннан сөйләшкән юк иде шул...»

Ә трубкадан колакка ягымлы тавыш агыла иде.

— Без сезне шимбә көнне кунакка чакырабыз. Көмеш туебызга. Минем хатын сезнең җәмәгатегез белән бик дус бит. Килми калсагыз, туебызның яме кимиячәк. Үпкәлим килмәсәләр, ди әнә Сөембикә апагыз. Шимбә көнне, кичке алтыда. Соңга кала күрмәгез! Чакырган кунагың килмәсә, шуннан авыр хәл юк, диләр. Туебызны хөрмәт итми калмассыз, иншалла!

— Әлбәттә, әлбәттә,— дип бытылдады Әнвәр, чакырудан бигрәк соңгы җөмләне күздә тотып.

— Көтәбез!

Трубканы куйгач, Әнвәр диванда китап тотып утырган Зәйтүнәгә:

— Шимбә көнне көмеш туйга чакыралар, — диде.

— Беләм.

— Белгәч, нәрсәгә шалтырата?

— Тәртибе шундый. Гаилә башлыгының үзен зурлап чакыру тиеш дип уйлыйлар.

— Ә мин бармасам?

— Үзеңә кара.— Зәйтүнә бераз тынып торды да, китабыннан башын күтәрми генә: — Бу инде кешенең үз-үзенә ихтирамыннан тора, — дип өстәп куйды.

Һәм янә китабына төртелде. «Бармасам, үз-үземне хөрмәт итмәгән булып чыгам икән, янәсе, — дип уйлады Әнвәр. — Анысы бер хәл. Өйдә калсам, тәрәзәгә карап, хатынны кызыл «Москвич» белән китереп куйганнарын көтеп торырмынмы?»

Юк инде, бусы бүтән булмас!

...Кунакка бару бер хәл, анда барырга әзерләнү үзе үк уй-тойгыларны тыныч, якты эзгә сала бит ул. Монда да шулайрак булды. Тимербулатны күршеләргә калдырып, берсе чәчәк бәйләме, икенчесе ал тасма белән әйләндергән бүләк тартмасы күтәреп, ярым караңгы урам буйлап барганда, арттан бер хатын-кызның, кызыгып:

— Кунакка баралар! — дигәне ишетелеп калды.

Олы бүлмәнең буеннан-буена сузылган өстәлләр затлы савыт-сабадан, сый-нигъмәттән сыгылып тора, диярлек була иде. Бәллүр савытларда йөзем-әфлисун, конфетлар, һәммәсе бериш бизәкле тәлинкәләрдә ризыклар, кыйммәтле графиннарда эчемлекләр, көмеш кашык-чәнечке — барысы да бәллүр люстрадан сибелгән яктылыкта җемелди, балкый.

— Ай-һай табынны мул әзерләгәнсез, савыт-сабагыз да бигрәк затлы икән, — диде Зәйтүнә, хатын-кызларча кызыгып. Аларның өендә очраклы рәвештә урык-сурык алынган савыт-саба гына иде шул.

— Хәзинәдә бары инде, бүгенгә дип махсус алган түгел,— диде Сөембикә. — Бергә гомер иткәндә дөнья малы күп җыела ул. Бу вазаларны туебызга бүләк иткәннәр иде, көмеш кашыкларны өй котлап бирделәр... Менә күрерсез, үзегезнең көмеш туегызга моннан кәттәләрен куярсыз әле!

Соңгысын әйткәндә, Сөембикә Әнвәргә карап мәгънәле елмаеп куйды. Зәйтүнә исә дивар буендагы пыяла шкаф киштәләрендә балкып торган бәллүр һәм фарфор савыт-сабага сокланып карап тора иде. «Бергә яшәсәң, хәзинәләр менә шушылай җыела икән бит...»

Ул бу уен киная белән генә Әнвәргә белгертмәкче иде, тик тегесе аңа илтифат бирмәде. Чөнки йотылып башка тарафка текәлгән, йөзе ничектер суырылып та киткән, алланып та чыккан иде. Ә анда, ачык ишек бусагасында, Лариса басып тора иде. Әйе, бар карашларны үзенә җәлеп итәрлек иде шул ул. Атаклы артистлар, рәссамнар, музыкантлар залга шулай һәммәсен сискәндереп килеп керә. Ишек яңаклары арасында ул рамга алынган портретка охшап китте. Әйтерсең лә рәссам аны бик ачык буяулар белән ясаган: озын итәкле зәңгәр ефәк күлмәк, куе җирән бөдрәләр, кып-кызыл иреннәр, җем-җем иткән алкалар һәм муенса. Менә ул шат елмаеп, һәммәсен кычкырып сәламләп эчкә атлады, итәге биленә, аякларына сыланып, сылу гәүдәсен чишендергәндәй итеп күрсәтте. Әнвәр, күзе чагылгандай, карашын аска төшерде.

Алдан уйлапмы, әллә күңеле сиземләпме, Наил Хәйдәрович кунакларны бик оста утыртты. Парлы кунак абруйлы — Зәйтүнәләр түргә чакырылды. Лариса исә ишек төбендәрәк калды, башкалар артында күзгә бик үк төртеп тормаслык булып, ишек янынарак урнашты.

Туй тиешле тәртип белән башланды һәм тигез-тату яши торган, мул тормышлы гаиләгә хас рух белән дәвам итте: чират белән тәбрикләү-котлау сүзләре әйтелде. Бәгъзеләре шигырь чыгарып килгән икән, шуны укыды. Шампанский чыжлады, бәллүр касәләр чыңлады. Юбилярлар ике ул үстергәннәр икән: өлкәне хәрби училище тәмамлаган, кечесе мәктәптә соңгы елын укый. Оялудан кызарынып чыккан егетләрне аягөсте бастырып мактадылар.

Каннар кызгач, тамак туйгач, әлбәттә инде җырга чират җитте. Нур өстенә нур дигәндәй, Наил Хәйдәрович гармунчы да икән әле. Өздереп авыл көйләрен уйнап җибәрде. Йөрәкләр җилкенде, авызлар ачылды. «Сарман»ны, «Шахта»ны җырлагач, тигез генә барган җирдән абына-сөртенә башлагандай булдылар: гармунчы әле бер көйне, әле икенчесен башлый, кушылмакчы булалар, тик сүзләрен белмиләр. Йөрәктә кайнаган хисләрне дәртле-моңлы җыр аша дөньяга сибәсе килә-ә, тик наданлык гаҗиз итә!

Сөембикә Зәйтүнә янына килде дә, иңнәренә кулын салып:

— Җырла әле, Зәйтүнә, — диде. — Син матур җырлыйсың.

Зәйтүнә аягүрә торып басты. Бар карашлар аңа төбәлде, башкалар артыннан җирән баш та сузылды. Зәйтүнә үзен читтән күргәндәй булды. Аның өстендә туена теккән ак ефәк күлмәк иде. Тантаналылыгын киметү, бераз гадиләштерү өчен, Зәйтүнә аның түшенә һәм җиңенә кызыллы-зәңгәрле чигү салган иде. Андыйларны авыл кызлары яратып кия. Сары чәчен шома итеп тарап, баш артына җыеп куйганга, ул тагын да гадирәк тоеладыр...

Ул башын бераз артка ташлады да, каядыр ишек өстенә, ә бәлки, үзе генә күргән бер ноктага төбәлеп, йөрәк очыннан өзеп, әкрен тавыш белән башлап җибәрде:

Шам-шәриф дигән калада, дусларым,
Кич ахшамсыз капкалар ябылмый...

Наил Хәйдәровичның җитез бармаклары чак ишетелерлек итеп кенә тальян телләренә орынды, тик ул әллә җырлаучының тавышына туры китерә алмады, әллә гармун кушылуны бик үк кирәк түгелдер дип уйлады, тынды. Бүлмәдә күкрәк түреннән бөркелеп чыккан моң гына калды.

Узган гомер белән калган хәтер
Сатып алыйм дисәң дә табылмый

...Калган хәтер... табылмый... табылмый...

Җырчы һөнәренә махсус өйрәнмәгән, тыңлаучыларның күңел кылларын тибрәндерергә осталыгын чарламаган кеше, мөгаен, гомерендә бары бер генә тапкыр шушылай үзәк өзгеч итеп җырлый аладыр. Ул һичкемне күрми, гүяки бүлмә бөтенләй бушап калган. Моңлы көйне фәкать үзе өчен генә сузадыр шикелле. Ләкин юк... үзе өчен генә түгел. Көй-моңга төреп, зарларын берәүгә сөйли ул. Һәм элегрәк сүз белән аңлата алмаганнарын менә хәзер җыр аша ирештерә алганын тоя.

Аның җырлаганын күп тапкырлар тыңлаганы бар Әнвәрнең, әмма мондыен ишеткәне юк иде әле. Моң аның күңел бикләрен чишеп, ябык капкаларын ачып җибәрде дә саф җил, нур булып бәреп кергәндәй тоелды. Һәм бөтен дөньяны оныттырды. Кеше тулы бүлмәдә алар икәүдән-икәү генә калган кебек булдылар. Җирән бөдрәләр астыннан утлы ук булып төбәлгән караш та Әнвәргә килеп ирешмәде.

Менә җыр тәмамланды. Һәммәсе дә бу минутта ниндидер серле вакыйга, үзгәреш булганын тоеп, тел тибрәтергә кыймый утырдылар.

Ниһаять, нечкә сынлы яшь бер хатын торып басты:

— Бигрәк моңлы җырлыйсыз, Зәйтүнә Мәҗитовна! — диде ул, хисләнүдән күз яшьләрен сөртеп. — Әллә ничек булып китте... Сездән мондыйны көтмәгән идем... Чөнки сез бәхетлеләрнең бәхетлесе бит, Зәйтүнә Мәҗитовна! Башкаларга да бәхет өләшүче бит сез! Миңа да ана булу бәхете бирдегез! Сез булмасагыз, минем улым, Шамилем, дөньяга килмәгән дә булыр иде! Күпләр мең-мең рәхмәт укый сезгә!

Һәммәсе җанланып китте. Зәйтүнә хөрмәтенә, сәламәтлек, гаилә иминлеге теләп, тост күтәрделәр. Бүлмә күңелле гөрелте белән тулды.

Зәйтүнәдән соң башка җыр сузып җибәрү мөмкин түгел кебек иде. Наил Хәйдәрович кунакларны күрше бүлмәгә әйдәкләде. Анысын да туйга әзерләгәннәр — Яңа ел кичәсенә бизәгәндәй иткәннәр: түшәм астыннан сузылган бауларга ал, кызыл, зәңгәр лампочкалар тезелгән, өске ут сүндерелгәнгә, серле бер мохит хасил булган иде.

Хуҗаларның өлкән улы магнитоланы тоташтырды. Карлыккан тамаклы бер ир кеше тавышы кискен ритмлы көйгә җырлап җибәрде. Аның сүзләре аңлашылмый, әмма дәрте турыдан-туры кан тамырларына агылып керә иде шикелле.

Башкалар кыймыйчарак торганда, уртага Лариса чыгып басты.

Әгәр дә без, дәрья салкынныннан туеп, кайнар канлы җир егетенең көйдергеч назына сусаган су кызын күз алдына китерергә теләсәк, бу минутта Лариса нәкъ менә шундый җан иясе иде. Төсле

лампочкаларның тылсымлы яктысында гүзәллек, сөю һәм ялвару төене булып бөтерелде ул. Аның күлмәге дә тукыма гына түгел, ә бәлки, гәүдәсе буйлап аккан су агымы булып күренә, сыгылмалы тәненең һәр хәрәкәте күзне алырга ирек бирми, ымсындыра, мавыктыра, үз янына чакыра иде. Бию аның хисләрен әйтеп бирү чарасы, күзгә күренмәс, әмма эләктереп алып, котылу юлын калдырмый торган җәтмәсе иде. Табындагы татлы шәраблардан да татлы иде аның тәненең борылышлары. Һәммәсе керфек тә какмый аңа төбәлгәннәр, Әнвәр исә бөтенләй тынсыз калган иде. Бу минутта ул күзне адаштыргыч яктылыкта җилпенгән нечкә беләкләрнең кайнар тыгызлыгын, боргаланган гәүдәнең эссесен, тыгыз иреннәрнең сызландырып үбүен өр-яңадан тойгандай булды. Менә ул куллар аңа таба җилпенде, сын болайга таба авышты. Әнвәр сискәнеп китте: хәзер, менә хәзер бу нәфис куллар аның иңнәренә килеп куначак, озын, кызыл тырнаклы бармаклары каты итеп эләктереп алачак һәм үзе белән уртага тартачак. Сыгылмалы гәүдә аның бөтен тәненә сарылачак, ихтыярсыз итеп үзе белән бергә боргаландырачак, тәмам әвәрә итеп, бу тамашаны күзәтеп торучыларның һәммәсенә, шул исәптән чигешле ак күлмәк кигән затка да: «Ул минеке! Минеке!» — дип, хәрәкәтләре белән, тантаналы карашы белән игълан итәчәк. Һәм барысы да аның бу ярышта җиңгәненә шаһит булып басып торачак. Аннан котылу чарасы юк кебек иде.

Гади бию генә түгел иде бу, гыйшык утында янган тәннең үз бәхете өчен көрәшүе иде.

Хисләр ташкыны хәнҗәр булып Әнвәрнең йөрәгенең уртасыннан сызып куйгандай итте: әле генә күрше бүлмәдә яңгыраган җыр бер мизгелгә тагын ишетелеп куйгандай булды. Җанның күпме әрнүе сыйган иде анда! Аның өчен әрнүе...

Әнвәр үзенә сузылган кулларны күрмәс өчен күзләрен йомып, башын читкә борды да артка чигенде. Коридорга ук чыгып китте. Һәм күрше бүлмәнең ишек яңагына сөялгән ак сынны күреп алды. Көндәшенең кыланмышларына түзә алмаган, бирегә үк чыккан. Әнвәрне кызгану тойгысы биләп алды. Таныш хис, Зәйтүнәне самолетка утыртып җибәргәч һәм аның озак кына вакыт очкыч канатыннан аерылмыйча торганын күргәндә кичерелгән тойгы иде бу.

— Әйдә, кайтыйк әле без, — дип, аның хәлсез салынып торган кулыннан тотып алды ул. — Инглизләрчә, сиздерми генә.

Әмма шым гына киенеп чыгып китә алмадылар, хуҗабикә мең мәшәкать арасында аларны күздән ычкындырмаган икән, янга чыгып басты.

— Бигрәк ямьле сездә, кызыгырлык итеп яшисез, — диде аңа Зәйтүнә.

— Көн дә бәйрәм, көн дә туй түгел инде бездә дә, төрле чак була, — диде Сөембикә.— Гаеп-кыегын күрмичә уздырып җибәрергә тырышасың, сөенечләрен зурлап кабул итәсең. Шунсыз рәхәт күрәм димә.

Һәм мәгънәле көлемсерәп куйды.

Рәхмәтләр әйтеп, саубуллашып урамга чыккач та, такси машинасында кайтканда да алар дәшешмәделәр. Зәйтүнә улын күршедән алып чыгып, көйләп-җайлап урынына яткырган арада, Әнвәр урынны җәеп, ике мендәрне янәшә салган иде инде.

Өске утны яндырып тормадылар, торшер серле яктылыгын үз тирәсенә генә сибә иде. Алай да Зәйтүнә ире алдында чишенергә яхшысынмады, соңгы вакытта күнегелгән гадәт буенча өстен ванна бүлмәсенә кереп алыштырды. Менә ул итәге идәнгә тиеп торган төнге күлмәктән бүлмәгә керде, караватта яткан ире янына килеп басты. Алар арасы бер адым, ләкин анда соңгы айларда тирәнәя барган чоңгыл бар иде шикелле. Аның төпсезлегеннән боз салкыны күтәрелеп тәнне куырылдыра иде кебек. Ул җилне куарга теләгәндәй, Әнвәр сак кына кулын сузды. Бармаклары тәнгә тимәде, тукымага гына орынды. Алар җавап көтә иде...

Зәйтүнә үзен янә самолет канатына чыгып баскандай хис итте. Аста — упкын, колакта — җил шавы, шул шау аша катгый, таләпчән боерык ишетелә: «Сикер! Сикер!» Тик күңел түрендә төерләнгән үпкә-рәнҗүләр тимер тотка булып кулларны үзенә ябыштырган. «Оныт үпкәләреңне, кичер саксызлык белән әйтелгән сүзләрне, артта калдыр һәммәсен. Сикер! Арагыздагы упкын аша сикер!» Менә күлмәк аша таныш, бик тә якын, кадерле бармакларның җылысы үтеп кергәндәй булды, Әнвәрнең күзләреннән таныш яктылык — кояш кыйпылчыгы булып уйнаган нур бөркелде. Зәйтүнә алгарак авышты. Әнвәрнең кайнар бармаклары аның ялангач беләгенә орынды, хатынның бөтен тәне аңа тетрәнеп җавап бирде...

...Әнисе Зәйтүнәгә шундый бер кыйсса сөйләгән иде. Бер әүлия ике кызга бер алманы урталай бүлеп ашаткан да: «Берегез ир бала табар, икенчегез — кыз бала, үскәч алар бер-берсенә гашыйк булырлар, башканы сөя алмаслар»,— дигән, имеш. Бу кызлардан Таһир белән Зөһрә туган. Бер алмадан яратылганга, алар бер-берсеннән башка яши алмаганнар икән дә инде.

Таһир белән Зөһрә генә шундыймыни? Асылда без беребез дә бөтен түгел, ярты гына! Тик күпләр үзенең яртысын гомер буе эзләп тә тапмыйлар. Ә бәлки, тапкач та ябыша-берегә алмыйлар. Анысының да хикмәтләре күп шул аның!

Зәйтүнә дә үзенең Әнвәр белән бербөтен икәнлеген шушы төндә генә беренче тапкыр аңлады. Һәм беренче мәртәбә шушыны аңлаудан туган бәхетне татыды. Бу гөнаһлы җирдә адәм балаларына тату мөмкин булган тойгыларның иң көчлесе, ләззәтлесе иде бу.

***

Әле кайчан гына кыш иде, әле кайчан гына Динә белән Мөдәррис бала тудыру йортыннан, калын юрганга төреп, зәңгәр тасма белән уралган сабыйны алып киткәннәр иде.

Әллә кай арада яз җитте, клиника каршындагы бакчада өрәңгеләр, каеннар яшелгә төренде. Күңелне алгысытып ботакларда сыерчыклар сайраша. Аларны күргәч, бакча юлыннан узып барган Зәйтүнә балачактан истә калган такмакны хәтеренә төшерде: «Сыерчык, сыерчык! Чирем, чык! Чирем, чык!» Язын килгән беренче сырчыкларны күргәч, шушылай дип такмаклый-такмаклый җиргә ятып аунасаң, ел әйләнәсендә чирләмәячәксең, имеш. Хәзер бераз соңрак кебек инде, ә шулай да шартына җиткереп аунасаң, барыбер дә шифасы тияр, бәлки?

Күтәрелеп кенә килгән йомшак чирәмдә тәгәрәү иллә дә рәхәт булыр кебек...

Кинәт биткә җиләс җил бәргәндәй булды. Эре адымнар белән бакчага кереп килгән берәү ягыннан исте ул. Хөсәен иде бу. Күрешми торган ике ел эчендә тагын да ныграк үсеп киткән кебек. Һәрхәлдә, ныгыган, җитлеккән.

— Синең йөзеңә багана башына караган кебек кararга туры килә хәзер, — диде Зәйтүнә, аның белән кул бирешеп күрешкәч.

— Ә син тагын да чибәрләнеп киткәнсең. Рәхәт яшисеңдер, мөгаен.

Хөсәеннең бу сүзләрендә яшерен киная чалынган кебек тоелса да, Зәйтүнә моны аңламаганга салышты, хәл-әхвәл сорашу башлады. Хөсәен, кан составындагы үзгәрешләргә карап, яралы кешенең күпме кан югалтканын билгеләү ысулын тикшерә икән. Күзәтүләренең нәтиҗәсен хирургларга җибәргән булган икән дә, бу мәсьәләнең гинекологлар өчен дә мөһим икәнлеген исәпкә алып, хирурглар аның хезмәтен профессор Ильясова игътибарына тәкъдим иткәннәр. Хөсәеннең Җәмилә Закировна янына килеп барышы икән.

Алар икесе дә эш турында гына сөйләшергә тырышалар, әмма икесенең дә язмышына күләгәсен салган берәү хакында дәшми калу мөмкин түгел иде. Тик Хөсәен аның исемен телгә алырга ашыкмады. Зәйтүнә иң мөһим сүзне үзе башларга тиешлекне аңлады.

— Син кайтканны ишетмәгән идем әле мин, — диде. — Лариса күрше кафедрага, Дәүләтшин кул астына күчкәннән бирле аның белән сирәк күрешелә.

Хөсәеннең йөзе үзгәреп китте — ул барысын да белә иде. Әмма бу хакта сүз куертып, үзенең дә, Зәйтүнәнең дә йөрәк ярасын кузгатырга теләмәде.

— Безнең дә юллар аерылды бит инде, — диде йомшак кына.

— Нишләп алай? Җәмилә Закировна әйтә, гаиләдә бер-береңнең гөнаһларын гафу итә белергә кирәк, ди.

— Гафу итүнең дә чиге була шул. Ахыр чиктә ниндидер бер киртәгә димме, бусагагамы килеп терәләсең икән. Шуны атлап үтмичә туктап калсаң, борылып үткәннәргә кайтып була әле. Әмма атлап чыксаң, бетте. Кире борылу юк. Мин ул бусага аша күптән атлап чыктым инде.

Аның тавышындагы салкынлык күңелне өшетеп җибәргәндәй итте, йөзендәге кырыслык үгет-нәсихәткә урын калдырмады.

...Кичен Зәйтүнә бу сөйләшү хакында Әнвәргә әйтергә дип авызын ачкач, туктап калды. Әти белән бәби бер-берсе белән бик мавыгышканнар, Әнвәр Тимербулатны бастырып кулларыннан тоткан да: «Күккү-ү, чыпчык! Тәрәзәдән очып чык! Һоп!» — дип малайны очыртып күтәреп җибәрә, тегесе тешләрен җемелдәтеп кет-кет көлә иде. Шушы минутта Ларисаны искә төшереп, ата белән баланың бәхетле минутларын юкка чыгарыргамы? Аны гына аңларга Зәйтүнәнең акылы җитә әле. Үз вакытында ул да, Хөсәен кебек үк, үткәннәрне киләчәктән котылгысыз аерып куя торган аяусыз бусага янына килеп терәлгән иде. Тик аны атлап чыкмыйча тукталып калырга, үткәннәренә борылып кararга көче җитте. Ул чактагы гамәлләре дөрес булганлыгы менә хәзер расланды.

Баланы яткызып, яшел абажурлы лампа яктысына утыргач, Хөсәен хакында сүз кузгату тәрәзәне ачып, җылы өйгә бозлы җил кертү кебек булыр сыман тоелды.

Әнвәр өстәлгә алсу кәгазен җәеп, готовальнясын ачып куйды. Кызыл бәрхет өстендә ак җәзбә-каләмнәр елкылдап ята. Әнвәр яңа эшкә тотынды — ул хәзер элеваторда баш инженер. Ашлык бушату өчен яңа җайланма ясамакчы. Капчыкларны машиналардан складка шудырып кына алып керсен дә үзе үк тәртип белән өеп тә куя торган булсын. Капчыклар кеше сыртына менмәсен, алар кулыннан үтмәсен. Югыйсә йөк төяүчеләрнең хезмәте ифрат авыр. «Карап торырга кызганыч!» — ди ул үзе. Ә теплицада эшләр ансыз да көйле бара икән инде.

Зәйтүнә, китабын алып, өстәлнең икенче ягына килеп утырды да:

— Әтисе, синең бу машинаң эшли башлагач, баербыз инде без, әйеме? — диде.

— Уйлап чыгаручыларның бездә кайчан баеганы бар? Ачышлар аларны бөлдергән генә. Бөлдергән дә көлдергән. Әле дә ярый безнең заманда «молодец» дип аркадан кагып куялар. Ә элегрәк күбесенең башын төрмәдә череткәннәр. Шунысыннан азат булганга куанырмын.

Алар көлешәләр, аннары берсе — сызымына, икенчесе китабына иелә.

Шәһәр өстенә тыныч төннең зәңгәрсу-кара канаты җәелгән. Ләкин караңгылыкка батыра алмаган: урамнарда, бакчаларда, юлларда, тәрәзәләрдә балкып утлар яна. Узган буыннарның йөрәк җылысыннан, акыл яктысыннан кабынган, кул көченнән яралган ул утлар җирдә бүген яшәүчеләрнең тормышын яктырта, җылыта.

Якты тәрәзәләрнең берсе артында янәшә утырган икәү ул утларны тагын да күбрәк кабызу, яктырак яндыру турында хыялланалар иде.

1985 – 2006.

Автор турында

Мәдинә Габделхак кызы Маликова 1935 елның 5 августында Татарстан АССРның Сарман районы Мортыш Тамагы авылында колхозчы гаиләсендә туган. Үз авылларында җидееллык мәктәпне тәмамлаганнан соң, 1950—1954 елларда — Минзәлә педагогия училищесында, аннары Казан педагогия институтында укый. Институтның тарих-филология факультетын кызыл диплом белән тәмамлап, 1959—1964 елларда «Чаян» журналында — корректор, 1964 елдан «Азат хатын» журналында — әдәби хезмәткәр, ә 1978 елдан 1987 елгача журналның җаваплы секретаре булып эшли. 1993 елдан алып — Бөтентатар «Кызыл Ай» җәмгыятенең президенты.

Узган гасырның җитмешенче-сиксәненче елларында «Азат хатын» журналы бөтен илгә бик зур тираж белән — 408000 данә тарала, анда эшләүче журналистлар республика һәм ил буйлап күп йөриләр, төрле һөнәр ияләре белән аралашалар, гажәеп язмышлы кешеләр белән очрашалар. Болар барысы да аларның сәләтен ачу өчен киң мөмкинлекләр тудыра. Мәдинә Маликованың очерклары, сәнгатькә, әхлак темаларына багышланган язмалары киң яңгыраш таба, журналда басылган беренче хикәяләре, повестьлары укучылар тарафыннан яратып кабул ителә.

1967 елда басылып чыккан «Юлдашлар» исемле беренче хикәяләр җыентыгында ук ул укучы алдына тирән әхлакый мәсьәләләрне җитди итеп куярга омтылуы белән игътибарны җәлеп итте. Һәм бу омтылыш аның озын гомерле иҗади эшчәнлегендә төп сыйфат булып калды. Авторның «Кар сулары», «Сары тюльпаннар», «Көндәшләр», «Ай сүрелгән чак иде», «Узма, гомер!» һәм башка хикәяләре моның ачык мисалы булып тора.

Язучының «Казан каласы — таш кала» (1967), «Кояш күпере» (1973), «Янар таулар яктысында» (1977) повестьлары, «Шәфкать» (1985), «Басып сайрар талы бар» (1987), «Фидая» (1990) романнары шәһәр һәм авыл интеллигенциясе —инженерлар, архитекторлар, рәссамнар, врачлар, артистлар тормышына багышлап язылганнар.

Халык язучысы Аяз Гыйләҗев үзенең бер чыгышында Мәдинә Маликованы «зыялы язучы» дип атаган иде. Чыннан да, зыялылык язучы иҗатының бөтен рухында чагыла. Ул, заман тормышының төрле өлкәләренә мөрәҗәгать итеп, геройларының рухи дөньясын бөтен тирәнлеге белән яктыртырга, кешеләр арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләрнең нечкәлекләрен ачарга омтыла, яшәешнең мәгънәсен яхшылыкка, матурлыкка хезмәт итүдә күрә. Мәдинә Маликова сюжетны оста, мавыктыргыч итеп кора белә, вакыйгаларны йөрәк аша үткәреп, укучының күңел кылларын тибрәндерерлек итеп тасвирлый.

М.Маликова детектив жанрында да уңышлы эшли. Аның «Хөкем» (1969), «Августның бер кичендә» (1970) , «Адашканга юл кайда?» (1971) исемле мажаралы повестьлары, жанр хасияте таләп иткәнчә, киреңке вакыйга-сюжетка корылган һәм укучылар тарафыннан яратып укыла.

М.Маликова үзенең әсәрләрендә башлыча хәзерге заман тормышын тасвирлый һәм бүген дә шушы юнәлештә иҗат итә. Аның «Алтын ятьмә» повесте (2001), «Кыргый дивизия» , «Берәгәйле бәрәңге» һәм башка хикәяләре (2001), «Өермә» исемле детектив романы (2002) һәм «Чәчкә балы» (2003 — 2004) «Югалган якутлар» (2003) исемле повестьлары, «Кызыл гөл» романы (2005) гасырлар алышынган чорда булган кискен үзгәрешләрнең кеше язмышына, аның рухына һәм үз-үзен тотышына йогынтысын тасвирлый.

Мәдинә Маликова драматургиягә дә кызыклы гына өлеш кертте. Аның «Оҗмах балалары» (1989) исемле драмасы Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә куелды, «Йөрәк ничек түзсен» (1989), «Моңнар төште башыма» (1992), «Синең өчен үзем үләрмен» (1994) исемле драма әсәрләре Минзәлә һәм Әлмәт театры сәхнәләрендә зур уңыш белән барды.

Мәдинә Маликова Татарстанның һәм Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре, журналистларның Хөсәен Ямашев исемендәге республика премиясе лауреаты (1980).

Мәдинә Маликова 1972 елдан Язучылар союзы члены, 1974 елдан 1999 елгача Язучылар берлегенең идарә әгъзасы булып сайланды. 1989—1990 елларда Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең рәис урынбасары булып эшләде.

(Татарстан Язучылар берлегенең
белешмәләр китабыннан)

Эчтәлек

ТЫЛСЫМ .....

ШӘФКАТЬ .....

Автор турында .....

Литературно-художественное издание

Маликова *Мадина Габдулхаковна*

ОЧАРОВАНИЕ. МИЛОСЕРДИЕ

Казань. Татарское книжное издательство. 2007

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

Маликова *Мәдинә Габделхак кызы*

ТЫЛСЫМ. ШӘФКАТЬ

Мөхәррире *Ф.И.Фәтхетдинова*. Рәссамы *Р.Ф.Әхияров*. Бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*. Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *А.С.Газизҗанова*. Корректорлары *Л.З.Шиһапова, Р.Н.Нуруллина*. Оригинал-макеттан басарга кул куелды 27.12.2007. Форматы 84г108 1/32. Офсет кәгазе. «Futuris» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 19,32. Шартлы буяу-оттиск 19,74. Нәшер-хисап табагы 22,46. Тиражы 2500 д. Заказ С–1656. Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19. **http://tatkniga.ru e-mail: tki@tatkniga.ru.** Оригинал-макет Jahatтм программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ. 420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.